ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2003



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*Кабан күле буе һәм Крестовников фабрикасы*



*Мәрҗани урамы һәм Г. Камал театры бинасы*

Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.

*Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән*

# Казан утлары
# Qazan utları

2003

5

(967)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ һӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Туган йортта кабат туам мин... *Шигырьләр* ..... 5
Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Өзелгән өмет. *Повесть* ..... 10
Басыйр РӘФЫЙКОВ. Хәтер мизгелләре. *Шигырьләр* ..... 49
Рафаэль СИБАТ. Инабәт. *Фәлсәфи роман.* ..... 52
Рифә РАХМАН. Ялгышканмын... *Шигырьләр* ..... 108

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Айдар ХӘЛИМ. Кырымда күргәннәрем ..... 110

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тарихыбыз тулымы? *(«Татар әдәбияты тарихы»ның VI томы басылып чыгу уңаеннан)* ..... 126
Флүс ЛАТЫЙФИ. 2002 ел прозасына бер караш ..... 135

**ФӘН**

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Өч халыкның өч шагыйре ..... 141

**ХӘТЕР**

Розалина НУРУЛЛИНА. Томаннарга еллар күмелде ..... 150

**МӨДӘРРИС ВӘЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ**

Истәлекләр. Хатлар. Документлар ..... 165

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Дәррия РАМАЗАНОВА. Үзәктә—зур мәсьәлә ..... 173
Берлекнен яна әгъзалары ..... 183
«Казан утлары» архивыннан ..... 184
Безнең календарь ..... 179
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 186

**ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР**

Розалина ШАҺИЕВА. Ханнар хәзинәсе ядкаре ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Р. СИБАТ. Философский роман «Упование» *(окончание)*; повесть Г. ГАЛИЕВОЙ «Утраченные грезы»; стихи Г. МУРАТА, Б. РАФИКОВА, Р. РАХМАН.
«Публицистика»: А. ХАЛИМ. «Воспоминания о Крыме».
«Литературная критика»: разговор за круглым столом о VI томе истории татарской литературы; статья Ф. ЛАТЫФИ «Взгляд на прозу 2002 года».
«Наука»: статья Н. ХИСАМОВА «Три поэта трех народов».
«Память»: статья Р. НУРУЛЛИНА «Ностальгия о прошлом».
«Книжное обозрение»: Д. РАМАЗАНОВА. «Острая проблема».
«Юбилей»: статьи к 50 летию писателя Мударриса Валиева.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: походный серебрянный футляр для Корана, принадлежащий Ураз-Мухаммед хану; писатель Индус Сирматов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": R. SIBAT. Philosophical novel «Entreaty» *(ending)*, G. GALIEVA´S story «Losed dreams»; the verses of G. MURAT, B. RAFIKOV, R. RAKHMAN.
"Journalism": A. KHALIM «Recollections about Crim».
"Literary criticism": talk at the round table about VI th volume of history of tatar literature; F. LATYFI´S article «Look on prose of 2002 years».
"Science": N. KHISAMOV´S article «Three poets of three people».
"Memory": R. NURULLINA´S article «Nostalgia by the past».
"Books review": D. RAMAZANOVA «The acute problem».
"Jubilees": articles devoted to the 50th anniversary of writer Mudarris Valiev.
"Our calendar".
The diary of social and cultural life.
On our covers: Camp silver Koran´s case of Uras Muhammed khan; writer Indus Sirmatov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.04.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8031. Заказ Я—228
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.



## Газинур Морат

### ТУГАН ЙОРТТА КАБАТ ТУАМ МИН...

#### Татар

Идел-йортның нигезенә
Субай итеп кагылган ул.
Бу дөньяга тартар булып,
Татар булып танылган ул.

Татар булып яшәүләре
Бу дөньяда кыен шуңа.
Шуңамы ул, субай килеш,
Сукбай кебек кыенсына.

Кыенсына үткәненнән,
Үз-үзеннән кыенсына.
Даруын да, агуын да
Йорткән садак-кынысында.

Бала кебек көлемсерәп,
Дала яткан кочагында.
Ятка—дару, агасына
Агу биргән кайчагында.

Дәүләт арты дәүләт корган—
Булган шундый сәләте дә.
Төшенмәгән үзе ләкин
Дәүләт саклау сәнгатенә.

---

Газинур МОРАТ *(1959)—шагыйрь, публицист; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Мин дөньяны тыңлыйм», «Түбә», «Җәяүле кошлар» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Бүленгәнне бүре ашар,
Дия-дия бүленгән ул.
Типтәр булып, башкорт булып
Исән калган үлемнән ул.

Исән калган нугай булып,
Әйләнеп йә керәшенгә.
Бүленгән ул, бүлгәләнгән,
Инде вакыт берләшергә!

Акбүз, диеп, тулпар, диеп
Атаган ул чаптарын да.
Мишәр, әнә, лыхыр, дия
Безнең казан татарын да.

Ничә гасыр шайтани рух
Татар, диеп кыбырсына...
Бу дөньяда татар булып
Яшәүләре кыен шуңа!

## Тарих безгә сәер сер калдырган

Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер,
Кайсы чордан, кайсы еллардан
Киләдер ул сәер сүз-гыйбарә:
«Татар тугач, яһүд елаган».

Ник елаган? Ни сер посып яткан
Бу китаплы кавем кальбендә?
Кайчагында аңлау кирәктер ул
Дөнья тоткан халык хәлен дә.

Булган ансы, әйе, татарның да
Дөнья тоткан гаярь чаклары.
Дала түмгәгенә абынып ла
Билен сындырган шул чаптары.

Татарны да, әйе, сөргеннәргә
Сөргән баскын туган җиреннән.
Без дә, бәлки, үз-үзебезләрне
Кабат җиңәр өчен җиңелгән?

Татарның да, әйе, язмышлары
Кузлы Сагыш белән чигелгән.
Без дә, бәлки, асыл кальбемезгә
Кабат кайтыр өчен сибелгән?

Үткәннәрен эзләп табар халык
Киләчәккә кайтыр юллардан...
Тарих безгә сәер сер калдырган:
«Татар тугач, яһүд елаган».

## Кол булганчы...

Кол булганчы көлгә әйлән—
Ашларсың Туган җирне.

Көл булганчы гөлгә әйлән—
Ямьләрсең Туган илне.

Бәндәләрдән
мең бәлаләр
күрә-күрә
Сулкылдый Җир—
өянәкле
бәгыребез.
Сөйгәннәрнең
иренennән
аерылып,
Шул бәгырьне
бер үбәргә
әзерме без?

## Туган йортта балан җыйганда

*Тәлгәш-тәлгәш баланнар—*
*Күзгә учак кузыдыр...*

И гомерләр...
Туган йорттан читтә
Җылы эзләп узган гомерләр.
Дастаннардан килгән мосафирның
Башмагы күк тузган гомерләр.

И Туган йорт...
Акбүз биләвем син,
Кабык арбам,
Киндер бишегем!

Әткәм-әнкәм күңеледәй
Һәрчак
Ачык синең капка-ишегең.

Туган йортта һәр тупылга кардәш,
Һәрбер өянкегә туган мин.
Әнкәемә кайтып сыенам да
Туган йортта кабат туам мин.

Туган йортка кайтып дәваланам
Җирсү дигән сәер хастадан.
Сихәтләнгәч,
дәрвиш-мосафирдай,
Ник сәфәргә кабат ясканам?

Беләм, әйе, соңгы сәфәргәчә
Җылы эзләп йөдәр күңелем...
Туган йортта
күзге учакларның
Кайнар кузын алдым үрелеп...

## Төнге идиллия

Төн—гүяки арфа...
Һәрбер кылы
Ай нурыннан аның үрелгән.

Тынлык сонатасы аһәңенең
Шавы килә галәм түреннән.

Галәм түрләрендә шытып чыккан
Чәчкәләре җәннәт багының.
Без ауныйбыз шунда...
Арабызга
Тын соната керә агылып.

Җәннәт чәчкәләре безне күзли.
Диләр бугай: менә тамаша.
Синең гүзәллекне көйгә салып
Уйный арфа...
Күзләр камаша.

## Карт һәм чабак

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кабанкүлдәй кадим каегында
Йокымсырап ялгыз карт утыра.

Каек төбендәге күлдәвектә
Чәбәләнеп ята сыңар чабак.
Сыңар чабак—гүя соңгы өмет,
Сыңар чабак—гүя соңгы чара.

Чабак чаклы гына соңгы өмет
Бәргәләнеп ята күлдәвектә.
Казан казнасының алтыннарын
Юкка гына күлгә күммәдек лә?!

Хан йөзеген йоткан картлач чуртан
Капмый калмас кебек кармагына.
Су кызлары табып бирер төсле
Ханбикәнең алтын тарагын да.

Сөйрәп чыгарыр күк албастылар
Казаланган Казан байлыгын да...
Йокымсырап утыра карт шулай
Кабанкүлдәй кадим каегында.

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кала чыр-чуына оеп, ярда
Чабак көтеп әнчек эт утыра.

## Имла

Чөйләп язган балчык, ташка,
Ташлар исән һаман да.
Чөй язу булып эрегән
Тояк эзе Далада.

Иманына имам иткән
Аннан Коръән имласын.
Әлиф белән күккә язган,
Күктә тапкан кыйбласын.

Үле телнең имласын да
Ят итмәгән, күрәсең,—
Яңалифчә язмак булган
Үлемсезлек сүрәсен.

Әлифләре киселгән дә,
Хәлфәләре асылган.
Ярый әле өмет исән:
Кала—ташка басылган...

## Аччы, туташ, ишегеңне...

*Заманча вариация*

—Аччы, туташ, ишегеңне, мин керәем,
Керфегеңә куныш эрәем.
Сөю сүрәсенең аять-шәмаилен
Күңел түрләреңә эләем.

Аччы, туташ, кочагыңны, мин керәем,
Җиләк иренеңнән үбәем.
Башым куеп ак күбектәй күкрәгеңә,
Кочагыңда килеш үләем.

—Әллә шагыйрьме син, абзый кеше,—
Әҗерен соң күпме түләең?..

## Шахтер агай җыруы

Үтте гомер күмер чабып,
Чабалмадык атларда.
Газиз башлар читтә йөрде,
Ярлар калды ятларга.

Үтте гомер... бәхет эзләп,
Калды... өмет... аз гына.
Безнең бәхетне таш басты
Кара Дию базында.

Үтте гомер...
Тын кысыла,
Читләрдә ят—һава да.
Әй, җил,
Туган җир һавасын
Алып килче дәвага.

Әй, җил, безнең сәламнәрне
Илтче Туган илләргә.
Сызгырып уз аулыбыздан
«Шахта» дигән көйләргә.

Сыздырып уз...
Сызуларның
Үз сихәте бар аның.
Исләренә төшмәбезме
Ятка калган ярларның?..

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Гөлчәчәк Галиева

## ӨЗЕЛГӘН ӨМЕТ

ПОВЕСТЬ

*Гел янәшә йөри*
*Гөнаһ белән савап.*
*Бөтенесе өчен*
*Бирәсе бар җавап.*
Фәнис Яруллин

Үз-үзең белән көрәшүдән дә авыррак тагын ни бар икән бу дөньяда? Менә бүген дә, инде ничәнче тапкыр, Талия хәтта үз-үзен күрә алмас дәрәҗәгә җитеп, үтә каттый карарга килде. Ана әйтәсе үпкә сүзләрен тагын бер мәртәбә күңеленнән кичерде.

«Касыйм абый,—диячәк ул ана—инде күптәннән күңелемне бертуктаусыз борчып торган берничә соравыма сездән җавап ишетәсем килә. Яшьлегемнең иң гүзәл елларын, кыз баланың иң зур байлыгы саналган сафлыгымны сезгә бүләк итү бәрабәренә ни-нәрсәгә ирештем соң мин? Егерме сигез яшемә җитеп, шушы буй-сыным, чибәрлегем, булганлыгым белән ни ирем, ни балам... Минем дә, нәкъ сезнең хатыныгыз шикелле үк, хәләл җефетле булып, бала сөю ләззәтен татыйсым килә. Бу—минем сезгә әйтергә теләп тә, әйтергә кыймый йөргән күптәнге хыялларым. Киләчәктә мине ни көтә? Бер генә мәртәбә булса да уйлап караганыгыз бармы бу хакта? Һич юктыр, дип уйлыйм. Сезгә бит бары үз рәхәтегез генә кадерле. Ә мин... җүләр бит мин. Яшьлегемә, артык беркатлылыгыма күрәдер инде, шәһәрнең үзәгендә нинди матур ике бүлмәле, өстәвенә чит ил җиһазлары белән тулган фатирым бар, дип йөрдем. Бактың исә, алар барысы да «служебный» гына икән бит. Җитте, бик җитте...

Бүген үк бу кадерсез, минем өчен киләчәге өметсез булган мәхәббәткә нокта куябыз. Мине йә башка эшкә күчерәсез, йә һич югы яшем утызга житкәнче үз гаиләмне корып җибәрергә мөмкинлек бирәсез.

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА—*язучы; «Тулгак» китабы авторы. Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Мин бит авылга әнием янына да кайта алмыйм. Мәктәпне тәмамлаганга ...н ел тулган кичәбезгә дә кайта алмадым, оялдым. Сезнең сөяркәгез булып ...яшәвемне укытучыларым да белә икән. Житте, бик житте! Моннан ары... һәммәсе дә бетте»,—диячәк ул ана. Кырт кисеп, өздереп әйтәчәк!

Әмма дә, ни хикмәттер, эшкә килеп үзен күрүгә һәм аның наз тулы ...ягымлы тавышын ишетүгә, барлык үпкә сүзләре, әйтерсең лә, җилгә очалар иде...

Беркөнне, аны командировкага озаткач, Талия эштән иртәрәк китте. Ничектер шулай, тукталышта трамвай көтеп торганда, каршы яктан кемнеңдер үзенә текәлгән күз карашын абайлап алды. «Шул кадәрле дә таныш йөз, кем булыр икән бу?—дип уйлап кына өлгерде...

—Талия, әллә танымыйсың да инде?

—Үләм, Хәмит, син түгелме соң бу?

—Әйе, Талия, мин бу—мин! Тик үлә күрмә, күпме көттем мин бу очрашуны,—дип, Хәмит Талия каршысына үк килде, һәм:—Савап булсын, күрешик әле,—дип, кулларын сузды.

—И-и-и, Хәмит, үзгәрепләр дә карагансың инде, малай! Танырлык кынамы соң... нинди чибәр! Тәмам егетләр солтанына әйләнгәнсең бит, әй,—дип Талия аны кочаклап ук алды.—Каян килеп чыктың әле син монда? Бу якларда ни эш бетереп йөрисең? Мин сине Самарада яши дип ишеткән идем. Ашыкмасаң, әйдә, читкәрәк китеп, беразсөйләшик әле.

—Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, диләрме әле? Синең белән очрашуны, һич югында читтән генә булса да, үзенә бер туйганчы карап калсаңые, дип күпме еллар көттем бит мин. Узган елны мәктәптәге унеллыгыбызда күрешербез, дип тә өмет иттем. Никтер кайтмадың... Ә бүген менә көтмәгәндә, һич истә-оста югында... Кем уйлаган... Их, нигә бу очрашу моннан биш ел элек булмаган икән?

—Нишләп алай дисең әле, Хәмит?

Тегесе бу сорауны колак читеннән генә очыртып, туры килгәндә әйтеп калыйм инде дигәндәй, ничәмә еллар күңелендә йөрткән, әйтелми калган серләрен ачарга ашыкты:

—Мин бит, Талия, синең мәхәббәтеңне яулар өчен ниләр генә эшләмәдем. Сыеграк буй-сынымнан кимсенәсеңдер дип, спорт белән шөгыльләндем. Актык тиеннәремне түләп бассейнга йөрдем. Самара авиация институтының кичке бүлеген тәмамладым. Эшләгән заводымда танылган белгечкә әйләндем, конструкторлар бүлегенә мөдир итеп билгеләнүгә дә ирештем. Боларның барына да синең өчен, синең хакка тырыштым. Менә бит ул—саф мәхәббәтнең көче! Гәрчә синнән бернинди җылылык тоймасам да, киләчәктә үземне барыбер яраттыра алырмын дип ышандым. Ни генә булмасын, рәхмәтем зур сиңа, Талия. Бер кызык вакыйганы исенә төшерим әле. Хәтерлисең микән, чыгарылыш кичәсенә бер атна кала ничек итеп мине кимсеткәнеңне? Хәтта: «Хәзер үк якаңнан өстерәп әниең янына алып барам»,—дип янаганыңны? Шул сезнең күрше Сәлимгәрәй юньсезнең сүзен тыңлап кына хур булдым бит ул чакта. Ул миңа, сер итеп кенә, кызларның нинди егетләрне яратулары турында әйтте. Аерата безнең тәкәббер Талия кебекләре, дип тә җиббәрде. «Егетнең, ди, чут-чут кенә тәмәке, чут-чут кенә аракы исе килгәнен, чут-чут кенә нахал булганын яраталар алар»,—ди, бит малай. Мин, җүләр, шуңа ышанып, бабаиның тәмәкегә сасыган күлмәген эчтән киеп куйдым. Дөрес, бер илле грамм тирәсе «чеметеп» тә алдым. Синең клубтан кайтканыңны капка төбегездә көтеп тордым. Сәлимгәрәй киңәшен тотып, кисәк кенә үзеңне кочаклап алдым. Хәтерлисеңме? Аннары күкрәгенә үрелмәкче булдым. Чут-чут кенә нахал булам имеш... Шунда с-и-и-н... анысын үзең дә хәтерлисеңдер инде... Шундый итеп янагыма чалтыраттың, ярый, анысы черт с ним инде. Әмма шулчак нәфрәт тулы күз карашыңнан йөрәгемнең телгәләнеп киткәнен гомеремдә дә онытасым юк. Менә шуннан соң, «артык юаш шул мин»,—дип йөргән Хәмитең нишләде дип уйлыйсың?

Талия рәхәтләнеп көлә-көлә:

—Беләм инде, беләм... Сәлимгәрәйнең әнисе икенче көнне безнең

әнигә болай дип сөйләгән: «Төннә белән безгә, нигәдер, коточкыч ярсып Хәмит килеп тә керде, пrәме безнең алда, Сәлимгәрәйне кыйнарга да тотынды. Көчкә аерып алдык. Хәмитне әйтәм, чичти котырганые. Араларыннан нинди кара мәче үткәндер, шайтан белсен, ә ничек дусларые бит үзләре»,—ди икән.

—Әмма да дөрес сөйләгән икән Сатыйга апа, рәхмәт төшкере! Ни өчен кыйнаганымны аңладыңмы инде?

—Аңладым, Хәмит, хәтта кирәгеннән дә артык аңладым шикелле... Сине тыңлап бар дөньямны онытгым. Шушы кадәр матур итеп сөйләргә каян өйрәндең әле син, ә? Элек син минем янда бөтенләй телсез кала идең бит.

—Их, Талия, Талиякәй, артык яраттым шул мин сине, ә син артык горур булдың. Оялганмындыр, күрәсең. Әни дә мине кечерәк чагымда: «Бигрәк юаш шул син, балакаем, бу кадәрле дә үземә охшарсың икән»,— дип сөя иде. Авылыбызда ике Хәлимә булып, шуның берсе—безнең әни бит инде. Анның да кушаматы юаш Хәлимә бит. Тик менә соңгы вакытларда бавырына зарлана башлады әле. Хастаханәгә салмый булмас, ахры, ябыгып та китте. Карале, Талия, нишләп соң әле без урам чатында торабыз? Вакытың булса, бәлки, якындагы берәр ресторанга кереп утырырбыз ә? Сине очрату шатлыгыннан, һаман үз хәлләремне сөйлим дә сөйлим. Минем бит синең хәлләреңне дә беләсем килә. Дөресен генә әйткәндә, яраткан ярың була алмасам да, якын дуслар булып кала алабыздыр бит, әйеме?

Талия аның бу сүзләреннән аерата җанланып, алдын-артын уйлап та тормыйча, Хәмитне үзенә чакырды. Үз өендә тынычлап сөйләшеп утырырга мөмкинлек барында, нигә әле рестораннарда кеше күзенә чалынып йөрергә?! Җитмәсә, эштән иртәрәк китәсе булгач, әнисе янына кайтып килүне сылтау иткәнен дә йөгерек кенә уйлап алды. Бигрәк тә шәп әле: телефоны да, фатиры да тынычлыкта булачак...

Ике катлы эшләнгән затлы ишекләрне ачып керүгә, тиз генә тирә-юньгә күз сирпеп алган Хәмит «аһ» итте. «Авылда сөйләгәннәре әллә дөрес микән?»—дип уйлап куйды ул.

Талия аны зал бүлмәсенә уздырып, моның кулына фото-альбом тоттырды да, бераз кабалана төшеп, аш бүлмәсенә ашыкты. Ул арада Касыймның халатларын, урындык аркасына эленгән галстугын, ванналагы кырыну җайланмаларын тиз генә юыласы керләр багына тондырды.

—Хәмит, өстәлне монда гына көйләсәм, гаеп итмәссеңме?

—Ни сөйлисең, минме инде ул гаеп итә торган кеше? Әйдә, үзем дә булышыйм,—дип күчтәнәчләрен күтәреп аш бүлмәсенә чыкты. «Ярый әле биш йолдызлы әрмән коньягы белән бер торт алганмын»,—дип сөенеп куйды Хәмит. Чәчәккә дә исәп бар иде дә, кесәдәге мөлкәтнең юллык кына калганын чамалап, ул уеннан кире кайтырга туры килде. Үтешли генә ул йокы бүлмәсенә дә күз төшерде.

—Сөбханалла! Яшәгән урының оҗмахларга тиң икән, малай! Кайларда эшлисең, нинди хезмәтләр башкарасың? Сер булмаса, бәлки сөйләрсең. Ничек бу җәннәттәй тормышка ирешә алдың?

—Зур, табышлы бер фирмада директор сәркатибе мин, секретарь хезмәтен башкарам. Әмма дә яратмыйм шул сәркатип дигән сүзне. Телебезгә сәркатип, мөхәррир, мәхкәмә, җөмһүрият, тагын әллә нинди «ханәләр» өстәгән булдылар. Аннары, татар телен дәүләт теле дигән булабыз бит инде. Менә безнең фирмада бөтен эш кәгазьләре дә гел урыс телендә генә. Эш барышы да шул телдә... Ярый әле, урыс теле укытучыбыз Любовь Сергеевна, желегебезгә төшсә-төште, әмма урыс грамматикасын нык үзләштертте, рәхмәт яусын үзенә. Ә менә нинди зур белемгә ия иде бит инде безнең Фатыйма апабыз—татар теле укытучыбыз! Фатыйма Җәлалиевнаның безнең күнелләргә салган алтын тел байлыгы яшәештә куллану таба алмыйча гаҗизләнә. Син моны Самарада ныграк та тоясыңдыр әле. Их, Хәмит, ана телебез әнә шулай сүнеп бара түгелме соң?

—Талия, син артык читкә киттең әле. Китапча сөйләргә өйрәнгәнсен. Үзең турында сөйлисе урынга миңа тел турында лекция укырга тотындың...

—Сөйләсәң дә, сөйләмәсәң дә, Хәмит, син ирешкәннәргә үк ирешә алмадым, билгеле. ВУЗларда уку миңа тәтемәде инде. Үзең беләсең, безнең тормыш җинел булмады. Мин туугa, юк кына чирдән, табибларның гаебе белән әтием япь-яшь көе гүр иясе булган. Бабайдан калган йорт-җир тузды. Әни башка кияүгә чыкмады. Мәктәптән соң ул минем тизрәк эшкә урнашып, акча эшләвемне теләде. Шуннан мин Казанда сәркатипләр хәзерли торган курска укырга кердем. Анда инглиз телен өйрәнү мәҗбүри куелган иде. Хәзер тәрҗемәче булып та эшлим. Синең шикелле үк танылган белгеч булмасам да, фирманың көзгесе бит син, дигән булалар инде үземне. Менә мин дә мактана беләм, име? Еш кына чит илләрдә дә булырга туры килә. Безнең фирма күбрәк Англия белән бәйле.

—Да-а-а, малай, мактанырлыгың да, горурланырлыгың да бар икән, әй! Чын күңелемнән котлыйм! Синең өчен бик шат! Кайбер классташларның синең турыда сөйләгәннәре, һм-м... Карале ай-йай, малай, бүлмәң саен телевизор, транзистор, залыңда нинди кыйммәтле музыкаль үзәк, тузан җыйгычыңа кадәр Америкада эшләнгән. Тузанны суга җыюга көйләнгән икән. Ә менә бу аш бүлмәндәге ялтыравыклы табадыр, кәстрүлдер—алары да безнекеләр шикелле гади генә түгелдер инде?

—Кызык, ничек син шул арада барын да күреп өлгердең әле, ә? Син мине торган саен гаҗәпләндерә барасың бит әле. Әйе, Хәмит, бу савыт-сабалар тозсыз, сусыз, майсыз, бик тиз пешерүгә көйләнгән, «цептер» дип атала. Менә мин сиңа тавыкны күз алдында гел үз тәме, үз тозы белән генә, тиз генә пешереп сыйлыйм әле.

Талиянең тавык тураган, бәрәңге әрчегән, гаҗәеп табалар арасында чуалган йөгерек, матур куллары Хәмитне бөтенләй әсир итте. Беравык ул, хәтта сүзсез калды. Аллаһыбыз бирим дисәме?!—Өеп бирә икән... Искиткеч чибәр төс-бит, зифалардан зифа буй-сын, булганлык, житезлек—кара син аны, кулы-кулга йокмый бит. Болар бер кешегә күбрәк түгелме соң?—Хәмит шулай уйланып утырган арада, Талия табаларны уттан алып өстәлгә куйды.

—Хәзер алар пешүләрен өстәлдә дәвам итәчәкләр,—диде ул.

—Гаҗәп бит, ә! Әкият бит бу. Хатынның туган көненә алып бүләк итәргә кирәк әле миңа да,—диде Хәмит.

Талия ирен чите белән генә елмаеп куйды, җай гына кунагының эш хакы белән кызыксынды.

—Аллага шөкер, хезмәт хакым зур минем. Син сәер генә елмайсаң да, савыт-саба алырга гына җитәр, дип уйлыйм. Премияләрен дә кушсаң, аена биш-алты мең тирәсенә баса.

—Юк, дускай, эш акчада гына түгел. Шулай да, өч-дүрт айлыгың китә дә китә инде. Савыт-саба—йорт әйберсе. Туган көн бүләгенә, бигрәк тә яраткан хатының өчен килешеп бетмәс, дип кенә уйлавым...

—Әйе, минем өчен кыйммәтрәк икән шул. Ә син үзең ничек алалдың соң боларны, эш хакың шулай зурмыни? Хатын-кызга нинди мәгънәсез сораулар бирә бу, дип гаепләмә тагын.

—Һич юк. Ә эш хакым сигездән алып ун меңнәргә кадәр җитә,—диде Талия. Хәмит гаҗәпләнүеннән хәтта сызгырып ук җибәрде.

—И-и-и, дускай, «миңа ВУЗлар тәтемәде», дип уфтанып утырган буласың тагы... Ниемә хәҗәт ул сиңа?

—Юк, Хәмит, ялгышасың. Безнең фирмада КХТИдан килгән егетләр, производство бүлеге ачып, нинди генә могҗизалар тудырмыйлар! Заманның базар шартларын шулкадәр оста файдалана беләләр. Менә шулар чит ил белгечләре белән фәнни телдә сөйләшәләр. Ә тәрҗемәгә минем теш үтеп җитми, шуннан икенче тәрҗемәче чакыралар. Киләсе елга, инде соң булса да, КХТИга керергә хәзерләнәм, егетләребез дә булышырга гына торалар үземә.

—Хәмит, менә, икебез өчен генә әзерләнгән сый-хөрмәтем—дип, Талия кунагын табынга чакырды.—Инде үз көчтәнәч-сыең белән мәҗлесе-безне ачып җибәрсәң дә була.

Зәвык белән көйләнгән өстәл янында аларның икесенә дә бик рәхәт

иде. Күрәсең, җиңел генә бушатылган беренче чәркә коньяк та үз ялкынын өстәми калмагандыр.

—Эх, Талия, безнең болай очрашу нигә генә хотя бы биш елга элегрәк булмады икән?

—Бу фикереңне инде икенче мәртәбә кабатлыйсың. Ни әйтергә телисең соң син? Бәлки, аңлатып бирерсең,—дип әйтеп кенә өлгерде Талия. Кинәт кисәк кенә телефон чылтырады. Икесе дә сискәнеп киттеләр.

—Кирәкле кишер яфрагы түгелдер әле, җавап биреп тормыйм,—диде хуҗабикә, акланган сыман итеп.

Шуннан соң Хәмит, нәкъ биш ел элек, Зария исемле кызны очратып, аңа гашыйк булуы, аннары исә шул кызга өйләнеп, бер ул, бер кыз үстерүләре, үзенең Зариясе белән бик тә бәхетле булуларын сөйләде.

—Чын күңелдән котлыйм үзеңне! Гомереңбуе бәхетле бул, Хәмит, син аңа лаек!—диде Талия. Ә үзе, никадәр тырышса да, күзләренә инә барган моңсулыкның торган саен тирәнәя генә баруын яшерә алмады. Аерата аның улы белән кызы турында сөйләгәндә бәхеттән балкып торган йөзен күреп тору кызның йөрәгендә үтә дә катлаулы авыр хисләр тудырды. Бу минутларда ул: «Кара инде, юньсез, кайчандыр үземне үлеп яратып йөргән егетнең бәхетеннән көнләшеп утырам түгелме соң?»—дип тә уйлап куйды.

Юк, һич юк... ниһаять, үзеннең дәвамың-балаң булганда гына шундый зур бәхеткә ирешергә мөмкин икәнлеген бөтен җаны-тәне белән аңлап, үткән тормышына үкенү хисләре иде бу.

Биш-ун минут үттеме-юкмы, йә Раббым, янадан!—Яңадан телефон чылтырый, өзлексез чылтырый гына бит, каһәр суккыры. Тәмам түземлеге беткән Талия: «Уф-ф-ф, барыбер алмыйм, бетмәс монда... рәхәтләнеп сөйләшергә дә бирмиләр»,—дия-дия телефон аппаратын ванна бүлмәсенә үк олактырды.

—Карале, Хәмит, баягынак син мәктәптә очрашу вакытында кызларның минем хакта нидер әйткәннәрен ычкындырганыең. Нигәдер ул турыда сөйләмисең әле.

—Мин бит аларның берсенә дә ышанмадым, Талия. Ә менә бүген, күрешүебездән соң, күңелемдә, хәтта инә очы кадәр дә шикләнүләргә урын калмады. Бәлки үзең дә ишеткәнсеңдер әле, имеш син—инде ничәмә еллардан бирле, дүрт балалы, олы гына яшьтәге бик тә бай бер бизнесменның сөяркәсе икәнсең. Сыйныфташларыңнан берсе белән дә аралашмыйсың, хәтта мәктәптәге очрашу кичәсенә дә кайтырга теләмәгәнсең. Укытучылар да: «Кемне-кемне, әмма Талияне мондый түбәнлеккә төшәр дип көтмәгән идек»,—дип әйтеп әйтәләр ди. Ышанмадым... Әрләшеп тә беттем әле үзләре белән. Кадрия белән Сәхрәгөл: «Безнең Хәмит һаман шул фәрештә икән әле»,—дип көлгән булдылар. Ну Сәлимгәрәй бирде кирәкләрен: «Җитәр сезгә гайбәт сатырга. Котыртмагыз Хәмитне, лутче, яхшы чакта туктагыз! Үзегезне бәргәләп ташларга да күп сорап тормас ул. Кем-кем, мин бик яхшы беләм аның карахтерын...»—ди. Үзе миңа елмаеп күз кыса. Син ишеткәнсеңдер инде аның авылда мәчет салдырып йөргәнен. Себердә алтын чыгара торган җирдә эшли икән.

—Әйе-е, Сәлимгәрәй барыбызны да шаккатырды ул, молодец! Рәхмәт инде...

—Нигә?

—Мине яклап чыкканың өчен... рәхмәт. Шулай шул, кеше теленә бер эләксәң, элеп тә алалар, селкеп тә салалар. Хәерле булсын. И-их, Хәмит дускай, шул матур мәктәп елларын әз генә булса да кире кайтарып булса икән, ә...—дип, оялуыннан Хәмитнең йөзенә күтәрелеп тә карый алмыйча, авыр сулап куйды Талия. Каршында утырган шушы мәһабәт егетнең ташып торган саф хисләренә үзе дә, шундый ук хисләр белән җавап бирә алмаса да, хөрмәте зур иде аңа. Менә бүген дә, үзе турындагы дөрес сүзләрне Хәмит авызыннан ишетү һай авыр, үтә дә авыр булды аңа. Күкрәк читлегендә туган эсселе-суыклы дулкыннардан йөрәге бәргәләнде, сулкылдап сукты. «Әйе, Хәмит, синең һәрчак сокланып җан атып йөргән,

горурлардан горур кызың шундый түбән жан булып чыкты шул... Син ишеткәннәрнең һәммәсе дөрес»,—дип әйтергә көче житкән булса, бәлки жаны болай ук кыйналмас та иде. Тик ул дустының хәтта заман бозыклыклары да йогынты ясый алмаган саф, самими күңеленә жәрәхәт салудан курыкты. Үзенең дә тиздән нәкъ жырдагыча, ялгышны төзәтеп, язмышны үзгәртеп яшь башлаячагына күңеленнән генә соңгы мәртәбә мөһер басты. Хәмиткә эчтән генә, үзенә булган ышанычы өчен рәхмәт укыды кыз. Алга таба бернинди чигенүләргә дә юл куймаячагына туган ышанычы күңелен тынычландырып жибәрде аның. Ниһаять, ул кунагының күзләренә туры карарга көч тапты:

—Бу юлы тостны мин әйтәм: матур киләчәгебез өчен, Хәмит!

—Мең риза...

Нәкъ шул вакытта ванна бүлмәсендәге телефон янадан аваз салды. Бу юлы хужабикә телефон трубкасын күтәрергә булды. Касыймдыр, дип шикләнмәсә дә, ванна ишеген эчтән ябып сөйләшәсе итте. Әмма трубкадан бернинди дә жавап ишетелмәде. «Сәер, кем шулай кич буе миңа табышмак ясый икән?».

Кунак та китәргә ашыга башлады.

—Юк, юк, Хәмит, хәзер вакыт та соң, анык кына барып кунар урының да юк шикелле. Әнә, берүзенә бер бүлмә, йомшак диван, ят та йокла!—диде хужабикә,—аннары көлә-көлә:—Мәгәр миннән курка калсаң, залның ишеге эчтән бикләнә. Шөкер, синең миннән, минем синнән шикләнерлек урыныбыз юк. Ашыкмыйк әле, әйтелә башлаган тостым да, әнә, телефон аркасында, ярты юлда өзелеп калды. Үткән гомер ничек булса да үтте инде. Алдагы матур, бәхетле киләчәгебез өчен тутыр әле чәркәләрне,—дип, Талия жәһәт кенә өстәлне тәртипкә китерде. Шулай матур гына сөйләшеп, бер-берен тыйнак кына кысташып күпме утырганнардыр... Менә бервакыт кисәк кенә, әйтерсең лә, көчле давыл белән ишек ачылып та китте һәм... һәм ачуыннан шартларга житешкән Касыйм болар чөкердәшеп утырган бүлмәгә килеп тә керде. Аның күз карашыннан үтәли тишәрдәй булып атылган дәһшәтле уклар иң әүвәл Хәмиткә төбәлделәр.

—Моны ничек аңларга, нәрсә бу, Талия? Кайчаннан бирле син мин өйдә югында, минем кыйммәтле сыйларым белән нинди ирләрне үзенә иярләндерә башладың?

Бу көтелмәгән күңелсез хәлдән Хәмит югалып кала язды. Аннары исә үзен кулга алып:

—Гафу итегез, миңа китсәм яхшырак булыр,—дип, мыштым гына урыныннан кузгала башлады.

—Дөрес, синең монда кирәгең юк, алдыңнан артың ямьле,—дип Касыймның кычкыруына да карамастан, Талия кунагын жибәрмәде.

—Беркая да китмисең, Хәмит. Вакыт та соң инде, аннан барып кунар урының да юк бит әле синең,—диде ул, тавышын көрәйтеп.

—Әле ул монда куна калырга да тиешмени? Ике тәкә башын бер казанга сыйдырмакчы буласыңмыни? Ай-һа-а-й... Әнә, безнең офисның ял бүлмәсе бүген буш тора, китсен шунда. Хәзер мин дежурныйны кисәтәм,—дип, Касыйм Кадыйрович түш кесәсеннән телефонын тартып чыгарды.

—Алай булса, мин дә монда калмыйм,—дип, Талия кырт кисте.

—Ну и ну-у, сезнең эшләр шуна ук барып життемени? Шулайдыр шул... Тикмәгә генә телефоның ваннага кереп качмагандыр...

—Касыйм Кадыйрович, туктагыз! Сез ни өчендер бүген исерек, мәгәр, аек булып шушылай кылансагыз, мин сезне тыңлап та тормасыем. Тыныч кына табын янында утырып сөйләшүгә ни житәр,—дип, Талия, тавышын йомшартып өстәл яныннан аңа урын күрсәтте дә, тиз генә тәлинкә-кашык, чәркә-чәнечкеләр тотып әйләнеп тә килде.—Мондый очракларда адәм рәтле жүнле кешеләр сүзне танышудан башлыйлар. Хужабикә буларак, бу вазыйфаны үз өстемә алыйм әле.

—Касыйм Кадыйрович, таныш булыгыз: сезнең каршыгызда Самара авиазаводының конструкторлар бүлеге мөдире Хәмит Нәбиуллин. Ул минем авылдашым, унбер ел бергә укыган сабакташым, сыйныфташым. Хатының

бәхетле иткән ир дә, улы белән кызы өчен жанын ярып бирердәй әти дә әле ул.—Ниһаять, Талиянең әле рәсми, әле ипле-ягымлы янгыраган тавышы ике ирне дә ипкә китерде, тын калдырды.—Инде килеп, Хәмит дус, сез дә таныш булыгыз: бу әфәнде безнең фирманың генераль директоры Касыйм Кадыйрович , өйләнгән, нәкъ сез ишеткәнчә, дүрт кыз баланың әтисе. Мине үзенә сәркатип итеп эшкә алган кеше дә—ул була инде. Әмма, ни кызганыч, бүгенгә кадәр мин аны бөтенләй дә белмәгәнмен икән... Инде хәзер, шушы танышу хөрмәтенә, чәркәләрне тутыр әле, Хәмит. Ә сез, Касыйм Кадыйрович, гадәттәгечә, үзегезнең «кыйммәтле» эчемлекләрегезне генә эчәрсездер бит?—дип Талия зур гына бер шкафның ишеген ярсу беләнрәк ачып жибәрде—үзегез сайлап алыгыз, аларның барысы да үз урыннарында, нәкъ үзегез куйганча. Бу шкафның ачкычын моннан соң үзегездә генә тотсагыз бигрәкләр дә яхшы булыр.

Шкаф бүлемнәрендә чит ил эчемлекләренең нинди генә юк: француз коньяклары, шампаннары, «Мартини» дигәннәре, инглиз «Виски»ләре, берничә капта калай савытлы алман һәм чех сыралары, тагын... тагын әллә ниләр. Шешә тартмаларының бизәкләре дә күз явынны алырдай... Уйламаганда-көтмәгәндә генә боларны күреп шаккаткан Хәмит: «Вот это да-а-а!»—дип ычкындырганын сизми дә калды. Аннары исә үзенең бу беркатлылыгыннан унайсызланып та куйды бугай әле.

Монарчы өстәлгә күз дә салмаган көенчә, сөйгәненә бер гөнаһсыз гаеп ташлаганын анлаган Касыйм ни әйтергә дә белмәде. Әле генә көнчелегеннән күзләре тонган, тагын әллә нинди әр-хур сүзләре яудырырга жыенган, үтә дә гасабилыгы чигенә житкән ир бөтенләй сүзсез калды. Йөзенә, муен тирәләренә кызыл таплар бәреп чыкты. Хәмит аны кызгана ук башлады.

—Бу очрашуыбыз ямьсезрәк килеп чыкса да, Касыйм Кадыйрович, нишләмәк кирәк, үткән эшкә салават, дигәндәй, онытыйк барын да. Талия, син танышу хөрмәтенә дип матур гына тост әйтә башлаганыең бугай, дәвам итәсеңме әллә?—дип, арада туган киеренке хәлне төзәтергә тырышты.

—Чыннан да, безнең кызлар ялгышмаган, фәрештәләргә тин икән бит син, дускай. Тик канатларың гына күренми. Ә менә бүгенге бу очрашу, аерата минем өчен, күптән кирәк булган. Үз бәһасен үзе белмәгән хатын-кызның, кайчан булса да, күзләре бер ачылырга тиештер ләбаса. Һәр икегезгә рәхмәт! Тостым үз көчендә кала. Бу очрашу, танышу хөрмәтенә!—дип, Талия чәркәсен алды.

Касыйм да түзмәде, телгә килде:

—Бу арада көнләшүдән йөрәгемне тырмаган төрле шик-шөбһәләр берсе артыннан берсе килеп кенә торды. Миннән башка да тагын кемен дә булса бардыр, дип уйлый торгач, үземне шушы хәлгә төшердем дә инде мин, гафу ит мине, Талия. «Курыкканга куш, койрыгы белән биш» дигәндәй, Хәмитне синең сөяркәң дип кабул иттем бит, гафу итегез. Чыннан да бик ямьсез килеп чыкты, черт возьми. Хәмит, әгәр булдыра алсаң, син мине чын ирләрчә анларга тырыш инде, яме. Талия—минем өчен алтын бәһасе. Аннан башка яшәүне мин күз алдыма да китерә алмыйм,—дип, Талияне кочаклап үпмәкче булды Касыйм.

Кунагы алдында унайсыз хәлгә калган хужабикә исә мәжлесне түгәрәкләүгә борды.

—Вакыт бик соң инде, берегезгә иртүк аэропортка, икенчегезгә анализлар алырга поликлиникага, ә мина эшкә барырга кирәк. Касыйм Кадыйрович, сез Хәмит белән йокы бүлмәсендә кунарсыз.

Ирләрнең монә риза булмауларын ишетүгә, дилбегәне үз кулларына алган хужабикә сүзен бик кыска тотты:

—Хәзер сезгә урын жәям дә, үзем залга кереп ятам. Ә сез үз жаегызны үзегез карагыз,—дип чыгып ук китте.

Касыйм ятырга ашыкмады. Хәмитне үзе яраткан кыйммәтле эчемлекләре белән сыйлады да сыйлады. Икесе дә шактый нык исерделәр.

Вәләкин бу төн һәр өчесендә дә авыр тәэсир калдырды.

* * *

*Ашкынып без, сөю серен саклап,*
*Онытмыйча Аллаһ вәгъдәсен.*
*Җир астына төшеп ятканда да*
*Яшәвеңнең җуйма мәгънәсен!*

Лена Шагыйрьҗан

Иртәнге чәй вакытында хуҗабикә өчен һич көтелмәгән сөйләшү булып алды. Касыймны озаткач та, Хәмит сүз катты.

—Талия,—диде ул.—Әгәр ачуланмасаң, мин сиңа димче булып карарга уйладым әле. Минем хатынның туганнан туган абыйсы бар. Үзенекен итә торган үзсүзле, әмма да акыллы, уңган-булган, Сембер мишәре. Бездән ун яшьләр тирәсе өлкәнрәк—Ахияр Абдуллин атлы кеше. Казандагы бер заводта баш инженер булып эшли. Хатыны белән уникě яшьлек кызы узган ел Киевтан очып кайтканда авиакатастрофага эләгеп һәлак булдылар. Ел тулмыйча өйләнү турында ишетергә дә теләмәде. Күптән түгел генә мәрхүмнәрнең ел ашын үткәрделәр. Ниятләп торган кешесе дә юк шикелле. Аллага тапшырып, үзегезне таныштырып карыйм әле. Килешеп китсәгез, мәйле, һич үкенмәссең, мәгәр, барып чыкмаса, бигайбә. Лаеш ягында, нәкъ Кама буенда ике катлы йорт салдырганнарые, быел иномарка машина алды, үзе бик әйбәт йөртә. Минемчә, Касыймыңнан мең өлеш артык...

—И-и-и, канатсыз фәрештәм, син дә-мин теләгән белән генә түгел бит әле ул. Андый акыллы, бай мишәрләрне әллә кайчан ияргәннәрдер инде... Димче булып, бәлки, туганлашып китәрбез дисеңме?—дип елмаеп, Талия үзенең ризалыгын сиздергәндәй итте.

* * *

Бу сөйләшүдән соң ике көн буена Хәмиттән хәбәр көтте ул. Ни булса да, Касыйм кайтып җиткәнче хәл ителсен иде дип теләде. Гаҗәп бит, бер күрмәгән, белмәгән кешене ашкынып көтә башлады. Ә хәбәр юк, мөгаен, барып чыкмагандыр, дип күнелсезләнеп тә алгалады.

Ә менә көннәрдән-беркөнне, кичке сәгать бишләр тирәсендә, кабул итү бүлмәсенә төз гәүдәле, озын буйлы, чем кара чәчле, шомырттай кара күзле, заманча киенгән бер ят кеше килеп керде. Талиягә сөзеп карады да, татарча исәнләште.

—Йомышыгыз Касыйм Кадыйровичка булса, ул хәзергә командировкада, тагын өч көннән кайтачак,—дип, Талия өстәлдәге кәгазьләрне җыя башлады.

—Юк, миңа ул кирәкми. Сез Талия буласызмы?

—Әйе, нәкъ үзе,—дип никадәр генә тыныч күренергә теләсә дә, кыз кинәт каушап калуын яшерә алмады.—Сез әллә Ахияр Абдуллин дигән кешеме?—дип, әйтергә бөтенләй тиеш булмаган соравын да ычкындырып ташлады.

—Әйе, нәкъ үзе.

Бу җавапны ишеткәч тә, аңа—өстәл арасыннан чыгар-чыкмас торган сәркатипкә, урындыгын капшап, тизрәк утырып өлгерү зарур иде. Югыйсә, тез буыннары хәлсезләнүеннән чайкалырга торган гәүдәсен сөрлегеп китүдән саклауның бердәнбер чарасы шул иде. Ахияр да кызның хәлен аңлады булса кирәк:

—Мин чыга торыйм. Сезне машинада көтәрмен. Эшегезне тәмамлагач, чыгарсыз,—дип берни булмагандай тыныч кына ишеккә юнәлде. «Йа, Раббым, шуның кадәрле дә җитдилек, шуның кадәрле дә тынычлык каян килгән бу кешегә?! Мин икәнен белгәч тә, керфегенең ник бер бөртеге селкенсен, таш кыядай тик басып торды,—дип уйлап куйды Талия. Әле, ничектер, бу кешедән куркып та калды шикелле.

Ул көнне Ахияр аны Камал театрына чакырды. Кыз шатланып риза булды һәм:

—Белмәдегезме, бүген нинди спектакль бара икән?—дип сорады.

—Туфан Миңнуллинның «Сөяркә»се бугай.

Сөяркә сүзен ишетүгә, Талия эсселе-суыклы булып китте. Ахияр авызыннан беренче көнне үк бу сүзне ишетү аның үзенә төрттергән кебек яңгырады. Нинди уй белән алып килде ул аны монда? Очраклылыкмы бу, әллә башкачамы? Ни кадәрле генә ачыкларга тырышса да, күңелендә туган бу сораулар җавапсыз калды.

Әмма спектакльнең барышы, аерата азагындагы Әнисә белән Хәбирнең мәңгегә аерылышу минутларын авыр кичерсә дә, Талиягә спектакль бик тә ошады. Төп каһарманнары нәкъ ул теләгәнчә үз язмышын үзе хәл иткәнгә ошады. Сәхнәдә ике сәгать буена үзен карап утыргандай булды ул. Менә кадәрге яшәү рәвешеннән канәгатьсезлеге тагын да тирәнәя төште. Спектакль тәмам, халык кул чаба. Ә Талия: «Бу әсәрең аркылы биргән сабагың минем кебекләрне уятыр, уйландырыр әле»,—дип, эченнән генә язучыга рәхмәт укый иде. Әгәр дә Ахияр, минем үткән юлымны белеп, бу спектакльгә махсус алып килгән булса да, ул бит аның олы акыллы кеше булуын гына күрсәтә, дип, азактан нәтиҗә ясады ул.

Алар һәр көнне шулай очрашуларын дәвам иттеләр. Ә шимбә көнгә кичен Ахияр кызны Кама буендагы йортына куна чакырды.

* * *

Озын юлның буеннан-буена җәйге табигатьнең гүзәллегенә сокланып, машина эчендәге искиткеч уңайлылыклардан ләззәтләнеп, бигрәк тә Ахиярның үз-үзенә нык ышанган горур кыяфәтенә карап туя алмыйча бара торгач, сәгать ярым вакытның узганын сизми дә калды Талия.

Инде бакчага килеп кергәч, тәмам исе китеп таң калды. Әйтерсең лә, ул төрле-төрле чәчәкләр дингезенә—оҗмах бакчасына килеп эләкте. Салмак кына искән җил белән дулкынланып утырган бу искиткеч матур чәчәкләр, әйтерсең лә, башларын ия-ия, гүя аны шушы гаҗәеп гүзәл, искитмәле сихри дөньяга чакыралар.

—Сөбханалла! Сөбханалла! Бу чәчәкләрне кем утырта да, кем генә шулай матур итеп үстерә икән?!—дип, Талия чиксез соклануын белдерде.

—Алар хатыным белән кызымның миңа булган соңгы бүләкләре, күпъеллык булгач, һәр язын үзләре шытып чыгалар—дип «акланды» ир.— Миннән фәкать су сибеп, чүпләрен утап торуны гына сорыйлар. Ышанасызмы, мәгәр, төрле сәбәпләр белән озаграк су сибелми торылса, йә хатыным, йә кызым «сусадым»,—дип, су сорап төшемә керәләр. Мина аларның җаннары шушы чәчәкләрдә калгандыр кебек тоела. Икесе дә чәчәкләрне үлеп яраталарые. Язмыштырмы инде... алар юк, ә мин исән...

«Ул фаҗигага ничек тарыдылар соң алар? Читен булса да, сөйләгезче»,— дигәндәй, кыз сораулы карашын иргә юнәлтте.

—Киевта минем бертуган апам яши. Узган ел аның илле яшьлек юбилеена өчебез дә, бераз булышырбыз, дип, алданрак килдек. Иртәгә юбилей дигән көнне мине срочно заводка чакыртып алдылар, ә алар калды... Югыйсә, өчебез дә бергә бетәсе булганбыз да бит...—Ахияр, тамагына тыгылган төерне йотып җибәрергә теләгәндәй, беркавым дәшми торды, аннан сүзен дәвам итте.—Ярый, Талия, ачуланмагыз инде. Менә шушы чәчәкләрне күрү белән, ихтыярсыздан, авыр, үтә дә авыр истәлекләргә уралам. Сезнең дә күзләрегезне яшьләндердем. Хәзер иң яхшысы—мин чәчәкләргә су сибим, ә сез җиңелчә генә капкалап алырдай ни дә булса әзерләрсез. Кайда ни барын күрсәтим дә...—дип, хуҗа кунагын култыклап йортка алып керде.

—Менә монысы суыткыч,—дип әйтә башлауга, Талия:

—Сез, барыгыз, көттермәгез чәчәкләрне, сусаганнар алар, туфраклары да кипкән. Ә мин монда үзем җайларга тырышырмын,—диде.

Ахияр чыгып китүгә, үз рестораннарыннан алган өчпочмакларын, гөбәдияне җылытырга куйды, чәй куеп җибәрде. Суыткычтан яшелчәләр табып, тәмле генә салат ясады. Төрле кабымлыклардан табын көйләде.

Хужа кеше, «Тукта әле, кунагым аптырап калмады микән, ярдәм итми булмас»,—дип шыпырт кына өйгә керсә... Бөтен өйгә таралган тәмле камыр ризыгы исләреннән, үтә дә зәвык белән бәйрәмчә көйләнгән өстәлне күрүдән ләззәтләнеп, күзләрен йомды. Бер йомды, бер ачты.

—Һа-ай, рәхмәтнең рәхмәте яугыры! Йортыма ямь керттең, жанымны тынычлыкка, жәрәхәтле көнелемне шатлыкка төрдең. Ни арада өлгердең, ә мин ярдәмгә кереп киләм тагы,—дип, ир кунагын беренче мәртәбә кысып кочаклады, «син»гә күчкәнен сизми дә калды.

Хужа, Касыймнан үзгә буларак, табынга шәраб-мазар куймады. Кунак та күчтәнәчкә алып килгән «Мускат»ына кагылмады, аның үз сумкасында ятканын да сиздермәде. Ахияр түземсезлек белән (нык кына ачыккан да булса кирәк) парлары чыгып торган кайнар өчпочмакка үрелде, бер үк вакытта, дивардагы газизләре сурәтләнгән фоторәсемгә кисәк кенә күтәрелеп караганын сизми дә калды. Хәер, бу аның инде ел буена гадәтенә әйләнгән эчке халәтенең бер чагылышы иде. Кирәк бит, сурәттән ана өчпочмаклар белән тулы таба тоткан гажәеп мөлаем хатын-кыз һәм шул табага үрелгән биш-алты яшьлек күбәләктәй кыз бала карап тора иде. Алар: «Без дә пешердек, безнекен дә ашап кара»,—диләр иде кебек. Талия әллә нишләп китте, хәтта өчпочмагы кулыннан төшеп китә язды. Төшәр дә шул... Өстәвенә: «Тәмле булсалар да, Сәриям пешергәннәргә житеп бетмәгән икән»,—дип тора бит әле. Талия, уңайсызланып, аларны үзе пешермәгәнен, фәкать рестораннан гына алганын әйтергә мәжбүр булды. Ярый әле, үз хатасын үзе аңлап, хужа гафу үтенә белде.

—Бары да үтәр, Талия, үпкәли генә күрмә инде берүк, мине аңларга тырыш... әгәр булдыра алсаң. Кайбер гамәлләрем, сүзләрем гел ихтыярсыздан килә дә чыга шул...

Әйе, бу кешенең йөрәк жәрәхәте бик тирән булып,аннан һаман да кан саркып торганын бөтен барлыгы-вөжүде белән аңлау кирәк иде шул әле Талиягә.

Йорт бүлмәләре белән танышып йөргәндә Талиянең гажәпләнүләре арта гына барды. Һәр бүлмәдә хатыны белән кызының төрле кыяфәтләрдә төшерелгән фоторәсемнәре эленгән, аларның берсе дә кабатланмый. Менә ул үз бүлмәсендә көзге каршында бизәнеп утыра, икенче рәсемдә бала имезә, кызларының бүлмәсендә икесе гимнастика ясыйлар, Яңа елга чыршы бизиләр. Ә йокы бүлмәсендә кыска гына төнге күлмәктән, урын жәя. Башын борып (рәсемгә төшерүче иренә караптыр) бик тәэсирле генә итеп елмайган. Наз тулы күзләрендә мәхәббәт ташкыны...

Менә алар Ахиярның кабинетына килеп керделәр: өстәл өсте тулы кәгазь, ниндидер схемалар, графиклар, тагын әллә ниләр... Диварның буеннан-буена—газизләренең чәчәкләр арасында, диңгез буенда, машиналары янында төшкән фоторәсемнәре...

—Менә шушы бүлмәдә мин дүрт елга якын эшемнән аерылмыйча кандидатлыкка диссертация яздым. Максатым—очкычларның очу тизлеген арттыру. Моннан өч ел элек докторлык диссертациясен яза башлаганыем. Әмма бер ел элек булган очкыч һәлакәте үз канатларымны каерып атты менә. Инде, бу искиткеч катлаулы эшне башкарып чыга алуыма хәзер ышанып та бетә алмыйм. Зато бездә төгәл фәннәр өлкәсендә эше булмаган төрле хөкүмәт, төрле партия житәкчеләре тиз генә кандидат та булалар. Кандидатлыкларын юып йөргән арада докторскийлары да өлгерә. ВАКта да алар тиз расланалар. Бу эшләр үзләреннән башка кемгә, ни өчен кирәктер, билгесез.

Карале, мин сүз белән артык мавыгып киттем ахры. Әллә ниләр сөйләп ташладым бит, әй. Мин бит килү белән мунча якканыем, әллә кайчан өлгергәндер инде. Әйдә, карап чыгыйк әле. Бездә кунакны мунчага беренче кертәләр. Арканны юарга үзем керермен,—дип Ахияр кунагына борылып күз кысты.

Талия ни дияргә дә белмәде. Әллә шаяра, әллә уены-чыны биргәме? Әллә инде кызны сынап каравы гынамы? Шулайдыр әле... Талия дә хәйләкәр: ишетмәмешкә салынгандай дәшми калуны кулайрак күрде. Ә менә су

сипкәннән соң тернәкләнеп киткән чәчкәләргә сокланмыйча мөмкинме соң?! Мунчага бара торган сукмак ике яклап үскән чәчәкләрдән бөтенләй тараеп калган икән. Аларның хуш исенә җаннар ләззәтләнә, кинәнә, рәхәтләнә. Эчми исерү дигәннәре менә шушыдыр инде ул. Кичкә таба тагын да көчәя төшкән җил белән алар Ахиярның аякларына, балтырларына уралырга житешеп чайкалалар, әйтерсең лә, әнә шулай хуҗаларына өзелеп сагынуларын белдерәләр.

Мунчаның ял бүлмәсенә килеп керүгә, аларны зурайтып эшләнгән фоторәсем каршы алды. Ләүкәдә әниле-кызлы чабынып утыралар. Авызлары колакка житкән, шаркылдап көләләр дә шикелле. Икесенең дә битләре—кызарып пешкән алмадай. Әнисенең тулы, тыгыз күкрәкләре мунчага кергән кайсы гына ирне ымсындырмас, ай-һай!!! Бераздан ян диварда чөйгә эленгән өч мунча халатына, һәм аз гына читтәрәк эленеп торган өч мунча сөлгесенә, алар белән янәшә шулай ук өч чөйдәге пляж киемнәренә Талиянең күзе төште. Бөтен жирдә тәртип, төгәллек, пөхтәлек. Барын да аңлады шикелле, шулай да, Ахиярга берничә сорау бирмичә булдыра алмады ул.

—Ахияр абый, кеше мәрхүм булганнан соң, гадәттә, аның гел искә төшереп, кайгыларны яңартып тора торган әйберләрен ераккарак алып куялар. Ә сездә киресенчә. Болай акылдан язарга да мөмкиндер бит?

—Юк, Талия, фәкать шушылай яшәү аркасында гына мин үземне ялгыз тоймадым. Җансыз булсалар да, аларның төрле кыяфәтләрдәге фоторәсемнәре, үзләре элеп калдырган өс киемнәре, хәтта өйдә кия торган башмакларына кадәр ел буе миңа көч биреп тордылар. Әмма ләкин гомер буе болай—үз-үзеңне алдап яшәүнең мөмкин түгеллеген дә бик яхшы аңлыйм мин,—дип өзгәләнеп әйтеп куйды Ахияр.

Атна буе көн саен очрашып та, бергә йоклау турында хәтта шаярып та сүз чыгармады ул. Бу хәлгә аптырый ук башлаган Талия: «Хәмит әйтмешли, чүт-чүт кенә нахал булса да, һич тә гаеп түгел инде үзе. Нишләптер артык житди шул. Сәламәт ир кешегә бер ел буе хатын-кызсыз ничек түзмәк кирәктер? Әллә инде бушангалап алыр өчен кеме дә булса бар микән?»—дип уйлап куйгаласа да, ул көнне йокы вакыты якынайган саен тынычлыгын жуя барды ул. «Алай-болай тәвәккәллеге житә калса, аңа ничек җавап бирергә: табигатем теләгәнчә кыюланыбрак китсәм, күп кенә сәркатипләргә хас булган жилбәзәктер дип (болай да сәркатипләр турында тузга язмаганнарны гел сөйлиләр бит), тыйнак булам дип бөтенләй җансыз ятсаң, кая инде ул минем Сәриямә житәргә дип нәтиҗә ясавы да мөмкин бит»,—дип уйлап кына бетерүе булды, Ахияр аш бүлмәсенә килеп тә керде, бер сүз дә әйтеп тормыйча, кунагын кулларына күтәреп, икенче каттагы йокы бүлмәсенә ашыкты. Талия «Ниһаять!»—дип чак кына ычкындырмады. Шулай да Ахиярның колагына, Сәрия ишетмәсен тагын, дигәндәй пышылдап кына: «Төшерегез, мин бит жинел түгел, үз аякларымда да бара алам»,—дип ирнең янагыннан йомшак кына үбеп алды. Бу хәлләрдән соң кая инде ул кызны кулдан төшерү! Ике баскычны бер сикереп, йокы бүлмәсенә очты гына егетең!

И, хатын-кызның чуардан чуар жаны... вакытында оста гына хәйләсен дә кора белә, мәгәр шулай кирәк икәнен тойса, егетнең бөтенләй гайрәте чикмәслек итеп кенә, каршылыгын да күрсәтә белә. Әйе, инде тәмам сүнеп барган ирне дә уятырлык көчкә ия бит син! Күрәсең, табигать үзе үк аның җанын шулай камил итеп яраткандыр.

* * *

Күзләрен әле ачарга да өлгермәгән Талия, кисәк кенә айнып киткәндәй, Сәриянең бу бүлмәдәге рәсемен күз алдына китерде һәм ашыгып диварга төбәлде. Шөкер, дивар буш иде.

Аңа рәсемнәрнең төрлесе төрлечә тәэсир итте. Аерата, мунчадагысы авыр эз калдырды. Сәрия сурәткә себерке күтәреп төшкән, әйтерсең лә, ул Талияне куа, нәрсә белән куа диген әле! Мунча себеркесе белән куа...

Касыйм шикелле, теге хәлләрдән соң, монысы да йоклап киткән

бугай дип уйлап, борылып Ахиярга карады. Карады да... имәнеп китте Талия. Ахияр тавышсыз-тынсыз гына елый иде.

—Ни булды? Моңа мин сәбәпчеме?

—Гафу ит, жаным, мин бит сине йоклап китте ахры, йоклаган көе йокласын, әйтәсе сүзләремне иртәгә әйтермен әле дип уйлаганыем. Гажәпләнмә дә, борчылма да. Бу—минем Сәриям белән бөтенләйгә хушлашуымнан, ә сиңа рәхмәтле булуымнан гына аккан күз яшьләре. Кешеләргә шактый кырыс күренсәм дә, күнелем йомшак шул минем, Талиякәй. Чыннан да, син бик тә хаклы, еллар буе үлгәннәр белән рәсемнәренә карап сөйләшеп гомер итү акылдан ук яздырмаса да, психиканы какшатырга бик мөмкин. Минем бу газаплы, фәкать сагыну, юксынулардан гына торган яшәвемне үзгәртсәң, бер син генә үзгәртә алырсың... Язмышымны сиңа тапшырам... Әгәр дә син риза булсаң. Миңа икенче тормыш бирер өчен Аллаһы Тәгалә бәлки сине юллагандыр, ә Хәмитне үзенең илчесе иткәндер, рәхмәт төшкере. Әйдә, иртәгә Хәмиткә чылтыратабыз, яучы икән, ахырга кадәр яучы булсын инде. Языльшканда шаһит булуын да сорарбыз,—дип, Талияне наз тулы күкрәгенә кысып, жавап көтте Ахияр. Көтеп-көтеп тә бер жавап та ишетә алмагач, ул, кинәт кенә, бөтен жанын вә тәнен чолгап алган көчле дәрт белән Талиянең түгәрәк алма кебек тыгыз күкрәкләрен, янып торган битләрен ярсып-ярсып үбәргә тотынды, ә кыз, ни өчендер, йөзен яшерергә тырыша иде...

«Кисәк кенә нигә үзгәрде соң әле, һич аңламассың бу хатын-кызны»,—дигән йөгерек уй белән ир баш очындагы төнге утны кабызды. Талиянең бите буйлап мөлдерәп аккан күз яшьләрен күреп, гажәпләнүдән беравык бөтенләй сүзсез калды. Бераздан үзен кулга алып, назлап кына аның күз яшьләрен сөртә-сөртә, әллә инде юатмакчы булыпмы, әллә инде, ике арада туган киеренкелекне шаяртуга әйләндереп, жайлап жибәрергә теләдеме:

—Син дә кемең белән булса да хушлашмыйсыңдыр бит?—дип сорап куйды.

Ә бит, чыннан да, бу шулай иде. Ихтыярсыз аккан күз яшьләре—күбрәк кӧтелмәгән шатлыктан да тудылар түгелме соң? Мондый вакытта ничек инде, бер дә уйламыйча гына, ашык-пошык кына жавап бирә алсын икән ул?! Касыйм белән сөйләшүнең үтә дә авыр булачагыннан да, Ахиярның артып ашкан житдилегеннән, назлы сүзләргә үтә саранлыгыннан куркып калудан да иде аның бу халәте. Касыймның һәрвакыт Талияне күкләргә чөеп мактаган сүзләрен, сүз арасында кушып жибәрә торган такмакларын сагынырга калса, нишләр ул?

*Күз алдымнан китәсе юк*
*Талдай зифа буйларың.*
*Ах, бәгърем әйтче миңа,*
*Кемдә икән уйларың?*

—ди иде бит аңа Касыйм.

Ул килгән чакта Талия елмаеп каршы алса:

*Кояшым син, аем син,*
*Бар дөньямны нурга күмгән*
*Сихри алсу таңым син,*

—дип башлап жибәрә иде..

*Шикәрем син, балым син,*
*Сөеп туймас ярым син,*
*Жаннарымнан артык күргән,*
*Иң кадерле парым син,*

—дип, битләреннән, иреннәреннән үбә-үбә дәвам итә иде...

Ә Талия: «Нәрсә син, хатының өчен чыгарган такмакларыңны саташып китеп миңа сибәсеңме? Рәзе мин синең парың? Их, син, Касыйм Кадыйрович, шулай алдап-йолдап, тәмле сүзең, такмакларың белән сыйлап яшь гомеремне суларга саласың бит, дип, шаярулардан узып, моңаеп кала башласа:

*Күп моңайсаң, бәгырькәем,*
*Саргаерсың, сулырсың.*
*Түземлекләр бирсен сиңа,*
*Барыбер парым булырсың.—*

дип киләчәктә бергә яшәү турында Касыйм үзе үк хыяллана башлый иде.

Ахияр белән аралаша башлаганнан соң, Касыймның күбрәк тәмле теленә, наз тулы күз карашына, шаянлыгына гына алданып яшәгәнен аңлады Талия. Чыннан да, хатын-кыз колагы белән, ирләр ашказаны белән ярата дип юкка гына әйтмиләрдер. Үзе дә бит Касыймның күңелен күреп, аны куандырыйм дип, тәмам аш остасына әйләнеп бетте. Әмма, кайбер сөяркәләрнен: «Мин законный ирләре белән торган хатыннардан бәхетлерәк яшим әле»,—дип сөйләгәннәрен ишеткәләсә дә, ышанмады. Ул инде үзен күптәннән җимешсез калган ялгыз агачка тиңли башлаган иде. Төпле гаиләсен кора алмыйча, фәкать сөяркә генә булып яшәвеннән канәгатьсезлеге, аерата соңгы вакытларда, үз-үзен күрә алмау дәрәҗәсенә китереп җиткерә башлаган иде инде.

Ә бүген, ниһаять, Хәмит әйтмешли, Касыймнан мең өлеш артык булган ир солтаны аңа тәкъдим ясый. Нәрсә бу, бәхет түгелмени? «Йә, Раббым! Чиксез шөкер! Алдагы көнемдә дә рәхмәтеңнән ташламыйча, ахырын да хәерле ит!»

Шул рәвешчә: үз шикләре, үз өметләре, үз хыяллары белән уйланып ята торгач, Талия фәкать тан сызыла башлаганда гына йоклап китә алды.

Иртәгесен уянып киткәндә янында Ахияры юклыгын күреп: «Йә, Раббым, йокы чүлмәге икән дип әйткәндер инде»,—дип уңайсызланып кына аска төште. Ахияр анда да юк иде. Аскы ишек төбенә кадәр ачык, кояш яктысыннан күзләр чагыла, ә тышта коеп яңгыр ява иде. Яңгыр астында кулларын югары күтәреп басып торган Ахиярны күреп, Талия аңа атылды.

—Гөнаһларымны яңгыр суы белән юарга нигә мине дә чакырмадың? Ә мин сине өй буйлап эзләп йөрим тагы. Кая гына барып төртелмим, анда Сәрия күзләре... Әйтерсең лә, алар миңа үпкәлиләр...

—Нинди гөнаһ турында сөйлисең син? Әнә, табигать үзе дә безне иртәдән үк кояшлы яңгыры белән котлый. Күпме көтте халык бу яңгырны! Каршындагы салават күперен генә күр син!!!

Шулкадәрле дә ачык җете төсләрдән чигелгән бу могҗизаны күргәч, Талия: «Сөбханалла! Абау җаным, бигрәкләр дә матур ич!»—дип, сабыйларча шатланып сокlануын белдерде.

—Бу гаҗәеп матур салават күпере безнең язмыш юлларын тоташтыру өчен тугандыр ул. Бу гүзәлләрдән гүзәл иртәне Сәриям белән кызымның безгә биргән фатихасыдыр дип тә юрыйсым килә минем. Кешеләр күк капусы ачылганда теләк телиләр, ди. Әйдә, без дә жылы яңгыр астында, салават күперенә карап теләкләребезне ирештерик әле Аллаһыбызга. Мин теләдән әйтим, ә син «амин!» дип тор яме,—дип Талиясен ярым кочаклап ниләр генә теләмәде, хыялланмады Ахияр! Хәере белән бергә кушылып, матур гаилә корып җибәрүләрен, аннан гомер буе бер-беренә тугры булып, тигез мәхәббәт белән яшәүне дә, шушы йортны тутырып бала-чага бирүне дә сорады. Шул чак Талия: «амин!» дип әйтәсе урынга:

—Монда сыймасалар, шәһәрдә өч бүлмәле фатирың да бар бит әле, аны да ятим итмәвең сораган көе сора инде, яме,—дип әйтә куйды.

—Шаяртуың гына булса да, рәхмәт үзенә. Мин моны синең вәгъдән дип кабул итәм. Бел аны, мәгәр мондый шартларда бирелгән вәгъдәләрдән читенә калсак, Раббым безне кичермәс. Йә, чыннан да вәгъдәме?

—Вәгъдәсен-вәгъдә... Әмма куркам. Сез бит мине һәрчак хатыныгыз белән чагыштырып яшәячәксез. Ә мин Сәрия апа кадәр үк булдыра алмасам...

—Кешеләр бер-берләрен кабатлый алмыйлар. Тугрылыкта Сәриямә охшаш була алсаң—минем өчен иң кыйммәтлесе шул.

—Ул яктан тыныч була аласыз.

—Рәхмәт, Талия! Болай булгач, вәгъдәләрне ничек итеп беркетеп куябыз инде?

—Сез дигәнчә булсын, мин барына да риза.

—Әйдә, башта безнең Кама «дингезендә» су коенып менәбез.

—Абау жаным, шушы янгыр астындамы? Болай да җепбөртексез булдык бит инде,—дип, ботларына сыланып беткән халатын сыпыра-сыпыра, Талия чыркылдап көлеп җибәрде.

—Аның кызыгы да, ләззәте дә менә шунда инде!—дип, ир һаман үз сүзен куәтләде.

—Юк, юк. Сез миннән башка гына йөзеп менегез, ә мин чәй кайнатыйм, үзегез әйтмешли, капкаларга бирәр нәрсә әмәллим.

Ахияр риза булмады, кунагын житәкләп, җилтерәтеп дигәндәй су буена алып төшеп тә китте.

—Ахияр абый, мин бит йөзә белмим, яр кырыенда гына чупырдыйм инде шунда.

—Аптырама, үзем өйрәтермен,—дип суга ук алып керде ул аны һәм кулларына йөзтүбән яткырып йөзү алымнарына өйрәтә башлады.

Менә тагын кайда икән ул рәхәтлек... Су эчендә ялангач тәннәренең бер-берләренә кагылып китүләре, аннары Ахиярның колач салып йөзүенә, йөзгән чакта уйнап торган мускулларына карап сокланулары әйтеп бетергесез ләззәт бирде Талиягә.

Ул көнне алар рәхәтләнеп ял иттеләр. Су коендылар, Каманың дингезләргә тиң мәһабәтлегенә сокланып көймәдә йөрделәр. Көндезге аштан соң Казанга кайтырга килешкән булсалар да, икесе дә бик теләп, дүшәмбе иртүк китәрбез дип, тагын бер кичкә калдылар. Бу—икенче уртак төннәре—мәңге онытылмаслык булгандыр, мөгаен. Талия дә, кичәге шикелле: «алай булсам, болай булсам» дигән шикләнүләрен, тартынып торуларын бер читкә атып, назга наз белән җавап кайтарды. Тик таң алдыннан гына, күргән төшеннән уянып китә алмыйча, «Ахияр абый» дип кычкыра башлады.

—Талия, саташасың ахры, уян тизрәк,—дигәч кенә:

—Йә, Аллам, ярый әле төшемдә генә икән...—дип күргән төшен сөйләп бирде.

—Ачык капкадан кешни-кешни, иллә дә матур бер колынчак килеп керде. Ай сымак кара кашкалы, үзе ап-ак төстә. Мин сокланып кулларымны сузуга, син: «Кагылма, тешләп алмасын, күршеләрнеке ул, ялгыш кергәндер, үзләренә кертим әле»,—дип алып чыгып киттең. Мин көтәм дә көтәм. Ә син юк та юк, инде курка башладым. Бервакыт колагыма: «көтмә, теге ак бүре аны үз оясына алып китте»,—дигән тавыш килде. Мин сине чакырып кычкыра башладым. Сине бүреләр ашагандыр дип куркып, калтырыйм. Ә үзем өнемдә беркайчан да әйтмәгән: «Нигә минем авызым ашка тисә, борыным ташка тия»,—дип, өзгәләнепме өзгәләнәм икән... Син уятмасаң, белмим, күпме азапланган булырыем. Әле дә йөрәгем чыгарга житешеп тибә.

—Талия, нигәдер, мин үзем төш күрмим. Саташуың гына булгандыр, кер куеныма, йом күзләреңне, назлап йоклатыйм әле үзеңне,—дип, Ахияр аны тынычландырырга тырышты.

* * *

Талия эшкә гадәттәгедән иртәрәк килде. Озакламый ишектә Касыйм да пәйда булды. Йөзе борчулы, күз төпләре шешемсерәгән. Бөтен килеш-килбәте, кыяфәте белән кайгы-хәсрәт кичергән кешене хәтерләтә. Күз карашында да күнелләрне айкап алырдай монсулык, тирән үпкә чагыла. Әле монарчы аны беркайчан да болай мескен хәлдә күз алдына да китерә алмаган сәркатип бөтенләй каушап калды.

«Бу кадәр үзгәреш минем аркада гына түгелдер, бер-бер хәл, бәлки, командировакасы уңышсыз булгандыр»,—дип уйлады Талия. Шулай да, үзен тыныч тотарга тырышып:

—Кайтуыгыз белән Касыйм Кадыйрович! Ни өчендер борчулы күренәсез, әллә юлларыгыз уңмадымы?—дигән булды.

—«Борчулы күренәсез» имеш. Ну артистка да инде үзең! Надо же,

гаепле икәнен белә торып... Теге чакта да мине түп башына утыртып шаккатырганыең,—дип тезеп китте тегесе—Каян килә синә шуның кадәр көч? Хатын-кызга табигатьтән бирелгән шул ул хәйләкәрлек... Әйт әле дөресен, минә үч итеп, егетне бераз биетеп алыйм әле, дип кенә өйгә кайтмый йөрдеңме? Кичә мин туры синә кайтып төштем. Өй буш, хәтта записка да юк. Шуны аңладым: мине көтмиләр... Бүген иртә белән дә сугылып карадым, опять шул ук хәл. Кайларда йөрден? Пычаксыз суясың бит, беләсеңме шуны... Нәрсә генә дисәң дә, яратам бит. Яратам, үлеп яратам. Киләчәктә барыбер бергә булачакбыз! Бераз кызларымны аякка бастырыйм, дип кенә азапланам бит. Мәскәүдән бер жылы хәбәр дә алып кайттым әле. Тиздән Думада ирләргә күпхатынлылык хокукы бирүче закон кабул ителәчәк икән. Ул законнары барып чыкса, Алла боерса, качып-посып йөрисе булмас, полный законный хатыным булырсың.

—Касыйм Кадыйрович, безгә бик житди сөйләшергә кирәк.

—Алла хакы өчен, туктат, матурым, бетер бу үпкәләп йөрүләреңне! Күп сүз нинди сүз диләр әле? Фатирны синә күчерү турында барлык документлар эшләнелгән. Тәртибең «5»лелек булса, фатир белән охрана өчен түләүне фирма үз өстенә алыр. Йә, килештекме, гүзәлем, калганын бүген эштән соң, өйдә сөйләшербез, куна киләм. Сагындым, үлеп сагындым...

—Юк, Касыйм Кадыйрович, юк, юк!—дип кырт кисте кыз.

Әллә инде болай тиз генә килешүнең чыннан да мөмкин түгеллеген аңлапмы, әллә инде көтмәгәндә генә хезмәткәрләренең килеп керүеннән шикләнепме, Касыйм аны үз кабинетына чакырды.

Һәм... һәм ишекне эчтән бикләп үк куйды. Тәмам тәкатен җуйган ир Талияне кочагына алды. «Сагындым, өзелеп сагындым, бәгърем»,—дия-дия, ул кызны шашып-шашып үбә башлады.

—Касыйм Кадыйрович, тынычланыгыз, сабыр гына урыныгызга барып утырыгыз әле. Сезгә...—Талия дә дулкынлана иде, бераз тын алды,—кайчан да булса мине дә тыңларга кирәктер бит инде. Мин дә сезгә өр-яңа бер хәбәр әйтергә телим ләбаса.

—Йә, әйтеп кара...—Ир сагаеп калды.

—Мин тиздән кияүгә чыгам... Бүген кич безгә очрашу мөмкин түгел.

—Нәрсә-ә-ә?

Касыйм, нишләргә дә белмичә, затлы күн көрсиенә гөрселдәп барып утырды. Нәкъ шул вакытта, көтеп кенә торгандай, кайсысыдыр ишек шакыды.

* * *

Кич. Тып-тын бүлмә. Ике арада авыр сөйләшү бара. Касыйм кызның теләген аңлый да кебек. Әмма аны үз кулыннан да ычкындырасы килми. Киләчәккә корган хыялларын, өметләрен тәмләп-илһамлап тасвирлаганнан соң да, кызны үзе белән калырга ризалата алмагач, соңгы чарасын сынап карамакчы булды.

—Талия, тормышта ирешкән барлык уңышларыңны, монарчы алып килгән зур хезмәт хакы-премияләреңне әллә үз казанышларың гына дип уйлыйсыңмы син? Әниеңә авылда бер дигән өй, мунча салганда, сыер алганда түккән акчаларым да онытылды булса кирәк. Инглиз телеңне камилләштерү, компьютер үзләштерү өчен дә, чит илләрдәге сәяхәтләрең өчен дә күпме долларлар очканын, ай-һай, тиз оныттың бит, кызыкай. Кемгә эләккән бу бәхет, дип яшисе дә яшисе урыңга, ашаган табагыңа төкерәсең түгелме? Югары белемең дә булмаган көенчә, бу базар дөньясына кем чыгарды сине? Әнә, үзең белән бергә сәркатипләр курсын тәмамлаучыларның кайсысы гына ирешә алды икән әле бу дәрәҗәгә, ә?! Бик сирәгеләр, мәгәр булса... Яшәгән фатирың...Фатирың тулы байлык... Күпме доллар... Ашаган белми—тураган белә шул. Ярар, чыксан-чыгарсың инде. Минем түккән көчем белән кемне генә бәхетле итәргә жыенасыңдыр, белмим. Бәхетле булырсыңмы икән соң үзең? Син миңа ничек рәхмәтсез икән, ул да синә шулай булмас, дип әйтә алырлыгың бармы?

Булса да була икән адәм баласында түземлек! Талия дә түзде, соңгы

чигенә җиткәнче түзде, тынлады. Бүлдермәде, бөтен эчен бушатырга мөмкинлек бирде ул аңа.

—Барысы өчен дә, бүгенге вәгазегез өчен бигрәкләр дә зур рәхмәт,—диде ул аннары.—Рәхмәт: шул оятсыз, ерткыч базар дөньясына керү өчен юл ачучы кеше булдыгыз. Нәкъ заманча иттереп яшь-яшь, саф кыз баладан үзегезгә сөяркә ясадыгыз. Әле ул гынамы—йөккә уздыртмас өчен алтыннан спираль ясаттыгыз. Аны куйдырту өчен зур тәҗрибәле гинекологны ялладыгыз. Бары да, бары да заманча... Бала тудырырга да хакым юк иде. Ун елга якын мин бит сезгә рәхәтлек бирүче җан иясе генә булдым. Ә үз хатынызыз узган берсен тупырдатып таба торды. Һәр балагыз туган саен өегездә генә түгел, фирмада да зур тантана ясалды. Минем шул чаклардагы кимсенүләрем, газаплы кичерешләрем өчен түләп бетерерлек хакның булуы да мөмкин түгел. Менә ни өчен мин, сез биргән оҗмахтан баш тартып, үз кулларым белән үз оҗмахымны булдырып, шунда үз балаларымның тәгәрәп үсүләрен телим. Ярый, сезнең ул хыялларыгызга алданып калдым да ди, бала тудыра алу чорым үтеп беткәч, ниемә хаҗәт миңа андый тормыш?! Дәүләт якласа, күп хатынлыкка да өметегез бар икән әле... Касыйм абый, бәгърем, рәнҗемәгез... аңлыйм, сезгә дә җиңел түгел, ә миңа тагын да авыр. Иремә ярарга тырышып яшәү һич кенә дә җиңел булмаячак. Үтә җитди кеше ул. Бер ел элек өзелеп сөйгән хатынын, кызын югалткан. Әле ул һаман да алар рухы белән, алар дөньясында, алар тудырып калдырган тәртипне саклап яши. Аңа сезнең дә, минем дә байлык кирәкми, үз мөмкинлекләре дә җитәрлек. Ул да, нәкъ минем шикелле, өе тулы нарасыйлары булуын тели. Ничәмә еллар спираль йөртүем аркасында, балага уза алмасам, ул риза булмаячак,—дип, ниһаять Талия мөлдерәп торган күз яшьләренә ирек куйды. Хәзер инде аерылышуның котылгысызлыгын тәмам аңлаган Касыймның да күңеле тулышты.

Талия исә, бераздан үзен кулга алып, битендәге күз яшьләрен сөртеп алды да, сүзен дәвам итте:

—Менә шуңа күрә дә, мөмкин булса, хәзергә үз эшемдә калып, фатирым да вакытлы гына булса да, үз исемемдә сакланса, тынычрак булырыем. Аллаһы кушып, бары да унай килеп чыкса, ул фатирның безгә кирәге дә булмас, дип уйлыйм.

—Талия, нигә әле булачак киявеңнең кем икәнен әйтергә теләмисең?—Үзен кулга алган ир дә гәпне тыныч кына дәвам итәргә тырышты.

—Кинәт кенә, көтмәгәндә ул гөнаһсыз җанның гүр иясе булуыннан куркам...

—Аңлатыбрак сөйләсәнче...

—Аңламыйсыз имеш... «Махсус эшләр» башкару өчен шакалларыгыз бар ич...

—Алай... Менә миңа, мәсәлән, аны түгел, сине юкка чыгару күпкә җиңелрәк түгелме соң? Сөйләвең буенча, ул кеше дә эшмәкәр булса кирәк. Ничек инде мин үземнең, фирмамның бик күп серләрен белгән һәм ун елга якын үзем үстергән кешене, ансат кына, икенче эшмәкәргә тоттырып җибәрим ди, ә?! Ул бәндәнең сиңа өйләнүендә башка интереслар да ятмый микән әле. Шулайрак тоела.

—Бик нык ялгышасыз, Касыйм Кадыйрович. Ә мин үзем өчен алай бик курыкмыйм да. Миңа кулыгыз күтәрелмәячәк бит сезнең. Мәгәр, ялгышсам, анысына да үкенмәм. Ачысын да, төчесен дә, бик күпләргә эләкмәгән «оҗмахын» да татыдым. Тик үз баламны сөю, күкрәкләремнән аны имезү ләззәтен татымый калуым гына кызганыч булачак...

* * *

Яна тормыш... Баш әйләндергеч тизлек белән бөтерелеп чоңгылга кереп киткән йомычка шикелле, Талия дә санап бетергесез, исәбе-хисабы булмаган мәшәкатьләрдән торган яңа тормышына башы-аягы белән кереп чумды. Ир хатыны белән сөяркә арасындагы күз алдына да китерә алмаган аермалыкны тиз татыды ул. Җитмәсә, инде ел буе бөтен эшне

үзе башкарырга күнегеп беткән ирдән, үтә унган хатын булып күренү өчендерме, барын да үз өстенә алды. Ир затына, билгеле ки, шул гына кирәк тә инде ул. Әмма Ахияр өчен бу бәһаләп бетергесез ярдәм булды. Эшендә, вакыт житмәү сәбәпле бераз бушый төшкән дилбегәне ныклабрак тартырга да, докторлык диссертациясен өр-яңадан башлап җибәрергә дә мөмкинлек туды.

Өендәге мәшәкатьләре никадәр күп булуга да карамастан, эшенә һич зарар китермәде Талия. Беркөнне, һич көтмәгәндә, аның эш бүлмәсенә әнисе килеп керде.

—Әни, нишләп йөрисең, берәр яман хәл юктыр бит?

—Юк ла, менә бер тешем төннәр буе үтереп сызлый башлады. Итмәгән им-томым калмады, аспиринның да бер файдасы тимәде. Йокларга ятуга, әй, тотына, минсинәйтим, чыдый торган гына түгел, суыртып алмый булмас. Аптыраган-җөдәгән, мичкә артын терәгән, дигәндәй, кая барыйм инде, сина килдем, үзең кайтмыйсың...

Шул арада, ачык ишектән күреп калган ахры, хуҗа кунакны үз кабинетына чакырды. Шактый озак сөйләштеләр. Соңыннан, Касыйм Талия янына чыгып:

—Хәзер әниенне үз ресторанабызга алып барып сыйлыйсың, аннан минем теш табибыма күрсәтәсең, бары да килешенгән. Машина ишек алдында, күпме кирәк, шулай файдаланыгыз. Синең урынга монда Света калып торыр,—диде.

Ишектән чыгуга, әнисе:

—Нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә аңа әз булыр. Бөтен дөньясына бер генәдер ул. Ә син, мина да әйтми-нитми, шушындый игелекле кешене ташлап, кияүгә чыгарга җыендыңмы? Әллә инде никахсыз-нисез генә чыгып та өлгерденме? Әниеннең хәер-догасын да гел пүчтәккә санныйсың инде, име? Начармы-яхшымы, хәләл сөтемне имезгән, яшьяшьтән тол калып, янадан кияүгә дә чыкмыйча, сине саклап үстергән анаң бит мин!

—Әни, бәлки әле ул минем булачак кияемнең кем икәнен дә беләдер.

—Нигә белмәсен, белә! Фәрештә күк, әүлия күк кеше бит ул! Хатыны белән баласын ташлаган Абдуллин Ахияр дигән кеше ди, дажы карточкасын да күрсәтте. Бик матур бер машина янында икегез басып торасыз. Бел аны, үзенә әйтә күрмә, сиңа әйтмәскә кушты. Раббым мине, тешемне сызлатып, монда җибәрмәсә, кияүгә чыкканыңны белми дә каласым булган икән. Син яшерсәң дә, Касыйм барын да белеп тора. Кызым, ялгышма, бәхетле башыңны бәхетсез итмә, Касыймны да рәнҗетмә,—дип каты гына әйтеп куйды.

Талия акбурдай агарып китте, хәлсезләнеп, барган җиреннән туктап калды. Тиз генә Ахиярга чылтыратып: «сак була күр»—дип кисәтәсе килде аның.

—Әни, син бүген, нишләптер, артык гайрәтле күренәсең, әллә үзеңә сөйләп кенә түгел, салып та бирдеме?

—Юк ла... дөрес, сыйламакчы да булганые, бүльнискә барасымны әйткәч, сумкама гына салды... Бик һәйбәт дару, алай-болай тешең сызлый башласа, йә булмаса, нык кына арып китсән, берәр рүмкә эчеп куй, файдасы зрә дә күп диде, рәхмәт төшкере.

—Әни,—диде торган саен гаҗизләнә барган кызы,—бәлки әле ул сина акча да биргәндер, ә син үзенне кимсеткәнне дә аңламыйча, аның йөзенә карап, рәхмәтләренне укый-укый, менә шушы кулларың белән алып та куйгансыңдыр? Мин синен нәфесенне яхшы беләм...

—Биргәннең битенә бакма диләр, нишләп алмаска ди әле, алдым шул. Хәзер авылда акчасыз, бигрәк тә аракысыз нишләп тә булмый. Җир сукаласы, утын-мазар, печән-салам апкайтасы булса да, каралтыкура төзәтергә дә—бәлүтең бармы гына диләр—пуллитр дигән сүз икән ул. Ярый ла син, уч тутырып акча аласың, ыристаранда гына ашыйсың,

таксиларда гына йөрисең. Ожмах шикелле фатирыңда китап укып, телевизор карап, түшәмгә төкереп яткач та...

Менә шуларны ташлап китеп карале, бүре булып уларсың. Ярар, чыксаң да чыгарсың инде, фатихамны да бирермен. Мәгәр Касыймны ташласаң, мәңге риза-бәхил түгел.

—Әни, аңламыйм мин сине. Кайчанга кадәр шул акча колы булырсың икән инде?! Укытучы булырга теләдем, хәерче буласың киләмени дидең, каршы төштең. Әнә, Кадрия институтка кереп, Казандагы инженер егеткә матур итеп, бөтен гореф-гадәтләрне жиренә житкереп, кияүгә чыкты. Ә син ул чакта минем күз яшьләремне бөтенләй күрмәмешкә салындың. Һаман сөяркә булып калуымны хуп күрдең.

—И, балам, ул чакта да «без—без инде, без—шөшле түгел»,—дип күпме аңлатырга тырыштым, тәки аңламагансың икән. Кадриянең әтисе үзе укытучы, үзе ушлый, үткен кеше булды. Ә мин кем? Әнә, югары белемле укытучы Кадрия белән Сәхрәгөлең, бик беләсең килсә, хәзер базар чилнуклары. Инженер ире эшсез калып эчә башлаган. Чилнуклар үзе акчаны шәп сугалар икән. Ирен эчүдән туктатыр өчен машина да алып биреп караган. Ә теге жүнсезе, исерек баштан утырып, каядыр бәрелеп челпәрәмә килгән, үзе бүлнистә ята бугай. Кадрияң балаларын әниләренә кайтарып ташлады. «Машина беткәнче, исерек тәресе дөмеккән булса икән ичмаса»,—дип зар жылыйлар. Сәхрәгөлләр дә адәм хуры булып беткәннәр, аерылыштылар. Төркиядә ниндидер төрекләр белән танышканнар ди алар. Килгәндә боларны гел каршы алып, густинса дигән жиргә урнаштыралар да, шунда төне буе гүләйт итәләр икән. Икенче көнне товар алышып, самалютка кадәр озатып та куялар икән ди. Кемдер бу хәлләрне тегеләрнең ирләренә тишкән ди. Бөтен бәла-каза шул көнләшүдән киткән ди. Хәзер синең гайбәтеңне чәйнәп йөрүләре дә, әнәтерә шул, синнән көнләшүдән генә бит ул. Касыйм күк берәүнең сөяркәсе булырга ничек кенә риза булырларые әле. Базарда жәй булса—кара-чутыр чегән хатыннары төсле каешланып, кышкы суыкларда—туңмас өчен дип ярты стаканны жибәреп, мих бәяләй кигән кулларын суккалый-суккалый, көннәр буе тыпырдашып торалар бит, бичаралар. Менә бу заман нишләтте бәндәләрне, хатын-кызны харап итте. Гыйбрәт түгелме бу сиңа? Авыл тулы, Казан тулы гыйбрәт хәзер. Ә син... «кияүгә чыгам, бала табам»,—дип кычытмаган жиреңне кашып йөрисең шунда. Баласы да пычагыма кирәк, кем рәхәт күргән алардан...

Түзмәде Талия:

—Әни,—диде,—житте, тукта! Син дә шулай әйткәч инде... Үзең кем рәхәтендә яшисең соң? Нигә йөрәгемне шул кадәр телгәлисең? Син бит тудырган балаң өчен түгел, акчасына, байлыгына кызыгып, чит бер кеше өчен тырышасың.

—Нишләп чит кеше булсын ди әле ул. Мин аннан күргәнне берәү малаеннан да күрми. Шыңгырдап торган йортлы, мунчалы итте, сыерга тиеңдерде. Әнәтерә, әле бүген дә: «мин сине мәңге ташламам»,—дип нишләргә белми тора. Кемнән күрәм мин мондый хөрмәтне? Менә син, бердәнбер балам булсаң да, анаң яшәгән авыл жулын бөтенләй онытып бетердең...

—И, әни, укытучыларымнан, Фатыйма апа белән Любовь Сергеевнаның күзләренә күренергә оят. Алар бит икесе дә минем өчен гел тырыштылар, икесе дә: «үземә алмаш булырсың»,—дип өметләнәләрие. Мәктәптәге очрашу кичәсендә мине чәйнәгәннәрен үзең дә ишеткәнсеңдер әле?

—Мина берни дә әйткәннәре юк әле, сиңа гел сәлам әйтергә кушалар. Менә Сәлимгәрәегез маладис ичмасам, икесенә дә бүләккә төсле телевизор апкайткан. Сиргиевнага болай дип әйтеп әйткән ди: «Үзәк бәгырьләребезгә төшсәгез төштегез, әмма дә урысларның үзләрен дә сатып жибәрә торган итеп урыс телен өйрәттегез, рәхмәт сезгә»—дигән ди. Сиргиевнагыз шунда жылап та жибәргән ди. Бәк авыр яшиләр алар, кызым. Яртышар ел буе шул бәп-бәләкәй зарплаталарын да ала

алмый тилмерәләр. Качып йөргәнче, лутчы бер кайтып хәлләрен белеп, күңелләрендә саклаган рәхмәтләреңне үзләренә әйтеп килсәң, бер изгелек булырые.

—И, әни-и...

—Касыйм чалдырган корбаннан өлешне аларга зуррак итеп бирәм, ничек кенә рәхмәт укып алалар әле. Укучыларыннан башка бер кешеләре дә юк бит аларның. Яшьтән үк безнең авылга килеп, кеше почмагында яшәп, күпме балаларны кеше иттеләр. Инде пенсиягә чыгар вакытлары да житеп килә. Тәки шул кеше почмагында ялгыз калдылар. Шундый зур белемле асыл затлар картлык көннәрендә сәдака карчыкларына әйләнеп баралар бит, әй...

—Бик дөрес әйтәсең әйтүен, әни. Менә шуңа күрә мин аларга күренергә дә оялам. Алар тудырган изге хыялларыма хыянәт итеп, ожмахларга тиң тормышта сөяркә булып яшәүне сайладым бит. Бу газиз жаннарның да гаилә корып, үз балаларын тудырып яшиселәре килмәгәндерме? Безнең авылда кем барые соң аларга тиң? Гомер буена, ялгышып та, ник бер яманатлары чыксын... Бәлки, гел әнә шул киләчәккә өметләнеп яшәгәннәрдер инде, бахыркайлар. Хатын-кызның ана булу вакыты кыска, һай, бик тә кыска бит ул, әни.

—И-и, балакайгынаем, әллә мине берни дә аңламый дип беләсеңме син? Түлке ир буласы кешеңне бер дә мактамый бит Касыйм. Һич кенә дә ышанмый ул тора алуыгызга, кире кайтачак ул, ди. Ә мин ул вакытта колач жәеп каршы ала алмам ди. Хараплар гына итә күрмә инде үзеңне, гомер буе үкенерсең...

—Әни, дим, ничекләр генә итеп аңлатыйм соң мин сиңа: менә син миңа әни булган шикелле, Касыйм да кызларына әти кеше. Әгәренки ул кызларына алай-болай минеке кук язмыш киләсен сизенсәме? Актык мөлкәтеннән мәхрүм калса-калыр, моңа һич тә юл куймас. Йә, кайсыгызга үз баласы кадерлерәк икәнен аңлыйсыңмы? Ә син мине янадан кая этәрәсең? Тагын нәрсә житми сиңа? Авылда халык егылып эчә диләр, әллә син дә... Әллә ансат кына килгән муллык нәфсеңне тагын да күпертә генә барамы?—Талия, үзе дә сизмичә, әнисенә тавышын күтәрә башлаганын аңлап, тыела төште.—Югыйсә, баланның зарына әз булса да колак салырыең. Элегрәк син мондый ук түгелиең бит... Йә, дөресен генә әйт әле, менә бүген күпме акча бирде ул сиңа?

—Күпме дип инде... ул әйтмәде, мин санап тормадым, бер канвиртны сумкама шудырды шунда,—дип сумкасын кызына сузды Шәргыя.

Талия, «Абсолют» дип язылган швед аракысын күргәч, ни диярга дә белмәде, башын гына селкеп куйды. Әнисенә бу «дару»ның алты йөз сум торуын әйткәч, тегесе, шаккатып: «китчәле, булмаганны»,—диюдән башка сүз тапмады. Кызының конверттагы биш кисәк меңәрлекләргә карап:

—Әни, жаным, боларның барын да үзенә кире кайтарыйк,—дип әйтүе генә булды, әнисе жәһәт кенә сумканы тартып та алды.

—Хәзер менә, көтеп тор, яме! Мин аны урлап та, сорап та алмадым. Мине хөрмәт итеп үзе бирде. Бер кулга эләккәнне кире бирергә мине жүләр дип белдеңме әллә?—диде ул.

Талия исә әнисенә Ахиярны мактады. Аның бик яхшы кеше икәнлеген, тормышы-көнкүреше дә искитмәле шәп булуын сөйләде. Касыймның мәкерле ялганнарын дәлилләп, әнисенең күзен ачарга теләде ул. Чыннан да, ана кызы сөйләгәннәрне сабыр гына тыңлады, тора-бара күзгә күренеп йомшарды да.

—Кайтыгыз, кызым, кайтыгыз! Ичмасам, авыл халкы алдында йөзебез юылыр, ак булыр. Шундый зур кешенең кызымны сорап кайтуы минем өчен дә олы дәрәҗә түгелмени? Менә диган итеп никахын да укытырбыз, Аллаһы боерса. Мишәрләр—алар, кызым, үтә дә дини кешеләр, сынатырга ярамас. Түлке кайтасы көнегезне миңа хәбәр итегез. Берүк Касыймга сиздерә күрмә. Ялганнары белән башымны әйләндергәне өчен, үз

көчтәнәчләре белән авылында бер диган мәҗлес үткәрим әле, Аллаһы боерса.

—Юк, әни, юк-юк, Аллам сакласын! Касыйм Кадыйровичның ул көчтәнәчләрен, бер җае белән, үзенә кайтарып бирергә кирәк!

* * *

Июльнең уттай эссе көннәре иде. Ахиярлар күбрәк Кама буендагы йортларында яшәделәр. Ниһаять, түземсезләнеп көткән көннәре дә килеп җитте. Никах мәҗлесенә Ульяннан әти-әнисен, ә Самарадан Хәмитләрне чакырды Ахияр.

Авылда үткән бу ике көн барысы өчен дә гомер буе сагынып сөйләрлек вакыйгага әйләнде. Беренче көнне никах мәҗлесе, икенче көнне исә язылышу булды. Талия үзенә шаһитлыкка яраткан укытучысын, сыйныф җитәкчесе Фатыйма Җәләлиевнаны, ә Ахияр, билгеле инде, Хәмитне сайлады. Язылышу мәҗлесенең түрендә Ахиярның әти-әнисе белән Фатыйма Җәләлиевна һәм Любовь Сергеевна утырдылар. Талия үз куллары белән аларның иңнәренә ак мамыктан челтәрләп бәйләнгән Ырынбур шәлләре япты. Шундый ук шәлне Зариягә дә бүләк итте ул.

Хәмит белән Талиянең кабынып китә алмаган мәхәббәт тарихын яхшы белгән һәм әле шуның өчен борчылып та йөргән укытучылары бер-берләренә серле генә итеп карап алдылар. Бу карашларда үкенечкә охшаган чалымнар да ярылып ята иде. Аңлаган кешегә, әлбәттә...

Ахияр да, соңга калмагаем тагын, дигәндәй, ашыга-ашыга Хәмиткә алтын җепләр белән чигелгән, үтә дә затлы вә дә кыйммәтле түбәтәй киертте.

—Нәселебезгә гадел, акыллы кияү булып кына керүең җитмәгәние,— диде ул шаяртыбрак,—инде изге күңелле яучы булып, ел буе туктаусыз янган хәсрәт утымны сүндерүче дә булдың, рәхмәт сиңа! Талиямнең теләкләренә кушылам. Зария сенлем, бу авыл халкы сине үз итеп, яратып кабул иткән икән, абыең буларак, мин моңа туганнарча шатмын. Инде мине дә, кияү итеп шулай кабул итсәләр, сиңа да зур шатлык булыр ул. Иншалла!—шулай диде Ахияр.

Бу сүзләргә, бик теләп, аның әтисе—кода да кушылып китте: «Изге күңелле кешегә Раббым гел изгелекләр генә кели. Хәмит киявебез шындый кеше булды, шөкер. Алар Зариябез белән икесе нәсел шәҗәрәбезнең матур гына яңа ботагын үстереп киләләр. Алда да шылай тырыш булсыннар! Амин! Ахиярыбыз үстерә башлаган ботакны, ни кызганыч, бер ел элек, җил-давыл сындырды да ташлады. Аның урынына менә бүген сындырды яңа ботак шытып килә, Аллаһының хәерле сәгатендә булсын! Ахияр улым, Талия кызым, без әниегез белән сезгә, шыл шытып кына килүче нәсел ботагыбызның мул җимешле булуын келибез. Сезнең задача—Хәмитләрне куып җитеп, узып китәргә!»—дип шаяртып та алды.

Талиянең әнисе кияүне дә, аның әти-әнисен дә бик ошатты. Касыймның: «әшәкеләрдән-әшәке Ульян мишәре»,—дип мыскыллавын исенә төшереп, «Болар кадәр затлы, мәһабәт кешеләрне ничек дип, шулай әйтергә кирәк? Сокланып туйгысыз кешеләр бит, югыйсә»,—дип сөенеп бетә алмады ул. Тик шулай да, күңеленең бер почмагында үзе дә аңлап бетермәгән бер тынгысызлык ояларга маташа иде кебек. Юк-юкта ишегалдына, капка тирәләренә дә күз салгалап ала. Йә Касыйм үзе, йә шымчылары (кияүне дә артыннан күзәтеп, кәртечкәгә төшерүчеләр шулар диде бит) ямьле көнемнең ямен ала күрмәсеннәр тагы, дип борчылды ул. Өстәвенә, кызының сөйләгән төше дә тынгы бирми. Ышана ул төшләргә. Аларны шактый ук дөрес юрау сәләте дә юк түгел үзендә. Әйе, юрый белеп юрасаң, алда ни көткәнен шул төшләр сиздерә дә инде. Ире белән кайнатасы вафат булыр алдыннан күргән төше дә ни буласын әйтте дә бирде бит әнә. Шуннан соң аның төшләргә ышануы тагын да көчәйде. Күрше-күлән дә күргән төшләрен юратырга дип еш

кына ана керә башлады, бигрәк тә яшь-җилкенчәк, кыз-кыркын йөри.

Талиягә дә үз сүзен, үз юрамасын тәфсилләп бирде ул.

«Кызым, төшенә кергән колынчак—бала булырга охшый. Ул колынны «күршенеке»—дип, кияүнең алып чыгып китүе һич кенә дә ошамый әле мина. Ничек кенә булса да, бер ел буе хатынсыз торган бит. Шул кадәр вакыт сәламәт ир кеше, кем белән булса да бушанмагандыр, дисенме? Нәкъ менә син шул төшне күргән төнне читтә берәр баласы тумады микән аның? Әгәренки дә шулай була калса, үзен әбәзәтелне сиздерәчәк әле ул хатын, сиздерәчәк! Әле ничек кенә сиздерәчәк! Ахирның үлеп бала ятратканын да белсә, мондый ир солтанын ычкындырмас өчен әллә ниләр кылуы бар... Хатын-кыз гел оятсызлана бара хәзер, заманасы шул, дип кенә җибәрәләр. Берүк сак була күр, кызым». Шулай диде ана әнисе. Шулай диде дә, кызының болай да тынгысыз-пошаманлы күнеленә янә тәшвиш салды.

* * *

Фирманың эше гөрләп барды. Зур табыш китерә торган бернича яна тармак ачылды. Касыйм үзен күкнең җиденче катына менеп житкәндәй хис итте. Киләсе Дәүләт советына депутат булып сайлану чараларын да күрә башлады ул. Әмма боларның берсе дә Талияне югалтудан туган сагыш, кичерешләрен баса алмадылар. Ул әле һаман да күнелендәге өмет чаткыларын сүндерә алмый интекте. Һәр иртәне, кабинетына узышлый, кызның үзенә карамыйча гына:

*—Әйләнерсең, тулганырсың,*
*Кайтырсың кулларыма,—*

дип такмаклап үтүләрен дәвам итте. Кайчакларда аның Талияне ярсып сөясе, иркәлисе килә иде. Ә кайчакларда ул нәфрәтеннән шартлар дәрәҗәгә житә...

Талия дә күзгә күренеп үзгәрә башлады. Ябыкты, күз төпләре көеп китте. Монарчы иннек-сөрмәне бар дип тә белмәгән кыз нык кына бизәнергә кереште. Артык бизәнгән кызларны өнәмәгән Касыйм исә, карап-карап йөрде дә, түзмәде, көннәрдән беркөнне әйтә куйды:

—Ташлале шул битләренне акшарлауларынны. Элеккеге чибәрлегенне кайтару өчен сина макияж түгел, ял кирәк. Ял житми сина. Минем белән яшәгәндә барыня—балерина күк йөри иден. Бар кеше дә минем күк түгел шул ул. Кияүгә чыкканына ай да юк, панимаеш ли, бөтенләй төс салдын. Әле бу—башы гына, битләрен кара тут белән тулгач нишләрсен икән? Ул чакта инде макияжынны килосы белән сыласан да ярдәм итмәс...

—Ул чактамы? Ул чакта мин жиргә тагын да горур басып, алар минем ана буласымны белдереп торучы изге тамгаларым, дип куанып йөрермен! Касыйм Кадыйрович, әйдәгез, минем битләремне дә, Алла бирсә, анда күренәчәк кара тутларны да калдырып торыйк әле. Минем сезгә бер соравым бар. «Фирманың табышы күпкә артты»,—дидегез. Кичә без акча алдык. Ә минем эш хакым шактый кимегән. Моны ничек анларга?

—Вазифан кечерәйде бит.

—Ничек кечерәйде сон әле ул?

—Элек син секретарь плюс тере сөяркә иден, ә хәзер—коры секретарь, ягъни сәркатип кенә,—дип шаркылдап көлеп җибәрде Касыйм.— Монысы инде гел чиста, үзегезгә тиеш булган эш хакыгыз, иптәш сәркатип.

—Ә иремә ничек анлатыйм?

—Нәрсә, акчанны да саный башладымыни инде? Ну, дает... молодец!—дип көлемсерәде Касыйм.

—Әй, сезнен белән сөйләшеп буламыни...—дип, кул селтәп, Талия кырт борылып ишеккә юнәлде.

—Ярый, ярый, чәпчемә, шаярттым гына. Киләсе айда аерманы

алырсың. Әмма шаяртсам да, җанкисәгем, мин сиңа чын хакыйкатьне әйттем. Ачулансаң, ачуланырсың. Талия, минем синнән өметемне өзгәнем юк әле... Фәридә Кудашева да үзәкләре өзелеп җырлый бит, син дә ул җырны яратып җырлый идең. Хәзер миңа калды җырларга...

*Беләм, син кайтмыйсың, шулай да,*
*Кайтырсың шикелле тоела...*

—Касыйм абый, сез өегездә дә шулай җыр сүзләре белән сөйләшәсезме? Мин кияүгә чыкканнан бирле җыр сүзләрен бигрәкләр дә еш әйтә башладыгыз, нәрсә бирә соң ул сезгә?

—Их, бәгырькәем, җыр-шигырь яратканыңны беләм бит, җырлый да, тыңлый да беләсең. Ә өемдә дүрт кыз бала, үзе дүрт балага торырлык теща-әби, плюс хатын—менә сиңа алты хатын-кыз, әле җитмәсә мәчебез дә кыз җенесеннән бит, үзем белән буладыр җиде җан. Җыр кайгысымыни анда?! Синең өчен генә бит ул алар! Инде аны да тыймакчы буласыңмы?

—Касыйм абый, тыйганга карый торган кешеме инде сез? Мине бик уңайсыз хәлдә калдырасыз бит. Болай ярамый инде. Иремә дә ишетелүе бар. Әгәр дә, бәхетсезлегемә, Ахиярдан аерылып китәргә туры килсә, мин сезгә инде кире кайтмаячакмын, шуны һич онытмагыз.

Шул кичтән башлап Касыйм, авыр булса да, Талиягә шигырьләр кушып сөйләвен туктатып, үзен гел салкын, рәсми тотарга тырышты.

* * *

Августның урталары җитте. Ниһаять, атна буе диярлек койган яңгыр да туктады. Көн гаҗәеп матур булып ачылып китте. Күк йөзе зәп-зәңгәр, ник бер болыт кисәге күренсен! Кояшның кыздыруы да июльнекеннән һич тә ким түгел. Табигатьнең шушы сихри тәэсиреннән дәртләнгән Талия бакчада җир җимертеп эшләде дә эшләде. Ахияр аны хәтта кисәтергә мәҗбүр булды. Соңгы көннәрдә хатынының, үз-үзен белми, шатлыктан очынып йөрүләрен ир эченнән генә юрап та куйды. «Аллаһы кушып, бәбигә узып йөрми микән? Шулай гына булсачы, йә Раббым!

Дүшәмбе көнне Талия эшенә дә очып килгәндәй килде. Икенче каттагы бүлмәсенә менгәндә ике баскычны бер итеп кенә атлады. Ачык ишектән хуҗасын күреп алгач, бераз тыйлыга төште үзе. Җылы гына исәнләштеләр. Талиянең кәефе күтәренке булуын сизеп алган Касыйм түзмәде, бераз шаяртып аласы итте:

—Син бүген ишектән килеп кергәндә—«Кояшым син, аем син»,—дип әйтерлек идең, чак кына түздем. Шатлыкларың Урал таулары шае дип әйтимме?

—Миңа һаман аягүрә йокымсырап йөрергә димәгәндер бит инде?

—Яңа тормышына тәмам ияләшеп беттең бугай, ә?

—Касыйм Кадыйрович, без сүзгә кереп китсәкме... Аллам сакласын! Лутчы эшкә тотыныйк...—дип, Талия үрли башлаган гәп колмагын кырт итеп өзеп ташлады.

Ләкин шатлык дигәне, һай кызганыч, бик кыска вакытка гына килгән икән шул. Кисәк кенә үзендәге үзгәрешне сизүгә, коелып ук төште ул. Күзләреннән ихтыярсыз кайнар яшь бәреп чыкты. Көне буе күңеле күтәрелмәде. Касыйм да сәркатибендәге бу кискен үзгәрешне сизми калмады. Тик ул аны үзенчә аңлады. Ике аралары шәп түгел ахрысы, ничек итеп кенә бу кызган саламга ут төртеп, дөрләтеп җибәрәсе икән дип, сөенеп тә куйды әле . Күңелендәге өмет очкынын янә кабызып җибәрде бу хәл. Озын-озак уйлап тормады, үз ресторанңарында утызынчы августны бәйрәм итәргә җыенганнарын әйтте дә, Талиягә ире белән парлап килергә кушты. Ахияр белән якыннан танышасы килүен дә сиздерде. Әмма бу чакыру астында нинди мәкер ятканын сизмәде шул Талия, һай, сизмәде...

* * *

Фирманың рестораны кала уртасында, Болак буеның ин җайлы матур бер җирендә урнашкан иде. Нәкъ көндезге унике тулганда кунаклар җыелышып беттеләр, нишләптер, Талияләр генә күренмәде.

Менә бераздан, соңга калып булса да, Талия дә килеп житте. Хатынның монсу йөзен, уйчан күзләрен күреп алган Касыйм тиз генә аның янына килде дә, һәр сүзенә рәсми төс бирергә тырышып:

—Нигә үзең генә, парлап чакырганыек бит?—дип, салкын һәм кырыс кына сорап куйды.

—Ахияр игътибарыгыз өчен рәхмәт белдерде, килергә риза да булганые, югыйсә. Туганнан туган абыйсы вафат булган. Аңа бүген Ульяньга очарга туры килде.—Талия дә салкынга салкын гына җавап бирде.

—Әйдә, безнең янга түргә уз. Сезнең өчен урынны махсус шунда калдырганыем—диде Касыйм.

—Юк, юк, Касыйм Кадыйрович, мин монда гына утырыйм әле,—дип, Талия сак кына ишек янындарак торган урындыкка килеп утырды. Гәрчә бәйрәм мәҗлесе бик күңелле барса да, ул монда үзенә ямь таба алмады. Гасабилы күңеле бар вөҗүде белән каядыр алгысына иде. Кая—үзе дә белми... Тизрәк бу шау-шудан ычкыну, котылу кирәк иде аңа. Җаны шуны таләп итә иде. Соңгы вакытларда кереп чыгарга да вакыт тапмаган, хәзер инде гел үзенеке саналган фатирына ашыкты ул. Бәйрәмнән соң анда кайтуын Ахияр хупламаса да, телефоннан сөйләшкәндә: «ярар инде, үзенә кара»,—дип сүлпән генә ризалыгын бирде. Хатынын үпкәләтүдән куркып кына ризалашты бугай.

Тәмам кыза барган кунаклар Талиянең киткәнен сизмәделәр дә. Йортына килеп җитү белән үк дулкынлана башлады ул. Ишеген ачуга, эчтәге ят караңгылык, бушлык, тузан исе авыр тәэсир уятты. Ул тиз генә калын пәрдәләрне тартып, бөтен өйгә кояш нурлары белән җан өрде. Тузан суырткычын да эшкә җикте. Кайда гына оялмамаган бу тузан, дымлы чүпрәккә дә эш табылды. Тәрәзәләрне ачып җибәрүгә, бүлмәләр җиләс һава белән тулды. Эш беткәч, һәр бүлмәдә бераз утырып, шундагы җиһазларга карап җанына рәхәтлек алды ул. Бүлмәләрендәге һәр көзге каршында тукталып, үзен күзәтергә дә онытмады. «Үз өенә кайткач, чибәрләнеп киткәнсең түгелме соң»,—дип елмайган булды, ул. Кызуланып эшләүдән битләре алсуланып китүне үзенчә юрады. «И, көзгеләрем минем, сез дә сагынгансыз ахры,яклашасыз бит, теге йорттагылар битемдәге алсулыкны яшереп, күз төпләремә күләгә төшереп күрсәтәләр»,—дип көзгеләре белән дә сөйләшеп алды. Аннары исә чистарткач ялт итеп калган савыт-сабаларын күзләре белән иркәләде. Шулай, бөтен хуҗалыгын барлап чыккач: «Сез барыгыз да, чыннан да, минекеләрме соң? Мәгәр Ахияр абыегызга ярый алмасам, кайтыр-егылыр урыным була алырсызмы? Үзең ташлап киттең бит әле безне, дип үпкәлисездер инде. Ахияр абый бик тә әйбәт кеше бит. Аның йортында да яшәргә яратам шул. Ай-һай, нәфесең бигрәк зур, дисезме?—Ул әнә шулай үз-үзе белән рәхәтләнеп сөйләшеп йөрде. Аннары күңеленнән: «Җитәр, җүләрләнәсең бугай инде. Хәзер үзең юын, чистарын да, бисмилланы әйтеп, белгән доганны укы. Кылган гөнаһларың өчен тәүбәгә кил, Аллаһының ярлыкавын сора. Менә шуннан соң инде үзенә бәби җибәрүен телә»,—дип җинел адымнар белән ванна бүлмәсенә юнәлде.

Талиянең бәйрәм мәҗлесеннән ничек, кайчан китеп барганын Касыйм үзе дә сизми-күрми калды. Аның бүген аерата монсулыгы, юк-юкта йөрәкне телгәләп алырлык итеп үзенә карап куюлары ирнен күз алдыннан китмәде, чын мәгънәсендә бәгырен сулкылдатты. Стадионда барган концерт та күңелен җәлеп итә алмады аның. Өенә дә кайтасы килмәде. Фәкать тугызлар тирәсендә генә, тән сакчысын ияртеп, өенә кузгалды. Юл унае булмаса да, аяклары, ихтыярсыздан, элек Талия торган тыкрыкка борылды. «Ярар, тәрәзәләренә булса да карап үтәрмен»,—дип

уйлады ул. Берзаманны, йә Раббым, үз күзләренә үзе ышанмады: урам ягындагы тәрәзәләрдә ялт иткән ут! Нәрсә бу? Йорт басучылармы? Фирмадагыларның берәрсенә әллә ачкычын биргәнме Талия? Алай икән, нигә миңа әйтмәгән? Нишләргә? Кирәк чагында ачкычы да юк бит аның, һай, мур кыргыры! Ни булса да булыр, дип, Касыйм ишек кыңгыравына басты. Җавап юк. Тагын басты. Тынлык... Милиция чакыртырга кирәк, дип уйлады ул. Шулай да, өченче мәртәбә шылтыраткач, Талиянең эчтән: «Кем ул?»—дигән тавышы ишетелде.

—Талия, син үзең генәме? Кайтышлый тәрәзәңдә ут күргәч, без, аптырап, Саша белән тикшереп карасы иттек,—диде Касыйм, гаеплерәк тавыш белән..

Ишек ачылып китте. Талияне күргәч, шатлыгы эченә сыймады Касыймның! Хәер, ул шатлыгын яшереп тә тормады. Тик куркудан, бу көтелмәгән очрашудан ап-ак булган Талия генә тынычлана алмады.

—Тәмам котымны алдыгыз бит. Касыйм абый, Сез Сашадан калмагыз инде, бергә килдегез, бергә китсәгез яхшы булыр ие,—диде ул, калтыранган тавышын басарга тырышып.

—Саша кайта торсын. Синең белән ачыклыйсы бер соравым бар әле. Җавабыңны ишетү белән китәрмен, курыкма,—диде Касыйм.

Сашаны озатып керүгә, Талияне каршысына утыртты да, сорауларын яудыра да башлады бу:

—Соңгы көннәрдә нигә бик күңелсез йөрисең әле син? Ни булды? Бүген аерата хәсрәтле идең. Монда ни өчен кайттың? Әллә начар торасызмы?

—И-и, Касыйм абый, сезнең мең соравыгызга җавабым бер генә—балага уза алмыйм бит... Мәгәр мин бала тудыра алмасам, ул риза булып тормаячак...—дигәнен сизми дә калды Талия.

—Йә, шуннан дөнья бетәме? Борыл да кайт үз «оҗмахыңа», берни дә югалтмыйсың ич!

—Берни дә югалтмыйм, имеш. Мин бит урманда түгел, кешеләр арасында яшим, кешеләр арасында эшлим. «Иргә ярый алмады, аңа сөяркәлек кенә төс»,—дигәннәрен ишетергә теләмим, хурланам. Сез шуны аңлыйсызмы? Тугры ирнең тугры хатыны, күп балалы газиз ана булып, балаларымны намуслы, иманлы итеп тәрбиялисем килә. Ни өчен бу өйгә кайттыммы?—Әйе, шушындагы байлыкны, хатын-кыз өчен уңай җайланмаларны сагынып кайттым. Куана-куана җыештырып, барына да сокланып туя алмадым. Сезгә дә рәхмәтләр укып, шушында узган матур көннәрне искә алып утырдым. Түзә алмадым, хәтта шкафтан алып, үз гомеремдә беренче мәртәбә, сездән башка, бераз гына коньягыгызны да эчеп куйдым. Менә шуннан соң, бу «оҗмахны» сагыну хисләрем капма-каршыга әйләнде дә куйды. Узган матур көннәр, дидем... Матурыемы соң алар? Дүрт кыз бала үстерүче ананың рәнҗешле күз яшьләре белән катнаш төннәр матур була аламы? Минем балага уза алмавым да шуларның рәнҗеш-каргышлары түгел микән әле? Аннан соң, менә бу байлыклар миңа тиешме соң әле? Нигә мин монда үземнең яраткан, миңа белем биргән укытучыларымны чакырып кунак итә алмыйм? Ә менә Ахияр абыйның йортына мин аларны рәхәтләнеп чакыра алам. Анда мондый роскошь юк. Йомшак мебельдән башкаларын барын да үз куллары белән ясаган ул. Зур эшләр, төзелешләр булса, барлык туганнары бергә җыелып эшлиләр, дуслыкларына сокланып туймассың.

Түземлеге төкәнгән Касыйм:

—Синең ирең дәүләт эшендә атнага ике көн ял итә. Безнең ишеләргә аның бер көне дә эләкми,—дип сүз кыстырды.—Син менә шушы фатирыңны, мондагы әйберләреңне бик зур байлык дип саныйсыңмы? Чын байлыкны әле синең күргәнең юк шул. Аны син түгел, шактый зур табышлы эшкуар булсам да, минем дә күргәнем юк.

Бездәге салымнар эшкуарны талауга көйләнгән. Ә хөкүмәт тирәсендә оялаган түрәләр дәүләт милкен җайлап кына, чүп кенә бәягә үзләштереп,

хәзер инде престижный фатирларының, өчәр-дүртәр катлы коттеджларының санын да белмиләр. Әле ул гына да житми, чит илләрдә виллаларын булдыралар. Чит ил банкларындагы долларларының да исәбе-хисабы юк. Балалары, хатыннары кибетләр, даруханәләр, ательелар, рестораннар, барлар, тагын... тагын әллә ниләр тоталар. Шуларның һәрберсенең үзләренә аерым шоферлары белән джип машиналары бар. Шәһәрнең иң жайлы урыннарындагы жирләрне тиз генә үзләренә алалар, шунда ук нидер төзеп куялар да, эшләрен дә ачып жибәрәләр. Ә безнең ише гади эшкуарның төшенә дә керә алмый бу жинел мөмкинлекләр. Начар гына жирне алу өчен дә шуларның учына акча төртә-төртә еллар буе чабасың...

Ә син фирма кичергән бөтен авырлык, киртәләрне белә торып... Их, Талия... Талия... Үзеннекеләрне генә алыйк, гомер буе колхозга бил бөгеп, күпме салымын түләп, жимерелергә торган өйдә яшәгәннәр. Сыер тоту турында хыяллана да алмаганнар. Кем соң аларның хыялларын тормышка ашыручы, ә? Ә үзенә инглиз телен өйрәнергә кем мөмкинлек бирде? Киләчәктә сине югары белемле итүне дә фирма үз өстенә алмадымы? Инде үзенне КХТИга да хәзерли башлаганнарые бит.

—Гафу ит, Касыйм абый, коньягың да күнелемне кузгатты бугай. Барысы өчен дә рәхмәт. Үзегезне дә, әни белән мина кылган яхшылыкларыгызны да беркайчан да онытмабыз. Бик еш искә алам мин сезне, Касыйм абый, сагынып искә алам. Яраткамындыр, күрәсең.

Алар әнә шулай, хатирәләрне яңарта торгач, гөнаһ шомлыгына каршы, төн узганын сизми дә калдылар...

* * *

Ниһаять, октябрь ае Талиягә зур сөенечләр китерде. Әле көннәр ул чаклы суык булмаса да, имчәкләренең аерым гына туңа башлавына һәм имчәк башларының төсе үзгәреп, каралыбрак китүенә сәерсенми кала алмады ул. Моны Ахиярына да әйтеп карарга булды. Ә анысы бу хәбәргә сөенгәнен белдереп, серле генә елмайды. «Аларны туңдырырга ярамас, каяле, үзем һәйбәтләп жылытыйм әле»,—дигән булып хатынын кочагына алды һәм колагына: «Мин ул үзгәрешне, сина сиздермичә генә, Аллага шөкер, дип күзәтеп йөри идем инде»,—диде.

Көннәр үтә торды, карындагы бәби үзен торган саен ныграк сиздерә барды. Ул казның баш-аяклары һәм эчке дирбияләре белән пешкән шулпалы бәлеш талап итү дисеңме, алма катнаштырып тозланган кәбестә дисеңме, әлү кагы, мичкә тәгәрәткән бәрәңге, тагын... тагын әллә ниләр... Әти буласы кеше көне-сәгате белән барын да табып торды.

Талия корсагын матур күтәрде. Косып маташулары да бер-икедән артмады. Тәскә-биткә дә әллә ни үзгәрмәде. Гәүдәсе дә матур гына түгәрәкләнеп килә. Ахияр аны күбрәк һавала йөртергә тырышты. Инде туачак сабыйга исемнәр дә эзли башладылар. «Малай икән—Булат исемле куярбыз»,—диде әти буласы кеше. «Кызга—Назлыгөл кушарыем. Син бит гөлләр яратасың, аларны шулкадәрле дә иркәләп-назлап үстерәсең, кайчакларда көнләшеп тә куям. Бу исемне дә синең хөрмәтенә дип эзләп тапканыем»,—диде булачак әни кеше.

Менә беркөнне, Аллага тапшырып, УЗИ аппаратыннан карату өчен консультациягә киттеләр. Ахияр машинада калды. Һәм ул, килгән-киткән һәр авырлы хатын-кызны күздән уткәреп, һәрберсенә үзенчә соклана торды. «Авырлы хатын-кыздан да мәхәббәтлерәк беркем юктыр бу дөньяда»,—дип, соныннан нәтижә дә ясап куйды ул. Әнә, берсе көчкә атлап килә. Йә, Раббым, тау кадәрле корсак, бер генә түгелдер, мөгаен. Яше дә шактый күренә. Барган жиреннән эчен тоткалап, туктап-туктап та ала, тыны житми ахры. Өсте-башы да әллә кем түгел. «Ходаем ярдәм итсен инде бу бичарага»,—дип анысын кызганып калды ул. Икенче берәве—яшь кенә, корсагы шактый күренә, йөзе нигәдер саргылт, әллә бавыры авырта микән? Ишектән чыгуга туктап калды. Туктады да, менә

сиңа мә, хикмәти Ходаl Кесәсеннән тәмәке белән шырпы чыгарды! Вәт җүләр, әллә тартырга маташа инде... Әйе, бөтен фасонын китереп, тәмен белеп тартучылар шикелле суыра да башлады бу. Ахияр түзмәде, машинасыннан чыгып, аңа таба атлады:

—Нишлисез сез, әй, үзегезне кызганмасагыз, туачак балагызны кызганырыегыз, ташлагыз тартуыгызны!

—Какое ваше дело? Не лезьте, что мне делать, я сама знаю, не маленькая. Если ты такой хороший, отвези меня в ресторан и угости,— дип хихылдап көлеп җибәрмәсенме кызыең! Ахиярның аягыннан башына кадәр күз йөртеп, оятсыз, мыскыллы карашын ташларга да тайчанмады, җир бит. Бу хәлне һич көтмәгән Ахияр бөтенләй әллә нишләп китте, башына зур кусәк белән тондырдыларммыни...

—Их, син юньсез, татар булмасаң—бу кадәр хурланмасыем. Милләтнең җан көеге бит син. Туачак балаң сиңа харам бит,—дип кенә әйтә алды ул.

—Харам, харам... он мне совсем не нужен. Наша Татария ведь богатая, будет воспитывать! А если не хотят, пожалыста, тогда американцам отдам. От них я за него и сама кое-что буду иметь, по-нят-но?

Нәкъ шул вакыт, язгы кояштай, йөзеннән көлтәсе белән нур сибеп чыгып килүче хатынын күргәч, ире барын да онытып, аның каршына ашыкты.

—Ахияр абый, җаным! Сөенче, сөенчегә ни бирәсең?! Йә, әйт инде, нәрсә бирәсең? Моның кадәр сөенечне күтәрә алырсыңмы икән, белмим. Егылып китсәң мин тотып кала алмам. Аякларыңа ныклап бас, яме!—Әйе, бу минутларда Талиянең шатлык тулы күзләреннән, дөрестән дә, тирә-юньгә көлтә-көлтә нур сибелә иде!

—Ни теләсәң дә бирәм, тизрәк әйт кенә.

—Син, кем дип әйтсәм, бик тә каты сөенериең, ә?

—Әллә Булатмы?

—Әйе, Ахияр абый, малай диделәр. Назлыгөлне икенче килгәндә бирербез, ә бу юлы Булатны алып торыгыз әле диделәр.

Ахияр, Талияне күтәреп алып машинага килеп җиткәнче үбә-үбә барды. Биттә үбелмәгән бер генә урын да калмагандыр, мөгаен.

Машинага кереп утыргач ул: «Ходаем миңа башта күтәрә алмаслык кайгы биреп сынады. Шөкер, сынмадым, сыгылмадым, җибәргән кайгы-хәсрәте өчен ялгышып кына да аңа тел-теш тидермәдем, ризасызлык күрсәтмәдем. Хәзер менә рәхмәтен индерә, башта сине җибәреп гаиләмнең яңа нигезен салды. Инде гаиләм тулы булсынга ир бала бирә,—дип шатлана-сөенә тезеп китте ул. Ә күзләрендә яшь тамчылары җемелди иде. Бу—кичергән бәхетсезлекләрен җиңү шатлыгы белән алмашка туып килүче бәхетенең катнаш яшьләре иде.

Шатлыгы эченә генә сыеп бетәрлек булмаса да, Ахияр хатынына күз тиюдән куркып, бу хакта беркемгә дә чишми торырга карар кылды. Мона Талиясен дә ризалата алды шикелле. Әмма кайсы гына хатын-кызның карынында ир бала йөртүе белән горурланып мактанасы килмәс икән?! Талия дә, бу олуг сөенече тел очыннан ычкынырга гына торса да, түземлеген ике көнгә җиткерә алды. Ике көн буена аның йөзеннән елмаю бер генә минутка да югалып тормады. Хәер, теле белән әйтмәсә дә, күзләреннән сибелгән очкыннар, йөзеннән бөркелеп торган якты нур, беренче көненнән үк, аның эчендә, яшерә алмаслык, олылардан-олы шатлыгы барын болай да кычкырып тора иде анысы. Бу хәбәрне беренче ишетүче фирманың хисапчысы Тамара булды, ә аның кушаматы—сер тотмас үрдәк.

Аяз көндәге яшендәй, җәен яуган кардай, Касыймга да килеп житте бу яңалык. Күнелендә сүнәр-сүнмәс кенә пыскып торган өмет учагына, әйтерсең лә зур бер чиләк бозлы су ордылар... Нишләргә дә белмичә, бер мәлгә ул бөтенләй югалып калды. Аннан, кабинетыннан чыгар-чыкмас, сәркатибенә күз төшерде. Аның бөтен бүлмәгә нур чәчеп,

тыныч кына эшләп утырганын бераз карап торгач, ишекне бәреп ябып, кәнәфиенә барып утырды һәм... уйга калды. Нишләп оныта алмый ул аны? Күрәсең, кырык жиде яшенә житеп, әле беркемне дә болай яратканы булмагандыр шул. Хатынына да яратып түгел, мәжбүри генә өйләнде бит ул. Исерек чакның ямьсез бер кыйссасы гына булган очрашудан арына алмады ул чагында егет. Дөньяга туачак бер гөнаһсыз жанны ятим итәргә намусы күтәрмәде. Аннары исә китте... Бер-бер артлы китте кызлар, китте кызлар... Ә менә бөтен мәшәкать-борчулардан онытылып, ләззәтләнеп ял итеп алу фәкать Талия янында гына була иде шул. Юк, аларны ятак кына берләштермәде. Икесенең дә шигъри моң, жыр белән тулган күңелләре дә, күп нәрсәдә уртак фикергә килә алулары да һәр очрашуларын бизи, тулыландыра, үзенчә мәгънәле итә иде. Талия аның өчен, һәр битен ачкан саен ташлый алмый укый торган тәмле китапка әйләнде. Әйе! Укыган әсәрләре турында сөйли башласа, Касыйм аны «артистлар да шулай сөйли алмый бит»,—дип рәхәтләнеп тыңлый иде. Ник кенә рөхсәт итте икән соң ул аңа кияүгә чыгарга? Ник кенә үзеннән балага уздыру чарасын күрмәде? Чукынып китсение кеше сүзе! За то малае туган булырие бит. Барысын да алып, эшкуар дусты Рафаэль шикелле Гонконгка гына китәсе иде. Күпме чакырды бит аны дусты, әнә, гөрләп эшләп ята хәзер. Андагы салымны безнеке белән чагыштыра торган да түгел икән, ничек ул баемасын...

Ташкын булып арта барган үкенү хисләренә, чыдый алмыйча, хәтта үз-үзен белешмичә: «Их, син—дурак!»—дип дәү йодрыгы белән өстәленә шундый итеп китереп орды Касыйм. Кырыйда гына торган сулы бәллүр кувшин идәнгә очты, чәлпәрәмә килде. Бу үтә дә кискен-сәер тавышларга сискәнеп киткән Талия кабинетка атылып кереп:

—Ни булды, Касыйм Кадыйрович? Агарып та киткәнсез...

—Агарырсың монда...—Соңгы вакытта шактый ук чал иңгән чигәсенә таянып уйга талган ир әллә көлә—әллә сулкылдый иде шунда ... —Калдырыгыз—мин жүләрне... кал-ды-ры-гыз! Бөтенләй кайтып китсәгез, яхшырак та булыр. Йә—хушыгыз...

—Гафу итегез, сау булыгыз,—дип Талия тизрәк моннан таю ягын карады... Һәм икенче көнне үк, декрет ялына кадәр түләүсез ял алып, эштән китеп тә барды.

Көткән вакыт якынайган саен, Талиянең тынгысызлыгы да арта барды. Баламны зәгыйфьләндермичә генә тудыра алырмын микән? Нинди акушерка туры килер икән? Имезергә сөтем булыр микән?—Әнә шундый, берсеннән-берсе борчулырак сораулар бимазалады аны. Гәрчә табиблар килгән саен тынычландырырга тырышсалар да, хатынның үз туксаны-туксан иде.

Май урталарыннан соң Талиянең корсагы чүпрәсеннән уңып, күпереп күәсеннән ташырга торган камыр төсле, күзгә күренеп зурайды. Ә майның соңгы иртәсен ул шактый кәефсез каршылады. Кисәк-кисәк әле эче, әле биле авыртып китүдән «ай», «ай» дип куйгалады. «Ни гажәп, үзе тиз ычкындыра тагы... Нишләп икән? Әллә ярамаган берәр әйбер ашадым микән?»,—дип тә уйлап куйды. «Бәлки тулгак дигәннәренең башлануы шулайдыр. Яшең шактый булса да, бигрәкләр дә бернәрсә дә белмисең шул әле»,—дип үзен-үзе дә битәрләп карады. Ахиярның каушап киткәнен күреп: «Карале, Булатың нишли, әле билемнән, әле эчемнән чеметә генә бит. Әтиенә әйтәм бит, дигәч туктый үзе тагын. Күп тә үтми, шундый да авырттырып тагын чеметә башлый, шаян»,—дип шаяртып алырга да көч таба иде үзе.

Баласын тудырган вакытта да тешләрен кысып түзде. «Мина башкалар шикелле сабырсызланып акырырга ярамас. Чөнки мин бу баланы Раббымнан үзем ялынып сорап алдым бит. Йә, Раббым, мин ничек тә түзәрмен, баламны сау-сәламәт итеп кабул итсәние!»—дигән сүзләрен, хәле кыенлаша барган саен кабатлады да кабатлады.

Ниһаять, таң алдыннан бала дөньяга килде һәм шунда ук бөтен

бүлмәне яңгыратып җылап җибәрде. Йә, Ходаем! Шушы сихри тавышны ишетү өчен күпме хыялланды бит ул. Ничекләр итеп шөкрана кылмыйсың! Кайвакытларда әнисе дә: «Шушы кадәр ашкынып бала теләвең хәерлегә микән...» дип куркыткалап куя иде. Кендек әбисе кулында җемелдәп торган зәңгәр күзле, түгәрәк йөзле тупыр-тупыр килгән улын күрүдән ташыган хисләрен язып бетереп кенә булмас, мөгаен. Шул татлы хисләрдән ике күзенә мөлдерәп яшь тулды: үзе көлде, үзе елады... Һай, мең газаптан соң туган татлы вә ләззәтле бу мизгелләр...

Ярты сәгать саен телефоннан чылтыратып торган Ахиярга аптырап беткән бер шәфкать туташы: «Телефоныгызны гына әйтегез, без үзебез хәбәр итәрбез»,—дип кенә котылган иде. Инде ниһаять, вәгъдәләрен онытмыйча, нәкъ сәгать өч тулганда бу шатлыклы хәбәрне Ахиярга ирештерделәр. Шуннан соң гына кызының тугач та төшергән фоторәсемнәрен, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, җыйнап алып куйды. «Минә кызым, кара күзем, без синең белән икәүләп төне буе әнеңнең таза-сау булып тууын теләп утырдык. Ниһаять, әле генә син калдырып киткән фани дөньяга Булат энең туды. Синең бу матур рәсемнәреңне мин аңа да күрсәтермен әле. Бераз үскәч, ул да безнең белән, туган көннәреңдә синең каберенә килер, чәчәкләр китерер, син бит минем бердәнбер апам булгансың, дияр, Аллаһы боерса! Эх, балакаем минем, белсәң иде үзәкләрем өзелеп сагынганымны, «Кара күзем, карлыгачым»—дип сөя идем үзеңне, ә син: «Әтием, бәгърем, мин сине бик яратам шул»,—дип елмаеп муеннарыма сарыла идең»,—ул әнә шулай һәр фоторәсемне үбә-үбә өстәл тартмасына салып куйды. Үзенең күзләре мөлдерәмә яшь иде. Өзгәләнеп кызын сагынудан һәм беренче малае туудан ургылып чыккан шатлык белән катнаш сагыш яшьләре иде алар.

Дивардагы фоторәсемнәрдән күзәтеп торган Сәриясе: «Без дә сине бик сагынабыз да, нишлисең, язмышыбыз шулай булган... Ә син борчылма ул кадәр, хәзер алар икесе дә изрәп, бик тәмләп йоклыйлар. Бар, син дә йоклап ал»,—дия кебек иде.

Баланы Кама буендагы йортта көттеләр. Сембердән әби белән бабай берничә көн алдан килеп өйне җылыттылар, мунча яктылар, чәчәкләргә мул итеп су сиптеләр. Талия яраткан шулпалы бәлешне пешерергә әзерләнделәр. Авылдагы әбисенең дә сынатасы килмәде. Бала өчен үзе сырган атлас юрганын, киезен, мамык мендәрен, үзе пешергән чәк-чәк, бавырсакларын һәм каклаган казын да кушып, такси белән килеп тә житте. Каршысына каударланып чыккан кода белән кодагыйны күргәч, аның йөзеннән сибелгән шатлык нурлары бөтен Кама буен яктыга күмәрлек иде шикелле.

—Аллага шөкер, сезнең дә килгәнегезне ишеткәч, сөенечем эчемә сыймады. Кияүне дә борчып тормыйча гына, икесенә дә сюрприз ясыйсым килеп, туры монда килдем. Беренче оныгымны сезнең белән бергәләп каршылыйсым бик тә килде. Өйләнешкән көннәреннән үк кызымны зурлаганыгыз өчен Раббым үзегезне дә зурласын!

Машинадан алган бүләк, күчтәнәчләрне күреп:

—И-и, кодагый җаным, син бигрәк зурдан кубкансың ич, рәхмәт төшкере! Каклаган казыңны күргәч, киявең егылып китмәсә ярый инде...—дип кода әйтә башлауга, кодагый, аны бүлдереп:—Чыннан да Ахиярымның болай ук яраткан ризыгын белмим мин. Аның белән корсаклы чагында каклаган каз дисәләр дә, шундук авызымнан сулар килерие, ул гынамы, калтырана ук башлый иием. Тугыз ай буена ашадым мин каклаган казны. Әтәләре бетә-бетешкә табып кына торды. Бәрәңге белән каклаган каз ашап, артыннан кара әпәй белән биш-алты чынаяк куе сөтле чәйне эчеп кәк итеп йөри торганыем. И-и, безнең дә барые бит яшь чаклар... Хәзер менә, Аллага шөкер, оныкларыбызны көтеп алабыз.

Күп тә үтмәде, өзлексез машина кычкыртуын ишетеп, кода-кодагыйлар дәррәү капка ачарга йөгерделәр. Машинадан бала күтәреп, авызын колагына кадәр ерган Ахияр чыкты.

—Әтәй, ата хакы зур булса да, шөкер, син инде күп оныкларыңны беренче булып кулыңа алган кеше. Мин бүген улымны түземсезлек белән беренче оныгын көткән дәү әнисенә бирим әле!—диде ул тантана белән.

Шәргыя куенындагы оныгыннан күзләрен дә ала алмыйча иң бәхетле мизгелләрен кичерде. «Йә, Ходаем! Сабыемны да рәхмәтеңнән ташлама?»—дип, мөлдерәмә тулы шатлык яшьләренә ирек куйды. Кодалары үзен кочаклап алганнан соң гына бисмилласын әйтеп, оныгын кода кулына тапшырды. Өйгә алып кереп үз караватына салгач, аны бишәүләп сырып алдылар һәм һәркайсы, балага карап, үзенчә, тын гына уйга калды. Беренче булып кодагый сүз башлады.

—Рәхмәт, Талия, үзем өч бала тудырып, үземә ник берсе охшасын. Бары да әтиләре төсле: озынча йөзле, кап-кара чәчле, шомырт кара күзле булдылар. Ә бу бала, сөбханалла, күзем тимәсен, миңа охшап, түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле булган бит.

—Әнәй, чәчләре бөдрә, ияге безнең малайныкы төсле матур гына батып торган туганнар да булмады микән безнең нәселдә?—дип сорап куйды Ахияр.

—И-и, улым, кем хәтерләп бетергән инде аны. Ә-ә-ә, сенлең Мәсхүдәнең улы бөдрә чәчле бит. Димәк Булатыбыз безнең якка тарткан, балакаем.

—Мәсхүдәнең ире үзе бөдрә чәчле бит,—диде Ахияр.

—Бишектәге бала әле бишкә төрләнә, диләр. Мин үзем дә түгәрәк йөзле, зәңгәргә охшаганрак яшькелт күзле бит. Бәлки әле ул минем якка да тарткандыр,—дип Талия сүзсез генә уйга калган әнисенә борылды.—Әни, Булатны бүген әнкәй белән бергәләп, сез коендырырсыз инде, яме. Мин карап, өйрәнеп торырмын, үзем тотынырга куркам әле,—диде.

—Кара син аны, читтән карап торып кына өйрәнмәкче. Үзең катнашмый өйрәнеп булмый аны. Бүген минем белән, ә иртәгә кайнанаң белән бергә коендырырсыз. Миңа иртүк китәргә кирәк. Өйдә күрше Зөлкамал карчыкны гына калдырганыем,—дип Шәргыя эшне үзенә кирәгенчә җайларга уйлады.

Мунчага кереп бикләнүгә үк Шәргыянең беренче соравы болай булды:

—Кызым, кияүнең Касыймны күргәне бармы?

—Анык кына әйтә алмыйм шул, әни...

—Балаң кемгә охшаган, дип уйлыйсың? Кияү шикләнгән төсле күренде миңа. Әллә инде, балакаем...

—Син дә йөрәгемне бозма инде, ичмаса. Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер, дигәндәй, әллә ниләр юрап утырма әле монда...

—Юраганым юш кына килә күрмәсен инде берүк. Кияүне бигрәкләр дә яратканыем шул. Кодалар да сокланып туя алмаслык кешеләр бит. Шөкерләр итеп кенә яшисе урынга, нишләпләр генә ялгышып киттең икән соң, балакаем?

—И-и, әни, кияүгә чыгып, Касыймны ташласан, риза-бәхил түгел дип баштук кем әйтте—син! Нәчәльник хатыннарының күбесе сөяркә тоталар икән, дип тукып торучы да син түгелме соң?! Онытмагансыңдыр әле, унтугыз яшемдә үк, Касыйм абый сиңа өй салып бирергә вәгъдә биргәч, ашка чакырганнарые дип, безне кич буена ялгыз калдырып чыгып киткән әни кеше—син түгелме соң? Бабаем исән булган булса, янымнан кич буена түгел, бер минутка да китмәгән булырые. Каян килгән ул сиңа шул кадәр акчага, байлыкка хирыслык? Инде ул чир миңа да йокты бугай... Ә менә үзең хәзер мине гаепләргә маташасың...

* * *

Булат, әнисен сөендереп, күзгә күренеп үсте, матурайды. Ана булу бәхетенә ирешкән Талия көннәр буе улы белән мәш килде: нарасыен берсеннән-берсе назлырак сүзләр белән иркәләде, шаярды, көлде. Елый

башласа, әниләргә генә хас итеп тәмләп кенә ачуланган булды. Их, күңеленең бер читен кара мәче тырнагандай тырнап торучы шиге дә булмаса... Ахияры да соңгы вакытта салкыная төшкән күк шул. Эше дә бик авыр, соңгы вакытта заказлар юк, эш тә юк. Салымнар арта бара, эшчеләрнең ризасызлыгы үскәннән-үсә, дип борчыла ул. Каян килеп настроение булсын... Болай да житди кеше, өстәвенә, төннәр буе докторлык эше белән утыра, чыдаган башына рәхмәт инде»,—дип үзен-үзе юатып та куя Талия. Әмма өйдә бала мәшәкате арта барса да, иренә булган игътибарын һич киметмәде ул. Ризыкларны да тәмлерәк итеп, төрлән-деребрәк әзерләргә тырышты. Кайбер көннәрне аяктан егылырлык булып арыса да, чыраена чыгармады, зарланмады, түзде.

* * *

Беркөнне, һич уйламаганда, Ахияр Талиянең өстенә әйтерсең лә боздай салкын су койды—яңалык әйтеп ташлады:

—Бу якшәмбедә фирмагыздан сезне котларга килергә жыеналар,— диде ул. Безне димәде, сезне диде.—«Сәгать уникеләргә килеп житегез, су коенырсыз, чын авыл мунчасында парланырсыз, рәхәтләнеп ял итеп китәрсез»,—дип чакырдым. Булат та исәйде, матурайды, хәзер аны кемгә дә күрсәтергә була. Минем заводтан соңарак килерләр, Алла боерса...

Бу хәбәрдән Талия тәмам каушап калды.

—Ничек—«сезне»? Кемне—«сезне»?—диде ул, сагаеп.

—Булат белән сине инде, билгеле...

«Ә нигә: «безне»—дип әйтмисең?»—дип сорарга бик талпынса да, дәшмәде Талия, авызына су капты.

Ниһаять, якшәмбе житте. Килделәр. Касыйм, Тамара, хәзерге сәркатип Света балага затлы төргәкләргә төрелгән кыйммәтле уенчыклар бүләк иттеләр. Талиягә ял акчасы итеп, илле мең сум акча да китергәннәр.

—Бик зур акча бит бу... Ул үзе шактый ким кәтә иде,—дип куйды Ахияр.

—Аның электән калган акчалары да барые,—диде хисапчы Тамара, ә үзе тиз генә директорга карап алды. Аннан өчесе дә читтәрәк торган бала арбасын сырып алдылар. Бәби кунакларның әле берсенә, әле икенчесенә, зәңгәр күзләрен жемелдәтеп, елмая башлады. Бераздан исә кычкырып ук көлеп жибәрмәсенме малаең! Кунакларны тәмам әсир итте, бит әй, боларга сүз әйтергә дә форсат бирмичә, тыпырдап торган аяклары белән кагылып киткән уенчыкларның чылтырауларына кушылып чыркылдый да чыркылдый гына бит...

—И-и, улым, син бүген бигрәкләр дә арттырасың әле, күз тияр дип тә тормыйсың. Матур апайларны күрдем, дип куанасың инде, име, егет кеше шул син. Көннәр буе диярлек бер үзең шул. Әтиең—эштә, әниеңнен йорт мәшәкатьләре исәпсез,—шулай дип, Талия килешле итеп кенә Ахиярына карап алды.

Гадәттә, бәби котларга килүчеләр мондый вакытта: «Кемгә охшаган?», «Кай жире кемнеке?»—дип шау-шу килеп алалар. Гажәп, бүген андый хәл булмады, әмма дә барыбер «Сөбханалла!»ны күп әйттеләр, билгеле. «Сер тотмас» Тамара исә берничә мәртәбә әле Булатка, әле директорына мәгънәле генә карап алгалады. Ә Света, астан гына, Тамараның касыгына тагын да мәгънәлерәк итеп төртеп куйды. Беренче булып баланы Тамара кулына алды, мактый-мактый сөйде. Шул вакыт кызык хәл булды. Касыйм балага каршы басып, иреннәре белән чөңгерә башлады. Ә сабыйның куллары Касыймның күзлегенә кагылды һәм күзлек жиргә очты. Бу хәлдән күңеле тулышкан ир яшьле күзләрен яшерә алмады. Беркавемнән сабыйның куллары тагын аңа таба сузылды. Бу юлы баланы кулларына алмыйча булдыра алмады Касыйм. Йә, Раббым, бер-берсенә карап торган зәп-зәңгәр күзләр, түгәрәк йөз, матур гына батып торган иякләр... Болар гына житмәгән—икесендә дә бөдрә чәч... Әле генә Тамара кулында

очынып торган малай, инде хәзер Касыймның күкрәгенә сеңеп беткән диярек, тыныч кына тик ята. Ниләр уйлап ята икән бу, ә?

Хәер, озакламый анысы да билгеле булды: ирнең күкрәген, кендек турын, бар вөҗүден рәхәт жылытып, кайнар агым җәелде. Һай, янә туган үз сабыеннның гөнаһсыз-илаһи вә газиз исеннән дә ләззәтлерәк ни бар икән тагын бу җиһанда, йә?!

Касыйм, баланы яратып, күкрәгенә кысты. Бу хәлдән каушап калган Талия тиз генә:

—Касыйм Кадыйрович, бирегез әле үземә, аргандыр инде, балакаем,—дип, кабаланып, улын кулларына алды. Әле ярый бу минутларда яннарында Ахияр юк иде. Ни вакытта киткән ул?

Бераздан хуҗа кунакларны аллы-гөлле чәчәк түтәлләре уратып алган мәйданчыкта көйләнгән өстәлгә чакырды. Табындагы сый гаять мулдан иде. Әмма элек Талия пешергән тәмле ризыкларны ашап туя алмаган Касыймның тамагыннан бүген бер тәгам ризык үтмәде. Күңеле дә күтәрелмәде. Котлавының да сүзе сүзгә ятмады, өчле-тугызлы гына килеп чыкты. Ул тизрәк китү ягын карады.

Кунакларның тиз китүенә хуҗа да канәгать калды.

—Мин бераз үз эшләрем белән утырыйм әле. Бала йоклаганда син дә ял итеп ал,—дип өйгә кереп үк китте.

Саф һавада бала изрәп йоклый. Тик менә әнисе генә җанын талкыган борчулы уйлар өермәсеннән арына алмады. Кунаклары белән бергә булган вакытның һәр мизгелен күз алдыннан уздырды ул. Касыймның: «Чакыруыгызга зур рәхмәт»,—дип китүе аны үтә дә шикле уйга салды. «Димәк ки, Ахияр абый үзе чакырган булып чыга түгелме соң? Ә ни өчен, нинди максат белән?».

Төнге уникеләрдә бала имезергә уянган Талия, янында ире юклыгын күреп, аптырап калды. Коридорга төшкән ут шәүләсен күргәч кенә: «Әле һаман язып утыра икән»—дип уйлап, тынычлана төште. Шулай да янына кереп чыгасы итте. Ишекне ачуга, ут яктысында, кәнәфиендә утырган җирендә йоклап киткән ирен күреп, җәлләп үк куйды. Күзе, ихтыярсыздан, өстәлгә төште. Анда Булат белән кызы Гөлнараның бер айлык вакытларында төшерелгән фоторәсемнәре ята. Талия тагын күңелсез уйларга уралып, ничек килеп керсә, шулай әкрен генә, аяк очларына гына басып чыгып китте. Шул көннән башлап, Ахияр анын йокы бүлмәсенә кермәс булды. Эшеннән дә сонарып кына кайта башлады. Кайтуына Камада су коенып ала. Аннан тиз генә кичке ашын капкалый да, кабинетына кереп, фәнни эшенә утыра.

Электәгечә өйгә шатланып кайтып керүләр, хатыны пешергән ризыкларны мактый-мактый тәмләп ашап, көлешә-көлешә сөйләшеп утырулар... Кая китте ул бәхетле чаклар?! Матур төш шикелле генә калдылар.

Монарчы бәхетле-тату гына барган тормыш, Касыймнар килеп киткәннән соң, икесе өчен дә тоташ газапка әйләнде. Тиздән, бик тиздән икесе өчен дә авыр сөйләшү булачагын да, араларында кара мәче булып сөекле баласы ятканын да чамалый иде Талия.

Көннәрдән беркөнне Ахияр эштән иртәрәк кайтты һәм хатынын каршысына утыртып, сүз башлады:

—Талия, минем сезгә салкынаюымның сәбәбен ачыкларга теләмисенме?

—Төп хезмәтең дә авыр, аның өстенә, житмәсә, нинди зур фәнни эшен бар, сине борчыйсым килми. Үз җаен белән, вакыты житкәч, үзен аңлатырсың әле,—дигән булды хатыны.

—Мин иртәгә эш буенче Самарага китәм. Аннан туры Мәскәүгә очачакмын. Кайчан кайтып житүем дә билгесез. Юлга чыкканчы, берничә соравыма җавап ишетәсем килә. Талия, син кайчаннан бирле ике тормыш белән яшисең?

—Ахияр абый, мин бер генә,—Талиянең тавышы калтыранып китте.—Син корган тормышта гына яшим бит.

—Мәгәр алай булса, нигә бала минеке түгел?

Талия өчен авырдан авыр, иң авыр, хәтта дәһшәтле, әмма күптән көтелгән сорау иде бу. Бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Чәч төпләреннән башлап бармак очларына кадәр кызыша башлады. «Нишләргә? Ничек җавап бирергә? Җылап җибәрмәсәм генә ярарые, сабырлык бир бер Аллам!»—дип теләде ул.

—Касыйм безгә килгәч тә, баланы күрү белән, үз баласы икәнен шундук таныды бит,—дип һөҗүмен дәвам итте ир. Үзең дә күреп тордың. Светаның Тамарага ни өчен төртеп куйганын да күрдең... Мәгәр син: «Юк, ялгышасың»,—дип расларга телисең икән, (мин мона шат кына булырыем) һәммәсен дә ДНК анализы аркылы ачыкларга мөмкин. Әгәр дә син риза булсаң, безнең веналардан алынган кан ДНК анализы өчен Мәскәүгә җибәрелә. Мәгәр син каршы булсаң, мин бу анализны ясатуга фәкать суд аркылы гына ирешә алам. Уйла, кайсын сайлыйсың?

Талия телсез калды. Әле аның мондый ДНК дигән анализлар турында ишеткәне дә юк иде. Бер мизгелдә кеп-кечкенә нарасыеның кан тамырына энә белән керүләрен, үзенең суд каршында басып торуларын күз алдыннан уздырып, әле агарды, әле күгәрде ул. Шулчак бала уянып тавыш бирмәсә, кем белә бит аны: нинди карарга килгән булыры...

—Баланы беразга имезми тор, җанны тынычландыра торган тамчыларны күбрәк тамыз да, кайнаган җылымса су белән эчеп җибәр. Аннары бал белән сөтле чәй эчеп куй, миңа да ясa, Булатны минем белән калдыр, үзең ничек тә тынычланырга тырыш,—диде Ахияр, ниһаять, тавышын йомшарта төшеп.

—Минем кичке ашка дип пешергән пылавым бар, бәлки ашап та алырсың,—Талиянең дә күнеленә бераз җылы йөгерде, ул улын үз кулына алмакчы булды.

—Пылауны үзеңә дә сал, син аны тәмле итеп әзерлисең, аша тынычлап кына. Ир балага ир кеше кулын тоеп яту кирәктер дә инде ул... Тыныч кына ята бит әле, җыларга да исәбе юк шикелле...

Иренең балага да, үзенә дә йомшарып, игътибарлы булып китүе, үлән тамчыларына караганда, шаять, мең мәртәбә шифалырак булгандыр.

Сүзсез генә шактый озаклап ашадылар. Аш артыннан кайнар чәй эчтеләр. Ир белән хатын арасындагы бу уңайсыз, авыр тынлыкны аратирә гөнаһсыз сабый гына: «ү-ә-ә—ү-ә-ә», «гы-гы-гы» дип үз телендә бозгалап куя иде...

Иртәгесен Ахияр аларны, үзе югында яшәргә җайлырак булыр дип, Казандагы фатирына алып кайтты. Әмма киткәндә:

—Мин кайтканчы ныгытып уйла! Касыйм белән дә сөйләш. Мәгәр, шикләнеп, баладан баш тарта икән, ул да ДНК анализын ясата ала. Аның мөмкинлеге миңа караганда күпкә зур. Әгәр дә бала аныкы икән, мин бу хыянәтеңне күтәрә алмаячакмын. Акча шкафта, кирәгенә тот, аптырап ятма,—диде дә, үпмичә генә саубуллашып чыгып та китте.

Самарада ул Хәмитләрдә тукталды. Беренче кичне үк: «Урам әйләнеп керик әле»—дигән булып чыгып киткән ирләрне көтә-көтә, Зария тәмам борчуга төште.

Ахияр хатынының ике тормыш белән яшәвен, өзелеп көтеп алган тәүге малаеның да сөяркәдән булуын әйткәч, Хәмит үз колакларына үзе ышанмады:

—Юк, юк!—диде ул өздереп. Мөмкин түгел! Хаталанмыйсың микән? Көнләшүдән генә түгелме?

—Һай, шулай гына булсае да бит. Юк шул, үзең беләсең бит инде, мин бервакытта да шикләнүдән генә нәтиҗә ясый торган кеше түгел.

—Шулай да, бик ашыкмале син... Кырт кисмә!

—Башта Ходаем, иң газиз кызым белән сөйгәнемне салкын гүргә салып, ачы хәсрәтен биреп сынады. Инде бераз тынычлана төшеп, бу хатынымның сөяркәсеннән туган баласын минем кулларыма салып сынавы нигә кирәк булды икән? Озак уйландым инде мин бу турыда, җавабын

да таптым шикелле. Күрдем дә—гашыйк булдым, дип кенә кабаланып өйләнергә уңсигез яшьлек егет түгел, кырыкны тутырып килүче ир ләбаса. Жиде кат үлчәгәч кенә кисәргә кирәклекне кем-кем, мин дә белмәгәч... Талиягә мин бүтән ышана алмыйм. Ышанычын югалткан хатын белән яшәү—ул инде тормыш түгел, үзеңне күрәләтә тәмуг газапларына салу гына...

Соңгы салам бөртегенә тотынуын чамаласа да, түзмәде Хәмит, әйтә куйды:

—Яратасың бит син аны. Яратасың!

—Шул яратуым хакына гафу итәм икән, бу инде минем сынуым булачак. Сәриям белән Гөлнара кызым мине гафу итмәячәк.—Ахиярның тавышы калтыранып китте. Үзе өчен кадерле булган бу исемнәрне телгә алуы авыр иде аңа, бик тә авыр иде.—Гомерем буе ул изге жаннарның бәддогасына дучар булырга теләмим. Читен миңа, Хәмит, бик тә читен... Йөрәкне бернишләтеп тә булмый икән шул, яраттым бит, Хәмит, яраттым, сиңа рәхмәтләр укый-укый яраттым. Авырга узганнан соң хәтта Сәриямә тиңләштерә башлаганыем бит, жүләр,—дип йөзе буйлап тәгәрәп төшкән күз яшьләрен сөртеп алды ул.

Хәмиткә бу сүзләрне тыңлап тору, бигрәк тә Талиянең бер ир дә гафу итә алмаслык хыянәте турында ишетү авыр иллә дә читен. һай, читен дә булды. Ләкин ул бу мәлдә янә шунысын да бик ачык аңлады: үзенә якын бу ике жанны элек ничек итеп димче һәм шаһит сыйфатында жинел генә кавыштырган булса, хәзер инде эшне зур фажигага житкермичә генә, артык катлауландырмыйча аларның аерылышуларына ярдәм итү дә аның өстенә төшәчәк.

* * *

Хәмит, бер атналык ял алып авыру әнисенең хәлен белеп килергә тиеш иде. Ахиярны Мәскәүгә озатуга, машинасын кабызып, туган авылына юл тотты. Юл уңаеннан Талиягә керде.

—Кем дип торам, и-и, минем канатсыз фәрештәм икән,—диде Талия, аның килүенә шатланып. Ахияр абый Самарага киткәние, сезгә кермәдеме?

—Минем авылга кайтыш, әнинең хәле әйбәт түгел. Сезне дә авылга апкитмәкче булам. Ахияр әле бер атнасыз да кайтмас. Хәзер миңа кимендә бер сәгать йоклап алырга кирәк. Булатыбыз кайда соң әле? Күрәсем килә үзен.

—Ул лоджияда йоклый.

—Ярый алайса, машина сезнең тәрәзә каршында, бераз күз салгала, яме. Сөйләшәсе сүзләр байтак, әмма соңрак.

Талия, ни дияргә дә белмичә, сәерсенеп калды. «Нәрсә булса да, жүнлегә түгелдер бу. Хәмит нииндидер шомлы хәбәр алып килмәде микән»,—дип тә уйлап куйды. Шулай да, авылга кайтасы килә иде аның. «Ахияр өйдә югында бигрәк әйбәт булыр»,—дип кирәк әйберләрен хәстәрләп тә куйды.

Хәмит сүзне каян башлап жибәрергә дип интегеп утырганда, ачык лоджиядан бала елаган тавыш ишетелде. Ана кушылып, үч иткәндәй, аш бүлмәсендә чәйнек тә сызгырып жибәрде.

—Бар әле, Хәмит, арбасында килеш кенә Булатны аш бүлмәсенә алып кил. Киткәнче бераз ашап-эчеп алырбыз,—диде Талия.

Үзе янына ят абыйның килеп басканын күреп, бала елавыннан туктады. Хәмит аңа карап-карап торды да: «Ахиярниемә дип коточкыч зур акчалар түгеп, ДНК ясарга уйлый икән? Кемнеке икәнлеге болай да күренеп тора бит инде...»—дигән уйдан туганы өчен жаны телгәләнде. Аннары Талия ишетерлек итеп: «Сөбханалла! Күз тимәсен, бигрәкләр дә матур егет икәнсен!»—дип куйды. Ана кешенең күңеленә бик хуш килде бу сүзләр. Ә хуш килмәслекләре алда иде әле...

—Их, Талия, мин сиңа ничек ышанганыем бит...—дип, ниһаять, Хәмит күнелендә җыелганын чыгара башлады. —Ә син, болай да коточкыч хәсрәт кичергән Ахияр абыйга бер ир дә күтәрә алмый торган өр-яңа ачылардан-ачы хәсрәт ясагансың. Ә мине нинди хәлдә калдырдың?

Бу сүзләрдән соң Талия бер кызарды, бер агарды, тик тел тибрәтеп сүз әйтерлек көч тапмады. Ахиярның үзенә биргән бәясен ишеткәч кенә телгә килде ул.

—Юк, Хәмит, дөрес түгел, кияүгә чыккач бер мәртәбә, бары бер мәртәбә генә ялгыштым. Ул Ахияр абый Ульянга киткән көн, утызынчы август, мөстәкыйльлек алуны бәйрәм иткән көн иде. Шуннан шул, бәйрәмнән соң үз фатирыма кайтып кундым. Тәрәзәдә ут барын күреп, соң гына Касыйм абый килеп керде. Күрәчәгем булгандыр инде, каршы торырга көчем житмәде. Ник кенә бардым шул мөстәкыйльлек бәйрәменә?..

—И, Талия, причем монда мөстәкыйльлек бәйрәме, үз мөстәкыйльлегенне саклый алмагач...

Түзмәде хатын, мөлдерәмә тулган күнеленә ирек куеп, елап җибәрде.

—Жә инде, жә, хәзер безгә юлга кузгалырга вакыт. Син, шулай да, кая киткәненне әйтеп язу калдыр Ахиярга. Ул минем монда керәсемне белмәде. Бәлки әле гафу итеп, сезне кайтып та алыр, кем белгән... Ярата бит ул сине... Ишетәсеңме? Я-ра-та...

Талия бераз уйланып торды да, кәгазь-каләм алып яза башлады. Әмма бетмәс-төкәнмәс күз яшьләре, коеп яуган яңгыр төсле туктый алмый, өзлексез акты да акты. Каләм карасы белән түгел, күз яшьләре белән язылган хат иде бу... Берничә сүзгә сыеп беткән, әмма бер йөрәккә сыеп бетә алмаслык коточкыч фаҗига ята иде бу хатта...

*Ахияр абый!*

*Без әни янына авылга киттек. Сиңа барысы өчен дә рәхмәт, зур р-ә-х-м-ә-т! Гафу итмәсегезне беләм, шуңа күрә сорамыйм да. Тик мин син уйлаганча ук бозык кеше түгел...*

*Соңгы сәламем белән Талия.*

* * *

Кызы белән оныгын күрү шатлыгы эченә сыймады Шәргыяненң. Иртә таннан кичкә кадәр, ару-талуны белмичә (аягы җиргә тимәде!), пешеренде-төшеренде, чәйгә чакырылмаган күрше-күлән, туган-тумача калмады. Кая гына барса да: көтү куамы, кибеткә төшәме, сөт тапшырамы—телендә гел оныгы булды, аны мактап бетерә алмады.

Талия үз хәсрәтен әнисенә сөйләргә базмады. Анын бу чиксез бәхетле көннәрен кара болыт каплавын теләмәде. Көтмәгәндә йөрәгенә кара кайгы салып, әнисенен кояштай балкып торган йөзен саргайтасы килмәде. Авылда болай да кешенен төрлесе бар: көнчесе дә, гайбәтчесе дә хәттин ашкан. «Шәргыяненң бүресе улый... Кызы турында төрле гайбәт таралганда койрыгын кысып кына йөргәние, хәзер тәмам әллә кем булды. Көн дә кунак җыя. Тоташка оныгы белән мактануыннан гарык булырсың, билләһи»,—дип, әнисенен зарыгып көтеп алган шушы бәхетен дә күпсенүчеләр табылды.

Талия бер ялгызы гына эчтән янды, көйде, шулай да, өметсез шайтан дигәндәй, үзе көн дә Ахиярдан хәбәр көтте. Кызының монсуланып киткән йөзен күреп, ана да шөбһәләнми калмады анысы. Әмма тупырдап торган оныгын күрүгә, анын «ә-гъе», «әвбе»ләрен ишетүгә, шик-шөбһәләре шунда ук төпсез чиләктән аккан су кебек юкка чыга иде.

Августның урталары якынлашып килә. Көннәр шулкадәрле дә күркәм-матур, кояшлы тора. Кыска гына вакытлы яңгырлар юл тузанын басып, агачларны юып, һаваны сафландырып җибәрә. Көзнең якынлашып килүен белдергән бер генә чалым да күренми әле. Авыл табигатенең

үзенә күрә бер төрле гүзәллеге Талиягә Кама буйларын, андагы чәчәкле сихри бакчаны, мунча кыегына оялаган пар күгәрченнәрнең чөкердәшкән-гөрләшкән, үбешкән вакытларын Ахияр белән бергәләп карарга яратуларын торган саен ешрак исенә төшерә. Андагы ике катлы йортның кояшлы бүлмәләрендә, аерата корсаклы чагында, гел кадер-хөрмәттә булып, ханбикәләрчә генә йөргән көннәрен үзәкләре өзелеп сагына ул...

Шулай бер кичне, тәмам эче пошуына чыдый алмыйча, ул ишегалдына чыкты, рәшәткә буендагы эскәмиягә килеп утырды. Битләрен назлап тын гына җил исте. Җанына рәхәт төнге авылның саф һавасыннан күңеле хушланып китте Талиянең.

Авыл тып-тын. Көне буе эшләп арыган халык изрәп йоклыйдыр. Тик бик еракта, авылның теге башында ук булса кирәк, бер эт өргәләп куя, ни житмидер... Абзардан кырт-кырт итеп сыер күшәгәне ишетелә. Бу авазлар төннең тынлыгын һич тә бозмыйлар, киресенчә, тагын да тирәнәйтәләр генә төсле. Әнә, түбән очта, илаһи тынлыкны ертып, кемдер гармун уйнап җибәрде. Бераздан аңа җыр кушылды, сүзләре әлегә аңлашылмый. Җыр якыная барган саен, сүзләре дә ачыклана төште:

*Ялгыз каеннардан ялгыз*
*Иттең бит җаныкаем.*

Кем өчен моңлана ул? Ялгыз калуында кемне гаепли? Шул «җаныкаем»ның өй түреннән җырлап үтеп йөрәген басамы? «Ә миңа соң нишләргә кала?»—дип, түзә алмыйча, ачыргаланып елап җибәрде Талия. «Сабыр ит, күтәрелеп миңа кара, мин дә гомерем буе ялгыз йөзәм бит. Елаганыңны ишетеп, сиңа иптәш булыйм дип, кара болытны куып җибәрдем әле менә, йөзенә генә түгел, күңеленә дә яктылык сибим әле бер», дигәндәй, күктә түп-түгәрәк тулган ай пәйда булды. Әгәр сукмакта энә ятса, ул да күренерлек бу яктылыкка таң калып, Талия күккә бакты. Күзләре чагылудан куллары белән битен каплап, күз яшьләрен сөртеп алды. Чыннан да, тынычланып та китте шикелле. Чү! Колагына машина тавышы ишетелде түгелме соң? Әйе, әйе, машина! Тыкрыктан алар урамына керде бугай. Әйе шул! Менә капка турына килеп тә туктады... Кем булыр икән бу, әй?! Талия хәтта үзен-үзе белешмичә «Ахияр абый, җаным!»—дип кычкырып капкага ташланды, калтыранган куллары белән капка бигеп ача алмыйча азапланды. Ә үзе «Хәзер, хәзер, Ахияр абый, хәзер ачам!»—дип тәкрарлавын дәвам итте. Ниһаять, капка ачылды, Талия баскан урынында тораташтай катып калды. Каршысында авызын колагына кадәр житкереп елмаеп, күңеле күтәренке чакларда гына шигырь юллары белән сөйләшергә ярата торган Касыйм берни булмагандай, басып тора, ә үзе, бар дөньяны яңгыратып, такмаклый:

*Йөрәгемнең януларын*
*Сизсәң дә, сизмәсәң дә*
*Ятларга калдырамма соң?!*
*Сөйсәң дә, сөймәсәң дә.*
*Син минеке, үземнеке,*
*Сөйсәң дә, сөймәсәң дә!*

Шулай диде дә бу, аптырап калган Талиясен кайнар кочагына кысты. Шундый итеп кысты ул, хәтта сөйгәненең җан авазы белән ыңгырашып җибәрүе дә каяндыр кысылып кына чыккандай булды.

—Улым ни хәлдә? Авырмыймы, үсәме? Һаман да шулай матурмы?

Әмма Талия дәшмәде.

Җавап ишетелмәгәч тә аптырап тормады Касыйм, гадәттәгечә көр тавышы белән бөтен ишегалдын яңгыратты:

—Син нәрсә, үпкәләдеңме әллә? Тиз генә кайталмадым шул, эшләрем күбәеп китте бит. Ә син Ахиярны түгел, мине көтәргә тиешиең ләбаса.

—Мин берни дә аңламыйм. Ахияр абый әллә сиңа да барып җиттеме?—дип, Талия дә, ниһаять, авыз ачып сүз әйтә алды.

—Ник, Хәмит берни дә әйтмәдемени?

—Нәрсә әйтергә тиеш иде соң ул?

—Сиңа килгәнче, ул бит башта миндә булды. Ахиярның Самарада сөйләгәннәрен барын да миңа сөйләде.

—Ә миңа, ни өчендер, бу турыда берни дә әйтмәде ул. Касыйм абый, син монда улыңны күрер өчен генә кайттыңмы?

Ишегалдындагы машина тавышына сискәнеп уянган Шәргыя, кунакны күргәч, үз күзләренә ышанмыйча «Бә-тәч, бу ни бу, өнемме соң, әллә төшемме?»—диюдән битәр берни дә әйтә алмыйча ык-мык килеп, әрле-бирле йөренде.

—Әни, тынычлан әле, яме. Лутчы чәеңне куеп җибәр. Болай син агу ашаган таракан шикелле инке-тиңке киләсең, соңарак барын да аңларсың,—дип, ике арада туган киеренкелекне көлкеле-шаяруга борып җибәрмәкче булды Талия.

—Ни-нәрсәдер дип шикләнгәнием шул аны... И, бала, бала... Тагыниләр күрәселәрем, ишетәселәрем бар икән... Йә, Ходаем, рәхмәтеңнән ташлама инде берүк...

Касыймның бала арбасы янында улына йотлыгып-йотлыгып карап, аның уянуын түземсезлек белән көткәнен сизгәндәй, Булат, әле иму вакыты җитмәсә дә, тыпырдап уянып китте. Кулларын Касыймга таба сузып, «Нәрсә карап торасың, ал инде мине»—дигән сыман, аякларын тераӣ гәүдәсен күтәрмәкче булды. Әти кеше аны кулларына алып бөдрә чәчләреннән, кечкенә генә булып чокырланып торган иякләреннән үбә башлады. Ә нәние әтисенең һәр үбүенә елмаеп туя алмагандай, елмая да елмая. «И, улкаем, Ходаемның бүләге бит син миңа! Ачынып үкенгәннәремне ишеткән бит ул, Ходаем, мең шөкер аңа! Ниемә хаҗәт ул безгә ДНКлар, име, улым. Беренче күрүемдә үк таныдым ич мин сине, кадерлем. Чүт кенә «Улым, бәгърем» дип кычкырып җибәрмәдем ул чакта, да...

Ә син, балакаем, «Күрегез ул бит минем әтием, аның күзләре тулы яшь, сез дә күрегез әтиемнең күз яшьләрен»,—дигән сыман күзлегемне алдың да аттың. Хәмит абыең килгәнче ниләр генә уйлап бетермәдем мин...—Ир, әнә шулай, улының күзләренә карап, аңа эч серен ачты. Аннан ул баланы әнисенә бирде:

—Бу чибәр егет ашап алсын, ә үзең мине тыңла. Без тиздән Канададагы Квебек дигән шәһәргә барып урнашачакбыз. Анда минем Зиновий исемле яһүд дустым эшли. Ул мине үзе дә күптәннән чакыра иде инде. Мәскәүдә очрашып сөйләштек, мин аңа ике фатир табып куярга куштым, берсе сезнең өчен, Алла боерса. Фирмадагы капиталның алтмыш биш проценты минеке, урынбасарларымның иң ышанычлысы Соловьев белән эш итәм. Баш бухгалтер кайбер операцияләрне эшләде инде. Сиңа бер дә куркып торасы юк, телең бар, бергә-бергә эшләрбез. Ахиярныкыннан да яхшырак тормышта яшәрсең әле, менә күрерсең. Анда салымнар бермә-бер аз, бизнесменнарга, аерата читтән килгәннәргә, дәүләт үзе ярдәм итә. Тел өйрәнү өчен акчаны да дәүләт ел буе үзе түли икән. Шул акчага полный яшәп була, хәтта бер мәртәбә туган иленә кайтып килергә дә җитә ди. Үзләре белән өлкән яшьтәге әти-әтиләрен алып килсәләр, аларга пособиеләр дә каралган ди. Анда кешенең кадере зур икән шул, бездә генә бит ул кешене фәкать талау чыганагы итеп кенә күрәләр. Шәргыя апа, син алай борчылма әле, бик сагынсаң, бик саргайсаң, түзәр хәлең калмаса, чакыртырбыз Донбаска дигәндәй, безгә килеп, рәхәтләнеп торып китәрсең. Фирма белән дә эшне дәвам итәчәкмен, шулай булгач, үзебез дә кайтып йөрербез. Талия, сиңа ирең белән аерылышуны ничек тә тизләтергә кирәк булачак, икең дә риза булганда, аны тиз хәл итәләр.

Миңа иртәгә, өч-дүрт көнгә, Мәскәүгә китәргә кирәк. Хәзергә сез монда калып торыгыз. Мәскәүдән кайтуга, сезне үзем килеп алырмын.

Бу сүзләрдән соң, читтәрәк утырган Шәргыянең күзләрен яшь томалады. Кызын чит-ят илләргә җибәрергә ризалашса да (риза булмый

нишләсен инде), әмма күңелендәге ниндидер шомлы тынгысызлык күз яшьләре белән генә чыгып бетә алмады. Йөрәген әрнетеп торган бу шом төн буена да үтмәде. Әллә инде ана күңеле нидер сизендеме?..

Иртәгесен Касыйм чыгып киткәч, бала алганны-салганны да белмичә, үксеп-үксеп еларга тотынды. Йокы вакыты житеп йокламады, имү вакыты житеп иммәде. Баланың туктый алмыйча үксеп елавы Шәргыянең болай да әрнеп сулкылдаган йөрәгенә шом өстенә шом гына өстәде...

* * *

Касыйм киткәннән соң узган берничә көн, жырларда жырланганча: «минуты ай, сәгате ел» шикелле, бигрәкләр дә озак тоелды Талиягә. Инде илаһи моңга чумган айлы төннәрдә, жаннарын көйдереп ала торган газаплы уйлары белән бер ялгызы калу аерата авыр булды аңа.

Менә беркөнне, төш вакыты узар-узмаста, урамда машина тавышы ишетелде. Ниһаять, Шәргыяләр турысына житкәч, кычкырта да башлады бу. Көтеп-көтеп зар-интизар булган Талия очты гына... һәм бөтен тавышына:

—Хәзер ачам, Касыйм абый, ай-йай, көттереп тә карадың инде,— дип зур капканы ачып жибәрде. Каршысында шофер Мидхәтне күреп: «Үзенең вакыты булмагандыр инде. Ярар, машина жибәргәч тә рәхмәт»,— дип уйлап куйды. Ул арада машинаның арткы ишегеннән чыгып килүче кеше... Кемне-кемне, ә менә аны!—һич тә көтмәгән иде ул, көтү түгел, ике ятып бер төшенә керүен дә теләмәгән, Касыймның хатыны—Камәрияне күргәч, әллә нишләп китте. Бер мизгел эчендә ни генә уйлап өлгермәде, нинди генә фаразлар кылмады, хәтта куркып та калды... Камәриянең кара янган йөзеннән, хәсрәтле дә, шул ук вакытта ачулы да күз карашыннан Талия сискәнеп, акбурдай агарынып китте һәм, ихтыярсыздан, артка чигенә башлады.

—Эх, бернәрсәңне тыя алмаган оятсыз жан , жир бит, себерке! Дүрт баламны ятим калдырдың ич...—Көтелмәгән кунак дөрестән дә бик ачулы иде, ул ярсый-ярсый Талиягә таба атлады.

—Камәрия апа, кеше көлдермик, әйтәсе сүзләрегезне өйгә кергәч тә әйтеп була канә. Нишләп алар ятим калсыннар ди, ул мине генә түгел, сезне дә алып китәм диде бит. —Талия аны тынычландырмакчы булды.

—Әйе, китте шул, китте, бөтенләйгә китте. Бары да синең арканда, тик син б... аркасында гына харап булды ла. Иргә дә чыкканыең лабаса... Юк, икән, житмәгән икән, ирең генә сина аз булган күрәсең, сөйрәлчек, директорыңнан бала табып ятмасыең, фахишә.

—Мине нинди генә әр-хур сүзләр белән кимсетсәгез дә түзәрмен. Ни булды? Анык кына әйтсәгезче!

Нәкъ шул вакыт, өйдән баланың ярсып елаган тавышы ишетелде. Талия өйгә ашыкты. Камәрия дә, чакырганны да көтмичә, аның артыннан атлады. Баланы күрүгә, якындагы урындыкка килеп лапылдап утырды да елап жибәрде. Сүзсез генә елады да елады ул. Бу вакытта аның Талиягә булган нәфрәте дә, ачуы да, жылы суда эрегән боз сыман юкка чыкты. Үзе дә карарга кызганыч, бер мескен хәлгә төште. Шулчак Мидхәт Талия янына килеп, әкрен генә:

—Моннан бер атна элек, сездән кайткан чакта Касыйм Кадыйрович машинасы белән бәрелеп һәлак булган. Яңа бистә зиратына күмдек. Сез Казанга кайткач, каберен үзем күрсәтермен,—диде. Бу коточкыч хәбәрдән Талия чайкалып китте. Әйтерсең лә, күсәк белән башына китереп ордылар... Чигә тамырлары шартлардай булып сулкылдарга тотынды. Күңеле тулышты, кычкырып елап жибәрүдән тыелып кала алса да, иреннәре дерелдәвен туктатырга көче житмәде. Баланы төшереп жибәрүдән куркып, аны калтырый башлаган куллары белән арбасына салмакчы булды. Көндәшенең хәлен сизеп, Камәрия баланы үз кулына сорап алды

да зәп-зәңгәр күзләрен жемелдәтә-жемелдәтә тупырдап яткан балага текәлде. Шулай шактый озак карап торганнан соң, йомшак кына итеп аның бөдрә чәчләреннән сыйпады, бармаклары белән матур гына батып торган аяк уентысын сыпыргалап куйды. Ниһаять, телгә килде:

—И, сабый, сабый, үкенечкә туган гөнаһсыз сабый, әти булган кешең дә юкка гына өзгәләнмәгән икән шул. Бигрәкләр дә нәни Касыймым булгансың икән бит...—дип түзә алмыйча, янә кайнар яшьләрен түгеп алды ул.—Үз кызларының ник берсе, хет әз генә булса да, аталарына охшасын, дүртесе дә—беткәнче үзем...

... Шәргыя капкадан керүгә, ишегалдындагы машинаны күреп, каушап китте. «Йә Аллам, Касыйм кайткан ич. Шулай иттереп китеп тә барырлар микәнни?.. дип уйлады ул. Аннан каударланып өйгә керде. Кунакларны таный алмаудан гажизләнеп, күзләре белән һаман Касыймны эзләде. Талиянең:

—Әни, бу—Камәрия апа, Касыйм абыйның хатыны була,—дип таныштырды Талия. Аның шулай дияе булды, ул хәтта үзен-үзе белешмичә, Камәрия кулыннан баланы тартып та алды. Һәм... кызына шелтәле-кисәтүле караш ташлап, бер сүз дә әйтмичә, бала белән өйдән чыгып ук китте.

—Безгә хәзер синең белән бик житди сөйләшү кирәк,—дип сүз башлады Камәрия—китәсе көнне Касыйм кая барасын әйтмәсә дә, төнлә өйдә кунмаячагын яшермәде, борчылып көтеп тормасыннар, дигәндер инде. Мин дә төпченмәдем... Аның монда булганын Соловьевтан гына белдем. Тик ул минем бүген монда килүне белергә тиеш түгел. Монда килүемнең төп сәбәбе—кайбер нәрсәләрне ачыкларга теләгәннән генә. Беренчедән, машина йөртүдә осталарның остасы булган кеше ниндидер күпер асты баганасына ничек итеп килеп бәрелергә мөмкин? Монда кайткач, аның нервысында уйнап, Канадага китәргә риза булмадың мәллә? Әллә машинасы төзек түгелиеме? Иртә белән сәгать ничәдә, нинди настроение белән чыгып китте? Китәр алдыннанмы, йә кичтән Соловьев белән сөйләшмәдеме? Сөйләшсә, нәрсә турында сөйләшкәнен хәтерлә. Соңгы көннәрдә Соловьев үзен бик сәер тота башлады. Касыйм фирмадагы өлешенең күбесен күчертте, дип бара, мәлгунь. Бу турыда Касыйм сиңа берәр сүз әйтмәдеме? Фирмага хәзер баш бухгалтер итеп читтән килгән кешене алдылар, тегесе үз теләге белән каядыр киткән имеш. Кая киткән—беркем белми... Әллә аны да...

—Әйе, иртән сәгать жидедә ул Соловьев белән сөйләште. Авылдан сөйләшкәнен, берәр сәгатьтән юлга кузгаласын әйтте. «Банктан күчерәсе акчага әзерләнгән документлар баш бухгалтерда. Әйтегез үзенә, беркая да китмәсен. Мин Мәскәүгә киткәнче хәл итәсе эшләр бар, әбәд вакытында эшкә кайтып житәм»,—диде. Монда нервы бозылырлык берни дә булмады, киресенчә әле, бик тә, бик тә шат иде ул. Төнне, бер мәртәбә дә уянмыйча, әйбәт йоклады. Машинасы да төзек, нәкъ сәгать сигездә, отличный настроение белән чыгып китте,—диде Талия.

—Менә нәрсә: Соловьев милициягә Касыймның кайда булганын белмәдем дигән. Миннән дә сорадылар, мин дә шулай дидем. Минем Соловьевтан шикләнүем тагын да артты хәзер. Болай булгач, милиция монда да килер әле. Ә сина миңа сөйләгәннәрнең барын да түкми-чәчми сөйләргә кирәк булыр.

—Касыйм Кадыйрович нишләптер Соловьевка артык ышана иде шул. Берничә мәртәбә кисәткән чакларым да булды югыйсә. Бүген мин да сезнең белән кайтыйм әле булмаса...

—Кайтып кайда тормакчы буласың? Иренә кайта алмыйсың, ул Касыймга телефоннан: «Извини, үз баланны үзең кара, в добавок, сөяркәң-не башка кияүгә бирмә, үзеңдә генә тот»,—диде. Икенче телефоннан үзем тыңлап тордым, үз колакларым белән ишеттем шулай дигәнен.

—Ахияр абыйдан бу кадәрен үк көтмәгәниием,—диде Талия, үзе комачтай кызарып чыкты.

—Ә ул синнән Касыйм малаен көттеме икән соң? Монда, жаныкаем, бәйрәм ашы кара каршы булган шул инде.—Камәриянең тавышында каһкаһәле тантана чалымнары бик анык тоемлана иде.

—Кайтып керергә минем үз фатирым да бар ич...

—Һе, бар иде дә,—хәзер юк инде менә!—Соловьев аны яна килгән главбухына биргән

—Ә-ә?!

—Кием-салымнарыңны зур тартмага тутырып, эшләгән жирендәге үз шкафына китереп куйганнар...

—Бәлки миңа турыдан-туры Соловьевның үзенә барырга кирәктер?..

—Анисын үзең чамала... Тик безнең белән түгел. Безне хәзер бергә күрергә тиеш түгелләр. Алла сакласын, мин котырткан диярләр. Хәзер, жаныкаем, үз жаеңны үзең кара инде...

«Жә, беттеме сүзең?»—дигәндәй, Талия көндәшенә карады. Әмма тегесенең сүзе бетмәгән иде әле, башлана гына иде.

—Син бик яшь чагыңнан ук иремнең сөяркәсе булдың. Мин барын да белеп, сизеп яшәдем,—дип дәвам итте Камәрия.—Әмма Касыймны өзелеп яратканга күрә, аны югалтудан куркып, мин сезгә комачауламадым, тавыш та чыгармадым. Ул минем сабырлыгымны, өйдә үзенә тиешле тәрбия кылуымны бәяли белде. Кызларымны үлеп яратты, алар өчен берни дә кызганмады. Мине дә яратты, дип әйтә алмыйм анысы. Тик шулай да, һәрвакыт мин аның хөрмәтен тоеп яшәдем, шуның белән дә үземне бәхетле санадым. Чөнки ул, башкалар шикелле эш урынындагы мөмкинлекләреннән, байлыкларыннан файдаланып, һәр итәк артыннан сөйрәлеп йөрүче ир түгел иде. Фәкать сине генә яратты. Син иргә чыккач, һай, ничек көнелсезләнде ул... Жыр, шигырь сүзләрен ятлауларын да ташлады. Инде шул халәтенә күнегеп, тынычлана башлагач кына, жиенебызның бәхетсезлегенә, син тагын өр-яңадан аның башын әйләндердең. Никадәр гөнаһсыз жаннарны харап иттең... Иреңә искитмәле борчу, хурлык китереп йөрәгең жәрәхәтләдең. Сабыеңа «зинадан туган» дигән хурлыклы тамганы салдың. Яратып кабул иткән атасыннан аны да мәхрүм иттең. Үзеңне кызганмыйм, әле ирең дә табарсың, кемнеңдер сөяркәсе дә булырсың. Әмма дә балаң жәл. Үги әти ничек кенә яхшы булса да, үги—үги инде ул... Әниеңне дә кызганмыйм, һәр ананың үз тәрбияләп үстергән жимешен үзе татып карамый хәле юк...—Әнә шулай диде ана көндәше.

Ниһаять, эчендәгесен чыгарып бетергәч, Мидхәткә: «Кабыз машинаңны, киттек»,—диде дә, чыгып та китте.

Талия нәрсәдер әйтергә теләде анарга. Тик булдыра алмады, теле көрмәкләнде. «Әни» дип кычкырмакчы булды, әмма бугазына нидер утыргандай, тавышы чыкмады... Үзенә карап еламсырап торган улын күргәч, йөзе яктырып киткәндәй булды. «Ачыккансыңдыр шул, бәгырь кисәгем, кил, имезим үзеңне...»—дип әйтмәкче иде дә... әйтә алмады. Ул сабыен кулларына алып күкрәгенә кысмакчы булды, гажәп, бу ни бу, уң кулын күтәрә алмады... Ябь-яшь башына өелеп килгән ачы хәсрәт, бертуктаусыз бәгырен телгәләп торган үкенү-газап вә өзелгән өмет хисләре Талияне тораташка әверелдергән иде...



# Басыйр Рәфыйков

## ХӘТЕР МИЗГЕЛЛӘРЕ

Яшел тынлык.
Ал таң чыгы.
Колакларда
Хәтер чыңы:
Үткәннәрнең
Ялган-чыны...—
Киләчәкнең
Тонык сыны!

Фикер кылдык җинаятьтән
Котылдык дип хәер биреп.
Чистардык дип, сафландык дип
Кара керне юып элеп.

Уйланырга һич вакыт юк
Тормыш асылына кереп:
Канун җәзасы—вакытлы,
Вөҗдан җәзасы—мәңгелек.

Басыйр РӘФЫЙКОВ *(1921)—шагыйрь, «Җырым сиңа минем», «Кадерле минутлар», «Туган тупсалар» һ. б. китаплар авторы. Троицк шәһәрендә яши.*

## Магнитогорск истәлекләре

Хәтереңдә нәрсә калган, и «бала»?—
«Сөрелгән сыйныф» актарган тау, дала...
Калган—газ, төтен бөркегән комбинат—
Таш кала!

Әйт, исеңдә нәрсә калган? Каберләр,—
Алар өстендә айлар һәм тәреләр...
Калган—югалтудан әрнер күңелләр—
Бәгырьләр!

Ис-хәтердә калган ни? Урал кышы...
Тыннарны кыскан «хуш» завод сулышы.
«Адашкан»нарны дәшүче гудок... Шул—
Язмышмы?

Хәтердә яра эзе—ул нык бугай.
Анда шатлыклы һичнәрсә юк бугай.
Ә дога? «Вакыт без тапмадык», кичерә күр,
Йа, Ходай.

## Җиргә гашыйк

Баш чыгарган ашлык, чәчәк исе,
Кырда ята... юллар камчысы
Һәм мин барам, җиргә гашыйк кеше,
Җирнең әле тере тамчысы...

Җилләр йөри иген арасында,
Заман әрнүләре колакта.
Утлы сугышларның шавы сыман,
Күкләр күкри ерак-еракта.

Алсу иртә көнгә алмашынган,
Һәр агачның, җирнең үз төсе.
Сүзләр хуҗа түгел монда күптән,
Җир кешесен раслый тик эше.

Еллар, вакыйгалар аша киләм—
Кайгы белән шатлык алыша.
Бер җиңәм дә, тагы бер җиңеләм—
Хисләр белән акыл тартыша.

Ә далада баш чыгарган ашлык,
Кыр өстендә юллар камчысы.
Һәм мин анда—җиргә гашыйк кеше,—
Туган илнең тере тамчысы!

❦

Бүгенге көн—
Безнең заман.
Бөек мирас—
Болгар, Казан.
Шуннан килә
Ирек, сагыш—
Канат кага
Хыял-аккош.

Йөзәр еллар башын иеп,
Тарихи өнсез калып,
Батырын да, сатлыгын да
Онытып бара халык.

## Төш күрдем

Төшкә керде Болгар йөк корабы,
Ярга төртте килеп борынын.
Ирек белән котлап горур улын:
—Әнә, диде,—лаек урының.

Көймә кочагына сикердем мин.
Ходам! Анда—җимерек ил ята...
Баксаң, безне һәр көн иртән шулай
Мәскәү радиосы уята...

Адым саен ни калыккан?—
Бабамнарның ул кабере.
Хәрабәләр, югалтулар...
Һәр халыкның үз хәтере.

Алар өстендә—очалар
Матәм киемле каргалар.
Үткәннәрдән килеп җилләр
Бәгырь ишеген кагалар.

Әллә инде тарих чиртә
Гөсләләрен һәм сазларын?—
Мин ишеткән кебек булам
Газап, өмет авазларын.

Уңышлар да, ялгышлар да булды,
Еллар буйлап, юллар буйлап киләм.
Үткәннәрем—сүтелмәгән йомгак,
Хыялларым—күтәрәсе чирәм.

Рафаэль
Сибат

# ИНАБӘТ

ФӘЛСӘФИ РОМАН

II

## Беренче бүлек

### Алсу

**1921** ел...

—Уйнап-көлеп яшә, шулчак житди булырсың!—дигән иде Хөснимәрдән.

Мөхәммәт, дөньясына төкереп, уйнап-көлеп яшәргә генә уйлаган иде, шул елны ул...

Әйе, шул елны ул... үлде. Үл-де...

Ә үлемнән дә житди нәрсә бармы соң бу дөньяда?

«Бәлшәвикләр влачны алган ел»ны, Федорыч арба-тимерхутында Шөнгә кайтып егылган Мөхәммәтне әнисенең үлеме көтә иде. Юк, әле ул кадерле, самими, игелекле, изге йөз ташка әйләнмәгән, ул әле коелган көзге каен яфраклары төсен генә алган иде. Ул әле сарылыктан, монсагыштан, хәсрәт кулләреннән, кайгы кумерләреннән улына жылы караш саклап калдырган кузләрен югалтмаган иде. Күзләр дә югала микәнни? Югалалар... Кешенен үлеме алдыннан алар төссезләнеп юкка чыгалар...

Шул әнисе үлгән елны Мөхәммәт вафат буласы кешеләрне күзләреннән танырга өйрәнде. Авырып хаста булып ятканнарны гына түгел, ә жир дөбердәтеп, дөп-дөп басып йөргәннәрне дә... Андыйларның күзләрендә мәэюс караш белән бергә әллә нинди иксез-чиксез сагыш-моң да, күзгә күренмәс, жанга сизелмәс әчке бер битарафлык та була. Болар барысы да диярлек тән-бәдән хәлсезлегеннән, чир-авырулардан килә, ә үлем битарафлыгы—жан чире ул...

Әйе!

1921 ел иде...

Үзенең каһәрле ачлыгы белән килгән ел...

Мөхәммәтләр Нократның аръягындагы урыс авылы Биктауда хәлле

---

Ахыры. Башы 4 санда.

генә кешегә яңа лапас эшләп яталар. Эш бәясе—туйганчы ашау. Хәер, Мөхәммәт Биктауда үзенең туйганчы ашаганын хәтерләми. Әнә Заһидулла дуңгыз салосын сугыпмы-суга, эшләгәндәй, җир җимертеп ашый. Керәшен Чәпчим Мәкчимне әйтәсе дә юк. Бары Мөхәммәт белән Әхмәдулла гына чучка итен ашау түгел, иснәп тә карамый. Ярый әле хуҗаның бәрәңгесе бар, ипие мулдан булмаса да, алар үзләрен ач кешеләр итеп тоймыйлар иде.

Әнә бит, авылдан китәр алдыннан гына ике кешене зиратка илттеләр. Ачлыктан шешенеп үлгән иде алар. Берсе эскерт төбеннән бер уч ашлык табып, кыш чыгып, инде бүртә башлаган орлыкларны ашаган. Ә аннан алданрак кына бер гаилә кайдандыр табылган ясмык онынннан ботка пешереп туйганчы, әчләре күбенгәнче ашаган. Ашаудан, кинәт күп ашаудан үлде алар.

Ишектән кергәндә, киң җилкәләре сыймагач, ян белән борыла торган Гыйбадулла әле берничә көн генә элек хатынын тиргәп ташлаган:

—Нишләп борчакны әрәм-шәрәм итеп өстәл өстендә калдырасыз?

Үзе берничә саргылт-яшькелт түгәрәк нәрсәләрне кабып та йоткан.

Сабыр-инпле хатыны моңа җавап биргән:

—Карале, сиңайтәм, ул борчак дигәннәрең кечкенәбез Хәлимәнең тәрәте иде ич.

—Иппи-амать!—дип кенә әйтә алган Гыйбадулла. Ә алар—таза тормышлы кешеләр.

Бу эрбәлүтсия, гражданнар сугышы әнә шулай таза тормышлыларның да тез астына китереп сукты. Шуңамы Заһидулла, гражданнар сугышы солдаты, кызыләрмис:

—Ник кенә бәлшәвикләр өчен сугышып йөрдем?! Болар безне ач калдырдылар ич,—дип сукрана.

Коры суга салып пешерелгән борчак изелеп бетмәгәнме, яшь баланың ашказанында калырга теләмәгән, тавык йомыркалары кебек, кире шуып чыккан. Шуннан соң Заһидулланың каты гына авырый башлаган кечкенә сеңлесен салкын гүр йотты...

Авылда эт, мәчеләр дә калмады бугай инде. Гыйбадулланың яшьтәше Баһави да үзләренең мәчеләрен суеп ашаган. Йомшак күпертмә йонлы бохар песие. Ите генә шәптән түгел икән, сөяк тә сөяк, бу да сөяк...

Зәйнә әнә Аяз муллалар чыгарып түккән бәрәңге кабыкларын җыеп пешергән. Икенче тапкыр шул юынтык су түгелә торган урынга килеп актарына башлагач, йорт хуҗасы хәзрәт тоткан моны:

—Син нишлисең, деңсез?!

—Нишләгәнне күрмисеңмени? Күзеңне май бастымы әллә?—дип акырган үз чиратында, сабыр канатын тиз сындыра торган Зәйнә.

Хәзрәт тә кызу канлы, әмма ул бу урында тарткалашуны әдәпсезлек санаган, күрәсең.

—Әйдәле, кардәш, минем белән. Мөэмин-мөселман халкына болай килешмәс. Күңлимә гамь вә госса[1] индирдиң. Истикъбаль[2] хакына, илла истикъбалебез өмидсез түгел!—дигән Аяз мулла, кинәт кенә йомшарып вә Зәйнәне бик нык җәлләп. Теләсә, тук та ачның хәлен белә.

Абыстай янына килеп кергәннәр болар. Өстәлдә, чабышкы аргамак кебек пошкыра-пошкыра, самавыр җырлап утыра икән, аның тирәсендә—үрдәк бәбкәләре кебек чәчәкле-чуклы чынаяклар.

Аяз мулла шундый инде ул: утырып чәй эчкәннәр, Зәйнә, рәхмәт әйтеп кайтып китәргә җыенгач, бер чиләк бәрәңге тутырып биргән. Өйләренә авызын колагына кадәр ерып кайткан Зәйнә ишектән керүгә үк:

—Кем... карчык! Безнең бәрәңге кабыгы балалаган!—дип кычкырып җибәргән.

Бөтен өй эче дерт!—итеп куйган. Бишек баласы Гафифә кычкырып елый ук башлаган. Зәйнәнең иң олы улы, гражданнар сугышыннан яраланып кайткан Фәрхетдин, кинәт сикереп торган да:

---

[1]Гамь вә госса—кайгы, хәсрәт.
[2]Истикъбаль—киләчәк.

—Эти, каян урладың моны?—дип сораган. Кечкенәдән дөреслеккә омтыла торган булып үсте ул. Шуңа күрә авыл халкы ана бер генә кушамат такты:

—Туры Фәрхи! Фәрхетдиннең намусы да Бәрхетдин!—дип тә җибәрәләр кайчак шаяртыбрак.

—Аяз мулла бирде...—дип җаваплаган улына Зәйнә.

—Аяз мулла?

—Ие!

—Белмим!—дип шикләнгән Фәрхи.

—Белмисен,—дигән Зәйнә, кыза төшеп.

—Мулла бирер микән? Мулла ала ул!

—Син бөтенесен дәген бер чыбыктан сөрмә, җәме. Башка муллалар бәлки алыр, ә бу бирде. Шуңа дагын ул гади мулла гына түгел, ә Аяз мулла! Бәлшәвик булдым дигәч тә... Аңладыңмы, малай?—дип, тавышын тагы да күтәрә төшкән Зәйнә.

—И-и-и, Раббым, көннәре чалт аяз тора, ник бер бөртек янгыр төшсен. Үләннәр дә тишелде дә корып бетте,—дигән аларны сүзсез генә тыңлап торучы Зөһрә, сүз сөрешен үзгәртеп.

—Аяз шул, ник бер болыт кисәге...—дип, аның сүзен җөпләгән Фәрхи.

—Корыга китте... Корытыр бу болай булса безне,—дигән Зәйнә. Ул болай да, үз хуҗалыгын үзе тартып баручы саналса да, ишле гаиләле, ярлы крәчтиян ич.

Гыйбадулла, Гайнуллар әле хәлле генә яшиләр иде, тормышлары нык, эшкә батыр кешеләр. Ә шулай да егерме беренче ел аларны да әйләндереп салды. Яталар хәзер аркасына ауган бака кебек тыпырчынып...

Менә шул елны Мөхәммәт үлде инде...

Түбәгә мендерелгән шактый юан бәбкә-кайчы ничектер ычкынып китте дә җиргә, корылып-төзелеп килә торган лапас астына су эчәргә дип төшкән Мөхәммәтнең башына:

Шап!

Дөнья кинәт караңгыланып китте. Кояш күзен йомды. Юк, якты кояш Мөхәммәт өчен генә күзен йомды. Чәпчим Мәкчим, Заһидулла, Әхмәдуллалар өчен түгел. Ул аларга һаман елмаеп карый иде.

Нәрсә соң ул үлем?

Үлеп барганда аның нәрсә икәнен уйламыйлар икән. Бары кеше үзенең билгесезлеккә очып баруын гына азмы-күпме аңлый икән...

Ә Мөхәммәт Азак дингезе буенда бер тапкыр үлеп караган, дөресрәге, аның югалткан кеше буларак, бу юлы да үлем турында берни дә уйламады.

Ах!—ул шулай дип әйтергә генә өлгерде бугай. Әмма башын кисеп узган бердәнбер кыска уй: «Беттем»...—иде.

* * *

Әле ике көн элек кенә кызыл йөзле, җирән чәчле, ак керфекле Әндри хуҗа алларына көлә-көлә бер табак дуңгыз ите утырткан иде.

—Тьфү! Тьфү! Мин күрмәдем—җен күрде...—диде Заһидулла. Чыраен сытып торса да, коты алынгандай кыланса да, үзе шундук бер симез һәм олы калҗаны карчыга тизлеге белән эләктереп алды да, арыш ипие белән тиз-тиз чәйнәп, йотып та җибәрде. Тамак ач, корсак буш чакта, шәригатен бер читтә торсын. Ни генә димә, шәригать тамак туйдырмый шул...

Мөхәммәт ана чыраен сытып карады. Заһидулла ни куәтле, гайрәтле кеше булса да, ничектер бөрешебрәк, кечерәебрәк калды шикелле.

Бер көннән соң аларга керәшен Мәкчим дә кушылды.

—Менә керәшенгә дуңгыз ите хәрам түгел!—диде Мөхәммәт. Ә Әндри хуҗага ул болай диде:

—Послушай, Иваныч! Если и дальше нас так будешь кормить, я уйду.

—А как тебя кормить надо?—дип гаҗәпләнгән булды Андрей дигәннәре.

—Сарык суй! Мөселман чучка ите ашамый,—диде Мөхәммәт, ана өстән аска карап.

—А-а-а... Вот в чем дело,—дип тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп, рәхәтләнеп көлде Андрей. Аннан соң кинәт кенә житдиләнде дә: Мөхәммәтнең калын жилкәсенә дусларча кагылып:

—Сделаем, браток... Вот сначала работу надо закончить,—диде. Аннары почмактагы сурәт-иконага карап чукынып алды.

—Господи! Каждому свое...

Андрейның ике чиләк су сыешлы казанында төшке ашка сарык түшкәсе салган аш кайный иде. Әйе, кайный иде... Әмма Мөхәммәткә сарык ите ашау насыйп булмаган икән, чөнки... Ашка керер алдыннан гына, башына юан һәм авыр бәбкә төшеп, Мөхәммәт үлде...

Иптәшләре шундук эшләрен ташлап, Андрейдан озын арбага жигелгән ат алып, аны туган авылы Шөнгә, жиренә житкереп жирләү өчен алып киттеләр.

Төштән соң кояш тагы да нык кыздыра башлады. Хәтта һава әлсерәгән эт теле кебек, үз алдына дерелдәп тора иде шикелле. Эсседә хәле киткән кош-корт агач яфраклары астына поскан. Күктә кабартып куелган ястыклар—берән-сәрән ак болытлар күпереп тора. Сарапул күле ягыннан искән хәлсез жил алар тарафына килеп житә алмый.

Аяк астындагы ком тешләргә тиеп шытырдый. Арбада Мөхәммәтнең алыптай озын һәм зур гәүдәсе. Беркем берни дәшми. Бары Андрей гына атны кызулатырга теләп, еш кына чөңгереп, бахбаен әйдәкләп ала. Юл уртасында туктап, камыт бавын ныгытыбрак бәйләде, чөнки ашыгычлык белән ул аны аннан-моннан гына эләктереп куйган иде. Аның йөзе караңгы: бердән, эше тәмамланып бетмәде, икенчедән, шушы алып гәүдәле яшь кенә егетнең кинәт үлеп китүенә ул хәйран калган иде:

—Яшисе дә яшисе бит әле аңа...

Ул арбага күз салды: өстенә чыпта ябылган Мөхәммәтнең гәүдәсе тәгәрмәчләр келтерәп барган көйгә селкенгәләп ала иде. Озын аяклары чыптадан чыгып тора, тупас ботинкалар кигәнгәме, әлеге аяк киемнәренең як-якка авышулары Андрейга коточкыч тоела, ул аларга күз салмаска тырыша, ат башына таба китә, әмма бахбай кызулый башласа, аңа—симез кешегә комнан бару шулкадәр авырая ки, ул еш-еш сулап тагын арткарак кала.

—Ничек кенә Нократ буена барып житәсе,—дип уйлый ул андый минутларда.

Инде менә елга ягыннан күпмедер дымлы салкын жил дә исеп куйгандай булды. Нократ ярына житәрәк күрделәр: бер акчарлак өстә-һавада әйләнеп-тулганып йөрде дә капыл гына суга ташланды, әмма... балык тирәнгәрәк чумып өлгерде булса кирәк, кош, берни дә эләктерә алмыйча, яңа корбан эзләп, тагын югарыга күтәрелде.

—Ашыкты...—дип куйды тәбәнәк буйлы, юан бармаклы Әхмәдулла, башындагы түбәтәе белән маңгай тирен сыпырып төшереп. Аның йөзе хәсрәтле, ул, ни сәбәптәндер, соңгы күнелсез вакыйгада үзен гаепле дә сизә иде.

—Ие шул... Әз генә көтсә, балыкны эләктерә иде,—диде Заһидулла, кәзәкиендәге соргылт ком тузанын кагып. Ул ничек кенә булса да Мөхәммәтнең үлеме турында уйламаска тырыша, гүя әлеге авыр хәлне онытып тору кардәшенең үлемен ялганга әйләндерә.

—Мин Мөхәммәтне әйтәм: үләргә ашыкты, дип... Ә син? Балык башы!—дип мыгырданды туганына карап Әхмәдулла, гомер буе капылт кына кешегә бәрелмәгән инсан. Сабыр да сына икән!

—Ә мин кемне әйтәм?!—диде тиз ярсучан һәм шулай ук тиз басылучан Заһидулла.—Мать твою!

—Ә син минем әнкәйгә тимә!—дип, тыныч кына әйтте Әхмәдулла.—Онытма: ул синең апаң. Әниең ягыннан тәтә тиешле ул сиңа.

—Әнәгез, әнә, карендәшләр,—диде аларны әрепләшүдән туктатып керәшен Мәкчим.—Чәпчим тәртәдән чыгып барасыз бит. Үлек янында болай туарылырга ярамый. Миннән читенсенмәсәгез, Әндридән оялыгыз әзрәк. Ул, татарча аңламаса да, йөзегез-күзләрегездән күреп тора ич. Юкса, чәпчим... Менә, чәпчим инде!

Заһидулла бу сүзләрдән соң авыр куллары белән Әхмәдулланың җилкәсенә сак кына кагылды, ә тегесе аның кулын йомшак кына кысты. Шушы ым-хәрәкәтләр белән туганнан туганнар «тәртә арасына керделәр».

«Ну бу карахтерны!—дип, эчтән генә үз-үзен сүкте Заһидулла.—Берәр мина ошамаган сүз яисә эш-гамәл булдымы, чырагач кебек чырт итеп кабынырга гына торам. Тәртә усактан шул минем, аз гына бөктең яисә каердыңмы, шырт итеп шартлый да сына. Менә, Мөхәммәт тә әйткән иде бит аңа: «Синең,—диган иде...—Заһидулла, тиз кабынучан һәм артык горур булуың, алдагы тормышыңда күп кыеннар ашатыр әле»,—дигән иде. Шулаен шулай да... Кыен ашамыйм, үземчә булмыйм дип, теләсә кемгә баш иеп, тез чүгеп яшиммени инде?! Мин кемнән ким? Яшәргә өйрәтмәсеннәр мине, чөнки барыбыз да—акыллысы, ахмагы да—бер генә тапкыр яшибез. Һәркем бер генә яши... Менә, яңа тормыш корабыз дия-дия, ачлыкка алып килеп терәделәр. Игенче ипи ашамый яшәсен әле? Көлке бит бу! Юк, еларлык хәл...

Эх! Менә Мөхәммәт... Яшь бит... Яшьтәш бит...»

... Атлы арба Нократ ярына килеп җитте. Кешеләр генә түгел, ат та Нократка күз салды.

Югыйсә, шаккатарлык берни дә булмады бит. Яшь кенә булсалар да, гражданнар сугышында катнашып, шул афәтнең барлык газапларын кичергән Заһидулла белән Әхмәдулла өчен Нократ ярына басу, туган елганы күрү үзе үк бер рәхәтлек кенә түгелме соң?

Түгел шул!

Әнә, арбада кардәшләре Мөхәммәтнең алып гәүдәсе ята.

Су буенда Әхмәдулланың яшерелгән завузной каегы[1] бар. Таллар арасыннан аның койрык ягы гына күренә, ә борыны ярга ук күтәртелеп куелган, чиләк юанлыгындагы имәнгә чылбыр белән эләктерелеп, бикләнгән.

Мөхәммәтнең гәүдәсен дүрт ир иңләп кенә күтәрде дә каекка алып кереп салды. Әхмәдулла аркылы куелган ике такта утыргычны алып куйган иде. Ята Мөхәммәт: аста—чыпта, өстә—чыпта. Каек акрын гына, авыр гына кузгалды. Гүя өстенә Ярмәкәй тавы кадәр йөк төялгән...

Арбадагы Әндри белән Мәкчим каршы якка—Биктауга юл алды...

* * *

Мөхәммәтнең җир иңәнле, кош оясы чаклы гына кечкенә өе мәрхүм белән хушлашырга килгән карт-корыны, әби-чәбине, ир-атларны, хатын-кызларны, бала-чаганы сыйдырып бетерә алмады. Ир-ат куе чирәм баскан шактый киң ишегалдында чүмәште, хатын-кызлар, яулык очы белән ирен-авызларын каплап, урамда, капка төбендә торсалар, бала-чага читән буенда, кычыткана чагыла-чагыла, нindидер тамаша көтә иде. Үлем алар өчен әле... әллә нинди аңлаешсыз ят нәрсә...

Беразчиттәрәк ике үсмер кыз шәйләнә. Дөрес, аларга әле күп булса уникe-унөч яшь булыр, ләкин әлеге үсмер кызлар үзләрен «ыбыр-чыбыр» арасында тотарга теләмиләр, чөнки ниндидер эчке бер сизенү аларга бәдәнитән үзгәрешендәге озакламый булачак күченешләр турында кисәтеп тора.

—Нигә үлгән соң ул, Алсу?—дип сорый кызларның юантыгы, төскыяфәте белән бурят яисә якутка тартымы.

—Нигә үлгән, дип... Мөхәммәт абый бит... Ул бит абыем Заһидулла белән Биктаудага урыска лапас эшли иде...

—Беләм-беләм...—дип бүлде аны юантык.—Безнен Әхмәдулла абый да алар белән...

—Менә шунда...—дип башлаган иде очкын кара күзле нәфис-сылу гәүдәлесе, иптәше аны тагын бүлде:

—Лапас өстеннән аның башына бүрәнә төшкән!

—Мескенем...—дип пышылдады сүзе өзелгәне, күзләрен йомып. Шулчак аның йөзенә кара пәрдә кунып алгандай булды.

---

[1] Завузной каек—«завузной» (завоз мәгънәсендә), йөк йөртү өчен.

—Әйдә моннан китик, Бибинур!..—диде ул дус кызына кинәт.

... Ирләр дә, хатын-кызлар да Мөхәммәтнең үлеменә бәйле хәлләр турында артык кычкырмый гына, ярым-йорты тавыш белән генә сүз куертып маташтылар. Әмма...

Ни турында ничек кенә сөйләшмәсеннәр, берәр хәл-гамәл хакында ни генә димәсеннәр, күңелләрен барыбер кыен вә газаплы, сагыш-хәсрәтле авыр тынлык баскан. Әҗәл өй эчендә калдырып китә торган моңлы, җан өшеткеч кара корымдай, коры уй тынлыгы бу...

Йортта үле Мөхәммәт...

Аның янында Аяз мулла, Гыйбадулла, Зәйнә, Гайнулла, Баһави. Чоланда тагын берничә карт-коры. Заһидулла, Әхмәдулла кебек яшьләр һәм урта буыннан берничә ир-ат кабер казырга җыенып йөри. Тагын берничә хәллерәк-көчлерәк кеше аларга кушылачак, шуларны көтәләр.

Кулына җиз комганын тоткан Аяз мулла үлекне юарга әзерләнеп йөри. Менә аның карашы Мөхәммәтнең нәкъ маңгай уртасыннан агып төшкән кызыл кан җебенә төште. Кан инде кипкән, ә эз калган. Хәзрәтнең тәне буйлап салкын бер дулкын узды. Гүя шушы кызыл җеп белән Мөхәммәтнең җанын суырып алганнар. Газраилдә—җепнең бер башы, икенче очына Мөхәммәтнең җанын эләктереп куйганнар.

Аяз мулла, аның үлемен ишетүгә:

—Иннә лилләйһи вә иннә иләйһи рәҗигүн[1]—дип укыган иде. Хәзер менә ач вә хәлсез авыл халкыннан азмы-күпме көче-дәрте калганнарын дәштереп алды:—Көне бик эссе... Тәне бозыла башлаганчы җиренә житкереп җирләргә кирәк!—диде.

Хәзрәт үз өеннән алып килгән тастымалны уң кулына алды да, комгандагы суы белән чылатып, Мөхәммәтнең маңгаендагы кызыл кан җебен сөртеп алырга теләде. Үзе әллә ничек кенә төчкереп куйды. Аның чиләдә салкын тигән кеше кебек төчкереп торуын тирә-юньдәгеләр аңлап бетермәсәләр дә, Аяз мулла моның нидән икәнен тиз чамалады. Тастымалны бит Асыл абыстай аңа үз сандыгыннан алып бирде. Ә ул сандыкта сөлгетастымал, мендәр-ястык тышлыклары, тәрәзә пәрдәләре, башка төрле бик күп чүпрәк-чапрак арасында көя даруы, нафталин, төрле ислемай-хушбуйлар белән бергә нашатыр спирты да бар. Абыстай соңгысын мунчадан ис тиеп кайтуга тота, чөнки аңа еш кына мунча исе тиючән. Тастымалга, шешәсенең бөкесе ачылыпмы, мул гына итеп нашатыр спирты түгелгән иде.

Хәзрәт ашыкмый гына Мөхәммәтнең маңгаендагы кан җебен сөртә башлады. Шунда...

Әйе, шунда...

Ул кинәт кенә:

—А-а-аһ-һ-һһ-һһ...—дигән әллә нинди газаплы, чәчләреңне үрә торгызырлык бер авыр аваз ишетте. Аяз мулланың тастымалы бер кавымга үлекнең маңгаенда туктап калды. Менә ул, үзе дә аңышып ук бетмичә, тастымалын Мөхәммәтнең маңгаеннан аерды һәм... катып калды...

Мөхәммәт әллә нинди бер тетрәнү белән бик авырсынып-авырсынып күзләрен ачты да керфекләре дерелдәү вә кашлары җыерылу рәнҗеше аша аңа шактый ук текәлеп тора башлады. Менә ул күзләрен йомды һәм тагы акрын гына ачты.

—Иң мөфтиме...—дип пышылдады Мөхәммәт, иреннәрен чак-чак кына селкетеп.

—Әлгаязе билла![2]—дип ычкындырды куркуы белән шаккатуы йөзенә бәреп чыккан Аяз мулла.

Җиз комган җиргә тәгәрәде. Суы «болт!» итеп түгелеп китте. Хәтәр тынлык... Әллә нинди сәер хәл...

Өй эчендәгеләр тораташ каттылар: мондый хәлне берсенең дә күргәне генә түгел, ишеткәне дә юк иде. Кемдер тышка чыгып йөгерде:

---

[1] Иннә лилләйһи вә иннә иләйһи рәҗигүн—берәр кеше үлгәндә яисә үлгәч әйтелә торган сүз. «Аллаһы бирде, Аллаһы алды» мәгънәсендә.

[2] Әлгаязе билла—Алла сакласын.

—Мөхәммәт терелде!

Хәзер инде ишек алдындагы, капка төбендәге халык хәтәр бер аптырашта калды:

—Үлгән кеше тереләмени? Шул, теге дөньяда гына...

Кеше туа да үлә, ә Мөхәммәт үлеп тагын терелде. Кабер казырга баручыларны тиз генә туктаттылар. Халык нишләргә белмәде, шау-гөр килде. Кемнәрдер Мөхәммәтнең өенә кереп чыкты. Зират ягыннан Заһидулла белән Әхмәдулла кайтып Мөхәммәт өенә атылдылар:

—Кан кардәшебез!

—Якын дустыбыз!!

Мөхәммәт бик хәлсез иде әле...

Халык тарала башлады, бары читән тирәсендә бала-чага гына әверетөере килә иде. Заһидулла белән Әхмәдулла Мөхәммәтне сакларга калдылар...

Берәр сәгатьтән, кояш баерга өч уклау биеклектә генә калгач, Аяз мулла тагын бу йортка килде. Кулында-култыгында Асыл абыстай төреп җибәргән күчтәнәчләр иде.

Заһидулла белән Әхмәдулла Мөхәммәтне инде киендереп үз ятагына салганнар иде. Әле күптән түгел генә ул яткан кабык чоланга чыгарып куелган.

—Хәлең ничек?—дип сорады хәзрәт йомшак кына, гүя бу егет алып гәүдәле Мөхәммәт түгел, ә әле генә туган сабый бала.

Мөхәммәт нәрсәдер әйтергә тырышып башын селекте.

—Менә, абыстаң сиңа бераз күчтәнәч җибәргән иде... Ашап ал, сина хәзер көч җыярга кирәк.

—Рәх-мәт!—диде егет.

—Берәр җирең авыртмыймы?

—Ба-аш әй-лә-ә-нә.. Ко-лак... шау-лый...

—Бер дә аптырама, үтә ул, үтәчәк ул!—диде дә Аяз мулла, аннары саубуллашып чыгып китте. Ул килгәч, хәзрәткә хөрмәт йөзеннән ишек алдына чыгып торган Заһидулла белән Әхмәдулла тагын өйгә керделәр. Алар искиткеч бу хәлне—үлү һәм терелүне—Раббының хикмәте, Аллаһының рәхим-шәфкате итеп кабул иттеләр, чөнки гражданнар сугышы еллары, ачлык аларның иманнарын какшата төшсә дә, егетләр дәһрилек сазлыгына батмаганнар иде әле. Ә Мөхәммәткә килгәндә, алар аның һәр сүзен шундук үтәргә, һәр кушканын эшкә ашырырга риза иделәр. Иң мөһиме, Мөхәммәткә җан керү белән алар күкрәгенә оялаган кара таш та юкка чыкты. Ул кара таш егетләрнең йөрәк тирәсенә Мөхәммәт үлеменнән соң оялаган иде.

Аяз мулланың Мөхәммәткә күчтәнәч китерүе Шөн авылы халкын уятып җибәргәндәй булды: кемнең кабардай-йотардай нәрсәсе бар—шуны урын өстендә яткан Мөхәммәткә ташыдылар. Мөхәммәтнең терелүен ишеткән Биктау урысы Әндри белән керәшен Мәкчим икенче көнне үк аның хәлен белергә килделәр. Әндри теге көнне пешергән итен ни сәбәптәндер кар базында тоткан—шуны алып килгән. Ит бераз бозланган һәм яшел кычытканга төрелгән иде. Керәшен Мәкчим дә бер тырыс каен җиләге алып килгән. Менә шунда Мөхәммәт кан кардәшләре Заһидулла белән Әхмәдуллага:

—Мине саклап ятмагыз... Эшне бетереп кайтыгыз... Башлагач—бетерергә кирәк!—диде.

—Соң, ни... Бе-те-рер-без,—диде Әхмәдулла сузып кына.

—Син бит әле авыру...

—Сине ничек ташлап китәсен?!—диде Заһидулла кырт кына.

Әмма да ләкин икәве дә соныннан бу кинәшкә күнделәр.

Ята шулай ялгызы Мөхәммәт...

Авыл халкы кергәләп-чыккалап йөри: һичъюгы төрле үләннәрдән төнәтмә китерә, тал һәм зелпе кайрысыннан ясалган саркынды кертүчеләр дә бар.

Ә берсендә...

Очкын кара күзле, нәфис йөзле бер үсмер кыз аңа сөт кертте.

—Исемен ничек синен?—дип сорый алды аны күрүгә тетрәнгән егет.

—Алсу...—диде оялып кына аңа читләтебрәк караган кыз.

* * *

1929 ел...

Апрель ае...

Өй кыегындагы төнге салкын элгән хәнҗәр-бозлар, кояш ныграк жылыта башлауга, ычкынып китәләр дә, җирдәге соңгы кар өеменең йөрәгенә кадалалар.

Басу-кырлардагы бинирһая ак кар толыбы юкара, йомшый, изелә, сытыла башлады. Беренче гөрләвекләр күренде һәм озак та үтми ташу атнасы башланды. Яшьләр, бала-чагалар боз агышын карарга Нократ ярына җыелдылар. Кешеләрне йөдәткән кышкы киеренкелек, муенны буып торган тар яканың сәдәбе өзелгәндәй, шырт итте дә бәндәләр янышнан читкә шылды.

Менә тышта чебен-черки, озынборыннар очып йөри башлады. Шул мәхлукларның яз аенда иң беренче күренүләре дә ни шатлык, ни манзара, ни тантана!

Язны иң беренче чәчәкләр белән каршылаучы шомыртлар бөтен аклыгы белән шартлыйм дип тора. Һәр шомырт агачы—ак таучык...

Илаһым! Тереклегең—тере! Язлар бу, язлар...

... Кошлар артыннан «Шөн шахтерлары» туган авылларына кайтты.

Шөн ягының шактый гына ирләре көзге бакча-кыр эшләре тәмамлануга, язга кадәр ялланып, Урал шахталарына эшкә китәләр иде. Шулай йөри-йөри, кайберләре гаиләләре белән шунда төпләнеп тә калдылар. Алар үзләрен «Урал шахтерлары» дип атыйлар иде. Ә менә «көз китеп—яз кайтып» йөрүчеләр үзләрен «Шөн шахтерлары» дип атады. Уралда төпләнеп калганнар аларны исә «кошлар» дип кенә үртәделәр. Әлбәттә, көлеп...

Әнә шул «кошлар»ны Пүләнкә олаучылары алган-булган күчтәнәчбүләкләре белән бергә Сасмак дигән авылга кадәр илтеп куя. Аннан соң алар, Сасмакта бераз сыйланып, биш чакрым араны җәяү генә тәпилиләр. Ни сәбәптән җәяү кайталар? Югыйсә, олаучы урыс агайлар «бай шахтерлар»ны Шөннең нәкъ үзенә, кирәк икән, Мәчкәрә байлары салдырган, Аяз хәзрәт муллалык иткән күркәм мәчет янына, әле авылның абыйлыэнеле Сабир һәм Шакир бай Хәзрәтовлар элек тоткан өч таш кибет тирәсенә дә алып килеп куярга каршы түгелләр. Түләсеннәр генә! Юк шул! «Шөн шахтерлары»на әбәзәтелни өч татар авылын җәяүләп узарга кирәк. Гармун уйнап, җыр җырлап. Алган күчтәнәч-бүләкләрен күрсәтеп. Кигән яңа өсбаш, хром итек, матур кипкәне дә күрми калмасыннар. Баш киеме генә булса да, анысы кеше матурлыгының таҗы бит ул!

Өч татар авылында күпме кызлар!

Ә Мөхәммәт өйләнгәнме әле? Юк. Ольгадан соң хатын-кыздан курка ул. Яннарына аяк атламый. Якынрак килсә, шундук җен-перигә әйләнерләр кебек.

Әнә шундый хатын сөймәскә әйләнде ул. Баштарак үзенең башы шап итеп түшәменә тия торган җир идәнле хәерче өеннән оялып йөрде. Егерме беренче елны Биктауда лапас салганда башына бәбкә төшеп үлеп терелгәннән соң, берничә ел әтисе эшләгән су тегерменендә ятты. Монда эшләү әтисе юлыннан китү генә түгел, ә Шөннең икенче тегермәнчесе Федорычка хөрмәт йөзеннән дә иде. Ә иң дөресе, халык бу эшкә күнүен сораган иде ич! Халык сиңнән сорый икән, димәк, син халыкка сыясың. Халыкка сыю—бу бит һәркемгә дә эләкми торган дан-дәрәҗә, зур шөһрәт! Нәрсә дигән иде әле Хөснимәрдән агай, Хөснимәрдән фәйләсуф?

—Мин халыкка сыйсам, халык минем җаныма сыя,—дигән иде ул.

Халык сине үзенә сыйдырса, син халыкны җаныңа сыйдырырга тиешсең дә тиеш инде ул! Ә бит бервакыт Хөснимәрдән агай Казанда авырып ятканда:

—Мин күбрәк кешеләр турында уйладым, ә кешеләр үзләре турында гына,—дип тә ычкындырды. Ни сәбәптән болай диде авыру агае?

Ә бит әле ул:

—Кеше турында булганыннан, булдыра алганыннан да артыграк, күтәребрәк уйларга кирәк, ә без гел киметеп уйлыйбыз,—дип тә әйткән

иде. Әй, Хөснимәрдән фәйләсүф! Раббым нигә сиңа гомерне җәлләп кенә биргән, ә?! Бер гаебең өченме? Ул «Гаебе—Олуг Гөнаһы» турында да сөйләгән иде агае.

Хөснимәрдәннең шулкадәрле дә дөньяны танып-беләсе килгән ки, бервакытны ул теләге шундый да авыр-газаплы чиргә әйләнгән ки, фәйләсүф җиде көн, җиде төн ач-ялангач килеш салкын кар базында ятып Аллаһыга ялварган:

—Хакыйкатьнең бер читен генә булса да ач мина, Раббым!—дигән.

Ул, шул сүзләрне һәр көн кабатлый-кабатлый, җиде килограмм, ягъни унҗиде-унсигез гөрәнкә авырлыгын җуйган, ансыз калган чаклары да булган. Әнә шулай үзенчә «Диоген бүчкәсе»ндә ятуының дүртенче көнендә бер аваз ишеткәндәй булган ул:

—Кояш барында шәм яндырмыйлар!

Бишенче көндә тәгаенрәк сүз ишетелгәндәй булган:

—Мина Яңа Пәйгамбәр кирәк түгел әле. Булганнары җиткән. Ә син Арадашчы була аласын!

Алтынчы көнне ризасызлык яңгыраган:

—Аздыгыз сез, кешеләр!

Җиденче көнне Илаһи Кисәтү Иңрәгән:

—Әле мин сезгә тагын бер Туфан җибәрермен! Ул Кызыл һәм Зур йолдызлар арасыннан Дәвер Фәрештәсе белән килер. Моны алдагылар белер. Онытмагыз: өч йөз алтмыш елга—Бер Кисәтү, өч мең алты йөз елга—Бер Туфан...

Хөснимәрдән баздан сытылып чыкан. Үзе нәкъ Өрәк кыяфәтле икән!

... Шуларны да искә төшерде Мөхәммәт өч татар авылы аша Шөнгә якынлашканда. Әнә Заһидулла—чая егет, артык тирән уйларга кереп тормады, һәр авылны шаулап-гөрләп узды, кызларга күз кысты. Очраган танышларын сыйлады, үзе дә сыйланды. Тегеләр аны күкләргә чөеп мактадылар, исерә төшкәч үзләре дә мактандылар, тагын сый эләкмәсме дип, турыдан-туры аңа ялагайландылар, әмма үзләрен бик сак тоттылар: Заһидулланың йодрыгы төшсә, сине түгел—мунчаңны!—аудара да аудара инде ул. Аның белән бик чамалап сөйләшергә кирәк, егет бит, сугыш чукмары булудан бигрәк, бик тә туры кеше, бер генә ялганны да сөйми. Кызурак канлы булса да, саф җанлы ул, ачык күнелле, ярдәмчел һәм юмарт.

Әнә, Әхмәдулла да өйләнмәгән егет, шуна карамастан, акылы, сабырлыгы, төпле уй-фикерләре, хәтта салкын канлылыгы белән алдыра һәм шулар белән бик күплардән өстен тора.

Ул былтыр яңа йорт салды, быел өйләнергә йөри. Заһидулланың да күз атып йөргән кызы бар—Аяз мулланың гүзәл Заһидәсе. Кара син аны, ә? Заһидулла-Заһидә! Заһид-Заһидә! Чүт кенә Таһир-Зөһрә түгел, чөнки Заһид-Заһидә дигәндә бөек мәхәббәт геройлары Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүн, Хөсрәү-Ширин, Йосыф-Зөләйха искә төшә. Ә Мөхәммәтнең күз аткан, йөреп киткән бер кызы да юк! Хет үзенә сиздерми генә гашыйк булып йөргәне дә. Хәер, ничә еллар тегермәндә ятып... Тегермән күсесенә кызлар күз сала димени?! Бер җилпуч онга алданып, әтисе кебек гомер уздырды шунда. Ярый әле эчкече булып китмәде. Чәкәш, Өчнәвер урыслары тегермәнчегә хәмер белән сало да алып киләләр иде ич! Әмма Мөхәммәт, әтисе эчеп үлгәннән соң, биргән антына тугры калды. Хәмер белән салоны авызына алу түгел, якын да китермәде. Тәмәке тартучылар янынннан үзе китеп барды. Һәр кичне йоклар алдыннан түшәгендә килеш кенә намаз укыды, ата-анасын, әби-бабаларын искә алып дога кылды. Бу ничектер Мөхәммәтчәрәк дога-намаз иде.

Өйне дә салды ул. Бер үзе диярлек. Дөрес, бура күтәрү, чытлау-мүкләү эшләренә авыл халкы өмәгә килде. Өмәсез өй күтәрү ул вакытларда гөнаһ эш санала иде булса кирәк. Кешеләр авыр тормышны үзара ярдәмләшеп алып бардылар. Өмә шунын бер матур күренеше иде.

Мөхәммәтнең өе башкаларныкыннан зурлыгы белән әллә ни аерылмый иде: урам ягыннан җиде аршин, бакча ягына таба унике аршин. Хәер, егерменче елларда Шөндә җиде аршинга унике аршинлы алтыпочмаклы

йортлар әллә ни күп түгел иде шул. Ә «тавык кетәге»дәй өйдә яшәгән Мөхәммәткә бу йорты хан сараедай тоелды. Шуның өстенә, Шөндәге барлык йортлардан аермалы буларак, аның өй эче бер аршинга биегрәк иде. Авыл халкы, кыш жылырак булсын өчен дип, үз йортын тәбәнәгрәк итеп сала, нигездән жиргә үк тери, балчык белән күмә. Ә Мөхәммәт башта таштан шулай ук бер аршин биеклегендәге нигез салды, шуннан соң гына ышкы белән шомартылган матур бураны аның өстенә күтәрделәр. Әлеге йортның тагы бер сере бар иде әле: аның агачларын Мөхәммәт үз жилкәсендә ташыды. Әйе, аның өшәнгәнрәк бер бахбае да бар иде инде йортка агач әзерләгән чакта. Ләкин ул ал күчәргә салып бер бүрәнә алып кайтса, егылыр хәлгә житә. Чегәннәрдән сатып алган иде ул аны. Алдап киткәннәр, каһәрләр! Тыштан ялтырап торса да, эчтән калтырап тора икән шул бахбай. Хет бүрәнәсе-ние белән үзен дә күтәреп алып кайт. Менә шуңа ул аны интектереп йөрмәде, яшел үләнгә арканлап куйды да өйлек агачларны үз жилкәсендә ташыды. Урман каравылчысы Иван Федоров аның бүрәнә күтәреп урманнан килеп чыгуын күргәч, артына утырды, күзләре акайды, нигәдер борыны мышкылдады:

—Как ты, Магомед?—дип кенә сорый алды ул,—Как ты без лошади?!

—Так.—дип, кыска гына жавап бирде Мөхәммәт. Аның көчен күреп таң калган, «чудо!» дип атаган каравылчы агач өчен юньләп акча да түләтмәде. Юкса Мөхәммәт Серафима карчыкның изге бүләге—алмазлар утыртылган ике алтын йөзек белән!—түләргә карар кылган иде бит! Менә хәзер дә шул уе өчен оялып бара егет! Аның төшенә бүрәнә-бүрәнә балыклар кергән иде. Төшкә балык керү—байлыкка!—ди халык. Эшләп акча ала алмады ул, әмма болгар карчыгы Серафима Мөхәммәт Болгареевка бәя бирер бетергесез ике йөзек-бүләк калдырды. Каян килеп эләккән ул Серафимага? Әби әйткән иде:

—Минем Теодор гайрәтле чагында юлбасарлар атаманы булды,—дигән иде. Дөрестер... Димәк, бу йөзекләр урланган, шуңамы кулларны пешерә. Мөхәммәт аларны ераграк яшерде...

Шулай үзалдына уйланып кайта егет...

Ә башкалар? Шөннәр укымышлы, бай тормышлы, тырыш кына түгел:

—Шөннәр—горур халык!

Бу горурлык вакыт-вакыт мин-минлеккә кадәр барып житә. Шөннәргә үз горурлыкларын кибеткә куеп, мескеннәргә сатарга да була. Аларга «татарье», «гололобый» дип кара, шундук маңгаеңа берне алырсың! Бигрәк тә мондый сүзләр белән Заһидулла янына килмә инде, ачуыннан кызулыгы белән имгәтеп ташлавы да бар, чөнки ул «Татар» сүзен байрак итеп күтәргән:

—Мин—татар малае Заһидулла!—дип кенә жиффәрә.—Үз исемемне түбән төшерсәм дә, татар исемен түбән төшермәм!—ди.

Сабантуйлар атавында аларны каршыладылар. Абыйсының муенына ташланган Алсу ялт итеп Мөхәммәткә карап алды. Егет тетрәнеп китте...

* * *

Алсу чык бөртегедәй якты һәм кечкенә, ифрат хәрәкәтчән, тәненең һәр күзәнәгеннән көч, дәрт, терелек, сәламәтлек-саулык бәреп торган чем-кара шомырт күзле, һәрчак елмаюлы йөзле, ифрат сылу, зифа гәүдәле, нык бәдәнле, нечкә билле, бит урталары нәни чокырлы, тыгыз-калын балтырлы, вә мәнле бер кыз бала иде. Мөхәммәт аптырый калды:

—Ничек аны бу көнгә кадәр күрми яшәлгән? Бер авылда яшәп? Хәер, буе өч чакрымлап булган Шөннең Мөхәммәт югары очында, беренче су тегермәне ягында, ә Алсулар түбән очта купец Стахеевның икенче су тегермәне тирәсендә яшиләр ич.

Өенә кайтып егылган егетнең ике кулына бер эш кермәде. Кышын миче ягусыз гына чыккан өйнең һавасын алыштырасы, тузан утырган өстәл-урындыкларның өстен сөртәсе, тәрәзәләрне юасы бар, чоланны чистартасы, ишек алларын себереп куясы бар. Ә уйда Алсу гына... Аның янып торган күмердәй кара шомырт күзләре. Сабантуйлар тавында абыйсы Заһидулланың

кочагына ташлангач, ялт итеп аңа карап алуы. Күршеләреннән башка Мөхәммәтне юньләп каршы алучы да юк иде бугай...

Шулай!

Туганнарсыз яшәү ачы суган булса, (ә ачы суганның кабыгын әрчесәң, елата!)—ялгызың яшәү, ялгызлык—мәңге тишелмәс сызлавык ул. Гел дә сызлап торыр, йөрәкне әрнетер, җаныңны ашар, күңелеңне төшерер, барыбер тишелеп акмас!

Шуңамы, ул Алсуны уйлап, Әхмәдулла әйтмешли:

—«Чашты»...»Чистый чашты...»

Чәе чәй, ашы аш булмады. Йокысы качты. «Чашты шул, чистый чашты»—төннәрен гел саташты. Әллә ниләр сөйләнде, йолдызларга карап утырырга ияләнде. Аңа инде хыялый төс инде, күзләре авыру кешенеке кебек елтырый башлады, урамнан узып киткән һәр кызга: «Бу Алсу түгел микән?»—дип күз ташлады. Мөхәммәтнең ирләрчә йөз чалымнары ничектер нечкәрә төште, катгыйлык кимеп, нәзберекләк тә аңа күчте. Ул, чыннан да, авыру иде—Мәхәббәт чире килде аңа. Гашыйклык—моннан да бөек авыру бар микән дөньяда?! Юктыр...

Менә хәзер генә, үз гомерендә бер Чын Сөюгә тап булганын аңлады ул. Ольга белән булган ирле-хатынлы уйнаулар бөтенләй башка нәрсә икән. Ул әле ярату—Чын Ярату!—түгел икән. Күрәсең, теләгең булса, теләсә кайсы хатын-кыз белән бу «уен»ны уйнарга була, ә менә өзелеп сөйгән Берәү генә буладыр, мөгаен. Хәтта «уен»дагы парыңа: «Мин сине яратам!»—дисәң дә, Болар барысы да ялган, күз буяу, ун минутлык ләззәт өчен мең утлы ялган сүзләр вулканы атылуы. Ун минут үтүгә, вулкан сүнә, түшәктә яткан гәүдәгә салкын караш, читләшү, хәтта аннан җирәнү туа. Ольга белән яшәгәндә шуларны да тойды ул, чөнки ирләр үзе бирелгән хатын-кызны бик өнәп үк бетермиләр, тагылып йөргәннәрне яратмыйлар, муенга асылынганнарны күрә алмыйлар. Ир-ат яулап алган Мәхәббәтенә баш ия. Бары шундый сөю генә аңа җиңү тәме, яшәү яме бирә. Чын гашыйклык кына ир затына көч-куәт, җегәр-ныклык, дәрт-дәрман, үзенне сау-сәламәт тою алып килә ала. Шундый халәт аның җанында тагы бер уңай сыйфат тудыра.

Ул—Җаваплылык Хисе!

Кемдер өчен үзеңне җаваплы тою—менә нәрсә гаиләләрне, кешеләрне берләштерә. Мөхәммәт бу хисне Ольгага карата бер генә тапкыр да тоя алмады. Димәк, ул аны яратмаган...

Шушы уйлар белән ярым саташып ятканда, аны байлар йортыннан әвәләнеп ясалган клубка җыелышка чакырдылар. Ул белә иде: илдә күмәкләштерү бара. Моның асылын авыл агае белән авыл апасы аңлап бетермәсәләр дә, күмхуҗга кергән булалар, чөнки өстән кушалар бит, ә авыл куштаннары һәм ялагайлары: «Әгәр кермәсәң...»—дип куркыталар.

Дөрес, күмхуҗларны ялагайлар һәм куштаннар оештырмады. Бу эшнең башында бәлшәвик-коммунистлар торды, чөнки коллективлаштыру партиянең төп линияләренең берсеннән санала иде. Ә яшьләрдән комсомоллар бу эштә партия вәкилләренә нык кына булыштылар. Ярлы-ябагай, ялкау-сөрхәнтәй, атсыз-чатсыз, хәерче-саилчеләр дә бергә кушылып эшләргә теләк белдерделәр. Ачлы-туклы яшәргә икән—барысына шул тормыш килсен, туклыкка ирешәбез икән—һәркемнең дә кулында ипи булсын! Хәер, бу тип кешеләргә «Тигезләү» дигән нәмәрсә ошый да ошый инде. Ул аның аңына нык сеңгән:

—Мин ач икән—күрше дә ипи күрмәсен, күкрәгән киереп йөрмәсен. Тук икәнбез икән—һәркем тук булсын...

Таза тормышлылар күмәкләштерүгә шикләнебрәк карадылар. Барысы булмаса да, күбесе. Егерме Беренче Елгы Ачлыктан соң Заһидулла, Әхмәдулла, Гайнулла кебекләрнең тормышы мантый башлаган иде инде.

Җыелышны район вәкиле Корнилов һәм гражданнар сугышы солдаты «билетлы бәлшәвик» Фәрхетдин алып бардылар. Фәрхи Мөхәммәтләр белән бер яшьтәрәк булса да, тормышлары азмы-күпме тернәкләнүгә, өйләнеп җибәрде: аның улы белән кызы да бар инде. Туры кеше булганга халык ин беренче аңа ышанды:

—Ул әйткәч—алдамас!

Сөйләшүләргә күчкәч, иң беренче Бәһави сүз алды:

—Жегерме беренче жыл гына кире кайтмасын, мин күмхужага түгел ... күтхужага да риза! Мәче ите ашап карадым инде мин.

Халык көлеште. Район вәкиле, Корнилов Фәрхетдингә борылып: «Это несерьезно!»—диде.

Шунда «серьезный» кеше сүз алды. Бу—сәләмә Габдрахман иде. Гражданнар сугышы солдаты.

—Эрбәлүтсия атларында,—диде ул.—Миравуй эрбәлүтсиягә кадәр барып...

—Конкретно?!—диде Корнилов аңа кычкырып.

—Кәнкрит әйткәндә, агайлар, бу калхуз дигәннәре кирәк инде безгә. Пример, жир генә эшкәртә башла. Сукалыйм, тырмалыйм дисәң, сука белән тырма тагарга ат кирәк. Ат дигәннәре һәркемдә бармы соң? Атлылар да бар, атсызлар да...

—Менә син!—диде залдан кемдер. Борылып карадылар. Кем булсын инде—шул туры сүзле Заһидулла. Чая баш!! Түземсезрәк инде ул...

—Тик кенә утыр, Корниловны бик фетнәчел, вак, әләкчән кеше диләр. Иң мөфтиме: сәвиткә каршы уй-фикерләренне эчкә яшер. Ул калхуз дигәннәрен мин дә аңлап бетермим әле—дип тиз-тиз генә Заһидулланың колагына пышылдады Мөхәммәт.

—Чыгып сөйлә!—диде Фәрхетдин Заһидуллага. Корниловның чырае качкан иде, маңгаенда жыерчык өстендә жыерчык. Һәр жыерчыгы: «Ну, әйдә сөйләргә чык! Ни әйтерсең икән?»—дия кебек.

—Габдрахман керер ул калхузга,—диде Заһидулла.—Эрбәлүтсия атларында мировуй пужар кабызырга йөрсә дә, аның калхузга бирер аты юк. Менә бездә бер бия, ике эш аты. Мин шуларны биреп калхузга кериммени? Ә икенче берәүнең хужалыгында сигез аяклы атыннан башка берние юк.

—Нинди сигез аяклы ат ул?!—дип, бүртенеп сорады татарчаны ару гына аңлаган, ярыйсы гына сөйләшә алган Корнилов.

—Үрмәкүч!—диде Заһидулла.

Халык тагы көлеште. Мыскыллы авазлар да яңгырады. Моны Корнилов колхозга каршы төшү дип аңлады.

—Безобразие!—диде ул.—Бу бит фетнә!

—Безнең эш үгетләү. Көчләмик. Халык үзе уйласын,—диде Фәрхетдин Корниловка жайлап кына.

—Ә теге... «Үрмәкүч» кем ул?

—Гражданнар сугышы солдаты. Батыр солдат! Бик гайрәтле егет!

—Күренеп тора... Бераз куыгын киметәсе иде моның.

—Авылдашлар,—диде Фәрхетдин Зәйнәгытдинов утырган урыныннан аягына басып.—Безнең эш—үгетләү. Әйе, мин колхозга керегез!—дим.—Менә бүген иң беренче булып үзем языламын. Кемнәр икеләнеп тора икән, өенә кайткач, тагы бер тапкыр уйлансын. Монысы—факт! Жыелышка килгәнегезгә, рәхмәт!

Халык Фәрхетдинне ярата иде, аңа ияреп шактый кеше күмәк хужалыкка язылды, ә Мөхәммәтне колхозга тегермәне алып керде, чөнки тегермән колхоз милкенә кертелде. Районда иң беренче булып төзелгән Шөн колхозына «Кызыл шахтер» исеме бирелде, аның рәисе утырган кәнсәләрдә (Шакир бай йорты) зур гына көзге, ике шкаф тора иде. Шкаф өстендә—шахтер лампасы...

... Мөхәммәт тегермәнгә бара иде...

Әйе, бара иде...

Әйе шул, ба-ра...

Шунда... Килсә килә икән!—Алсу килә! Көлеп килә.

—Исәнме, Мөхәммәт абый,—диде ул якты елмаеп.

—Ни...—дип, тотлыкты Мөхәммәт.

—Ипиен чиме?—Алсу матур итеп көлеп жибәрде.

—Иң мөфтиме...

—Бәрәч, безнең Мөхәммәт абыебыз мөфти дә икән әле...

«И чукынчык кыз, үтерә бит бу!»—дип эчтән генә уйланып алды егет. Ә үзе ордым-бәрдем сорап куйды:

—Исемең ничек әле?

—Үпкәлим, Мөхәммәт абый,—дип иреннәрен матур гына турсайтты Алсу, йөзенә хәтта газаплы житдилек тә өстәлде: «Исемемне дә белми...»

—Бу сорауны моннан жиде-сигез ел элек биргән идең бит, Мөхәммәт абый!

—Әйе... Биргән идем... Иң мөфтиме, үлеп терелгән елым...

Кыз сискәнеп китте. Мөхәммәт буталчык уйлардан, киреле-морылы сүзләрдән арынды:

—Алсу, бүген кич тегермән янына кил әле!

—Кызлар егетләр янына түгел, егетләр кызлар янына килә бугай, Мөхәммәт абый,—диде Алсу, аның очрашуга чакыруыннан кинәт туган шатлыгын яшерергә тырышып.

—Мин сезнең яктагы, түбән тегермән турында әйтәм...

—Ул бит инде эшләми, анда он тартып булмас,—дип, тагы шаяртмак булды Алсу.

—Мин уйнап әйтмим! Киләсеңме?—диде Мөхәммәт, аның шомырт кара күзләренә туры карап. Аңлады, сизде, тойды Алсу: егет аңа битараф түгел. Юк, түгел! Аларны Сабантуй тавында каршылаганнан соң Алсуның йөрәгендә биниһая олуг учак кабынган иде инде. Хәер, шул егерме беренче елны урында яткан Мөхәммәткә сөт керткәннән бирле, гади генә «Исемең ничек?» сүзеннән соң кызның күңеленә әллә нинди тынгысыз тынычсызлык керде. Ул егеткә туры карый алмый иде, аны күргән саен әллә ничек дәртсенеп китә. Жәйләрен Нократ буендагы комлыкта, кышларын кар-бәс белән томаланган тәрәзә пыяласына Мөхәммәтнең рәсемен төшереп азаплана иде. Бу эш юктан маташу булмыйча, гашыйк кызның жидти ижади эше иде. Өй мәшәкатьләре кимеп торган арада шулай жан сусавын басу иде ул. Бу өлкәдә ана сәләт Күкнең үзеннән сендерелеп, рәссамлык аның өчен гади нәрсә генә түгел, ә күңеленә оры булып ябышкан серле-тылсымлы, мистик галәмият, жан балкышы, рухи яктырыш, яшәүнең йөрәгенә ятышлы бер матур, рәхәтле-ләззәтле, очкынлы-ялкынлы ягы иде.

Газаплы да, татлы да нәрсә ул Ижат!

... Кич...

Чикерткәләр чурлый, су буенда бакалар үзләренчә жыр суза. Тын, жылы, йомшак төн...

Озак көтте Алсуны Мөхәммәт. Менә агачлар арасыннан аның ак күлмәге чалынып китте. Кыз килеп житүгә, егет аны күтәреп алды. Бераз куркынган Алсу аның таза-нык муенын чытырдатып кысты. Егет әйләнгеч юллар белән аны күтәргән килеш ярты чакрым атлап, капка төпләренә бастырып куйды:

—Минем янымa килгәнең өчен бик зур рәхмәт!

## Икенче бүлек

### Шәрәфетдин

Икенче көнне Заһидулланы районга чакыртып алдылар.

—Син нәрсә, халыкны колхозга каршы котыртып йөрисең?—диделәр аңа милиция бүлегендә.

—Минем беркемне дә колхозга каршы котыртканым юк!—диде Заһидулла катгый рәвештә, үзенең хаклыгына нык ышанып.

—Ә жыелыштагы сүзләрең?!

Районга китәр алдыннан гына Мөхәммәт аңа:

—Анда авызыңа су кап! Монда ярый инде, үзебезнекеләр,—дигән иде.—Онытма: озын телледәр кыска гомерле була.

Шул турыда уйланып тора иде Заһидулла.

—Ә җыелыштагы сүзләрен?!—дигәнгә сискәнебрәк китте. «Суын, суын—ярсыма, тыел! Сабырлык төбе—сары алтын, ә сабырлык өчен тыела белергә кирәк»,—дип, уйлап алды ул эчтән генә.

—Мин җыелышта колхозга каршы бер сүз дә әйтмәдем,—диде ул сорау алучыга.

—Ә нигә үзең колхозга кермисен?

—Уйлыйм әле...

—Кара аны, озак уйланма. Мин синең турында сорашып торырмын. Ә хәзергә азат, шулай да төрмә сагынып тора бугай үзенне,—дип озаттылар аны милиция бүлегеннән.

Куркыту-кисәтүләргә һәрвакыт җирәнеп караган Заһидулла борылып аларга бер «бик шәп сүз» әйтмәкче булган иде, тагы Мөхәммәтнең үгетләве исенә килде:

—Сак бул! Тизәккә басма—исе чыгар, бүкәнгә типмә—аягың каймыгыр...

Шул сүзләрне хәтеренә китерү аны коткарды да, чөнки тегеләр нәкъ менә аның ярсып китүен, каршы төшүен көтәләр иде. «Контра»га актив рәвештә көрәш алып баруларын күрсәтү өчен Заһидулла кебек «бер экземпляр» кирәк иде аларга. Әмма...

Заһидулла тиз кызып китүчән булса да, тиз генә басыла да белә иде. Аннан соң ул күнеленең бер чите белән боларның үзенә тозак коруын сизде. Сүзләрен бакыр булганда, дәшмәвең көмеш икәнен шундук аңлады һәм, Мөхәммәт әйтмешли, авызына «су капты». Әти-әнисен дә хәтерләде:

—Мине төрмәгә япсалар, алар нишләр? Шунда ук Заһидәсе дә исенә төште:

—Ана өйләнергә йөрим бит мин. Инде ризалыгын да алдым. Аяз хәзрәт белән Асыл абыстай каршы килмәсәләр...

Заһидулланың, төрмәгә ябылып, бераз акыл алып кайтуын сәләмә Габдрахман бик теләгән иде. Җыелышта барлык кеше алдында адәм рисвае итте ич. Әмма дә ләкин... Теләк күп вакытта теләк кенә булып кала шул, бик-бик күп теләкләр, эшкә әйләнми, тормышка ашмый шул! Югыйсә, кемнәр генә ни теләмәс тә нәрсәләр сорап теләнмәс! Тезләнмәсләр дә көчле теләккә буйсынып тезләнә.

Заһидулланың районнан сау-таза килеш үз аягы белән кайтып килүе авыл халкын шатландырды. Ләкин бик күпләр бу хәлдән үзләренә сабак алдылар һәм телләрен тешләре артында бикләбрәк тоттылар:

—Калхузга каршы сүз әйтергә ярамый икән. Бу совиткә каршы чыгу була. Моның өченме?!

Заһидулланың исән-имин кайтуына әти-әнисе белән Заһидәдән кала иң сөенгән кеше Мөхәммәт булгандыр. Дөрес, Әхмәдулла белән Фәрхетдин дә шат иделәр, башкалар да кулын кысып ризалык белдереп уздылар. Ә Мөхәммәт аны тегермәненнән чыгып каршы алды:

—Йә, ничек?

—Су каптым!

—Иң мөфтиме, вакытында тыелырга кирәк. Тыела белү—акыллылык билгесе. Тел теләсә нәрсә әйтү өчен, үзенә зыянга такылдау өчен бирелмәгән безгә... Йә, ярый! Рәхмәт, акылыннан чыгып китмәгәнсең...

Ул инде, Заһидулла кайтмый микән дип, берничә мәртәбә чыгып караган иде. Ә анарчы бер сәер-кызык хәлгә тап булды: тыштан тегермәнгә бер чебен очып керде. Алар монда болай да күп буталалар. Ләкин монысы башкалардан нык кына аерыла: шома сыртлы, зәңгәрсу канатлы эре генә нәрсә. Үзе чамасыз безелди, тавышы да шактый калын—төклетуранықы кебек. Менә ул, Мөхәммәтнең маңгаена утырды. Кулын күтәрә төшсә дә, үтермәде аны Мөхәммәт, чөнки шулчакта Заһидулла исенә килде.

—Кит, чебен!—диде ул канатлы мәхлукка.—Олак бар, юкка тавышланып йөрмә...

Чебен очып киткәч эченнән генә:

—Ул да җан иясе бит...—дип, үз гамәленең дөреслегенә үзен ышандырды.

—Без Алсу белән...—диде Мөхәммәт Заһидуллага, милиция бүлегендә сорау алулар, янаулар турында сорашып иптәшенең саруын кайнатасы килмәде.

—Нәрсә Алсу белән?—дигән булды Заһидулла хәйләле елмаеп.

—Йөрибез!

—Йөрегез соң...

—Йөрү дигәч тә... Мин аны бик яратам!

—Менә рәхмәт!—диде Заһидулла көлеп.

—Көзгә өйләнешергә исәп,—дип куйды Мөхәммәт рәхәт елмаеп.

—Алсу нәрсә ди?

—Ул риза!

—Әти-әни бу турыда беләләрме соң?

—Юк әле. Алдан ук белгертеп куясы килми. Куркам: бәхетемнең бер чите кителер кебек. Ә син безгә ризамы?—дип сорады ул турыдан-туры.

—Бер-берсен яраткан егет-кызга кем риза булмасын, ди? Сорап торган буласын тагы!

Мөхәммәт кордашының җавабыннан бик тә разый калды, җанында нindидер канәгатьлелек, күнел күтәренкелеге, әйбәт кәеф туды. «Да, кыз да утызда...»—дигән ди берәү.

Мөхәммәт тә утызын тутырып килә иде инде. Хәер, егетләр өчен утыз яшь өйләнеп җибәрү өчен кулай вакыт ул. Монысы яшьлек юләрлеге белән Ольгага өйләнү түгел инде. Монда Хөснимәрдән агай белән Мәхмүдбәк абыйның үгетләве дә кирәк түгел. Дөресрәге: ул Ольгага өйләнмәде дә бугай, «гүзәл полячка» үзе аңа «өйләнде» кебек...

... Заһидулланы милициядә «төснәтеп» кайтарганнан соң авылда ике вакыйга булып алды. Беренчесе: Фәрхетдин Зәйнәгытдиновны район үзәгенә эшкә алулары иде. Аны җир бүлеге нәчәлнигы итеп билгеләделәр. Колхозчыларны тагы җыелышка чакырдылар. Менә шулвакыт сәләмә Габдрахман сайрап күрсәтте инде! Бу сүзне район вәкиле алдында әйтмим дисә дә, «эрбәлүтсия атлары» да ычкынды аның теленнән, «Ленин-Сталин партиясе» дә калмады, «мировуй пужар»ны да өстәде. Ул алдан ук авыл советы рәисе белән партячейка секретарен «майлап куйган» иде, бернича ялагай белән куштаннарны да әзерләп-көйләп өлгерде. Габдрахман бар көче белән колхоз рәисе булырга омтылды һәм моңа иреште дә. Ә бит Фәрхетдин Корниловка:

—Минем урынга тегермәнче Мөхәммәтне куегыз. Белеме дә житәрлек, урысчасы да чарланган. Иң әһәмиятлесе: халык аңа ышана, хөрмәт белән карый. Туры сүзле, вөҗданлы кеше. Тиктомалдан беркемне дә рәнҗетмәс,—дигән иде, тегесе аның сүзенә колак салмады.

Яна рәисне сайларга район вәкиле буларак Фәрхетдин үзе килергә тиеш иде, ләкин ни сәбәптәндер авылына кайта алмады. Корнилов кыска гына:

—Ул авырып тора,—диде.

—Әле кичә генә күрдек, таза-сау иде бит, ничек өзлегеп киткән соң ул?—дип сорады кызыксынучылар.

—Белмим. Мин доктор түгел!—дип сүзне өзде Корнилов. Дөресе: ул «Туры Фәрхи»не өнәп бетерми иде.

Дөрес, халык Фәрхетдиннен «раюнный ләчәлник» булып эшләвенә риза булды, юкса унлап татар авылы булган Пуләнкә районында «югарыдарак эшләүче» бер татар да юк. Хәер, Банат исемле бер кыз комсомолда эшли иде. Инструктормы, инспектормы шунда. Алар Шөннән Пуләнкәгә бишалты еллар элек күчеп киткәннәр иде. Әтиләре сәүдә эшендә...

Фәрхетдиннең үзен рәислеккә димләвенә аңык берни әйтмәсә дә, бу эшкә күпмедер риза булса да, Мөхәммәт җыелышта «речь толкать» итеп тормады. Ә Габдрахманның кайнар нотыгыннан соң: «Эшләсен әйдә! Бик атлыгып тора бит»,—дип уйлады. Шуның өстенә ул кордашының эшкә каты икәнен белә иде. Көч-җегәргә килгәндә дә бер дә сәләмә кеше түгел. Мөхәммәт белән Заһидулладан кала Габдрахман авылның иң куәтле кешесе иде. Кешеләрне үз артыннан иярте белә, ә бу сәләт бик сирәк кешеләрдә

гена була бит. Шуның өстенә командалык итәргә дә ярата һәм һәркемгә аерым «путхут» ясый да белә. Мөхәммәткә дә шундый, үзе әйтмешли, «путхут» ясады:

—Син, кордый,—диде ул анарга.—Тегермән, пример, пулный худка эшләми инде ул. Син, кордый, анда гына бикләнеп ятма, сине, безнең картларча әйтсәк, «ләчәлник» та итик әле. Син, кордый, пужарнайны кулына ал әле. Бер үзенә биш ат, ике ярдәмче, вә дә килеп, Хәбәч карт. Ул, үзең беләсен, төнге каравылчы...

—Уйлап карармын,—диде Мөхәммәт сабыр гына.

—Ә син уйлама, эшлә син! Без барыбыз да, пример, матур сөйлибез, матур итеп эшли генә белмибез. Ә пужарнайда эшләүнең нәрсә икәнен беләсен бит. Бигрәк тә җәй пужар куркынычы арта. Ут белән судан берни калмый!

—Шулай булгач, «эрбәлүтсия атларында миравуй пужар» кабызып торасы да юк!—дип, аны бик нык чеметте Мөхәммәт. Тегесе аңламаганга сабышты:

—Сүз сүз белән, кордый, эш эш белән! Пример... —Рәис булып алгач, Габдрахман үзе белгән яисә ишеткән шактый гына рус сүзләрен кушып сөйли башлады: «пример», «наш великий вождь», «коллективизация», «срок», «задание», «устав», «партлиния» һәм башкалар шундыйлардан иде.

Шулай итеп Мөхәммәт янгынчы булып китте. Дөресен әйткәндә, тегермәндә яту аны туйдырган иде инде: халыкның онлык ашлыгы чамалы, бүген кемдер килсә, иртәгә эт тә юк! Ятасың ялгызың, бары Алсу белән кечке очрашулар гына аның күңелен ача, киләчәккә өмет-ышаныч тудыра иде...

Ә беркөнне...

Авылдашының соравы буенча ул тегермәнгә он тартырга киткән иде. Капчыкка соңгы җилпуч арыш онын лар төбеннән кырып-себереп ятканда, ашыгып сулуы капкан Хәбәч карт килеп керде:

—Ләчәлник!—диде ул шөбһәле йөз белән.

—Нәрсә?—дип көлемсерәде Мөхәммәт.—Каланчадагы суга торган тимерең өзелеп төшкән мәллә?!

—Юк!—диде картлач.—Пужарнайга мәет китерделәр.

—Кайдан?—дип аптырый калды Мөхәммәт тә.

—Нократтан агып килгәндә балыкчы Мәгъсүм күргән үзен. Суда ятып шешенеп-бозылып беткән инде ул...

Тегермәнне бикләп янгын сараена ашыктылар. Ат җәймәсе капланган үлек бер караңгырак почмакта ята иде. Мөхәммәт җәймәне чак кына күтәреп аның йөзенә бакты һәм чүт артына утырмады:

—Похмелкин? Генка...

Муенында чиләк... Тимерчыбык белән бәйләп куйганнар. Чиләккә ком яисә таш тутырганнар, күрәсен...

* * *

Өзек-өзек көннәр тезелеп кенә килә...

Нигә «өзек-өзек көннәр»?

Генка Похмелкинның үле гәүдәсен янгын сараеның караңгы почмагында күрү, бигрәк тә аның өстендә чебеннәрнең болыт булып кайнашуы, мәеттән килгән укшыткыч сасы ис, өстенә ат тире сеңгән пычрак җәймә каплап куелуы—коточкыч бер авыр сурәт булып Мөхәммәтнең күңеленә сытылып-изелеп керде. Шуның өстенә Генканың борыны маңгае белән тоташкан урында нык кына яньчелгән, сул чигәсе кангамы, балчыккамы укмашкан. Похмелкинга башта авыр тимер әйбер белән сукканнар, аннан соң муенына чиләк бәйләп, шул чиләккә таш яисә ком тутырып суга атканнар. Ольга Нократ буендагы бер авылда аның әшнәләреме шунда, әллә туганнарымы яши дигән иде ич. Генка Ольганы да бераз вакытка шул авылга алып китмәкче булган бит...

Ольга, Ольга...

Ни генә димә, күпме генә фараз кылма, хет төннәр буе гоманлап ят: Похмелкинның үлемендә аның кулы уйнаганы сизелә иде...

Үчкә—үч, үлемгә—үлем!

Ул бер үк вакытта фәрештә дә, шайтан да иде. Ярата—чын күнелдән! Күрә алмый—бөтен йөрәге белән! Әнә Генка Похмелкинны интектереп үтергәннәр, газаплары үле йөзендә дә чагыла иде хәтта. Шулай тоелды...

Азак дингезеннән Казанга кайткач, Мөхәммәт һәрвакытта диярлек Ольга янында Похмелкинның шәүләсен күрде. Озаграк вакытка Казан урамнарына чыгып китсә, кайтып керүгә Ольга борчыла, борсалана иде. Теге әкияттәге дию кебек:

—Адәм исе бар!—дип куярсың.

Нигә ике дә уйламыйча, күзен дә йоммыйча Ольганы ташлап китте ул? Мөхәммәтне флигельдән әнә шул «Похмелкин исе» куа иде. Ул һәркөн, һәртөн диярлек Генканың рәттән генә булуын тойды. Бу әйтеп бетермәслек авыр хәл булып, егет башын кая алып качарга белми йөрде. Яшәдеме ул бу вакытта Ольга белән? Юк! Ул торды гына... Ә яшәү белән тору, тереклек итү белән тормыш корып азаплану арасында зур аерма бар. Нәрсә дигән иде Хөснимәрдән агай—авыл фәйләсуфы?

—Динебезнен биш баганасы булган кебек, яшәештә Кеше өчен иң кирәк биш нәрсә бар. Болар:

1) тән-бәдәннен исән-саулыгы;
2) жан-рухның тынычлыгы, иманлылыгы;
3) гаилә ныклыгы;
4) тормыш иминлеге;
5) йорт-жир, милләтен бөтенлеге.

Похмелкинның мәете Мөхәммәтнен жан тынычлыгын алды, рухына кара болытлар жыйды. Азак дингезендә аны ишкәк белән сугып үтерергә теләгән, Ольганың әтисе дворян Адам Азадович Василевскийны үтереп, гәүдәсен дунгызларга тураклап салган кансыз, кабахәт, явыз бу кешенен мәете Нократ буйлап агып килгән дә...—һич кәтмәгәндә кара ямьсез истәлек, канлы хәтер булып аның күнеленә кереп утырды. Куа-куа Мөхәммәт аны хәтереннән, һич кенә дә куып чыгара алмый. Шунамы төннәре йокысыз уза... Шунамы көннәре әллә ничек өзек-өзек кенә тезелеп килә... Чирне дә куа ала чын ир, ә хәтерне—юк!

... Тышта елак, мәгънәсез, эчпошыргыч янгыр сибәләп куя да, нәрсәгәдер төртелгәндәй, туктап кала. Шул кинәт сибәләве белән йоклар-йокламас яткан Мөхәммәтнен хәтерен янарта. Гүя сүнгән лампага ут элә. Дөньяда яфрактай яшел, кардай ак, кояштай сары, комдай көрән, күк йөзедәй зәңгәр, кандай кызыл янгырлар да була.

«Өйләнергә кирәк! Быел көзгә үк өйләнергә...»—дип уйлый ул. Күз алдына Алсу килеп баса һәм бар кара хәтерне юып төшерә. Ул татлы хыялларга чума... Һәр янгыр—салават күперенен бер төсе ул. Бары күрә белергә генә кирәк! Күнел күзләре белән...

Икенче мизгелдә ул Похмелкин турында уйлаудан арынырга теләп Заһидулланы исенә төшерә: «Өйләнүгә, Заһидәсе белән азмы-күпме тормады, Вятка-Нократ аръягына, аюлар янына качты. Шунда йорт, каралты-кура житкерә дә үзенчә яши, имеш! Мин ирекле кеше, ди. Ничек яшисем килә, шулай яшим, ди. Габдрахманнар «мне не указ», ди.

—Ялгышасың!—диде аңа Мөхәммәт.

—Нәрсәдә минем хатам?—дип сорады Заһидулла турыдан-туры.

—Авылдан... Халыктан аерылуында!

—Габдрахман кубызына биергә кушасынмы?

—Калхузда эшләп тә үз кубызына биергә була...

—Нигә син үзен рәислеккә кермәден?

—Халык сорамады ич!

—Халык, халык...—диде ярсып Заһидулла.—Калхуз рәисен сайлауны өч ялагай, биш куштан хәл итте. Менә сина халык!

—Халык—кара сарык...—дип тә өстә инде...

—Анысына ук телем бармый, Мөхәммәт. Шулай да халыкнын

битарафлыгы, әркәклеге, куркаклыгына ачу килә минем. Җыйнаулашып үз сүзен әйтергә җөрьәт итми. Аны гел нәрсәдер тотып килә. Авыл агаен бигрәк тә... «Тимә миңа—тимәм сиңа!» Менә аның төп дога-аяте, тормыш кагыйдәсе, яшәү кануны, Коръәни сүрәсе.

—Халыкка кагылма!—диде Мөхәммәт.—Ул болай да изелгән, тапталган. Егерме беренче елгы Афәт—Ачлыкны гына хәтерлә, ничек кырылды авылдашлар...

—Габдрахманнар «Әмрикә күчтәнәче» бүлеп яттылар,—диде Заһидулла аңа каршы төшеп.—Менә күрерсең, әҗерен алачак әле ул, халык өлеше тишелеп чыгачак!

—Йә, ярый!—диде Мөхәммәт аның белә килешә төшеп.—Иң мөфтиме, Сугыш белән Ачлык кына булмасын! Менә дөньяның куркынычы шунда. Без барыбыз да гражданнар сугышын һәм ачлыкны уздык. Башка... Раббым күрсәтмәсен!

... Нократ суы май аенда мул булып болыннарга җәелгән иде. Инде менә Көмеш Елга үз ярларына кайтты. Чәчү тәмам булып, кояш тагы да яктырак карый башлагач һәм ныграк кыздыра төшкәч, су басып узган болыннарда куерып яшел үлән күтәрелде, дистәләрчә күлләрдә балык калды. Дөрес, алар бармак буе чуртаннар, нәни генә елтыр бәртәсләр, олырак сәдәп кадәрле алтынсу кәрәкәләр генә әле. Көзгә үсеп житәчәкләр! Эссегә китеп, күлләр корымаса һәм балыкларны каргалар чүпләп бетермәсә. Хәят-тереклектә яшәү өчен туктаусыз көрәш бара. Яшәү-үлем көрәше бу...

Авылда юа атнасы башланды...

Яшьләр көчтән килгәнчә, хәле булганча ясанып-киенеп, Олы күл ягындагы болынлыкка җыелдылар. Мондагы юа! Хет чалгы белән чабып ал!

Болынлыкта—чыр-чу, гармун моңы, көлү тавышлары. Баштарак кызлар бер якта, егетләр бер читтәрәк торалар. Ике яклы «разведка» бара: кемнедер кемдер күзли, кайсыдыр икенче берәүгә сүз ката. Менә уеннар башлана:

—Бу дөнья—уен-көлкеләр дөньясы ул!

Егет халкы күзенә төшкән кызларга сүз ката, биергә чакыра, таллар арасыннан йөреп килергә тәкъдим ясый. Егет кыз алдында көязләнә, үзен «фырт»—булдыклы икәнен күрсәтә, бераз мактанып та ала, әмма дә ләкин күбрәк күңеленә кергән кызны мактый:

—Бу дөнья—мактау-мактанулар дөньясы да әле ул!

Бер төркем яшүсмерләр Мөхәммәт, Заһидулла, Әхмәдулла кебекләр алдында ачыктан-ачык ялагайлана, һәр сүзләренә колак сала, әйткән бер әмерләрен үтәргә әзер тора.

Бу дөнья—үзара ялагайланулар да дөньясы бит әле ул!

Ялагайлану—Мөхәммәтнең күрә алмаган нәрсәсе. «Ялагайлану—гаебеңне юуның, тормыш куының, үзеңә унайлыклар тудыруның иң җинел-жирәнгеч вә ансат-түбән юлы ул»,—диган иде Хөснимәрдән агай.—Коллар юлы... Әмма аның өчен горурлыгыңны үтерергә кирәк. Һәр ялагай—үтерүче ул.

—Ялын-ялагайланма!—дип тә өстәде Хөснимәрдән агай.—Тезләнгән дә аягына баса ала. Ялагайлансаң да—яла якма! Яла ягу—ялагайлыктан да яман...

Шулай булгач, Хөснимәрдәнчә: ялагайлыктан да түбән, начар, әшәке яклар да бар икән кешеләрдә. Бәндә яманлыкта шайтанны да уздыра диләр бит!

Юа атнасында кызларның чабата, галуш, ак һәм төрле оекбашлары, алъяпкыч-яулыклары бизәлгән, егетләрнең ботинка, хром-кирза итекләре шыгыр-шыгыр килгән, күлмәкләре җилдә җилфердәгән, кепка-фуражкалары чәчне янга чыгарып кырын салынган була. Болынлыкта сабантуй да булып узды.

Атна буе җыеннар китте...

Ат-арбага төялгән, хәтта самавыр, табак, калак-кашыгын, иләк-чиләген дә алган кешеләр җыеннан-җыенга йөри башлады. Күбесе туган-тумачасына атап бара, шулай да күчтәнәчкә каклаган каз, бөтен ипи, көз җыелган чикләвек, киптерелгән шомырт, башка тәм-томын, берәр көнлек камыр ризыкларын алырга да онытмыйлар.

Бу якларда жыеннар уза торган өч авыл бар: Ямул жыены—«Черкиле жыен», бу жыен вакытында урман-сазлыклардан миллионлаган черки көтүе күтәрелә һәм алар бәйрәм итүчеләр өстендә жанлы кара болыт булып биешеп торалар, күзгә, колак, борын тишекләренә кереп йөдәтәләр. Вахит жыены—«Базарлы жыен». Халык бу жыенга бәйрәм белән бергә сату-алу итәргә дә йөри. Әйтик, арба артына картая башлаган сыерын да тага. Итлеккә суяр иде, жәй көне анын кадәр итне кар базында гына саклап булмый. Сөт эчәм дисән, сыер урынына кәжә генә дә алмыйча булмый. Әнә ул үз-үзен нык яратучы ахмаклык хайванның мөгезенә үк эленгән. Ул аларны сөзешергә дип тотмый, ә арка кашырга гына башында йөртә. Хәер, сөзешмәү—үзе үк шәп нәрсә ич. Кешеләр әнә мөгезсез дә сөзешергә генә торалар...

... Мөхәммәт үз уйларынан үзе көлемсерәде:

—«Менә ахмак! Кәжә турында фәлсәфә сатып утырган бул инде, ә?! Ангыра һәрвакыт башкаларны үзеннән ангырарак дип уйлый,—шулай дияр иде Хөснимәрдән агай».

Шөн жыенын—«Мәчетле жыен»,—дип атыйлар иде, чөнки авылда ике мәчет булып, аларнын манаралары дәһрилек чоры килгәч тә киселмәде, бары Шакир һәм Сабир бай йортыннан әвәләнгән клуб ишле Шөн халкы өчен тарайгач һәм искерә башлагач кына түбән мәчетне «яңа клуб»ка әйләндерделәр. Ә 1850 елны Мәчкәрә байлары белән Шөннең Шакир һәм Сабир Хәзрәтовлар белән бергә салган югары мәчете, манаралы килеш калып, гасырдан гасырларга күчеп яшәде: бераз яңартылып, түбәләре калайга алыштырылып, егерме беренче гасырга да күчте...

...Мөхәммәтнең мәйдан уртасына чыгып бил алышуга артык хирыслыгы булмаса да, көче-куәте ташып торган кеше буларак, Шөн мәйданында көрәшкә чыкты ул. Аның белән тартышырлык кеше авылда Заһидулла гына иде, ләкин ул көрәшкән кеше түгел, «Заһи» кул сугышына оста, менә анда Гыйбадулла улы—ай-һай!

Мөхәммәтнең батыр калуын, чиккән сөлгеләр алуын иң горурланып күзәткән кеше Алсу иде. Анын очкын күзләренең тагы да очкынланып куюын күрсән! Егете көндәшен иплэп кенә салганда, үз-үзен белештермәстән кул чәбәкләп куюын күзәтсән! Ул әле «Көрәш» дигән рәсем ясаячак.

Алсу үзен Күкнең жиденче катында итеп сизә иде.

* * *

Жыеннар туктап, азмы-күпме узуга, аръяк болыннарга печәнгә төштеләр...

«Бу дөнья—уен-көлкеләр, бәйрәмнәр дөньясы» дисән дә, бу дөнья, иң беренче—эш-мәшәкатьләр, туктаусыз хезмәт дөньясы да ул! Бигрәк тә авыл жирендә...

Авыл—эш, эш һәм тагын эш ул. «Эш» дигәнең бәндәне тотучы ау ул.

Эш—мондагы халык өчен өлешенә тигән көмеше. Бу «көмеш»не алтынга да әйләндерә алмыйсың, ләкин аны бакыр итәргә дә ярамый! Ярамый—ач калуың бар...

Габдрахман Мөхәммәтне печән өстенә чакырды. Юк! Башкалар белән командалык иткән кебек тавышын бөердән генә чыгарып, акырып-бакырып тормады:

—Мөхәммәт, кордый! Көннәр яңгырсыз торганда печәнне кибәннәргә кертергә кирәк,—диде.—Синең көчен-куәтен белән... Пример...

Әйе! Әйе шул! «Синең көч-куәтен белән жинеп чыгарбыз» дип әйтә белде. Һәр ханнын үз саны, ди... Тынлады Мөхәммәт.

Ярдәмгә урманнан, аюлар янынынан Заһидулла да килде. Ул инде өен житкезеп бетергән, киләсе елга каралты-кураларны салып куям дип йөри иде.

Анламассың кеше холкын!

Заһидулла белән Габдрахман бер-берсенә һаман сырт белән торалар, ә менә печәнчеләр арасында Гыйбадулла малае үзен чын калхузник кебек тота, жир жимертеп эшли. Башкалар бер кибәнне әвәләп маташканда, алар

Мөхәммәт белән икене салып куялар. Габдрахман да мыек астыннан гына елмаеп китә яннарыннан.

Чукынып китсен!

Кумәк эш—түмгәк эш түгел...

Кумәк эш—чүлмәк эш! Гөл чүлмәге...

Авылдашлар белән печән чабу, чүмәлә тарттыру, кибән салу көз, кыш, яз буена тансыкка әйләнә икән. Рәхәт иде монда Заһидуллага. Кичкырын керәшен Мәкчим дә сугылып китә, алар якын-тирәдәге саега башлаган күлләргә чуртан тотарга баралар, аннан соң корымга каралган чиләктә ысландырып кына балык шулпасы пешерәләр. Заһидулла белән Чәпчим Мәкчим Мөхәммәткә сиздерми генә, агачлар арасына качып, берәр чәркә «чөгендер суы»н төшерәләр.

Мөхәммәт сизмәмешкә салыша, ә эченнән: «Мәкчиме Мәкчим инде, яшьтән үк сәүдәгәр Стаканов белән кучер булып йөреп, эчәргә өйрәнгән. Хәмердә пешкән кеше. Ә Заһи моны бит гражданнар сугышында гына каба башлаган. Бөтенләй тыелмас кеше дә түгел, кирәк чакта үзен кулга ала да белә. Нигә аңа бу челләдә шайтан суы?»—дип уйлый.

Керәшен Мәкчим—шәп кеше. Ул сөйләшергә бик тә ярата, ифрат түбәнчелекле, ярдәмчел, бәндәчел инсан. Аның нииндидер сөйкемле сөяге бар...

—Менә, Мөхәммәт энем, сезне сагынып килдем әле,—ди ул.—Чәпчим сагындым! Әндринең лапасын күргән саен син искә төшәсен. Шундый авыр бәбкә башына төшеп тә исән кал әле, ә?! Төшләремә керде ул бәбкә минем. Гел сискәнеп уяна идем. Сискәнми кара! Чәпчим сискәнерсең...

—Үз башына төшсә, тагы да ныграк сискәнер идең әле,—дип көлә Заһидулла.—Кеше башына төшкән, күрше ашына төшкән таракан гына ул...

—Әй, карендәшләр, яратам бит мин сезне!—дип тагы рәхәт елмая «чөгендер суы»ннан бераз кызып киткән Мәкчим. Ул бит куышлар янына килеп житкәнче, ике жиргә туктап, аны йотып алган иде инде.—Әйдәле, кәефен дә шәп, «әче миләш»не жиффәр!—ди ана Заһидулла.

—Һи, карендәшләр! Аның өчен бит... Ни...—дип кенә куя Мәкчим, хәйләкәр генә елмаеп.—Әнә куышларда йокларга ятканнар инде, ә без миләшләп торырга тиешме? Юк инде, эш кешесе ял итсен. Аның моңа тулы правасы бар. Чәпчим бар! Ә син, Заһидулла, мине озата бар, менә шунда... Онытма: без Советлар Союзыныкы гына түгел, шул Союз үзе үк безнеке! Мәсәлән, чәпчим минеке!

Мөхәммәт «менә шунда»ны да аңлый: хәзер болар яшерелеп куелган жирдәге шешә төбен ялаячаклар, аннан соң куышлардан ике йөз адымнар киткәч, Мәкчим үз жырын башлаячак:

*Коелардин су алганда*
*Төшеп калды чиләгем.*
*Дөнжа безгә ачы миләш,*
*Кемнәр каба жиләген?..*

Үзәк өзгеч көй бу. Сагыштан тегелгән моң...

Аны шулай итеп дөньясында бер Мәкчим генә жырлый аладыр...

Заһидулла белән Мәкчим юл чатындагы ике колачка сыймаслык юан карт тирәк янына туктыйлар. Аның юлдан күренми торган ягында бер кеше сыярлык куышы бар. Ауга, балыкка йөргәндә, әлеге черек куышка Мәкчим кайбер әйберләрен яшереп тота. Менә хәзер дә ул әлеге куышка, үз өенә чумган аюдай, кереп тә китте һәм шешәсе белән бергә ипи һәм дуңгыз салосын да тартып чыгарды. Мөхәммәт чучка маена жирәнебрәк караганга, Мәкчим салоны куышларга кадәр алып килми, шушында калдыра. Заһидулла ияләнде бугай инде, «чучка мае, фәлән-фәсмәтән» дип нәзберекләнеп тормый, «чөгендер суы»н йотуга, ялт итеп кабып та куя:

—Бу арада эшти дә эшти. Иртә эшти, кич тә эшти. Эш ашап эшләр пешми!—ди.

—Нәрсә ул эшти? Бер дә ашаган ризыгым түгел,—дип сорый Мәкчим.

—Борчак боткасы! Ашадым берчак, пешмәгән борчак...

Мәкчим тәгәри-тәгәри көлә, үзе Заһидуллага бармак яный:

—Җегерме беренче җылны онытма! Чәпчим онытма... Эчсәң—башына алма, ашказаныңда кайнат!

Ә пешеп житмәгән борчак Заһидуллага сабый килеш үлеп киткән сеңлесе булып күз алдына килә. Яшьли үлгәннәр—йөрәк ярасы алар...

Заһидулла Мәкчимне Биктауга таба озатып китә. Куышлар тирәсеннән шактый ерагайгач, алар парлап сузалар:

*Дөнҗа безгә ачы миләш,*
*Кемнәр каба җиләген?..*

... Ике кешелек куышларында берүзе генә булудан файдаланып, Мөхәммәт Алсуга дәшә:

—Йокламадыңмы әле? Безнең куышка кереп утыр. Синең белән сөйләшәсем килә...

Йоклыймы соң Алсу!

Ул көтә бит, көтә. Егетенең бер, юк, ярты гына сүз әйтүен көтә. Әнә Бибинур да, йоклаганга сабышып, аларны тыңлап ята. Белмимени Алсу, бик белә:

—Бибинурның да Мөхәммәткә «кашыгы төшкән...» Ләкин ул шактый ук мин-минлекле кыз, бу турыда беркемгә дә сиздермәскә тырыша, Мөхәммәткә таба сузылган мәхәббәт җебен яшерергә маташа. Әмма...

Күзләр бит алдый алмый!

Алар барысын да тавышсыз гына кычкырып торалар...

Мөхәммәт белән Алсу житәкләшеп болын буйлап йөриләр. Ак томаннар эчендә әкияти затлар кебек алар.

Төнге чык аяк киемнәрен юешли. Салкынча, тыныч, иплө, әллә нинди рәхәт, игелекле төн. Куаклар арасыннан кинәт кенә йокылы кошлар пырхылдап очып китә. Батыш күле өстеннән аксыл-көрән пар күтәрелә. Гүя Батыш бинаһая олы, галәмәт зур табак, аны пешеп чыккан кайнар бәрәңге белән тутырганнар. Менә утыра пар чыгарып...

Рәхәт иде бу күл янында...

Алсу белән рәттән басып тору Мөхәммәткә әллә нинди ул тоймаган хыялый хисләр тудыра, исәрләндерә бара кебек. Алсуга да рәхәт иде...

Рәхәт! Рәхәт!! Рәхәт!!!

Шушы минутлык рәхәт тойгысы өчен дә якты дөньяга килергә ярыйдыр. Рәхәткә мәхәббәт тә кушылса, бу инде ләз-зәт! Тойгыларның да тойгысы, хисләрнең дә хисе...

Мөхәммәт Алсуны каз мамыгыдай җиңел генә күтәреп ала, сакланып кына мангаеннан үбә. Кыз бөтен жаны-тәне белән аңа сыена, егетнең кыска итеп алдырган куе кара чәчләрен сыйпый.

Мөхәммәт сак вә йомшак адымнар белән аны куышларга таба алып китә. Төнгелеккә арбаларга бәйләп калдырган атларның берсе пошкырып куя. Куыш халкы күптән йоклый инде. Егет кызны аягына бастыра һәм:

—Тәмле матур төшләр күр!—дип шалашына озата.

—Рәхмәт!—ди кыз.—Сиңа да матур төшләр!—Ул үрелеп кенә аның яңагыннан үбеп ала һәм, житез тиендәй, куышы эченә сикерә.

... Табигатькә көз төсмерләрен иң беренче болындагы кибәннәр алып килә. Аннан соң басу-кырлардагы арыш, бодай, арпа, солы көлтәләре һәм шул көлтәләрдән ясалып-өелеп куелган сосланнар... Тагы да соңрак, бәрәңгесе алынып, каралып калган бакчалар, саргаюга йөз тоткан агач яфраклары...

Әбиләр чуагы иде...

Бакчалар өст ндә, читән-коймаларда пәрәвез җепселләре. Әле кыш турында хәбәр иткән бер генә нәрсә дә юк. Бары тирә-юнь, табигать кенә ниндидер сәер моң эчендә йөзә. Чишмәләр моңлырак челтериме шунда, елгалар сагышка манылып агамы... Күктәге кинәт күренгән кара-кучкыллы болытлар нидер хакында кисәтәме...

Күктә ни өннәр? Ни тавышсыз ораннар? Ни алхәбәр бу? Югалтулар табышымы әллә аерылулар сагышымы...

И, туган як!

Нинди гүзәл тирә-ягын!

Хак Тәгалә ялга чыгып, жирнең иң матур урыннарын күрим дисә, беркөн Нократ буена килеп чыгар иде. Шушыннан Галәмнең йөрәк тибешен тыңлар иде Ул.

... Мөхәммәтнең вакыт-вакыт, Хөснимәрдән агае кебек, танып-белүдә Хакыйкатьнең күпмедер өлешенә ирешәсе килә, Дөньяның бер читен генә ачып карарга омтыла-ашкына башлый.

Аны алда яңа тормыш, зур үзгәреш көтә. Быел көз алар Алсу белән кушылачаклар. Хәзерге вакытта аның өчен иң әһәмиятлесе әнә шул! «Иң мөфтиме», дияр иде ул үзенчә.

Хәер, алай дисәң, «иң мөфтиме» Хөснимәрдән сүзе ич!

1929-30 елларның уңышы начар булмады.

Шул көзге уңышта Мөхәммәт белән Алсуның туен уздырдылар. «Пир на весь мир» булмаса да, матур гына бәйрәм-мәҗлес булды ул. Әлбәттә, «Кызыл шахтер» колхозы крәстияннары гармунга «Шахтер көен» тарттылар:

*Шахтур җегет кумер чаба*
*Вак-вак итеп кисәген.*
*Гомерем булып, таш басмаса,*
*Ташламам, җанкисәгем.*

Мөхәммәт кунакларга сиздерми генә Алсуның беленнән кочып алды һәм яратып күзләренә карады, үзе шундук, корт чаккандай, сискәнеп китте:

—Кызның күзләренә әллә нинди сүз белән әйтеп бетермәслек тирән сагыш тулган иде.

Нәрсә бу? Ни-нәрсәне аңлата бу моңлы һәм әллә нинди эчкә яшерелгән караш?

Төнлә алар зөфаф кичен уза алмадылар:

—Бүген мина кагылма...—диде Алсу сак кына. Егет тыңлады, кыз аның куенында, мәче баласыдай йомшак кына сыенып, мес-мес кенә килеп йоклады. Атна буе кыз аны тоткарлап килде.

—Нәрсә соң бу?!—диде тәмам гаҗизләнгән Мөхәммәт.

—Мин бу дөнья кешесе түгел бугай... Ул эштән куркам мин...—диде чарасызлыктан Алсу.—Бәлки мина хәмер эчеп карарга кирәктер?

—Авызынны йом! Гөнаһ бит бу! Сафлыктан, яшьлектән көлү...—дип бүлде аны Мөхәммәт.

... Алар Заһидуллаларда соң өлгерә торган көзге алмаларны җыялар иде. Алсу көлә, чырык-чырык килә, Мөхәммәткә ымсынып-ымсындырып карый, карт алмагачның ботагы буйлап өскә таба үрмәли. Менә инде чери башлаган юан гына ботак сынып китә, Алсу аркасы, баш чүмече белән жиргә егыла һәм тынсыз кала. Күтәреп карасалар, башы—кара кан, ә алмагач төбендә үлем-мендәр булып очлы таш ята...

* * *

Бу дөнья уен-көлкеләр генә дөньясы гына түгел шул, ул—үлем-җитемнәр, чир-авырулар да дөньясы... Шуңа карамастан, хәтта кабер дә ике йөрәк арасында сузылган мәхәббәт җебен өзә алмый. Чын ярату һәрвакытта да бер генә буладыр, мөгаен. Хәер, алай дисән, Ярата Белү—Талант ич ул һәм бу талант һәркемгә дә бирелми. Дөрес, бик күпләрдә көтү булып яшәү теләге-хисе бар. Әмма ул кешеләрнең бер-берсен яратудан туманган, ә борынгы заманнардан килгән саклану-оешу инстинкты. Пар-пар булып яшәү дә—инстинкт. Ә Ярату? Бу—Илаһилык...

Мөхәммәт Алсуның каберен зиярәт итәргә һич бара алмады. Югыйсә югары тегермәннән ерак идемени зират?! Шөн елгасын басмадан чыгасың да яр өстенә күтәреләсең, тагын ике йөз адымнар үргә таба атласаң, мазарстанга юлыгасың. Әмма...

Күрәсе килми Мөхәммәтнең аның каберен, юк!—Күрәсе килми. Шул балчык өеме астында кызның гүзәл йөзе, сылу гәүдәсе ятуга ул һич тә ышана алмый. Иргә чыгып та саф килеш китеп барган кыз иде ич ул.

Зөфаф кичәнен дә ни икәнен белми мәңгегә югалды Алсу.

Ул үлгәч, егет сулыкты, ябыкты, йөзенә сары ингәндәй булды. Ашаган ашы тамагына каладды, эчкән чәеннән агу тәме килә кебек тоелды. Мөхәммәт бервакытта да үзен хис кешесе итеп санамаган иде. Менә сиңа, мә! Йә, кешенең күңел төбенә төшеп кем караган, ди?! Ә ул төптә ниләр генә юк...

Алар бит Алсу белән хушлаша да алмадылар: карт алмагачның черек ботагы шартлап сынды, үлем бозлы кулын кызга салды.

Ни үкенеч! Әллә ул үзенең бу дөнья кешесе түгеллеген чыннан да сизенеп яшәгәнме? Шуңа бу фани дөньядан бакыйга гөнаһсыз сабыйдай, керсез нарасыйдай китәргә теләгәнме? Нәрсә бирә соң бу аңа? Аңлаешлы нәрсә түгел, һич башка сыймый...

Мөхәммәт күп уйланды, шуңа карамастан сүзсезләнгәннән сүзсезләнә барды. Бары төннәрен генә үзалдына сөйләнеп ята торган булды:

—Ник күпсенден аны бу дөньяда, Раббым? Алам дисәң, аның өчен мин җанымны бирергә дә әзер идем ич...

Әмма...

Кеше өчен кеше яшәргә мөмкин, ә бәндә өчен бәндә үлә алмый. Үлем—һәркемнең үзенеке генә...

Инде чын ир-ат булган Мөхәммәт үз тормышындагы барлык кыеклы-мыеклы якларны исенә төшерде:

—Кем каргышы аның баш очында? Акча эшлим дип, Хөснимәрдән агайга ияреп, әнисен ташлап, Азак диңгезенә китеп баруы дөрес түгел идеме? Әнисе рәнҗедеме аңа? Ана рәнҗеше беркөн тормышыңда кара язмышка әйләнәчәк олуг бер үпкәләү, чамасыз ризасызлык, дөньяга сине китергән изге затның әрнү-газаплары, авыр кичерешләре ич...

—Әллә үз гомерендә бары бер генә мәртәбә, әтисенең әнисен рәнҗеткән күреп, ата кешегә җикеренүеме? Соңгы вакытларда хәмергә ияләнсә дә, әтисе начар кеше түгел иде аның. Йомшак, яхшы күңелле, ипле кеше иде ул. Ә хәмер? Монысы—йомшак холкыннан. Бигрәк тә тормыш авырлыгыннан, ниндидер түбәнлеккә төшерә торган чарасызлыктан. Һәркемнең ике җилкәсендә ике фәрештә утырса, колак һәм баш артларында өч шайтан утырыр, ди. Шул шайтаннар гел яманга котырта икән. Шайтан коткысы—гөнаһ боткасы...

«Без яшәгән саен яманлык чокырына төшә барабыз. Шулвакыт бу чокырга тагын да түбәнрәк төшмәскә ант бирәбез. Күпмедер вакыт уза һәм карыйбыз: тагы шул чоңгылга төшеп барабыз икән бит! Түбән төшү җинел икән. Бары яхшылык-матурлык Тавына күтәрелү генә авыр...»

Шулай дигән иде Хөснимәрдән агай...

«Иң мөфтиме», Мөхәммәт тә Алсу белән шул тауга күтәрелергә теләде. Рәссам-кыз матурлыкны күрмимени инде ул?! Мөхәммәтнең барлык омтылышы яхшылыкка таба иде! Эшлә яхшылык—көт явызлык,—диләрме әле?

Алсуны ул өзелеп сөйгән иде...

Ә шулай да...

Аны туйганчы назлый-иркәли дә алмады. Кыз әллә нинди тоткарлыкка керде, атна буе тән кушылуын тыеп килде. Нигә кирәк булган аңа бу тоткарлану? Фәрештәләр аның колагына:

—Син бу дөнья кешесе түгел...—дип пышылдаганнармы әллә?

Сүндереп җиргә ташлаган бер бөртек шырпыга тормас кешеләр бар җирдә. Похмелкин кебекләр... Нигә дип бу дөньяга килә икән мондыйлар? Алар белән ничек яшәмәк кирәк ди, ә?! Иң гаҗәбе: алар да бит кеше исемен йөртә, моны ничек аңларга?

Борынгы грек философы Диоген юкка гына:

—Кеше эзлим!—димәгәндер. Бу турыда ана, бер сөйләшеп утырганда, Ильяс-Хәлфә Хәзрәтов әйткән иде.

Заһидулланың да тормышы буталып бетте әнә, бары Әхмәдулла гына бирешми...

...Алсуның еллыгын уздыргач, Мөхәммәт өченче тапкыр бәхетен сынарга булды, ул өйләнергә карар кылды. Әлбәттә, күзенне йомып теләсә кайсы хатын-кызга өйләнү түгел иде бу. «Өйләнү—түгел сөйләнү»,—дигән

Тукай да. Кайда гына яшәмә, ир-атка хатын-кыз кирәк! Ул өйгә нур, чисталык, пөхтәлек кертә, чиста кием-салым, тәмле аш-су булдыра. Мөхәммәтнең өйләнергә карар кылуында тагы бер төп сәбәп бар иде: менә Алсу үлгәннән бирле инде аның тирәсендә Бибинур бөтерелә. Чишмәдән суын да алып кайтып бирә, идәннәрен юып, өен дә җыештырып чыгып китә. Хәтта песигә сөт, эткә сөяк-мөяк тә алып килгәли...

—Яраттымы ул Бибинурны?

—Юк!

—Шулай булгач, ник анарга өйләнергә карар кылды?

—Яшәргә кирәк иде, яшәргә... Ялгызлык—үтерә торган нәрсәләрдән... Бибинур үзенә күрә генә түгел иде...

Андагы ул кирелек, тәкәбберлек! Ике-өч кешегә җитәрлек иде аның бу кире сыйфатлары. Шул ук вакытта Мөхәммәт аңа кул селтәп тә карый алмады. Ул күзләренең гел тартып торулары! Моңа адәм баласы түгел, җеннең үзе дә, шайтан да түзә алмас...

Бибинур—үзе үк җен кызы иде бит! Башкорт хатыныннан туса да. Әнисе Җомабикә дә җомыкый түгел иде.

Кыз Мөхәммәтне изалады, тилмертте, шашыну дәрәҗәсенә җиткерде, ә иң соңгы мизгелдә «алмасы»н каптырмый гына чыгып тайды. Егет тә аны «бушка» әүмәкләүдән туйды, шуңа турыдан-туры:

—Әйдә өйләнешәбез!—диде.

—Алсу белән өйләнешкән кебек, бер атнагамы?—дип, йөрәгенә кагылды, иң изге хисенә тиде Бибинур.

—Алсуга тимә!

—Аны гына яраттың инде...

—Яраттым—мәңге онытмам!

—Мине яратмыйсың бит син, ә үзең өйләнәм дисең.

—Яратмыйча да өйләнергә мөмкинлеген мин аңладым инде. Яши торгач, ир-хатын бер-берсенә ияләшә бит. Иң мөфтиме, ике арада суыклык кына тумасын. Ә болай, ошатам мин сине, бик ошатам.

Бибинур егетнең «яратмыйча» дигән сүзенә үпкәләп китеп барды.

... Кыш җитте...

Җир өстендә ак куяндай ап-ак кар ята...

Декабрь ае әле бу, кыш башы. Көннәр үтергеч кыска, төннәр өч торып, өч ятып йокларлык озын.

Кыш үзенең аклыгы белән күңел тынычлыгы да алып килә. Көз сугыласы көлтәләр сугылган, киптереләсе ашлык киптерелгән, алынасы бәрәңге алынган. Тагын нишләргә? Хәзер, колхозчы булгач, Урал шахталарына күмер чабарга китеп булмый. Ят үз өендә өеңдәге аю кебек. Иртә белән кар көрисе, терлекләргә печән бирәсе барын бар да... Болар барысы да ярты сәгатьлек эш.

«Кызыл шахтер» колхозы бу кышта атлар сарае салу өчен Бояр урманыннан агач кисәргә булды. Башта Габдрахман «лесник Әндри» янына барып кырт-мырт сөйләшеп карады:—Калхуз өчен... Партия линиясен тормышка ашырып...

Әмма вә ләкин... Үзе әйтмешли:

—«Упшый язык» таба алмады...

Лесник: «Лес—народное добро»,—дип кенә җавап бирде. Мөхәммәт белән Әхмәдулла Әндригә лапас эшләгән кешеләр, бер җаен табарлар әле дип, Габдрахман аларны Биктауга, урман каравылчысына юллады.

Әндри шактый гына картая төшкән, әмма күзләрендә һаман шаян очкыннар, сүзләрендә—яшәү дәрте.

—Сальца или баранину?—дип шаяртты ул икесен дә кочаклап һәм өстәлгә таба этәреп. Матур гына сөйләшеп утырдылар, агач мәсьәләсе дә унай хәл ителде. Әндри «урман патшасы» булып эшләгән соңгы ун ел эчендә нык кына котайган иде: яна мунча һәм йорт салдырган, өй эчендә аерым өстәлдә патефон тора, ишек алдында—велосипед. Абзарда ат пошкыра, сарайда сыер мөгри...

Кайтканда Заһидулланың Нократ аръягындагы йортына сугылдылар.

Гыйбадулла улы әле яңа гына авылдан килгән икән. Мөхәммәтне коточкыч хәбәр көтә иде:

—Бибинур агуланган...

—Ничек?

—Уксус эчеп,—диде Заһидулла аның күзләренә карап.

Беравык сүзсез тордылар...

—Син аңа кагылмаган идеңме?—дип сорады Заһидулла.

—Уксускамы?—дип сорый алды Мөхәммәт. Аның башы каткан иде, гүя баш мие урынына шыплап пычкы чүбе тутырганнар.

—Бибинурны... «Кызны бозмаган идеңме?» дип сорыйм мин синнән. Көзлектә синең янда күп болганды ул...

—Бибинур түгел, Алсуны да...

—Нәрсә Алсу?—Заһидулла шикләнә-аптырый калды.

—Үлгән Алсудан көнләшә ул,—дип әйтә алды Мөхәммәт.

Әхмәдулла аңа гына хас сабырлык белән сүзгә кушылмады, итагатьәдәп саклый белде.

—Соң, үлгән артыннан үлеп булмый инде...

... Өрпәк кар...

Атын Шөнгә өшәнгәнче куды Мөхәммәт...

Нократ өстенә килеп керүгә, күңелен моң-сагыш басты. Дөньяда сагыш зоналары бар, моң кырлары бар. Җыр да шунда туа. Тумый икән, искә төшә. Онытыла башлаган сүзләре-көе белән. Мөхәммәт тә:

*Дөнья безгә ачы миләш,*
*Кемнәр каба җиләген?*

—дип, чүт кенә жырлап җибәрмәде. Үз гомерендә кычкырып җырлап йөргәне булмаса да. Ул бит эчтән генә моңланып йөри...

Шөнгә кайткач, әнисенең ай-ваена да карамастан, Бибинурны әле авыру килеш үзенә алып китте. Кызның әтисе эштә иде.

Кич Аяз мулладан никах укыттылар һәм Мөхәммәт белән Бибинур бергә яши башлады.

Урак вакытында тупырдап торган уллары туды. «Шәп вакытта, шәрәфле айда, урак өстендә туды, Шәрәфетдин кушабыз»,—диде Аяз хәзрәт. Каршы килмәделәр. Бала Мөхәммәт белән Бибинурны иң якынайткан нәрсә булды. Бу яктан алар икесе дә улларына бик рәхмәтле иде. Ул тугач, каралтыкурада, абзар-сарайда мал-туар, кош-корт күзгә күренеп артты.

... Шәрәфетдин кечкенәдән каз ите ярата иде. Каз шулпасы пешкән көнне ул канат яисә тәпи эләктерә дә шуны ялый-ялый урамга йөгереп чыга һәм янына җыелган малайларга:

—Менә бүген ашка әнәй ярты каз салганые,—ди.—Туйганчы ашадык, Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле...—Шул сүзләрдән соң янында бөтерелгән, утырып койрыгын селкеп торган этенә сөяк ата.

Малайлар төкрекләрен ялый һәм көнләшеп:

—Нишләрсең? Каз ите ашаганнарның эте дә каз сөяге кимерә шул...—диләр.

Ә аларны ирештерергә Шәрәфетдингә бир инде. Бәйләнә калсаң, ул төп кебек нык, үгез кебек таза, житмәсә, кирәкмәгән озын буйлы. Ашауга да таза: иреннәрен чуп-чуп китереп, майлырак ризык булса, уң кулының биш бармагын ялый-ялый, мыш-мыш килеп, рәхәтләнеп, тәм табып ашый. Эшкә дә хәтәр булып чыкты ул. Бер тотынса, тәүлек буе эшләр, һич арымас.

Унжиде яшендә үк өйләнде Шәрәфетдин. Яссы-җәйпәк табанлы булуы сәбәпле, аны армиягә алмадылар. Шәрәфетдин моңа шаккатмады: ул бит солдат булырга түгел, ә сукачы булырга туган. Житмәсә—балта остасы. Өйләнгәндә дә сузгалап тормады: Гайнулларның үзеннән өч-дүрт яшькә олырак, таза гәүдәле кызларын алды да кайтты. Гайнуллар ел саен кырыкилле баш каз асрый иде. Кызларыннан бигрәк, шул казларга өйләнде бугай Шәрәфетдин.

* * *

Бер башлангач, гомер ага да ага икән ул...

Гомер агышын туктатыр бер генә көч-кодрәт тә юк бу дөньяда. Гомер, сыналып килеп, бер мәңгегә сынар өчен бирелә.

Җәйне көзнең сары яфраклары каплый, көзне кышның ак карлары, кышны язгы сулар-ташулар... Адәм баласы менә шулай дүрт фасыл эчендә бәргәләнә. Аның өчен Бишенче Фасыл юк. Бу фасыл бәлки мәңгелек булыр иде. Бишенче Фасыл—Үлем...

Еллар узган саен, җан яралары төзәлә төшсә дә, Мөхәммәт Алсуны онытa алмады. Ул аның хыялый мәхәббәте, яхшылык-матурлык Тавына менүдә мәңгегә аерылган юлдашы булып калды. Төшләренә еш керә иде Алсу, ләкин нарасый-сабый кыяфәтендә. Бары тавышы гына үзенеке иде һәм көлеп җибәрүләре аныкы. Гөнаһсыз сабый... Үзе үк нииндидер изгелек.

Бибинур гомер буе Мөхәммәттән көнләшеп яшәде. Ул инде күптән гүргә кергән Алсуны искә төшереп кенә көнләшеп калмады, ә авылның һәр хатын-кызын үзенең көндәше итеп карады. Бу—аның чире иде, бавырын—үт куыгын зәгыйфьләндерүгә, йөзен саргайтуга алып барган яман гадәте булды. Көнләшү—холык авыруы бит ул.

Тормыш ялгыш өстендәге ялгышлардан тора икән. Иллегә житеп, балалары башлы-күзле булган кешеләр, гадәттә, борылып үткәннәренә карый. Ә анда—үкенечләр, үкенечләр, үкенечләр... Яшьлектә үк хата-ялгышлыклар күп киткән.

Нигә, япь-яшь кенә килеш, ике ирдән унмаган Ольгага өйләнде Мөхәммәт? Беренче ире үз милләтеннән, үз ыруыннан булса, үч алу өчен хәйләләп, Похмелкинның «ястыгы», хайвани омтылышлар чүпрәге булу нигә кирәк булган ул хатынга?

Әй, Хәснимәрдән агай! Син бит авыл фәйләсуфы, дәрвиш, бер тапкыр да өйләнмәгән кеше иден. Нигә өйләндердең син мине Ольгага? Менә хәзер, илленең аръягына чыккач кына, Мөхәммәт сине аңлады:

—Син бит, төсе-кыяфәте, фәлсәфи акылы булган кеше Ольгага үзең гашыйк идең. Ольганың сиңа карамаячагын белдең дә, бу гүзәл хет үзебезнең егеткә булсын, дип, мине аңа өйләндердең...

Ә син, Мәхмүдбәк абый!

Корыч куллы, батыр йөрәкле Кырым татары. Татарларның аерылып калган бер өлешенең асыл вәкиле. Син нигә мине Ольгага өйләндерергә тырыштың? Сине сөеп, кыядан елгадагы ташларга ташланган Алияң исеңә төштеме? Ольганың минем өчен бәргәләнүләрен, атлыгып йөрүләрен күреп:

—Кушылсыннар болар!—дидеңме.

Ә минем йөрәккә карадыңмы соң син?! Күрдеңме анда мәхәббәт-ярату чаткысын?

Тормыш—төзәлмәслек ялгышлар...

Әнә беркемгә дә баш имәгән, үземчә яшим дигән Заһидулланың тормышы буталып бетте.

Габдрахман үз башын үзе ашады. Ә бит беркатлы булса да, начар кеше түгел иде ул. Мөхәммәт Заһидуллага да әйтте:

—Аңла син Габдрахманны. Ул бит революцияне байларны талау, юкка чыгару дип аңлады. Ул бит Совет властен үзенә дә власть бирүче дип аңлады. Иң мөфтиме, ул—яман кеше түгел!

Габдрахманның үзенә дә акыл өйрәтте:

—Син Заһидулла кебекләрдән курыкма, син Габдулла кебек кәрләләрдән курык! Менә күрерсең, ул синең башыңны ашаячак әле...

Тыңламады Габдрахман, власть тотучыларга һәрвакыт ялагай, куштаннар ошый ич!

Ә Алсу? Их, Алсу, Алсу...

Синең гомер яфрагыңны кем һәм ни өчен өзде соң? Нишләп мин сине саклый алмадым? Нишләп? Бу дөньядагы бердәнбер мәхәббәтемне! Миңа багышланган рәсемеңне гамәлгә ашырмыйча китеп бардың син. «Көрәш» дип атарга теләдең син аны. Әнә болгар карчыгы Серафима

әбидән мина ике алтын йөзек калды. Мин аларны истәлек итеп сакладым. Азак дингезе истәлеге итеп. «Үләр көннәрем килеп житкәч кая куярмын?»—дидем. Белмим әле, белмим. Белмәгәнне белмим дияргә кирәк! Бу—ихласлык. Кешеләргә күп вакытта житми торган нәрсә. Без бит белмәгәнне дә беләбез дибез, белгәнне белмим дип кире кагабыз. Шундыйрак инде ул кеше холкы.

Мөхәммәт йорты алдындагы эскәмиядә үз уйларына батып утыра иде. Шулвакыт кәнсәләрдә кизү торучы кыз йөгереп килде:

—Мөхәммәт абый, сине калхуз рәисе чакыра!

—Габдрахман малаемы?—диде ул. Ә үзе эченнән генә уйлап куйды: «Үз янына чакыртып «задание» бирмәсә, Габдрахман малае рәис булып та утырмас иде. Хәзер төш житеп килә. Әбәдкә кайтканда сүзен әйтеп китсә, теленә тилчә чыкмас иде әле. Юк, ул Мөхәммәт кебекләргә «задание» биреп, башкаларның күнеленә буйсыну чүпрәсе сала ич. Их, Габдрахман яшьти! Авылдан шәһәргә качкан бу малаең, сугыштан соң авылга кайтып, синен урынга баш булды бит».

—Һәр эшне бисмилладан башларга кирәк!—дигән иде Хөснимәрдән агай. Онытты бит бу сүзне Мөхәммәт, онытты. Ин беренче, ул Ольгага бисмилласыз өйләнде. Аннан сон...

Өзелеп яраткан Алсуы белән зөфаф кичендә бисмилла әйттеме ул? Эченнән генә булса да... Юк! Анын бит бу кызны тизрәк үзенеке итәсе килде, шул уй белән янды. Кабаланды, Ольга белән булган ирле-хатынлы уйнаулардан соң үзен бик тәжрибәле итеп санап, Алсуны бер алуда сындырырга теләп, ифрат ялгышты. Ә Алсу артыгы белән тыйнак һәм саф иде, ул анын мондый дуамаллыгыннан курка калды. Телгә шома булса да, жаны белән инсафлы кыз иде бит ул.

Шаклар катарсын! Куркуыннан йомгак булып бөтерелерсен! Монда синен жорлыгын «жукка-чур»га чыга да чыга инде...

... Мөхәммәт алма вә карлыган бакчасы аша турылап кына идарәгә китте. Алмалар сары иде әле, ә карлыганнар «кара күзләре» белән аңа карап торалар. Кагылмады Мөхәммәт аларга, бары идарәгә житәрәк кенә кызыл карлыганнан берничә бөртек өзеп авызына капты.

Керә-керешкә үк:

—Габдрахман малае Мөхәммәт абыйсына тагын ни задание бирергә жыена?—дип сорады. Тегесенен ачуы йөзенә үк чыкты:

—Мин—«Габдрахман малае» түгел!—диде.

—Бәрәч, Габдрахманныкы булмый, кемнеке буласын сон син?

—Әйе, мин—Габдрахман улы, ләкин минем үз исемем бар...—диде рәис төксе генә.

—Беләм исеменне.

—Белгәч, исемем белән ата!

—Сине бит авыл халкы «Усал Баттал»дип йөртә. Мин дә «усал» дигән кушаматынны кушып әйтимме?

—Ихтыярын—бәрәңге!—диде Баттал, аңа сөзеп карап.—Тик мине «Габдрахман малае» дип, бала-чагага тинләп атавынны ташла!

Мөхәммәт белән Баттал арасыннан кара мәче узган иде. Рәис яшь чагында Бибинурга гыйшык тотып, тик кыз гына аңа борылып та карамады. Баттал колхоз рәисе кәнәфиенә утыргач, уракчы хатын-кызларны юл буенда сагалап торып, башак яисә уылган орлык алып кайтмыйлар микән дип, тикшерә иде. Хатыннарнын тәнен капшый-капшый тикшерүнен ин мыскыллысы Бибинурга эләкте. Берсендә күлмәген күтәреп, ыштан балакларына кадәр тикшергән, таза-калын ботларын сыпырыштырып алгач, түзмәде Бибинур, Мөхәммәткә бу турыда елый-елый сөйләде.

—Әгәр минем хатыннын ыштан бөрмәләрендә тагын бер казынсан, кулынны сындырам!—диде ир рәискә.—Шуны онытма, Габдрахман малае!

Менә шул көннән китте инде Батталга «Габдрахман малае» дип кенә дәшү. Дөрес, Мөхәммәтнен үзенен дә ана исеме белән дәшәсе килә, әмма рәиснен аны кыерсытырга маташуы, үч алырга чамалап йөрүе, үзенен дошманы итеп күрүе ничектер ана үз исеме белән дәшүне тыеп килә иде.

—Йә, рәис, әйдә ачуланышмыйк!—диде Мөхәммәт килешүгә барып.—

Булган—онытылган. Үч саклау көчне югалта. Миңа ни «задание»ң бар?

—Шпагинның уха ашыйсы килгән...

—Шпагинның?

—Әйе!

—Шуннан?

—Шуннан... Минем Пальманы жик тә Пуләнкәгә барып Шпагинны алып кайт! Сез аның белән танышлар бит?

—Танышлар да, дуслар да... сугыш вакытында мин бит заводта автомат цехында эшләдем. Аның «ППШ»асын ясадык. Шпагин безнең авылга да кайткалап йөрде. Сабантуйларны ярата иде ул. Тагын каз бәлешен...

—Синең Шәрәфетдинең Шпагин өчен махсус каз бәлеше пешергән, диләр. Шул дөресме?

—Дөрес! Шәрәфетдин үзе дә каз дигәндә...

—Беләм. Аны юкка гына Каз Шәрәфетдин дип атамыйлардыр инде.

Сөйләшү унай агымга керде. Баттал. «Каз Шәрәфетдин» дип чеметеп алса да. Мөхәммәт моңа артык әһәмият бирмәде:

—Каз икән каз! Таз Шәрәфетдин түгел ич...

Пальма янгын сараендагы бишенче ат иде. Кызыл бия. Бик шәп чабышкы. Аннан туган Актай белән Каратай да бик йөгерек атлар. Пальманы Мөхәммәт татарчалаштырыбрак:

—Пәлмән!—диде. Аны улы Шәрәфетдин бик ярата. Пәлмән өчен Пуләнкәгә барып кайту уен гына: чыга да югала һәм бер-ике сәгатьтән соң кире кайтып та керә. Шул ук янгын сараенда колхоз рәисенең җәйге тимерхут арбасы белән кышкы кошевка-чанасы да тора. Гадәттә, Баттал үзе ат җигеп мәшәкатьләнми, кирәк вакытта Мөхәммәтнең ике ярдәмчесеннән берсе бу эшне башкара. Рәис үзе эскәмиягә утыра да тәмәке төтәтеп, җигүле атны көтә.

—Минем хатын авырып тора... Бибинурны әйтүем. Үзем бара алмам инде. Баттал энем, Шәрәфетдинне генә җибәрермен.

Бибинур исеме чыгуга, рәис каршы килә алмады, бары:

—Үзең барсаң, солидно буласы иде дә...—дип кенә куйды.

—Ә Шәрәфетдин миннән кай ягы белән ким? Ул да солидный егет!—диде Мөхәммәт ана.

—Яшь бит әле ул. Бала-чага сыманрак.

—Булыр яшь! Ул егерме бердә инде. Өч бала атасы: ике кызы, бер улы бар.

«Өч бала атасы» Батталның бөеренә тиде. Ул бит, Бибинурга үч итеп, фронттан маржа алып кайтты. Әлеге күзенә үк мутлык чыккан, тотанагы булмаган маржа-медсестра башта батальон командирының сөяркәсе иде, аннан корсак төшергәч, капитан аны үз яныннан куды һәм кызый «отчаянный татарин» Батталга елышты. Батталны батальонда чыннан да «отчаянный татарин» дип атадылар. Аларның балалары булмады, Баттал моңа бик кимсенде. Төшереп алган көннәрендә хатыны Зинаны җәберсетте, аек чагында:

—«Бу зина бәрәненнән нинди бала булсын! Моның күлендә парахут та баткандыр, целый батальон үткән моның өстеннән!»,—дип уйланды.

Шәрәфетдин Пальманы тиз жикте, әбәдкә кайтып китмәгән Баттал янына керде:

—Районда башка йомышларыгыз юк идеме?—дип сорады.

Җавап кыска иде:

—Юк!

—Ярый мин киттем. Пальма белән очам гына!

—Тормышлар ничек?—дип сорады рәис Бибинур малаеннан. Бу чәнечкеле, төртмә сорау иде.

—Аллага шөкер! Ит ашыйбыз әле,—диде тук чырайлы, таза гәүдәле, озын буйлы яшь ир көр тавыш белән. Бу аның дежур җавабы иде. «Тормышлар барамы?»—дип сорауычыларга Шәрәфетдиннең бер генә җавабы әзер иде:

—Аллага шөкер! Ит ашыйбыз әле...

Өченче бүлек

## Алмазар

Георгий Семенович Шпагин атаклы корал ясау остасы иде. Әле Бөек Ватан сугышына кадәр үк алар конструктор Дегтяров белән ДШК дип аталган эре калиберлы пулемет ясыйлар. Бу хәл 1938 елда ук була. 1941 елны Шпагин пистолет-пулемет уйлап таба. Шпагинның «ППШ» дип аталган пистолет-пулеметы совет солдатларының яраткан коралына әйләнә, конструкторга шул ук 1941 елны Сталин премиясе бирелә, ә 1945 елны ул Социалистик Хезмәт Герое исемен ала. 1946-50 елларда аны СССР Югары Советына депутат итеп сайлыйлар. Менә шул елларда ул Шөн авылына килеп йөри башлый, балыкчы Мәгъсүм белән дуслаша.

Вятские Поляныда, Шөн татарлары әйткәнчә, «Пуләнкә»дә Шпагин яшәгән йорт бүген дә тора әле, ул күптән инде музейга әйләндерелгән. Өй Нократның текә ярында утыра, монда шактый тыныч, яр буйлап елга агымы унаена китсән, әрәмәлекләр һәм урман башлана, конструктор бу урыннарга гөмбәгә йөргәләгән...

Даны зур булса да, Георгий Семенович бик тә ипле, кешелекле, тыйнак, хәтта түбәнчелекле кеше иде.

Шәрәфетдин килеп керүгә, ул аңа бер генә җөмлә ипләде:

—А, Шараф! Сын моего друга Мухамета. Увези меня в Шуни. Устал я, хочу поотдохнуть...

Пальма Шпагинны Шөнгә кош канатында алып килгәндәй генә итте. Пуләнкә тавын күтәрелүгә, кызыл бия туган як һавасын сиземе, Шәрәфетдиннен дилбегә кагуын да көтмәстән Шөнгә жилдерде. Колак төбендә жил... Дүрт-биш чакрым узуга, авыллар... Мәтби, Чәкәш, Сасмак...

Татар авылы Сасмакка кергәч, Шәрәфетдин Пальманы туктатты да урамдагы сиртмәле коедан су алып эчте.

—Нихәлләр?—дип сорады таныш-белешләре.

—Аллага шөкер! Ит ашыйбыз әле...

Шәрәфетдиннең күнел көрлегенә, көләчлегенә разый кешеләр аның жилкәсеннән кактылар:

—Маладич тә инде үзең! Һич бирешергә исәбең юк.

—Шушы яшьтәме?!

—Ничә әле сина?

—Егерме бер тула инде.

—Балаларың?

—Өчәү! Ике кыз бер-бер артлы туды. Малай ике ел көттереп.

—Егет икәнсең! Быел көрәшергә исәбең бармы?

—Көрәшкә мәйданга кем дә чыга ала. Минем исәп—батыр калырга!

—Калачаксың да! Бу гәүдән беләнме? Сукага жигәргә була бит сине...

—Өметсез шайтан гына, ди. Ә без, Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле!

—Ярый-ярый. Уңышлар сина, Шәрәфетдин!

Шәрәфетдинне кайда да яраталар иде, ул зур гәүдәсе белән дә теләсә кайсы ярыкка сыйды. Күнел көрлеге, көләч йөз—менә нәрсә тарта иде кешеләрне Шәрәфетдингә. Аның белән аралашу—үзе бер гомер. Бераз беркатлырак булса да, ул чын ир-ат иде. Ирләр янында да, хатын-кызлар янында да үз абруен һич төшермәде. «Мин—Мөхәммәт улы! Мин—татар малае!» Бу сүзләр аңа зур горурлык китерә һәм ул үзенең буш кеше түгеллеген аңлап яши бирде. Гомумән, яшәүне ул гомерлек бәйрәм дип аңлады һәм атады.

—Безгә керәбезме?—диде ул Шпагинга, Шөнгә кайтып житкәч.

—Сезгә дә керермен әле. Ә хәзер әйдә турыдан-туры Максимга!

—Балыкчы Мәгъсүм абыйгамы?

—Да!

Шәрәфетдин Пальманы түбән очка куды. Мәгъсүм белән Георгий яшьтәшләр иде, икесе дә 1897 елгылар. Мәгъсүмнең йорты авыл очында,

моннан өч йөз адымнар Бәләкин утравына таба киттенме—Нократ җәйрәп ята. Ә анарчы болыннар, дистәләгән күлләр. Иң зуры—Таллар авылы ягындагы Олыкүл. Комаяк, Торф, Сергей күлләре дә кечкенәдән түгел. Түгәрәк күл шактый тирән. Күлләрдә балык мыжлап тора. Бигрәк тә Камышлы күлдә. Комаяк та тирән вә чип-чиста сулы күл. Җәен бала-чага монда көне буе су коена егетләр ат йөздерәләр, кызлар-киленнәр кер чайкый. Күлләргә, Нократ куеннарына Мәгъсүм мурда сала. Мурда—чыбыктан үреп эшләнгән яисә нык-калын җептән үрелгән балык тоту коралы. Аның авызы киң генә булып, ул артка таба тарая бара. Балык кердә торган тишеге 10-15 сантиметрдан артык киң булмый. Гадәттә мурдага чуртан, алабуга, бәртәс, сыла балыклары керә. Башкалары да эләккәли.

... Балыкчы Мәгъсүм аларны капка төбендә көтеп тора иде. Колхоз рәисе Баттал аңа Шпагинның кайтасын алдан ук хәбәр иткән, күрәсең.

—Исәнме, Георгий!—дип, Мәгъсүм аңа көрәк кулларын сузды.

—Саумы, Максим,—диде Георгий. Ул инде Шөнгә кайткалап йөргәндә кайбер татар сүзләрен өйрәнеп-отып та алган иде.

—Сина кунак килдем,—диде Шпагин аңа елмаеп. Георгий Семенович—бөек конструктор, корал ясау остасы, даны илгә һәм дөньяга таралган мәшһүр инсан булуына карамастан, үзен кешеләр белән бик гади тота, уен-көлке яратучан, мактауларга бик хәйран калмый, егылып китми торган адәми зат иде. Чын ир-ат! Татарларга мөнәсәбәте дә ихтирамлы иде аның. Ул районда эшләүче Банат белән райком инструкторы Майтап Гайнетдинованы да яхшы белә иде.

1950 елның апрель аенда Георгий Семенович Шпагинны ВКП(б)ның Киров өлкә конференциясенә делегат итеп сайладылар. Ул поездда «татарлар купесы»на туры килде: әнә Майтап Гайнетдинова утыра, янында яшь кенә татар егете. Үзе озын буйлы, таза малай.

—О, Георгий Семенович!—диде аны күрүгә Майтап.

—Без бер купега эләккәнбез икән. Моны билгеләп үтәргә кирәк! Ну, мои татары,—дип елмайды Шпагин.

Майтап тиз-тиз генә табын әзерләде. Теге таза егет сумкасыннан бер бөтен пешкән каз алды һәм аны, кискәләп-тураклап өстәлгә салды. Ашау ризыклары янына бер акбаш кунаклады. Монысы Шпагин кучтәнәче булды. Ул шома стаканнарга хәмер койды. Аннан утырган җиреннән торды:

—За тебя, Майтап!—диде.

Эчтеләр, капкалап алдылар...

Күпмедер вакыт узгач, Георгий Семенович таза егеткә елмаеп карады да:

—Давай знакомиться! Как тебя звать?—диде.

—На войне звали Гришей,—дип куйды егет.

Шпагин тагын елмайды:

—Син мина татарча исемеңне әйт.

—Залялов Гаяз!

—Вот и прекрасно! Очень красивое имя. А ну-ка, выпьем за здоровье Гаяза!

Икенчесен тотканнан соң егет тә батыраеп китте:

—1942 елда мин Төньяк Кавказда автоматчы идем. Сезнең «ППШ» мина бик нык булышты,—диде.

Шулвакыт Шпагинның әллә ничек кенә күңеле нечкәреп китте, күз төпләренә яшь бәреп чыкты. Кинәт ул урыныннан күтәрелде, Гаязны барып кочаклады, урыс гадәте буенча ике янагыннан үпте. Егет тә чүт елап җибәрмәде. Майтап аптырабрак кына кульяулыгын чыгарды. Георгий Семенович Шпагин да бик нык дулкынланган иде.

—Мин Шөндә үз кеше, Гаяз. Сина кунакка килэм әле. Сабантуйга!—диде ул егеткә.

—Килегез! Көтәрбез!

Шулчак Георгий Семеновичның йөзе яктырып китте, ул, күзләрен уйнатып, егеткә яратып карады да:

—Мне очень нравится ваше национальное блюдо бялиш!—диде.

—Бәлеш икән бәлеш! Пешерү—безнең эш, ашау—сезнең эш,—диде тәмам батыраеп киткән Гаяз.

Киров шәһәрендә Гаязның зур фоторәсемен Мактау Тактасында күреп, бераз тукталып торды Шпагин. Аннан озак кына егетнең кулын кысты:

—Игенче—иң бөек хезмәт иясе ул! Синең эшең жир шарында иң кирәк һәм данлы-мактаулы эш ул,—диде.

... Шөндә Шпагин үз авылындагы кебек иркен йөри, кешеләр белән һәрчак үзе башлап исәнләшә, хәлләрен белешә иде.

—Балык бар, Максим?—диде ул Мәгъсүмгә.

—Не идет рыба... Ветер...—дип, Георгийга зарланды Мәгъсүм, тегенең «татарча»сына үзенең «урысча»сы белән.—Но ты, Георги Семеныч, не волнуйся, найдюм. Много найдюм рыба! Патерпи немнужка...

Мәгъсүмнең балык табасына ышанган Шпагин саф һава сулап киләм әле дип, бакча артларына китте. Мәгъсүм балык тоту коралларын караштырып калды. Хатыны аш-су әзерләп йөри иде.

Чирек сәгать вакыт үтмәгәндер, Шпагин йөгереп диярлек кайтып килде:

—Карале, Максим,—диде ул.—Сезнең бакча артындагы Камышлы күлдә кыргый үрдәкләр! Ху-у-у! Егерме-утызлап булыр. Берәрсен атып алыйм әле,—һәм ул мылтыгын алып кире йөгерде. Камышлы күл буенда ату тавышлары яңгырады. Күпмедер вакыттан соң, үрдәк күтәреп, атаклы конструктор үзе дә күренде. Авызын колагына кадәр ерган.

—Ну что ж!—диде ул.—Если не будет ухи из рыбки, сварим-ка ее из утки.—Шпагин үз-үзеннән бик канәгать иде.

Үрдәкләрне чистартырга лапас астына кереп киткән Мәгъсүмнең хатыны аны үз янына чакырды:

—Кил әле, карт! Кара менә, нинди кыргый үрдәкләр булсын болар. Чүрәкәй бит ул күгәрченнән аз гына зуррак, болар каз кадәр.

Үрдәкләрне күргән Мәгъсүм дә аптырабрак калды. Әйе шул! Болар кыр үрдәгеннән бигрәк...

—Әнекәем!—диде хатыны.

—Ни булды?

—Безнең үрдәкләр ич болар. Менә бит аякларында тамгасы да бар. Үзем тамгалап куйган идем. Күршеләрнеке белән кушылсалар, аерып алырга дип...

—Кычкырма, карчык! Мин дә сукыр түгел, безнең үрдәкләр икәнен күреп торам.

—Шуннан?

—Йолкы, эчләрен ал да икесен дә Казанга сал! Шпагин—бик затлы кунак. Синең улларың ул ясаган «ППШ» белән фашистларны кырдылар. Кунакка безнең үрдәкләр икәнен сиздермә. Кара аны! Шпагин да тамгалы кеше, даны дөньяга таралган.

* * *

Күнеләндә ни үкенечләр булса да, кеше яше арта барган саен тыныч тормышка омтылып яши башлый. Дөрес, олыгая башлаган, картаюга бер адым атлаганнар үткәннәрдәге булган хәлләрне кабартырга яраталар. Теге яки бу вакыйгаларны хәтерләгәндә, Шөн халкы аны Шпагин Георгий Семенович исеме белән дә бәйләп әйтүчән булды.

—Шпагинны Югары Советка депутат итеп сайлаган елны мине «Кызыл шахтер» колхозы председателе итеп утырттылар. Башта районга беренче янына чакырттылар. Аристип Иванович Николайди миңа әйтте: «Колхозларның хәле мөшкел: жигәр атлары калмады, сыерлар күтәрәмдә, чәчәргә орлыклары юк... Ачтан халык урлаша, яшьләр авылларны ташлап шәһәргә, Урал шахталарына качарга маташа. Колхозларга каты куллы председательләр кирәк! Сине «Кызыл шахтер»га куярга теләк бар. Алынасыңмы шул эшкә?

—Алынам!

—Кара аны, син-фронтовик, батыр солдат! Сугыштан лейтенант булып кайттың. Бирешмә, махы бирмә!

Үзенең рәислеккә утыруын шулай сөйли иде Баттал Габдрахманов.

—Шпагин сайланган елны мин бер олау балык тоттым—дип искә ала балыкчы Мәгъсүм.—Әллә инде Олы күлнең бар балыгы кергән мурдаларга. Әле бит сит[1] тә салган идем...

—Шпагинны сайлаучылар белән очрашуга мин алып кайттым,—ди Мөхәммәт.—И Пальманың кызулыгына шаклар катты инде ул. «Не лошадь, а машина!—ди.—Ради бога не гони его,—ди. А то опрокинешь меня, Мухаммет»,—ди. Әй күңелле дә кайттык соң!

—Шпагинны сайлаган елны кылупта бик тә әйбәт сату оештырганнар иде. Шикәре-чәе, конфеты-прәннеге дисеңме? Печенҗә-клиндерләр дә булды, тозлы балык белән колбаса да алып килгәннәр иде. Акчаң гына булсын! Калхузда таякка эшләп, каян килсен инде акча?—дип тә сөйләнделәр соңыннан Шөн кешеләре.

—Шпагин абыйны сайлаганда, миңа уналты гына яшь иде әле,—дип искә алгалады Шәрәфетдин дә.—Уналтыда гына булсам да, мин инде буй житкән егет идем. Шул елны сабантуйда беренче тапкыр көрәшкә кердем, ә кичке уенлыкта Шәрифәне үптем. Бу үбүем дә беренче тапкыр иде...

Шулай инде...

Шулай корылган!

Кеше бер үк вакытта бүгенге һәм шулай ук үткәннәр вә киләчәк белән дә бергә яши. Бу ниндидер кодрәти, серле, тылсымлы, сихри Канун икән?..

Гомер узган саен, бигрәк тә балалар үсеп житеп, башлы-күзле булгач, кеше күңеле тынычлыкка, ипле тормышка тартыла. Ул салмаклана, һәр сүзен үлчәп әйтә, һәр эшен уйлап эшли. Юк, бу әле сәлперәю-сүлпәнләнү түгел, ә бары тигез тормышка кереергә тырышу гына, ә бит...

Әйе!

Ә бит вакытлар узган саен тормыштагы вакыйгалар да куера бара.

Син инде шау-шулы, матавыклы, кычкырышлы хәл-мәлләргә, тавышлы гамәлләргә катнашырга да ашкынып тормыйсың, яшьләрнең кызып китүенә, әтәчләнүенә мыек астыннан гына көлеп карыйсың. Ә барыбер—юк!

Икенче караганда, син үзең дә вакыйгалар уртасында икәнсең бит! Шаулыйсың, бәхәсләшәсең, үз фикереңне башкаларга да сеңдерергә тырышасың, дөреслегенә инандырырга маташасың.

Илле яшен узгач, Мөхәммәт тә тыныч тормыш бусагасына баскан кебек булган иде...

Пальманы янгын сараенда тугарып кайткан улы Шәрәфетдин ана дәште:

—Әти, сине Мәгъсүм агай да, Шпагин абый да бүген кичкә кунакка чакырдылар.

—Соң, улым... Әниең чирләп тора ич. Йортында берәү авырып ятканда, кунакка бару дөрес нәрсә булыр микән? Иң мөфтиме, әниең рәнжер бит миңа...

—Рәнжемәс, әти! Без өйдә бит... Мин дә, килене Шәрифә дә аның янында ич... Балалар да: «Әби, әби»,—дип, өзелеп кенә торалар. Әнә бит иң кечкенәсе дә әбисе янына үрмәләргә маташа.

—Ярый инде... Төшеп менәрмен соң... Иң мөфтиме, Георгий Семеновичны үпкәләтмәскә кирәк. Үзе бик кешелекле, бәндәчел ич!

—Әти белеп тор: кунакта бүген Герой Фәйзи һәм аның белән Мәскәүдән кайткан, сугыш узган яшь подполковник та булачак икән. Өс-башыңның рәтлесен ки! Сакал-мыегыңны төзәт. Урамга көзгегә карап чык. Тормышыбыз, Аллага шөкер! Ит ашыйбыз бит әле...

Мөхәммәт улына бик тә яратып карады:

—Әле егерменең аръягына гына чыкса да, бераз беркатлырак булса да, акыллы ич Шәрәфетдин! Тәртип-тәрбияне дә белә. Балалары да, заказ белән эшләнгәндәй, бер-бер артлы гына тудылар. Ел саен диярлек бер

---

[1]Сит—русча сеть сүзеннән, балык тоту коралы.

сабый! Әле беренчесе имидән аерыла алмый, икенчесе әнисенең имиенә ябыша. Хәер, килендә сөт күп, булыр-булмас арык сыерың бер якта торсын! Өч бәбәен берьюлы имезсә дә, сөте бетә торган түгел...

... Мөхәммәт киенеп-ясанып урамга чыкты һәм Мәгъсүмнәр йортына атлады. Өйдә хуҗаның хатыны гына иде, ул:

—Ирләр бакча ягында, шунда чыгып тор, Мөхәммәт, мин хәзер... Ашны өлгерттем инде, балык шулпасын гына пешереп бетерәсем бар. Мәгъсүм: «Кара аны! Балыгың изелеп бетмәсен!»—дип, кисәтеп чыгып китте. Утыны каен бит, хәтәр яна!

—Черегрәк усак өстә, аның ялкыны йомшаграк,—диде Мөхәммәт.

Бакча ягына чыгуга, аны Георгий Семенович Шпагин кочаклап алды:

—А, мой друг Мухаммет!—Бу сүзләр башкаларның да Мөхәммәткә булган карашын бер карышка югары күтәрде. Мәҗлескә җыелучылар шактый иде. Иң беренче, ана Шөннән китеп, Гәрәмәчи шахталарында эшләп, шунда төпләнеп калган Хәсән Хөснетдинов сүз катты. Мәгъсүмнең яшьтәше һәм дусты. Ул:

—Дөресме, Мөхәммәт? Сине Азак дингезе буенда балык сөзеп йөргәндә, ун потлы якорь күтәргән, диләр.

—Мин ул якорьны ике мәртәбә күтәрдем. Тик ул ун потлы түгел иде, ә тугыз потлы. Бер пот артык булса, мин аны бәлки күтәрә дә алмаган булыр идем,—диде Мөхәммәт.

—Ничә яшьтә идең син ул вакытта?

—Унҗиде тулып, унсигез белән бара идем...

—Мин дә күтәрдем тугыз потлы якорны,—ди Хәсән.—Тик ул вакытта мин 24 яшьтә идем инде.—Дөрес әйтә: Мәгъсүм белән Хәсән яшьтәшләр һәм иптәшләр. Әнә шуңа да балыкчы аны да кунакка чакырган. Алар икесе Мөхәммәткә кадәр авылның иң куәтле егетләре булганнар... Ә Хәсәнгә килгәндә, ул туксан кешедән бер үзе тугыз потлы якорь күтәргән. Бәхәскә кереп... шулай итеп тугыз потлы якорь күтәрүчеләр Шөндә икәү булып чыкты.

—Син безнең Шөн батыры!—дип аның кулын кысты Җәләлетдин угылы Гаяз Җәләлов.

Мөхәммәт белә: бу таза куәтле егетнең аны сабантуйда көрәштә бик егасы килгән иде. Батыр исеменә лаек булу һәр көрәшче өчен изге вә рәхәтле омтылыш ул, әмма мондый егетләр Мөхәммәт тарафыннан мәйданда гел арка сөякләренә сылана килделәр. Тирә-юньдә, чыннан да, аны күтәреп салырдай кеше Гаяз гына иде. Каяндыр бик таза киндер чикмәнле ар килеп чыкты-чыгуын. Мәйданда ул бар көрәшчеләрне кырды гына, тик Мөхәммәткә каршы тора алмады. Торып кара!

Герой Фәйзи дә аңа үз итеп кулын сузды. Ул, Советлар Союзы Герое булса да, үзе тәбәнәгрәк буйлы булгангамы, әллә бу ир-атның чамасыз куәтле ир икәнен белгәнгәме, Мөхәммәт алдында күпмедер дәрәҗәдә югалып кала иде. Көч властьтамы яисә беләктәме, ана кешеләр һәрвакыт хөрмәт илә карый... Алмагач төбендә утырган колхоз рәисе Баттал Габдрахманов та аңа үз итеп кул бирде, йөзенә төче елмаю чыгарды. Башкалар хөрмәт иткәндә, бар, күрмәмешкә салынып утырып кара син! Әле бит монда колхоз председательләре җыелышы түгел, ә бөек ату коралы ясаучы Георгий Шпагин утыра, аларның авылдашы Шөн егете Фәйзрахман Сабиров та Мәскәүдән кайткан. Ул Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исемен алган кеше, сугышта ук батальон командиры, капитан дәрәҗәсендәге офицер булган. Хәзер ул, әнә, майор погоннары таккан, янында бер подполковник хәрби дә утыра. Анысы ни урыс, ни хохол, ни поляк шунда. Исеме Адам бугай, фамилиясе Азадович кебек. Белорус яисә югослав-сербмы соң ул? Белмәссең! Буталды бу соңгы елларда милләтләр!! Аты-ат түгел, чаты чат... Яһүд токымыннан берәү Иван Иванович Иванов булып йөри, паспортына карасаң, милләте: «урыс» дип язылган.

Өйгә ашка кергәнче әлеге подполковник шыпырт кына Мөхәммәт янына килеп басты:

—Сезгә минем сүзем бар иде,—диде. Шактый гына акцент белән сөйләшсә дә, подполковник татарча шактый шәп сукалый иде.

—Сез кайдан? Татарча ничек шулай әйбәт сөйләшәсез?—дип сорады үз чиратында Мөхәммәт тә, сорау биреп. Үзе ул дертләп китте, күнеле айкалды: бу сөйләшүнең юктан түгеллеген бөтен жаны белән сизә иде. Шул ук вакыт йөрәге тулы сораулар, шик-шөбһәләр... Аның әллә кай төшләре авыртып киткәндәй булды.

—Мин тугыз яшькә кадәрле Казанда бер татар карчыгында тәрбияләндем,—диде подполковник.

—Сезне кем дип белик? Исем-атыгыз?—дип сорады Мөхәммәт. Аның бу хәрби кеше белән бәйле серне тизрәк чишәсе килә иде. Хәйран яисә коточкыч хәбәр булса булсын, дөреслек кенә өскә калкысын!

—Мин Адам Геннадьевич Азадович булам...

—Туган ай-елыгыз?—диде Мөхәммәт, кабаланып һәм шактый ук әсәренеп.

—1918 елның 22 июне...

—Әтиегез кем?

—Генка Хмелев дигән кеше бугай...

—Әниегезнең исемен хәтерлисезме?

—Ольга... Милләте белән полячка... Хәтта поляк татарларыннан бугай әле ул...

—Син—минем улым! Син Адәм Мөхәммәт улы Болгареев буласың,—диде Мөхәммәт ана турыдан-туры.

* * *

Шулвакыт хужабикә кунакларны өйгә чакырды:

—Прашу дамуй!

Мөхәммәт белән яшь подполковник нишләргә дә белмәделәр. Сүз иң хәтәр жирендә өзелде бит. Подполковник берьюлы ике ут эчендә калды: Кем ул? Кем?!—Адам Геннадьевич Азадовичмы? Әллә... Менә бу аның алдында торган пәһлеван ир әйткәнчә: ... Адәм Мөхәммәт улы Болгареевмы? Подполковник буй-гәүдә, йөз төсмерләре белән дә үзенең Мөхәммәткә нык кына охшаганын күрмәде түгел, күрде. Ул бер-бер артлы папирос суырганда, Мөхәммәтне нык кына күзәтте. Нindидер эчке хис, сизенүтоем—менә шушы жиденче сизгер хис көче аңа ул күзәткән кешенең аңа якынлыгын, хәтта бик тә якынлыгын сөйли иде кебек. Әле Герой Фәйзи Сабировка ияреп кайтканда ук ана каяндыр иңгән алхәбәр бу авылда сәер ачышлар, сискәндерерлек яңалыклар буласын пышылдап өлгерде ич! Менә беренче ачыш вә хәтәр яңалык:

—Ул Адам Геннадиевич Азадович түгел икән, ә Адәм Мөхәммәт улы Болгареев исемен-атын йөртәсе икән бит! Болай булса, паспортыңны алыштырырга да туры килмәгәе әле...

Шуна карамастан, ачыклыйсы-барлыйсы урыннар да күп. Бу мәһабәт ир белән аның әнисе кайда һәм кайчан очрашканнар? Бәлки, алар арасында нindидер мәхәббәт тә булгандыр?

Подполковник иң беренче шушы сорауларга жавап табарга тиеш иде. Казанда аны тәрбияләп торган татар карчыгы аңа әнисенең Ольга исемле полячка булуы, аның Генка Хмелев дигән бер бәндә белән Нократ буендагы бер авылга китеп баруы турында сөйләгән иде. Ә аңарчы... Ольганың бик тә озын буйлы, көчле-куәтле, матур-таза яшь бер татар егете белән флигельдә яшәп ятуын да яшермәде. Әби сүзләренә караганда, малай шушы яшь егетнең улы булырга тиеш. Адамны тәрбиягә дә ул татар кешесе улы булганы өчен генә алган икән. Хет бисмилланы белеп үссен, дип...

Сонынннан мәскәүле Азадовичлар Адамны ничектер Казанда эзләп табалар һәм Русия башкаласына алып китәләр. Ольганы үзләрендә Генка Похмелкин белән 1917 елны ук күргәнлектән, аңа Геннадьевич дигән ата исемен бирәләр. Ә менә фамилияне үзләренекен куялар:

—Азадович!

Адам хәрби училищеда укый, аннан офицер булып чыга, Ватан сугышында катнаша, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнә.

...Кунаклар соң гына таралдылар...

Ике үрдәк салып пешергән токмачлы аш, балык шулпасы аларга иркенләп утырырга мөмкинлек бирде. Хәмер дигәне дә чиләге белән иде дигәндәй...

Мөхәммәттән башка һәрберсе диярлек кыза төште.

—Ничек син, Мухаммет, ничек син аракыдан тыела аласың?—дип сорады Шпагин.

—Мин аны гомеремә авызыма алмадым!

—Ә бу зәһәр сыеклыкка нәфрәтең кайдан?

—Минем әтием тегермәнче иде. Минем яшьләрдә эчеп үлде ул. Аракыга нәфрәт шуннан... Теләк-нәфсем дә юк ана...

—Фронтта булып, сугыш газапларын күрсәң, тотар идең дә син аны!—дип чеметте Баттал.

Мөхәммәт аның күзенә батырып карады:

—Мин сугышның башында ук алындым,—диде.—Тик ул вакытта безнекеләрне немецлар көненә алтмыш-житмеш чакрым куа килделәр. Кайда безнекеләр, кайда немецлар? Шуларны белергә дә вакыт булмады. Ул вакытта фронт дигән нәрсә дә юк иде әле... Сугышның башында утка кергәннәр дә батыр йөрәкле солдатлар иде. Аларның күбесе кырылып бетте, шактые авыр яралар алды. Ул вакытта беребез дә орден-медальләр турында уйламадык...—Ул Батталның ике-өч сугышчан орден тагылган түшенә карап алды:—Әнә шуңа башларын сугыш башында ук салганнарга тиешле орден-медальләр жинүче булып кайтканнарга күбрәк тагылды...

Авыр тынлык урнашты...

Һәркайсына әллә ничек унайсыз вә жайсыз иде. Берәү дә ни «ык», ни «мык» димәде...

Ә шулай да...

Шулаен шулайдыр да...

Әнә, Мөхәммәт үзе дә сугыштан исән кайтты ич! Яраланып Сосновка госпиталендә ятты да Вятские Поляны заводының ату коралы ясау цехында эшли башлады. Бу эшкә аны сугышта бер кулын терсәктән өздереп кайткан майор Николаиди кодалады:

—Сине сугышта бу гәүдәң белән беренче атакада ук атып үтерәчәкләр,—диде ул ярым шаярып.—Үзең бер фашистны чәнчелдердең, ди. Ә менә син заводка эшкә күчсәң, йөзәрләгән гитлерчыларны юк итәрлек корал эшләрсең. Монысы ил өчен зуррак файда булыр.

Тынлады Мөхәммәт грек Николаидины, алар бит Азак дингезендә бер әртилдә эшләделәр. Аристин Ивановичның ул вакытта жандармнардан качып йөреше булган. Соныннан ул—революция солдаты, гражданнар сугышында—кызылләрмис, кызыл командир.

1942 елның февралендә Мөхәммәтне хәрби госпитальдән чыгардылар һәм ул турыдан-туры районның хәрби комиссары майор Николаиди янына китте. Юк, ул комиссарга ялагайланып тормады, бары бу хәлендә үзенең фронт өчен саулыгы житәр-житмәс икәнен аңлады. Аннан соң майор китергән дәлилләр дә саллы иде бит:

—Фронтта син бер фашистны чәнчелдерерсен, ә заводта син ясашкан «ППШ»лардан йөзәрне кырырлар!

Майор Николаиди ана заводтагы хәлне дә аңлатты:

—Онытма! Эш авыр анда. Икешәр смена куганда аягүрә йоклаучылар да бар. Ашау житмәүдән, кан азлыктан станок янында егылучылар да юк түгел. Ә ничәмә эшче кысылып-бәрелеп имгәнде, гомерлек инвалид калды.

Урам буйлап югары очка таба атлаганда, ин ахырдан баручы Мөхәммәтне Адам көтеп алды:

—Сезгә, әгәр армаган булсагыз, бер-ике сорау бирергә мөмкинме?

—Рәхит ит...—Ул: «Рәхим ит, улым!»—димәкче иде. Әмма тыелып калды. Нидер тотты. Адам үзе дә ана «әти» димәде бит.

—Сезнең әни белән мөнәсәбәтләрегез ниндирәк иде?—дип сорады подполковник.

—Без аның белән Азак дингезе буенда очраштык. Шунда 1917 елның

сентябрь башында өйләнештек. Ләкин без Ольга белән ике ай гына ирхатын булып яшәдек.

—Шуннан? Мин сезнең улыгыз буламмы?

—Әйе!

—Ә Геннадий Хмелев?

—Геннадий Хмелев түгел ул, ә Генка Похмелкин...

—Әни белән аларның мөнәсәбәтләре ничек иде сон?—дип сабырсызланыбрак сорады Адам.

—Бик катлаулы иде,—диде Мөхәммәт акрын гына.

—Нишләп?

—Синең әниең Генка Похмелкинны үтерергә йөрде...

—Ник?—диде аптырап подполковник.

—Ул...—Мөхәммәт әллә ничек кыенсынып калды.

—Әйтегез! Ни авыр сүз булса да, мин түзәрмен... Миңа дөреслек кирәк!

—Ин мөфтиме—дөреслек...—дип куйды Мөхәммәт.—Генка Похмелкин синең бабаңны, Ольганың әтисе Адам Азадович Василевскийны үтергән...

Алар беравык сүзсез генә атладылар. Бер кавым сүзсез тору үз уйларына чумып, кайбер фикерләргә килү өчен кирәк иде.—Ә мин отчество итеп аның исемен йөртәм?! Вот зараза!—диде кинәт пошаманга төшкән, ачуы йөзенә чыккан подполковник.—Димәк, мин бабам исемен йөртәм.

—Бабаң исемен...

—Отчеством Мухамметович булырга тиешме?

—Минем улым булгач, шулайрак инде,—дип елмайды Мөхәммәт, аңа сак кына карап.

—Фамилиям?

—Әниең ягыннан синең фамилияң—Василевский.

—Әтием ягыннан?

—Анысын да әйттем инде: Болгареев! Үзең сайла...

Алар тагын тын гына атладылар...

Еракта, карасу-зәңгәр урманнар артында таң беленә башлаган иде инде. Кайбер әтәчләр саташып кычкырып та куялар. Шулай да дөньяда үле тынлык әле...

—Соңгы соравым,—диде подполковник.—Сез минем әнигә яратып өйләндегезме? Мәхәббәт булдымы сезнең арада?

—Дөресен әйтимме?

—Да, дөресен!

—Мин ул вакытта яшь егет идем әле. Мәхәббәтнең ни икәнен дә белмәдем. Хатын-кызны ярату соң гына килде миңа...

—Аңладым!—диде подполковник хәрбиләрчә кыска гына итеп.—Әти!—диде ул Мөхәммәткә.—Мин паспортны алыштырачакмын. Чын әти исеме белән чын фамилиямне куйдырачакмын. Киләсе елга хатыным белән кайтырга рөхсәтме? Татарчага да яхшылап өйрәнермен.

—Әтисе янына улы кайтмыйммыни инде!

Әмма... КГБда эшләүче Адам билгесез сәбәпләр аркасында үлеп киткән. Паспортын алыштырырга да рөхсәт бирмәгәннәр аңа. Шулай итеп, гомерендә бер тапкыр күргән беренче улын ата мәңгегә югалтты.

* * *

Һәрбер кабер зират жире өстенә яна жөй, күнелгә тирән жәрәхәт алып килә. Бер жәрәхәт юылып-төзәлеп бетми, икенчесе чират көтә.

Бибинур үлем хәстәрен күрә башлады: кәфенлеген барлады, мәетне өйдән алып чыгып, укыласы аять-сүрә укылып, кузгалып китәр алдыннан хатын-кызларга өләшәсе яулык, кульяулыкларын санап куйды. Уе тыныч, хәрәкәтләре сабыр иде аның. Соңгы вакытларда шинебрәк калган гәүдәсен дә шактый жинел йөртә, ашау үтмәү чире калын-таза кул-беләкләрен, ботбалтырларын, мендәр-мендәр күкрәкләрен шактый ашаган иде инде. Көннәрнен берсендә ул ашказаны авыртуга чыдый алмый уянып китте һәм тан атканчыга кадәр үлем турында уйланып ятты:

—Шушы гәүдәмне кара туфракка, кызыл балчыкка күмеп куйсыннар әле ә? Хәйран нәрсә бу. Һич башка сыя торган хәл түгел! Ә бит... Әйе, ә бит үлем—чарасызлык ул. Ул килмәсенгә бер чара да юк. Капка төбеңә килеп басса, әҗәлне иң усал эт белән дә куып җибәреп булмый...

Мөхәмметкә өлкән улы Адам күңел җәрәхәте калдырып киткән иде, менә хәзер Бибинур өчен чамасыз борчыла башлады ул:

—Чагыштырмача яшь бит әле. Кырыкны узганына кайчан гына?! Җир җимертеп эшләгән, эшләгән кебек ашаган Бибинурның шулай тиз хастага калуына, үзе күрмәсә, ышанмас та иде. Әллә яшьлек юләрлеге белән серкә эчүе ашказанына зур зыян салганмы соң? Эчүе дә—үләм дип иде бит...

Бибинурның үләсен кырык көн алдан сизенде Мөхәммәт. Бер төндә хатыны саташып:

—Йә, Алла! Китәсе дә бар бит... Әзерләнергә кирәк,—диде.

Иртәгесен ир хатынына сиздерми генә аның йөзенә күз төшерде. Тулы, янып торган кызгылт битләр саргая төшкән. Ә күзләре... Аларда битарафлык, чарасызлык, ахырың белән килешү... Һәм—эчкертен моң-сагыш, хәсрәт билгеләре, боегып калу, өметсез караш...

...Бибинурны гүргә индергән елны Мәскәүгә китеп барган Георгий Семенович Шпагин да вафат булды. Ул да карт түгел иде әле, илле биш яшьләрдә генә...

«Халыклар атасы» Иосиф Сталин исә 1953 елның март башында миллионлаган «балалары»н ташлап китте, фанидан бакыйга күчте. Монысын ил иң зур кайгы итеп кабул итте:

—Бөек юлбашчыдан башка ничек яшәрбез дә нишләрбез? Кем кая алып барыр безне?

Әмма вә ләкин...

Патша тәхете буш торамы? Юк! Аңа менеп, артын салып утырырга теләүчеләр бихисап. Тик ул тәхет башкаларга бәхет китерәме соң?

...Шул ук елларны сугышта билгесез югалган Фәрхетдин Зәйнәгытдинов турындагы хак сүзләр дә Шөнгә кайтып ирешге: Волхов сазлыкларында чолганышта калган әлеге политрук, дошманга әсир төшмәс өчен, пистолеттан үзен-үзе атып үтергән. Туры Фәрхи һич икеләнеп тормаган, үз чигәсенә туп-туры терәп аткан...

«Дөньяда яшәүче кешеләр саны кадәр үлем бар,—ди иде Хөснимәрдән агай.—Һәр кешенең үлүе бер үлемне үтерү дә әле ул. Үлеп тә кеше Үлемне җиңеп китә...»

Шәп сүзләр! Хәтәр сүзләр!

Әмма, әмма вә әмма...

Беркем дә үлемне җиңәм дип үлми бит. Үлем—чарасызлык ул. Айга менеп тә аннан котылып булмый! Әҗәл—котылгысыз бер көн, соңгы бер мизгел. Тик тормыш иткәндә беркем дә үләр өчен яшим дип тормый. Яшим әле, ди.

—Яши алганча яшик! Үлем безнең эш түгел. Килер, беренче тапкыр һәм соңгы кат аның белән күрешербез,—дигән иде бервакыт ошбу дөньяның михнәт-газапларын да, рәхәт-ләззәтләрен дә шактый татыган Заһидулла. Ул туры, инсафлы, дөреслекне ярата торган кеше, әйтсә—хагын әйтер. Ялагайлану, куштанлыкның ни икәнен дә белмәде...

...Бибинурның үлеменнән соң Мөхәммәт хатын-кыздан нык кына читләште. Ә болай ул иллене узган үз җегәрендәге ир-ат иде әле. Әмма аның башына бер вәсвәсәле уй-фикер кереп утырды:

—Хатын-кыз минем белән бәхетле була алмый. Мин бәлки шәп ирдер дә... Ә бәхет түшәктә генә ятмый шул! Хәер, мин үзем дә хатын-кыз белән тулысынча бәхетле була алмадым. Бәхет китердеме миңа Ольга белән тору? Юк! Иң яраткан кешем Алсудан да минем җанымда тирән кичерешләр, авыр үкенечләр, әрнү-газаплар, мәңгелек күңел җәрәхәте генә калды ич. Ләкин мин яраттым! Иң мөфтиме, сөю—гыйшыклык, мәхәббәт ич! Әгәр минем йөрәгемә Алсуны яраткан кадәр нәфрәт өелсә, күптән атом бомбасы булып шартлар идем инде. Бу шартлаудан башкалар башына кара ташлар коелыр иде бит. Ә болай...

Ак күнел, пакь күнел белән яшик әле. Соңгылыкта Соңгы Нокта көтә сине. Ә хәзергә—өтерләр, өтерләр, өтерләр...

Иң мөфтиме, әнә бит оныклар үсеп килә. Аларның балигъ булганын, үз тормышларын корып җибәрүләрен дә күрергә кирәк! Бу дөньяга шуның өчен дә киләбез түгелме?..

Жәл, бик жәл... Олы улы Адам үлгәннән соң, аның хатыны алар белән араны шундук өзде. Адамның балалары булдымы икән? Юктыр... Алар турында бер сүз дә әйтмәде ич. Нилектән үлгән? Герой Фәйзи авылга тагын кунакка кайткач:

—Радиациядән,—диде.

Мөхәммәт авыр башын аска иде...

...Кеше кайгы-хәсрәтләргә, моң-сагышка гына уралып яши алмый. Елның һәр фасылы аның күңеленә әллә нинди үзгәрешләр, җан ачышлары, сәер омтылышлар, кичектергесез теләкләр алып килә. Бигрәк тә яз! Яз айлары вакыт-вакыт мәхәббәттә акылдан язу айлары булып, шаулап-гөрләп бәреп керә. Март әле ул кыш белән булышып, шарт-шорт килә. Ә апрель... Апрель—чын мәгънәсендә яз кызы инде ул! Март—ир-ат. Апрель—хатын-кыз.

Мөхәммәт сабырланырга маташкан иде, зур теләкләрсез генә яшәргә уй корган иде. Бигрәк тә җомга көннәрендә тынычланырга уйлады ул:

—Җомга... Күзләреңне йом да намаз укы... «Мин гөнаһлы!»—дип, башыңа туки... Күңелеңдә галәмнең үзе кадәр бушлык. Догалар белән тутыр аны...

Менә беренче язгы яңгыр...

Апрель ахыры яңгыры...

Әллә нишләтте ул Мөхәммәтне. Кинәт бәрде, ямьле-тәмле, рәхәтле-ләззәтле, хәтта аңгыратырдай яңгыр. Мондый көчле яңгыр—искән җил, аккан болыт кына, агачларда ямь-яшел яфраклардан шыбырдашып коелган елтыр су тамчылары гына. Әмма бер гомер ул. Безнең кыска гына гомеребезнең тылсымлы бер мизгеле. Бу мизгел сине җан йокысыннан уята, рухыңа меңәрләгән шәмнәр элә...

Төштән соң кояш чыкты. Тыкырыктан өелеп су төште. Яңгыр кайдадыр катып калган кар-бозларны да җебетеп-изрәтеп ташлады.

Мөхәммәтнең йөрәге бәргәләнә иде:

—Матурлана дөнья, чибәрләнә. Һай!

Беренче язгы янгыр җанынның йозакланган урыннарын ачарга ачкычлар алып килсен әле. Борылыш ачкычлары! Нәрсә бу, нәрсә?! Яшәүгә чакырумы?! Табигать-хәяткә кушылып китәргә өндәүме?

Борылышлар, борылышлар...

Нократ та әнә борылып-борылып ага. Аның һәр борылган урынында яңа манзара ачыла. Гомер дә шулай борылып-бормаланып ага түгелме? Һәр борылма артында—яңа вакыйгалар, көтелмәгән хәлләр, бер күрмәгән кешеләр белән танышу яисә дистә еллар элек күргәннәр белән кабат очрашу.

Күкләрдә магнит давыллары булса, кеше җанында мәхәббәт-нәфрәт давыллары...

... Ә элек күргәннәр белән кабат очрашу дигәндә, Мөхәммәт күңелендә бер тетрәндергеч вакыйга булды.

1944 ел...

Сугыш бетүгә таба бара. Мөхәммәт ул вакытта һаман да әле Вятские Поляны ату коралы ясау заводында эшли иде. Шул вакытта ул Серафима карчыкның аңа бүләк ителгән бриллиант кашлы алтын йөзекләрен, «Фронт өчен!»—дип, дәүләткә тапшырды. Бер дә икеләнмичә генә. Моның өчен аңа аз гына акча да бирделәр, азык-төлек алырга да ярдәм күрсәттеләр.

Мөхәммәтнең күптән тозлы балык ашыйсы килеп йөри иде. Тимер юл вокзалында буфет бар. Менә шунда вакыт-вакыт сугыш чоры өчен сирәк булган азык-төлек тә сатыла иде.

...Вокзалга товар вагоннары таккан поезд тукталган. Шыксыз, кара вагоннар. Кайберләренә кечкенә генә тәрәзәләр уелган, алар тимер рәшәткәләр белән капланган. Менә шул тәрәзәләрнең берсеннән Мөхәммәт сак кына, хәлсез генә аваз-тавыш ишетте:

—Мөхәммәт энем...

Анын аяклары калтырады: «Кем бу? Бик тә таныш тавыш ич. Кем булыр?»

Ул тавыш килгән тәрәзәгә текәлде: анда ап-ак чәчле, озын ак сакаллы, йөзе жыерчыкланып беткән, бик бетәшкән бер карт тора иде.

—Мөхәммәт, мине таныйсыңмы син?

—Юк!

—Мәхмүдбәк бит мин... Азак дингезен искә төшер...

—Мәхмүдбәк абый!—Мөхәммәт тетрәнеп китте.

—Монда... Вагоннарда һава житми, сусызлыктан интегәбез... Кырыла халык...

—Сез... Сезне ничек?—кенә дия алды Мөхәммәт.

—Безне Кырымнан сөрделәр... Сталинның приказы буенча... Булдыра алсаң, син безгә бер шешә генә су алып кил. Йотымлап булса да, бүлешеп эчәр идек...

Мөхәммәт агачлар арасыннан пычранып беткән шешә тапты, ерак булмаган йорт янындагы коедан су алып, аны яхшылап юды да эченә су тутырып, рельсләрдәге кара вагоннарга таба йөгерде.

Әллә каян гына автоматлы сакчы пәйда булды:

—Стой, кто идет? Стрелять буду!

Тимер рәшәткәле тәрәзәгә омтылган Мөхәммәтнең шешәсен кулыннан тартып алды да рәшәткә кырыендагы ташка бәреп ватты:

—Нельзя! А ты уходи отсюдово! Они—враги наши... Они—враги народа...

Мөхәммәт тозлы балыгын да онытты, буфетка кереп тормыйча, вокзалдан шәһәр ягына китеп барды. Ул төнне йоклый алмады. Тетрәнүләр төне иде ул...

Ничек инде Мәхмүдбәк аңа дошман булсын?! Бердәнбер атын сатып Мөхәммәт өчен жылым штрафын түләде, алар белән гел дус яшәде. Гомумән, Мәхмүдбәк беркем белән дә дошманлашып йөрмәде ич! Похмелкинны да дошман итмәде.

Аннан соң тулы бер халыкны дошман дип буламы?! Аны туган жиреннән, туган иленнән куган кеше—менә кем дошман!

Мөхәммәт хәзер дә—Сталин үлгәннән соң да, бернәрсәне аңлап бетерә алмый:

—Ни вөжданы, ни ояты белән ул Рузвельт, Черчиль белән очрашуга Кырым конференциясенә бара алган? Бер кеше, хәтта ул «бөек юлбашчы» булса да, бөтен бер халык кадәр халыктан кирәгрәк, әһәмиятлерәк, югарырак, файдалырак, мәгънәлерәк, бөегрәк була аламы? Ничек халыкны туган жиреннән аерып чит-ят якларга куып жибәрергә жөрьәт иткән ул? Йөрәге таш булганмы анын?! Иң бәгырьсез адәм дә бу эшкә барырга тиеш түгел бит! Туган жир, туган ил, туган як дигән төшенчәләргә карата бер канун да бар ич:

—Кайда яшәргә теләвен халык үзе генә әйтә ала!

Ә тираннарның халыкка карата үз кануннары...

* * *

Сабантуйлар вакыты килеп житте...

Шәрәфетдин көрәшкә бик житди әзерләнде. Ундүрт яшендә атлар чабышында ул Пальма белән беренчелекне яулаган иде. Узган ел көрәшкә чыгып икенче урынны алды. Дөрес, Шөндә икенче урын, икенче батыр дип сөйләшмиләр, батырга егылган кешене, ягъни батыр күтәреп салган соңгы көрәшчене монда «батыр асты» дип йөртәләр. Батырын батыр да, ну—«асты» шул! Батыр астында калган кеше, мактаулы булса да, рәхәт исем түгел!

Башта, гадәт буенча, бала-чагалар көрәште, аннан зурраклар, егетжиләннәр. Атлар чабышы узгач, барлык уеннар уйналып, бар төр ярышлар тәмам булуга, алар мәйдан уртасында икәү генә калдылар: Мамадыш-Вахит

якларыннан килгән тельняшкалы матрос һәм Шәрәфетдин. Матрос аннан бер башка тәбәнәк булса да, төптән юан чыккан. Мондыйларны Шөндә «аркылысы-буе бер» дип кенә җибәрәләр. Шәрәфетдин аңа хас беркатлылык вә хәйләсезлеге белән: «Мин бу матросны салам да салам инде»,—дип уйлады. Шуңа ул сөлгеләр белән билне урауга, матросны җан көченә үзенә тартып китерде һәм... Күтәреп кенә алыйм дигәндә, матрос әллә ничектер шуышып кына аның киң җәелгән аяклары арасына кереп китте дә Шәрәфетдинне күтәреп, шапылдатып яшел чирәмгә әйләндереп салды. Аның хәтта борыныннан кан китте, алдагы көрәш вакытында берәү аның дәү генә борынына башы белән төшкән иде.

Мәйдан шаулады, шау-гөр килде:

—Хәрәмләде!—диде кемдер.

—Юк, чиста салды!—дип каршы төште икенчесе. Шәрәфетдиннең көндәшләре, аны өнәп бетермәгәннәр:

—Чыгып кит мәйданнан! Булды бит инде, тагын ни көтәсең?—диделәр. Бигрәк тә Карсак Габдулла нык тырышты. Ул озын буйлы, куәтле кешеләрне бер дә сөйми иде, шуларны күрүгә җене кузгала иде аның:

—Йөрмәсеннәр әле телеграмм баганасы кадәр буйлары белән. Әллә кем булып! Башкалар белән тигезләү өчен аларның башларын кисәргә кирәк!

Халык сабыр гына утырган Мөхәммәткә борылып карады:

—Мөхәммәт, чык уртага! Әйдә, көрәшеп кара...

—Киленнәрнең батырга дип чиккән сөлгеләрен читкә җибәрикмени?! Аның янына килеп утырган улы канлы борынын сөртеп, гаепле кеше сыман башын иде дә чиксез әрнү вә оялу белән:

—Булмады, әткәй!—диде.

—Ашыктың, улым!

—Мин аны...

—Көрәштә һәр көндәшеңә хөрмәт белән карарга кирәк! Ә син...

—Алырмын да салырмын дигән идем.

—Салырсың, бар! Кеше бит ул, бодай капчыгы түгел...

—Тормышлар ничек, Шәрәфетдин?—дигән булды алар яныннан читтәрәк утырган Габдулла авызын ерып.—Һаман да ит ашыйбызмы?

—Көрәшкә чыгам диеп бер тәкә ашап бетердем, ну, пазурга калдым,—диде Шәрәфетдин.

Карсак Габдулланың сүзләренә төшенеп җитмәгән Шәрәфетдин үзенә хас беркатлылык, хәйләсезлек, сафлык, ачыклык белән әйтте шул. Кемнәрдер хихылдашып маташты. Батырны ектырырга йөрүчеләр аз түгел!

Шунда Мөхәммәтнең тәкате корыды:

—Бир әле, улым, сөлгеңне!—диде ул.

Мөхәммәт мәйдан уртасына чыгып басты. Кулында—улының каны сөртелгән сөлге. Җиләнен салып читкәрәк куюга матрос шурләп үк китте. Ун ел сабантуйларда батыр калып, аның мондый бүрәнә мускуллы, юан беләкле көрәшче ир затын очратканы юк иде әле. Бу бит әкәмәт, бу бит—тау! Шул, аяк чалып ексаң гына... Йә бот арасына кереп аударсаң гына инде...

—Гадел көрәш!—диде аңа Мөхәммәт.

—Хәрәмләшүгә кергәнем юк әле,—дип кисте матрос.

Бу көрәшченең хәйләсен белә иде ул: кешегә юри билен бирә дә, теге алам дигәндә генә, көндәшен күтәреп алып, җиргә китереп сала. Мөхәммәт сөлгенең очларын тегенең корсак астыннан ук шытырдатып кысты: менә хәзер селкенеп кара! Матрос бер аягын җирдән аерып янгарак атларга гына теләде, Шөн батыры аны һавага ук күтәреп алды.

—Салыйммы?—диде ул аңа.

—Юк!

Ул аны аякларына төшерде, ипләп кенә... Мөхәммәтне батыр итеп күккә чөйделәр, «рәхмәт булдырдың!», «маладич», «картая белмисең икән әле»,—диделәр. Иң шатланган кеше, әлбәттә, улы Шәрәфетдин иде.

—Мине пазурдан коткардың! Рәхмәт, әткәй!—диде ул аңа.—Нү, маладич та инде үзең!

—Синең батыр каласыларың алда әле, бер дә борчылма, улым,—диде ана Мөхәммәт.

Бу батыр калу Мөхәммәтнең авылда абруен тагын да күтәрде. Анда үз-үзенә ышаныч туды, ул әллә нинди өметләр белән яши башлады, яшәүгә-тормыш итүгә үҗәтләнебрәк тотынды. Нәрсә диген иде әле Хөснимәрдән агай?

—Песи булып яшәсәң дә, үзенне бер генә көн булса да арыслан итеп той!

Бу яз, бу сабантуй аңа яшәү дәрте китерде, әллә нинди сихри көчләр индерде. Ә бит ул, иллене узгач, гомерем әллә ни калмас инде диген тәшвишле уйларга килгән иде, чөнки якын кешеләренең үлеме аның йөрәгенә тирән яралар ясады. Гомумән, белгән-аралашкан, бер табактан ашаган кешеләрнең үлеп китүен, кинәт кенә мәңгегә югалуын Мөхәммәт авыр кичерә иде. Әле чагыштырмача яшь кенә килеш әтисенең, әнисенең, Хөснимәрдәннең үлемен күрү—аның күңеленә җәрәхәт өстенә җәрәхәтләр өйде. Нәрсә-нәрсә, ә үлем башта аңа табышмак булып килде, ә соңыннан ул да бу котылгысыз канунга буйсынды, авылдагы үлем-җитемнәргә бераз гына булса да ияләнә төште. Ә моңа тулысынча битараф булу юк та юк инде ул! Үлем—иң Бөек Сер ул...

—Яшәү—Олуг Мәгънә!—диде бервакыт аңа авыл фәйләсуфы Хөснимәрдән агай.—Үлем—Мәгънәсезлек... Кешенен бу фани дөньяда тормыш итүе—Мәгънәнең Мәгънәсезлеге ул...

Азак дингез буенда аның бу сүзләрен аңламаган иде Мөхәммәт, менә ярты гасырдан артык яшәгәч кенә төшенде.

Ә шулай да Мәгънә өчен яшәргә, булсынга эшләргә кирәк. Барысын да мәгънәсезлеккә китереп терәү—үзе үк хата фикер...

... Соңгы вакытта баш миен бораулап торган сорауларга җавап эзләп шактый талчыккач, Мөхәммәт бу уйлардан котылу юлын бер генә нәрсәдә күрде:

—Эш кирәк! Ике кулга бер эш. Ахмакка әнә бар да шакмак. Ә акыллы нидер эшләргә, иң мөфтиме, нидер төзәтергә тиеш. Кара уйларга чумып, үз-үзенне җимереп күпме утырырга була. Әнә, өй мичен янартып салырга кирәк, мунчаның аскы ниргәләре чергән—алыштырырга яисә күтәртеп таш кыстырырга!

Колхоз эшеннән арынган араларда ул Кәҗә үзәнендә кирпеч сукты, тимер мичтә аларны яндырды. Мондагы үзле кызыл балчык бер түгел, йөзләрчә өйлек кирпеч сугарга җитәрлек иде.

Җәй уртасы...

Инде аргы як болыннарга печәнгә төшәргә дә күп калмады. Бәләкин утравында, Кәримулла атавында, Кәҗә үзәне каршындагы таллыкларда котырып бөрлегән өлгерде. Эштән бушый алган хатын-кыз, бала-чагасын ияртеп, бөрлегәнгә йөрде. Бу якның сый-нигъмәте җир өстендә үсә!

Мөхәммәтнең дә кирпечләре сугылып—яндырылып беткән. Менә соңгы арбаны төяп кайтса... Нигәдер Шәрәфетдин күренми әле. Ул килгәнче дип, Мөхәммәт тә якын-тирәдән бераз бөрлегән капкаларга булды. Аннан соң оныкларга «мәм-мәм» җыярга. Эченә әрекмән яфрагы салып, бер кәләпүш алып кайтсан, «бабай, бабай»,—дип, тез өстеннән төшмәсләр.

Куелыкка кергәч...

Әйе, кергәч...

Ул бер хатынга очрады һәм «бөрлегән капкаларга» дигәнен дә онытты. Яшькелт күлмәге өстеннән ак түгәрәкләр төшерелгән зәңгәрсу алъяпкыч япкан, ак яулыктан чигеп торган колагына көмеш алкалар элгән, аягындагы галушлары елкылдап торган «кәртинкә» хатын иде ул. Яше егерме бишутызлардан артмас. Алъяпкыч баулары белән кысылган нечкә бил, йомры беләкләре, яулыгыннан ишелеп торган кара чәчләре, уймак ирене, нәфис ияге, хәтта кулындагы тырысы да аны искиткеч гүзәл итеп күрсәтәләр иде. Бер кавымга Мөхәммәт тораташ катып калды. Хатын да аны күрүгә куркынып китте бугай, тел тибрәтеп бер сүз дә әйтә алмады. Торалар читтән-миттән генә, астан карашып.

Ә шулай да хатын чаярак зат икән:

—Мөхәммәт абый, мин бу таллыкта адаштым. Безнең Таллы авылына кайтырга юлны ничек табасы икән?—диде ул иргә матур гына күз сирпеп. Күз сирпеше әллә нинди тылсымлы...

—Син минем исемемне каян беләсең, сеңлем?—дип сорады кинәт кенә җылынып киткән Мөхәммәт. Ул чәч төбенә мул булып тир бәргәнен сизде.

—Абый! Сез бит быел сабантуйда батыр калдыгыз. Ә батырларны бала-чага да белә.

Рәхәт булып китте Мөхәммәткә. Ул инде шушы хатын белән ниндидер яктырыш, якынлык киләсен күнеле-җаны белән сизә, тоя иде. Ниндидер алхәбәр, серле күзаллау бу турыда аның башына тукып килде һәм менә, әлеге гүзәлне күргә ул моңа тулысынча ышанды.

—Әйдә, күрсәтәм юлны,—диде ул хатынга. Алар таллык буйлап киттеләр...

Ни хикмәт: аның аяклары һич тә юлга таба түгел, ә таллар эченә, куелыкка алып баралар иде. Нәрсә бу? Ни могҗиза? «Нү!»—улы Шәрәфетдин әйтмешли.

Мөхәммәт бер генә нәрсәне ачык аңлады, әгәр бу «картинкә хатын»ны юлга алып чыга икән, әлеге гүзәл зат аның өчен мәңгегә югалачак. Ә моны ул теләми, юк!—теләми, чөнки ошбу зат аның соңгы ымсынуы, йөрәгендә бер мизгелдә кабынган ахыргы Олуг Хисе. Аның соңгы вакытларда боегыбрак яшәве нәкъ менә шушы хатындай үз пары булмавыннан килә икән!

—Абый, сез мине кая алып барасыз?—дип сорады гүзәл зат, бераз курка төшеп һәм «син»нән «сез»гә күчеп.

—Исемең ничек синең, сеңлем?

—Нәфисә.

—Нә-фи-сә... Бик матур исем! Җисеменә күрә икән исемең дә... Карале, ирең бармы синең?

Хатын дәшмәде. Аннан:

—Бар иде... Күптән түгел генә вафат булды,—диде.

—Нәфисә, чык миңа кияүгә! Мин сине бер күрүгә бик ошаттым!—дияргә мәҗбүр булды ир. Мөхәммәт «яраттым!» димәкче иде дә, бу олуг сүздән үзе үк оялды: «Иллене узгач, җилле сүзеңне дә төптән уйлап әйт...»

...Кирпеч сугарга киткән Мөхәммәт авылга «картинкә хатын» алып кайтты. Унике ел ир белән торса да, Нәфисәнең беренче иреннән баласы булмаган икән. Язга ул тупырдап торган малай тапты. «Зарсыз бала булсын!»—дип, аңа Алмазар дип исем куштылар. Гәүдәле, чибәр бала иде ул. Җиде яше тулыр-тулмаста мәктәпкә укырга керде Алмазар. Бу балага иң шатланган кеше Шәрәфетдин булды бугай:

—Кара инде безнең әткәйне! Минем балаларыма энекәш булырлык малай ясап куйды бит, ә?! Нү! Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле!

Алмазар үсә төшеп, буй җитә башлагач, Шәрәфетдин, әтисе йортыннан аерылып, башка чыкты. Аңа йортны бергәләп салдылар.

Алмазар Болгареев, Казанда төзелеш институтын тәмамлап, Шөнгә кайтты һәм авылда беренче булып ике катлы кирпеч йорт салды.

—Иске йорт та нык иде әле...—диде аңа Мөхәммәт.—Ике ятажлы кирпеч йорт! Байларча түгелме?

—Иске йорт дия-дия, искечә яшәмик, әткәй! Бер төзегән гомерлек булсын, оныкларга да калсын,—дип кенә куйды улы.

## Дүртенче бүлек

## Кайту

2001 елның гыйнвар башы...

Авылның йөзьяшәр карты Мөхәммәт йортында бәйрәм, тантана—юбилей. Кунакларның саны йөзгә якын иде, һәрхәлдә тирә-юньгә, сала-

калаларга илле пар кунакка чакыру җибәрелде. Бергә укмашып-туганлашып беткән Болгареевлар, Җидановлар, Хәзрәтовлар нәселе Казанда да күп, Мәскәүдә дә бар. Бу нәселдә хәзер үзбәк, казакъ, рус, немец, фин, швед, француз каннары да бар. Япон, гарәпнеке дә юк түгел. Бер әзәрбайҗан кияүләре дә бар әле...

Гомумән...

Чит милләт ир-атларына кияүгә чыккан вә канны яңарткан әлеге нәсел кызларын санап китсәңме?! Әле саганганнарга тагын ким дигәндә ун милләт вә килен өстәргә булыр иде. Казанда әнә яһүдкә чыккан чыбык очы кыз туганнары юкмыни?! Әмма...

Болгареевлар, Җидановлар, Хәзрәтовлар—иң беренче, татарлар! Әйе, чын татарлар! Татар була алганнары... Хет татар була белгәннәре... Йәисә татар булырга тырышканнары... Татар булырга исәп тотканнары... «Мин—татар!»—дия алганнары...

Калганнары, бер урыс кияү әйтмешли:

—Шелуха!

Татарчалап җибәрсәң, җиргә төкереп ташланган көнбагыш кабыгы инде. Орлыгын ашау өчен төкреккә кушып чәйнәлгән көнбагыш кабыгы. Ята әнә җирдә, аны кем дә таптап китә, аны чыпчыклар да ашамый, чөнки ул—орлыксыз...

Орлыксызга әйләндерелгән кемсәләр күпме әле ул татарда?! Бихисаптыр... Һәрхәлдә санын беркем дә төгәл генә белми...

Мөхәммәтнен өч улы, бер кызы гына булса да, оныклары икеләтә артык инде. Шәрәфетдин балалар санын бишкә житкерсә, Алмазарның ике кыз, бер улы туды. Икенче кыз белән сәеррәк хәл дә килеп чыкты әле. Мөхәммәт, улыннан, килене янына барып кайтуга, сорап куйды:

—Кем?

—Кыз...

—Икенчесе малай булыр дип көткән идем...

—Мин дә көттем дә...

—Бабайга малай кирәк!

Ата кеше әллә ничек нәүмизләнгәч, Алмазар әйтте:

—Кибете бикләнмәгән ич әле, эткәй!

—Нәрсә-нәрсә?

—Бала чыга торган кибеткә йозак эленмәгән әле дим...

«Нү!»—дияр иде Шәрәфетдин.—Кара минем бу малайны, хатыны, рус теле укытучысы Зоя әйтмешли, «образлы сөйләшә». «Кибете бикләнмәгән.» Шәп сүз бу, билләһи! Бикле һәм биксез әйберләр күп ул дөньяда...

Шул төнне үк аның төшенә икенче онычкасы керде. Әле кичә генә дөньяга килгән, бабасы бер тапкыр да күрмәгән нарасый:

—Бабай!—диде, аңа фәрештәләр йөзе белән карап.—Нигә син минем малай булып тумаганыма үпкәлисең әле?

Коты чыкты Мөхәммәтнең:

—Юк, юк, балам! Мин сиңа бик разый, эш кыз йәисә малай туудамыни? Иң мөфтиме, игелекле бала бул!

—Син миңа рәнжемисеңме, бабай?!

—Юк, балам... Зинһар үзең миңа рәнжемә...

Йокысыннан кычкырып елап уянган иде ул вакытта Мөхәммәт. Әнә хәзер ул бала Казанга консерваториягә укырга керде инде. Теле юньләп ачылганчы җырлап йөри башлаган сабый бит ул! Әнисе—керәшен кызы Зоя да матур җырлый.

Ә икенче онычкасы төс-биткә каплаган куйган Мөхәммәт инде! Вәт әкәмәт!

...Мөхәммәт тора-тора да үткәннәргә кайта, үз уйларына кайта. Әйе! Кешеләр китү белән генә түгел, кайту белән дә яши. Кайтулар...

Гомерлек кайтулар...

Үзенә, дәненә, халкына, туган җиренә кайтулар. Мәңгелектән килеп—мәңгелеккә кайтулар...

Туган көненә бер ай кала ана район гәжитеннән яшь кенә бер

корреспондент кыз килгән иде. Аның турында очеркмы, мәкаләме язарга. Сорауларны күп бирде...

—Бабай, сез тәмәке тарттыгызмы?

—Юк!

—Аракы эчтегезме?

—Юк!

—Димәк, шуңа күрә озак яшәгәнсез...

—Юк!

Кыз аптырап калды:

—Ә озын гомерле, таза-сәламәт калуыгызга нәрсә ярдәм итте?—дип кабатлап сорады.

—Инабәт,—диде бер сүз белән карт.

—Ина-бәт? Бу сүзне мин анламыйм. Гарәп сүзе түгелме ул?

—Инабәт—яшәүгә өмет югалтмау, кешеләргә гомерлек ышаныч саклау, тормыш итүдә үҗәтлек ул. Дөньяга яратып карау, сөенә белү, иманлы булу, рухи тынычлык...

Кыз бабайны аңлап бетерә алмады: «эчмәдем—тартмадым, начар гадәтләрем булмады, саф һавада күп йөрдем, яраткан ризыкларым—яшелчә, җиләк-җимеш иде» дисә, бу сүзләрне кем дә аңлар иде, ә бу карт авыз тутырып:

—Гомер буе ит ашадым, яратып ашаган ризыгым—балык иде,—дип тора. Вәт, сина бабай, өйлән давай! Әле бит ул шаяртып алырга да ярата, төртмә сүзләр ычкындырырга да күп сорамый. Әмма әдәпле кеше!

Әлеге кызга Мөхәммәтнең әйтәсе тагын бер сүзе бар иде:

—Озак гомер итәсең килсә, көнләшеп яшәмә, кешегә үч тотма, эчле булма, хөсетләнмә! Дошманыңа да үлем теләмә! Комсыз булма!

Әмма вә ләкин...

Андый кешеләр дә озак кына яшиләр ич. Мисалга, Габдулланы гына алыйк. Җитмеш яшендә паралич суккач та, ун еллап урын өстендә ятты, бары 1997 елның башында гына якты дөньядан китте. Әле бит караватында ятканда да, үләр көннәре якынлашкач та, сораган ди:

—Теге карт тәре катмадымыни әле?

—Кемне әйтәсең?—дип сораган аның күләгәсенә әйләнгән хатыны.

—Кемне булсын? Мөхәммәтне әйтүем... Ул бит миннән унҗиде яшькә зуррак. Мина кадәр беренче булып катса, ни булган инде, ә! Ә жук, жук!

Габдуллага бәйле бер вакыйга аның хәтеренә нык кына уелып калган...

Сиксәненче еллар башы иде...

Үзе дүрт ел буена эшләгән янгын сараен сагынып, Мөхәммәт шул тирәләргә килгән иде. Ярмәкәй тавы астындагы бура кадәр ташларга озак кына карап торды. Көчле агымлы торба-чишмәдән кушучлап су эчте. Бу гади су түгел иде, ә нефтьчеләр бораулап та җир мае чыкмаган, минераль чишмә булып, ашказаны авырткан, буыннары сызлаган кешеләр аны еракларда килеп алалар.

Шул вакыт ул янгын сарае тирәсендә ниндидер тавыш ишетте. Шул якка барса...

Әйе, барса!

Анын Шәрәфетдине карсак Габдулланы бер кулы—(ә ул кул—ипи күрәге!) буып алган да атлар караучыны әллә ниләрдән ваз кичтерә:

—Нү! Конюх коротконос! Моннан соң атларның фуражын урламам, диген...

Габдулла гырылдый:

—Урл-ла-мам...

—Минем жизнәм—дуңгыз дин!

—Дуң-гы-ыззз...

—Мин үзем дә хайван дип әйт!

—Ха-ай-ва-ан...

—Шәрәфетдин абый, дип өстә!

Габдулла мышкылдый, гырылдап ала:

—Шәрә...

—Мин мунчада түгел! Нигә урамда шәрә калырга?

—Шәр-рә-фетдин аб... бый...

—Менә шулай! Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле!—Шәрәфетдин карсак Габдулны селтәп чирәм өстенә ата. Тегесе сикереп тора, өстен аннан-моннан каккалап, агачлар арасына таба йөгерә. Мөхәммәт түзә алмый, авызын кулы белән каплап, күзләреннән яшь чыкканчы үзалдына көлә. Аннан соң, посыбрак торган жиреннән чыгып, улының жилкәсенә кулын сала:

—Үтерә иден бит, улым!

—Бер хайван үлүдән...

—Тизәккә басма, исе чыгар.

—Андыйлар үзләренә кагылмасларына расчут ясап яшиләр дә... Нү!

—Дөрес! Әмма да ләкин бер пешекләүдән генә акыл-тәртипкә килми шул алар.

—Пешекли белсән, тәртип ишегенә тиз табалар, әткәй!—диде үз сүзенә вә әле генә кылган гамәленең хаклыгына нык кына ышанган Шәрәфетдин. Аңа һәрвакытта үз-үзенә ышану хас.

«Тәртип ишеге...»

Ожмах ишеге шул тәртип ишегеннән башлана түгелме? Ишекләр, ишекләр... Ничәмә-ничә ишекләр узды Мөхәммәт үз гомерендә. Кердечыкты... Китте-кайтты... Ул Егерменче Гасыр башы ишеген ачып килгән иде бу дөньяга, менә Егерме беренче Гасырныкын үзе өчен мәңгегә ябып китәсе калды. Килү һәм китү... Алар икесе дә кешеләр өчен үкенечле булмаска тиеш! Үкенечләр өчен яшәү инсан күтәрә алмаган иң зур көенеч түгелме? Шуның өчен якты дөньяга килүнең ни хәсияте бар соң?! Бу үзе хәрамлыр, изге-кыйммәтле гомерне санга сукмау, кадерен белмәү, хакарәт итүдер. Ә Мөхәммәт яшәүнең кадерен, тәмен-ямен яшьтән үк белде, елыйсы чакта көлде, саулыгын саклады, көнен вә үкенечләр китерер гамәлләрен дә матур эшләре белән аклады. Үзе әйтмешли, «иң мөфтиме», ул бер генә жан иясенә дә зыян салмады.

Теге гәжиттән килгән кыз аның турында ару гына мәкалә әвәләгән иде. Булдыра икән бит, чукынчык! Мөхәммәт аны ничектер баласытып утырган булды бит әле. Хәзер менә шул эшенә читенсенә. Хәтта оялыбрак та китте әле.

Мәкалә ярты бит булып чыккан, фоторәсемен дә урнаштырганнар. Билләһи, күнеле булды карт юләрнең. Югыйсә, һәрнәрсәгә шаклар катып утыра торган чаклары да узып киткән иде инде. Ә шулай да...

Ә шулай да...

Сине мактасалар, бу мактау күнелгә сары май булып ята икән! Йөрәген дә дәртлерәк тибә башлый, жаның рәхәтләнә, рухың тагы да яктыра төшә...

Шул гәжитне күтәреп Шәрәфетдин дә килеп керде:

—Әткәй, данын районга таралды. Өлкә гәжитендә дә бу язманы бастырабыз дип торалар икән. Нү!—диде ул. Шәрәфетдиндә—Бибинур холкы, әтисенең төс-кыяфәте. Менә әкәмәт!

—Ә хәзер әйдә мина кунакка! Безне каз бәлеше көтеп тора,—диде улы аңа яратып карап.

* * *

Кешеләр юньсезләнә икән, атлар да тешләшә, сыерлар сөзешә башлый.

Соңгы елларда Мөхәммәт кошларны күзәтергә ярата. Ил базар мөнәсәбәтләренә күчкәч, кешеләр психологиясендә генә түгел, кошларның үз-үзләрен тотышында да шактый үзгәрешләр барлыкка килде. Әйтик, сыерчыклар элеккеге кебек яз башында авылларга өелеп-өелеп күп кайтмый һәм сандугачлар да өздереп-өздереп сайрамый. Югыйсә, былбылларның алхәбәрчеләре ич алар...

*И сайрый, и сайрый!*
*Дәрт-моң сыерчыктан...*
*Көнләшеп шуңардан*
*Тиресле абзардан*
*Мөгрәп сыер чыккан.*

Каргалар элеккечә үк каркылдый, тик бу каркылдауда нindидер даулап итү өстенә әллә нинди оятсызлык та бар:

—Кар! Кар! Кар!

Яңа урыслармыни...

Чәүкәләр элеккегә караганда шактый ук юка-сыек. Тавышлары да көзге Нократта хәлсез дулкыннар чыйпылдавы кебек:

—Чыек... Чыек... Чыек...

Бу авазларда әллә нинди моң-сагыш...

Саесканнар усалрак чыркылдый. Элек алар йорт тирәсенә берәрләп кенә килә иде, хәзер, бүгенге көн сукбайлары кебек, ике, өч, хәтта дүртәүләп йөриләр. Безнең халык саесканны үз йортының яисә лапасының түбәсендә күрсә:

—Әһә! Безгә кунак киләчәк!—дип юрый иде. Хәзер болар икешәрләп-өчәрләп койма тактасында чыркылдап утыралар—бер түгел, ярты кунак та юк. Кунакка йөрешүләр дә бетте, һәркем әкәм-төкәм кебек, үз йортына бикләнде.

Руслар саесканны «сорока-воровка» диләр. Мөхәммәт мона быел тагын бер кат ышанды: июнь башындагы сабантуйлар вакытында этенә дип, ипи калдыклары, сенерле-итлерәк сөякләр салып, савытны ашый-ашый күбенеп беткән маэмаеннан читкәрәк куйган иде, шуның яртысын ташып бетергәннәр, чукынчыклар! Ипие ипи инде, ә сөяк нигә кирәк булган аларга? Саесканнар эт түгел ич инде сөяк кимерергә, әллә аларның да этләшүеме бу?!

*Туганнар да читләшә,*
*Эреләр дә бетләшә,*
*Саесканнар этләшә—*
*Сүз әйтмәссең тешләсә...*

Авыл тирәсендә карлыгачлар ояламый инде, яр карлыгачлары керәшәләр дә Нократның текә ярларына йөзләрчә оялар ясап, шуңа атылып кереп, атылып чыгып йөрмиләр. Нократта балык беткәнме...

Ә менә тәлитүт-селкенчәкләр авылда кабат күпләп пәйда булды. Шома-зифа буйлы, елгыр гәүдәле, кара-ак түшле, озын койрыклы, көрәнсу төстәге бу ике канатлылар, теләсә кайда хәзер. Бүгенге эшмәкәрләр кебек...

Бер чыпчыклар гына элеккечә чыркылдаша. «Чыпчыклар кебек чыркылдашып яшәгез»,—дигән Гайса пәйгамбәр дә. Чыпчыклар—гади халык...

...Алмагачта сандугач сайрый.

Ах!

Мөхәммәтнең йөрәге өзелеп төште...

—Мин дә шигырь белән уйлый башладыммы?—дип шаккатты ул. Нәрсә дигән иде Хөснимәрдән фәйләсуф? Болай диде:

—Инсани Затның Шигырь белән Уйлый башлавы Камиллек дәрәҗәсенә ирешеп килүе ул...

Йә, Алла! Йә, Алла! Йә, Алла!

Бу сүзләренә Хөснимәрдән агай, жиде көн ашамыйча-эчмичә караңгы вә тирән суык базда шәрә килеш Хак Тәгаләгә ялварып ятканда ирешкәнме?!

Нәрсә дигән иде әле тагын авыл фәйләсуфы? «Дөньяда башта Караңгылык белән Яктылык бергә кушылган булган, Бөек Кодрәти Көч Аларны Аерган...»

«Нур—Аллаһы, Кара Төртке—Иблис»,—дип тә әйтте ул.

...Бервакытны Мөхәммәтнең килене Зоя нindидер галим язган бер китап алып кайткан иде. Анда «моннан ун меңме, ун миллионмы еллар элек материя белән электромагнитик дулкыннар бергә кушылган булган» дип язылган иде. Кызыксынып укып утырган булса да,—ә аның килене йортка кызыклы китаплар ташый!—әлбәттә, Мөхәммәт бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмыйча җәфа чикте, шуңа карамастан, Материя—Караңгылык, Электромагнитик Дулкыннар—Яктылык дигән нәтиҗәгә килде. Хөснимәрдән шәкерте ич!

«Нү!»—дияр иде олы углы Шәрәфетдин...

Нәрсә дигән иде әле Шәрәфетдин теге карсак Габдулны янгын сарае

алдында бер кулы белән буып алганда? Әйе, болай дип сорады:

—Син, Карсак, кыслаларның кайда кышлаганын беләсеңме?

—Жук...—дип гырылдый теге.

—Ә кыслаларның сызгырганын ишеткәнең бармы?

—Жу-ук... Ә жук!

—Жук син, Карсак! Колаксыз бәндә. Сызгыруны да ишетмисең. Нү! Ишетмисең, ә? Нү!

—Ие, ни? Ә жук... Жук инде!—ди Габдул.

—Жукка мин үзем дә тук. Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле!

Әйе! Күр—нәрсә әйтер, ишет—ни күрсәтер?!—дигән иде Хөснимәрдән агай.

... Ә бу вакытта Мөхәммәт угылы Шәрәфетдин Болгареев немец жизнәсен каз шулпасы белән сыйлап утыра иде. Вольдемар Финк—Идел буе немецы, тау кадәр кеше. Ифрат эшчән. Шөн халкы аңа бер генә кушамат такты:

—Мачтур! Һәр эшкә мачтур бу чукынчык нимеч!

Әйе! Вольдемар һәр эшкә оста, мастер кеше иде. Бер генә эштән дә жирәнмәгән, һәр нәрсәгә кулы ятып-ябышып торган Шәрәфетдин бу әзмәвергә бераз көнләшеп карый, салып алгач, аны оскыртырга ярата:

—Җизни, ә жизни?

—Әү!—ди Вольдемар, көрәк кулларын өстәл астына яшереп, юкса икесен бергә өстәл өстенә куйса, тәлинкә, кашык, чәнечке, пычак, чынаякларга урын калмый да диярлек. Дәү бу куллар! Вольдемар Финк Шәрәфетдиннең «жизни» диюенә үлә дә китә инде, берсендә шул сүздән соң кызып китеп, «Их кайнеш!»—дип, кысып кочаклаган иде, малаеңның күзе чәшкә кадәр булып акайды, сөякләре шыгыр-шыгыр килде, көч-хәл белән тын алды. «Сара апа ничек чыдый икән моңа?»—дип кенә уйлый алды ул.—Кеше түгел бит бу, үгез. Чистый үгез инде менә. Нү!

Вольдемар Финк урысчаны үз туган теленнән яхшырак белсә, татарчаны урысчадан да яхшырак белә иде. Алар бит Мөхәммәт белән озак еллар тимерчелектә эшләделәр. Вятские Поляны заводында «секретный сейфлар» мәңгегә бикләнеп калса, Вольдемарны чакыралар—ача да бирә чукынчык нимеч! Шул эшенә бер яшнек сыра, ике савыт аракы, тозлы балык, ун гөрәнкә колбаса төяп кайта да очраган бер кешене сыйлап йөри. Халык көлә:

—Демар, Демар! Хет колбасаңны хатыныңа калдыр инде...

Демар—Вольдемар, ат кебек көчле—куәтле кеше, үгездәй таза немец, рәхәт елмая:

—Сарам өчен минем мәңгелек колбасам бар!

Уллары Роберт, Валера, Юра, Рудольф, Петя Шөндә татар мәктәбен тәмамладылар да элеккеге Союз буенча таралып беттеләр, бары иң олылары Роберт кына Германиягә күченеп китте. Яһүдәгә өйләнгән. Бик шәп торалар, ди...

—Җизни, ә жизни?!—ди Шәрәфетдин.

—Әү!—дип рәхәт елмая Вольдемар.

—Нигә син безнең Сара апага өйләнден?—дип оскырта аны Шәрәфетдин житди кыяфәт белән.—Син бит немец, берәр немка тапмадыңмыни, татар кызы Сарага өйләнмәсәң, ә?

Вольдемар тагын да рәхәтрәк елмая һәм һәрвакыттагы кебек бер үк сүзләр белән жавап бирә:

—Үз гомеремдә татарлардан да шәфкатьлерәк, миһербанлырак, ярдәмчелрәк кешеләрне очратмадым,—ди.—Менә сездә өй бурасын өмә ясап күтәрәләр, үлекне бөтен авыл жыелып соңгы юлга озата, үз бәрәңгесен алып бетергәч, күршесенә булышырга керәләр, янгын чыкса, тирә-яктан шундук жыелып сүндерәләр... Йә, әйт инде, кайнеш, ничек яратмассың бу халыкны?!

Ә Шәрәфетдин нишли? Ат булып кешни.

—Нү, жизни! Маладич нимеч син, жизни! Җизни урысның жизнь сүзеннән бугай ул. Нү, жизни! Синең белән булганда яшәү теләге тагын да арта...

...Кешеләрнең иң алама вә гөнаһлы яклары—үз нәфесләрен һәм теләкләрен вакытында тыя алмауларында. Әнә шуннан инде бар юньсезлекләр башлана. Ә бит...

Дөньяның нигезләре бәндәләрнең теләкләре кабул булмауга корылган. Әгәр инсаниятнең бар теләкләре тормышка ашып барса, жирдә туфан калкыр, гарасат кубар, мәхшәр туар иде. Әле болай да...

«Не!»—дияр иде Хөснимәрдән агай.

Бу—чама хисен югалтмау дигән сүз. Булганына шөкер кылып яшәү. Кирәктә—әйтәсен әйтеп, кирәкмәгәндә—дәшмәү...

Ни гажәп!

Шәрәфетдиннең бар теләкләре дә тормышка ашты бугай. Ничек алай? Ул бит бервакытта да күктәге йолдызларга үрелмәде, бәхетен читтән чәлдермәде, чама хисен һич югалтмады, булмаганга—юкка күз атмады.

«Бу дөнья—сый-хөрмәтләр, мәжлес-рәхәт күрмәкләр дөньясы»,—дип уйлады ул. Әнә бит: кичә туганнан туган Сара апасы белән немец жизнәсе Вольдемар Финкларны сыйлады, бүген каз бәлешенә кияүләрен чакырды. Белә ул: «Һәркемнең үз чираты, вә дә килеп, үз өлеше!»

Әмма!—башта иң зур хөрмәт Әтигә—Мөхәммәткә! Аннан туганнарга, жизнәләргә һәм дә килен-кияүләргә... Нишләсен белә Шәрәфетдин, моның өчен кемне эшләтәсен һәм нишләтәсен дә чамалый-аңлый ул. Чамалый белү, алдан сизенү, аяк астында булачак коены тою кирәк.

—Матри аны!—диде ул аш салып маташкан хатынына сырышып.—Матри, Шәрифә! Бу кече кияү нindirәк кешедер, чуртым белсен. Нү! Сыеңны жәлләмә, төпчек кызыбыз алдында оялырга туры килмәсен. Кире өйләренә кайткач, кече кияү: «Сездә адәм рәтле сыйлый да алмадылар»,—дип багалмабызны тәпәләмәсен. Казанга пулный бер каз сал, вактөякләреннән бәлеш пешер. Каз бәлеше! Аны атаклы конструктор Георгий Семенич Шпагин да бик яратып ашый иде.

—Беләм лә!—дип, бер сүз белән аның нотыгын кисте Шәрифә, бүрәнә беләкләрен сызганып куеп. Шәрәфетдин хәтта бер адым артка чигенеп куйды. Әле картайгач та тазалыгын жуймаган карчыгы әллә аның белән көрәшергә телиме? Юк икән! Әнә бит тагы телгә килде, бу юлы йомшак кына дәште:—Ә син, карт, бар, кибетне әйләнеп кил. Хәмереңне, үзең әйткәнчә «пыяла самавыр»ларыңны кирәк санаганча алып кайт.

Тик чама хисен югалтма!

И сыйладылар да инде алар олы һәм кече кияүләрен. Читтән килгән кече кияү сорап та куйды:

—Көн саен каз боты! Сездә...

—Нү!—дип көлде Шәрәфетдин.—Бездә казлар дүрт ботлы!

* * *

Нәфисә, матур яшәп, матур үлде. Дөресрәге, үлгәнчегә кадәр диярлек матурлыгын жуймады, аны оныклары, туганнарының балалары «Матур әби», «Алма абыстай» дип кенә йөрттеләр. Инде житмеш бишкә житкән карчык булса да, аның йөзен жыерчык басмады, ияге алга калыкмады, күрүе дә начараймады, ишетүе дә әйбәт иде, ә күзләрендә—жылылык һәм сизелер-сизелмәс очкыннар. Иң гажәбе: берничә урт тешеннән башкалары барысы үз урыннарында элеккеге кебек жемелдәп утыра бирделәр. Тешләренең шулай озак саклануына ышанмаучылар да булды:

—Протездыр ул. Ясалма тешләр...

—Юк, үз тешләрем,—диде Нәфисә.—Протез куйдыру—авызлык кигән ат булып яшәү ул... Элек тешләремне каты күмер белән агарта идем, соңыннан шуткә-паста белән...

Әйе, Нәфисә, матур яшәп, матур үлә белде. Үләренә кырык-кырык биш көн кала, иң беренче, бу турыда Мөхәммәткә белдерде:

—Карт, мин авырып торам бит...

—Сизенәм, карчыгым... Үтешле чир булсын!

—Юк, Мөхәммәт... Безне мәңге аерылу көтә...

Ни дияргә дә белмәде Мөхәммәт, юатырга теле бармады, Нәфисә сабый түгел. Булнис, врачлар дип тә тормады, чөнки үлем алдында шул ук докторларның көчсез икәнен белү өстенә, килгән әҗәлне аларның куып җибәрә алмаячагын да әйбәт аңлый иде ул. Капка төбенә Әҗәл килсә, аны иң усал эт белән дә куа алмассың!

Кырык өч ел бергә яшәгән хатынына йомшаграк, иплерәк, ягымлырак сүзләр әйтәсе килде, хәтта бу авыр хәбәрне уен-көлкегә борасы итте:

—Нинди аерылу ди әле ул, Нәфисәм? Менә мин синнән егерме бер яшькә зуррак, ә һаман да аерылулар турында уйлаганым юк!

—Һәркемнең үз гомере... Хәтерлисеңме, син миңа ни дигән идең? Кеше өчен яшәргә була, әмма кемдер өчен үлеп булмый. Һәркемнең үз үлеме бар...

Хөснимәрдән агай сүзләре...

...Нәфисәне җиде кат ап-ак кәфенгә төреп, өстенә хушбуйлар сибеп, Бибинур янына күмделәр. Бибинурны кайчандыр Алсу белән рәттән җирләгәннәр иде...

...Хәтерендә Мөхәммәтнең, хәтерендә: Алсу каберен аршын ярым, ике аршын казып төшүгә, ташлык китте. Гүя Алсуны аласы гүрне таш ишек белән каплап куйганнар. Ирләр кабернең бу урынын бик авыр үттеләр, чөнки кәйлә-көрәккә караганда монда ломнар күбрәк эшләде. Авыл халкы таш чыгудан куркып, бу урында башка кабер казымады, ә менә 1953 елны Бибинур вафат бугач, ире аның Алсу белән рәттән җирләнүен теләде. Җыелган халык зиратта бәхәскә кереп тормады, Мөхәммәт әйткән урынга кабер казыды һәм—ни гаҗәп!—анда ташлы урын аз гына иде.

Нәфисәне дә Алсу, Бибинур белән рәттән гүргә иңдерделәр. Аның өчен казылган кабердән таш бөтенләй чыкмады. Мөхәммәт бу урында тагын бер каберлек урын күреп, анысын үзе өчен киртләп-киртәләп куйды. Алсу белән Бибинурның бура-чардуганнары күптән череп беткәнлектән, Шәрәфетдин белән Алмазар өч кабер өчен бер зур чардуган ясаттылар. Алар аны күгәрмәс алюмин-цинк таяклар, калайлар, «стойка»лардан эшләткәннәр иде, ике ел узуга, бу күгәрми торган чардуганны сүтеп, башы-аягы белән алып киттеләр. Кемнәр? Төсле металл җыеп сатучылар! Алар бит электр линиясендәге километр-километр алюмин чыбыкларны да кисеп алып китүдән тайчанмыйлар. Әзер товарга күбрәк акча гына булсын. Бу хәбәрне ишеткән Мөхәммәт, ялгыз гына калып, кычкырып елады:

—Зиратка кереп әрвахлар өстендәге чардуганны сүтеп алып китсеннәр әле? Кая барабыз? Туфан җибәр шулар өстенә, Раббым! Йә җанымны ал! Мондый хурлыкны күрмәс идем...

Юк, туфан бар кешелек өстенә ул, инсаниятнең яхшы һәм матур адәмнәре дә җәфа күрәчәк бу туфаннан. Явыз-яман, ямьсез-чорсыз адәмчекләргә бу дөньяда ук бирәр җәза булмас микәнни, Раббым? Әнә илне талау, завод-фабрикаларны «бакыр тиен»гә сатып җибәрү, алтын запасларын күпләп чит илләргә озатуны дәүләт-хөкүмәт әһелләре башлап җибәрде, бу Бурлык Вирусы инде күпләргә күчә бара. Аларга да Алланың кәһәре төшмәс микәнни?! Юкса, шагыйрь әйтмешли:

—Юктырсың ла, Алла!—дип куюың да бар. Ә монысы тагы да зур имансызлыкка, денсезлеккә, дәһрилеккә, манкортлыкка, урлау-талауга, җимерүгә-үтерүгә, дөньяви янгынга, тоташ фәхешлеккә, кешедән хайванга әйләнүгә илтәчәк.

Хайванизм... Кешене хайванлаштыру...

Коммунизм төзибез дип, җитмеш ел буена лаф орган илгә хайванизм яный...

Балык башыннан кортлый, ди. Хайванизм да башлыклардан башлана.

«Озак яшәдем,—дип уйлады Мөхәммәт.—Әмма гомерем ахыры борчулы сораулар, юньсезлеккә аптыраулар, киләчәкне күңелсез юрауларга туры килер дип кем уйлаган? Заһидулла сөйләгән иде... Ана Малмыж мулласы әйткән ич, колхозлар төзелә башлаган елларда ук әйткән: «Бу әле көчләү-ләрнең башы гына...—дигән.—Аның икенче дулкынында безне алырлар, без югалырбыз,—дигән.—Болары ярый әле, тик бу гасырның ахырын да

кара тәстә күрәм мин,—дигән... Шуның өстенә туачак гасыр башы да өметле күренми»,—дигән.

...Шәрәфетдин белән Алмазар тагын яңа чардуган ясаттылар. Бу юлы тимердән. Яшел тәскә буяп та куйдылар. Яталар Мөхәммәтнең хатыннары бер өй-чардуган астында: Алсу, Бибинур, Нәфисә... Озакламас, Мөхәммәт үзе дә монда килеп урнашыр... Үзе урнашмас, әлбәттә, алып килеп урнаштырырлар. Галәми кануннар шуны куша, бары тик шуны...

...Шәрәфетдин белән Алмазар теге «төсле металл» егетләрен яхшы гына «төснәткәннәр» икән. Чыгышлары белән Шөннән булмасалар да, татар егетләре бит! Кая бара татар! Татар алга таба нинди юлны тотар? Инде бүген татар зиратына кереп, чардуган сүтеп йөргән татар егетләреннән ни көтәргә? Милли таркаулык күбрәк картларда түгел, ә яшьләрдә күренә бит. Әмма яшьләрсез киләчәк—өметле киләчәк түгеллеген кем дә белә. Уфтана Мөхәммәт, бик тә уфтана. Әнә бит Нәфисә вафатыннан соң аларның Алмазар белән арасы да суынып киткәндәй булды. Нәрсә бу? Әнисенең йөзгә житә язган әтисеннән алдарак үлүенә ризасызлыкмы? Әллә элеккерәк сызлавыкмы?..

Ул «сызлавык»ны да яхшы хәтерли Мөхәммәт. Алмазар Казанда укыганда ук яратып йөргән керәшен кызы Зояга өйләнергә жыенуын әйткәч һәм аның хәер-фатихасын сорагач, Мөхәммәт тиктомалдан гына «киртә жимереп ташлады»:

—Шушы гәүдәң, төс-кыяфәтең белән үзебезнең мөселман кызын таба алмадыңмы?

Алмазар артык туры булуы өстенә кискенрәк тә кеше иде:

—Ә син, әти, беренче хатыныңа ничек өйләнден? Муеныңдагы тәресен күрмәденмени?

—Беренче хатыным Алсу минем!

—Әйдә, әткәй, хагын сөйләшик: синең унжиде яшендә үк өйләнгән беренче хатының Ольга! Ул синеке!

Имәндә икән чикләвек!

Кеше төкереген күрмә, изүеңә маңка төшкән, диләрме әле! Хак сүзләр! Йә, Алла!

Яшәп-яшәп тә акыл керми безгә...

Әллә озаграк яшәгән саен ул акыл дигәннәре, челләдәге ялгызаерым күл кебек, гел саега бара микән? Алай дисәң, каян килә бу әллә нинди уйлар? Алар бит акыл-ми эшчәнлеге...

...Әйе шул, Ольганың тәресе муенында иде. Ә Зоя такмый аны. Алга таба киленен яратып, үз итеп өлгерде Мөхәммәт, Зоя бит кайбер яклары белән Алсуны искә төшерсә, гәүдәсе, төс-кыяфәте, бигрәк тә холкы-гадәтләре Нәфисәне күз алдына китереп бастыра иде.

Зоя аңа йомшак-бәрхет тавышы белән:

—Әти, әти...—дип кенә торды. Чиста-пөхтә булды, йорт эшләреннән бер дә чирканмады. Тагын ни кирәк!

Эх, карт юләр!

Унжиде яшьтә Азак дингезе буенда «поляк гүзәле» Ольгага өйләнүеңне «яшьлек юләрлеге» дип атасаң, инде картаеп беткәч, төпчек улыңның керәшен кызы Зояга өйләнүенә каршы төштең.

Акылсыз дип кем әйтмәс сине!

Бик акыллы, тәкъва мөселман булсаң, әнә кызыңны татар егетенә сакларга иде! Ә ул мәктәп бетерүгә, бер мафиоз урыска кияүгә чыкты. «Яңа урыс»ка... Кияү аның Нәфисәсен «теща Анфиса» дип кенә йөртте, кызы Алсуга «Анна» дигән исем кушты, ә Мөхәммәт аның өчен «деда», «старый» иде.

Мөхәммәткә кызның гамәле сау тешнең сызлавы булып тоелды.

* * *

Алмазарның ике катлы кирпеч йорты... Йорт тирәсендә дистәләгән машина. «Мерседес», «Волга», «Жигули», «Ока»лар һәм бер автобус...

Монда берьюлы өч бәйрәм уздырырга жыеналар:

—Мөхәммәт 2001 елнын гыйнвар башында ун дистәсен тутырды!

—Алмазар белән Зояның көмеш туйлары: алар шәп яшәделәр һәм яшиләр. Алмазар Зояга: «Жаным!»—дип кенә торды. «Жаным» дигән жүнле иргә хатын-кыз ярты жанын бирә.

—Төзүче Алмазар белән укытучы Зояның хезмәт стажы да егерме биш елдан узып китте. Әле үзен быелгы хисап-сайлау жыелышында «Нократ» авыл хужалыгы әртиленә рәис итеп тә куймакчылар икән.

Биек түшәмле кунаклар залында сигез өстәл «П» хәрефе рәвешендә тезелгән. Алар өстендә—сый-нигъмәт, төрле-төрле кабымлыклар, «Баллысу», «Боржоми», «Шөн» сулары. Пычаклар, кашык, чәнечкеләр юеш-коры, салкын-эссе, симез-арык, төкле-шәрә кулларның үзләренә кагылуларын көтеп ята. Хатын-кызлар мондый мәжлесләрдә, өстәл артына утырганчы ук, әллә каян килә торган күпсүзлелеккә, такылдыклыкка дучар булып, бер-берсенең күлмәк-костюмнарына күз салып, алтын йөзек, алкаларына үзләренчә бәя биреп, верандада туктаусыз гәп куерталар. Ирләр бакча ягында, лапас артында сигарет көйрәтә. Һәркайсының йөзендә олуг мәжлесләр, затлы кешеләр, югары түрәләр жыелган истәлекле очрашулар, бүләкле бәйрәмнәр, Мактау кәгазьләре, орден-медальләр бирелә торган утырышлар алдыннан була торган сәеррәк эчке бер тантана.

Кунакларны йортка чакырдылар...

Һәркем тезеп куелган йомшак төпле урындыкка үз урынын чамалап чүмәште. Түрдә Мөхәммәт, анын уң ягында Алмазар белән Зоя, сул кул якта хатыны Шәрифә белән Шәрәфетдин.

Алардан ерак та түгел, берничә зуррак түрә, күкрәкләрен киереп, аркаларын йомшак артлы урындыкларга терәгән.

Мөхәммәт мондый күп кешеле мәжлесләрне өнәп бетерми иде, шуңа ул шактый гына дулкынланды, ап-ак кыска чәчләре төбенә тир бәрде, урындыгында да иркенләп һәм иплe генә утыра алмады, боргаланды, борсаланды, борчылды.

Кемдер, түрәләрдән берәү булса кирәк: «Бабай сүз әйтсен әле!»—дигәч кенә, әлеге мәжлеснен гади бер ашап-эчеп утыру гына түгел, ә тантаналы вә кирәкле, әһәмиятле һәм кадерле бер жыелып утыру икәнен аңлады. Уллары аңа икесе ике яктан карадылар:

—Сөйлә, әткәй!

—Ни әйтим? Бер сүз әйтү өчен дә бер гомер яшәргә кирәк.

—Үз сүзеңне әйт!—диделәр уллары.

—Калдымы икән бездә үз сүзем дигән сүз?

—Менә син әйтсәң, калган була!—диде кискенрәк, яшьрәк, бераз тәкәбберрәк Алмазар.

—Зарланма, әткәй, ит ашыйбыз әле. Аллага шөкер!—дип көлде бераз беркатлырак, әмма ачык жанлы, инде житмешен тутырып килсә дә, һаман да көр күнелле калган Шәрәфетдин.

Мәжлестәшләр, Мөхәммәт һәм анын ике улының сөйләшүләрен ишетмәсәләр дә, болар арасында ниндидер бәхәс бара бугай диеп, бераз сагаеп калдылар. Шуңамы хәл киеренкерәк төс алгандай итте. Мондый чакта житәкче агайлар «дилбегәне үз кулына алуны» мәгъкуль күрәләр.

—Сүз бирелә,—диде районның хакимият башлыгы.—Сүз бирелә Шөн авылының атаклы кешесе, илле ел тегермәндә эшләгән, дүрт ел янгынчылар башлыгы вазифаларын үтәгән йөзьяшәр Мөхәммәт абзый Болгареевка.

Монда инде бернишләп булмый. Мондый вакытта ык-мык килеп тора алмыйсың. Мөхәммәт,бераз бөкрәя башлаган озын гәүдәсен күтәреп,аягына басты. Аны беренче күрүчеләр аһ итте:

—Мондый озын буй мәжлестәгеләрнең берсендә дә юк!

—Карале, әl Картка йөз тулган инде, ә кыяфәтенә карап сиксәннән артыкны бирерлек түгел!

—Пәһлеван бабай бу!

Мөхәммәт бераз уйланып торды:

—Озак яшәсәм дә, аз сөйләрмен,—диде ул, ниһаять. Анын бу сүзләрен кул чәбәкләп каршы алдылар:

—Картта акыл да нык икән әле. Әйтә белә бу бабай...

—Ашау эшне калдырмый, ашамау эшне калдыра,—дип дәвам итте Мөхәммәт.—Шулай диеп моннан сиксән еллар элек Азак дингезе буенда балык сөзгәндә әйткән иде миңа Хөснимәрдән агай. Ул дәрвиш, илгизәр, фәйләсуф кеше иде. Оланнар! Бүген безне зурлап җыелгансыз икән, ашагыз-эчегез, уен-көлкеләргә урын бирегез, бер-берегезне мактагыз һәм мактаныгыз! Ялагайланмагыз гына... Бер гасыр башыннан икенче гасыр башына күчеп яшәгән кеше буларак, тагы бер киңәшем бар: үзегезне яклый алыгыз һәм халыкка терәк булыгыз! Бары үз-үзләрен яклый алганнар гына халыкка да терәк булачаклар. Монысы—бабайлар сүзе. Әмма... Хәрәм байлыкка омтылу—кешене акылсызландырып кына калмый, ә, иң беренче, аның милли аңын томалый. —Яңа гасыр киләчәк... Кансыз озынборын кан эчүдән шартлап үләчәк... Бу—Малмыж мулласының яшьтәшем һәм авылдашым, якын дустым Заһидуллага әйткән сүзләре...

Шушы урында тукталып, ул берәм-берәм ике улына да карап алды һәм дәвам итте:

—Ә хәзер үз сүземне әйтәм...

Аннан беравык кына тын торды һәм, тирән сулап, өстәде:

—Мәче булып туган—мәче булып яши, эт булып туган—эт булып яши. Кош кош булганга оча, гөлчәчәк гөл булып үсә. Каен наратка әйләнми, имәннән өрәнге ясап булмый. Без татар булып туган—татар булып яшик! Сак булыйк—халыкларга бертөсле битлек кидерү бара... Тагын...

—Барыбыз да бер нәрсәне онытмыйк, Кешелек Хәтере: Мәхәббәт, Яхшылык, Матурлыкны да, Нәфрәт, Яманлык, Мәкерне дә һәрвакыт истә тота.

«Ничек теләдем шулай яшәдем вә киттем дә бардым, миннән соң дөньясын ник туфан басмый», дигән бәндәләрне дә Җавап һәм Җәза көтә. Монда булмаса—тегендә...

Мин үз сүземне әйттем, оланнар!

—Вот так да!—диде район хакимияте башлыгы, тел шартлатып һәм шаккатып. Ул бу «яшен яшәгән карт»тан мондый сүзләр көтмәгән иде.

—Минем әткәй үзе фәйләсуф ул!—диде Мөхәммәтнең аркасыннан кагып Алмазар. Аның күз төпләренә яшь бәрде. Бераз кырысрак улыннан моны көтмәгән Мөхәммәт үзе дә йомшап китте. Мәҗлескә җыелганнар гөрләтеп кул чапты. Картның алдына бер фужер шампан шәрабе куйдылар.

—Шушы яшькә җитеп эчмәгәнне!—диде ул көлеп.

—Әйттең, әткәй!—диде Шәрәфетдин аны яннан кочып.—Аллага шөкер, ит ашыйбыз!

Халык гөрс итте...

Мәҗлестәшләр елмаю-ялагайлану, көлү-мактау, уен-мактанулар аша Ашауга вә Эчүгә күчтеләр...

Мәҗлес гөрләде: кемдер нидер сөйләде, кайсындыр нигәдер сүзеннән туктаттылар, икенче берәүне көчли-көчли «рич» әйттерделәр, тыйнаграк урында утырган «мокыт»ка күпме сорап та сүз әйтергә ирек бирмәделәр.

Мөхәммәт арыды, мондый шау-шулы мәҗлесләр өчен түгел иде инде ул. Юк, түгел! Һәрнәрсәнең үз вакыты бар: яшәү—яшьнәүнең дә, үлем—сүнүнең дә...

Ул акрын гына торды да үз бүлмәсенә кереп ятты.

Кичә алар олы улы белән мунчада чабынып-юынып чыкканнар иде. Иң башта «бабай бабайны» чапты. Шулай диде Шәрәфетдин, гомер буе дежур сүз итеп җанында йөрткән «Аллага шөкер, ит ашыйбыз әле»,—дип тормады:

—Ят, әткәй, ләүкәгә... Йә, Раббым! Бабай бабайны чапсын әле,—диде. Нү!—дип тә куйды әле.

Әз-мәз суынып алыйм, сулуны яхшыртыйм дип, алгы якта утырып торды Мөхәммәт. Шунда күкрәгендә нидер шырт итте. Карт йөрәген тотты, аның хәле авырайды...

«Йөрәккә урнашкан җанның җебе өзелә башлады бугай»,—дип уйлады ул.

Шәрәфетдин мунчадан аны җитәкләп алып кайтты, җылы чәй эчерде,

өстенә калын юрган салып йокларга яткырды. Шул йокы аңа тагы ниндидер яшәү көче кертте бугай. Иртән ул аякларында таза гына йөри иде инде... Юкса: «Китү шушыдыр»,—дип уйлый башлаган иде. Аң томаланган иде бит. Акыл китте.

—Шагыйрьләрдә Акыл тайпылышы була, аларда Ан Илаһилыгы!—дигән иде Хөснимәрдән агай. Һе, Акыл тайпылышы, ә...

... Ишек шакыдылар:

—Керергә мөмкинме?

—Керегез, кер!—диде Мөхәммәт.

Бүлмәгә тәбәнәк буйлы, чәче маңгайдан коела башлаган, бөркет борынлы, матур йөзле, зур күзле кеше килеп керде.

«Кырым татары Мәхмүдбәк!—дип уйлап куйды Мөхәммәт.—Гәүдәсе генә җыйнаграк... Тагын—сөйләшү үзгәрәк»...

—Мин Казаннан! Шагыйрь Мәлик Әгъләм булам!—диде кунак.—Татарның татар булып калган шагыйре!

—Ишеткәнем бар... Кайсыдыр журналда рәсемең белән шигырьләрең бар иде.

—Рәхмәт сезгә, бабай! Сез милли иман, милли идеябез сүзләрен әйттегез!

—Милли иман, милли идея сүзләренә төшенеп җитмим,—диде Мөхәммәт.

—Халкыбызның үз кыйбласы, якты киләчәге өчен көч салу, тырышу ул!—диде шагыйрь.

—Ә!—дип куйды карт.—Хөснимәрдән агай аны «татарлык» дип атый иде.

* * *

... «Бер дә үзгәрмичә, бертөсле торган кешеләрдән куркыгыз, болар—таш йөрәклеләр»,—дигән иде Хөснимәрдән агай.

«Йә, Алла!

Мин дә менә һич тә селкенмичә, бертөсле ятып торам ич. Әллә мин дә, әйе!—Мин дә таш йөрәклегә әйләнеп барам микән?»—дип, шыр җибәрде карт.

Аннан соң ул, урынга яткач, «теге якка чыгып йөргәләүләр»гә ияләнеп китте: әз генә черем итмеме, аның җаны бакый дөньяга барып кайта. Бу «барулар» гадәттә төш күрү рәвешендә... Әмма да ләкин... Хикмәт бит төш күрүдә генә түгел иде, чөнки шушы төшләнеп-саташып ятулар вакытында ул ниндидер бүлмәгә килеп керә һәм инде күптән үлгән ата-бабаларын, әни-әбиләрен очрата, алар белән сөйләшә, фикер алыша. Кайвакыт сүзсез генә утырып торалар.

Шулай бер «теге якка чыгып киткәч», ул дистәләгән кешеләр арасында Хөснимәрдәнне дә очратты һәм «бәлшәвиклар влачны алган елны» ук үлеп киткән агасыннан сорап куйды:

—Хөснимәрдән агай, бу нинди бүлмә соң?

—Үлгәннәр белән исәннәр очраша торган урын бу,—диде тегесе.

—Ә кайда ул әлеге урын?—дип сорарга җөрьәт итте ул. Хөснимәрдәннең җавабы кыска булды:

—Исәннәр өчен—Күктә, үлгәннәр өчен—Җирдә...

Нишләп Хөснимәрдән агай аның төшләренә еш керә икән? Кайсы ягы вә нәрсәсе белән аның күңеленә шулай тирән һәм матавыклы булып кереп калды ул? Югыйсә озын гомер юлында ана әллә кемнәр очрады ич! Араларында зур тәэсир калдырып, күңелгә мәңгегә уелганнары да юк түгел.

Нигә Ольга аның төшенә бер дә кермәде? Нигә аның эзләре дулкынсу юган комдагы тамга-билгеләр кебек юкка чыкты? Әллә Ольга, үз хыянәтеннән үзе куркып, аның исенә дә килмәде, хәтер түренә дә кереп карамады микән? Ә бит...

Кырым татары, батыр йөрәкле һәм кыю Мәхмүдбәк аның төшләренә еш керде, исенә гел төшкәләп торды. Берсендә хәтта үзенең Алиясе белән

теге Сәләхир елгасы буенда күрде ул аларны. Алия елгага ташланган «Ташлама»кыясын да күрде. Ә бит Сәләхир елгасы белән «Ташлама» кыясын үз гомерендә бер дә күргәне юк иде. Шулай булгач, кайсы дөнья чын соң? Син яшәп ятканымы, әллә төшләргә кергән теге дөньямы? Ул бит яшь чагында төш күрүгә бөтенләй әһәмият бирми иде: төш күрүләр дөньясы түгел, ә өннәр дөньясы кыйммәтлерәк, кадерлерәк, газизрәк күренә иде аңа. Иртән уянгач, төшемме бу, өнемме дип тә ятмады: «Уянгансың икән, тор!»—дип, бисмилласын әйтеп, аякларына басты.

Алсу да еш керде аның төшләренә. Иң авыры: аның карт алмагачтан егылып төшеп, баш чүмече белән җирдә яткан ташка бәрелеп, харап булуы иде...

Их, Алсу, Алсу! Синсез хәзер дә ямансу...

Күңелемдә нинди авыр хисләр, кырып та ала алмаслык кара кайгы калдырып киттең син. Мин үз гомеремдә бер генә затны да шулкадәр сөймәдем. Ольга—яшьлек юләрлегем иде, Бибинур—ничарадан бичара чагымда башым әйләнеп, рухи авырып йөргәндә бер терәк булды, ә Нәфисә минем йортыма үз аяклары белән килеп кергән хатын. Аны да яраттым, ләкин үземчә...

Дөресен генә әйтәм, Алсу: «Мин аларның берсен дә хурламыйм. Ничек дигән әле борынгы бабаларыбыз? «Өлешемә тигән көмешем»,— дигәннәр! Әнә, мина Азак дингезе буена килеп төпләнгән сиксән яшьлек карчык Серафима әби дә гашыйк булган ич. Үзенең гомерлек ире Теодорга охшатып...

Мин өмми—белемсез кеше түгел, укырга артык зур хирыслыгым вә җан ихтыяҗым булмаса да, тормышны, тулы гасыр яшәп, тәҗрибәләрем аша аңларга тырыштым. Бу дөньяда минем кадәр озак яшәгән кеше үзе үк бәхетле инде ул, шуна мин Яктылыктан Караңгылыкка бер дә борчылусыз, аптырауларсыз, күз яшьләремне коймыйча, хәсрәтләнмичә, ипле бер иркенлек белән күчәм. Дөрес, элегрәк мин бу гәүдә-тәнемне ике-өч аршин җиргә тыгып куюларына эчке каршылык белән яшәдем, бу гамәлдән куркып та йөрдем. Аллага шөкер, хәзер мин бу яктан да тынычлык, иплелеккә ирештем. Ә бу үзе үк гүзәл нәрсә, матур вакыйга. «Шулай яшәп, шулай китсәң иде дөньядан» дигән сүзләрне гомер буе күңелемдә йөрттем. Бөек шагыйрь бит аларны барыбыз өчен әйтеп калдырган.

Яшәүдән туеп китеп тә булмый, әлбәттә. Бу—Аллаһы алдында да, халык алдында да, балаларың, туганнарың алдында да зур гөнаһ. Адәм баласы дөньяга елап килсә дә, елап-сыкрап китәргә тиеш түгел! Чөнки китү—үзе үк Бөек Күчеш ул. Аңа битарафлык, чарасызлык, күңел төшүләр, кәефсезлек белән дә карарга ярамый дип беләм. Һәрхәлдә, соңгы елларда шулай гоманлап яшәдем. Гоманлаулар Хакыйкатькә алып бара. Яшьлегемдә Азак дингезе ярларында, суларында да булдым. Картлыкта да Азак Дингез була. Ул—китү...

... Картның хәле бик киткәч, Казаннан кунакка кайткан табиб Талипны, профессор Хәзрәтовны чакырдылар.

—Йә, бабай!—диде ул керә-керешкә елмаеп.—Сәламәтлегең әйбәттер бит? Ир булсаң, чиргә ирек бирмә! —Кияү кеше елмаеп-көлеп кенә сөйләшә. Үзе ифрат ягымлы. Шуның өстенә барлык Хәзрәтовлар кебек чибәр! Булса да булыр кеше, әмма моның кадәр булмас!

Мөхәммәтнең хәле хәл түгел иде инде, хәлле кеше урын өстендә ятамыни.

—Хәл бер мәлне кө тә,—диде ул фәйләсуфлар гыйбарәсе белән, сүзләренә күпмедер дипломатия дә кыстырып.

—Ә нинди мәл ул?—дип кызыксынды табиб Талип.

—Кайтам...

—Кая?—дип аптырады табиб.

—Теге дөньядан килдем, шул дөньяга «Кайтам»...

Табиб, атаклы профессор Хәзрәтов, сискәнеп китте.

—Юк, юк. Што син, бабай. Никак, кайтмыйсың әле. Ә безне, врачларны, кая куясың? Без сине терелтәбез. Син, никак, нык бабай бит.

Тагы ун ел яшәрлек энергиян бар. Менә кыйммәтле яхшы дарулар алып килдем. Шуларны да кабып җибәрсәнме. Никак, шәп дарулар. Все будет отлично! Син бит безнең авылда иң озак яшәүче. Син әле рекорд куясың бездә озак яшәү буенча. Никак!

—Рекорд куяр өчен яшәмиләр,—диде карт.

—Риза. Никак, но согласен...

Карт дәшмәде...

—Ә шәп дарулар?.. Алар бит, никак,—диде Талип.

—Иң шәп дару—һава,—диде карт. Тагын шәп дарулар: тәмле чәй, чишмә суы, җиләк-җимеш, яшелчә, татар бәлеше, өчпочмагы, чәкчәге, токмачлы тавык ашы, ат ите, казылык, күзикмәк, дурчмак...—ул санап арды.

—Но,—дип каршы төште профессор.—Синдә чир бар. Син бабай, никак, авыру. Синнән чирне куарга кирәк. Никак, куып чыгарырга!

—Чирне мин тирләп тә чыгардым... Сулыш чыгарып та чыгардым... Әнә, Чыкмый Торганы кергән!

... «Тегеләякка йөргәләүләр»,—дигән иде... Әйе, дигән иде Хөснимәрдән агай Азак дингезе буена балык сөзәргә барганда. Әй, ахмак чак! Әй, тиле яшьлек! Үзең дөрес, сүзең-уең дөрес булмаган чаклар!

«Теге якка йөргәләүне» Мөхәммәт ул вакытта гап-гади генә итеп, акча эшләргә читкә чыгып эшләп йөрүләр дип кенә аңлаган иде бит. Бүгенчә әйтсәк—«шабашка!».

Ә «теге якка йөргәләүләр»—хәтәр нәрсәләр икән ул. Иң беренче бу «йөргәләүләр»—үткән көннәренә, яшәлгән елларыңа кайтулар икән ич! Ә икенчесе...

Монысы тагын да серлерәк һәм күпмедер дәрәҗәдә куркынычрак та. Бу—төшләреңдә булса да «теге дөньяга кереп-чыгып йөрүләр» икән! Йәисә шул ук төшләреңдә кемнәрнеңдер (әлбәттә—үлгәннәрнең!) сиңа «кайтып-китеп йөрүләре»...

Йә, Алла!

Исәннәрнең «Кайтулары» була инде...

Ә менә... Үлгәннәрнең «Кайтулары»...

Менә бүген дә Хөснимәрдән агай төшкә керде. 1917 елны, «большевиклар влачны алган сәнәдә», вафат булган сәяхчан, дәрвиш...

Ниләр диде соң ул аңа? Менә ниләр:

—Тыштан—боз, эчтән—ут бул!

—Тыштан—куян, эчтән—арыслан бул!

—Тән хәрәкәтен Җан хәрәкәтенә туры китер!

—Талант Күктән бирелә... Аны исраф итмә!

—Тудыңмы—Яшә! Үлем—синең эш түгел...

—Тайпыл-тайпылма: Яхшылык та, Явызлык та үзеңнән...

—Тап һәм таны: бер хәрефтә Бөек Сүз башы ята. Ишет һәм аңла: бер авазда—Даһилыкка ирешерсең...

Нишләп катлаулы сөйләште ул? Фәйләсуф булгангамы?

... Кич якынлаша... Ургылып-ыргылып караңгылык инеп килә...

—«Сизенәм: мин Вакыт аша үтеп барам, ә Вакыт минем аша уза тора...»—дип уйланды Мөхәммәт.

«Инабәт» дип язган иде Хөснимәрдән агай үзенең дөнья йөреп вә күреп, майланып-каралып беткән блокнот-дәфтәренә.. Мин Инабәтнең—Өмет, Ышаныч, Инану икәнен беләм, аның һәркемдә Яшәү Көче, Яшәү Үҗәтлеге тудырганын да беләм. Юкка гына йөз ел яшәдеммени мин?!

Ә менә Хөснимәрдәннең «Не»сы белән «Инабәт»не ничек аңларга? «Не»—Яктылык һәм Караңгылык, шулай булгач, «Не» фани дөнья һәм бакый дөнья дигән төшенчәне дә үзенә ала. Инабәтне дә «Не» белән аңлатырга була. Бу—дөньядагы бәхетенә, яшәячәк матур көннәренә, алдагы гомеренә өмет тотып, ышанып яшәү генә вөҗдан иркенлеге, намус хөрлеге, күңел көрлеге китерми әле ул дию, чөнки әлеге хәл хәяттә ярты бәхет кенә. Тулысынча бәхетле булу өчен Аллаһы һәм Теге Дөньяга да өмет итеп, ә тәгаене: ышанып-инанып яшәргә кирәк. Шул очракта үлем гади

бер кучешкә—елгада каекта бу ярдан теге як ярга чыгуга—гаҗәеп бер Яктырышлы Гармоник хәл-халәткә әйләнә...

Нәрсә дигән иде әле Хөснимәрдән Фәйләсуф?

—Тап һәм таны: бер хәрефтә Бөек Сүз башы ята. Ишет һәм аңла: бер авазда—Даһилыкка ирешерсен...

Таптым һәм таныдым: «Эн»—Караңгылык, «Йо»—яктылык. Ә «Не» үзе нәрсә соң ул? Ул бит «Эн» һәм «Йо» авазларыннан гына тора. «Эн» һәм «Йо»? Энйо!.. Энйо. Дөнья...

«Йә, Раббым! Тулы Дөнья дигән аваз—аһәң түгелме соң бу?»—дип уйлый алды актык сулышын алган Мөхәммәт.

## Ахыр сүз

Хөрмәтле укучы!

Бу әсәрнең яртысы 1978 елның октябрь-ноябрь айларында язылган иде. Шуннан соң ул егерме дүрт елга якын китап шкафында тузан җыеп ятты. Мин аны быел Яңа гасыр килү белән кузгаттым, чөнки, гомер булганда, узган гасырдагыны бу гасырда күтәреп карау, язганыңны кабат язып чыгу бер дә начар эш түгелдер, дим.

Менә бу эшне дә очладык...

Әмма бу гади очлау гына түгел, ә, дүрләп-дүртләп очлау? Нәрсә ул дисезме? Шушы «Инабәт» романы белән минем, ягъни Рафаэль Сибатның, «Кайту» тетралогиясенә соңгы нокта куелды, димәк ул тәмамланды. XX һәм XXI гасырлар кисешендә-кучешендә язылды ул романнар. Геройлары да—гасыр кешеләре. Аларның өчесе ошбу дөньяда озак кына гомер итеп китәләр. Габдулла сиксән яшькә кадәр яши, Заһидулла—туксанга, ә Мөхәммәт йөзгә үк җитә. Һәр образның—үз идея нагрузкасы, эстетик эшләнеше, эмоциональ тәэсире, әдәби көче, дөньявилыгы, типиклыгы, кире яклары бар.

Шунысы да кызыклы: «Кайту» тетралогиясенең аерым романнары өч журналда басылды: «Исабәт»—«Казан утлары»нда *(№№ 11, 12, 1997ел)*, «Атлар рәнҗеше»—«Идел»дә *(№ 10, 11, 1999 ел; № 5, 2000 ел)*, «Ялгызак»—«Казан утлары»нда *(№ 4, 5, 2000 ел)*.

Ихтирам белән иң яхшы теләкләрдә калып:

Рафаэль Сибат.



## Рифә Рахман

### Ялгышканмын

Күзләреңдә йолдыз
Яна дигән идем...
Бергә янулардан
Мәхрүм иттергәнсең.
Күкрәгеңдә гөлләр
Көлә дигән идем,
Син бит аларны да
Шунда киптергәнсең.

Чәчләреңне җилләр
Сөя дигән идем:
Сөю җилләренә
Инде рөхсәт беткән.

Кояш бага, дидем,
Битләреңә күктән—
Шул көн үпкә сүзең
Күккә менеп киткән.

Күзләреңдә йолдыз
Яна дигән идем.
Алар анда бары—
Тоткын икән, тотык.
Сүрелмәсен өчен
Якты-җылылары,
Кала икән ялгыш
Кунган нурны тотып...

*

Гади төнне серле ясар өчен,
Утның була шәмгә әлдергәне,
Җилнең була, көч-куәтен сынап,
Син кабызган шәмне сүндергәне.

Шәмнән шәмгә күчкән утлар да бар.
Бар аларның качкан, йөгергәне,
Сукбай җилләр кебек, дөньялыкта
Үз-үзеннән кеше көлдергәне.

---

Рифә РАХМАН—*шагыйрә, «Керфекле тәрәзәләр», «Күзләрең төймәләнсә» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Кем кабызган аны—Бөек көчме?
Күзегездә утның серлесе бар.
Үз сереннән үзе авырайган...
Аның миңа нидер сөйлисе бар.

Көтәсезме, көч-куәтен сынап,
Ялгыш капкан утны сүндергәнне?—
Өйне җылы, серле ясар өчен,
Учакка ут Сездән элдергәнне?

## Элек һәм хәзер

Табигатьтә бар нәрсә дә—тигезлектә!
Юнаннарда Аллалар да —һәр җенестә!
Зевс, Лето, Аполлон һәм Афродита...
Омтылганнар үзләренчә гаделлеккә...

Берсе оста булган аның җыр-сәнгатькә,
Икенчесе дан-шан алган мәхәббәттә.
Никахны—җан, тән теләген буйсындырган
Бер алиһә! Афродита ул, әлбәттә.

Хәтта Зевс (!) башын игән, ул килгәндә,
Өч алиһә буйсынмаган нибарысы!
Кочаклаган һәм елмайган, кирәк чакта
Әсир иткән татлы сүзе йә тавышы.

Тик матурлык белән генә җиңә алган,
Кулына ук-җәя, хәнҗәр еш алмаган.
Гадиләрне, галиләрне яраткан ул—
Андыйлардан мәрхәмәтне кызганмаган.

Алиһәләр һәм аллалар ярышканнар.
Чын мәгънәдә хәтта бил дә алышканнар.
Җырлап, уйнап, сөеп, назлап яшәгәннәр
Гыйш-гыйшрәттә үз тиңнәрен табышканнар.

Олимп тавы башларында хакимлекнең
Күктә, суда, җирдәгесен булдырганнар.
Ә Зевстан—җефетләре—матурлыкны
Яклар өчен, алиһәләр тудырганнар...

...Пәйгамбәрләр—диләр, бездә—ирләр генә,
Ә Алланың юк җенесе һәм өммәте.
Әйе! Булса ул да әгәр ирләр кебек,
Кылыр идемени—чиксез мәрхәмәтне?!

Салыр идемени җәннәт—аналарның
Аягының асларына, алдына ук?!
Нибарысы яхшы шигырь генә яз син—
Җефетеңнең күзләреннән атыла ук.

Ә электә... шул ук Гомер (!)—менә чын ир!
Таң калырлык—иҗат иткән Афинасы:
Зевска тиң һәр нәрсәдә илаһ кызы—
Тапкырлык һәм гадел сугыш алиһәсе.

Гаделлекне көтәм көчле җенестән мин:
Булмасын ул бары бәдән белән көчле!
Башкаларның башларыннан күтәрелмәс
Галим, шагыйрь... киң күңелле бер ир кеше!

# Publisistika
# Публицистика

## Айдар Хәлим

# КЫРЫМДА КҮРГӘННӘРЕМ

### Казан, Акмәчет, Кияү-кала...

КҮПТӘН, бик күптәннән чакыралар иде Кырымга мине дусларым. Үземнең дә ул тарафларда булмаганыма инде алты ел тулып узган икән. Мин анда 1997 елда Йошкар-Оладада чыгуы белән кулга алыначак «Убить империю!» китабына мәгълүматлар тупларга барган идем.

Кырымда бу арада нинди яңалыклар күзгә чалынган да, казантатар һәм кырымтатар тәрәккыятендә чагыштырырлык нинди үзгәрешләр булган соң? Ягъни, кайсыбыз «алга киткән» дә, кайсыбыз «артта калган»? Депортацияләнгән халыклар арасыннан, берденбер дип әйтергә мөмкиндер бәлки, кырымтатар халкын кире туган җиренә дәүләт түгел, ул үзен-үзе, үз көче белән кайтарды. Үз көче белән, нормаль кеше акылы күз алдына да китерә алмаган каршылыклар аша, җырда җырланганча, «чит илләрдә күп йөрегәч, үз илләре ят булган» иленә кайткан милләтнең яңадан тернәкләнүе, тамыр җибәрүе—Берләшкән Милләтләр Оешмасының социология институтлары өйрәнергә тиешле ФЕНОМЕНАЛЬ КҮРЕНЕШ. Минем милләтнең «үзенә кире кайту» лабораториясендә галәми микроскоп белән шушы ук милләтнең куанычлы һәм үкенечле күз яшен күрәсем килде. Авыр нәрсә ул мондый күз яше. Хәтта туган җиргә кайту куанычыннан туганы да авыр. Күтәреп булмаслык авыр. Андагы тоз кояш нурында эреми. Андагы җәүһәр Җир Шарының бер генә банкы сейфларына салынмый. Чөнки ул банкрота чыкмый. Кем идек? Кем булдык? Яшермим, шушы һәм башка бик күп сораулар борчый иде мине. Аннан, бер уңайдан, биш яше тулып килгән Кадрия кызыма Кырымны, Кара диңгезне күрсәтермен дигән хыялым да бар иде. «Аны әнисе белән диңгез ярындагы берәр куышка алып барып урнаштырам да, берничә көн үз эшләрем белән Кырым буйлап сәяхәт кылып алам»,—дип уйладым мин.

Һәм шулай булып чыкты да.

...Июль башлары иде.

Симферополь (алга таба без аны татарча үз исеме белән Акмәчет дип йөртербез) тимер юлы вокзалында безне борынгы кырымтатар дустыбыз Бекир Нематуллаев үзенең оныгы Эдем белән каршылады. Бекирнең хатыны Рәзимә—Әлмәт кызы. Никадәр уңган, игелекле, алтын бәрабәренә торган кешеләр!.. Аларга карап, Казан ханлыгы заманындагы Казан татары белән Кырым татары арасындагы бергәлек менә шундый классик югарылыкта булгандыр, дип уйлыйм.

Рәзимә белән Бекирнең ике баласы бар—кызлары Сусанна, уллары

Арсен. Сусанна һәм аның кияве Исмет Таврия дәүләт университетын кырымтатар теле һәм мәдәнияте буенча тәмамлаган белгечләр. Сусанна әлегә өйдә утыра, уллары Эдем белән Билалны үстерә. Исмет исә, соңгы елларда алып-сату, коммерция белән шөгыльләнгәнгә күрә, юлдан кайтып та керми диярлек. Бүгенге көндә яшь гаилә ата-аналары ярдәме белән алардан ерак булмаган урамда үзләренә йорт җиткереп килә...

Рәзимә белән Бекирнең уллары Арсен медицина институтында укый. Әлегә өйләнмәгән. Ата-ана, шул ук безнең Казан татары сыман, уллары «маржага» өйләнә күрмәсен иде дип хаклы рәвештә ут йота.

Бекир белән Рәзимә заманында Чаллыда яшәп, КамАЗда эшләгәннәр, аннан, туксанынчы еллар башында, кырымтатар халкы һәммә яктан кыр казлары сыман бер бауга теркәлеп туган тарафларына тартылгач, Кырымга кайтканнар һәм, үзләре әйтмешли, «сусыз далада су, утсыз салада ут табып», йортсыз-җирсез, эшсез, пропискасыз («паспортсыз»), татар кичергән барча авырлыкларны кичереп, Акмәчет янында Кырым татарлары нигезләгән Фонтан бистәсендә менә дигән йорт төзүгә ирешкәннәр.

Мин 1996 елда ул чакта әле төзелеп бетмәгән йортта һәм аның алдында гына җәйрәп яткан чикләвек үзәнлегендә «Җәмилә» дигән шигыремне язган идем.

Берничә көн Акмәчеттә яшәп, Рәзимә белән Бекирләрдә кунак булганнан соң, без алар ярдәме белән җиңел генә Кара Диңгезнең Лукыл Борыны дигән борынындагы Хаҗи-Булат (Угловое) авылы янындагы ял базасына урнаша алдык.

Әйе, хәзер, кырымтатар халкы туган туфрагына кире әйләнеп кайткач, үз авыллары һәм шәһәрләренең тарихи исемнәрен кире кайтара башлаган. Гомумән алганда, урыс-татар милләтләреннән торган Кырым җәмгыятендә, безнең карашка, бу хакта урыслар тарафыннан бер дә кирәкмәгән, урынсыз тарткалаш алып барыла. Ни өчен дигәндә, 1944 елда милләтне куып алып киткәннән соң, барлык татар авыллары, бистәләре, шәһәрләренең исемнәре Звездное, Полевое, Красноармейское, Цветочное, Брянское, Почтовое, Песчаное кебек мәгънәсез, дәлилсез, тоссыз, дәресрәге, төче исемнәр белән алыштырыла. Мең ел буе Тозлы дип йөртелгән авыл соңгы кырык-илле елда гына Краснозвездное булып китә алмый бит инде! Менә шулай итеп, Угловое төбегенең дә кайчандыр «Хаҗибулат» булганлыгы ачылган. Береүләр аны горурлык белән Хаҗи-Булат ди, икенчеләр өйрәнелгәненчә һәм колонизаторларча киреләнеп, Угловое дип йөртә. Нишлисең, халык психологиясе шундый инде, монда дәвалану өчен вакыт кирәк. Әлбәттә, СССР, аннан Рәсәй хөкүмәтләре юньле, ике күзле хөкүмәт булса, аларның төп халкы булган урыс-славян халкы, Европаның, әйтик, немец халкы кебек тәрбияле, социаль оятлы булган булса, үзләре куып алып киткән милләтләр алдында гафу үтенер, илле ел сөргенлек бәясен, исән сакланган йорт-кураларны кире кайтарып, җимерелгәннәре урынына яңаларын төзеп биреп, шулар белән бергә тарихи атамаларны да аякка бастырган булыр иде дә бит... Кая инде ул! Монда буш даладагы палатканы кәрчин сибеп яндыралар. Бу «бик аңлашыла» да. Бер караганда, «оккупант» милләт сөргеннән кайткан милләтнең тарихи исемнәрен генә булса да кире кайтарырга теләве белән килешергә тиеш кебек. Әмма—юк, килешми оккупант, шуның өчен дә оккупант бит ул. Ул әле кайчандыр үзе басып алган халыкны «оккупант» дип атый хәзер, чөнки куылган, мескен халык кире кайтырга тырышып ята бит.

Кырымга бүген украиннар түгел, урыслар хуҗа. Анда украин хакимияте бик үтеп керә алмый әле. Кырым—ул урысларның мукшы Юрий Лужков күрергә теләгән һәм әлегә ул тудыра алган «Севастопольле» форпосты. Лужков Кырымда изелгән татарларга түгел, изүче офицерларга фатирлар төзи. Шуны «гаделлек» дип дөньяга кычкыра. Кырымның урыс телле газеталарында, нәкъ Казанның «Вечерка»сындагы кебек, урамнарга яңа исем бирү очракларында, гадәттәгечә, акыл сату башлана: вәт, имеш, бу татарларга ни җитми, нигә ул урамга яңа исем? Яңа исемле такталар язып элү өчен күпме буяу, акча кирәк, элек әйбәт иде, тыныч иде, беркем милләтеңне сорамый иде, фәлән-төгән... Мин Казан «Вечерка» сының баш мөхәррире—Татарстан мөстәкыйльлегенә Штанин, Грачевлардан да зуррак зыян салган, аның табутына соңгы кадакны каккан татар Хасбулат Шәмсетдинов, туган Казан татарларын батырганнан соң, Грач, Бахарев кебек шовинистлар белән укмашып, хет Кырым татарларына тимәсен иде дип теләкләр телим.

Ничек кенә булмасын, мин бу язмаларымда Кырым татарларының тарихи атамаларына тугры калу дөресрәк булыр дип уйлыйм һәм аларны, мөмкин булган очракларда, борынгы, дөрес аталышларында атарга тырышырмын.


*Бакчасарай урамнарының берсе*

Менә без таң белән Бекирнең яшел төстәге иске «Москвич»ына утырып, Хаҗибулат авылыннан Акмечет-Бакчасарай-Акъяр (Севастополь) юлы буйлап киләбез. Рульдә Бекир үзе. Рәзимә артта, мин Бекир белән янәшәдә утырганмын. Юл Кача елгасы (татарның «кача»сы урысның «убегать» диген сүзен аңлата инде) үзәне буйлап «кача-кача гына» бара да, сыртка күтәрелеп, Акмечеткә таба сыпырта. Кайдадыр астарак, Элмә («Алма») елгасы Акъярга (Севастополь) таба ашыга...

Юлдашларым сөйләвенчә, хәзер Кырымда хосусый төзелеш эшләре шактый сүлпәнәйгән. Болар барысы да акчага бәйләнгән. Әмма мин беләм, монда икенче, кире агым да хәрәкәткә килде. Әйтик, үткән гасырның туксанынчы еллары башында, әле «перестройка», «демократия» диген нәрсәләр чәчкә атып кына барган чагында, «депортацияләнгән халыкларга ярдәм» диген төшенчәгә карата караш сәяси яссылыкта иде. Америка Кушма Штатлары, Германия, бигрәк тә Төркия, Кырым татарларына ярыйсы гына ярдәм күрсәтте. Халыкара хәйрия фондларыннан килгән акча тулаем диярлек кайтучыларга йортлар төзүгә китте. Бу заманда хәлсез булган Рәсәй мондый ярдәмне үзе күрсәтә алмагач, дөресрәге үзе дә таланып яткач, әлегрәк—теләмәгәч, башкалар күрсәткән ярдәмнән көнләшеп, халыкара планда бу ярдәмгә аяк чала башлады. Бу инде Рәсәйгә хас булган «печән өстендәге эт»—үзе дә ашамау, башкага да бирмәү халәте иде. Нәтиҗәдә, «депортацияләнгән халыкларга ярдәм» шигаре тагын да шул спекулятив алкымга ятты, яшеренбатырын түгел, бу «ярдәм материясенә» сөлек кебек ябышып, аның «канын» эчүчеләр күбәйде. Европа Советы кебек оешмаларда «урындагы экстремизм, терроризм» белән куркытып, Рәсәй Кырымга булган ярдәмгә астан гына «ветолар» сала башлады. Нәтиҗәдә соңгы вакытта чит илләрдән кергән акча күләме кискен кимеде. Рәсәйдән ярдәм булмагач, Украинадан да бик чамалы булгач, чит ярдәм кысылгач, мескен милләткә бары тик үзенә генә ышанырга кала. Һәм ул шулай яши дә. Соңгы чорда кырымтатар бизнесының җанлануы сизелә. Ярыматауда алар төзегән офислар, икешәр-өчәр катлы коттеджлар күтәрелә...

Менә Вилино, Брянское, Передовое авыллары. Ул авылларны як-яклап Урта Азиядән кайткан милләттәшләребез «басып алган». Аларның озакламый, Ходай кушса, татар авылларына әйләнәчәкләрен раслап дигәндәй, мәчет манаралары калыккан. Шунысы кызык: һәр авылның башындамы, берәр читендәме, бер-берсенә су тамчысы кебек охшаган, әмма безнең карашка, йорт дисәң йорт, келәт дисәң келәт булмаган, кечкенә, рәт-рәт булып төзелгән сөер яңа алачыклар күзгә ташлана. Гафу итегез, алар штамп буенча ясалган бәдрәф алачыкларын хәтерләтә иде.

—Болар нәрсә?—дип сорыйм Бекирдән.—Кырым татарлары өчен төзелгән авыллар түгелдер бит?

—Тәзерләр сиңа Кырымда татар өчен йорт!—дип шаркылдап көлеп җибәрә Бекир.—Кырымның быел гына очып төшкән императоры коммунист Грачның «коммунизм төзелешләре» алар. Авылларны Кырым татарлары басып алмасын, янә урыс «поселенец»ларын китертеп, урыс халкының санын киметмәс өчен төзелгән йортлар алар...

Бер тапкыр малын монда, тарихи Ватанында, икенче тапкыр тегендә, сөргендә ташлап китәргә, инде туган туфрагына кайткач, эшсез, йортсыз-җирсез, пропискасыз яшәп, палаткаларына кадәр крәчин сибеп яндырылуга, яңадан кыйналуларга дучар ителгән татар милләтен нинди «гөнаһлары» өчен шулкадәр дә яратмаска, күрә алмаска, һәм аның сабыйлары өстеннән шулкадәр дә көләргә мөмкин?! Гафу үтенәсе, бар малын-җирен кире кайтарып бирәсе урында?!

Мин Вилино авылы мәчетенең хәнҗәр кебек биек манарасын күреп куанам.

—Безнең татарга иркенлек бирсәң, күккә дә алка тагар иде,—дип дәвам итә сүзен Бекир.—Әмма Грач татарларның җәмәгать исәбенә үзләре төзегән һәр мәчете өчен үч алып, Кырымның һәр тавы, һәр биеклегенә тимер, бетон тәреләр куя башлады. Аларны бу эшкә Алексей Икенче атакай дәртләндерде... Судак тавына да тәре куйганнар иде алар. Татарлар бәреп ватты...—Бекир беразга тын алалмый тора. Аның яше гүя бугазына тыгыла.—Телисең икән, мөмкинлегең бар икән, рәхим ит, чиркәү төзе, халкыңны иманга, әхлакка чакыр. Нигә син тәреләр белән табигатьне рәнҗетәсең? Экологияне пычратасың? Ул бит бер Ходайныкы... Нишләп мөселман үзенең Аен элми икән соң тау башларына?.. Элми, чөнки мөселман динендә экспансия дигән нәрсә юк...

Дөрес сөйли Бекир. Минем бер хәл исемә төшә. Узган ел мин Кафтауда ял иткәндә Лермонтов булган урыннар буйлап сәяхәт кылган идем. һәм анда түбәсенә тәре менгезелмәгән тау тапмыйча хәйраннар калган идем... Пятигорск шәһәрендә мине бер нәрсә тетрәткән иде... Андагы атаклы «Мәгарә эчендәге күл»гә керү белән, ташка яңа гына кадаклап куелган зур тәре игътибарны үзенә җәлеп итә. Шунда ук ике чечен сугышына да фатыйха биргән «изге Алексей атакайның» бу тәрене «ачканда» сөйләгән фатыйхасы язып куелган. Мәгарәдән чыгу белән—а та, тау кырлачы астында атаклы шифалы су чыганагы. Әнекәйгенәм, нәрсә күрәм: автоматларын һәм киемнәрен шунда чишенеп ташлаган шәрә, исерек урыс солдатлары, кулларына шешә-шешә аракы тотып, «гаң-гаң» килеп, сүгенешеп, шунда, изге чыганак казанында коенган булып яталар!..

Шушындый шакшылыкны күргәннән соң минем өч көн буе күңелем уйнады—тамагыма ризык ала алмадым.

Мин адәмнәр арасыннан иң бозыкларының тәреләрне тау түбәләренә үрләтүләренең серен беләм. Моның сере христиан дине, аның бер юнәлеше саналган православие мәзхәбе кичергән кризис, өзеклектә. Кеше йөрәгенә үтәлмәгән идея кризисы. Дини православие тәгълиматы, инде аптыраган үрдәк сыман, арты белән күлгә чума, ягъни мәсәлән, ачуын кая куярга белмичә, үзенең кизәнү таяклары булган хоругвлары белән тау башларын булса да биләп, басып аласы килә. Израилитләрнең мөселманнарга каршы соңгы ун еллыкта тырыша-тырмаша эшләп биргән ялган «терроризм» теориясе нигезендә, христианчылык һәм православие бар дөньяның зиһенен яулап алып барган мөселман динен ниндидер ваһһабчылыкта, террорчылыкта гаепләп, Америка колы белән кыйнатасы, юк итәсе, җир йөзеннән себереп түгәсе килә...

Их, далалардан тауларга әйләнә барган Кырым табигатенең илаһи матурлыклары! Таулар сиңа баскычы-баскычы белән йөзем плантацияләрен суза. Ал, алар барысы да синеке, үзебезнеке!—ди ул.

*Таланган ташлардан кан тама, дип*
*Җиргә төшсәм,—ул таш уты икән.*
*Телләремдә тәмлим!—ут дигәнем*
*Йөземнәрнең алсу суты икән...*
*Күрәм, таулар сәндерәсе буйлап*
*Кырымда булыр дип бер җәннәт,*
*Йөзем чыбыкларын бәйләп йөри*
*Хак Пәйгамбәребез Мөхәммәт...*

Үзәннәр алсу рәшәдә йөзә. Төркиядән алып Тын океанга кадәр сузылган төрки-татар дөньясы... Скиф бабаларыбызның Чуфут-Каладан алып Алтай тауларына кадәр кадап куелган таш балбаллары!..

Тик төрки-татар кайчандыр үзенеке булган бу киңлекләренә инде үзе хуҗа түгел. Юл буйларында татар апалары катык-сөт, эремчек (татарлар

сөргендә чакта монда мал агын күреп тә булмый иде!), помидор, алма, чия һәм башка яшелчә, җиләк-җимеш сатып утыра. Туган якларымның мал аклары искә төшеп китә. Якташым язучы Нурихан ага Фәттах искә төшә. Моннан утыз ел элек ул безнең барыбызның һушын алып һәм бик тә гадел рәвештә урысларның «молоко» лары татарның «мал агы»ннан, «творог»лары—«туар агы»ннан алынганлыгын искәрткән иде. Әнә, татар кызы сыерын күгүләнгә арканлап чыгып килә. Башындагы кызгылт яулыгы бер яккарак шуган, тез башлары чыкка чыланган. Минем куанычым әчемә сыймый башлый. Бу сеңелләр-апалар белән илнең тәненә җан кайткан кебек тоела...

Мин Җир һәм Тир, Тән һәм Җан феномены турында уйлыйм. Кырымның төп халкы булган татарны шушы туфрактан куганнан соң, илле ел эчендә Кырым туфрагы уңыш бирмәс булды. Милләтнең борынгы тарихи татар сугару системасына нигезләнгән тәҗрибәсе юк ителде. Кырым татары гына үстерә торган бодай, Кырым татары гына үрчетә торган куй сарыгы, мамык кәҗәләре, кырым татары гына сава торган сыер һәм башка төр малларның нәселләре ишәюдән туктады. Кырымтатар халкы гына үстерә торган помидор, баклажан, борыч, суган һәм башка төр культуралар ярыматауны ташлап китте. Кырым татарлары гына үрчетә торган каракүл сарыклар, алар гына или торган каракүл тиреләр юкка чыкты. Кырым татары гына үстерә ала торган атаклы йөзем—виноград сортлары Кырымны ташлап каядыр качты. Ярыматау кипте, корыды, җил-өермәләр кашлавына әйләнде, бар СССРны кунакка чакырып, урыс сүгенүенә, эчкечелек һәм башка төр бозыклыкка өйрәтү үзәгенә әверелде...

Сез карагыз әле, бүген Кырымга Кеше—Акыл Иясе белән чит-яклардан аның ФЛОРАСЫ ҺӘМ ФАУНАСЫ кайта. Кырым татары, аның моңы белән бергә үсемлек, яшелчә, җиләк-җимеш дөньясы, малы-туары кайта. Аның сыерлары, куйлары-сарыклары, кәҗәләре, хәтта аның гына икмәген-җиләген, һавасын-суын яраткан сукыр тычканнары, чебен-черкиләре дә кайта... Кинәт кенә миндә кыллар чиртә башлый... Минем хәтеремдә (нишләптер!) Казанда үткән яшьлегебез хатирәләренең бер тере мирасы булган мәшһүр мандолиначы Исмәгыйль ага Һилалов сыны күтәрелә. Шигырь ярала:

*Нәрсә булды?—Тырнак очларында*
*Зеңгелдек моң чиртеп кукләрдән,*
*Күрәм, кырмыскалар кайтып килә,*
*Һәркайсы мандолин күтәргән...*

Куылган халык кире кайта. Сирәк күренеш. Тетрәндергеч күренеш. Бүтән кабатланмаска тиешле күренеш. Әгәр империя яшәүдән туктаса, әлбәттә, кабатланмаска тиешле күренеш.

Сез карагыз әле, табигатьтә Аллаһуның үзеннән генә килә торган бөек җәза бар: Тәннән Җанны (Халыкны) көчләп аерсалар, Җан Тәнне, ничек кенә теләсә дә, үзе белән алып китә алмый, нәтиҗәдә, урында калган Тән, ягъни Объект, Җаннан, субстанциядән аерылган килеш корырга (тора-бара төмам үзгәрергә, «үләргә») мәҗбүр була. Сөргендәге Җан исә Тәнне эзләп, сагынып, юксынып саргая һәм Тәненә кире кайту өчен үзен барлык җәфаларга дучар итә... Сталин күп кенә милләтләргә мондый феноменны «бүләк» итсә дә, ни кызганыч, урыс иленең сәясәт фәне бу феномен үзенчәлекләрен бүлкәләргә бүлеп, хезмәтләр—аерым бер *«ҖАН һәм ТӘН БЕРЛЕГЕ»* дигән фәнне тудыра алмады әле. Дөресрәге, теләмәде. Аның моңа «мохтаҗлыгы» юк. Аның «Яңа Чечнялардә» генә мохтаҗлыгы бар. Чынлап та, империячел бөеклек белән чирләп корыган җәмгыятьнең бу фәнне тудыру өчен гражданлык теләге булмаса, башка милләтләрнең моның өчен гражданлык көче, мөмкинлеге юк. Моны Татарстан галимнәре, язучылары, политологлары тудыра алган булыр иде...

Чынлап та, Казан татар галимнәре, Татарстанның икътисади, сәяси, иҗтимагый фәненең күп катлы микроструктурасы моны булдыра алыр иде...

Биредә бер чигенеш сорала сыман.

Иҗтимагый тормышта тарихи хәтер дигән бөек этәргеч бар. Комнар кучкән вакытта да милләтне милләт итеп шушы илаһи хәрәкәтләндерүче көч (двигатель)—тарихи хәтер саклый. Кырымтатар туганы турында тарихи хәтерне

аның казантатар туганы беркайчан да җуймады. Бу хәтерне ерак бабайларыбыз, әле Казан һәм Кырым ханлыклары исән чакта, аларның икесенең ике төбәктә яткан бер, уртак дәүләт рәвешендәге дәүләт булуын раслап, Казанда хан итеп шул ук Кырым ханнары—Гәрәйләрне тотуы белән мөңгегә ныгытып куйган булган. Юк, бу һич кенә дә Казанда хан булырлык кеше булмаудан түгел! Бу чара шул заманнарда ук тирә-якны чирле кара кан булып оешып, йота барган Мәскәү экспансиясенә каршы стратегик каршылык чарасы булган. Бу бер һәм бердәм милләт өчен көрәш чарасы саналган. Никадәр алдан күргән безнең бабаларыбыз! Әмма алар соңгы чиктә стратегияне дөрес файдаланмыйча, дөрес кулланмыйча гына харап булалар. Менә безне аердылар. Ун елда ике тапкыр имля алыштырган ике «суверен милләт» иттеләр. Һәм... юк иттеләр.

Әйе, соңгы чорда бәлки төрекләрдән башка, Казан татары кебек башка бер генә төрки милләт тә кырымтатар турында ул кадәре кайгыртучанлык һәм борчылу күрсәтмәгәндер. 1944 елгы фаҗигадән соң үз язмышын Татарстан белән бәйли алган кырымтатар туганнарыбызның хәл-әхвәле, тормышы аларга башка җирләрдәге мөнәсәбәттән чыгып чагыштырганда байтакка яхшырак булды. Бер милләтнең ике канатын тәшкил иткән ир һәм кыз балаларның уртак казан-кырымтатар гаиләләре төзеп бер-берсен саклап калган мисалларны меңләп вә меңләп китереп булыр иде. Казан татары Кырым татары булган икмәк пешерүчесен дә, укытучысын да, җимешчесен дә үзенә сыйдырырга тырышты. Казантатар әдәбияты совет тоталитаризмының иң хәтәр елларында да кырымтатар туганнар турында «өстәл өчен» булса да әсәрләр язарга, аларны «качып-посып» булса да чыгарырга, укырга, таратырга тырышты. Безгә бит Кырымга юл да ябык иде. Без, татар язучылары, СССР Язучылар Берлегенең Кырым Күктүбәсендәге (аны басып алган «өлкән агайларыбыз» «Коктебель» дип кенә үзгәртеп җибәрделәр) иҗат йортына юллама көгазе ала һәм анда бара алган хәлдә, тән йокыларыбызны югалтып, һәрдаим һәм һәр адымда кырымтатар эзләрен, кырымтатар сөйләшен, кырымтатарның исән калган молекулаларын эзли, бәдрәфкә әйләндерелгән хан каберлекләрен «качып-посып» кына булса да зиярат кылып, яшь түгә һәм «Кайчан да булса бер чыгар» дигән өмет белән сыкраулы җырлар да яза идек... Әйе, андый җырлар язылды, әйе, андый заманнар килде, әйе, ул җырлар соңлап булса да милләтләребезгә җитә алды...

Әле ерак җитмешенче елларда шагыйрь Равил Фәйзуллин үзенең «Колонизатор әлифбасы» дигән шигырендә, мәсәлән, болай дип язган иде:

*Куа да,*
*бүтән ыру адәмнәрен җиреннән-суыннан,*
*үз хатыны, балалары алдында,*
*хозурланып әйтә тиран:*
*«Җиңдем!»—диеп.*

*Бераз вакыт үткәч,*
*оныкларына тукый:*
*«Бу җирләрне азат иттем!»*

*Соңрак—*
*иске зират урыннарын абзар ясагач,*
*оныкларының балалары:*
*«Ватаным!..» дип шигырь яза.*

1983 елда шагыйрь бу темага яңадан—инде катгыйрак алкымда—кире кайтты:

*Таулар кузгатыр идегез*
*Халыклар күчергәнче!*
*Икмәк үстерер идегез*
*каберләрне сөргәнче!*
*Җырлар чыгарыр идегез*
*Указлар чыгарганчы!*
*...Котырына шулай вәхши*
*үз канын чыгарганчы...*

Татар шагыйренең ачык позициясе бу мәсләктән чыгып караганда барлык милләтебезнең ачык позициясе иде. Димәк, йөзебез аклыгы иде.

Хәтерләсәгез, туксанынчы еллар башында милләтләребезгә кайчандыр тартып алынган азатлык витамины кайта башлаган көннәрдә Кырымга юл саба башлаган туганнарыбызга беренче булып ярдәм кулын без—Казан татарлары суздык. Әйткәнемчә, безнең йөзебез ак. Чечен халкы белән дә нәкъ шулай килеп чыкты. Алар алдында да, иншалла, безнең йөзебез ак булды һәм булачак. 1989 елда язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова Кырымда ике тапкыр булды һәм «самиздат» журналында «Крым: правда и ложь» дигән мәкаләсен бастырып чыгарды. Бер үк вакытта ул Көнбатыш Европа илләрендә, беренче чиратта Германиядә һәм Даниядә, Кырым татарларын яклап лекцияләр укыды. Татар Иҗтимагый Үзәге күч алган туксанынчы еллар башында казантатар милли хәрәкәте Кырымга берничә сәяси экспедиция оештырды. Милли хәрәкәт штабы әгъзасы язучы Зәки Зәйнуллин халкыбыз җыйган кием-салым һәм азык-төлекне КамАЗ машиналарында Кырымга илтеп кайтуны оештырды. Кырымтатар туганнарыбызга каршы карагруһчылык басымы көчәйгән һәм погромнар башланган авыр чорда без Казанда һәм Уфада «Кырымга ярдәм» фонды булдырдык. Ирек Гарипов һәм Тәлгать Әхмәдишиннар җитәкчелек иткән «Азатлык» татар яшьләре оешмасыннан берничә яшь төзүчеләр бригадалары Кырымга барып, мөһаҗир туганнарыбызга җир дәгъвалап, йортлар төзүдә катнашты.

Шул ук Иҗтимагый Үзәк башлангычы белән татар милли хәрәкәте Казанда ел саен кырымтатар туганнар куылган 18 май көнен «Кырым татарларын яклау көне» итеп үткәрә башлады. Бу акциядә катнашу өчен Казанга Кырымнан абруйлы делегацияләр, шул исәптән Кырымтатар Милли Мәҗлесе рәисе мөхтәрәм Мостафа-бей Җәмилев үзе дә килә иде. Безнең мөнә дигән публицистларыбыз Венера Якупова, Флюра Низамова Кырымда булып, тетрәткеч мәкаләләр циклы яздылар. Атаклы фоторәссам Риф Якупов Кырымда яшәп җәберләнгән милләт турында фотоальбом әзерләде. Инде килеп, шушы юллар авторының кырымтатар, казантатар һәм чечен халыкларының империягә каршы уртак көрәше турында «Убить империю!» дигән китабын язуы һәм бу китапның Йошкар-Олада басылып чыккан сәгатьтә органнар тарафыннан кулга алынып, читлектә ятуы турында тагын бер тапкыр әйтеп китү урынлы булыр кебек. Әлеге ярдәмне бит, кызганычка каршы, төркиләрдән—үзбәк тә, казах та, кыргыз да, төрекмән дә, әзербайҗан да түгел, ә безнең туган казантатар милләте вәкилләре эшләгән. Бу эшләрне әле һич кенә дә эшләнгән эшләрнең тулаем исемлеге дип кабул итәргә ярамый. Тиешле урында нигә горурланмаска? Әгәр һәр төрки милләт кырымлы кардәшләребезгә шундый ярдәм күрсәткән булса?!

...Кая карама, соңгы ун-унбиш елда, ягъни татар туганнарыбызның хәләл туфракларына кайтып урнашканнан соң яңартылган йөзем бакчалары. Йөзем җимеше әлегә сатуда күренми. Йөзем соңлабрак өлгерә шул. Быел аннан уңыш күп булачак. Ул ифрат дәрәҗәдә яңгыр ярата. Без килгәннән соң Кырым ярыматавында малларны, машиналарны йөздереп алып китәрлек яңгырлар булды. Шуларның икесенә мин үзем дә эләктем һәм Акмәчет вокзалына таба аккан ташкында чак-чак кына агып китмәдем.

Акмәчет, ягъни Симферополь дигәннән. Симферопольгә килү юлы минем өч шәһәр: Мәскәү—Казан һәм Киев аша үтте. Бу өч шәһәрне үткәннән соң кайта-кайта аларның язмышы турында уйландым. Гүяки алар мине әзерлекләр һәм бу язмаларны мөмкин кадәр соңгарак калдырырга тырышалар иде. Шулай итеп, язмаларга тотына алмыйча ярты елга якын вакытым үтеп тә китте. Бу шәһәрләр тарихын махсус өйрәнмәсәм дә, алар турында белгәнемне берәмтекләп чыгу да мине «көтелмәгән нәтиҗәләргә» алып килде. Мәскәү шәһәре тарихы, минемчә, аерым мәсьәлә. Шуңа күрә юлъязмаларым башында Казан, Акмәчет, Киев шәһәрләре турында кыскача гына чагыштырма фикерләремне әйтеп китәм.

Беренчедән, алар өчесе дә төрки-татар нигезләгән шәһәрләр. Икенчедән, өчесе дә төрки-татар мирасы булып исәпләнергә хаклы булса да, өчесенең берсе дә тулаем төрки-татар кулында түгел. Бүген хәтта Казанны да мин чын татар шәһәре дип атый алмыйм. Кем атый алыр икән? Укыган кешеләр хәтерлидер, минем «Татар вакыты» романының төп герое—үлем түшәгендә саташып яткан Мотаһар Чынбарысов кулына сулы чиләк һәм пумала алып, Казан Кремле диварларын шакшыдан юа, тазарта башлый... Казанның татар

шәһәре түгеллегенә ышану өчен, әйе, Казан Кремленә керергә һәм элекке губернатор сараена, аның каршындагы хан сарае хәрабәләренә генә күз ташлау да җитә...

Мин күптән түгел тамыры ягыннан татар булган Иван Бунинның чәчмә әсәрләрен яңадан укыдым. Нобель премиясен яһүдләр кулыннан «ялгыш» алган Шолоховны исәпләмәгәндә, ул урыс язучылары арасыннан бердәнбер Нобель премиясе лауреаты. Үзененең «Темир-Аксак-Хан» дигән хикәясендә ул безнең бөек мирасыбыз—төрки дәүләтләребез, шәһәрләребез, сарайларыбыз, аларның чын иясе—«страдальческо-недоуменный татарин»ының язмышы турында ачынып, менә нәрсә яза: «...Скоро распались все царства его, в запустение пришли города и дворцы, и прах песков замел их развалины под вечно синим, как драгоценная глазурь, небом и вечно пылающим, как адский огнь, солнцем... А-а-а, Темир-Аксак-Хан! Где дни и дела твои? Где битвы и победы? Где те, юные, нежные, ревнивые, что любили тебя, где глаза, сиявшие, точно черные солнца, не ложе твоем?

Все молчат, все покорены песней.»

Биредә татар җырлый. Язучы татар җырының тәэсирен тасвирлый. Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиевалар моңын тасвирлый, диярсең. Безнең әле, татар язучысы исемен йөртеп тә, Бунин кебек, татар моңын болай тәэсирле сурәтли алганыбыз юк кебек...

Бу өч шәһәр арасында иң борынгысы—Симферополь. Аңа ике мең ярым ел булса да, бу кулдан-кулга күчеп, төрле мәдәни катламнарны берләштергән шәһәр чагыштырмача зур түгел—анда хәзерге көндә нибары дүрт йөз меңләп кеше яши. Тарих фәнендә шәһәрне безнең эрага кадәр IV гасырда Киммериядән килгән урартлар, греклар нигезләгән дигән фикер яши. Мин үзем бу фикер белән килешмим. Аңа, күп кенә галимнәр раславынча, Көньяк Урал һәм Идел буйларыннан килгән төрки сармат кабиләләре нигез салган, дигән гипотеза миңа дәлиллерәк булып күренә. Шул ук сарматлар Кырымның «Черек-Су» кальгасын (хәзер Чуфут-Кала хәрабәләре) салуы тарихка билгеле нәрсә. Безнең эраның III гасырына кадәр ул төрки сарматлар, аннан төрки скифлар (мин аларның, Садри Максуди кебек, төрле нәселләргә караган төрки кабиләләр булуына иманым камил) кулында була. Аннан греклар, аннан герман, аннан румнар, аннан яңадан төрки һуннар кулына күчә бу күпне кичергән шәһәр. Бер заман, утрауда греклар хуҗалык иткән чорда, аның «Скифлар Неаполе» исеме белән йөртелүе дә билгеле. Безнең эраның VIII-XIII гасырларында ул «Татар Кирмәне», аннан соң Акмәчет исемен ала, Екатерина IIнең 1783 елда Кырымны Рәсәйгә кушканыннан соң нибары бер елда үтеп өлгерми, Акмәчет «Симферополь» дип үзгәртелә. Шулай итеп, «татарларның шәһәр төзи белмәве», Алабуга каласы «урынында» «Елабуга», Бөгелмә «урынында» «Бугульма», Мамадыш «урынында» «Мамадыш» крепостьләре «төзелгән» булуы тагын бер тапкыр җиңел генә раслана. Кызык бит, гүяки урыс килеп «Бугульма»ны «нигезләгән дә куйган, аңарчы «дикое поле»дә беркем яшәмәгән! Әйе, Бөгелмә кебек шәһәре булган татар үзе тычкан тишегендә яшәгән икән. Ә менә урыс Казан алынганнан соң ике йөз утыз ел үткәч (1781), «киң күңеллелек» күрсәтеп, «дикое поле»дә шәһәр төзеп, аңа, җитмәсә, татарча «Бөгелмә» дигән исем дә биреп куйган бит әле! Әгәр аны урыс үзе нигезләгән һәм төзегән булса, ул аңа бирәр «Святой Посад» дигән исем бирер иде, шулай бит? Татарлар шәһәр төзи белмәгәч, ике йөз мең гаскәр белән ике ай буе камап торып та ала алмагач, шул ук Италия, Германиялардән китертелгән дары һәм шартлатучы мастерлар (немецчәдән «оста» дигән сүз) ярдәме белән диварлары ике-өч урыннан шартлатылып кына алынган татар Казанын кем төзегән булды икән, татар үзе төземәгәч?! Ләкин басып алучы Казанны «яңадан нигезләнгән» дигән фикерне сеңдерү өчен хан кремлен барыбер нигезенә кадәр яндыра һәм аны үз стилендәге «кытай тешле» диварлар (Мәскәүнең «Китай-город»ын хәтерлисезме?) белән «крепость-посад төзи», имеш. Бу мәсьәләдә урыс шовинистлары шулкадәр узынды ки, 1977 елда КПСС Политбюросында Казанның сигез йөз еллыгын билгеләү турындагы мәсьәлә каралганда Леонид Брежневның «Татары не строили, они лишь разрушали города, празднованием пока подождем» дип, Казаныбызның бәйрәмен туктатып торуы бар дөньяга билгеле оятсызлык булды бит. Безнең татар милләте белән болай сөйләшергә ярамый иде. Һәм ул Брежневка бик

рәнҗеде. Аның рәнҗешенең нәтиҗәсе булып Брежневның табуты каберенә гәрселдәп төште, тәүбә вә тәүбә!.. Кабул итмәде татар болай тупас сөйләшүне. Ул бит әле, ни дисәң дә, урыска империя төзеп биргән милләт. Һәм Казанның сигез йөз түгел, мең еллык шәһәр икәнлеген расларга булды аның илһамлы иманы. Һәм раслады да.

Казан турындагы фикеремне, бер башлагач, тәмамлап куйыйм инде булмаса. Нишләп урыслар 1552 елда Казанны да «яңадан нигезләмәгәннәр» икән? Нигә аңа да яңа исем бирмәгәннәр, йә булмаса «Биектау—Высокая гора», «Базарлы Матак—Базарные Матаки» кебек бик тә «тирән мәгънәле» итеп «Котел» дип атамаганнар соң? Нигә, урыс туганнарыбыз Актауны Актау, Биектауны Биектау дип әйтә алмый мыни? Нигә Высокая Гора? Ә менә нишләптер Казанны «котел» дип атамаганнар алар. Моның өчен хәтта яулап алуны үзенең яшәү рәвеше итеп таныган урысның да оятсызлыгы җитмәгән дип уйлыйм, ни өчен дигәндә Казан ханлыгы кебек олуг дәүләтне басып алып, аның илле мең кеше яшәгән (бу заман өчен дөньяның иң зур шәһәрләре санына кергән) башкаласын җимерү барлык кешелек алдында эшләнгән җинаять булган, аларның бу җинаятьне яшерергә хәленнән килмәгән.

Мөстәкыйльлеккә юл тоткан Татарстан республикасы җитәкчелегенең соңгы ун ел эчендә Казан Кремле эчендә дәүләти масштабларда археологик эзләнүказынуларны оештырып, меңләгән документаль табышлар туплап, бар дөнья алдында башкалабыз Казанның мең еллык тарихын раслату, аны ЮНЕСКОның тарихи мирасы исемлегенә керттереп, Казан Кремле өстенә ЮНЕСКОның бөтендөнья туграсын элдереп куюбу безнең халкыбыз, Республикабызның, Президентыбызның зур тарихи җиңүе булып исәпләнергә хаклы.

Татар тарихын күрмәмешкә салышу ниятендә иске татар шәһәрләре өстенә «крепость» утырткан булып, аларга яңа исемнәр бирү мәсьәләсендә Симферополь ачык мисал булып тора ала. Оятын җуйган колонизаторлар әле 1980 елда Мәскәүдә чыккан һәм «прогрессивлыкның классикасы» исәпләнгән «Советский энциклопедический словарь»дә бу хакта «Симферополь—столица скифского государства Неаполь Скифский, затем татарская крепость Керменчик, в XV веке татарское поселение Ак-Мечеть, на месте которого в 1784 году ОСНОВАН СИМФЕРОПОЛЬ» дип кенә җибәрә. Менә бит ничек. Ак-Мәчет барлыкка-бар булган, әмма Симферополь барыбер аның урынында «ОСНОВАН». Логика кайда икән боларның? Әллә югыйсә җимергәннән соң «основан»мы? Бу хакта язылмый. Бу үзеннән-үзе аңлашылган, күрәсең. 1944 елда кырымтатар халкын куганнан соң татар каберләре өстендә заводлар салу сәясәте менә кайчаннан килгән ул. «Симферополь» сүзенең мәгънәсен мин хәтерләмим. Кул астымда мондый сүзлекләр дә юк. Ләкин мин «полис»ның грекчадан «шәһәр» икәнлеген беләм. Урман, кержак урысларының тормышын көнбатыш төртәләргә куып кертүне төп сәясәте итеп таныган Әби Патша «полисларны» бик ярата һәм төрки шәһәрләргә, урысның исе-косы да булмаган «яңа шәһәрләренә» колониаль Севастополис, Симферополис, Ставрополис, Борисполис кебек «бигрәк тә «урысча булган атамаларын» куша да куя. Бетте-китте. Шулай итеп, урыс мохиты «Европага тәрәзә ача». Менә өч гасыр инде урыс үзе һәм без үзебез шушы гаделсезлек белән килешеп яшибез. Нишләп әле чынында «Петроград» дип аталырга тиешле шәһәр инде «Ленинград»тан соң да, егерменче гасырның туксанынчы еллары башында, яңадан «Санкт-Петербург»ка әйләнде? Монда «Урыс рухы»ның ни катнашы бар?

Минем «Киев»ның кайчандыр төркиләр тарафыннан нигезләнүенә һәм аның безнең тарихи әдәбиятта «Кияү шәһәре» дигән төшенчәдән алынган булуында шигем юк. Борис Рыбаков кебек бөекдержавачыл тарихчылар аны VI-VII гасырларда «полян» дигән славян кабиләсе нигезләгән дип расларга тырыша. Моның өчен дөнья картасыннан космик телескоп белән булса да зурайтып, шәһәрләр тудыра алырлык «полян» кабиләсен эзләп табасы бар әле. Әгәр без мондый тарихчылар күрсәткән VI-VII гасырларга туктасак, бу чор төрки милләтләрнең ерак Алтайлардан миллион ябык арба-кибиткаларда һаүһаулап килеп чыгып, бар Европаны яулап алганнан соң, Кафтауда, Балканда һәм Идел буенда дистәләгән төрки дәүләтләр, империяләр оештырып, чәчкә аткан чорына туры килә...

Кызганычка каршы, безнең татар тарихчылары татар тарихын шушы дөньяви глобаль укмашу процесслары белән бер күренеш итеп өйрәнә

алмый. Безнең, элегрәк язганымча, һаман да шул «Идел буенда Болгарыбыз булган, аның мунчаларында кайнар сулар торбалардан килеп торган...»

Кайчандыр яңа археологиябезнең, нумизматиканың аталары булган Альфред Халиков, Равил Фәхретдиннәр, Әзһәр Мөхәммәдиләрнең ачышлары Рәсәйне шаулаткан иде. Алар башта монголлар, аннан урыс ушкуйниклары яндырган Болгар, Иске Казан, Сарай-Бирке казылмаларыннан берәр метр калынлыгындагы көл катламнары, чүлмәк-чүлмәк борынгы болгар, Казан ханлыгы акчалары, башка материаль шаһәдәтнамәләр тапты. Соңгы чорда Альфред Халиков вафатыннан соң туган бушлыкны бу өлкәдә, минем уйлавымча, талантлы, милләтпәрвәр җанлы археолог галимнәребез Альберт Борһанов, Фаяз Хуҗиннар реаль иҗтиһат белән тутырырга тырышалар. Генетик сыекланган булсак та, нинди асыл егетләребез бар әле безнең! Мин алар гына эшли алган, әмма әлегә милләтебез күреп, бәясен бирмәгән хезмәтләренә эчемнән куанып бетә алмыйм, аларга Ходай Тәгаләдән озын гомерләр телим.

«Кырым» белән «Украина» сүзләренең тамырлары уртак. Чөнки кырымтатар белән «у-КЫР-аин» милләтенең тамырлары уртак. Ягъни, Украина сүзе үзе үк ике өлештән—төрки һәм славян тамырлары, кисәкчәләреннән тора. «У»—славян предлогы («янында»). «КЫР»—төрки (кыр, ялан, җир). «Ин, ина»—славян окончаниесе (славян-ин, мишар-ин, башкир-ин, татар-ин) «У-кыр», «кыр кырында», «кыр янында» була, абайлыйсызмы? Кыскасы, «Украина»—Кырымга карата «у» (у моря, у Византии) булган, «Кырым янындагы өлкә, җир» булган территория. «Кыр»ым—«минем кыр»ым», «минем Ватаным», «мое поле», «моя Родина» була бит инде. Без, төркиләр, төрки кыпчаклар, гомер буе шул «поле» ягъни «половец»лар булганыбыз өчен тукмалдык һәм тукмалабыз.

Бүгенге украин милләте төрки белән славян милләтләренең аерып ала алмаслык кушылмасы, симбиозы ул. Их, кая икән безнең татарның шушы мәсьәлә белән шөгыльләнә торган галимнәре!.. Кызганычка каршы, әйе, тагын да шул «кызганычка каршы», бездә үткән гасырның җитмешенче еллары уртасында тугандаш казах кыпчакларыбызның бөек тел белгече Олжас Сөләйменовның шушы җитди теманы күтәргән «АЗ и Я» китабын дәвам итәрлек кеше табылмады. Атаклы Әбрар ага Кәримуллин китеп барганнан соң, бу өлкәдә яңа яшь талантларның күренгәне юк әле.

Әйе, Украина топонимиясе юкка гына төрки атамалар белән чуарланып бетмәгән. Дөресрәге, анда бар атамалар да йә булмаса чагыштырмача яхшы сакланган, йә бозылган килеш сакланган төрки атамалардан тора. Син Киев сусаклагычы ярындагы «Дымер» шәһәрчеген ал. «Дымер» исә яһүдиләр «местечко»сы «Жидомир—Житомир» (Мир жидов—яһүдиләр тормышы) кебек әллә каян төрки-татарлыгы белән кычкырып торган «Тимер» бит инде. Син «Тетер»елгасын ал. «Тәтер» бит инде. Минем туган авылым Кәркәлетамактан унике чакрымда кечкенә Тәтер елгасы ага, ул Ашкадар елгасына коя. Тәтер-Арыслан дигән бик зур татар авылы да бар ул елга буенда. «Тәтер»нең әле «татыр», ягъни «тозлы» дигән төшенчәдән дә алынуы мөмкин...

Соңгы елларда украин тарихчылары украин халкының славянлашкан төркиләр булуын фәнни гамәлгә куйды. Алар «Кияү-Киев» кирмәнчегенең төркиләр тарафыннан нигезләнүе турында байтак фәнни хезмәтләр язды. Минем фикеремчә, кырымтатар һәм украин милләтләре кебек бер-берсенә кияү һәм киләш булып, алышып-барышып, үзара «гөр килеп», кирәк икән, бер-берсенә яу чабып, кирәк икән, бер-берсе белән дуслыкта, тынычта яшәп, кирәк икән, бер-берсеннән туганнарча көлеп, тешнәшеп, «Запорожье казакларының Төрек солтанына хаты» кебек артык «тешнәк» хат язган ике милләт җир шарында сирәктер. Шунысы кызык, бу ике милләт арасында, Тукай әйтмешли, «вак-төяк шаярышу»дан тыш, зур, күзгә күренгән, кешелек хәтерендә калган феодаль сугышлар булуы турында бер генә мәгълүмат та юк.

Мин төрки-татар цивилизациясе нигезләгән бу өч шәһәрнең байтак уртак якларын күрәм. Аларның өчесе дә борынгылар, бик борынгылар. Араларында иң өлкәне—Акмәчет. «Симферополь», янәсе. Аннан—Кияү. «Киев», янәсе. Аннан Казан. «Казань», янәсе. Әйтерсең, урыс «Казан» дия алмый. «Сазан» дип әйтә ала ул, бер дә «Сазань» дими. «Алабуга» дип тә әйтә ала, тик бер аваз белән булса да боза—«Елабуга» ди. Татарныкы булгач, ул «Алатау»ны «Алатырь», «Галим»не Галимово, «Сәлим»не «Салимово» ди... Шулай итеп, «ово» белән «ин, ино» кушымчалары теләсә нинди милли телләрдән

килгән атамаларны «урысныкы» итә дә куя. Рәхәт, иркен—контроль юк, чабуга басу, җиңнән тарту юк...

Бу өч тугандаш шәһәрләр өчесе дә тигез, бераз иңкүрәк урынны сайлап урнашкан. Чынлап та казанны хәтерләткән урынга утырганнар. Акмәчеткә килсәк, дөрес, Кырым татарлары кайткач ул күзгә күренеп зурайды. Бүген анда өч йөз меңгә якын татарның өчтән бере яши дип авыз тутырып әйтергә мөмкин. Шәһәрне соңгы елларда татарларның «үз белдекләре белән тартып алынган җирләрдә» салынган җиде бистәсе уратып алды. Акмәчет базарлары, базарларның акча-икътисад мөнәсәбәтләре татарлар кулына күчә бара. Акмәчет базарлары ике бөртек яшь кебек Казан базарларын хәтерләтә.

Бу өч тугандаш шәһәрләрнең өчесендә дә ниндидер якты һава. Өчесе дә бик матурлар. Араларында иң матуры, әлбәттә, Кияү-Киев.

Украинада куанырлык нәрсәләр байтак. Урыс матбугаты мондый куанычларны бездән яшерә. Мәсәлән, украин газеталары 2002 елда үткән елга караганда инвестицияләрнең, туристларның ике тапкыр диярлек артык керүе турында яза. Сәламәтлек саклау министры Виталий Москаленко Украинаның барлык өлкәләрендә сабыйларның үткән елга караганда бер ярым тапкырга күбрәк туууын билгеләп үтә. Әлбәттә, халык авыр яши. Кайда да авыр яши. Акча-икътисад мөнәсәбәтләренә килгәндә, биредә акча берәмлеге булган украин гривнасы соңгы елларда урыс рубленә карата шактый кыйммәтләнгән. Ул—тотрыклы. Ул безнең өчен—«доллар». Элеккеге премьер-министр, хәзер Леонид Кучмага карата оппозициядә торган җәмгать эшлеклесе Виктор Ющенко—яңа украин икътисадының һәм акча сәясәтенең атасы—бу юнәлештә үзенә күрә украин Столыпины рәвешендә гәүдәләнеш тапкан. Бездә, Татарстанда, андый экономист юк. Бәлки Фәрит Газизуллин шул ук «оя»дандыр? Әмма ул Мәскәүдә бит. Ул Мәскәүне баета. Гривнаның бүгенге хәлен менә шуннан аңлагыз. Моннан алты ел элек урысның бер сумы утыз гривна микъдарына туры килә иде. Хәзер бер украин гривнасы алты сумга тиң.

Киев урамнарында мин урыс теленда язылган бер генә игълан, реклама, язма күрмәдем. Барысы да украин телендә. Министрлыкларда, оешмаларда, җитәкчелектә һәм гади хезмәт звеноларында—украиннар утыра, урыс теле бөтенләй колакка чалынмый диярлек. Мин моңа оешмаларда үзем булып һәм үзем күреп ышандым.

Киевны беренче тапкыр 1986 елның сентябрендә Чернобыльгә барышлый һәм аннан кайтышлый күргән идем. Анда ул урыс шәһәре иде. Хәзер Киев украин шәһәре. Безнең Казан кайчан шулай татар шәһәренә әйләнер икән дип сыкрандым мин Киевтагы уңай үзгәрешләрне күргәч.

Крещатикта, Украина Верховный Радасы каршындагы бакчада, аннан Богдан Хмельницкий һәйкәле каршында сәгатьләр буе уйланып утырдым. Минем биредә Татарстан Президентын, аның Югары Советы Рәисен, хөкүмәт җитәкчеләрен, сәнгать әһелләрен, язучыларын күрәсем килде. Бу шәһәрдә дистә меңләгән һәм мине яхшы белгән бихисап татарлар яшәсә дә, анда Татар Иҗтимагый Үзәге, милли оешмалары булса да, хәтта «Әл-Баян» исемле татар-мөселман газетасы чыгып килсә дә, мин... ялгыз идем. Юк, моның өчен беркемгә дә үпкәләмим. Болай гына, үтеп барышлый гына әйтәм. Чөнки мин килүем хакында беркемгә дә хәбәр итмәдем һәм мондый очрашулар өчен юлымның бу уңаенда мөмкинлекләр дә юк иде. Сәгатьләргә генә исәпләнгән сәяхәтемдә минем яраткан «Кияү-кала»мны бер ялгызым карыйсым килә иде. Китәр вакытым җитсә дә, бу шәһәрне нигәдер ташлап та китәсем килми иде. Гүя мине борынгы бабайлар, Дәрдмәндләрнең «кучкән комнарыннан» калган рухлары җибәрми иде...

Шәһәр белән хушлашыр алдыннан Михаил Булгаковның «Андреев түбәне»ндәге туган йортын барып карадым. София соборын, Киев-Печора лаврасын яңадан тамаша кылдым...

Киевтан мин Акмәчеткә юл алдым.

Анда мине Исмәгыйль Гаспралы исемендәге Кырымтатар Үзәк китапханәсендә укучылар белән очрашу көтә иде.

## Гаспралының гыйлем гыйльманнары

КИТАПХАНӘГӘ барып алдыннан Кырымтатар Милли Мәҗлесендә булып, анда рәис урынбасары—Мәҗлеснең аппарат җитәкчесе Ремзи-бәй Ильясов белән очрашып, шактый кызыклы әңгәмә кордым. Мәҗлеснең төрле регионнарда йолдызлык булып таралган бүлекчәләреннән бирегә тере нерв җепселләре килә. Туктаусыз телефоннар челтери. Кабул итү бүлмәсендә тегеннән-моннан кайткан, урындагы хакимияткә шикаять белән килгән инсаннар. Минем белән сөйләшкән арада Ремзи аларның һәркайсына җавап биреп барды. Бер үк вакытта машина чакыртып, ишек алдына чыгарга һәм мине озатып калырга да вакыт тапты. Мин боларның барысын да яралып килгән кырымтатар милли дәүләтенең минем турыда кайгыртуы итеп кабул иттем. Моңа бик тә рәхмәтле идем.



*Акмәчет. Кырымтатар милли мәҗлесе бинасы.*

...«Гыйльман»—гарәпчәдән, җәннәт хезмәтчеләре дигән сүз. Китапханә, борынгычарак әйтсәк, көтепханә—гыйлем җәннәте ул. Аны оештыручылар һәм көндәлек тәрәккыятен бар итүчеләр—шул гыйлем җәннәтенең хезмәтчеләре була инде. Куанырлык та шул: Рәсәйдә, шул исәптән, кызганычка каршы, Татарстанда да китапханәләр ябылган чакта, шушындый авыр шартларда, сөргеннән кайткан милләтнең, Украина дәүләте теләктәшлеге белән, Кырым республикасы масштабында кырымтатар Үзәк китапханәсен оештырып җибәрүе—бу аерым милләт масштабыннан дәүләтара масштабларга чыга торган мәдәни һәм сәяси вакыйга.

Кырымтатар милләте—кырылган милләт. Кырымнан сөрген тарафларына барып егылганчы өчтән бере кырылып беткән милләт. Һәм... шул вакыйгаларга илле алты ел үткәннән соң, нәкъ 1990 елның сентябрендә, инде кире Кырымга кайтып егыла алган татарларның изге Акмәчетләрендә «Симферополь Үзәк шәһәр китапханәсе»нең кырымтатар бүлеген оештыра алуы, кемнәрдер тарафыннан «кырылып бетәргә тиешле милләтнең», инде үзелдем, инде үзелдем дигәндә генә соңгы мәгърифәт җебен саклап кала алып, ялгап җибәрүе—бу Җир Шарының милләт атамасын йөрткән барлык тере җан ияләре өчен мәңге өйрәнелергә тиешле олугъ сабак. Французларның «Ирекле кеше, төрмәгә эләгеп, мәхбүс булмам, бай кеше, янчык тотып, хәер сорашмам, димә, боларның арасы—бер адым»,—дигән әйтеме бар. Әйе, тормышның диалектик бәхраларын үтеп, бүген бар дөньяга даны таралган Лондон, Нью-Йорк, Париж, Мәскәү, Санкт-Петербургның атаклы китапханәләре киләчәктә исән калу өчен көрәштә, ничек кенә сәер һәм көлке тоелмасын, сөргеннән кайткан героик милләт оештырган Исмәгыйль Гаспралы исемендәге Үзәк кырымтатар милли китапханәсенең тәҗрибәсен дә күз уңнарыннан ычкындырмаска тиешләр. Бу бөек иҗтиһат һәр кеше, һәр милләт, һәр мәдәният өчен гыйбрәтле сабак. Бу сабакның ике канаты бар: ничек «тегеләр» кебек болай эшләргә ярамый һәм ничек «болар» кебек болай эшләп була?

Минем белән очрашу башланганчы, без директор урынбасары Ниявер-бәй Куршутов белән китапханәнең фондлары, бүлмәләре буйлап танышып йөрибез.

—Татарстан Үзәк Милли китапханәсе белән безнең арада тыгыз элемтә яши,—дип куанычын җиткерергә ашыга Ниявер-бәй.—1997 елда ике арада килешүгә кул куелды. Татарстан китапханәсенең ул чактагы директоры Разил әфәнде Вәлиев безгә бик зур ярдәм күрсәтте... Сез аңа күп итеп сәлам әйтегез, ярыймы?—Ниявер-бәй чем кара күзләре белән миңа текәлә дә, аннан кискен генә сорап куя.—Нишләп сезнең Үзәк китапханәнең исеме юк? Казан

татарында исем берерлек адәм калмаган мәллә?—Без икебез дә көләргә тырышып елмаябыз, бу тырышлыктан йөзебез чытылып куя.—Уфа Үзәк Милли китапханәсенең исеме бар, ул Казанда гыйлем эстәгән татар Зәки Вәлиди исемен йөртә, без үзебезнең китапханәгә, Ходайга шөкер, Гаспралы исемен ала алдык...

Әйе, читтән караганда, чынлап та сәерсендерә торган нәрсәләр күп инде ул безнең Казан татары тормышында. «Ленин» исемен йөрткән урамга «Кремль» исемен бирүләр, татарның палачы—Жданов исемен (!!!) бетереп, инде бер бетергәч, бу урамга «бирәр» Кол Гали, анысы хәлеңнән килмәсә, Михаил Худяков, Александр Ключарев кебек асыл урыс кешесе, анысы да хәлеңнән килмәсә, Натан Рахлин кебек татарга хезмәт иткән асыл яһүди исеме бирәсе урында аңа сионистларның халыкара теле Эсперанто исемен кушулар, Сөйдәшевкә инде илле ел буена һәйкәл куя алмыйча, Шаляпинга бер атна эчендә иң үзәк урамга һәйкәл куюлар, татар радиосын, татар телевидениесен тар-мар итүләр... Күп инде алар, күп!..

Бернечә йөз генә китабы булган кырымтатар китапханәсе иң элек бер кечкенә бүлмәдә эшли. Анда башта бер, аннан ике хезмәткәр була.

Бүгенге көндә Исмәгыйль Гаспралы исемендәге кырымтатар Үзәк китапханәсе Акмәчетнең Самокиш урамындагы 8 нче санлы гүзәл бер бинада урнашкан. Татар байлары тарафыннан 1840 елда «Рушдия» мәдрәсәсе өчен махсус төзелгән бу бина 1917 елгы революциядән соң, бигрәк тә 1944 елдан 1994 елга кадәр, нәкъ кеше язмышлары кебек, сәяси кысым-репрессиягә эләгә—аны мәгарифкә һәм иманга катнашы булмаган төрле оешмалар биләп, таушалтып һәм пычратып килә. Ярый әле җимереп ташламыйлар—бүген шунысына куанырга кирәк. Әмма Ходай Тәгаләнең рәхмәте киң. Менә, игътибар итегез. Кешеләр кебек, биналар да аклана (реабилитацияләнә) икән. 1994 елда Акмәчеткә Нидерландиядән ата-бабаларының эзләре буйлап Кырым татары—«Төркестан-Әзәрбайҗан» милли үзәге җитәкчесе Мехмет Тютюнҗү килеп чыга һәм бу тарихи бинаны сатып алып, Кырымтатар Милли Мәҗлесенә бүләк итә. Бернечә ел анда Милли Мәҗлес һәм «Голос Крыма» редакциясе эшли. Шул ук Тютюнҗү әфәнденең һәм украин милләтчеләренең тырышлыгы белән Нидерландия хөкүмәте Көнчыгыш Европа институтының Анна ханым Прис җитәкчелегендә бер төркем хезмәткәрләреннән «Акмәчеттә Үзәк кырымтатар китапханасен булдыру» проектын эшләтә. Озакламый Нидерланд Корольлегенең Тышкы Эшләр Министрлыгы халыкара украин «Видроджения» («Яңарыш») фондына бинаны үзгәртеп кору өчен 240 мең доллар акча бүлә. 1998 елның сентябрендә «Тебодин-Украина» фирмасы бинада реставрация эшләрен башлап җибәрә. 1999 елның май-июнь айларында эшләр төмамлана һәм инде 1995 елдан Исмәгыйль Гаспралы исемен алган Үзәк кырымтатар китапханәсе яңартылган бинага күчеп тә килә. Шулай итеп, укучы үзе дә аңлагандыр, Кырымдагы һәм ерак Төньяк диңгез ярларындагы кырымтатар һәм украин милли патриотларының бердәм тырышлыгы нәтиҗәсендә, Сталин козгыннары талап туздырган китап җәннәте яңадан аякка бастырыла.

Китапханә фондындагы 20 мең китап белән яңа бинага утыз хезмәткәр һәм Нидерландиядән күчерелгән долларлар исәбенә сатып алынган 22 компьютер һәм башка электрон җиһазлар күчеп килә. Бу барлык кырымтатар халкы күләмендәге вакыйгага әйләнә. Быел китапханә Сорос фондыннан 24 мең доллар грант откан. Интернетта үзләренең сайтын ачкан. 2000 елда кырымтатар мәдәният тормышында шушы ук Нидерландиядәге «Видроджения» фондына бәйле тагын бер зур вакыйга булды. Алар биргән акчага Таврия Милли университетының социаль фәннәр кафедрасы мөдире, профессор Виктор Юрьевич Ганкевичның бөек мәгърифәтче, нәшир һәм җәмәгать эшлеклесе Исмәгыйль Гаспралының тууына 150 ел тулу уңаеннан «На службе правде и просвещению» дигән монографиясе чыкты. Төрки мәдәниятләр тарихында чит милләт вәкиле тарафыннан төрки мәдәният вәкиленә багышлап язылган мондый төпле хезмәтнең, минемчә, моңа кадәр күренгәне юк иде әле. Аны Днепропетровск типографиясе бастырып чыгарган. Моның өчен кырымтатар халкы Донецкидә яшәгән танылган Казан татары бае Ринат Әхмәдовка һәм украин халкына бик тә рәхмәтле.

Китапханәне оештырганда аңа нигез булып атаклы кырымтатар телчесе Басыйр Гафаров фонды хезмәт итә. Фондта милләтнең И. Гаспралы, Җ.

Сәйдәмәт, А. Озынбашлы, О. Чокраклы, Б. Чобан-задә, Ш. Бәктори, А. Кречинский, Э. Шәмьи-задә һәм башка шундый мәшһүр уллары һәм кызларының шәхси китапханәләре, әсәрләре, тормыш документлары, гомер язмалары тупланган. Алар арасында Төркиядә һәм Румыниядә 1930-1998 елларда нәшер ителгән «Әмәл» һәм «Кырым» мәҗмугалары, 1957-1990 елларда Ташкентта чыгып килгән «Ленин байрагы», «Йылдыз» журналының тулы тупланмалары бар. Бераздан коллектив Мәскәүнең Ленин исемендәге Үзәк китапханәсеннән 1944 елга кадәр кырымтатар телендә басылган 1600 китапны кайтартуга ирешә. Әле Мәскәү саклагычларында тагын да 3000 кырымтатар китабы бар икән. Мәскәү китапларны кайтарып бирергә бик ашыкмый. Кемгә мөрәҗәгать итсәң дә, мәсьәлә Киев белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләргә барып төртелә, татар җәмәгатьчелеге эшне турыдан-туры йөртә алмый. Китапханә бүген кырымтатар китапларын туплау буенча зур эш алып бара. Коллектив чит-ят тарафлардан елына өч меңнән артык китап җыя. Бүгенге авыр заманда бәләкәй эш түгел бу. Сүз уңында шунысын да әйтеп китү урынлы булыр: китапханәгә Татарстаннан татар һәм урыс телләрендә мин дә күтәрә алганчы китаплар алып килеп тапшырдым. Алар арасында безнең Тарих институты чыгарган хезмәтләр байтак иде. Әлбәттә, хуҗалар минем үземнең «Книга печали», «Убить Империю!», «Веселая книга», «Биктырыш», «Казлар киткәндә», «Кыяр каралары» дигән китапларымны да куанып кабул иттеләр. Мин урысча китапларымның кайберләрен Акмәчетнең Үзәк шәһәр китапханәсенә дә тапшырдым. Андагы хезмәткәрләрнең, милләтләре белән татар булмаса да, минем бүләкләргә—бу очракта Казан бүләкләренә никадәр шатлануларын күрсәгез иде!.. «Әйдәгез, безгә дә очрашуга килегез!—диләр алар.—Киләсезме? Кайчан киләсез?» Мин шунда бер нәрсәгә тагын да инандым: безгә, татар язучыларына, күп йөрергә, республиканың, безнең әдәбиятның, мәдәниятнең данын һич тартынмыйча, киң күңеллелек күрсәтеп, таратырга, күрсәтергә кирәк. Без, югыйсә, үзебезне-үзебез кимсетәбез. Нәкъ теге мәкальдәгечә: «Шикләнгән шикләнә—чикмән бөркәнә». Шулай итеп, Сарман-Минзәлә чикмәне астыннан чыкмыйча, үзебез турында бөек уйларда авыз эченнән ботка пешереп, банкет-премияләр көтеп, гомеребез дә үтеп китә. Каләмдәшләрем үпкәләмәсен, белеп сөйлим. Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтим: киләчәктә Кырым ягына юл тоткан Казан татары анда һич кенә дә буш кул белән бармасын, юл биштәренә берничә генә китап булса да салып барсын һәм аны Исмәгыйль Гаспралы китапханәсенә алып барып тапшырсын иде. Бу барлык татар җәмгыяте өчен изге бер йолага әйләнсен иде. Әгәр ул китаплар Кырым, кырымтатар тематикасы буенча икән, тагын да отышлырак булачак...

Бүген Кырымда татарлар өч йөзләп авылда, бистәдә һәм шәһәрдә күмәкләп яши. Шуңа күрә, Гаспралы исемендәге мәркәзи китапханә халыкны агарту эшен урыннарга күчерергә тырыша. Туган телдә китап басу эше әлегә бөтенләй диярлек юлга салынмаган булса да (республиканың «Крымучпедгиз» нәшриятында мәктәпләр өчен күпмедер күләмдә басылган әсбапларны, «Таврия» нәшриятында ел саен чыгарыла килгән 2-3 нәфис әдәбият китабын исәпкә алмаганда, кырымтатар телендә эшләүче нәшрият әлегә юк), үзәк китапханәчеләр үзләрендә булган байлыкны мөмкин кадәр киңрәк таратырга тырышалар. Китапханәнең беренче филиалы Акмәчетнең татарлар яшәгән Марьино бистәсендә 1999 елда ачыла. Хәзер аларның саны унга якынлашып килә. Карасу-Базар (Белогорск), Кизләү (Евпаторий) калаларындагы филиаллар араларында иң эреләрдән санала.

Китапханәдә кысан. Хезмәткәрләрне утырту, халыктан җыелган әдәбият, сирәк кульъязмалар, документларны урнаштыру өчен бүлмәләр җитешми.

—Тагын берәр грант отсак, без китапханәнең икенче бинасын төзи башлаячакбыз,—ди ярымшаян елмаеп һәм ныклы ышаныч белән Ниявер.— Безнең планнар зур—без, кырымтатарлар, урындагы әдәбиятны, нинди телдә булуына карамастан, бөтен дөнья буйлап җыябыз һәм җыячакбыз. Төркиядә алты миллион, Румыниядә 60 мең, Америка Кушма Штатларында егерме мең кырымтатар яши. Анда безнең хакта күп материаллар басыла. Барысын җыярга, тупларга кирәк. Бу җәһәттән Татарстанның Үзәк Милли Китапханәсе белән эшлисе эшләр байтак әле. Сезнең архив һәм китапханә фондларында Кырым һәм кырымтатар тарихы буенча чыганаклар тулып ята... Әмма барысы өчен дә акча кирәк, барырга кирәк, йөрергә кирәк...

—Безнең татарның көне «кирәк» белән башлана, «кирәк» белән тәмамлана инде аның,—дим мин.

—Менә без күптән түгел Галимҗан Ибраһимовка багышланган әдәби кичә үткәрдек,—ди минем шаяртуны тирәнтен кабул итеп Ниявер.—Бер дә Казанның «кирәк» дигәнен көтмәдек. Менә хәзер безне сезнең белән очрашу көтә...

Безнең күзләребезгә яшь бәрә. Без борадәрләрчә елмаябыз.

Мин диварда эленеп торган афишага ымлыйм. Озакламый кырымтатар әдәбиятының классигы Шамил Алядиннең тууына туксан ел тулу көнен билгеләячәкләр икән. Шамил Алядин кырымтатарның легендар язучысы. Аның үлгәненә нибары алты гына ел икән әле. Казан татарларының турыдан-туры кодасы иде ул, мәрхүм. Казан татарларының күренекле шагыйре, татар шигъриятендә фәрд жанрын тудыручы һәм аның остасы Әдхәт Синугыл—Шамил Алядинның кызы Ләйләнең кияве була, ягъни мәсәлән. Ләйлә—күренекле журналист. Кырым татарларының урыс телендә чыккан популяр газетасы «Голос Крыма» да эшли. Мин Ниявер-бәйгә Әдхәт Синугыл белән Кырымга юлга чыгар алдыннан гына Казанда очрашуым турында сөйлим.

—Безнең китапханәнең шура әгъзасы ул,—ди Ниявер-бәй.—Ул монда бик еш була. Чук гүзәл кеше!.. Улы, җәмәгате белән дә килә!

—Килми генә карасын,—дим мин шаяртып.—Килмәсә, мин аның фәрдләрен Казан матбугатында тунап чыгам!...

Тагын көлешәбез.

Без сирәк кульязмалар бүлегенә керәбез.

Мин андагы байлыкны күреп таң калам һәм тетрәнәм.

Минем алдымда Кырым ханлыгы диванының—вәзирлегенең, ягъни безнең көннәр теле белән әйтсәк, «Министрлар кабинеты»ның 1608-1783 еллар арасында тупланып килгән 61 томы ята... Кара-көрән кара белән гарәп имлясында йөгрек кош каурые язган бу вәсыйкалар (документлар) гүяки тәмугъ ялкыныннан исән чыккан васыятьләр иде. Мондый том-дәфтәрләр барысы 219 берәмлек булган. Әлегә аларның, әйтүебезчә, нибары 61е генә табылган.

Аларның табылуы—үзе бер тарих. Безнең «сөекле илебездә» генә була ала торган вакыйга.

Бу—бөтендөнья җәмәгатьчелеге белергә тиешле тарих. Сабак-тарих. Гыйбрәт-тарих. Тагын да «ничек эшләргә ярамаган һәм ничек мөмкин булган» тарих. Соңгы җептән өзелми калган тарих. Эзләрендә пәйгамбәрләр рухы сакланган тарих.

Әлбәттә, бу аның мин белгән өлеше генә. Бу тарихны тулысы белән ачыкларга һәм язып чыгарга кирәк иде дә бит. Моның өчен әлегә кырымтатар җәмгыятенең әзерлеге, кызганычка каршы, башкарып чыгарлык тарихчылары, язучылары юк шул. Бу җәһәттән аларга барлык төрки җәмгыять, шул исәптән казантатар җәмгыяте ярдәмгә килә алган булыр иде.

1976 елда Украина мәдәният министры рөхсәте белән Бакчасарай археология музеннан Салтыков-Щедрин исемендәге Ленинград китапханәсенә 377 берәмлек сирәк документлар мирасы тапшырыла. Сөйләүләренчә, нәкъ шул «архив чистарту» чорында музейда Ленинград архив институтыннан килгән Соколова дигән сеңелкәшебез практика үтә. Ул мич ягучы булып эшләүче һәм гел кызмача булырга яраткан картның ниндидер борынгы дәфтәрләр белән мич ягуын күреп ала һәм бер шешә аракы хакына әлегә исән-аман сакланган 61 дәфтәрне «сатып» ала. Соңыннан, еллар үткәч, ул бу тарихи документларны Гаспралы китапханәсенә тапшыра...

Нинди батырлык, гүзәл кешелеклелек адымы бу!

Ә без бу ханымның исемен дә белмибез.

Кырымтатар архивы, сәнгать әсәрләре, көнкүреш, кием, археология табышлары үзенең чын хуҗасын көтеп бүген Санкт-Петербургның Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәсе, Киев тарих музее, Киев рус сынлы сәнгате, Каховка, Запорожье крайны өйрәнү, Львов тарих музее подвалларында әсир хәлендә ята. Бүген бары тик элеккеге СССР халыкларының этнографик музее саклагычларында гына да Кырым татарларына караган 2021 номер, 2184 әйбер саклана. Кырымтатар җәмәгатьчелеге, җайлап аякка баса башлаган кырымтатар зыялылары аны коткару—кире Кырымга кайтару өчен юллар эзли. Бу юнәлештә кырымлы туганнарыбызга без дә ярдәм күрсәтергә тиешбез.

Минем белән булган әдәби очрашу шундук сораулар белән башланып китте. Көн ифрат та кызу булуга карамастан, кырымтатар һәм казантатар җәмәгатьчелегеннән шактый санда җыелган вәкилләрнең уйлары-телəкләре Казанда, Идел буенда иде. Сораулар күп төрле, аларның кайберләренә махсус әзерлексез җавап та биреп булмый: Татарстан мөстәкыйльлеге нәрсә ул? Татарстанның үз гаскәре булачакмы? Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләр рәсми Акмәчет белән Киев арасындагы мөнәсәбәтләрдән нәрсәсе белән аерыла? Татарстанның сәнгате һәм әдәбияты вәкилләре нигә Кырымга юлны суыттылар? Рейхстаг башына беренче Җиңү байрагын элгән Гази Заһитов кайчан Рәсәй Герое исемен алыр? Академик Роальд Сәгъдиев татармы, әллә яһүдиме??? Америкада яшәп, «Татарстанга мөстәкыйльлек кирәкми» дип кычкырып яткач, аның татарлыгыннан ни файда? Америкада яшәгән икенче бер атаклы галим Вил Мирзаяновны нигә кичә Казанга кертмәделәр? Аның «Вызов» дигән китабы сатуга чыгачакмы? Чечен халкына карата кылынган җинаятьләргә халыкара бәя бирелерме? Татар әдәбиятында нинди яңа исемнәр күренде? Алар арасында Галимҗан Ибраһимов кебек бөекләр бармы? Һәм башкалар, һәм башкалар...

Җәмәгатьчелекнең информацион әзерлеге бик сыек. Аның өчен татар әдәбиятындагы иң бөек исем—Галимҗан Ибраһимов. Фикер шул калкулыкта катып калган. Җәмәгатьчелек моның өчен гаепле дә түгел. Чынлап та заман шундый. Некрасов әйтмешли, «бывали хуже времена, но не было—подлей...» Казаннан Акмәчеткә, Акмәчеттән Казанга бер данә газета-журнал килми. Мең еллык уртак тарихыбызның «нәтиҗәсе» менә шушы.



*Гаспралы китапханәсендә очрашудан соң.*

Очрашуның әдәби өлеше казантатар туганнарыбызның шигырьләр укуымны үтенгәннән соң башланып китте. Кырым татарлары Казан шивәсенең телен шактый яхшы аңлый. Әгәр без Исмәгыйль Гаспралы салган көчне салып, бу юнәлештә бер-ике ел бергә эшләсәк, милләтләребез хәзер үк бер милләт булырга тора да бит... Без гасырлар буе кыйналган, таралган, таркалган һәм кайчандыр бер милләт булган милләтнең балалары идек... Без инде «Бетте, өзелде» дигәч китапханә җебе белән хәятне бәйләп җибәргән Гаспралы өммәтенең гыйлем гыйльфаннары—*китап җәннәте хезмәтчеләре идек*. Гыйльфан! Нинди матур сүз, матур исем! Безнең авылда бертуган Гыйльфан, Гыйльман, Сәлмән абзыйлар бар иде. Алар нинди матур кешеләр иде! Минем тирә-юнемдә шул ук Гыйльфаннарны күрәсем килә. Юк алар, Гыйльфаннар. Минем тирәмдә—Русланнар, Робертлар, Роксаннар... Алар туган телләрен дә белмиләр. Нишлисең, әмма, әмма... Гаспралының гыйлем гыйльфаннары, чишмәләр булып, безгә телебезне дә кайтарыр, Ходай кушса! Амин, шулай була күрсен иде!..

Өч сәгать дәвам иткән очрашу тәмамланганнан соң сурәткә төшү башланды. Бер милләтнең ике баласын хәтерләткән Кырым һәм Казан татартуганнарның аерыласы килми иде...

Югарыда, биектә соргылт даланы, каракучкыл тауларны кайнар рәшә дулкыннарында тирбәтеп, Кырым кояшы ялкынлана...

Каяндыр җиләс җил исеп куя.

Яңгыр, күптән көтелгән яңгыр булыр кебек!..

*Ахыры киләсе санда.*

## ТАРИХЫБЫЗ ТУЛЫМЫ?

**«ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ»НЫҢ VI ТОМЫ БАСЫЛЫП ЧЫГУ УҢАЕННАН**

**Мансур Вәли:**

Бик үк еш булмаса да, рухи-мәдәни тормышыбызда күңелле яңалыклар күренгәләп тора. 2001 елда «Раннур» нәшриятында басылып чыккан «Татар әдәбияты тарихы»ның VI томы —әнә шундый вакыйгаларның берсе булды.

Менә хәзер безнең алдыбызда шул китап ята. Аның күләме дә шактый гына—34 басма табак текст. Китапта күрсәтелгән санга ышансак, тиражы да бәләкәй түгел—20 мең данә.

Без бүгенге «Түгәрәк өстәл» сөйләшүенә әнә шул саллы хезмәт дөнья күрү уңаеннан җыелдык. Әйдәгез, ихластан фикер алышыйк, үзебезнең тәэсирләребез белән уртаклашыйк.

Беренче сүзне бу томның җитәкчесе һәм фәнни редакторы, филология фәннәре докторы Флүн әфәнде Мусинга бирәбез.

**Флүн Мусин:**

Элекке СССРдагы иң тирән тамырлы һәм күптән танылган әдәбиятларның берсе булса да, татар әдәбияты тарихын фәнни өйрәнү шактый катлаулы процесска әверелде. Монда совет чоры идеологиясе, бигрәк тә ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары өстәмә кыенлыклар тудырды. Шунлыктан байтак вакытлар безнең тарих өлешчә генә өйрәнелеп килендe. Аны тулаем колачлап яктырту мөмкинлеге бары 1960 еллардан соң гына туды. Һәм әнә шул шартларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар әдәбиятының күптомлы тарихын язу планлаштырылды. Башта фундаменталь характердагы бу хезмәтне биш томда башкару күздә тотылган иде. Алтмышынчы еллар уртасында булачак биштомлык әдәбият тарихының план-проспекты эшләнеп, киң әдәби-фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан тикшерелде һәм кабул ителде. Әлбәттә, бу план-проспектта әдәбият тарихын язу концепциясе нигездә шул чор рухында иде. Алга таба әлеге тарихны язу буенча эш җәелдерелде һәм аңа безнең төп фәнни көчләребез тартылды. Шундый гомум тырышлык белән әлеге биш томлык хезмәт сиксәненче еллар башына нигездә төгәлләнде. Һәм шул вакытта әдәбиятыбыз тарихын биш томда гына яктырту белән чикләнергә ярамаганлыгы ачыкланды. Чөнки план-проспектта да, язылган томнарда да әдәбиятыбыз тарихының алтмышынчы еллардан башланган яңа, мөһим һәм хәтта «яңарыш» дип атарлык чоры өлешчә генә искә алынган иде. Бу яңа чорны мөстәкыйль рәвештә, аерым томда яктырту ихтыяҗы туды. Һәм бу эш эшләнде дә. Әмма узган гасырның 60-80 елларындагы әдәбиятыбызны яктырткан бу алтынчы том идея-теоретик яктан алдагы томнар рухында язылды һәм сиксәненче еллар ахырында нигездә эш төгәлләнде. Әмма ул вакытта инде бу томны шул хәлендә дөньяга чыгару үзен акламаячак дип

табылды. Бердән, аның идеологик яктан заман таләпләренә җавап бирмәячәге ачыкланса, икенчедән, бу томда әдәбият тарихын XX йөз ахырына кадәр яктырту кирәк дип табылды.

Нәтиҗәдә том өстендә эшләү туксанынчы елларда да дәвам ителде. Башта авторлар үзләре язган бүлекләрне кабат карап, яңартып чыктылар. Аннары том редколлегиясе 60-90 еллар әдәби хәрәкәтен эзлекле һәм бербөтен процесс итеп күз алдына бастыру юнәлешендә редакцион эш башкарды. Әлбәттә, бу эш дәвамында хезмәтне элекке елларның тенденциоз карашларыннан һәм бәяләреннән арындыруга һәм гомум әдәби хәрәкәт, аның аерым тенденцияләре, күренешләре, конкрет язучылар иҗаты хакында объективрак фикер йөртүгә дә дикъкать ителде.

**Азат Әхмәдуллин:**

—Иң башта бер мөһим фикерне әйтеп үтик әле. Без бу «Тарих»ның үз вакытында чыгып калган алдагы биш томы турында «искергән», «кичәге көн җимеше» дигән кебек сүзләрне күп ишеттек һәм ишетәбез. Ләкин асылда дөрес булган бу бәяләр белән килешкән хәлдә дә, әлеге томнарның әдәбият белемебез өчен алга таба бер зур адым булуын танырга тиешбез. Чөнки кичәге идеологик һәм эстетик принципларга нигезләнгән булсалар да, бу томнарда күпгасырлык әдәби мирасыбыз тупланып бирелгән иде. Аерым язучылар турындагы мәгълүматлар, аерым әдәби әсәрләр хакындагы фактик материаллар, һәр тарихи чордагы әдәби процесс буенча әйтелгән фикерләр күп яктан үз кыйммәтләрен бүген дә саклыйлар. Аларны туплау-җыйнауга караганда бүгенге көн күзлегеннән карап аларга бәя бирү, әлбәттә, чагыштырмача җиңелрәк. Әмма моның өчен безгә яңа һәм ныклы бер концепция эшләргә кирәк.

**Флүн Мусин:**

Билгеле, әдәбияттагы яңарышны дөрес ачу бурычы фәнни тикшеренү методологиясенә дә игътибар бирүне, аңа да билгеле бер үзгәрешләр кертүне сорый. Без бу томда элекке еллардагы сыйнфыйлык принцибыннан күпмедер арынып, әдәбиятны тарихилык принцибына нигезләнеп һәм милли юнәлтелгән рәвештә өйрәнүгә дикъкатьне арттыра төштек. Әдәбиятыбызны күпмилләтле совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлеше итеп караудан аны милли мөстәкыйль сүз сәнгате дип аңлауга күчә башладык.

Алтынчы томда бу юнәлештәге беренче эзләнүләр һәм күзәтүләр, әдәби тарихыбызны яңартып язу өчен күпмедер нигез булып тора алалар. Әйтергә кирәк, мондый эш башланды инде. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге XX йөз әдәбиятыбыз тарихын яңартып язу эшенә тотынды.

Безнең милли идеологыбыз Г. Исхакый XX гасыр әдәбиятына түбәндәге вазыйфаны йөкләгән иде: «...без башка халыклар кебек әдәбият белән идарә кылыну гасырына җиттек. Моннан соң безнең халкыбызның тормышында да әдәбиятка иярү, әдәбият күрсәткәнчә йөрергә, булырга тырышу күренәчәктер. Әдәбиятның халкымызның киләчәге өчен зур файдасы булачак вә (ул) халкымызга юл башчысы булачактыр».

Әйтергә кирәк, узган гасырның беренче елларында Г. Исхакый әдәбиятка йөкләгән мондый гомуммилли вазыйфага XX йөзнең соңгы елларында кабат дикъкать ителә башлады һәм Ә. Еники аны, безнең заман ихтыяҗларына туры китереп, болай шәрехләде: «Русия империясендә яшәүче татар халкын бөтен бер милләт итеп саклау, аларның милли мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итү—әдәбиятыбызның иң изге бурычы».

Узган гасырның башында һәм ахырында ике олы классигыбыз шул дәвер татар әдәбиятына йөкләгән әлеге миссиянең әдипләребез тарафыннан ничек үтәлүен ачу XX йөз әдәбиятыбыз тарихын яңартып язуның төп максатларыннан берсе булырга тиеш.

**Азат Әхмәдуллин:**

VI томда әдәбиятны яңача күзаллау күренә. Бу—әдәби процессның үзегенә яңа төр, сәнгатьчәлек ягыннан камилрәк әсәрләр куелуда гына түгел, ә социализм чорында иҗат ителгән әсәрләр арасында шул вакыттагы идеология

кысаларында булып та, гомумкешелек идеалларын чагылдыра алганнарын алгы планга чыгаруда да күренә. Заманында дәррәү рәвештә нефть темасына, КамАЗ проблемаларына ябырылган татар әдәбиятының табышларга гына түгел, ә югалтуларга да дучар булуы ачыктан-ачык әйтеп-аңлатып бирелә анда. Томның баш мөхәррире профессор Флүн Мусин язган, шул чор әдәби хәрәкәтенә багышланган бүлекнең яңача һәм тирән булуын да күрсәтеп үтәргә кирәк. Мин аны хәтта киләчәктә язылачак әдәбиятыбыз тарихының булачак концепциясенә кереш дип тә карар идем. Әдәби процесска, жанрлар торышына караган (проза—Ф. Мусин, поэзия—Т. Галиуллин, драматургия—Н. Ханзафаров) бүлекләрдә дә яңа концепция чаткыларын күзәтергә мөмкин.

**Мәдинә Маликова:**

Бу китапның дөньяга чыгуын, әлбәттә, хупларга кирәк. Һәм без, язучылар, аны тарату, әдәби җәмәгатьчелеккә җиткерү өчен тырышырга тиешбез.

Бездә ел саен дистәләгән яңа әсәр дөньяга чыгып тора. Бу агымнан иң кыйммәтлеләрен, иң мөһимнәрен сайлап алу, әдәбиятның ярты гасыр эчендәге үсеш тенденцияләрен фәнни нигездә яктырту җиңел эш түгел. Китапның авторлары алга куелган бу максатка ирешкәннәр.

Минем уемча, бу китап шул чор эчендә иҗат ителгән әсәрләрнең киләчәк язмышында бик мөһим роль уйнаячак. Монда кертелгән, анализланган һәм югары бәяләнгән әсәрләр, мәдәниятыбыз хәзинәсенә рухи байлык булып өстәлер, ярты гасырның әдәбияты шуларга карап бәяләнер.

Мәгълүм ки, әдәбият турындагы тәүге төшенчәләр иң элек мәктәптә бирелә һәм күпчелек өчен ул төп нигез булып кала да. Ә мәктәп дәреслекләренә, һичшиксез, менә шушындый китапларда югары бәяләнгән, аерым алып анализланган әсәрләр кертеләчәк. Димәк, алар үсеп килгән буынның күңеленә дә кереп калачак. Бирелә телгә алынмаган яисә санап кына кителгән әсәрләрнең язмышы турында болай дип кистереп әйтеп булмый. Бу урында галимнәрнең җаваплылыгын искәртеп китәргә кирәк. Минем иманым камил, узган чорларда туган бик күп әдәби җәүһәрләр тарих көле астында күмелеп калганнардыр, чөнки аларны күтәреп алып, халыкка күрсәтүче булмаган. Бу чорда да шундый ук хәл кабатланмас, дип ышанып әйтеп буламы? Әйтик, бу томда Рафаил Төхфәтуллинга, Аяз Гыйләҗевка аерым бүлекләр багышланган, аларның иҗаты әдәбиятның агымыннан аерып алып күрсәтелгән. Моңа алар, әлбәттә, бик лаек. Шул ук вакытта Мөхәммәт Мәһдиев иҗатына багышланган аерым бүлек юк. Хәлбуки, егерменче гасырның икенче яртысында Мәһдиев иң күренекле прозаик иде. Бу хәл тиешенчә уйланып җитте микән һәм фәнни нигезләнде микән?

Язучыларны да үз иҗаты хакында җитди уйлануларга этәрә бу китап. Әйтик, аерым бүлекләр багышланган исемнәр арасында хатын-кыз исеме юк. Ярты гасыр эчендә бер генә татар хатын-кыз язучысы да аерым алып анализларлык, чорның әдәби тормышында әһәмиятле урын алырлык иҗат итә алмаган... Моңа уфтанырга гына кала.

Хатын-кызлар әдәбиятка үз бизәге, үз сүзе, үзенең рухи байлыгы белән киләләр, аларны ир-ат алыштыра алмый. Шуңа күрә аларның бөтен көчләренә иҗат итә алмавы, талантлары ачылмавы әдәбиятны ярлыландыра, аның үсешен тоткарлый. Хәер, бу нәтиҗәне беренче чиратта язучылар үзләре һәм аларның оешмасы булган Язучылар берлеге ясарга тиеш. Әдәбият тарихы ул—безнең көзгебез, әгәр анда чагылган бик күп ир-егетләр арасында бер генә хатын-кызның йөзе дә чагылмый икән, монда галимнәрне гаепләү дөрес булмас.

**Азат Әхмәдуллин:**

Мин бераз аңлатма биреп китим әле. Бу томны әзерләүчеләр түбәндәгеләргә таянып эш йөрттеләр. Беренчедән, томга монографик бүлекләр итеп иҗатлары инде тәмамланган, матур сүз сәнгатендә чын мәгънәсендә эз калдырган язучылар кертелде. Икенчедән, әлегә исән-сау булган, әмма инде әдәбиятыбызда үз сүзен әйтә алган, бүгенге әсәрләр арасында аерылып торган иҗат җимешләре булган язучылар урын алды. Аларны сайлап алуда коллектив фикере, әдәби тәнкыйть фикере төп рольне уйнады. Барлык язучыны да «Әдәбият тарихы»на кертеп бетереп булмый икәне барыбызга да аңлашыла. Шулай да игътибар иткәнсездер, бүгенге мөһим әсәрләрнең күпчелеге күзәтү характерындагы бүлекләрдә тегеләйме-болаймы урын алды яисә чагылды. Бу сүзләрне мин,

мәсәлән, үзем яхшырак белгән драматургик процесска караган бүлеккә карата ныклап әйтә алам. Монда бер генә драматургның да сәхнәдә куелган пьесасы онытылмаган, хәтта яшь буынның уңышлырак әсәрләре дә күз уңында тотылган. Әлбәттә, драматургиядә бу җәһәттән эш җиңелрәк, әсәрләр саны йөзәрләп кенә санала. Прозада, бигрәк тә шигъриятттә исә эш катлаулырак. Боларда әсәрләр саны меңәрләп исәпләнә, авторларның исемнәрен генә санап чыгу да күп урын алыр иде. Шуңа да монда сайлап алу принцибы зур роль уйный. Менә монда инде тарихчы галимнең эрудициясе дә, гыйльми принциплары да, хәтта кайчакта шәхси симпатиясе яки зәвыгы нинди булу да бик мөһим. Әгәр дә бүгенге тәнкыйть сүзләрендә шул соңгылары истә тотылса, без, том авторлары, аларны кабул итәбез.

Без бүгенге сөйләшүдән үзебез өчен киләчәктә эш йөртү өчен нәтиҗәләр ясарлык мәгънәләр дә эзләп утырабыз. Чөнки Г. Ибраһимов исемендәге институтның әдәбият белеме бүлеге XX гасыр әдәбияты тарихын иңләп алган яңа зур хезмәт язуны планлаштыра. Бу—әдәбият гыйлеменең хәзерге торышыннан карап, бүгенге югарылыкта язылган, концепциясе яңа булган тарих булыр. Безнең бурыч: анда 6 томлыктагы кимчелекләр кабатланмасын иде. Бу концепция буенча эшләнгән хезмәттә, ихтимал, материалны бирү формасы да үзгәрәк булыр. Әйтик, бүлекләргә бүлү, монографик бүлекләрне бирү мәгънәсендә. Бәлкем кайбер язучыларның мирасын чагылдыруны иҗади мәктәпләргә берләштереп бирергәдер?

**Фәрит Бәширов:**

Мин Азат абыйның сүзен дәвам итим әле... Әйе, булды, бу томны бөтенләй чыгармаска диючеләр дә булды. Өр-яңадан эшләү идеясен куәтләүчеләр дә аз түгелләр иде. Бастырмый калу иң җиңел юл анысы, әлбәттә. Ягъни, китап та юк, проблема да юк! Әмма, XX гасырның икенче яртысындагы татар әдәби хәрәкәтен эченә алган бу том бүген кирәк! Укучыларга, укытучыларга кирәк, гомумән, әдәбият тарихыбыз белән кызыксынган һәркемгә кирәк! Күпме фактик материал, әдәби-мәдәни байлыгыбыз хакында никадәр мәгълүмат тупланган бит анда! Шуңа да, фикерле укучыбыз ул биниһая материалны аңы, заманча карашы аша уздырып, үзе нәтиҗә ясар дигән нияттән чыгып, хезмәтне нәшер итәргә кирәк табылды. Тагын шуны да әйтү зарур: томның әһәмиятен аңлаган, укучы ихтыяҗына гаять сизгер булган «Раннур» нәшрияты китапны заманы өчен зур тираж белән бастырып та чыгарды.

Ә инде кемнәр белән карап, төзәтеп чыгарга дигән уй үзеннән-үзе төшеп калды. Безнең өр-яңа том төзерлек башка галимнәребез юк, янәдән шул авторларга мөрәҗәгать ителде. Һәм, шушы китапны чыгаруда турыдан-туры катнашкан кеше буларак икърар итәм: галимнәребез һич сыкранусыз үзләре язган бүлек-өлешләрне кабаттан җентекле күздән кичерергә риза булдылар. Шәхсән мин үзем аларга, бу иҗтиһадлары өчен тиен дә акча түләнмәгәнлеген белгән хәлдә, фәкать китапның кирәклеген аңлап фидакарьләрчә эшләүләре өчен чиксез рәхмәтлемен.

Хезмәтнең дөнья күрүе баштан ук ниятләнгән алты томлыкның төзек бөтенлеген саклау хакына да кирәк иде. Табигый ки, бу том, яңа таләпләр нигезендә иске идеологик штампларны тәнкыйть күзлегеннән тикшереп «сөреп» чыгуга карамастан, кимчелекләрдән азат түгел. Чөнки сипләнгән йорт һич кенә дә яңа йортка дәгъва кыла алмый. Аннан килеп, кайбер бүлекләрнең авторлары (Г. Ахунов, Ф. Миңнуллин), шул җөмләдән баш мөхәррир Н. Г. Юзиев та—инде мәрхүмнәр. Алар язганнарга тоталь ревизия ясау ирексездән бакыйларның рухына кагылу булыр сыман тоелды. Шул рәвешле, китапны бар «минуслары» белән басмага тәкъдим итү максатка ярашлы дип табылды.

Аннары бу томнан янә шуның өчен дә баш тартып булмый иде, чөнки ул соңгы чор татар әдәбияты белән таныштыручы бердәнбер фәнни хезмәт ролен үти. Китапта 60-90 еллар әдәбиятының проза, поэзия, драматургия кебек асыл төрләрендә үсеш-табыш күренешләре белән беррәттән, кыенлыкларга, эзләнү процессларына да дикъкать бирелә. Хезмәт әлеге юнәлештә җитди мәсьәләләр күтәрә һәм аларны чишү юлларын тәгаенли. Бу исә, үз чиратында, алдагы тикшеренүләрдә дә, шул уңайдан, татар әдәбияты тарихының яңа томнарын әзерләүдә дә (әйтергә кирәк, бу эш инде бара) ныклы таяныч булачак. XX гасыр ахыры әдәбияты сыйфат ягыннан да, тармаклану җәһәтеннән дә милли әдәби-мәдәни тормышта үзгә урын били. Аны үзләштерү, әчке хасиятен ачарга

омтылу бүгенге әдәби процессны аңлау, алга таба фикер йөртү өчен дә ныклы нигез әзерли.

**Роза Хафизова:**

Татар әдәбияты тарихының VI томын кулга алдык. Куанычлы вакыйга. Димәк, язган әсәрләребез таркалып, югалып калмый, тарих битләренә теркәлде дигән сүз. Табигый ки, балалар язучысы буларак, мине китапның балалар әдәбиятына караган өлеше кызыксындырды.

Бу томда балалар әдәбияты тарихына багышланган күләмле генә мәкалә урнаштырылган. Мәкалә 60-90 еллар әдәбиятын эченә ала. Авторы—Фатыйма Ибраһимова. Автор көченнән килгән кадәрле бу чор әдәбиятын барларга, аңа бәя бирергә тырышкан. Мактауга лаек гамәл. Әмма 30 еллык балалар әдәбиятын шушы бер мәкаләгә кысрыклап кертергә тырышу, нинди генә күзлектән карасаң да, мантыйкка сыймый. Бу мәкаләдә балалар әдәбияты хәтта жанрларга да бүлеп каралмаган. Барысы бергә—проза, поэзия, драматургия... Анда балалар язучыларының исемнәре, аларның кайбер әсәрләре (60-70 еллар тирәсендә язылганнары) телгә алынган, билгеле. Әмма аларга җәмгыятьнең үсеш тенденцияләре белән бәйле рәвештә төпле анализ җитенкерәми.

Белгәнемчә, ул елларда балалар язучылары гына түгел, иң дәрәҗәле өлкән язучыларыбыз да балалар өчен әсәрләр язуны үзләре өчен мактаулы эш итеп санадылар. Нәкый ага Исәнбәт, Гомәр ага Бәширов, Нәби ага Дәүли, Ибраһим ага Сәлахов, Мөхәммәт Мәһдиев һ. б. язучылар югары сыйфатлы әсәрләре белән балалар әдәбиятын баеттылар. Миңа калса, безнең 60-90 еллардагы балалар әдәбияты язылган әсәрләрнең саны, аларның эчтәлеге, үзәккә куелган проблемаларның төрлелеге ягыннан чагыштыргысыз бай булуы белән аерылып тора. Бер мәкалә генә 30 еллык балалар әдәбиятының торышын тиешенчә чагылдыра алмый.

**Рифә Рахман:**

Алтынчы томлыкның чыгуы—зур шатлык, әлбәттә. Шуңа да карамастан, ул күңелдә яшәгән борчуларны арттырды гына. Мин үзем китап белән танышуны «эчтәлек»тән башлыйм. Шул битне ачуга ук йөрәк кысылып куйгандай булды.

Турысын әйтим: галим-голяманың, монографик планда анализлау өчен, авторларны сайлау принцибыннан канәгать калмадым. Сүзне поэзиядән башлыйк. Алтмышынчы еллар шагыйрьләрен уяткан, дөнья әдәбиятында үз урынын алырлык шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов иҗаты аерым тикшерелмәсен әле!

Әгәр без ничәдер унъеллыкны бергә анализлыйбыз икән, ничек инде җитмешенче-сиксәненче еллар прозасыннан М. Мәһдиевне калдырырга мөмкин?! Аның турында XXI гасыр әдәбиятында язарга җыенмыйбыздыр лабаса! Шундый сораулар бихисап.

Күләм арта дип уйлаганда, бәлки әдәбиятны чагылдыруны тагын да кыскарак аралыкка калдырырга кирәк булгандыр. Ә нигә аерым авторларга бирелгән бүлекләрне кыскартмаска?! Бәлки, әдәбиятның үзен кечкенәрәк аралыкларда өйрәнергә кирәктер?

Гомуми характердагы язмаларда, әдәбиятта әллә ни эз калдырмавына карамастан, әдәби мирасы зур булмаган яисә хәзер инде язудан бөтенләй туктаган авторлар мактап телгә алынып, әдәбият йөген ныклап тартып баручыларның исеме дә аталмау шулай ук борчый.

Мин үзем М. Әгъләм, Л. Шагыйрьҗан, М. Галиев һәм башка авторларга—урынны, ә инде мактау обоймасына кергәннәрне яңадан карап чыгу, йә үзгәртү өчен вакытны кызганмас идем. Ә бит әле кычкырып торган талантлы күпме шәхес—гел тибәрелүдә! Фән, әдәбият дөньясына тирәнрәк узган саен, гаделлекнең йә бөтенләй торгызылмавын, ә сирәк кенә очракта бик соңга калып торгызылуын күрәсең, төшенкелеккә биреләсең. Кызганыч, бер үк иҗатка, бер үк каләм иясенә әдәби җәмәгатьчелек белән фәнни җәмәгатьчелекнең карашы еш кына кискен аерыла.

**Гөлчәчәк Галиева:**

Татар әдәбияты тарихының VI томы дөньяга чыгу үзе бер тарих. Ул күптәннән көтеп алынган зур вакыйга. Анда аерым бүлек итеп бирелгән

язучыларның иҗатларына проза буенча—Р. Сверигин, Ф. Хатипов, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, поэзия буенча— Н. Юзиев, Г. Ахунов, Р. Мостафин, З. Рәмиев, драматургия буенча—А. Әхмәдуллин, әдәбият фәне һәм тәнкыйть буенча Н. Юзиевлар тарафыннан язылган җитди анализлар зур игътибарга лаек. Рәхмәт яусын үзләренә, бакый дөньяга күчкән мәрхүм Нил Юзиев һәм Фәрваз Миңнуллиннарның урыннары җәннәттә булсын!

Яңарыш та сизелә бу томда, әмма иске фикерләрдән дә арынып бетә алмаган. Бу томның күптән язылган булуын искә алып, өстәмәләр кертелергә тиешлек турында, ни өчендер, кереш өлешендә дә бер сүз дә әйтелмәгән. Анда мин мондый юлларга тап булдым. «Үзенең бөтен иҗаты белән кадерле мирасыбызга әйләнгән Нил Юзиев хакында махсус бүлекчә бирү кирәк табылды». Ә бүлекчә дигәннәре—искиткеч талантка ия булган, ифрат та тырыш һәм үтә дә эшчән булган мәрхүм галимебез Нил Юзиев турында кыска гына белешмәдән гыйбарәт.

Томның проза бүлегендә ул елларда актив иҗат иткән Фәнис Яруллин турында бер генә җөмлә дә бирелмичә, аны бөтенләй игътибарсыз калдыру аңлашылмады.

Аннары, хатын-кыз язучыларыбызның берсенә дә аерым бүлек бирелмәгән. Авторларыбыз андый игътибарга лаек булырлык хатын-кыз язучылар юк дип әйтергә теләгәннәрме?

**Зиннур Мансуров:**

Нигезе зур булган әдәбиятның тарихы да зур. Дөресен генә әйткәндә, теләсә кайсы әдәбиятның «тәрҗемәи хәле»н җәмгысе 3 меңнән артык биттән торучы аннал-елъязмаларга сузып та булмый. Бу уңайдан без халкыбызның биниһая зур талант көче, аның зур әдәбияты, зур әдипләре белән хаклы рәвештә горурланып яши алабыз. Һәм, әлбәттә, форсаттан файдаланып, бу уникаль хезмәтне әзерләгән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, бигрәк тә томнарны эшләгән галимнәр төркеменә, язучыларга, шулай ук нәшриятләргә ихлас рәхмәт белдерәсе килә. Алар чын-хак тарих язу өчен бик үк җиңел булмаган төрле шартларда, тиешле матди әҗер алуга да өмет итмичә һәм хәтта юньле-башлы рәхмәт тә ишетмичә, тау кадәр «кара эш»не, татар халкы тарихына бер саллы өлеш рәвешендә кирәрлек бик тә кирәкле гамәлне фидакарьләрчә башкарып чыктылар.

Әмма күчеш елларының очын-очка ялгау елъязмачыларга беркайчан да җиңел бирелми. «Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы томында да авторларның ике ут арасында калуы сизелә. Шуның нәтиҗәсе буларак, әдәби хәрәкәтнең яктыртылышы искечә фикерләүдән әлегә арынып та бетә алмаган. Китапның иң зур кимчелеге, мөгаен, әнә шуннан гыйбарәттер. Чын хакыйкатьне ачу юлындагы байтак киртәләрне җимергән «үзгәртеп кору»га да инде ике дистә ел чамасы вакыт үтеп бара. Өр-яңа гасырда яшибез. Татар әдәбиятының 60-90 еллардагы үсешенә, инде әйткәнемчә, бераз гына читтәнрәк караш ташларга да мөмкинлек булды. Әмма совет идеологиясенең ген-зиһен күзәнәкләренә сеңгән тәрбиясен алай ансат кына үзгәртү мөмкин түгел шул. Безнең һәммәбез дә шушы мәктәптән: әлеге елларда иҗат иткән каләм ияләре дә, аларның язганнарын бәяләүче әдәбият галимнәре дә...

Ничек кенә булмасын, китапның туганда ук бераз «искерә» төшүен мин алай ук калкытып куймас идем. Тарих язу кебек четерекле эштә андый хәлләр еш күзәтелә. Үзебезнең фикерләү калыпларын ничек кенә бәяләсәк тә, әдәби хәрәкәт агышын нәкъ менә без теркәп калдырырга тиештер. Мондый вазифаны киләчәк буын вәкилләренә йөкләп булмый бит инде, гәрчә алар «саф, ачык күзләр белән, чын аң белән» эш итәргә өметләндерсәләр дә. Аңлашыла ки, илхалыклар тарихында төрледән-төрле хата-ялгышлар хөкем сөргән кебек, әдәби елъязмаларда да хакыйкатькә бик үк туры килмәгән шәрехләүләр булырга мөмкин. Минемчә, иң мөһиме—яктыртыла торган әдәби хәрәкәт турында мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат бирү, милли традицияләр дәвамлылыгын ачып күрсәтү, яңа тенденцияләрне тоемлау... Шул ук вакытта әдәбият тарихы гомум үсеш юлыннан тайпылу очракларын да гадел рәвештә чагылдырырга тиеш. Менә шундый хезмәт бүгенге әдәби җәмәгатьчелек өчен дә, киләчәк заман укучылары өчен дә файдалы булачак. Әдәбиятыбыз тарихының әлеге яңа томында боларның барысы да бар дип уйлыйм.

**Рабит Батулла:**

Бу сөйләшүдә катнашучылар төрле сүзләр белән бер үк фикерне әйттеләр: —Әйбәт китап чыккан... кирәкле китап. Ләкин анда җитешсезлекләр күп... Исемнәре санап кителүдән узмаган шәп шагыйрьләр дә, исемнәре бөтенләй китапка кермәгән язучылар да моңа үпкәлидер, әлбәттә.

Китапта үз әсәрләрем турында фикер әйтелмәгәнгә мин һич тә үпкәләмим, чөнки искергән ысул белән макталганчы, яңа ысулда сүгелүең мең өлеш артыграк.

Әдәбият фәне, тәнкыйть ул яңа шәхесне ачарга яки мәгълүм әдипнең без белмәгән якларын бәян итәргә тиеш. Шуны эшлиме безнең әдәбият галимнәре?

Рәшит Әхмәтҗан, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Лена Шагыйрьҗан кебек шагыйрьләрнең халык моңнарына таянган әсәрләренең, хис аша зиһенияткә тәэсир итүе, ә Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Фәиз, Ләис Зөлкарнәйләр, Җәүдәт Сөләйман, Рөстәм Сүлти кебек шагыйрьләрнең ассоциацияләр аша халык күңеленә узарга омтылулары турында язарга да язарга, юкса. Боларның һәрберсе диссертациялек мәүзугъ.

Сиксән ел буена турысын әйтергә ярамаганда татар шагыйрьләре, бигрәк тә алтмышынчы еллардан башлап, әйтергә теләгәннәрен тел төбенә, астарлы сүзгә яшереп, читләтеп, кактырып-суктырып иҗат итәргә дучар иде. Өстеңдә кылыч асылынып торганда шулай кылмый, кая барасың? Кырык ел шул юнәлештә иҗат ителгән әсәрләрнең тел төбен ачып салу—галимнәрнең, тәнкыйтьчеләрнең бурычы.

Рәшит Әхмәтҗанның музыкага, симфонияләргә тиң иҗаты, аның асылы, иҗат ысуллары турында да җитди хезмәт күренми шикелле.

Лена Шагыйрьҗан кебек кантарлы куәгә ия шәхеснең иҗатын толыкманы белән кем өйрәнеп ята?

Рәдиф Гаташның лирикасы үз галимнәрен көтеп ята.

Разил Вәлиев белән Марсель Галиев—икесе дә олпат әдип, аларның каләме бар жанрларда да иркен гизә.

Инде үзләре остаз, инде үзләре күпме шәкерт тәрбия кыйлган шушы әдипләргә әдәбият тарихчылары аерым бер том багышламаса, XX йөз татар әдәбияты тулы канлы булып күренмәс!

Алтынчы китап исә, гомум сүзләр, иске гыйбарәләр белән язылган мәкаләләр белән тулган. Язучыларның, әдипләрнең, шагыйрьләрнең җанлы иҗади образлары китапта күренми.

Әлбәттә, күп хезмәт түгелгән, язылганнары да ярыйсы, әмма алга таба әдәбият фәне коры фәнни мәкалә белән түгел, җанлы сүз белән җанлы иҗат турында сөйләргә тиеш.

**Зиннур Мансуров:**

Минемчә, бу томның шигърияткә багышланган өлеше уңышлы чыккан. Төп мәкаләнең әдәбият белгече һәм тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин тарафыннан язылуы бик табигый. Ни өчен дигәндә, аның соңгы берничә дистә елда шигърият өлкәсендә иң нәтиҗәле эшләүче галимнәребезнең берсе булуы һәркемгә мәгълүм. Шагыйрьләребезнең һәрбер әсәрен ул исемләп беләдер шикелле. Үзе генә дә бер шигъри энциклопедия чыгарырлык мәгълүмат туплаган, шигъриятебезне теләсә нинди мөнбәрләрдән тәкъдир итәрлек шәхесебез!

Әдәбият галиме Нил Юзиевнең шагыйрьләр Гамил Афзал һәм Шәүкәт Галиев турындагы аерым мәкаләләре дә чын иҗат портретлары таләпләренә җавап бирә. Аларны укыганнан соң үзалдыңа янә әйтеп куясың: Нил абый һәрвакытта да яңача фикерләргә омтылучы, тирән һәм масштаблы итеп уйлый белүче, югары интеллектлы, шигъри җанлы галим дәрәҗәсендә кала алды һәм анда күп кенә әдәбият белгечләрендә күзәтелгән «катып калганлык» беркайчан да булмады.

Минем карашымча, авторлар даирәсен төрләндерү җәһәтеннән язучы Гариф Ахуновның шагыйрь Равил Фәйзуллинга багышланган мәкаләсен урнаштыру да акланадыр. Чынлыкта иҗат серләрен җаны-тәне белән тойган әдипләрнең үз каләмдәшләре турында язуы әдәби тәнкыйтьнең бер кызыклы тармагы рәвешендә инде күптәннән яшәп килә. Бу табигый күренешне йөз чөермичә генә таныргa һәм күмәк хезмәтләргә һәртөрле авторларны активрак тартырга кирәк. Әдәбиятыбыз турындагы төп тарихи белешмәне язганда

принципиаль карашлар төрлелегенә ирешү бик мөһим. Югыйсә китапта бер үк авторлар еш кабатлана, ә мондый хәл үзеннән-үзе чикләнгәнлеккә китерә.

Таләпчән укучыга китаптагы кайбер мәкаләләрнең урыны-урыны белән тарих-елъязма стиленә бик үк туры килмәве дә сизелгәләп куядыр. «Әллә соң алар әдәбият тарихы өчен махсус язылмаганмы икән?» дип көрсенергә мәҗбүр буласың. Ничектер, башка уңай белән эшләнгән докладларны «кайчы һәм келәй» ярдәмендә ашлау-сипләү очраклары да булгандыр кебек тоела. Кайбер авторларга энциклопедик кыска-тыгыз бәя бирү осталыгы җитеп бетми. Теге яки бу каләм иясенең кайтышрак әсәрләрен яки китапларын аның уңышлары рәтендә санап үтүләр дә күзгә ташлана. Аерым әдәби жанрлар буенча язылган махсус бүлекләрдә (шул исәптән кереш мәкаләдә дә) шушы тарихи вакыт аралыгында әдәбиятыбыз казанышы булып танылган кайбер яңа әсәрләр һәм, әлбәттә, аларның авторлары, шулай ук яңа тенденцияләрнең төсмерләнүе ничектер телгә алынмаган. Гомумән, күзәтүләрдә соңгы биш-алты ел, кай очракта хәтта дистәгә якын ел ни сәбәпледер төшеп калган шикелле. Нәкъ менә шушы чорда киң танылуга ирешкән зур шагыйрьләребез Роберт Әхмәтҗан, Рәшит Әхмәтҗан, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Зөлфәт һ. б. ларга багышланган бүлекчәләр бирү дә елъязманың офыкларын киңәйтебрәк җибәрер иде. Полиграфик яктан шактый әйбәт эшләнгән басманы күренекле әдипләрнең фотосурәтләре белән бизәү дә кирәк булгандыр.

Сүз дә юк, тормышның үзе теләсә нинди тарих дәреслегеннән күпкә баерак, гыйбрәтлерәк булган кебек, әдәбиятның җанлы хәрәкәте дә елъязмаларның тар кысаларына сыешып бетә алмый. Әмма әдәбиятыбыз тарихының VI томы авторлары, барыбер, үз максатларына ирешкән дип саныйм. Һәрхәлдә, бу китапта һәр каләм иясе үзен туган йортында кебек хис итәдер. Ә инде искечә фикерләүдән котыла алмауга килгәндә, бу мәсьәләне кыска вакыт эчендә генә хәл итеп булмый. Бозылуга дучар ителгән җирне, туфракны эшкәртеп торгызу өчен дә озын-озак еллар дәвамында эш алып барырга кирәк. Рухны «реставрацияләү» өчен дә шактый вакыт таләп ителә. Ә әдәбиятны чын сәнгатьчәлек күзлегеннән чыгып өйрәнү эшен методологик принципларны бергәләп яңартудан, алмашынып торучы идеологияләрдән мөмкин кадәр азат булган уртак концепция әзерләүдән башлау хәерлерәктер.

Татар халкы, әйе, китаплы халык. Безнең әдәбият тарихы китабы да зур әдәбиятыбызга лаек булырга тиеш!

**Рифат Сверигин:**

Татар әдәбияты тарихының алтынчы томында минем дә «бер тамчы балым» бар—шуңа күрә авторларының берсе буларак та мин аның дөньяга чыгуына сөенәм. Ә бит аны югалтуыбыз да бик мөмкин иде! Ул «соң булса да, уң булсын» дип укучыларга җиткерелде. Кайберәүләргә хезмәт чыннан да бераз искерә төшкәндәй булып тоелырга мөмкин: «безгә моннан 15-20 ел элек әйтелгән фикерләр нигә кирәк инде?» диючеләр дә табылыр. Минемчә, монысы кирәгеннән артык сагаю булыр иде. Чөнки авторлар элеккеге мәкаләләрен яңабаштан карап, яңартып чыктылар. Әмма шунысы бар: бу галимнәрнең берсе дә конъюнктура җилләренә карап принципиаль концепцияләрен җиңел генә үзгәртә, алмаштыра торганнардан түгел.

Хәтта бу материаллар хәзер «бераз искергәнрәк икән» дигән очракта да безнең әлегә альтернативабыз юк—хәзерге әдәбиятка бәйләнешле материалларны яңача яисә шушы дәрәҗәдә бергә җыеп, туплап яктырткан башка басмалар әлегә эшләнмәгән. Шуңа күрә, әлеге алтынчы том «менә бу—яңа гасыр татар әдәбияты» дип китап сөючеләр кулына тоттырырлык бердәнбер китап булып кала бирә. Укытучылар, югары уку йортлары студентлары өчен дә бик кирәкле һәм уңайлы кулланма ул.

Әлбәттә, алга таба әтрафлырак, масштаблырак эзләнүләргә күчәргә кирәк. Мәсәлән, «Хәзерге әдәбият тарихы»ның өч томлыгы яисә биш томлыгы дип фараз итик. Шул вакытта әдәби хәрәкәт тә, агымнар да, әдипләрнең иҗатлары да тулырак ачылыр.

Безгә, ниһаять, әдәби күренешләрне фәкать социаль-сәяси күзлектән яисә конъюнктурага туры китерергә тырышып анализлау чиреннән котылырга кирәк. Әдәби әсәрләргә эстетик җәһәттән якынлашып, алардагы сәнгатьчә гүзәллекне бәяләү, образлы фикерләрне авторның әдәби осталыгы, кулланган стиль-сурәтләү чаралары белән, тормыш күренешләрен үзенчә художестволы итеп

яктырту осталыгы белән бәйләнештә аңлату, анализлау—беренче чиратта әнә шулар житешми бүгенге әдәбият фәненә һәм әдәби тәнкыйтькә. Димәк, әлеге өлкәдә эшләүчеләрдән эстетик хәзерлекнең аеруча камиллеге, фикер кыюлыгы, аерым очракларда аның оригинальлеге, эрудиция сорала.

Чынбарлыкта исә, әлегә боларның күбесе яхшы теләкләр дәрәҗәсендә генә кала бирә. Әдипләрнең индивидуаль иҗат стильләрен тикшерергә алынучылар да, нигездә, лингвистик анализдан ары уза алмыйлар. Шушы уңайдан, бүгенге әдәбият гыйлеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә тарала һәм көчәя башлаган бер күренеш яисә тенденция турында да әйтеп үтәргә уйлыйм: хәзер кайбер галимнәребез татар язучыларының аерым әсәрләрен дөнья әдәбиятындагы күренешләр, хәрәкәтләр, агымнар, методлар яктылыгына куеп карарга, аңлатырга тырыша башладылар. Бу—гомумән алганда, игътибарга һәм мактауга лаеклы күренеш. Моның шактый кызыклы һәм матур үрнәге булып миңа Йолдыз Нигъмәтуллинаның рус телендә яңа гына дөнья күргән «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве» / *Казань: изд. «Фән». 2002.* / исемле китабы тоелды. Шәхсән мине галимәнең дөнья әдәбияты һәм сәнгатендә туып, яшәп килә торган яңа күренешләрдән хәбәрдарлыгы сокландырды.

Төп проблема һәм кыенлыклар үзебезнең татар җирлегендә туган әдәби әсәрләрне өйрәнгәндә барлыкка килә башлый. Чагыштырып анализлау эшенә җөрьәт иткән бүтән галимнәребез гадәттә бер аякка аксый башлый, яисә дөнья әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә аларның алыш-бирешләре бик чамалы була, яисә, киресенчә, анысын үзләштерәм дип азапланганда яңа милли әдәбияттагы сәнгати-эстетик үзгәрешләрнең асыл мәгънәсе һәм структур үзенчәлекләре игътибардан читтәрәк кала. Бәлки менә шуңа күрә яшь тикшеренүчеләрне модага кереп килүче, әмма эчтәлекләре күпләргә бигүк ачык булмаган ялтыравыклы терминнар ныграк кызыксындыра торгандыр. Һәм менә шуннан соң инде татар әдипләре әсәрләреннән көчәнеп, тырышып, модернизм яисә постмодернизм күренешләрен хәтерләткән элементлар табып, аларны бөтендөнья әдәбиятындагы шаукымнарның татар әдәбиятына килеп җитүе, аны баетуы, дип аңлатулар китә... Әмма, дөресендә, әлегә шул терминнардан ары китү юк—биркалар белән уйнау-шаяру гына бара.

Дөрес, ялтыравыклы терминнар белән белер-белмәс шаяру алтынчы том авторларына хас түгел—инде олыгаеп килүче бу галимнәр гомерләренең калган өлешләрендә «бозылырга» өлгермәсләр дигән нык өметтә калабыз. Әдәбият тарихының яңасын башка, яшьрәк галимнәр язарлар. Аларга югарыда әйтелгән куркыныч янамасын иде. Моннан котылу чарасы бер генә—дөнья әдәбиятындагы процессларны бик яхшы белү өстенә, туган әдәбиятындагы кызыклы һәм бүген барлыкка килә торган күренешләрнең үзләренә генә хас оригиналь якларын җентекләп өйрәнү һәм шуларның эчке образлы мәгънәләрен укучыларны ышандырырлык итеп аңлату, төшендерү чараларын эзләү. Ә монысы—терминнар белән туп чөеп уйнау түгел. Бу—бөтенләй башка әйбер.

**Фәрит Бәширов:**

Шәхсән мин үзем бүгенге утырыштан канәгатьмен: фикер алышу нигездә конструктив төстә барды. Язучылар, гомумән, кызык халык бит алар! Алар белән әңгәмә-бәхәс кору—үзе бер гыйбрәт. Гомер бакый әдәбият галиме белән язучы арасында күзгә күренмәс киртә яшәп килде һәм алга таба да яшәр инде ул... Язучы—хис кешесе, галимнең төп кыйбласы—акыл, фикер дөньясы. Бүгенге сөйләшү—моның ачык мисалы. Томга карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренең күбесе «обоймага» кергән әдипләр иҗатына «чамадан тыш киң урын бирелүенә» юнәлтелгән иде. Башта аңламадым. Аңлаттылар. Баксаң, «обойма» дип һәрвакыт игътибар һәм хөрмәт үзәгендә булган язучылар күздә тотыла икән. Алай... «Хуш...»,—дип әйтер иде мондый очракта Әмирхан ага Еники. Соң, җәмагать, ул әдипләр бит иҗатлары белән әдәби процесста танылуларын талантлары, тырышлыклары һәм үтә актуаль проблемалар күтәреп шуларга җавап эзләүләре, чишелеш юлларын күрсәтә алулары аша яулап алган шәхесләр, ләбаса! Югарыдан төшерелгән күрсәтмә нигезендә сайлап алынган затлар түгелләр! Әдәбият белеме иң әүвәл мәсьәләгә төрле яклап килүне, комплекслы өйрәнүне таләп итә. Бер көнлек уңышлар түгел, ә еллар дәвамында әйдәп баручы көч булган, вакыт сынавын узган иҗатлар үзәккә алына икән—бу нинди хилафлык ди? Кирәгез соң «обоймага», раслагыз каләмегезнең ныклыгын—

килер хөрмәт тә, аерым игътибар да, махсус өйрәнүләр дә. Ә хәзергә—бигайбә! Шуңа да мин томның төзелеше дөрес дип саныйм, әдәби процессны билгеләүдә сайлаган мәсләге отышлы дип таныйм. Ә бәхәс-сөйләшү оештыру, һичшиксез, кирәк нәрсә. Үз кабыгыңа бикләнеп кенә фикер йөртә калсаң, мүкләнә башлавыңны сизми дә калуың бар. «Хакыйкать бәхәстә туа», диләр бит. Бергә-бергә уйланыйк, эзләник. «Ничек эшләмәскә иде» дигән тәнкыйть белән бергә «алга таба ни рәвешле эшләргә» дигән сорауны ешрак бирик. Җавап эзлик. Кыйблабызны ачыклыйк.

---

Флүс Латыйфи

# 2002 ЕЛ ПРОЗАСЫНА БЕР КАРАШ

ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ «ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ» ҖЫЕЛЫШЫННАН

Узган ел дәвамында басылып чыккан чәчмә әсәрләр турында сөйләгәндә без иң әүвәл татар прозасында бүген хөкем сөрүче вәзгыятьне ачыкларга тиеш. Әлегә гади укучы тоемлап та бетермәгән, чекрәеп үк тормаса да, инде тамырлана башлаган процессларны, тирән зәвыклы язучы яисә тәнкыйтьче күзе генә тотып ала алырлык кайбер үзгәреш-үсеш чалымнарын, йә булмаса, прозаның котылгысыз рәвештә зәгыйфьләнә баруын тоябызмы, сиземлибезме? Прозада сан һәм сыйфат ягыннан нинди үзгәрешләр бар?

Сан ягыннан исә үзгәрешләр житәрлек. Сиксән еллык тарихы һәм инде үзенә генә хас, калыплашкан традицияләре булган «Казан утлары», чыга башлавына берничә ел гына булуга карамастан, үзен дәрәҗәле олпат журналлар сафына куя алган «Мәйдан», яшьләргә хас максимализм чалымнарын да сиздереп килүче «Идел» һәм академик «Мирас» журналларында узган елда барысы 68 авторның туксанга якын проза әсәре басылып чыккан. «Ялкын», «Чаян», «Сөембикә» кебек журналларда, «Мәдәни жомга», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» кебек газеталарда дөнья күргән әсәрләрне дә исәпләсәк, укучыга барып ирешкән әсәрләр саны бәлки ике йөздән дә ашар иде.

«Мәдәни жомга» газетасы, мәсәлән, «Атлар турында хикәяләр» дигән махсус бәйге оештырды һәм анда егермеләп автор катнашты. Дөрес, ул хикәяләрнең кайберләре теге яки бу кешенең тормышында булып узган хатирә-истәлектән гыйбарәт булса да, арада чын мәгънәсендә югары әдәби кимәлдә эшләнгәннәре дә аз түгел иде. Ул циклны киләчәктә дә дәвам иттереп, бәлки махсус җыентык–китап чыгару да кызыклы бер гамәл булыр иде. Татар тормышын, татар тарихын һәм чынбарлыгын без аттан аерып карый алмыйбыз лабаса!

Сан ягыннан караганда, прозабызда хәлләр менә шундый.

Инде сыйфат ягына килик. Аны еш кына тормышыбыз, яшәү дәрәҗәбезнең сыйфаты белән дә тәңгәл куеп карыйлар. Бәлки дөрестер дә. Ләкин минем аксиомага әйләндерелгән бу карашны кире кагасым килә. Алыйк үткән гасыр башында илне тетрәткән инкыйлабларны, кара реакция хөкем сөргән чорларны, алыйк егерменче еллардагы ачлык-ялангачлыкны, утызынчы еллар афәтен һәм икенче бөтендөнья сугышы дәһшәтен, аннан соңгы хәерчелек һәм кемнәрдер мактаган, кемнәрдер хурлаган торгынлык елларын... Татар басма әдәбияты барлыкка килгәннән соң татар

халкы узган гасыр барышында бер генә тапкыр да рәхәт бакчасында яшәмәде. Совет чоры исә адәм баласы күңелендә тернәкләнгән авыр йөкне—коллык психологиясен тагын да нығытып, бәйләп, бастырыклап куйды. Шул халыкның бер вәкиле булган, әсәрләрендә шул халыкның уй-хыялларын чагылдырып яшәгән язучыларга җиңел булганмы соң? Җиңел булмагандыр. Әмма ул елларда әдәбиятыбызның алтын хәзинәсенә кергән күпме әсәрләр иҗат ителгән?! Әйе, заманалар үзгәрә бара, ул кешелек аңында гына түгел, ә социаль-иҗтимагый яссылыкта да гаять зур трансформация кичерә. Җәмгыять күзгә күренеп ике катлауга—байлар һәм ярлылар катлавына аерыла бара. Бөтен четереклек нәкъ менә шунда да инде. Матди байлык тудыручылар рухи байлык тудыра аламы? Юк, дияргә туры килә. Кызганычка каршы, үткән гасыр башында эшләгән һәм яшәгән, татар әдәбияты-сәнгатенең матди нигезен тәшкил иткән Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Кәримовлар бүгенгә күренми. Очын очка көчкә ялгап яшәгән ярлының исә рухи байлык турында уйларга вакыты да мөмкинлеге дә юк. Рухи байлыкны бары тик халыкның бәгыреннән суырылып чыккан әрфиядәй үтә дә юка бер нәни генә катлам кешеләре—бу очракта, әдәбият әһелләре генә тудыра ала.

Темадан бераз гына читкәрәк тә киттем. Ләкин мин моны аңлы рәвештә эшләдем. Бүгенге чынбарлыкны, аның су асты агымнарын ачыкламыйча торып, проза кебек җитди жанрдагы үсеш тенденцияләрен һәм аның кайсы якка бару ихтималын да, аның юнәлешләрен дә бик ук ачыклап булмый.

Йә, хуш! Инде килеп, гомумән, бүгенге прозада нинди тенденция өстенлек итә, әлегә күзгә чатнап кермәгән, әмма һаман саен үзен сиздерә баручы нинди яшерен процесслар бара?

Аларның сөенечләре дә, көенечләре дә җитәрлек. Иң беренчесе һәм күзгә ташланганы—проза жанры җанлана, әсәрләр күп языла башлады дидек. Журнал практикасыннан чыгып әйтә алам, 1998 елдан башлап редакциягә ел саен биш-алты роман килеп керә тора. Әле быелның ике генә ае үтте, ә инде «Казан утлары» папкасына өч роман, берничә повесть, шактый санда хикәяләр кереп тә өлгерде. Дөрес, кергәннәрнең байтагының кире кагылу ихтималы да юк түгел. Ләкин хикмәт шунда, проза жанрында иҗат итүчеләр, ниһаять, аңнарына килделәр бугай. Бусы сөендерә. 2002 елда Татарстан журналларында басылып чыккан әсәрләрнең гомуми саны да бу хакта бик ачык сөйли.

Шул ук вакытта икенче бер тенденция аеруча көендерә, шөбһәгә сала. Редакциягә кергән әсәрләр көпшәк, сюжет сызыгы, композицион төзелеше таркау, аларның ашык-пошык, тизрәк редакциягә илтеп бирим, бастырыйм да азмы-күпме каләмхак алырмын дип язылганлыклары сизелеп тора. Әдәби телнең, камил, матур, йомшак һәм ягымлы телнең тәмен тоеп, аның барча мөмкинлекләрен, эчке куәтен, резервларын тоеп һәм кулланып язган әсәрләр калмады диярлек. Еш кына бу әсәрне авторы язды микән, әллә бер-бер төрле техника кулланып ясады микән дигән фикер кала. Чөнки аның теле машинада ясалгандай җансыз һәм хиссез булыр, салкын булыр, ана куенының җылысын тоймаган ул сүзтезмәләр берничә җөмлә укуга ук гайрәтенне чигерә башлый.

Дөрес, философиядә сан кайчан да булса бер сыйфатка әйләнә, дип әйтәләр бугай. Инде безгә әнә шул сыйфат бәрәкәте кунар көннәрне көтәргә генә каладыр да инде. Бүген югары трибунадан бу хакта аерым басым куеп сөйләргә омтылуым да шуннан килә. Корама тел белән язылган әсәрләр күбрәк дөнья күргән саен, ирексездән күңелдә укучыларның зәвыгы кими бара торгандыр, алар «агач тел»не дә әдәби тел шушы икән дип кабул итә башлыйдыр дигән урынлы борчу һәм шөбһә туа. Язучыларның кайберләре үзләре дә кибәкне бөртектән аера алмаганда гади укучы нишләсен?!

Яхшы! Әсәрләр күп языла дидек. Инде килеп бүгенге язучыларыбыз нинди темалар күтәрә, җанын борчыган нинди вакыйгалар хакында укучыларына бәян итәргә тели? Яшерен-батырын түгел, әле моннан ун-унбиш ел элек кенә язучыларны бер яктан чикли, икенче яктан коткара торган бик үтемле темалар бар иде. Тарихи тема исә тыелган, милли тематиканы әйткән дә юк, дини фәлсәфә белән сугарылган әсәр яздың исә, сары йортка—җүләрләр йортына илтеп тыгарга да күп сорап тормаслар. Язучыны әнә шул чакларда производство темасы коткара килде. Алдынгы колхозчының яисә эшченең гаилә хәлләрен, эшендә югары күрсәткечләргә ирешү өчен ничек көрәшкәнен сурәтләсәң, мәхәббәт хәлләреннән манзаралар кертеп җибәрсәң, унай герой сыйфатында урыс милләтеннән берәр алдынгы эшче яисә партком секретаре, йә булмаса коммунист образын кертеп җибәрдең һәм түшенә лауреат медале алу хакында шикләнмичә уйланырга мөмкин иде.

Әмма мәңге җимерелмәслек тоелган социалистик система бармак төртүгә

ишелде дә төште, СССР дигән империя таркалды, монарчы үтемле һәм «дәрәҗәле» темаларның поты бер тиенгә әйләнде. Татар язучысы нишләргә тиеш иде, нәрсә хакында язарга тиеш иде? Һәм ул юллар чатында аптырашта калды. Хәер, бер татар язучысы гына да түгел! Һәм менә шушы аптыраштан чыгар өчен әдипләребезгә унбиш еллап вакыт кирәк булды да инде. Күзләребезне томалап торган кара япмаларны алып аткач шаккаттык, дөньяда тема бетәрлек түгел икән лəбаса! Менә сиңа мә! Производство темасына тыкшыну гомумән дә әдәбият эше түгел икән. Җир йөзендә бөтен адәм балаларын, бар дөнья халкын борчый торган гомумкешелек кыйммәтләре хакында әле безгә язарга да язарга икән. Өченче мең еллыкка кереп килгәндә генә, татар язучысы социалистик вә коммунистик идеаллардан арынып, әнә шуларны аңлар дәрәҗәгә иреште, ниһаять. Һәм буа ерылды. Сүз уңаеннан гына, әле илленче-алтмышынчы елларда татар прозасында елына бер яисә ике роман язылу олы вакыйга санала, һәр роман матбугат битләрендә гаять тә җитди сөйләшүләргә сәбәп була торган иде. «Казан утлары»нда басылып чыгуга ук алар буенча укучылар конференцияләре, очрашулар уздырыла, ә инде роман хәтле роман язган әдип дан вә шөһрәткә күмелер иде.

Алда әйтеп киткән, әдәбиятта сизелерлек төсмер алган процессларның тагын берсе —татар прозасының тематик яктан киң колач ала баруы. Прозаның офыклары нык киңәйде. <u>Беренчедән,</u> соңгы берничә елда гына да моңарчы бездә бөтенләй диярлек күтәрелмәгән, дөресрәге тыелган милли тематикага киң күләмле эпик полотнолар иҗат ителде. <u>Икенчедән,</u> татар тарихы әдәбиятта үзенең лаеклы урынына кайтып утырды. <u>Өченчедән,</u> дин вә иман мәсьәләләрен үзәккә алган гыйбрәтле әсәрләр туды. <u>Дүртенчедән,</u> язучылар ялган коммунистик идеалларның кеше аңына тискәре йогынтысын курыкмыйча фаш итә башладылар. <u>Бишенчедән,</u> монарчы берьяклы гына сурәтләнгән икенче бөтендөнья сугышы тарихына яңача караш барлыкка килде, аны совет чорындагыча ялган «героизм» ноктаи назарыннан карап кына түгел, ә бәлки гади сугышчылар, гади халык күзлегеннән, һәм хәтта без дошман дип атаган яктан карап язылган әсәрләр дөнья күрде. <u>Алтынчыдан,</u> әдипләр хыял белән чынбарлык арасындагы рәшәсыман дөньяның тылсымлы, бер караганда мистик, икенче караганда фантастикага якын катлауларына үтеп керергә җөрьәт итте. Әле бармакларны бөгеп, алга таба да санап булыр иде. Моннан егерме-утыз ел элек без хыялыбызга да кертеп карамаган темалар түгелмени болар?!

Менә шушы гаять тә катлаулы һәм четерекле темаларны нигез итеп алган әсәрләр узган елда да шактый ук күп басылган.

Иң элек—романнар хакында. Роман жанрында, ягъни кеше җанының үтә дә каршылыклы вә катлаулы дөньясын, тормышны йөзләрчә, меңнәрчә нюанслар аша күп яктан күрсәтергә мөмкинлек бирүче эпик полотнолар туу әдәбиятның, язучыларның никадәр тирәнгә сөрә алуын күрсәтүче барометр хезмәтен үти. Басылып чыккан кадәреләренең романмы, түгелме икәнлеген раслауны яисә кире кагуны әдәбият галимнәре өлешенә калдырып, конкрет әсәрләргә күчсәк, былтыр әдәбиятыбыз сигез романга баеган дидек. «Казан утлары»нда Мәдинә Маликованың «Өермә», Рауль Мирхәйдәровның «Һәрнәрсәгә—акчалата» дип исемләнгән детектив романнары, Факил Сафинның «Саташып аткан таң» романының икенче китабы һәм Сафуан Поварисовның «Оҗмахка бер адым» трилогиясенең өченче кисәге басылып чыкты.

«Мәйдан» журналында Рафаэль Сибатның «Шаһ тур», Вахит Имамовның «Тозлы яра» романнары, «Мирас» журналында Локман Бадыйкшанның «Колымадан кайткач» исемле романы һәм «Идел» журналында Рәдиф Сәгъдинең «хыялый кыйсса» дип куелса да, үзенең күләме һәм күтәрелгән проблемаларының колачлылыгы белән роман дип әйтелергә хаклы «Ике кояшлы дөнья» әсәре дөнья күрде.

Роман жанрында кызыклы бер тенденция күзәтелә. Бер яктан, әле һаман күпсүзлелектән җәфа чигүче су кебек озын романнар язу дәвам итсә, икенче яктан, тыгыз концентрацияле, катлаулы сюжетлы, аз сүзле, әмма сурәтләү-тасвир көче ягыннан алда әйтелгәннәренә биргесез, хәтта киресенчә күп яктан отышлырак яңа төр романнар барлыкка килә башлады. Һәм бу аңлашыла да. Чөнки заман үзгәрде, кешеләр үзгәрде. Югары тизлек, компьютерлар заманы килде, дөньяны информация ташкыны басып китте. Әйтик, унтугызынчы гасырда кеше бер елда алган кадәр информация-мәгълүмат бүгенге заманда инде иң күп дигәндә атна-ун көн эчендә килеп җитә. Кеше алардан башка яши алмый. Никадәр генә каршы торсак та, теләсәк тә теләмәсәк тә, без бүген инде телевидение һәм компьютерлардан башка яши алмыйбыз. Һәр аерым индивидуум акылы интернет челтәре аша бөтендөньяның акыл челтәренә тоташа бара. Бу—котылгысыз хәл. Хикмәт күләмдә түгел, хикмәт—

кыска вакыт аралыгында ни-нәрсәләр әйтеп өлгерүеңдә, әйткән хәтлесен кеше күңеленә үтемле образлар, җете буяулар белән житкерә белүеңдәдер.

Бу яктан караганда, икенче елда редактор һәм язучы буларак кына түгел, ә гади укучы буларак та сискәнеп куярга мәҗбүр иткән әсәрләр байтак булды. Һәм аларның иң беренчесе итеп мин Уфадан Марат Кәбировның «Сары йортлар сере» исемле, күләме белән илле-алтмыш биттән артмаган повестен әйтер идем. Никадәр тыгызлык, экспрессия, читләтеп әйтә белү. Шушы илле битлек повестька тормыш чынбарлыгының бөтен кабахәтлеге, «изге максатлар» хакына ди-ди халыкларга карата үткәрелгән телсезлек, динсезлек, йоласызлык, милләтсезлек сәясәтенең бөтен ачылыгы, аның кешеләрдән эш малы, эш хайваны ясавы бөтен тирәнлеге белән, осталарча чагылдырылган. Аны укып чыкканнан соң мин, Галимҗан Гыйльманов язарга яратканча, шок хәлен кичердем. Без барыбыз да сасы сөрем чыгарып утыручы, тәнбәдәннәребезне генә түгел, миләребезне агулаучы, халыкка кирәкле әйбер түгел, ә сугыш кораллары, сугыш җиһазлары житештерүче албасты заводларның кушылдыгы гына икән бит. Шул заводларга яраштырып, яннарына тулай торактан артык җире булмаган, барысы бердәй сары төскә буялган күпкатлы бараклар, «яшьлек каласы» дип йөртелүче шәһәрләр корып куйганнар, авыллардан халыкны китереп тутырганнар. Болар көне-төне агулы цехларда сыгылуны тормыш дип, тулай торакларда җан асрауны яшәү дип белә. Шушында гарип балалар тудыралар, шушында яшәгән сыман итәләр, шушында картаялар. Шушында җан бирәләр. Йа Хода! Телен, динен, йолаларын сакларга теләүче изге җаннарны монда ычкынган дип, тиле дип саныйлар. Баксаң, үзләре сары йортларда яшәүче тилеләр ләбаса! Ләкин алар моны аңларлык хәлдә түгел инде. Галимнәр билгеләгәнчә, поп-модернизм юнәлешендә иҗат ителгән бу әсәрне мин татар әдәбиятының гына түгел, гомумән, хәзерге заман әдәбиятының иң мөкәммәл һәм тирән эчтәлекле әсәрләреннән дип саныйм.

Тагын бер сөендергән әсәр—Әсгать Сәлахның «Соңгы вальс» повесте булды. Бер караганда, автор әдәбият өчен әллә нинди яна алымнар, янача сурәтләү ысуллары, тасвирлауда монарчы күрелмәгән эслүбе гамәл дә алып килми шикелле. Гап-гади «курортный роман» диярсең. Ләкин менә шушы «курортный роман»ның асылына, мона кадәр зур күләмле әсәрләре белән бөтенләй күренмәгән Әсгать Сәлах, заманыбызның жанын-бәгырен ботарлап, ачык яра-жәрәхәтләренә тоз салып торучы коточкыч дәһшәтне—атом һәлакәте фаҗигасен сала белгән. Әсәр һәм язылышы, һәм кеше язмышының фаҗигале вакыйгаларына бәхетле мизгелләрне оста үрә белүе белән дә игътибарны җәлеп итә. Укысаң чәчләр үрә торырлык! Моннан унбиш ел элек каһәрле Чернобыльда булган атом станциясе һәлакәте әле бүген дә анда катнашучыларны тән газапларына дучар итә, якыннарының җаннарын утка сала. Бу әсәр бүген Түбән Кама янында атом станциясен коруны яңартуга битараф караучыларны ваемсызлыктан уянырга чакыра, чаң суга. Тагын бер гаҗәпләндергән ягы—элегрәк укыган хикәяләрендә Әсгать Сәлахның озак еллар район газетасында эшләгәнлеге үзен нык сиздерә, әсәрләренең теле, йомшаграк итеп әйткәндә, зәгыйфьрәк, җөмләләре йорт нигезенә кагыла торган бетон субай баганаларын хәтерләтә иде. Бу әсәрендә исә, ниһаять, авторның халыкчан, йомшак, кайчандыр Гариф абый Ахунов әйткәнчә, мамыклы теле ачылган. Бу әсәр өчен барыбызга да сөенергә генә кала. Шунысы ачыктан-ачык сизелә, Әсгать абый басылып эшли, ирешкәннәрен кат-кат чарлый торган язучыларыбызның берсенә әверелеп килә. Редакция папкасында аның тагын бер әсәре, язылышы белән «Соңгы вальс»тан ким булмаган яна повесте ята.

2002 елны мин хәтта повестьлар елы дип әйтергә батырчылык итәм. Сан ягыннан гына түгел. Һәм тематика ягыннан, һәм язылышы, мавыктыргыч сюжетларга байлыгы белән дә узган елда ин уңышлы әсәрләребез повесть жанрында булды. Зәки Зәйнуллинның «Гарасатлы юллар» повесте бу исемлекне тагын да тулыландыра төшәргә ярдәм итә. Икенче бөтендөнья сугышы, анда совет сугышчылары күрсәткән батырлык, каһарманлык хакында әдәбиятыбызда шактый күп язылды. Араларында әле бүген дә яратып укыла торганнары бардыр. Әмма алар барысы да диярлек бер аягына аксый, ягъни сугыш кырларында булган чынбарлыкны, вәхшәтне берьяклы гына тасвирлый. Адәм баласына барысы да хас: аның җанына батырлык та, куркаклык та, дуслык һәм иптәшлек тә, мәхәббәт һәм үчлек тә, моң һәм дәрт тә, хәйләкәрлек һәм мәкер дә, нәфрәт һәм шул ук вакытта, әйтер идем ки, дошманына карата мәрхәмәтлек хисе дә һәм башка бик күп, бик күп төшенчәләр сыя. Бу хисләр исә сугыш кырында, экстремаль шартларда йөзләтә тапкыр көчәя төшә торгандыр. Зәки абый повестенең кыйммәте сугыш елларындагы вакыйгаларны берьяклы гына бизәмичә, тулы канлы итеп бирә белүендә. Фин армиясе офицерының татар егетенә булган мөнәсәбәтен генә карагыз.

Бу бит үзе бер кино төшерерлек эпизод. Әгәр безнең чын, нәфис фильмнар төшерүче киностудиябез булса, иң беренче чиратта шушы әсәр буенча кино төшерелергә тиеш булыр иде. Фин гаскәре формасында да татар кешесе—татар булып кала белгән, Кызыл армия солдаты—татар егете әсирлеккә төшкәч, ул аны ни финнарга, ни кызылларга сиздермәслек итеп үз ягына озата белгән. Бу бит татар халкының асыл канунына әйләнерлек вакыйга. Татарга татардан башка ярдәмче дә, иптәш тә юк! Әйе, дошманнар арасында да дуслар бар, дуслар арасында да дошманнар житәрлек. Әсәрнең фәлсәфи кыйммәте дә шуны анларга омтылудан, шуны татар укучысына житкерергә омтылудан туадыр. Хәтта Зәки абыйның артык каударланып, тел дәрьясын бер селтәнүдә кичеп чыгарга омтылудан туган һәм бик үк камил булмаган җөмлә төзелешен дә гафу итәсең, әсәрдәге вакыйгалар барысын да оныттыра.

Алда әйткәнебезчә, бүгенге әдәбиятның агымы тыелгысыз, күзгә күренмәс су астында, чонгылларда уйнаучы өермәләре көчле, борылмалары кискен. Әнә шул кискен борылмаларның берсе—тематик төрлелек. «Өермә» дигәч тә, күз алдына, нишләптер, Мәдинә ханым Маликованың «Өермә» романы килеп басты. Соңгы елларда бөтен барлыгын, күнел жылысын, шәфкатьлелек хисен «Кызыл Ай» хәйрия җәмгыяте эшчәнлегенә багышлаган Мәдинә ханым, ниһаять, безнең сөенечебезгә, әдәби эшчәнлеккә әйләнеп кайтты. Әйләнеп кайтты һәм күпләребезне хәйран калдырып, бер-бер артлы менә дигән роман-повестьлар иҗат итәргә керешге. Аның мавыктыргыч сюжетка корылган «Алтын ятьмә» повесте «Казан утлары»нда 2001 елда басылып, шактый югары бәя алган иде. Икенче елда инде ул «Өермә» дигән романы белән дөньяга аваз салды. Шушы күләмле ике яңа әсәре белән автор әдәбиятта Мәгъсум абый Насыйбуллиннан соң бушап калган детектив жанр мәйданын җанландырып җибәрде, ана яна сулыш өрде. Хәер, аларга беренче караштa гына коры детектив әсәр дип бәя бирергә мөмкиндер. Чынлыкта исә алар адәм баласын детективлардагыча кискен ситуацияләргә куеп сынап карау, ягъни психологик жанрга тартым әсәрләр булып чыкты. Мәдинә ханымның теле сыгылмалы, җанга якын. Ул әсәр геройларын сурәтләгәндә, бары тик хатын-кызлар гына тотып ала белгән бик күп детальләр белән эш итә һәм, әйтер идем, уңышка ирешә.

Камил Кәримовның «Ак бүрек» повесте белән Рауль Мирхәйдәровның «Һәрнәрсәгә—акчалата» романы да детектив жанрны үстерүгә сизелерлек өлеш булды. Дөрес, Камилнең повесте детектив булудан бигрәк, торгынлык елларындагы вәзгыятькә сатирик бәяләмә ул. Ә андый эслүбтә, яшерен мәгънәсен юл арасына яшереп яза белүчеләр, ачы күз яшьләренә буылып, шул ук вакытта сурәтләгәннәреннән каһкаһә берлә көлә белүчеләр әдәбиятыбызда бармак белән генә санарлык.

Рауль Мирхәйдәров татар әдәбиятында, дөресен әйтергә теләсәк, бәхәсле фигура. Ул урыс телендә яза. Әмма Оренбург якларындагы татар мохитында тәрбияләнеп үскәнлектәнме, Рауль гомере буе татар дөньясына тартылып, татар музыкасына, татар сәнгатенә гашыйк булып яши бирә. Һәм олыгая барган саен татарлыкка тартылу анда арта гына бара. Әдәбиятыбыз аксакалы Марс Шабаев тәрҗемәсендә нәкъ татарча янгыраш алган «Һәрнәрсәгә—акчалата» романын анализлау кирәкме икән дигән урынлы сорау да туарга мөмкин. Бәлки шулайдыр да! Әмма мин Татарстан Язучылар Берлеге әгъзасы булган Рауль Мирхәйдәровның иҗатына күз йомып китә алмыйм. Чөнки әсәр тәрҗемә ителеп, журнал битләрендә басылып чыгуга ук татар әдәбиятының уртак байлыгына әверелде. Ул безнең дә казанышыбыз. Еракта булса да, безнең өчен анлаешлы һәм якын Чечня җирендә канкойгыч сугыш барганда, Русия җирендә җинаятьчелек шаулап чәчәк аткан бер мәлдә татар укучысы өчен мондый колачлы әсәр бигрәк тә кирәк иде. Бу роман, әдәбиятта гына түгел, Русия җирлегендә барган коточкыч су асты агымнарының кайдан башланганлыгын, аларның кая илткәнлеген анларга ярдәм итүе белән отышлы. Бусы бер яктан. Икенче яктан караганда, Марс абый Шабаевның теле сокландыргыч! Менә кайда ул тәрҗемә осталыгы.

Форсаттан файдаланып, шуны да әйтеп үтәсем килә: тәрҗемәчеләр бер көндә генә үсеп чыкмый. Безгә һәр ике телне камил белгән тәрҗемәчеләр бүген су кебек, сулар һава кебек кирәк. Ни өчен, мәсәлән, «Соңгы вальс»ны, «Сары йортлар сере»н, «Гарасатлы юллар»ны, Фәүзия Бәйрәмованың «Алыплар илендә»сен, Айдар Хәлимнең «Татар вакыты»н яисә башка әсәрләрне урысчага тәрҗемә итеп чыгармаска. Безнең инде туган телендә укудан бизгән татарларыбыз өчен үз милләте белән горурлану хисләре тудырырлык әсәрләр ич алар. Бизгәннәрне бары тик татар әдәбиятының иң яхшы әсәрләре аша гына татарлыкка өндәп була да!

Шушы кыскача гына күзәтүдән дә әдәбиятның соңгы елларда тематик колачы никадәр киңәйгәнлеген ачык күзалларга була, дип беләм. Әле боларга Факил Сафинның

«Саташып аткан таң»ын, Суфиан Поварисовның «Оҗмахка бер адым» романнарын да өстәсәң, картина шактый тулы булыр. Дөрес, аларның язылу дәрәҗәсе төрлечә. Факил Сафин—әдәбият йөген җигелеп тартучыларның берсе. Тел җәһәтеннән булсын, сюжет-композиция кору җәһәтеннән булсын, аның язганнарына тел-теш тидерерлек түгел. Ә менә Суфиан ага Поварисовның еш кына күпсүзлелек белән мавыгып, сюжеттан читкә салулавы күзәтелә. Хәер, ничек кенә булмасын, Уфада яшәп иҗат итүче өлкән каләмдәшебез Галимҗан Ибраһимов кебек халкыбызның йөзек кашын тәшкил итүче олуг шәхес хакында яза башлаган трилогиясен уңышлы тәмам итеп чыкты. Бусы да мактауга лаек эш.

Тарихи романнары белән танылып өлгергән Вахит Имамов исә кинәт кенә урта гасырлардан XX йөзгә әйләнеп кайтты. Аның «Мәйдан» журналы битләрендә укучыларга барып ирешкән «Тозлы яра» романы, татар әдәбиятында беренче тапкыр буларак, конформизмның кеше язмышындагы аяныч нәтиҗәләрен калку итеп күрсәтә алды.

Инде килеп, менә каләр әдәбиятыбызда күрелмәгән ике кызыклы темага аерым тукталыйк әле. Мин алдарак дин вә иман мәсьәләсен үзәккә алган әсәрләр туа башлады, әдипләребез хыял белән чынбарлык арасындагы рәшәсыман дөньяның тылсымлы катлауларына үтеп керергә җөрьәт иттеләр дигән идем. Шунысы кызык, бу ике четерекле тематика буенча юл сыза башлаган язучыларыбыз—икесе дә хатын-кызлардан. Беренче юнәлештә Фәүзия ханым Бәйрәмова аеруча уңышлы эшли. Әйткәнемчә, аның борынгылык белән бүгенгене ялгарга, ислам фәлсәфәсен аңларга омтылган, дин вә иманның гына халыкны туры юлга күндерәчәгенә иман китергән әсәре—«Алыплар илендә» повесте «Мәйдан» журналында басылып чыкты. Фәүзия ханым игелекле эш эшли.

Икенче үзенчәлекле юнәлешнең әнкәсе әдәбиятыбызда Нәбирә Гыйматдинова булды. Аның «Идел» журналында «Парлы ялгыз» әсәре дөнья күрде. Нәбирә ханым әсәрләренең халыкта киң таралуы, яратып укылуы беркемнән дә сер түгел. Ләкин минем әйтергә, ассызыклап куярга теләгәнем ул түгел. Әдәбиятта кызыклы бер хәл күзәтелә. Берәр язучының яңа табышы, бигрәк тә уңышлы әсәре буламы—бер-ике елдан аны инде дистәләгән каләм тибрәтүче кабатлый башлый. Нәбирә ханымның «Сихерче»сеннән башланган юлны бүгенге көндә инде, нигездә, ир-атлар таптый. Аларның исемнәрен әйтеп тормыйм. Укыган кешеләр белә булыр, уңышлы таптыйлармы, әллә әйбәт башланган серияне кабатлыйлар гынамы?!

Хикәяләр хакында. Алдарак әйтелгән 68 авторның яртысыннан күбесен хикәячеләр тәшкил итә. Алар кемнәр? Бу сорауга чиста арифметик исәпләүләр белән җавап бирүе кыен. Хикәя язучылар арасында Ләбибә Ихсанова, Кави Латыйп кебек мөхтәрәм өлкәннәребез дә, Айдар Хәлим, Тәлгат Галиуллин, Факил Сафин, Зиннур Хөснияр, Равил Вәлиев кебек бүген әдәбиятның төп йөген җигелеп тартучылар да, Нурулла Гариф кебек яшьләр дә бар. Иң күзгә ташланганы шул—хикәя жанрына журналистлар һәм яшьләр актив тартыла. Мисал өчен әнә шул кырык биш авторның өчтән бере миңа элек хикәяче буларак бөтенләй таныш булмаган яшьләрдән һәм журналистлардан. Монысын да күнелле хәл дип бәялик. Ләкин... Их, шул каһәр суккан «ләкин» булмаса. Журналистлар һәм яшьләр каләменнән төшкән хикәяләр телсезлеге, сюжет сызыгының бер генә каптырмага эләктерелгән булуы белән аерылып тора. Аларның редакция хезмәткәрләре тарафыннан авторга карата күрсәтелгән хәерхаһлык аркасында гына басылып чыгуы беренче җөмләләрне укуга ук күзгә ташлана. Нишлисең, яшь алмаш шулай авыр тәрбияләнә торгандыр инде ул.

2002 елда басылып чыккан хәтлеләре арасында Факил Сафинның «Гөлләрем, сиреньнәрем» («Мәйдан» журналы) хикәясен мин бу жанрның үткән елдагы иң зур казанышы дип әйтер идем. «Казан утлары» журналы битләрендә дөнья күргән әсәрләре белән татар хикәяләре хәзинәсенә Равил Вәлиев («Биш патрон»), Айдар Хәлим («Бөркетле баганалар»), Зиннур Хөснияр («Айның туган-тумачасы юк») һәм Нурулла Гариф та (Кыска хикәяләр) үзләренең асыл өлешләрен керттеләр, дисәм, ялгышмамдыр кебек.

Менә шундый хәлләр бүгенге татар прозасында. Дөресрәге, өченче меңъеллыкның икенче елында әдипләребез әнә шундый чәчмә әсәрләр иҗат иткәннәр. Һәм сан ягыннан, һәм тема төрлелеге ягыннан, әдәби осталык һәм тел җәһәтеннән дә вә үрнәк алырлык, вә гыйбрәтле хәлләр житәрлек. Вакыт галиҗәнап иләгеп үткәннән соң, шиксез, аларның иң лаеклылары, укучы күнелен яулаганнары әдәбиятыбызның алтын фондында үзенә урын табар.

Иң сөендергәне шул, әдәбиятның умыртка баганасын тәшкил иткән проза жанры бер урында гына тормый, эзләнә, казына, актарына, тәҗрибә вә экспериментлар ясый һәм, ахыр чиктә, минемчә, тарихтагы үз юлын беркемгә дә бирергә җыенмый.

Гәп
Фән

**Нурмөхәммәт Хисамов**

*филология фәннәре докторы*

# ӨЧ ХАЛЫКНЫҢ ӨЧ ШАГЫЙРЕ

(Кол Гали, Әхмәди, Дүрбәк)

«Өч халыкның өч шагыйре» дигәндә без мөселман милләтләренең һәм дәүләтләренең хәзерге бүленешен күздә тотып хөкем йөртәбез. Югыйсә, XII, XIV, XV йөзләр әдәбияты турында сүз йөрткәндә бердәм кануннар нигезендә үскән уртак әдәби барыш аңлашылырга тиеш. Югарыда исемнәре аталган шагыйрьләрдән Кол Гали—XIII гасыр Идел буе болгар-татар шигърияте вәкиле, Әхмәди—XIV гасырда яшәгән госманлы шагыйре, Дүрбәк исә—XV гасыр Урта Азия шагыйре. Ягъни аларның һәркайсы төрки мәдәниятнең мәгълүм төбәкләренә карый: Идел буе, Кече Азия, Урта Азия. Хәзерге сәяси-әдәби төшенчәдә аларның берсе—татар шагыйре, икенчесе—төрек шагыйре, өченчесе исә үзбәк шагыйре хисаплана.

Аларны эзлекле эчке бәйләнешләр бердәмлегенә уртак Йосыф—Зөләйха темасына язылган дастаннары берләштерә. Бу тема Мөселман Көнчыгышы әдәбиятында дөньяга «Коръән» ингән дәвердән бирле эшкәртелеп килсә дә, төрки әдәбиятларга бары XIII гасыр башыннан гына килеп керә. Гарәпләрдә, мәсәлән, ул «Тәфсир»ләрдә яктыртыла, фарсыларда «Кыйссасел әнбия» китапларында бәян ителә. Шигъри дастан рәвешендә аны беренче тапкыр Фирдәүси (X гасыр) иҗат дәрәҗәсенә күтәрә. Аңарчы Йосыф пәйгамбәр хакындагы хикәят рәвешендә эшләнеп килгән сюжетка фарсы шагыйре «Йосыф вә Зөләйха» исемле әсәр яза. Шул рәвешле «Коръән»дә һәм «Тәфсир» янсә «Кыйссасел әнбия»ләрдә аз вакытка чагылып үткән хатын сурәте әсәрнең Йосыф белән тиң каһарманына әйләнә. Ана башлап «Зөләйха» исемен биргән автор да Фирдәүси булган.

Фирдәүсидән соң фарсы әдәбиятында XI йөз Һират шәехе Габдуллаһ Әнсаринең гаять бай эчтәлекле һәм бик күп төрле мәгълүматны эченә алган «Әнисел мөридин» әсәре барлыкка килә. Аннан соңгы гасырларда иҗат иткән барлык авторлар да төп чыганак буларак шушы әсәргә таяналар.

Йосыф сюжетына, дөресрәге Йосыф-Зөләйха сюжетына, Мөселман Көнчыгышында нәүбәттәге шигъри әсәрне XIII йөз башы төрки шагыйре Кол Гали иҗат итә. Аның «Кыйссаи Йосыф» дастаны 1233 елның 12 маенда Иделнең түбән агымында угыз-болгар-кыпчак мохитендә тәмамлана. Шушы көннән Мөселман Көнчыгышы әдәбиятының бәрәкәтле сюжеты төрки мәдәниятнең дә үз малына, үз байлыгына әйләнә. Заманының олуг фикер иясе Кол Гали үзенең әлеге әсәре белән язма культурасы элек-электән килгән төрки халыкларны, төрки шигъриятне алдынгы дөньяның гүзәллек һәм гаделлек идеалын эзләү һәм үзләштерү хәрәкәтенә китереп куша. Төрки кавемнәр әлеге әсәрне, аның сюжет һәм эчтәлек байлыгын зур рухлану белән күтәреп алалар. Һәр гасырда шул сюжетка берничә әсәр язылу һәм аларның саны XX гасырга 40 ка җитүе шуны күрсәтә. Мөселман Көнчыгышында Йосыф-Зөләйха сюжетын яратып һәм иң күп кулланган әдәбият та төрки әдәбият дип әйтә алабыз. Шунлыктан, бу хакта фикер йөрткәндә, үзеннән-үзе «Төрки Йосыфнамә» дигән төшенчә туа.

Төрки Йосыфнамәгә нигез салучы Кол Гали сюжет эшкәртелешенә нинди яналыклар алып килә соң? Бу сорауга без, чагыштыру нигезе буларак Фирдәуси поэмасын күз уңында тотканда, төгәлрәк җавап бирә алырбыз, мөгаен. Фарсы шагыйренең әсәре исә «Тәфсир»ләрдә, «Кыйссасел әнбия»ләрдә тупланган мәгълүматка таянып язылган. Ә ул мәгълүматлар, үз нәүбәтендә, «Тәурат»тагы шәрехләүләргә барып тоташа. «Тәфсир»ләр дигәндә, иң әүвәл Табари «Тәфсир»е (IX гасыр) нигез чыганак булган. Фирдәуси, шушы чыганакларда яктыртылганча, әсәрнең үзәгенә ата-угыл мөнәсәбәтен куеп, Йосыф-Зөләйха мөнәсәбәтен сюжетның ярдәмче сызыгы рәвешендә алган. Әсәрдә Йосыф туганнары барысы да исемнәре белән бирелә. Поэманың яналыгы шунда ки, әсәрнең мәхәббәт сызыгы Йосыф белән Зөләйханың никахы белән очлана. Каһарманның Зөләйхага өйләнгәнче җариядән ике баласы туган була.

Кол Гали сюжетны төрки дастаннар калыбына кора. «Әнисел мөридин»дәге мәгълүматларны сайлап алганда да ул дастан схемасына туры килгән вариантка туктала. Мәсәлән, Зөләйханы Йосыфка төштә күреп гашыйк булган кыз итеп сурәтли. Каһарманның ана өйләнгәнче бернинди балалары хакында сүз юк. Кол Галичә, Йосыф белән Зөләйханың бергә гомер итүләре нәтиҗәсендә 12 угылы туа. Шул ук өлгене шагыйрь аның бер анадан туган энесе Ибнейәминга дә күчерә: аның да 12 угылы туа. Шагыйрь бу санны, сюжетның унике кардәш хакында булуын истә тотып, башка вакыйгаларга бәйле рәвештә дә куллана. Әйтик, Йосыф 12 ел зинданда ята. Кодес бәге Йосыф белән барган сәүдә кәрванын 12 меңле гаскәр белән куа чыга һәм башкалар. Әсәрнең стиль-өслүб ягы да төрки дастаннарга тарта. Ул тоташ диалогка, ягъни кара-каршы әйтешкә корылган.

Шагыйрь каһарман сурәтен эшләгәндә дә дастан каһарманы өлгесенә таяна. Мәсәлән, Мисырда сату вакытында мөнадиләр аның ун сыйфаты арасында бер мөһим үзенчәлеге итеп тән куәтен атыйлар:

*Алтынчы: алып йөрәклү һәм һәйбәтлү,*
*Кырык ирдән куәти артук имди.*

Магик бирешмәү сыйфаты да дастан каһарманнарына хас. Югарыда телгә алынган 12 меңле гаскәр, кәрванны куып житкәч, сугышчылар Йосыфның бер күз карашыннан өч көнлек йокыга тала.

Каһарманның зинданнан чыкканда үзенең тоткын иптәшләрен азат иткәнче үз азатлыгыннан баш тартуы «Дәдә Коркыт» дастаннарындагы каһарманнарның (Бамсы-Бәйрәк) затлы гамәлен хәтерләтә.

Йосыфның атасы Йагъкуб сурәтендә дә Дәдә Коркытны хәтерләткән үзенчәлекләр бар. Әйтик, аның үзе өчен кабер казучы фәрештәләргә юлыгуы һәм тере килеш кабергә кереп җан бирүе Дәдә Коркыт хакындагы әфсанәләрдән алынган.

Шагыйрь әсәргә, гомумән, төрки үзенчәлек бирергә тырышкан. Мәсәлән, Зөләйханың Йосыф чәчләрен толымлап үрүе төркиләрдәге ирләрнең затлы нәсел билгесен чагылдыра. Каһарманнарның 12 шәр угылы да борынгы төрки каганнардан таләп ителгән беренче сыйфатның ныклы ир токымы—угылларга ия булырга тиешлеген чагылдыра.

Әсәрнең аеруча мөһим төрки үзенчәлеге аның шигъри шәкелендә чагыла: дастан баштан алып азаккача төрки дүртьюллык белән язылган. Аның бу сыйфатын төрек әдәбияты тарихчысы Васфи Маһир Кожатөрк аеруча соклану белән билгеләп үтә: «... turk dortlukleryle manzum roman meger ne gozel olurmus»[1]. Шигырьнең строфикасы Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани әсәрләре кебек үк 12 шәр иҗекле дүртьюллыклардан тора, ягъни Идел буе шагыйре халык шигыренә таянып эш итә. Строфалар калыбы, кафияләшү принцибы бик борынгы төрки шигырь өлгесенә туры килә. Мәхмүд Кашгари «Диван»ында андый үрнәкләр күп. Күз алдына китерү өчен «Кыйссаи Йосыф»тан менә бер үрнәк:

*Бән зәгыйфи хикмәт таба сән йандыргыл,*
*Пәндү хикмәт айытмага сән кандыргыл;*
*Садрим ичрә мәдәд шәмгыйн сән йандыргыл,*
*Хәтеримни сән мөнәүүәр кылгыл имди.*

Шагыйрь, илһам сорап, илаһияткә шулай мөрәҗәгать итә.

Кол Гали әсәре укымышлы төрки дөньяга тиз тарала. Шәһри Болгарда дастан язылуга уртача бер кеше гомере узгач (60 ел), Йосыфның кече углы «Мамил»

исеменә кабер ташы куела. Болгар тарихында шушындый жиде таш билгеле.

Әсәрне шул ук гасырда Кече Азия шагыйрьләре күтәреп ала. Шәйяд Хәмзә, «Кыйссаи Йосыф» текстын бик аз гына үзгәртеп, композицион яктан үзенчә янартып, аны гарузга күчерә. Шул ук гасырда төрек әдәбиятында янә бер «Йосыф вә Зөләйха» дастаны языла. Сүлү Фәкыйһ дигән шагыйрь, текстны бик нык үстереп, эпизод һәм вакыйгаларны психологизм белән сугарып, алардагы драматик башлангычны көчәйтеп, гаять кызыклы һәм зур күләмле әсәр яза.

Сүлү Фәкыйһ вариантында ээлекле рәвештә бер нәрсә күзгә чалына: шагыйрь даимән Кол Гали һәм Шәйяд Хәмзә йогынтысында калса да, аңлы рәвештә алардан ераклашырга тырыша. Мәсәлән, Мисырда Йосыфның базар игъланчылары санап киткән сыйфатларының урынын алмаштыра. Әйтик, Кол Галидә беренче сыйфаты итеп каһарманның гүзәллеге (Әүвәл улдыр: кадди йахшы зариф үзлү) телгә алынса, Сүлүдә милли чыгышы (... бу гыйбранидыр) беренче урынга куела. Аннары шагыйрь һәр сыйфатны шәрехли һәм аларга фәлсәфи төсмер өсти. Мәсәлән, угланның гүзәллеген сәүдәгәр шулай тәкъдим итә:

*Гүзәл улдыр ки, мәлахәтлү ула*
*Һәм сөзи дәхи хәләүәтлү ула*
*Йохса кәнду хуб сөзи суук*
*Кыйммәти бир куз ола анүң куук*
*(Гүзәл улдыр ки, кайсы ягымлы була,*
*Һәм аның сүзе татлы була,*
*Юкса шулай да була: үзе матур, сүзе салкын,*
*Аның бәһасе дә гади бер шәүлә*
*Яки өреп күпертелгән куык була.)*

Шагыйрь персонажларның исемен, әсәрдәге вазифасын үзгәртә. Кол Галидә, Фирдәүсидәге һәм Әнаридәге кебек үк, базар игъланын мөнадиләр башкарса, Сүлүдә—сәүдәгәр үзе башкара. Аның исеме дә Кол Галинең сәүдәгәре Малик Дугыр (фарсы чыганакларында: Малик Зәгар) булса, Сүлү аны Малик ибне Сафрага әйләндерә.

Урта гасыр төрек әдәбиятында сәлҗүк шагыйре Шәйяд Хәмзәдән башланган шигъри ярыш, ягъни нәзыйрә традициясе, Йосыф сюжетын эшкәртүнең күпгасырлык үсешендә куәтле бер этәргечкә әверелә. Әсәр эчтәлеген һәм формасын камилләштерү хәрәкәте Хәмдигә (XV йөз) һәм Ташлыжалы Яхъяга (XVI йөз) чаклы дәвам итә. Бу темага композицион һәм шигъри тел җәһәтеннән иң камил, эчтәлек ягыннан иң гүзәл әсәр—әлбәттә, Хәмдинең «Йосыф вә Зөләйха»сы. Композицион төзеклек, психологик эчтәлекнең тирән эмоциональлеге һәм метафорик теленең галилеге, гомумән, төрки шигърият үсешендә мөһим бер этап хасил итә. Шагыйрь үз чорының барлык гыйлемнәреннән хәбәрдар булып, үзенең метафораларын шул эрудициягә нигезли. Менә бер мисал:

*Багласа бир нигәрә безе дил*
*Иши күндән күнә улур мүшкил*
*Әгәр олмаса нәкъду висал*
*Гыйшкдан карз алур мәлали хәйал.*
*(Йөрәк безне бер гүзәлгә бағласа,*
*Эше көннән-көнгә мөшкел булыр,*
*Әгәр кулда кавышуның тотарлык малы булмаса,*
*Хыял зарыгуы гыйшыктан бурычка алыр.)*

Күренә ки, Хәмдинең метафорик теле Низами теленнән дә катлаулырак һәм зәвыклырак.

Әмма Шәйяд Хәмзә белән Сүлү Фәкыйһтән соң «Йосыфнамә»нең кинәт Хәмди югарылыгына ирешүе шигъриятнең үсеш мантыйгына туры килми. XV йөз шагыйре бу әсәренә керешкәндә, төрки «Йосыф вә Зөләйха»лардан тирән канәгатьсезлеген искәртә. Ул Фирдәүси белән Җами дастаннарына гашыйк. Әмма төрки шигъриятнең өч гасыр дәвамында үзе эшләгән сәнгатьчәлек алымнарыннан, сюжетны төрләндерү барышында туплаган сыйфатлардан баш тартырга яки читкә китәргә мөмкин түгел. Хәмди шуна таяна һәм шуларны үстерә. Тик ул ничаклы даһи булса да, Сүлүдән соң ук мондый феноменаль сикереш ясый алмас иде, арада күпер булып торырлык бер шагыйрь һәм бер әсәр сорала. Аннары... бер XIII йөздә өч дастан языла да, бөтен бер XIV йөз буш кала. Сюжетка һәм темага

мөкиббән киткән төрек шагыйрьләренең бөтен бер гасыр дәвамында шуна битараф калулары мөмкин түгел. Һәм алар битараф калмаган да.

XIV йөздә Әхмәди исемле шагыйрь шушы темага гаять оригиналь әсәр язган. Кызганыч ки, ул әсәр төрек әдәбияты тарихчыларына билгеле түгел. Хәзергә аның бердәнбер кульязмасы Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә саклана. Ул безгә элекке Ленинград университеты профессоры мәрхүм Габдрахман Таһирҗанов китапханәсеннән күчте. Ана исә галимнең атасы хәзерге Апас районы Морзалар авылы мулласы мәрхүм Таһирҗан хәзрәттән мирас булып калган.

Кульязманың әүвәлге һәм соңгы сәхифәләре юкка чыккан. Ул зәңгәрсу төстәге XVIII йөз рус кәгазенә язылган. Калган тексты яхшы сакланган. Без аны җентекләп тикшергәч, төрек шигъриятендәге «Йосыф вә Зөләйха»лар арасында үзенең кануниятле урыны булган гүзәл әсәр дип таптык. Әхмәди Кол Галидән башлап Сүлү Фәкыйһкәчә үсеш дәвамында тупланган сәнгатьчә казанышка таяна, сюжетны яктыртуга зур яңалыклар алып килә. Һәм шунысы кызык ки, Хәмди дастанында аның әсәреннән килгән йогынтыны, эзләрне аермачык күреп була.

Без башта шагыйрьне Әхмәди Гермияни түгелме икән, дигән идек. Профессор Таһирҗанов та шундый гоман белдергән иде. Әмма төрек әдәбияты тарихларында һәм энциклопедияләрдә Әхмәди Гермиянинең андый әсәр язуы мәгълүм түгел. Әхмәди Аккойунлу түгелме, дигән шик тә туды. Истанбулдан анысының кульязмасын алдырып тикшердек—ул да булып чыкмады. Без өйрәнә торган шагыйрь бөтенләй башка, монарчы билгесез калган Әхмәди дия алабыз. Аның әсәре—ялгыз төрек әдәбияты тарихын гына түгел, гомумән, урта гасыр төрки шигъриятен тулыландыра һәм бизи торган ядкяр. Чөнки ул урта гасыр төрки шигъри үсешенең уртак нигез һәм кануниятләренә таянып мәйданга килгән һәм үзеннән соң төрки мәдәниятнең төрле төбәкләрендәге шигъри үсешкә йогынты ясаган.

Шушы гүзәл дастан төрки Йосыфнамә тарихына нинди яңалыклар алып килгән соң? Аның төп яңалыгы Шәййад Хәмзә һәм Сүлү Фәкыйһ әсәрләрендәге Кол Галинең тарту көченнән ераклаша бару омтылышын сындырып, янә Кол Галигә якынаю ихтыяҗын гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Йосыф сюжетында иң тәэсирле эпизодларның берсе—каһарманның коллыкка сатылгач, юлда ана кабере өстендә елавы. Мәшһүр шәркыятьче һәм төркиятче галим Е. Э. Бертельс Фирдәүси әсәрендәге еглау эпизодын сәнгатьчә иң көчле урыннардан саный. «Шагыйрь моның белән гаять читен мәсьәләне хәл иткән,—ди ул.—Үзенең дәрәҗәсе белән буй җитмәслек каһарманны укучыдан кызгандыруга ирешкән». Әйтергә кирәк ки, ана кабере янында еглау мотивы борынгы Сүрия шагыйрьләрендә, хосусан йәһүдиләрнең «Агада» әдәбиятында ук эшләнгән.

Кол Галинең бу эпизодны эшләүдәге төп яңалыгы—баланың зарын биру белән чикләнмичә, елауның диалогка корылуында да. Ягъни шагыйрь тасвирынча, Йосыф анасына «әлләре-азаклары баглу» булуыннан, кардәшләренең үзен коллыкка сатуларыннан зарлана. Гүреннән ананың да кызгану (әсиркәү) сүзләре ишетелә. Бу алым борынгы төркиләрнең Орхон-Енисәй мәрсияләрендә теркәлгән язуларны хәтерләтә. Аларда сүз, кагыйдә буларак, мәрхүмнәр исеменнән әйтелә («... каганымдан, будунумдан адырылдым»). Диалог ананың углы өчен илаһияттән коткару соравы белән тәгәлләнә. Авторның шушыннан соңгы үз сүзләре Кол Галидә дә, Әхмәдидә дә бер үк төсле:

*Бу мунаҗәт ирди ахыйр ник-ү нәҗт*
*Вирди Раббим солтанәти таҗ-ү тәхт;*
*(Бу мөнәҗәт ахырдан рәхәткә һәм азатлыкка алып килде,*
*Раббым патшалык, таҗ һәм тәхет бирде.)*

(Әхмәди)

*Ул мөнаҗәт Йосыфа дугри улди,*
*Таҗ-у тәхт вә солтанәт улди имди.*

(Кол Гали)

Дастанның хиссияткә бай һәм тәэсирле вакыйгаларыннан зинданда интегүче Йосыфның тәрәзәдән Кәнган гарәбе белән сөйләшүен алыйк.

Кол Гали бу сөйләшүне әкият һәм дастаннардагы кебек метафоралы табышмакка кора. Табышмаклы сөйләм үзенең асыл тамырлары белән борынгы төркиләрнең кыз ярәшү йоласына, дипломатия, солых төзү һәм шомчылык теленә

барып тоташа. Татарларда афористик жанрларның күренекле белгечләре Нәкый Исәнбәт белән Хуҗиәхмәт Мәхмүтов шулай саный.

Кол Гали дастанында Йосыф, зиндан тәрәзәсеннән күреп, гарәп сәүдәгәренә шулай сорау бирә:

*Йосыф әйдер: Кәнгандән келүрмүсән,*
*Анда бер каба агач белүрмүсән,*
*Чәүрәсендә бутаклари белүрмүсән,*
*Ул бутаклар ун икиму тәмам имди?*
*Әй дәрига, нә йыракдур Кәнган или,*
*Фиркать әһле кемсәләрә дөшәр йули.*
*Галәл дәвам йил исдүкчә Кәнган йили*
*Ул йигачдан хәсрәт кукси кәлүр имди.*
*Гарәб әйдүр: «Аңладым бу сүзүңни,*
*Белдем, фәһем әйләдем бу разыңни,*
*Вәләкин дыңлайурмән бу сүзеңни,*
*Бу иш ичрә нә хикмәт вар?»—дәйүр имди.*
*«Каба агач дидекең Йагкуб дорыр,*
*Унбер угли хезмәтендә хазыйр дорыр,*
*Ун икенчи «Йосыф» адлу гаиб дорыр,*
*Хакыйкатьдә ани корд йиди имди...*
*Андан бирү йарли Йагкуб калди хәйран,*
*Аглайуб зари кылур мөдам гөрйан...*
*Йосыф гамин куңлүндән һич кидәрмәз,*
*Үгүтләб кемсәнең угтин алмаз,*
*Йосыф диүб таг-ташлар аглар имди».*

«Каба агач» метафорасы Дәдә Коркытка баглы угыз дастаннарыннан алынган булырга охшый. Ягъни «нәсел агачы» дигәнне аңлата.

Менә шушы ук сөйләшү Әхмәдидә ничек бирелгән:

*Аһ дәрига, ул йигаҗ билүрми сән,*
*Аслы ауракыйн фәһем кыйлурми сән,*
*Аһ дәрига, йил исдүкчә Кәнгани*
*Мүшк, ганбәр куки кәлүр бил ани...*
*Айди гарәб: «Фәһм идәрем сүзиңи,*
*Ликин гаҗәб таң калурм үзиңи...*
*Каба йигаҗ дидүкиң Йагкуб нәби*
*Унбер угли хидмәтидә бар аби*
*Ун икенҗи гаиб улан Йусуфи*
*Курд йийүбтүр һич куримаз күз суфи...*
*Бәнду вә нәсихәт аңа кыйлмаз йари*
*Наләсидин тагы таш аглар бари.*[1]
*(Аһ кызганыч, ул агачны беләсеңме,*
*Аның тамыр-яфракларын күзалламыйсыңмы,*
*Аһ кызганыч, Кәнган җиле искәндә,*
*Мөшек-ганбәр исе килә, бел аны...*
*Гарәп әйтте: «Сүзеңне төшенәм,*
*Ләкин гаҗәп, таң каламын үзеңә...*
*Биек агач дигәнең—Йагькуб нәби,*
*Унбер углы аталарына хезмәт итә.*
*Уникенче-юкка чыккан Йосыфны*
*Бүре ашады—һич кипмидер күз суы...*
*Киңәш һәм үгет аңа дус түгел,*
*Аның аһ-зарыннан барлык тау-ташлар елый.)*

Китерелгән өзектә Кол Галидән алынган метафора (каба агач—биек агач) һәм гыйбарәләрне бирелә аерымачык күреп була. Конкрет текстта уртаклык уфтану ымлыкларына чаклы туры килә («Аһ дәрига»).

Төрки Йосыфнамә тарихында Әхмәди олуг бер яңалыкчы булып күз алдына

[1]Әхмәди. Йусуф вә Зөләйха. Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар фонды 39, № 3881. С. 75 а-б. *(Гарәп язуында.)*

баса. Ул үзенә кадәрге өч йосыфнамәчедәге тасвирның композицион алымын бөтенләй янача кора. Тегеләрдәге диалогик хикәяләүдән ул өр-яңа композицион корылыш ясый. Диалоглардагы аерым персонажлар сөйләмен бүлеп алып, алардан монологлы бүлекләр төзи. Шул рәвешле ул, Кол Галигә, Шәййадка һәм Сулугә хас өслүбне таркатып, диалогик сөйләмне монологик сөйләмгә әверелдерә һәм андый кисәкләрдән «Сөэале шаһи Таймус», «Җавабе хәзрәти Йусуф галәйһиссәлам», «Җавабе Зөләйха» кебек бүлекләр эшли.

Йосыф сюжетының барлык төрки тәрдәшләрендә дә лирик башлангыч зур урын ала. Кол Галидә, мәсәлән, әсәрнең кереше һәм хәтимәсе, Йосыфның ана кабере янында еглавы, Зөләйха монологы кебек кисәкләрдә лирик эмоциональлек күзгә бәрелеп тора. Әхмәди, мондый өлешләрнең сәнгатьчәлек җәһәтеннән зур мөмкинлекләрен төшенеп, аларны лирик жанрлар калыбына сала һәм әсәргә тулаем көчле эмоциональ яңгыраш бирә. Әйтик, тирән психологик очракларда Зөләйханың туры сөйләмен газәл рәвешендә бирә. «Газәле Зөләйха» кебек бүлекләр әсәрдә байтак очрый. Шагыйрь башка жанрлар үзенчәлегеннән дә еш файдалана. Мәсәлән, Рәййанның: Йосыфка йомшаграк бул, дип Зөләйханы үгетләве «Касыйдәи шаһи Рәййан» дип бирелә. Әмма эпик хикәяләрнең азагы сөенечле тәмамланса, автор аны мәдхия итеп, моноримлы (бер кафияле) монолог рәвешендә бирә. Менә Йосыфның атасын каршылау вакытында әйткән сүзләре:

*Мәрхаба, әй тәхте шаһым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй бәхте шаһым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй афитабым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй маһитабым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй дилдә зарым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй мурги зарым, мәрхаба,*
*Мәрхаба, әй бүлбүл зарым, мәрхаба.*
*Мәрхаба, әй гүлфидарым, мәрхаба!*[1]
*(Хуш килдең, әй шаһ тәхтем, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй шаһлык бәхтем, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй кояшым, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй ай балкышым, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй күңел зарым, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй зарым кошы, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй былбыл зарым, хуш килдең!*
*Хуш килдең, әй күңел гөлем, хуш килдең!)*

Бу гимнда каһарманның шатлык тантанасы гына түгел, ата белән угылның озакка сузылган фирак драмасы да гомуми метафорик шәкелдә чагылыш тапкан. Әлеге тираданың гали аһәне сәламлау гыйбарәсенең мисраг башында һәм азагында үзгәрешсез килүе нәтиҗәсендә хасил була. Һәр мисраг уртасында бары метафора рәвешендәге риторик эндәш кенә яңарып бара.

Шунар охшаш тираданы үзәк өзгеч трагик яңгыраштa каһарманның анасы кабере янында еглау эпизодында күрергә мөмкин:

*Аһ дәрига, калды анам, әлфирак,*
*Ибнейәмин, Динә—нәтәм, әлфирак,*
*Аһ дәрига, чәкдим рәнҗи, әлфирак,*
*Тәңре биргәй вәсли гәнҗи, әлфирак,*
*Аһ дәрига, үтсә йыл-ай, әлфирак,*
*Собхишами һиҗрани, вай әлфирак!*
*(Аһ кызганыч, калды анам—хуш сау бул!*
*Ибне Йәмин, Динә калды—нишлим инде, хуш сау бул!*
*Аһ кызганыч, рәнҗү чиктем—хуш сау бул!*
*Тәңре бирсен яңа кавышу—хуш сау бул!*
*Аһ кызганыч, үтсә ел-ай—хуш сау бул!*
*Көн-төн үтәр айрылуда,—вай, хуш сау бул!*

Һәр ике тирадада мөкәммәл музыкаль ритм яңгырый.

Зөләйханың аерым газәлләрендә шагыйрь шигырь үлчәмен төрләндерә.

[1] Әхмәди. Йусуф вә Зөләйха.—С. 136 а.

Каһарманнарның, аеруча Зөләйханың эчке кичерешләрен аларның монологы аша төрле лирик жанрлар калыбында бирү дастанны психологизм белән баета, персонажлар язмышындагы драматизмны тирәнрәк ача һәм тулаем хикәяләүне яңартып тора, сафландыра. Әхмәдидәге композицион корылышны тагын да камилләштереп Хәмди куллана. Ул да персонажларның диалогик сөйләмен монологик сөйләмгә әйләндереп, аларны аерым бүлекләр итеп бирә. Монологлар, мәсәлән, «Хитабе Рубил», «Хитабе Шәмгун», «Хитабе Ляви», «Хитабе Йәһүдә» рәвешендә янгырый. Шушындый һәр бүлектән соң «Җавабе Йусуф» дигән бүлекчә килә.

Йосыф сюжеты төрки мәдәниятнең һәр өч төбәгендәге сәнгатькәрләрне кызыксындыруда дәвам итә. XV гасыр башында тимериләр дәүләтенең бер үзәге булган Бәлх шәһәрендә Дүрбәкнең «Йосыф вә Зөләйха» дастаны иҗат ителә. Бу уңайдан гаять мөһим бер үзенчәлеккә игътибар сорала. Шагыйрьнең «Йосыф-Зөләйха» сюжетына алынуы төрле төбәкләрдә охшаш тарихи шартларга туры килә. Әйтик, Кол Гали Идел Болгарстаны өстенә магул яулары янаган бер дәвердә иҗат итә. Әсәр, кардәшләрнең үзара низаглашуын гаепләп, илне, халыкны, дәүләтне бердәмлеккә туплау вазифасын башкарган. Галимнәр, хосусан Галина Горбаткина, Шәййад Хәмзә дастанында Сәлҗүкләр дәүләтенең үзәкләшкән хакимиятен ныгыту турында кайгырткан, ди.

Мондый тарихи-иҗтимагый актуальлек Дүрбәк дастанында аеруча үткен чагыла. Шагыйрь аны тимериләрнең тәхет өчен үзара сугышлары чорында камалыштагы шәһәр шартларында иҗат итә. Табигый ки, әсәр кардәшләр ызгышын гаепләп язылган.

Шагыйрь шушы камалыш чорында «Коръән» белән янәшә фарсы телендә нәсер белән язылган «Йосыф кыйссасы»н укуы хакында һәм янындагы дусларының «төрки телдә» шигъри әсәр иҗат итәргә кинәш бирүләрен әйтә. Үзбәк галиме мәрхүм Иргәш Рөстәмов шагыйрь телгә алган фарсы нәсеренең Абдуллаһ Әнсаринең «Әнисел мөридин» әсәре икәнлеген исбат итте.

Дүрбәкнең «Йосыф вә Зөләйха» дастаны композицион төзеклеге, шигъри теленең камиллеге һәм сюжет корылышының җыйнаклыгы белән аерылып тора. Үзенең сәнгатьчә эшләнеше ягыннан ул шул ук XV гасырда иҗат ителгән Хәмди дастаны белән бер югарылыкта тора. Әсәрнең бер үзенчәлеге шунда ки, күпчелек «Йосыф вә Зөләйха»лардан аермалы буларак, бу дастан Йосыфның атасы Йагкуб белән күрешү эпизодында, сөенечле, тантаналы рухта тәмамлана. Югыйсә, Әхмәдидән башка барлык «Йосыф вә Зөләйха»лар каһарманнарның вафаты белән тәмамланып моңсу янгыраш ала. Дүрбәк әсәрнең мондый апофеозы аша ватандашларын һәм замандашларын якты киләчәккә ышануга һәм оптимизмга юнәлтә.

Бер үк гасыр шагыйрьләре Дүрбәк белән Хәмдинең композицион корылыш җәһәтеннән бердәй җыйнаклыкка һәм төзеклеккә ирешүе икесенең дә нииндидер уртак әсәргә үрнәк итеп таянулары хакында сөйләмиме? Текстларны чагыштыру нәкъ шундый нәтиҗәгә китерә.

Иң әүвәл Дүрбәк әсәренең үзенчәлегенә, сюжетның башка тордәшләре янәшәсендә күзгә ташланган яңалыгына тукталыйк. Үзбәк шагыйре әсәр үзәгенә, Фирдәүси, Абдуллаһ Әнсари, Кол Гали һәм Хәмдигә кадәр иҗат иткән төрек шагыйрьләре кебек үк, ата белән угыл мөнәсәбәтен куйган. Сюжетның мондый корылышы «Коръән» һәм «Тәүрат» бирелешенә туры килә. Ә инде «яңалык» дигәндә, Дүрбәк Йосыф сурәтен, бүтән бер шагыйрьдә дә булмаганча, кешелек йомшаклыгына ия каһарман итеп яктырта.

Мәсәлән, Зөләйха белән никяхлашкач, Йосыф кәләшенең үзенә карата суынуын бик авыр кичерә. Хатын, кайнар мәхәббәтен бары Аллаһыга юнәлтеп, иренә битарафлык күрсәтә. Йосыф гажизлектән Аллаһыга ярсу сүзләр белән эндәшә:

*Һәр нә Зуләйха чәкиб ирди бәла*
*Кыйлма аныйндек мәни сән мөбтәла.*

*Лөтф кыйлыб гүрүмә илт, йа рәхим,*
*Ничә чәкаин бу азаби әлим.*

*(Зөләйха ничаклы бәла чиккән булса,*
*Аның кебек мине дә бәлагә салма!*
*Кызганып, мине гүремә илт, йә рәхим,*
*Ничек чыдыйм бу газапка?!)*

Зөләйханы үгетләү өчен ул аның янына Рәййанны җибәрә. Ансы да ярдәм итми. Шул рәвешчә, ул—хатын кырык ел эчендә күргән гыйшык гамен кырык көн эчендә күрә. Кайчандыр Зөләйханы сабырлыкка өндәгән пәйгамбәр, сабырлыгын җуеп, Тәңрегә: «Йә җанымны ал, йә Зөләйха белән кавыштыр!»—дип ярсый. Мондый мотивлар элеккерәк шагыйрьләрдә булырга мөмкин түгел иде. Дүрбәк—үз чоры шагыйре. Анын каһарманнары гамәлендә Низаминең «Ләйлә вә Мәҗнүн»е дә, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е дә, Хәрәзми һәм Сәйф Сараи лирикасының кайнарлыгы да чагылыш таба. Дүрбәк Зөләйхасы, мәсәлән, Йосыфка «Күзем нәркизе Зөһрә күзе кебек чәчәк атсын»,—дип эндәшә. Ягъни әсәрдә Шәрекънең «Таһир-Зөһрә» дастаны эзен дә абайлап була.

Төрки «Йосыфнамә» гаилә мәсьәләсендә Кол Гали эзеннән бара, ягъни анда бер мәхәббәткә корылган бер хатынлы гаилә идеясе үткәрелә. Бу мотив Дүрбәктә дә үзгәрешсез кала. Янә бер гаять мөһим үзенчәлек шунда ки, төрки «Йосыф-Зөләйха»ларда Йосыф Мисыр мәлиге Рәййанның төшен юраугa ук падишаһ (солтан, шаһ) дип игълан ителә. Тәүратта ул фиргавенның вәзире була. Фирдәүсидә башта—вәзир, аннары падишаһлык ала. Төрки шагыйрьләр кульминацион бу мәсьәләне фольклор рухында, хосусан тылсымлы әкиятчә хәл итәләр. Ягъни читен мәсьәләне чишүгә, каһарман тәхеткә утыра. Кол Галидә Рәййан Йосыфка: «Падишаһлык бәндән сәна лайык дорыр, җөмләнез аның әмрин дотын имди»,—ди. Тәхет тапшыру формуласы нәкъ фольклорча яңгырый.

Дүрбәк Йосыф сурәтен эшләгәндә дә, дини чыганаклардан һәм шигърияттәге үз элгәреләреннән аермалы буларак, каһарманны Йагъкубның иң кече углы итеп бирә. Юкса атаның иң кече углы Ибнейәмин санала. Үзбәк шагыйре монда да тылсымлы әкиятләрдәге «кече угыл» мотивына таяна.

Әсәрдәге аерым эпизодларның бирелеше һәм күп кенә шигъри юллар гаҗәп дәрәҗәдә Әхмәдине хәтерләтә.

Менә шушындый бер очрак. Күзләре күрмәс булган Зөләйха хезмәт күрсәтүче кызлардан Йосыфны элек бер очраткан җиргә итүләрен сорый. Нияте Йосыф баскан эз тузаның чәчләренә һәм күзләренә сибү була. Шунда Йосыфны очраткач, ул болай ди:

*Имди кыйлың сухтаи дилгә нәзар,*
*Булди йузиң бәндәси шамсу камәр;*
*Сәбру тәхаммил сәни кыйлди азиз*
*Сузиң иди шәһду шәкәрдән ләзиз.*[1]

*(Көйгән җанга бер күз салыгыз,*
*Кояш һәм ай йөзеңә кол булды!..*
*Чыдамлык һәм сабырлык сине газиз кылды,*
*Сүзең бал—шикәрдән татлырак иде.)*

(Әхмәди)

*Сухталар халинә салгыйл нәзар*
*Булди йузиң бәндәси шамсу камәр*
*Сабру тәхаммул сәни кыйлди азиз*
*Сузиң ирур шәһду шәкәрдин ләзиз.*[2]
*(Көйгәннәргә бер күз сал,*
*Кояш һәм ай йөзеңә кол булды...*
*Сабырлык һәм чыдамлык сине газиз кылды,*
*Сүзең бал—шикәрдән татлырак.)*

(Дүрбәк)

Әхмәдидәге гыйбарәләр («Сәбру тәхәммил сәни кыйлди азиз») Әнсаридән алынган. Әмма шагыйрьдән болай сүзгә-сүз күчерү гаеп эш түгелме? Урта гасыр шигъриятендә мондый контаминация еш очрый һәм ул гаеп саналмый.

Йосыфның Зөләйханы юату сүзләре белән дә шундый ук хәл.

*Сабыр илә табкайсән ахир бу морад*
*Билиң бола гамь йигән әлбиттә шад*[3].

---

[1]Әхмәди. Йусуф вә Зөләйха. S.—94 а
[2]Дурбек. Юсуф ва Зулайхо. Тошкент, 1959, С.—106.
[3]Әхмәди.—S.—94а.

*(Сабыр белән табарсың ахырдан бу мораdны,*
*Гамь йоткан, әлбәттә, булыр шат.)*

(Әхмәди)

*Сабр билә тапкасән ахир мурад*
*Гамь йигән адәм булур, әлбиттә, шад.*[1]
*(Сабыр белән табарсың ахырдан бу морадны,*
*Гамь йоткан әдәм булыр әлбәттә шат.)*

(Дүрбәк)

Күзәтүләребез тагын да дәлиллерәк булсын өчен йәнә зуррак бер өзек китерик. Шул ук вакыйганың дәвамыннан менә мондый кисәккә күз салыйк:

*Тазә күнкилүм йарайа сәбти нәмәк*
*Үртәнүр аhим утидин нуh фәләк;*
*Ушбу йирә барди ул хүкми илаh*
*Калиб иди ушул йирә Йусуф бәраh.*
*Алди аниң урнидин хак гобар*
*Сачти ани башина би хуиштә бар*
*Ушбу йириң сүрди йүзин йүзинә*
*Аглайубән тулдуруб хак күзинә*
*Дәр иди кем туфрак имәс бу гүйә*
*Жан дил илә күзләримгә тутиа.*

*(Саф күңелем ярасына тоз сипте,*
*Аhым утына дөрләр иде тугыз кат күк...*
*Илаhның хөкме белән ул шушы җиргә барды,—*
*Ул җиргә Тугры Йосыф килә иде.*
*Аның урыныннан тузанлы туфрак алды,*
*Үз-үзен белмәстән аны башына сипте,*
*Шушы җирнең йөзенә йөзен куйды,*
*Елый-елый күзенә тузан тутырды.*
*Әйтте: «Бу гүя туфрак түгел,*
*Ә минем җаныма, йөрәгемә һәм күзләремә тутия*

(Әхмәди)

*Тоза жарохат үзә сипти намак*
*Үртәнүр аhим утидин нуh фәләк*
*Йитди ушал ләхзә бә әмри илаh*
*Анда ки Йусуф туруб ирди бәраh*
*Алди ушал йир йүзә туфракларин*

*Сачти ушал ләхзә башига барин*
*Сүртәр иди йүзини ул йиргә зар*
*Йиглар иди зар чу абри баhар*
*Дир иди: Бу туфрак ирүр гүйе*
*Жону күнгүл күзигә чун түтийе.*[2]

(Дүрбәк)

Бу ике шагыйрь әсәрләреннән китерелгән үрнәкләр текст җәһәтеннән тулысынча диярлек туры килә. Кафияләр, ритм, сүзләр үзгәрешсез диярлек кабатлана. Фәкать аерым гыйбарәләр генә бераз үзгәртелгән. Күзгә күренеп торган мондый тәнгәллек очраклы була алмый.

Әхмәди тапкан һәм Дүрбәк кабул иткән мотив һәм төшенчәләр Зөләйханың гажиз халәтен, аның күргән чиксез михнәтләрен, язмышыннан арса да, сынмаган холкын калку итеп чагылдыралар. Алар ханымның ярсу, тыелгысыз, чигенмәс характеры мантыйгына бик ипле ятыша.

Әлеге өч шагыйрь әсәрендәге эзлекле багланышларны күздән кичерү берничә ныклы нәтиҗә ясарга нигез бирә.

Беренчедән, төрки мәдәниятнең һәр өч төбәге: Идел буе, Урта һәм Кече Азия уртак әдәби тормыш белән яшәгән. Берсенең сәнгатьчә казанышы шундук икенчесенең дә казанышына әйләнгән.

Икенчедән, мондый тыгыз алмашу гомумән әдәби үсешне тизләткән. Әсәрдән-әсәргә камилләшү бик кыска вакыт эчендә урта гасыр төрки шигърияten зур казанышларга алып килгән. Кол Гали Идел буе әдәбиятында Котб (XIV йөз) өчен, Дүрбәк—Нәваи өчен, Хәмди Фүзүли өчен җирлек әзерләгән, ә үзара исә логик рәвештә берсе икенчесе өчен камилләшү мәйданын хасил иткән. Кол Гали—Шәййад Хәмзә, Сүлү Фәкыйһ, Әхмәди өчен жирлек әзерләсә, Әхмәди Дүрбәк һәм Хәмди өчен жирлек әзерләгән.

Өченчедән, үзара тыгыз һәм бәрәкәтле багланышлар нигезе булып уртак әдәби тел хезмәт иткән. Ул әдәби-шигъри барышның уртак кануниятләрен булдыруга китергән.

Дүртенчедән, урта гасыр төрки шигъриятендәге назирә хәрәкәтенә куәтле этәргечне төркиләр дөньясына бәрәкәтле, гүзәл сюжет алып килгән XIII йөз башы Идел буе шагыйре Кол Гали ясаган.

[1]Дурбек.—С.—107.
[2]Дурбек.—С.—107-108.

Хәтер

## Розалина Нуруллина

# ТОМАННАРГА ЕЛЛАР КҮМЕЛДЕ...

*Исем белән түгел, эше белән*
*Ватан улчи кеше йөрәген.*

Н. Дәүли

Уртак шатлыклар-хәсрәтләр, табышлар-югалтулардан тыш, аның да, минем дә үзебезгә генә хас, бер-беребезгә мәгълүм булмаган кичерешләр дә күп үткәндер йөрәктән. Кырык дүрт елдан артык бергә гомер кичелгән. Әмма безне берләштергән хисләр, фикерләр гомер урталарына җиткәндә икебезне бер җан, бер тән итеп яшәтте, нинди тетрәнүләр дә безне аера алмады.

... Ибраһим белән мин университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый башлавымның беренче аенда ук белеш булдым. Бу–1947 ел. Дүрт кенә ел элек оешкан булса да, бүлектәге әдәби түгәрәкнең даны киң таралган. Аның утырышларына университетның башка факультетларыннан, Казанның башка вузларыннан әдәбиятка омтылучы һәм үз телебездә аралашырга теләүче яшьләр җыела иде.Бу уку елындагы беренче җыелышка группабыз белән килдек. Безнең белән бергә укучы кече лейтенант Мәхмүт Хөсәенов шигырьнең асылы турында доклад ясады. Аның янында берничә егет утыра иде. Түгәрәк җитәкчеләредер болар дип уйладык. Утырыш тәмамлангач, шул егетләрнең берсе минем яныма килеп: «Сез кем, кайдан?»–дип сораштырды, үзе белән таныштырды–өченче курс студенты Ибраһим Нуруллин икән.

Без укырга кергәндә бүлектә әле дүрт кенә курс бар, штатта бер укытучы–кафедра мөдире доцент Рабига Афзал кызы Хәкимова һәм лаборант, безнең Яңа Бистәдәге атаклы Исмәгыйль доктор кызы Зәлфә Усманова эшлиләр иде. (Зәлфә искиткеч чибәр, нәфис кыз, мин аны сугыш елларында шәһәребездә барган «Багдадский вор» фильмының төп героинясына охшата идем. Аннары ул Булат Гыйззәтуллинга кияүгә чыкты.)

Штатта торып укытучылар булмаганга, түбән курсларга җитәкчелекне фронтовик студентлар алып бара. Алар бездән 5-6 яшькә өлкәнрәкләр, киеп йөргән шинельләре, гимнастеркалары күпмегә җитдирәк, тәҗрибәлерәк икәнлекләрен күрсәтеп тора. Ибраһим–шуларның берсе һәм иң хөрмәтлеләреннән. Ул безнең группаның кураторы булды. Дөрес, ул шинель дә, гимнастерка да киеп йөрми, әмма дәрәҗәсе–зур. Тукай исемендәге стипендия ала иде, аннары Сталин исемендәгесенә лаек булды.

Мин аны берниндн икеләнү, шөбһәләнү белми торган, үзенә һәм киләчәгенә ныклы ышаныч белән яши торган кеше итеп саный идем.Яшьлегемдә миңа игътибар иткән беренче егет булгангамы, ул елларда кызлар һәм малайлар аерым мәктәпләрдә укыганга, моңарчы егетләр белән якыннан аралашырга да туры килмәде, мин Ибраһимны очратканда дулкынланам. Аңа олы итеп, буй җитмәслек шәхес итеп карыйм. Менә хәзер Ибраһимның ул чактагы көндәлекләрен актарганда, гаҗәпләнеп, хакыйкатьне күрәм: юк икән, аның җаны тиз җәрәхәтләнүчән булган икән. Ул да иптәшләренең дустанә мөнәсәбәтенә мохтаҗ булган, урынлы һәм урынсыз төрттерүләр аны газаплаган, үзенең дә кайбер сүзләре, гамәлләре өчен борчылган.

Ибраһим, үзенең үткәне турында язганда, үзен бизәмәгән эш-гамәлләрен яшерми. Менә бер мисал: парашютчылар түгәрәгенә йөргәндә аларны мехчылар клубы ишек алдындагы вышкадан сикерергә алып баралар. «Вышка артык биек тә түгел,–дип яза ул,–28 метр гына. Малайлар минделәр дә сикереп төштеләр, минем йөрәк җитмәде, сикермичә кайтып киттем».

Мин дә аны бизәп күрсәтергә хакыйкатькә хыянәт итеп матурларга уйламыйм. Ул гомере буе вакыйгаларны ничек булган, шулай яктырту өчен көрәште. Нәкъ менә көрәште. Үзенең табигатеннән килгән йомшаклыкларны җиңеп, вәзгыять таләп иткәнне кыла алган кеше хөрмәткә күбрәк лаеклы. Иң зур җиңү кешенең үзен-үзе җиңүе бит. Болай гына кирәк булганда тәбәнәк вышкадан да сикерә алмаган Ибраһим сугыш вакытында, гамәли мәҗбүрият килеп тугач, 71 метрлы вышкадан, беренче үк булмаса да, икенче булып сикергән. Чөнки ил дәһшәтле, аяусыз, канлы сугыш эчендә, ә ул–солдат, ул–комсомол, сугышчан һәм сәяси хәзерлек отличнигы, шул халәте аңа куркуын җиңәргә көч биргән. Мин аңа 1975 елда Совет Армиясе көне белән котлавымда түбәндәге юлларны язганмын: «Сине чыдам, батыр, кыю кешеләр көне белән котлыйм һәм сине шундыйларның берсе дип саныйм. Син тумыштан ул сыйфатлар белән мул итеп бүләкләнмәгән булсаң да, акыл белән аларны үзеңдә тәрбиялисең. Монысы тагын да мактаулырак».

Ибраһим гомергә үз-үзе белән көрәшеп яшәде. Кайчакта холкы-табигате җиңә, кайчакта–ихтыяры. Әмма көрәш туктаусыз барды.

Аның шундый кеше булып җитешүенә нәрсәләр сәбәп булган, үзен-үзе тәрбияләргә кирәклекне аңлаткан шартлар ниндиләр, моңа аны нәрсә этәргән–бу сорауларга җавапны бала чагыннан, туып үскән гаиләсеннән, ата-анасы мохитеннән эзләргә кирәк дип беләм.

* * *

*Сабыйлык төш кеби улыр.*

Г. Кандалый

Ибраһим Нуруллин 1923 елда туган. Әтисе–укытучы, әнисе гади хатын, авылның иң чибәр кызларыннан булган. Ибраһимның әнисе дә, әтисе дә–халле гаилә балалары. Әнисенең нәселен, Бикчуровларны, кара байлар дип йөрткәннәр. Нәселләрендә укымышлылар булмаган. Әтисе ягыннан бабасының тормышын Ибраһимов болай сурәтли: «Аның өе урамга перпендикуляр итеп салынган алты почмаклы, калай түбәле зур өй иде. Киң ишек алды лапас, сарай, келәтләр белән уратып алынган. Урыс капканың урам ягында тимер ишекле таш подвал бар иде.

Авылыбызның тегермән буасы булганлыктан тирәнәйгән, киңәйгән кечкенә елгасы буенда бабайның «путаш заводы» бар иде. Ул «завод» дигәнең ындыр табагы кебек мәйданчыктан һәм зур казаннан гыйбарәт булганы хәтеремдә калган. Фәкыйрьлегә һәм балаларының күплеге белән авылда беренче урынны тоткан Гайфук бабай әнә шул завод өчен җәен-кышын өй борынча йөреп, көл җыя иде. Соңрак бабайны кулак ясап хокукыннан мәхрүм иттеләр, мөлкәтен алдылар.

Шушындый гаиләдә туып үссә дә, Ибраһимның әтисе Зиннәтулла мал җанлы, байлык юнәтүче кеше булмаган. Мәдрәсәне тәмамлагач, укытучы булып эшләгән. Әнисе Нәвал бик житез иде. «Безнең тормышны әни алып барды»,–дия иде Ибраһим. Аларның авыллары Парау бик матур табигатьле урында. Якында гына зур урманда–чикләвек, кура җиләге, карлыган; икенче яктагы Чирмешән буендагы Киерче болынында җиләк, юа, балтырган үсә. Әни урман-болын байлыкларын җыярга бик оста иде. Аннары ул тегүчелек белән дә шөгыльләнгән, колхозда эшләгән, биргәнен дә, бирмәгәнен дә өенә ташыган, гаиләсенең тамагын туйдырган.

Ә әтисе–күбрәк җәмәгать эшендә. Нурулла бабай, инде сукырайган булса да, мал-мөлкәтен алалар, ә улы коммунизм турында лекцияләр укый, берничә фикердәше белән коммуна оештыра. Менә шушы тормышка ике төрле караучы кешеләр–бер яктан, эшчән, гаярь, мал булдыручы бабасы һәм әнисе, икенче яктан, иҗтимагый тормышны, җәмгыятькә хезмәт итүне үзенең яшәеш рәвеше иткән әтисе... Аларның рухи варисы булган Ибраһимның да холкы каршылыклы, беренче карашка бер-берсе белән сыеша алмый торган сыйфатларга ия иде. Тормышы һәм иҗаты аның шул фикерне раслаучы хәлләргә бай. Ул еш кына әйткән сүзенә кылган яки кыла алмаган гамәленә үкенә иде. Хәтта «Үкенечләрем» дигән махсус парча да язды.

Ул вакыттагы тәртипләр шундый булган: укытучы әтисен әле бер авылга, әле икенчесенә бик еш күчереп йөрткәннәр. Зирекле Куакта 7 сыйныфны тәмамлагач, Ибраһимны әтисе Мәләкәскә рус мәктәбенә бирә. Әмма бик яшьли (44 яшендә) әтисе кара сары авыруыннан үлеп киткәч, Ибраһим башта Чаллыда, аннары Казанда әнисенең энесе Харис абыйларда торып укый. Казанда мех техникумына керә.

Совет хакимиятен никадәр генә яманласак та, ул заманда тормыш никадәр авыр булса да, бүген тарихта исемнәре калган һәм калачак күп кенә татар балалары нәкъ менә совет тудырган шартларда белем алып, олы юлга чыкканнар.

Техникумда укыганда Ибраһим тулай торакта яшәгән, нинди түгәрәк эшләсә— барысына да йөргән, музыкага сәләте зур булмаса да, кыллы уен кораллары оркестрына да катнашкан, мандолина, скрипкада уйнарга өйрәнгән, «музыкант» буларак техникум кысаларына гына сыймыйча, филармония оркестрында уйнаган, хәтта «филармония артисты» дигән таныклыгы да булган. «Җәваһирә Сәләхова безнең оркестрга кушылып җырлый иде»,—дип сөйләгәне хәтеремдә. Ул әле тагын парашютчылыкка да әзерләнгән. Бу түгәрәккә кабул иткәннәр икән, димәк, ул бик сәламәт булган.

Бер Ибраһим гына түгел, барлык иптәшләре дә белемгә омтылып, җанлы тормыш белән яшәгәннәр. Ибраһим алардан бәлки әдәбиятны артык яратуы белән генә аерылып торгандыр. Кече яшьтән үк күп укый, һәр язучының исемен белә, үзләрен күрергә хыяллана. Ике тапкыр ул мондый бәхеткә ирешкән дә. Берсе Ульяновск өлкәсе Яңа Мылыклы районы Әбдери авылында укыганда була. Аларның мәктәбенә Сәхаб Урайский килә. Техникумда укыганда Матбугат йорты тирәсендә ул аны тагын очрата, ләкин эндәшергә базмый. Икенчесе Лопатинода (хәзер—Волжск) яшәүче туганнарына барганда поездда Муса Җәлил белән бер вагонга туры килә. Ул аны рәсеме буенча таный һәм барып җиткәнче аның янында кайнаша. Әлбәттә инде, сүз ката алмый. Ибраһим тартык, карарсызрак малай булган һәм гомеренең азагына кадәр аның ул сыйфатлары сизелеп-сизелеп ала иде.



*Ибраһим һәм Розалина Нуруллиналар. 1951 ел.*

Ибраһим техникумда укыганда Яңа бистәдәге мех комбинатының безнең өй каршындагы фабрикасына практикага йөргән. Бәлки, мин дә аңа очрагандырмын, әмма үзеннән алты яшьләр кечерәк кызчыкка ул карамый да үткәндер.

1941 ел. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башланган көннәр. Комсомол райкомыннан килеп, техникумның IV нче курсында укучылардан: «Үзегез теләп сугышка китәсезме?»—дип сорыйлар. «Китәбез»,—диләр яңа гына үсмерлектән чыгып килүче егетләр. Ибраһим парашютлы десант гаскәрләренә эләгә. Алар Мәскәү янында өйрәнүләр үтәләр, аннары мондый гаскәрләрнең тиз генә кирәк булмаслыгы ачыкланыпмы, ашыгыч мохтаҗлык чыгыпмы, аларны җәяүле гаскәр ясыйлар. Себергә куылган Идел буе немецларының ташландык авылларына күчерәләр.

Ибраһим Сталинград фронтында Әстерхан юнәлешендә сугышка керген. Дулкын-дулкын булып җәелгән ком калкулыкларын менә-төшә бара торгач, алар немецлар урнашкан окоплар каршысына ук килеп чыгалар. Немецлар ара-тирә миномётлардан атып куялар, ә безнекеләргә җитәкчелек итүче, нинди дә сугышчан хәрәкәтләргә өндәүче бер командир да юк. Шунда сәяси һәм сугышчан хәзерлек отличнигы, комсомол Ибраһим Нуруллинның йөрәге түзми, бер иптәшен үгетли дә алар пулеметларын окоптан чыгарып куеп, немецларга ата башлыйлар. Менә боларның башта бер ягында, аннары икенче ягында мина ярыла. Өченчесе болар өстенә төшәргә тиеш. Кире окопка чумарга туры килә.

Шунда, Калмык җирләрендә Яшькүл районында барган һөҗүм вакытында,

1942 елның 20 ноябрендә Ибраһим каты яралана. Сул аягының тубыгы мина кыйпылчыгы тиеп чәрдәкләнгән. Санитарлар аны палаткага урнашкан кыр госпитале кырыена китереп салганнар. Яралылар күп. Ибраһим көн буе диярлек ялан кыр өстендә яткан. Көз, салкын, исән аягының бармаклары өшегән. Санитар булып йөрүче, элек үзе белән бергә хезмәт иткән Чухванцев фамилияле солдат килеп чыкмаган булса, бәлки ул күп кан югалтудан һәлак та булыр иде. Аны танып алгач, Ибраһим булышуын үтенә, тегесе күтәреп алуга, аңын югалта һәм шуннан соң гына табиблар кулына эләгә. Ибраһимның сугышта аяксыз калуы турында уйлаганда, аның малай чагы хатирәсе итеп сөйләгән бер хәл исемә төшә.

Мәктәпләрдә безне, Алла юк, дини хорафатлар зарарлы, болар—капитализм калдыгы, дип тәрбияләделәр. Ә өйдә әби-бабайлар дога өйрәтәләр. Бу ике төрле тәрбиянең чарпылышы да еш булып тора. Бервакыт малайлар арасында, Алла бармыюкмы, дип бәхәс кита. Ибраһим аягы белән җиргә тибә-тибә, менә әгәр булса, аягымны җир упсын, дип кычкырган. Ун ел үткәч, аның аягы Әстерхан даласы туфрагына күмелеп калган...

Аннары—бер ел буе госпитальдә. Бер кисәләр аягын. Төзәлми. Тагын кисәргә кирәк. Ә авыртуны баса торган дарулар юк икән. Павел Корчагинны идеалы иткән Ибраһим Нуруллин табибларга әйтә:

—Кисегез әйдә местный наркоз белән генә, түзәрмен.

Ә ул наркоз сөяккә үтми бит! Сөяк авыртуын киметми! Шуннан Ибраһимны ыңгырашырга яратучыларга үрнәк итә башлыйлар. Әмма авырту аның үзегенә үткән булырга тиеш, чөнки соңыннан аз гына авыртудан да курка иде. Ә сызлану, тән газаплары аны гомере буе эзәрлекләде. Һава торышы алмашынган вакытларда яисә ниндидер безгә билгесез сәбәпләрдән инде кисеп алынган аягында үтә чәнчү башлана, тәненә сеңгән егерме өч мина ярчыгының кайсы да булса берсе вакыт-вакыт кузгалып куя. Нишләптер ул сызланулар күбрәк кичкырын, төнгә каршы башлана, әмма шундый газаплары хакында ул бер кемгә дә сөйләми, мин генә беләм, хәтта балалар да аңышып җитмиләр иде.

Мондый авыртулар вакытында да, зур кайгылар, борчулар булганда да аның өчен төп дару—китап. Ә андый чаклар күп, бик күп булды...

Госпитальдә дә ул бик күп укыган. Добролюбов, Чернышевский, Писаревларның әдәбият турындагы әсәрләрен шунда өйрәнгән. Лев һәм Алексей Толстойларның, Шолоховның, татар әдипләреннән Шәриф Камалның әсәрләрен кайта-кайта укыды. Ә болай ул татар әдәбияты дөньясында күренгән һәр яңа әсәр белән танышып барды, нинди дә булса бер өлгереп җиткән мәсьәләне җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итәргә азык биргәннәре турында бөтен даирәне селкетеп ала торган мәкаләләр язды.

* * *

*Егетлек кош кеби улыр.*

Г. Кандалый

Менә егермесен тутырган яшь егет ике култык таягына таянып туган авылына кайтып төшә. Ибраһимны туган-тумачалары кунакка алалар. Андый мәҗлесләрнең берсен Ибраһим үзе кичергән үкенечле хәлләрнең берсе итеп сөйли иде.

Кунак табынына итле токмач шулпасы килә. Госпиталь ризыгыннан тәмам гарык егет (әнисе дә бәрәңге-катыктан артык нәрсә белән сыйлый алмый) ашны бик яратып, туйганчы ашый. Аннары каз ите тутырылган табак килеп утыра. Ах, тәмле, әмма инде урын юк. Бер елдан соң көзен әлеге Йосыф абыйлар Ибраһимны тагын кунакка дәшәләр. Бу юлы инде алданмыйм дип, ул ашны чак кына капкалап утыра. Соңыннан ит чыга чыгуын, ләкин инде узган елгы кебек табак тутырып түгел, сай савытта берничә кисәк кенә. Ибраһим аны-моны абайлап алганчы, ул кисәкләрне дә эләктереп бетерәләр. Тагын үкенеп кайтып китәргә туры килә.

Монысы көлке. Ә җитдие ничек? Шул елны ук (бу 1943 ел булырга тиеш) Ибраһим мәктәптә эшли башлый. Элек аңа башлангыч сыйныфларны бирәләр. Бер көнне мәктәпкә иртәрәк килсә, 7 нче сыйныф малайлары өйгә бирелгән мәсьәләне тактада чишә алмый азапланалар. Ибраһим, кызыксынып, яннарына килә, мәсьәләне чишеп бирә. Моны читтән генә күзәтеп торган директор яшь укытучыны

бүлмәсенә чакырып ала да, битәрли башлый: «Ничек шулай эшләдең, ә чишә алмаган булсаң?! Укытучының абруе турында уйларга кирәк»,–ди. Ибраһим көлемсерәп кенә куя. Ул математикадан көчле. Шуннан соң директор, моңарчы үзе алып барган математика, физика фәннәрен аңа биреп, югары классларны укытырга күчерә. Укытучы булarак Ибраһим үзе дә малайларча мавыгып эшли, дәресләрне кызыклы, күңелле итәргә тырыша. Моның бер алымы–тәҗрибәләр ясау. Спиртовкасыз тәҗрибәләр уздырып булмый, ә спирт юк. Яшь укытучы аптырап калмый, әнисенең бәрәңгесен төйи дә күршедәге Сакчы исемле чуаш авылындагы спирт заводына кита. Ярты литр спирт бирәләр, тәҗрибәләр ясарга мөмкин. Электр звоногы ясап күрсәткәндә укучыларның гаҗәпләнүләре! Әнә шулар һәм китаплар, иҗади хезмәт Ибраһимның авылдагы яшәешен бизи. Шунда ул беренче хикәяләрен яза, аларны «Совет әдәбияты» журналына юллый. Шунда ул беренче тапкыр хикәясе басылып чыкканны күрү бәхетенә ирешә.

Эш һәм хезмәт кенә тормышны түгәрәкли алмый. Яшь егет бит әле ул. Күңеле мәхәббәт тели. Көндәлегенә «Йөрәк мәхәббәтсез яши алмый», дип язып куйган. Хат аша бер кыз белән таныша, фоторәсемен ала. Егет күңеле фотодагы кызны хыялы белән бизи, аны акыллы итеп, нәфис, нәзакәтле итеп күрә һәм, ниһаять, күңеле түзми, аның янына үзе кита Кызганычка димме, бәхеткәме–кызның тагын бер сөйгән егете кайдандыр кайтып төшкән була. Ике егетен очраштырмас өчен, икесенә дә игътибар бирер өчен кызның нинди тапкырлык күрсәтүен һәм хәйләләр коруын көлке итеп Ибраһим үзе «Мәхәббәтләрем» исемле парча да язган иде.

1945 елның көзендә Ибраһим инде–Казан дәүләт университеты студенты. Укырга ул ашкынып, үз алдына махсус бурычлар куеп килә. Аның планы мондый: философияне, рус, көнбатыш, татар әдәбиятларын, әдәбият теориясен ныклап үзләштерергә, бер повесть язарга, пианинода уйнарга һәм биергә өйрәнергә. Ул хәтта тимераякта шуарга тырышып караган. Ул елларда катоклар эшли иде, аларда тимераякны алып торырга да була, алар яшьләрнең күңелле һәм мәдәниятле ял урыннарыннан санала иде. Көндәлегенә язганча, ул тимераякны кигәндә үз алдына: «Шуа алырмынмы инде?»,–дип куйган. Янындагы малай аңа: «Маресьев очкан да әле»,–дигән. Тимераякта шуа алмаса да, велосипедта йөри иде.

Үзенең аяксыз булуына кимсенгәнме ул? Баштарак кимсенгән булырга тиеш. «Район үзәгендә» хикәясе үзен шул хисләрдән коткарырга теләп язылган кебек. Көндәлекләрендә дә берәр матур кызга күзе төшеп, тегесе илтифат итмәсә: «Нишләп инде ул минем шикелле тәбәнәк, ябык, аксак егетне сайласын»,–кебегрәк җөмләләр очрый.

Күңелен саф, гамәлләрен күркәм итү өчен Ибраһим студент елларында, бигрәк тә беренче-өченче курсларда укыганда, нык тырышкан. Күркәм сыйфатларга ия иптәшләренә сокланган. Техникумда укыганда андый кеше–Хәй Газизов. Габделхәй Газизов үз алдына зур максатлар куеп, шуларга тайпылышсыз омтылып яшәгән. Ул чакта безнең идеал Ленин иде. Габделхәй дә ил өчен, халык өчен тырышучы гадел, акыллы булырга теләгән. «Ленинның сыйфатларны үземдә булдырачакмын»,–дигән. 23 яшендә Ленинградны саклап сугышканда һәлак булмаса, ул совет режимының сүздә игълан иткән кыйммәтләреннән нык читләшкәнен, әлбәттә, аңлар иде.

Ә университетта Ибраһимның сокланганы–Фазыл Фасеев. «Фазыл,–дип яза ул,–искиткеч саф кеше, дәртле, ялкынлы. Урман кебек табигый, ә урман шәһәр паркларыннан матуррак». Фазылның әйткән сүзләрен көндәлекләрендә еш китерә. Берсендә Фазыл, партия җыелышыннан чыккач: «Мондый җыелышлардан чистарып чыгасың»,–дигән. Группадагы кимчелекләр тикшерелгән җыелыштан соң: «Бөтенесе өчен дә үземне гаепле сизәм»,–дигән. Ә бервакыт әйткән: «Незаметный тормыш белән торасым килә».

–«Ник?»–дип сораган Ибраһим.

«Янып-көеп яшәү бик авыр. Бөтенесе турында да борчыласың, бөтен җирдә үзеңне җаваплы сизәсең».

Ә безнең арада Фазыл үзен бер дә житди тотмый иде. Ул кызларны кочакларга, алар белән шаярырга ярата. Ә ул заманда кызларга егетләрдән кочаклату килешмәгән, мөмкин булмаган эш һәм сөйгәне белән генә бик яшерен генә эшләнә иде.

Ибраһим гомере буе Фазылны бик югары куйды. Татар бүлегенең 50 еллыгы уңаеннан язылган «Юл башы» исемле истәлегендә: «ул чакта ук инде (ягъни студент елларында–Р. Н.) Фазылның даһилыкка якын торган талантка ия булганлыгы сизелә иде»,–дигән сүзләр бар. Соңыннан да кайберәүләргә сәләтле, намуслы, хаклык өчен

керәшәләр, дип сокланды. Мәсәлән, Альберт Яхинга, Мөхәммәт Мәһдиевкә, Әгъдәс Борһановка.

1946 елдан Ибраһим язучылар даирәсенә керә башлый, җыелышларга, төрле секцияләрнең утырышларына йөрү белән генә чикләнмичә, алар белән шәхсән аралаша, үзе белән таныштыра. 1946 елның 30 апрелендә проза секциясендә хикәяләрен укыгач, Атилла Расих, Гаврила Беляев, Фатих Хөсниләр аның әсәрләрен, башкаларга иярми, үз тавышы бар, дип бәялиләр. Әмма төшенкелек аһәңе сизелеп тора, дип тәнкыйтьлиләр дә.

Шуннан соң ул нәфис әдәбиятның асылы турында ныклап уйлана башлаган. «Язучы булу өчен иң әһәмиятле, иң типик кешене күрә белү кирәк. Алар, җанлы кеше кебек, үзләре хәрәкәтләнсеннәр, аларны теләсә ничек тартып йөртеп булмасын. Үз язганнарымдагы фальшны яхшырак сизә башладым... Димәк, минем йөрәгем сизгеррәк була бара». (1946 ел, 1 июнь.)

«Кичә К. Нәҗмидә булдым. Ул киң күңелле кеше икән. Бераздан ике кызчык килделәр. Алар рус мәктәбеннән, 6 нчы сыйныф укучылары икән. Кызлар–әрсезләр. Алар К. Нәҗмидән үзе турында озын итеп язып бирүне сорыйлар. Аларга сбор өчен К. Нәҗминең биографиясе кирәк икән. К. Нәҗми биргән брошюрадагы биография кыска икән. Нәҗми гаепле елмая. Аның эше күп, ләкин ул баш тарта алмый. Кызлар һаман «наступать» итәләр, карточка сорыйлар. К. Нәҗми карточка эзләп йөгереп йөри.

Ниһаять, кызлар китәләр. С. Әдһәмова көлә: «Сөйләштереп оныттырдык үзләрен»,–ди. Ул иреннәрен матурайтырга тырыша. Аның йөзендә элеккеге матурлыгы сакланган. К. Н. олы кеше булса да, бераз мактанмый булдыра алмый. Ләкин ул мактану бик мөлаем. «Туган ил, туган ил»,–дип әллә ничә тапкыр кабатлады. Ахырдан шкафларын ачып җибәреп, «Туган ил» өчен җыйган материалларын күрсәтте». (1948 ел, 15 декабрь.)

Ибраһим матурлыкны, нәфислекне сизә һәм бәяли белә иде. Табигать яме дә аның күңелен тибрәндерә, хатын-кыз матурлыгына да битараф калмый иде.

Егет белән кыз буларак, без аның белән 1947 елның октябрь азакларында очраша башладык. Театрга барган идек. Нинди спектакль икәнен хәтерләмим. Ул чакта егет белән кызның күрешүләре театрга, кинога (күбрәк кинога) бергәләп бару рәвешендә уза иде. Шуннан соң Ибраһим көндәлегенә: «Күңелемдә, күкрәгемдә, гомумән, тормышымда, яктылык хасил булды. Ул–Розалина образы. Менә шундый яктылык булганда яшәү җиңел, сулу иркен. Бу яктылык астында үзеңнең максатларыңны ачыграк күрәсең, бу максатка ирешү өчен ул сиңа көч бирә.

Ул акыллы булырга тиеш. Мин театрга чакыргач, аз гына да борғаланмады... Менә ул күренде. Йөзе нормаль булмаганча житди, житди генә түгел, ә киеренкелек чагылган, хәтта газаплану сызыклары чыккан кебек» (26 октябрь, 1947 ел). Ничек төгәл аңлаган ул минем халәтемне. Мин үземнең кыяфәтемне яратмый идем, көзгегә карарга курка идем. Аның бу чакыруы да ялгыш кына булгандыр, хакыйкатьне күреп алгач, бу эшенә үкенер, дип уйлый идем. Хәзер Ибраһимның көндәлегеннән үзем турында язылган бу юлларны уку миңа бик рәхәт булды. Димәк, гомере буе мин аңа яктылык булып тоелганмын. Вафатына ике ел кала язган котлавында да: «Син минем өчен яктылык нуры»,–дигән. Безнең очрашулар өзелгәләп торса да, ул дүртенче курста миңа тәкъдим ясады. Әмма мин икенче курста гына укый идем, гаилә корырга әзер түгел идем әле. Без 1951 елда өйләнештек. Ибраһим инде–аспирантурада, мин дүртенче курсны тәмамлап киләм. Ул гаилә кору эшен кичектерергә ярамаганны аңлап, тормыш итәргә яраклы кешене хистән битәр акыл белән эзләп алды. Ибраһимның ныклап миңа күңел беркетүенә Сафа Сабировның да йогынтысы булды, ахры. Ул мине Сафаларга алып барган иде, алар белән бергә Казансу буйларында йөрдек, мин су янында Сафаның кызлары белән әвәрә килдем. Сафа үзе гел әйтә: «Ибраһимга сине мин бирдем»,–ди.

6 апрельдә безнең Яңа Бистәдәге өебездә әни кечкенә генә туй мәҗлесе уздырды. Безнең якта туй гадәте–бераз ашап-эчкәч, табынга бал белән май чыгаралар. Моның ике хасияте бар. Яшьләрнең гомере муллыкта үтсен һәм татлы булсын, дигән теләк белдерү, икенчесе–бал-май чыккач, кунаклар бүләкләрен (акчалата дип күздә тотыла) шунда куелган тастымалга салалар. Без андый «иске» гадәтләргә буйсынмыйбыз, без–яшьләр, яңалар. Бу йоладан баш тарттык.

Без Зур Вахитов урамында Каюм Мостакаев өенең түр бүлмәсендә яши башладык. Каюм Мостакаевның исеме әдәбият һәм журналистика тарихы белән

шөгыльләнүчеләргә мәгълүм. Ул яшьлегендә Тукайны, Фатих Әмирханны күреп белгән, зыялы яшьләр даирәсендә кайнаган, газета-журналларга язышкан. Ибраһим шул заманнар турында аның белән озаклап сөйләшеп утыра иде.

Мин килгәндә Ибраһимның бөтен байлыгы бер язу өстәле һәм китаплар иде. Тар тимер караваты, урын-җирләре университет тулай торагыннан алынган. Сөнелесе Гөлләр белән яшәсәләр дә, өстәл-урындык, савыт-саба, кашык-пычак—Каюм абыйларныкы. Хәтеремдә, мин аларга төшкәнемнең икенче көнендә үк кашыклар, пычак һәм тәмәке савыты алып кайттым. Мин ул вакытта, укуым өстенә 35 нче мәктәптә китапханәче булып эшләгәнгә, бераз акчам бар иде. Урын-җирне миңа кайсысын әни, кайсысын апа-җиңгәләрем юнәттеләр. Тагарактыр, үтүктер кебек әйберләрне әниләргә барып алып торам. Яңа Бистәнең Зур Ямаш урамында торсалар да, миңа адым саен күршеләрдән сораугa караганда, аларга барып кайту җиңелрәк һәм рәхәтрәк.

Хәерче булсак та, күңелле яшәдек үзе. Өйләнешкәч тә, 1951 елның Май бәйрәменә безгә кунакка, ике яшьлек кызлары Йолдызны алып, Мәрьям белән Җәмил Гыйльмановлар килделәр.

Җәмил белән Ибраһимның дуслыгы әтиләреннән мирас булып калган. Әтиләре икесе дә укытучы, фикердәш, сердәш булганнар. Җәмил Ибраһимнан ике яшькә кечерәк, университетка да соңрак кергән. Анда беренче килгән көнне үк мактау тактасында Сталин стипендиаты Ибраһим Нуруллинның рәсемен күргән. Шунда ук үзенә сүз биргән: мин дә шушы дәрәҗәгә ирешермен. Һәм ирешә. Алар менә шулай гел ярышып яшәделәр. Зур мәсьәләләрдә генә түгел, вак-төяк нәрсәләрдә дә алар арасында һәрвакыт әнә шундый бер-берсеннән уздырырга тырышу сизелә иде. Бу алар шахмат уйнаганда аеруча күзгә ташлана иде. Җәмил бик озаклап уйлап кына йөри, Ибраһим аны ашыктыра:

–Йоклатасың бит инде, Җәмил,–ди. Җиңеп чыгучы көр итеп тамагын кырып куя, шаян сүз белән җиңелүчегә төрттереп ала. Җәмил дә үчен кайтара. Безгә килгәч, Ибраһимны алып бөтен өйне әйләнеп чыга: «Ник бу яндыргычның чыбыклары чыккан килеш тора? Хатыныңны ток сукканны көтәсеңме? Ник бу ишегең ябылмый? Ник пычагың үтмәс, ник, ник, ник?..» Ибраһимның кулыннан ватылганны төзәтү кебек эшләр килсә дә, өйдәге хәлләргә әлләни игътибар бирми иде шул.

Җәмил Гыйльманов сабыр, тыныч табигатьле, тирәнтен уйлап эш итә торган кеше иде. Андыйларны, ил агасы булырдай, диләр. Ибраһимның аны өлкә комитетының идеология секретаре итеп куясы килә иде. « Менә ул анда булса, кешеләрнең язмышлары гайбәт буенча түгел, гаделлек белән хәл ителер»,–дия иде. «Татарстан коммунисты» журналында редактор, Фәннәр академиясе филиалының тарих секторы мөдире сыйфатында да Җәмил Гыйльманов барлык хезмәткәрләренең эшен, тормышын уңайлату өчен кулыннан килгәнне эшләде.

Җәмил сәяси нисбәттән четерекле мәсьәләләрне хәл итүдән качмады, болай эшләнсә, өстәгеләргә ошамасын яхшы белгән хәлдә үз фикереннән чигенмәде, ил, халык тарихын бозмыйча, фәнни дөреслектә чагылдыру өчен күп көч куйды. Фәндә һәм сәясәттә иштирак итүенең башында да, соңыннан да ул шундый булып калды. «Коммунист Татарии» журналында баш мөхәррир чагында Ә. Борһановның җәнҗаллы мәкаләсен чыгарды. Анда автор Октябрь революциясенең җиңүендә эсерлар кебек вак буржуаз партияләрнең дә әһәмияте зур булды, дигән фикер үткәрә. Ә бу,–60 нчы елларда, эсерларны хыянәтче, сатлык дип сүккән заманда, гаять кыю фикер иде.

Татар мәдәнияте һәм әдәбияты мәсьәләләрен хәл иткәндә дә Җәмил кыю һәм батыр булды. Моңа Ибраһим белән аралашу, сөйләшү-бәхәсләшүләрнең дә йогынтысы булгандыр, дисәм, шаять, хата булмас. Чөнки Тукай, Әмирхан һәм, гомумән, XX йөз башы әдәбияты, мәдәнияте белән җенләнгән Ибраһим булган җирдә татар мәдәниятенең мөһим вакыйгалары һәм шәхесләре турында сүз чыкмый калмый. Ибраһимның мәсьәләне тирәнтен аңлап һәм белеп бәян итүе Җәмилнең дә ул чор турында хәбәрдарлыгын арттыргандыр, ул хәлләргә игътибарын юнәлткәндер.

Җәмил минем дә шәхсән дустым, ышанычлы кешем иде. Өйдә яки эштә нинди дә булса четерекле мәсьәлә буенча киңәш кирәккәндә, мин йә әнигә, йә Җәмилгә бара идем.

Бу әле Җәмил белән Ибраһим һаман бер-берсе белән килешеп, уйнап-көлеп кенә яшәделәр дигән сүз түгел. Әйттем инде, Җәмил—тарихчы, рәсми оешмада эшли,

димәк,–сәясәтче, рәсми хакимиятне яклый. Ул Сталиннан да баш тартмады, Хрущевны да яратты. Берчакны аңа нindидер конференциядәме, тарихчылар форумындамы Никита Сергеевичның үзен тыңларга туры килде. Шуннан инде ул аны аеруча мактый башлады. Ибраһим Хрущевның һәр эшен тәнкыйтьли, күп сөйләвен яратмый. Язучылар һәм әдәбият тормышына катыша башлагач, аеруча сөймәс булды. Берчак, Җәмилләргә куна килгәч, бәхәс шуңа барып җитте ки, төнге сәгать икедә Ибраһим мине пырылдатып алып чыгып китте. Торабыз тукталышта. «Йа–дим,–эш өчен бернинди әһәмияте булмаган бәхәс аркасында дустың белән аерылышасыңмы инде?» Үзенең дә эче поша. Кире борылып кердек. Җәмилләр дә бик борчылганнар иде, алар да шатланды.

Ибраһимның иң якын, көндәлек аралашып яшәгән дусты белән таныштырып һәм үзенең холкын аңларга ярдәм итә торган мисаллар белән мавыгып алгарак кереп киттем. Яңадан безнең тормыш итә башлаган чакка кайтыйк әле.

Ул чагында сабакташ дусларыбыз да күп: Фәния белән Рашат Гайнановлар, Наилә белән Зәет Мәҗитовлар, Алмазия белән Фазыл Фасеевлар, Сания белән Яхъя Халитовлар–безнең шикелле үк яшь гаиләләр. Бары Рәкыя белән Зыя Мансуровлар гына бераз өлкәнрәк. Атна саен диярлек кемдә дә булса җыелабыз. Мондый җыелулар балаларыбыз тугач та дәвам итте. Аптырап тормыйбыз, баланы юрганга төреп күтәрәбез дә китәбез. Ирләребез яңа язган әсәрләрен укыйлар, фикер алышалар, бәхәсләшәләр. Иркенчелек, тәнкыйтькә кем дә үпкәләми. Барыбыз да тигез, кеше бүлмәләрендә яшибез, ашаганыбыз ипи дә бәрәңге, бәйрәмнәрдә винегрет та селедка. Бер-беребездән көнләшү әле юк. Сүз–гаиләнең матди хәленнән яки кемнең дә булса дәрәҗәсеннән күпсенү турында. Соңрак нәкъ менә шушы нәрсәләр яшьтәшләр-сабакташлар арасын суытты, бөтенләй аермаса да, элекке ихласлык шактый кимеде.

Сабакташлардан тыш, бездә ул чакта Сафа Сабиров, Каюм абыйның дусты, әдәбият белгече Мөхәммәт ага Гали, Ибраһимның авылдашлары еш булды. Мәскәүдән кайтышлый Әдип Маликовның кунып чыкканы хәтеремдә Аның бик дулкынланган, хисләре ташыган чагы иде. Яраткан кызы Сажидә турында илһамланып Ибраһимга сөйләгәне истә калган.

Ибраһим кунаклар алып кайтырга бик ярата. Кунак килсә, өстәлгә шәраб кую тиешле санала башлаган чак. «Три семерки» дигән шәраб бик модада иде. Ибраһим берәрсен ияртеп кайтып керә, ә минем табынга куярга юньле нәрсә юк. Күршегә чыгып чабам, әҗәткә алып кибеттән ризыклар китерәм. Ә бит әҗәтне түләргә кирәк! Бер көнне Ибраһимга әйттем: «Син кеше ияртеп кайтып керсәң, мин чыгып китәм. Теләсәң ничек сыйла!» Шуннан соң беркадәр тыелды. Ә кунак чакыру гомер-гомергә аның иң яраткан эше булды. Дуслар белән дә, туганнар белән дә гәп корып утыру–аның өчен дөнья рәхәте. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Ибраһим минем туганнарымны үзенекеләр кебек үк якын күрде, яратты. Ә минем туганнарым күп. Без сигез бала идек. Аеруча ул минем әниемне хөрмәт итте. «Акыл иясе безнең әнкәй»,–дия иде.

Ниһаять, безнең беренче кызыбыз Гүзәл туды. Аны бала тудыру йортыннан алып кайткан көн Ибраһимның иң бәхетле көне булды. Ул аны бик көтеп алды. Еш кына: «Ник тумый инде?»–дип куя иде.

Ләкин без яшәгән шартларда бала үстерү җиңел булмады. Баланы коендырырга, чүпрәкләрен юып киптерергә кирәк. Ә өйдә бик салкын. Карлы-бозлы юлдан чиләк-коянтә белән су ташырга, ашарга әзерләргә, иртән баланы башта әниләргә илтергә, аннары эшкә чабарга кирәк. Кич мин баланы әниләрдән алып күтәреп кайтып керәм, көне буе өйдә эшләп утырган Ибраһим уку залына дип чыгып китә Аспирантураның өченче елы китте, диссертация яза. Соңыннан баланы яслегә биргәч, хәл тагын да кыенлашты. Бала бик еш авырый башлады, ә авыру баланы караган көннәр өчен больничный түләмиләр. Мин бик ябыктым...

Аспирантураны тәмамлаганда Ибраһимның диссертациясе әзер иде инде. 1954 елның 11 февралендә ул аны яклады. Һәм беренче зур хатаны шунда ясады. Диссертация яклагач, банкет үткәрмәде. Ул принципиаль рәвештә: «Ни өчен әле мин кемнәрнедер үземнең шатлыгымны уртаклашырга чакырырга тиеш?»–диде. Дөрес, без бик ярлы идек. Ибраһим ярты ставкада гына ассистент, хезмәт хакы 550 сум. Бүлмәбезгә аена 300 сум түлибез. (Без Каюм абыйлардан киткән идек инде.) Кечкенә балабыз бар. Ибраһимның әнисе бездә яши. Әмма банкетның гамәли әһәмиятен аңлаган булсам, ничек тә тырышкан һәм Ибраһимны күндергән булыр идем. Ибраһим үзе дә бу кыланышның нәтиҗәсе нинди буласын белмәгән. Якуп

ага Агишев соңыннан аңлаткан: «Галимнәр дөньясына яклау вакытында түгел, банкетта кирәләр». Хәзер һәркемгә мәгълүм хакыйкать безгә килеп җитмәгән шул. Ул чакта диссертацияләр яклау юк дәрәҗәсендә, татар теле һәм әдәбиятыннан профессорлар бөтенләй юк, кандидатлар да бармак белән генә санарлык.

Ә исталекле ул көндә 11 февральдә без Крайний урамындагы 7 нче йорт кухнясының ул чакта үзебез яшәгән, такта белән бүленеп алынган яртысында Җәмил Гыйльманов, чуаш егете Петр Константиновлар белән дүртәүләп, пилмән белән сыйланып бәйрәм иттек.

Ибраһимның кандидатлык диссертациясе «К вопросу о развитии идейно-эстетических и литературных взглядов Г. Тукая» дип атала иде һәм ул аны рус телендә язды.

Ул чакта тормышны чак кына җиңеләйтеп җибәргән нәрсә–Ибраһимның әдәбияттагы беренче уңышы булды. Мәгариф министрлыгы балалар өчен язылган хикәяләргә ябык конкурс уздырды. Ибраһимның балалар өчен язылган хикәяләре бар иде. Сюжетларны минем энеләрем һәм сеңелләрем бирәп торалар. Шунда Ибраһимның «Эш беткәч уйнарга ярый» исемле хикәясе беренче бүләккә лаек булды.

Аспирантураны тәмамлагач, Ибраһим татар теле һәм әдәбияты кафедрасында (ул чакта кафедралар бүленмәгән иде әле) ярты ставкада эшли башлады. Хезмәт юлы беренче адымнарыннан ук шактый катлаулы, авыр булды. Моңарчы ул университетның мактаулы, абруйлы студенты, башта Тукай, аннары Сталин исемендәге стипендиат, үз группасында укучыларның күбесеннән һәм белеме, һәм сәләте ягыннан бер башка өстен. Беренче курста укыганда ук университет студентларының фәнни хезмәтләре конкурсында диплом белән бүләкләнгән, «Совет әдәбияты» дигән калын журналда хикәяләре басылган, татар теле һәм әдәбияты бүлегенең җитәкчеләреннән дисәң дә була. Алар–Фазыл Фасеев, Рәшат Гайнанов, Әхәт Нигъмәтуллин, Әхмәт Юныс–бүлекнең иҗтимагый-сәяси яшәешенә тон бирәләр. Диссертациясен бик яраттылар, бертавыштан үткәрделәр. Үзенә ихтирам белән карауларына күнеккән. Аңарда бәлки бераз һавалану да булгандыр.

Студент чакта әдәби түгәрәкләр утырышларында берсен-берсе аямыйча тәнкыйтьлиләр, бәхәсләшәләр. Зур дөньяга, язучылар, галимнәр даирәсенә чыккач та ул шул гадәтне кугандыр. Хәер, принципиаль булу, иманы хакына туры сүз әйтүне ул намус бурычы санады, бу аның яшәү кагыйдәсе иде, гомере буе ул шундый булды. Мондый кешене беркайда да колач җәеп каршыламыйлар. Тәнкыйть конфет түгел.

Һәм менә ул–кафедрада укытучы. Ассистент кешегә артып калган, моңарчы хуҗасы булмаган фәннәрне тапшыралар. Аеруча ул вакыттагы татар бүлеге шартларында. Рабига апа вафат иде инде. Мөдир–Хатип Госман. Ибраһим Хатип Госман белән студент чакта ук нәзари теоретик семинарда бәхәсләшкән. Студент башы белән укытучыга (ул чакта Хатип Госман педагогия институтында эшли иде әле), танылган язучыга каршы чыгып бәхәсләшүе, хәтта өстен дә калуы, әлбәттә инде, ошамагандыр. Кыскасы, Хатип Госман Ибраһимны өнәмәде. Ибраһимга беренче елында ук борынгы әдәбият, халык авыз иҗаты кебек моңарчы аңа аз таныш курсларны бирделәр. Ул фәннәр буенча дәреслек түгел, хәтта программа да юк. Икесе бергә 70 сәгатьләп лекция.

1952 елда Ибраһим «Новый мир» журналында татар хикәяләре турында мәкалә чыгарды, шуны фәнни эш планының үтәлеше дип тәкъдим итте. Хатип Госман риза булмады, фәнни эш планын үтәмәгән И. Нуруллинны факультетның партбюросы утырышына куйды. Янәсе, акча өчен мәкалә язган. Мәскәүдәге иң дәрәҗәле калын журналда мәкалә чыгаруның әһәмиятен аңлаган партбюро әгъзалары Хатип Госман белән килешмәде, Ибраһимга шелтә белдермәде, фикер алышу белән чикләнде.

1955 елда безнең гаилә өчен гаять әһәмиятле һәм шатлыклы өч зур вакыйга булды: икенче кызыбыз Миләүшә туды, безгә бүлмә бирделәр (Язучылар берлегеннән) һәм Ибраһимның «Эш беткәч уйнарга ярый» исемле хикәяләр китапчыгы чыкты.

Язучылар берлегенә Ибраһимны 1953 елда кабул иттеләр. Аның «Рәхмәтулла абзый», «Ана хисләре», «Район үзәгендә» исемле хикәяләре 1944-45 елларда «Совет әдәбияты» журналында басылган, 1948 елдан башлап шул ук журналда дистәләрчә мәкалә-рецензияләре дөнья күргән. Язучылар берлегенә керүе аның тормышында иң каршылыксыз үткән беренче адым (икенчесе–диссертация яклавы). Ул үзе бик шатланды.

Яхшы, хуш. Фатир мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Сталинның, язучылардан калган фатирларны язучыларга гына бирергә дигән күрсәтмәсе бар иде. Хатип

Госманга Маяковский урамында яңа салынган йорттан фатир бирелгәч, аларның Лобачевский урамындагы бүлмәсен Язучылар берлеге Ибраһимга билгеләде. Без күченәсе көнне (ул вакытта без Кремлевский урамындагы барак сыман ярымподвал өйнең бер бүлмәсендә 250 сум түләп яши идек), мин яңа туган кызыбыз Миләүшәне күтәреп иртәдән үк Хатип абыйларга килеп утырдым. «Төрле хәл булуы мөмкин, балаңны алып кил»,–диделәр. Һәм бу бик акыллы киңәш булып чыкты. Чөнки безнең кулда әле ордер юк. Барлык җитәкчеләр Верховный Совет сессиясендә, ордерга кул куярга кеше юк. Берлекнең ул чактагы секретаре Газиз Иделле белән Ибраһим көн буе чаптылар, бары тик сәгать кичке бишләр тирәсендә генә кемнәрдер аркылы кул куйдырып, ордерны алып кайттылар.

Ул арада район Башкарма комитеты үзләрендә чиратта торган кешегә бу бүлмәгә ордер биргән. Алар кием шкафы һәм тагын нәрсәләрдер алып йорт алдына килеп басканнар. Мин Гүзәлне яследән алып кайтып ишекне ачкач, бәреп кермәкче булдылар, мин ишекнең ике ягына таянып аларны тоткарладым, ул арада бүлмәдәге берничә ир килеп тегеләрне кысрыклап чыгардылар. Шуннан алар, Хатип абыйлар әле күчеп китмәгән булсалар да, безне фатирга кертмиләр, дип милиция чакырганнар. Нәкъ Газиз Иделле белән Ибраһим кайткан чакка милиция килде. Милиция хезмәткәрләре Газиз Иделле белән бергәләп барып карасалар, тегеләрнең өстәлдә чәй табыннары да җыелмаган килеш тора икән.

Алай да алар китмиләр, көч белән кермәкчеләр. Шуннан Ибраһим бер төркем студентлар алып килде. Студентлар ике якка тезелеп бастылар. Бер ише безнең машинага төяп китергән әйберләребезне алып керә, икенчеләре шул машинага Хатип абыйныкыларныкын чыгарып төйи. Саташтырып берсе чыгарып куйганны икенчесе алып керүләр дә булгалады. Әмма без бүлмәгә кереп утырдык. Соңрак нинди зур фатирга күчсәк тә, ул бүлмәне алганда кичергән шатлык булмады. Үзе зур–20 квадрат метрлы, ишектән керүгә аш өстәленә барып төртелмисең, аңа кадәр әллә ничаклы барасың. Үзе биек. Түшәме 5 метр ярымда. Зур тәрәзә, балкон.

Хатип абыйларның бик зур–буе 2 метр, иңе 70-80 см.лы кием шкафы бар иде. Яңа фатирга сыймас, дип, аны безгә калдырып киттеләр. Икенче көнне Хатип абый шкафны алырга дип килде. Ләкин Ибраһим шул ук төнне аны икегә ярып китап шкафлары иткән иде инде. Чөнки шатлыктан төн буе йоклый алмаган идек. Шкафка эләрлек әлләни киемнәребез юк, ә китапларны урнаштырырга кирәк.

Бу бүлмәдә яшәгәндә тормыш вакыйгаларга бай булды. Болар үзләре дә СССРда зур үзгәрешләр барган еллар. XX нче съезд, Сталинның шәхес культын фаш итү, Дудинцевның «Не хлебом единым» әсәрен йотылып укыган чаклар. Шушы бүлмәдә яшәгәндә безгә Себердән, «Сталин санаториеннан» Мәҗит Рәфыйков кайтып төште. Ябык, авызын ачса, үпкәсе күренә. Бездә ул күпме яшәгәндер, бер аймы, икеме. Шул тирә Ибраһим аңа Язучылар берлеге аша ниндидер тәрҗемә (Горький әсәрләрен бугай) табып бирде. Ул көндез китапханәдә эшләп утыра, кичләрен Ибраһим белән шахмат уйныйлар. Мәҗитне университетта укыганда кулга алган иделәр. Ибраһим «Мәҗитнең башы ник Себер китте» дигән парчасында ул тарихны язган иде. Мәҗит эше буенча Ибраһимны Черек күлгә чакыргач, ул: «Юк, Рәфыйков дошман түгел, кимчелекләргә эче пошып кына сөйли»,–дигән һәм үзенең фикерен протоколга үз кулы белән язып куйган. Мәҗит ул язуны үзе дә укыган, шуңа күрә якын дусты итеп безгә кайткан. Чыннан да, ул вакытта шаһит итеп чакырылучылар арасында тагын кем шундый егетлекне эшли алды икән.

Мәҗит белән Ибраһимның дуслыклары гомер буена барды. Аларның туган көннәре дә бер-бер артлы: Мәҗит 17 апрельдә туган, Ибраһим–18ендә. Шуңа күрә озак еллар буе икесенең бәйрәмен бер итеп бездә үткәрә идек. Бу гадәт Мәҗит буйдак чаклардан башланды.

Бу бүлмәдә яшәгәндә безгә Уфадан Хәсән Сарьян килеп төште. Хәтеремдә, аны каршыларга төшкән Ибраһим вагондагы урын-җирләре һәм эчкән чәйләре өчен дә түләп алып менгән иде. Ул да берничә атна яшәде кебек. Фатирга күчкәч тә гаиләсен Уфадан алып килгәнче еш килә иде, кунып та кала иде. Кешеләр арасында чиста мөнәсәбәтләр булуын аңлый алмый торган вак җаннарның гайбәте араны бозды.

Ибраһим кулыннан килгәнчә кешеләргә ярдәм итәргә ярата, шуннан рәхәтлек таба иде. Авылда укыткан чакта алып барылган көндәлегендә шулай дип язылган да: «Их, рәхәт тә соң кешеләргә ярдәм итү». Зәет Мәҗитовка озак кына өлкән укытучы вазифасын бирми тордылар. Ике бала булгач та, фатир ала алмыйча, тулай торакның

бер бүлмәсендә яшәп интектеләр. Ибраһим ике очракта да ректорга кереп хәлне аңлатып ярдәм итте. Хәтта Җәмил Гыйльмановка да булышты әле ул. Гәрчә Җәмил сәяси-иҗтимагый мәгънәсендә Ибраһимнан абруйлырак та булгандыр. Алар уллары өйләнеп оныклары тугач та ике бүлмәле хрущевкада озак яшәделәр. Җәмил үзе өчен тырыша торган кеше түгел иде. Фәннәр академиясенең Казан филиалында сектор мөдире үзе. Хезмәттәшләре үгетли торгач, фатир сорады һәм аңа Икенче Горкидан фатир бирделәр. Үзенең аягы авыртуга, хатыны Мәрьям йөрәк авырулы булуга карамастан, ул риза булды. Китте Ибраһим шәһәр Башкарма комитетына. Аңлатты, сөйләде. Һәм аларга Татарстан урамыннан торак бирделәр.

Ибраһим тормышның базарга, кибеткә керосинга бару кебек чүп-чараманына катнашмаса да, «глобаль» эшләрне, миңа әйтмичә, сюрприз итеп үзе башкара иде. Шулай ул телефон куйдырды, телевизор алды. Телевизор әле бик азларда гына. Кичен барлык күрше балалары (коммуналкада биш гаилә яшибез) безгә кереп идәнгә тезелешеп утыралар, иртәгесен ата-аналары зарлана, суык тидергәннәр. Безнең бүлмә бик салкын була иде шул.

Ятыш-торыш байларча, өстә-башта югарак, дигәндәй, шул бүлмәдә торганда Ибраһим пианино алды. Янәсе, без балаларны заманча тәрбиялибез, мәдәниленнең үзебез ала алмаган билгеләрен аларда булдырабыз. Көйгә-моңга сәләтләре булса да, озак укымадылар, 4-5 сыйныфны гына тәмамладылар. Музыка мәктәбенә балаларны әби-бабалары житәкләп йөртә. Ә бездә андый мөмкинлек юк. Гүзәл Гоголь урамындагы балалар бакчасыннан Горький урамындагы 1 нче музыка мәктәбенә үзе генә барып йөрде. Сәләтләре бар иде, тырышлыклары җитмәде. Ә башлангыч музыкаль белемнең зыяны тимәде. Үзләре хәзер канәгатьләр.

Безнең бу елларда чагыштырмача тернәкләнеп китүебезнең сәбәбе–Ибраһимның «Аның йолдызы» исемле пьесасының академия театрына кабул ителүе, «Тукай Петербургта» пьесасының «Совет әдәбияты» журналында чыгуы. «Аның йолдызы» пьесасын ул 1955 елда беренче тапкыр Гаграга Иҗат йортына баргач язды. Моны искә алуым шуның өчен–ул анда үзбәк язучысы, соңыннан Үзбәкстан компартиясе Үзәк комитетының беренче секретаре булган язучы Рәшит Рәшидов, Рәсүл Гамзатовлар белән таныша. Икенче елны Переделкинода, «Тукай Петербургта» пьесасын язганда, төрек язучысы Назим Хикмәт белән танышып, якыннан аралаша, аларның бергәләп төшкән фотолары да бар.

* * *

*Без язмышка үпкә белдермибез.*

Н. Дәүли

Ибраһим өчен 1955–1962 еллар арасы иҗади шатлык-омтылышлар белән бергә икеләнүләр, эзләнүләр чоры булды. Нәфис иҗат һәм фән арасында калып, кайсысына өстенлек бирергә икәнен аныклый алмый изаланды. 1961 елда ул бер елга түләүсез отпуск та алып карады. Сугыш инвалиды буларак 43 сум пенсиясе бар иде, мин «Ялкын»да эшли идем, анда хезмәт хакы да зуррак, гонорары да күбрәк, артык аптырамадык үзе.

Ибраһимның җаны әдәби әсәрләр язу ягында. Пьесалары өстенә ул Тукай турында хикәяләр циклын башлап җибәрде. «Язгы үрләр» исемле повесть өстендә эшләде. Тик бу өлкәдә уңышсызлыклар еш кабатлана башлады. «Аның йолдызы»н Галиәсгар Камал исемендәге академия театры кабул итте–куелмады. Аны сәхнәләштерергә тиешле режиссер Ширияздан ага Сарымсаков театрдан китәргә мәҗбүр булды. Ә Ибраһимның әсәре халык театрында гына куелды. Урицкий исемендәге клубта куелганда тамашачы күп җыелган иде үзе.

«Тукай Петербургта» пьесасы рус телендә телевизион спектакль рәвешендә телевидениядән күрсәтелде. Ул вакытта тапшырулар бары тик турыдан-туры гына алып барыла иде. Тукай ролен күренекле артист Провоторов уйнады. Ул гәүдәсе, кыяфәте белән Тукайга бер дә охшамаган булса да, шагыйрьнең холкын, кичерешләрен тулы аңлап башкарды һәм без аны Габдулла Тукай дип кабул иттек.

«Тукай Петербургта» пьесасын университетның драма түгәрәге дә әзерләде һәм аны академия театрының ул чактагы бинасында күрсәтте. Хәтеремдә, Гатаулла Баязитов ролен бугай–Миркасыйм Госманов, Джаконданы–Кояш Тимбикова, Тукайны Рим Кәримов уйнаганнар иде.

Хезмәт өлкәсендә икеләнүләр фән файдасына тәмамланды. Гыйльми хезмәткә

өстенлек бирү тормыш шартлары белән тәгаенләнде, вакыйгалар куерышы шул юлны сайларга мәҗбүр итте. 1960 елда язучылар өчен махсус йорт салдылар. Ибраһим шуннан фатир сорады. Сугыштан аяксыз кайткан кеше, ә йорт университетка да, берлеккә дә якын урнашкан, Горький урамының Татарстанга чыга торган чатында. Ул вакытта берлек рәисе Афзал Шамов иде. Берлек фатир бирергә риза булмагач, Ибраһим партия шәһәр комитетына мөрәҗәгать итте, аннан Нуруллинга фатир бирүне таләп иттеләр. Фатирны Ибраһимга ул йорттан түгел, Зәки Нуридан бушаганны, Ленин районыннан бирделәр.

Язучылар берлеге каршысында аның хәлен катлауландырган тагын бер вакыйга булды. Алтмышынчы елларда Сталинның шәхес культын фашлау нәтиҗәсендә туган фикер иркенлеге безнең әдәбиятта, минем күзәтүләрем буенча, Равил Фәйзуллин кебек яшьләр иҗатында нәфис әдәбиятны, аеруча шигъриятне, яңа баскычка күтәрсә, «Рәшә», «Ике буйдак», «Язгы авазлар», «Саз чәчәге» кебек укучыны уйландыра торган, чын мәгънәсендә нәфислек белән язылган әсәрләр туса да, теге яки бу әдәби күренешкә бирелә торган бәһаләр нисбәтеннән әллә ни зур үзгәрешләр күзәтелмәде, идеологик дилбегә фикерләрне нык тезгенләп тотты. Ибраһимның ачы тәҗрибәсе шуны күрсәтә

1937 елда нахакка Себергә куылганнардан Галимҗан Нигъмәти aклангач, исеме халыкка кайтарылгач, аның әсәрләренең җыентыгын төзүне Ибраһимга тапшырдылар. Ул үзенә хас таләпчәнлек һәм тырышлык белән аның әдәбитәнкыйди, тарихи мәкаләләрен җыйды, искәрмәләр эшләде. Ибраһимның фикеренчә, Г. Нигъмәтинең иң көчле мәкаләләре Г. Тукай иҗатына багышланган. Г. Нигъмәти иҗат иткән 20-30 елларда әдәбият белемендә вульгар-социологизм методы хөкем сөргән. Шул метод белән эш иткән галим Тукайны вак буржуа шагыйре дип саный. Чөнки Тукай авыл халкы, крестьяннар турында яза, ә крестьяннар вак буржуа катламына карый. Татарстан китап нәшриятының җитәкчелеге Нигъмәти мәкаләләренең ул урыннарын сызып, кыскартып чыгару ягында. Ибраһим моның белән килешми: беренчедән, китап, башлыча, галимнәргә һәм укытучыларга, әдәбият тарихы белән кызыксынучыларга юллана, тиешле аңлатмалар бирелгәч, мәсьәләне дөрес аңларлар, икенчедән, мондый җыентык тагын кайчан чыга әле. Мәсьәлә партия өлкә комитетында каралды. Нәшрият һәм Язучылар берлеге җитәкчелегенә берүзе каршы торган Ибраһим җиңелде, җыентыкны төзүдән баш тартты, искәрмәләрен бирмәде. Шуннан соң 8 ел буе нәшрият Ибраһимның китапларын чыгармады.

Ибраһим журналда чыккан хикәяләрен җыеп, 1960 елда нәшриятка тапшырды. Эчке рецензияләрне Ибраһим Гази белән Гази Кашшаф язганнар, уңай бәяләгәннәр, чыгарырга тәкъдим иткәннәр. 1961 елның 25 гыйнварында нәшриятның художество советында аны чыгару мәсьәләсен карыйлар һәм 10 мартында Ибраһим түбәндәге җавапны ала: чыгыш ясаучылар «тупланган хикәяләрдә заман темасы, бүгенге зур эшләр белән тулы тормыш сулышының сизелмәвен, авторның актуаль мәсьәләләрдән читтә торуын әйттеләр».

Китабы кире кагылу, пьесасы кабул ителеп тә куелмый калу, фатир һәм Г. Нигъмәти унаеннан килеп чыккан тәмсезләнү Ибраһимның рухын төшерде, шул ук вакытта барасы юлы турында ныклап уйланырга мәҗбүр итте. Профессиональ әдип булып яшәү мөмкин түгел.

Шулай итеп, Ибраһим фән юлын сайлады. Тукай турында зур әсәр язу хыялы да аның күңелен фәнни эшкә бәйли. Тукай яшәгән заманның эченә керү, аның рухын тоеп тәмаман күзаллау өчен, бөек шагыйрьнең үз тормышын өйрәнү белән бергә аның янәшәсендә яшәгәннәрне дә аерым алганда Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Рәмиев, ул чагында кычкырып әйтергә ярамаса да, Гаяз Исхакый кебек бөек шәхесләр белән мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен, аларның көнкүрештә һәм иҗатта чагылуларын белергә кирәк. Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырган экспедициягә ияреп 1959 елда Тукайның туган якларында йөреп, шагыйрьне азмыкүпме белгән, аның турында ишеткән кешеләр белән очрашып, истәлекләрен язып алып кайтты, ул якларның үткәнен һәм бүгенгесен күзәтеп очерк язды.

Тукай яшәгән заманның сулышын тою өчен Ибраһим күп вакытын архивта үткәрде. Татар крестьяннарына, зыялыларына, мәктәп-мәдрәсәләренә карата алып барылган суд материалларын өйрәнде. Рус һәм башка халыкларның атаклы кешеләре турында язылган әсәрләрне укыды. Аеруча аңа Ю. Тыняновның «Кюхля», А. Моруаның Бальзак турындагы «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан әсәре ошый иде.

Шулай итеп, алтмышынчы еллар уртасында ике юл чатында торганда Ибраһимның тәҗрибә биштәрендә нәфис әдәбиятка нисбәтән байлыгы—«Эштән соң уйнарга ярый» китапчыгы, ике пьесасы, Тукай турында берничә хикәясе, дистәгә якын сатирик һәм башка хикәяләре, «Совет әдәбияты»нда һәм үзәк журналларда басылган зур һәм җитди мәсьәләләр күтәргән унбишләп мәкаләсе, газеталарда чыккан берничә дистә эреле-ваклы язмалары бар иде. «Комедия көлке капчыгы түгел», «Тормышчан сюжетны яклап» кебек киң нәзари (теоретик) карашларга нигезләп язылган мәкаләләре редакция биштәрендә. Боларны нәфис әдәбият белән гыйльми эзләнү өлкәләрен берләштерүче дип карарга мөмкин.

Шулай да, профессиональ язучы булып яшәргә мөмкинлеге юк. Университетта эшләү фәнни-тикшеренү алып баруны таләп итә. Ул якта—«Тукай эстетикасы» китабы, үзе укый торган курслар буенча берничә программа, ел саен фәнни йомгаклау конференцияләрендә ясала торган докладлар.

Ул елларда татар әдәбияты тарихы буенча бер доктор—Мөхәммәт ага Гайнуллин гына булгандыр, мөгаен. Хатип Госман әле якламаган, Гали Халит Ибраһимнан соң яклады. Докторлыкка омтылу, профессор булу буй җитмәслек зур эш булып тоела иде. Ибраһимның докторлык диссертациясенең темасы укыту барышында, лекцияләр курсының нәзари (теоретик) концепциясен эшләү процессында туды. Үзе шәйләгән закончалыкның башка төрки әдәбиятларга, аеруча әзәрбәйҗан, үзбәк, казакъ әдәбиятларына да хас икәнен ачыклау аны бурычының колачлы һәм әһәмиятле булуына инандырды.

Ул бик таләпчән укытучы иде. Яшьләрдә ул фикерләү куәсен үстерү өчен тырышты. Аңа имтиханны бер керүдән генә тапшыра алмаучылар еш булды. Аеруча читтән торып укучылар арасында. Укытучының ниндилеге турында хәбәр студентларда буыннан-буынга күчә. Кайберәүләр аңардан куркып бөтен китапны күңелдән ятлап киләләр. Моңа аның җене чыга. Укытучы буласы кеше бит яки инде укыта да торгандыр, аңлап сөйләсен, мәсьәләнең асылына төшенсен.

Апастамы, Балтачтамы командировкада вакытта минем ирем Нуруллин икәнне белгәч, бер хатын исе китеп: «Ничек торасыз аның белән, бик усал кеше бит ул?»—дигән иде. Юк, Ибраһим усал түгел, таләпчән иде. Ә өйдә ул минем эшемә катышмый. Ашау-эчү, кием-салым, өй җиһазларын һәммәсен үзем алам.

Ул елына бер көнне генә аш-су тирәсендә кайнаша—8 Март көнне. Иртүк тора, табын әзерли, аннары балаларны уята, өчәүләп тезелеп туш көйләп минем янга киләләр, чәчәкләр, балалар үзләре ясаган рәсемнәрен, кәгазь кәрзингә тутырып «5», «4»ле билгеләрен бүләк итәләр. Елның өч көнендә—8 Мартта һәм 5 майда (Матбугат көнендә), минем туган көнемдә Ибраһим миңа чәчәк бүләк итми калмый иде. Хәтта инде параличланып үзе йөри алмый башлагач, гомеренең соңгы елларында да. 1993 елның 5 маенда без Сосновый Бор дигән шифаханәдә идек. Шунда да ул, горничный хатыннан үтенеп, кар бетүгә баш калкыта торган вак кына зәңгәр умырзая чәчәкләре китергән иде. Соңгы маенда чәчәк юнәтә алмагач, яшел яфраклы бәйләм бүләк итте.

* * *

*Дошманнардан үзем сакланырмын,*
*Дусларымнан Ходай сакласын.*

Халык мәкале

Ибраһим белән Хатип Госманиның мөнәсәбәтләре вакыт-вакыт шактый киеренке булса да, А. Яхин кафедрага мөдирлеккә килгәнче, ямьсез төс алмады. Төп бәхәс кафедрада фәнни эшнең юналеше хакында барды. Хатыйп Госман борынгы әдәбият белән мавыга, борынгы текстларны табу, эшкәртү белән шөгыльләнә. Ибраһим фикеренчә, бу Фәннәр академиясе хезмәткәрләре эше, ә вузда укытучылар дәреслекләр һәм башка уку әсбаплары язарга тиеш. 1977 елда «Советская Татария» газетасында (27 май саны) «Кто напишет учебник» дигән корреспонденциясе дә басылды. Сүз уңаеннан, ул язмага күп хатлар килде, рус кешеләре язды: нигә кирәк ул үлеп бара торган халыкка дәреслек, русча укысыннар!

Дәүләт нәшрияты китапларымны чыгармый, дип, Ибраһим кул кушырып утырмады, университет нәшриятында, офсетта фәнни хезмәтләре дөнья күрде. Ике кисәктән торган «XX йөз башы татар әдәбияты тарихы буенча лекцияләр курсы»

(1962–1964), «Шәриф Камал иҗаты» (1963), «Тукай иҗаты» (1964) һәм ул вакытта факультетта вакыйга тудырганы—20 табаклык «Егерменче йөз башы татар әдәбияты» (1966). Иң җимешле елы—1964. Ул елны аның өч китабы дөнья күрә. Алда әйтелгәннәрдән тыш, ниһаять, 40 яшьлеге уңаеннан, нәшрият Ибраһимның «Образлар дөньясында» исемле мәкаләләр җыентыгын чыгарды.

Ибраһим күп эшләде, бик күп эшләде. Көн саен иртән алтыда йә алтынчы яртыда ук тора, кием шкафы түбәсенә асылына-асылына гимнастика ясый, салкын су белән коена. Аннары алма бәлешедер, ешрак, әлбәттә, печенье сыман нәрсәләр белән куе итеп чәй эчә. Эшкә утыра. Сәгать тугызга кадәр кузгалмый эшли. Бу гадәте ялда Иҗат йортларында да үзгәрми. Лекциягә барасы булмаса, иртәнге аштан соң да төшкә кадәр өстәл янында. Төшке аштан соң бераз йоклап ала да дөньяга, кеше арасына чыгып китә. Күрәсе кешеләрен күрә, Матбугат йортында шахмат уйный. Күбрәк «Чаян» йә «Казан утлары» редакциясендә уйныйлар.

Күп эшләве, студентлар өчен кулланма әсбаплар язуы Хатип Госманда Ибраһимга галим буларак ышаныч һәм хәтта беркадәр ихтирам да уятты бугай. Ул аның университет басмаханәсендә китаплар чыгаруына комачауламады, нахак бәла якмады. Бервакыт мин дә офсетханәдә татар журналистикасы буенча әсбап чыгармакчы идем. Менә берзаман әйтәләр: «Х. Госман чылтыратып: «Тизрәк чыгарыгыз»,—дип, үзәккә үтте, ә хәзер килеп алмыйсыз». Ник Хатип абый минем әсбап өчен тырыша икән, дип аптырасам, Ибраһимның да шунда бер язмасы ята икән, ул шуның турында кайгырта икән. Нуруллин белән Нуруллинаны буташтырганнан. Кафедра мөдирен гаять бизи торган сыйфат бу.

Хатип абый Ибраһимны кеше буларак өнәп бетермәсә дә («Киребеткән, ничек торасың шуның белән?»—дигәне бар), ул аның фәнни казанышларын инкарь итмәде, комачауламады. Бу Ибраһим докторлык диссертациясе яклаганда бик ачык күренде. Ләкин әле докторлык диссертациясен яклауга барып җитәсе бар.

Бик озак роман күрми торган татар әдәбиятында илленче еллар башында Кави Нәҗми белән Гомәр Бәшировның романнары чыккач, алар хөкүмәт һәм укучылар тарафыннан бик югары бәяләнгәч, елга ерылды. Бер-бер артлы калын-калын романнар чыга башлады, повестьлар күбәйде. Ибраһим көндәлек әдәбият һәм тәнкыйть белән даими танышып бара иде. «Казан утлары», «Вопросы литературы», «Дружба народов» журналларын бер дә калдырмый укый. Әсәрләрне укыган саен бер нәрсә өчен пошыра—озын язылa, мәгънә ягы саерак. Шуның сәбәпләрен эзли торгач, «Кыскалык турында» дигән мәкалә язды. Ул мәкаләнең язмышы турында уйлаганда, Нәби Дәүли сүзләре искә килә. Ул, «Мин җирдә калам» китабын бүләк итеп, түбәндәге сүзләрне язган: «Дустым Ибраһим Нуруллинга. Сугышта давыл аша юл яручыга. Тормышта таяк белән дә тугры баручыга».

Алтмышынчы елларда Ибраһим «яшь галим», «яшь язучы» чикләрен үтеп, олылар дөньясына керде. Яшәү рәвешебез дә беркадәр үзгәрде. Әмма ял рәвешебез яшьләрчә калды. Мәҗлесләрдә «Без яшь әле, яшьлек өчен күтәрик бокалларны» дип җырлыйбыз. Яшь ич әле без. Ибраһимга кырык юк, миңа утыз тулып кына киткән. Балаларыбыз мәктәптә генә укыйлар.

Безнең күз алдында Идел киңәеп, Казансу елгасы Кремль янына ук килеп җитте. Төшке аш вакытында Матбугат йорты янында гына туктаган троллейбуска утырып барып, су кереп киләбез. Идел үзенә дәшә. Менә без Җәмилләр белән уртагыннан катер сатып алдык. Машинаныкын икегә кисеп ясалган ике цилиндрлы стационар моторлы. Балалар, дуслар белән Казансу өстендә җилдерәбез генә.

Ел саен ял вакытында кая да булса барырга тырышабыз. 1959 елда балалар белән пароходта Уфага сәфәр кылдык. Анда Нәҗип Әсәнбаевларда булганыбыз, Зариф Бәшири белән очрашканыбыз хәтеремдә. Зариф Бәширинең котылып кайткан еллары иде. Исәлекләрен яза икән. Ибраһим белән Тукай турында озаклап сөйләшеп утырды.

Алтмышынчы елда шикелле, без Зәет Мәҗитовлар белән ике гаилә булып, отпуск вакытында Иделдәге Алтын атау дигән атауга чыктык. Утрау бик кечкенә, бездән башка һичкем юк. Көндезләрен балыкчылар гына тукталып китә. Аларда ике малай, бездә ике кыз. Палаткалар кордык. Без, ваемсызлар, аны-моны уйламадык. Зәет акыллырак булды. Аның ау мылтыгы бар икән, шуны алган, Җәмилләрнең Белка исемле этләрен дә алырга күндерде. Төнгә ул янына мылтыгын куеп ята, ә безнең аяк очына балта сала. Ибраһим сыңар аяк белән торып балтаны кулга алганчы, буласы эш була инде үзе. Тик балта шулай да тынычлык бирә. Ялыбыз хәвеф-хәтәрсез үтте.

Кичләрен учак ягып, Идел ярында утырабыз. Көн буе өзлексез искән җил кичен тына. Тулган айның шәүләсе Идел өстенә көмеш юл суза, без йә җырлашып, йә сөйләшеп рәхәт гизәбез. Күңел тыныч, яшәү ямьле.

Ибраһим бик еш Казанга кита Шәһәр Башкарма комитетына фатир артыннан йөри. Менә иртәгә кил, менә берсекөнгә кил, дип йөртәләр дә йөртәләр. Берчакны мин барган идем, иртәгә ордер алырга килегез, диделәр. Барып карадык фатирны. Үзе биек, үзе зур. Коридорыннан ат җигеп үтәрлек. Беренче кат. Без беренче катта яшәүне начар дип белми идек. Хәер, хәзер дә, кырык ел яшәгәннән соң да, мин аның начарлыгын күрмим.

Фатир алганда да, хәтта литфондтан Иҗат йортына юллама алганда да, шифаханәләрдә дәвалану вакытларында да Ибраһимның сугыш инвалиды булуы зур ярдәм итте.

Алтмыш дүртенче елда сугыш инвалидларына ярты хакына «Запорожец» машинасы сата башладылар. Соңыннан аны бөтенләй бушка бирәләр иде. Сигез йөз сумга машинаны алдык та, обкатка үтмәвен дә исәпләп тормыйча, Ибраһимның энесе Наил яшәгән Салагыш авылына киттек. Исәбебез—алар белән бергә Кама буенда чатыр корып яшәү. Күңелле яшәдек. Тирәякта беркем юк. Су коенабыз, кояшта кызынабыз. Кама өстенә карап утырабыз, кәрт сугабыз. Гүзәл белән Миләүшә күбәләк, кырмыска кебек бөҗәкләрне күзәтәләр, су буенда комнан сарайлар салалар. Кичләрен учак ягабыз. Дөнья борчуларын онытып, рәхәт диңгезендә йөзәбез. Аш-су учак өстендә әзерләнә Киленебез Мәрвәнең әнисе Зәйнәп кодагый мич ашлары, бавырсак пешереп китергәли. Ибраһим белән Наил кармак салалар. Кайчакта берничә балык та эләгә Ибраһим гомер буе балыкка йөреп тә ун-унбиш балык тотты микән. Хәер, берчакны минем энем Булатка ияреп чыгып, тирәннән ала торган кармак белән беләк буе өч корбан алып кайткан иде.

Аннан Барҗыга Юныс Әминевләргә барулар, алар белән якындагы күлдән кәрәкә сөзеп уха пешерүләр, аларда кунак булулар, сөйләшү-көлешүләр матур төш кебек кена Юныс аганың хатыны сөйләгән бер көлке истә калган. Юныс ага берчак хатыны янында: «Карчык, бәрәңге алып менимме?»—дип сырпалана башлый. Бер шулай, ике, өч... Хатыны гаҗәпсенеп һәм нәрсәдер сизенеп, базга төшеп караса, бәрәңге арасына аракы шешәсе яшереп куелган икән.

Кайтыр юлга чыктык. Салагыштан күпме генә киткәнбездер, машинабыз бармый башлады. Авыл шоферлары машиналарны бик яхшы беләләр. Кардан валының ниндидер шөребе төшеп калган икән, рәтләп җибәрделәр. Инде кайтып җитәбез дигәндә—тагын бәла—генератор моторга энергия бирми. Тагын—бәхет. Авылга ерак калмаган, аккумулятор хисабына барып җиттек. Шоферлар кирәкле подшипникларны табып төзәттеләр, кемнәрдер безне өйләренә чакырып чәй куеп сыйладылар. Нинди күркәм заманнар булган. Ул елларда авыл халкы гаять мәрхәмәтле һәм мәнле иде.

Ибраһим, башы төрле уйлар белән тулгангамы, бик таркау, онытучан иде. Өйдә һәм барган җирләребездә аның таягын, күзлеген эзләп үткәргән вакытны җыйсаң, ничә көннәр җыелыр иде икән? Төрле җирләрдә ул калдырган таякларны, папкаларны, каләмнәрне, машина көпчәгенә һава өрдергәндә кырыена куеп, шуннан кияргә онытып таптанып ваткан күзлекләрне җыеп өйсәң, бер йөк машинасы булыр. Машинаны гараждан чыгаргач, капкаларын шар ачык килеш калдырып китүләр, вакытында карамыйча төрле детальләрен югалтып юлда туктап калулар. Берчакны машинасының картерыннан маен алыштырам дип агызып бетереп, яңасын салырга онытып китеп көн буе йөреп кайткан. Җәмил әйтәдер иде: «Ибраһим кулында да йөргәч, бу «Запорожец» бик яхшы машинадыр?»—ди иде.

*Ахыры киләсе санда*

*Мөдәррис Вәлиевкә 50 яшь*

# САГЫНАМ. РӘХМӘТ УКЫЙМ

*Гомеремнең күбрәк өлешен туган туфрактан, туганнардан аерылып яшәргә туры килгәнлектән, күңелемә сагыну хисе иртәрәк оя коргандыр кебек.*

*Мин әле дә сагынып яшим: балачагымның моңсу рәхәтен һәм авылымның якты күңелле кешеләрен; мәктәп елларын һәм студент хөрриятен; хезмәт һәм иҗат юлындагы кыен да, бәхетле дә мизгелләрне...*

*Кемгә ничек туры киләдер, ә миңа гомер юлымда гел генә мәрхәмәтле кешеләр очрады. Кардәшләрем һәм авылдашларым, сабакташларым һәм остазларым... Яраткан кешеләрем һәм фикердәшләрем... Кайда гына эшләсәм дә, хезмәттәшләремнән һәм җитәкчеләремнән уңдым. Һәммәсенең исемнәрен атау өчен, мөгаен, журнал битләре җитмәс иде. Фани дөньядан киткәннәренең урыны җәннәттә булсын, исәннәрнең изгелегенә игелекле гамәл белән җавап кайтарып өлгерергә язсын, дим.*

*Борынгы хатлар шәкелендә, «һичберсен аермаенча» рәхмәт укыйм һәм бу язмаларны шул яд итүнең бер рәвеше булыр дип уйлыйм.*

Мөдәррис ВӘЛИЕВ

## Тирәнлекне тою

Иҗатта тирәнлекне тою да җиңел түгел, һәм ул сыйфат һәркемгә тәтемәгән. Тоя белү—талант, бәхет; тоя белмәү—бәла, бәхетсезлек.

Салих Маннапов—бәхетле тәнкыйтьче. Татарстан китап нәшриятында чыккан китабының исеме генә дә автор уй-фикерләренең шигъри булачагын әйтеп тора: «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя». Үзе үк шигъри юлга өнди, һәм, сизмәстән, кафияләп дәвам итәсең: «Шуңа имән яфракларын соңлап коя».

Китапның тәүге юлына игътибар итик: «Яңа яуган кардан алмагөл исе килә». Нинди шигъри киная соң бу? Бу сорауга мәкаләгә эпиграф итеп алынган «әнием сүзе» җавап бирә: «Балачакка кайту кешенең гомерен озайта». Димәк, кеше бөтен гомере буе балачагыннан, яшьлек елларыннан аерыла алмый—гомер карлары яуганда да чәчәк исе аңкый.

Өлкән язучыларның автобиографик әсәрләреннән дә (аларны С. Маннапов Әмирхан ага Еникинең «Соңгы китап» исеме берләштерә дип әйтү ягында), Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә»сеннән дә, Аяз Гыйләҗевнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт» һәм «Язгы кәрваннар»ыннан да шушы алмагөл исен тоя, хәтта «балалар өчен» дип мөһер сукмаган китапларга да (Н. Фәттах—«Сызгыра торган уклар») «бала йөгереп керә», ди автор. Бу күзәтүләр, ничектер, нечкә күңел җепләре аша бер-берсенә килеп бәйләнә һәм мәкалә мәкалә генә булып калмый, ул лирика белән сугарылган бер хикәяне хәтерләтә, дияр идем.

«Тәллитут» дигән сәер исемле мәкалә дә язылышы белән шундый ук тәэсир калдыра, ул да балачакка һәм туган туфракка бәйле. «Туган туфракка сабый чакта җибәргән тамырлар гына кешене ватанлы итә, хәтерле итә—бәхетле итә». Табигать сурәтләренең мифлардан, җыр-бәетләрдән тәрәзә йөзлекләренә, кульъяулык читләренә «килеп кунганын» күрә белү өчен, йә булмаса киселгән агач төбендәге сырларны патефон тәлинкәсенә охшатып, анда нинди көй язылырга мөмкинлеге хакында уйланыр өчен, Ходай тарафыннан бирелгән үтә сизгер күңел кирәктер.

С. Маннапов үзенең фикер йөртүләрендә татар язучыларының әсәрләре белән чикләнми, аның әдәбият мәйданы киң, аңа рус язучысы Виктор Астафьев

та, кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов та, башкорт шагыйре Мостай Кәрим дә рухи азык бирә, әмма «шүрәле каргаган» киләчәксез авыллар, киләчәксез телләр хакында пошынганда, исемсез елгалар хакында уйланганда үз җиренә кайта, хәтта күңеленнән Болгар илләренә сәяхәт кыла.

Китапта язучыларның, шагыйрьләрнең иҗади портретларына байтак урын бирелгән. С. Маннапов һәр язучының, шәхеснең үзенә генә хас сыйфатын, характерын, иҗади үзенчәлеген оста тотып ала. Һәр язучыны, шагыйрьне иҗатлары белән бер-берсен бутарга мөмкин булмаган шикелле, тасвирлау чараларын да бутарга мөмкин түгел. Һәрберсенә берәр шигъри образ, штрих таба.

Мәсәлән, мин Хәсән ага Туфанның иҗатын һәм тормышын энәсеннән җебенә кадәр беләмдер, дип уйлый идем. Чыннан да, аның шигырьләре юлы юлга укылган, чирек гасыр чамасы аралашып яшәлде, бер бүлмәдә төннәр буе йокламый сөйләшеп чыккан чаклар булды; аның, С. Маннапов язганча, киеренке кичерешләр шагыйре, җил-давыллар очрашудан туган нык җегәрле уйлар шагыйре икәнен дә белдем төсле, әмма Туфан аганың «яшәү рәвеше—чын мәгънәсендә юл халәтендә» икәнлеген үзең өчен ачыклыйсың, һәм бөек шагыйрьнең «зур дөньясы, эчкәрәк, тирәнрәк кергән саен, шулкадәр иркен, чиксез, мәңгелек булып тоела башлый». Хәсән Туфанның, әйе, җирнең, халыкның язмышы, киләчәге, аның мәңгелеге өчен янып яшәгәнлеге бөтен сыны белән күз алдына баса.



*Яңа Кырлайда Г. Тукай һәйкәле янында.*
*Сулдан уңга: Н. Нәҗми, Г. Бәширов, Ә. Еники, Р. Миңнуллин, М. Вәлиев. 1998 ел.*

Туфан хакындагы мәкаләне автор «Туфан тәрәзәсе», ә Сибгат Хәким хакындагысын «Язылмый калган җыр сагышы» дип атый. Алар янәшә тора. Әдәбиятта да, китапта да.

Җыентыкта язучыларның иҗади портретлары сериясе аерым урын алып тора, хәтта аерым-аерым сәхифәләр дә бар.

«Авылда комбайнчы булып эшләүче абзам бар минем. Унсигез яшеннән сугышка алынган. Гомере буе баш күтәрми эшләгән. Бик йомшак күңелле, сабыр-ихлас кеше. Зурдан кубасы берәр эш килеп чыкса, аның белән киңәшуңаш итәргә тырышам. Ашыкмый гына тыңлар, суына төшүеңне көтәр, шуннан соң гына җай белән үз киңәшен бирер. Кем әйтмешли, беркайчан да яшелли урмас». Шулай башлана Хисам Камалов хакындагы мәкалә. Шунда ук язучы барлык холкы, яшәеше белән күз алдына баса, соңыннан инде детальләштерәсе генә кала.

«Ул үзенең шигырьләренә охшаш», «...уяу янартау шикелле кайнап-күкрәп торучы әдип...», «...ул, яшенне үзенә тарткан имән кебек...», «язучының йөзендәге җыерчыклар, чәнечкеле тимерчыбык сыман, тирән уела төшә, ул бөтен гәүдәсе белән, кемнедер әче җилдән ышыкларга иткәндәй, алга таба талпынып куя»—бу—Нәби Дәүли.

Сүз кадерен җаны-тәне белән тойган Габдулла Шәрәфи; «...яңа мәйданнар яуларга омтылучы кайбер кысыр чәчкәләрнең тамырын каерып ача, аларны көйдергеч кояш астына тартып чыгара» алган, «яңалыкка сусау, хезмәткә һәм яшәүгә сусау» кичергән Рахмай Хисмәтуллин; прозада, драматургиядә талантлы әсәрләре белән танылган, әмма оригиналь әкиятче дә булуын сагындырган Әхәт Гаффар портретлары укучының күңеленә сеңеп кала.

Әйе, күңелгә сеңеп калган фикерләр, күз алдына баскан сурәтләүләр

күп. Алда әйтеп киткәнемчә, аерым сәхифәләр дә бар, алар Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Фәннур Сафин, Зиннур Мансуров иҗатына багышланган.

Китапта исемнәр байтак... Шулай да татар шигъриятенең кайбер күренекле һәм хөрмәтле исемнәре китапта чагылмавы сизелә, әмма бу хәлне тәнкыйтьченең күңел юнәлешенә туры килмәү белән дә аңлатырга мөмкиндер.

Әйе, исемнәр күп. Алар арасында шәхес булып җиткәннәре, киләчәктә шәхес булырдайлары бар. С. Маннапов аларның барысына игътибарлы, шулар арасында кайный, һәр сүзендә аларга булган мәхәббәте, кайгыртуы күренеп тора. Шундый ук йөзле исемнәр бар чакта «исемсез» китап язу мөмкин түгелдер. Әмма С. Маннапов та «тәнкыйтьченең эчендә тагы бер тәнкыйтьче утырганын» таный. Шуның өчендерме, «укыйсың—күңелне кузгалтмый» торган әсәрләр турында сүз барганда, «ни өчен урта кулның базары югары?», «тәрәзәсез-ишексез өй ... ул нәрсә?» дигән бик мөһим һәм кирәкле сорауларына җавап биргәндә, теге яки бу язучының, шагыйрьнең исемнәрен күрмибез. Бу, бәлки, китапның табигатенә туры килмидер... Ә шулай да җыентыктагы «юк! җиңел укылмаска тиеш шигырь!» дигән эндәшле җөмләгә үз карашымны әйтәсе килә: мин гомерем буена җиңел шигырьләрне авыр укыдым, хәтта укый алмый читкә куйган чакларым булды, ә «авыр» дигән шигырьләр һәрвакыт җиңел укылдылар.

Бу китапны да мин җиңел укып чыктым. Һәйбәт шигырь китабын укыган кебек укыдым. Шагыйрьлекне тумыштан, диләр, әмма Салих Маннапов шикелле тәнкыйтьчеләр дә тумыштандыр, чөнки аның һәр язмасында шигърият барлыгын тоймау мөмкин түгел.

*Нәҗәр Нәҗми. 15 декабрь, 1988 ел.*

## «Үз авылымда туган икән...»

НӘБИ ДӘҮЛИ ХАТЛАРЫННАН



*Н. Дәүли белән М. Вәлиев. 1988 ел.*

Мөдәррис туганым!

Хатымны ничек башларга да белмичә аптырап утырам әле. Бик тә кызыклы хәл килеп чыкты. Үзең дә беләсеңдер, минем иҗатым турында бу озын һәм зур гомердә әллә ни күп язмадылар. Мин үз "шеф"ымны түземле рәвештә көттем. Кайчан да булса, кемнеңдер минем иҗатыма да күзе төшәр, кем дә булса минем язмышым турында да үзенең туры сүзен әйтер әле, дидем.

Күп еллар узды. Ләкин андый "шеф" тиз генә күренмәде. Ә мин һаман көттем... озак-озак өметләнеп яшәдем.

Ә карасаң-торсаң, андый кеше минем үз авылымда туган икән. Әйтерсең лә, Язмыш, менә мин сиңа үз туган авылыңда андый кешене дөньяга китердем, ул үсеп җитәр, Казанга барыр, сине очратыр, дип әйткән сыман. Бу минем өчен чыннан да олы бәхет булды. Рәхмәт, туганым Мөдәррис! Ярый әле мин исән чакта очрадың. Синең "Казан утлары"нда чыккан мәкаләң мине бер дә булмаган олы шатлык белән тетрәтте. Бу—минем иҗатым турында беренче олы сүз.

*Нәби Дәүли. 4 июль, 1980 ел.*

Хөрмәтле Салих туганым!

Мин синең "Тамыр тирәнлеген яфрак тоя" исемле китабыңны тагын бер кабат укып чыктым. Синең талантың турында фикерем бермә-бер артты. Син минем иҗатым турында бик оста фикерләреңне йөрәк аша уздырып язгансың. Бу озын гомеремдә үзем турында шундый хак һәм кешелекле сүз ишетү миңа олы бәхет булды. Мин әле телгә алырлык кеше икәнмен. Син моны үзеңнең хак сүзең белән расладың. Синең шикелле хаклыкны яулаучылар булганда, мин тыныч кына иҗат итә алам.

Китабыңны укып чыккач, миңа менә шундый матур уйлар килде. Мин үземнең соңгы минутымда да сиңа рәхмәт әйтеп, сиңа бәхетле тормыш, иҗатыңда шатлыклы уңышлар теләп дөнья кичәрмен.

*Нәби Дәули. 16 октябрь, 1988 ел.*

## «Үзеңне тыебрак язарга кирәк»

ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕННӘН (1982 ЕЛ, 18 ФЕВРАЛЬ)

**Мансур Вәлиев:** Салих Маннаповның мәкаләләре соңгы еллар тормышын, заманыбызның рухи чынбарлыгын өйрәнү буларак, әдәбиятыбызга башка жанр иҗатчылары керткән кадәр үк өлеш кертәләр һәм укучы өчен шул ук дәрәҗәдә кызыклы һәм кирәкледер. Салих Маннапов —барыннан да бигрәк шигърият тәнкыйтьчесе. Һәм, тагын да төгәлрәк итеп әйтергә теләсәк, уйлы-гамьле, фикерле-хисле тәнкыйтьче, шагыйрьләр белән бергә рухи талпынышның яңа хасиятләрен ачарга һәм аңларга теләп яшәүче җан. Иң мөһиме: Салих Маннапов шагыйрьләр турында чын мәгънәсендә вәкаләтле кеше булып яза, шигърият кануннарын гына түгел, шигъри дөньяның эчке тормышын, һавасын да нык тоеп яза.



*Сулдан уңга (беренче рәттә): Флүн Мусин, Фарваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин; икенче рәттә: Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Фәиз Зөлкарнәй, Әмир Махмудов, Назыйм Ханзафаров. 1983 ел.*

**Ибраһим Нуруллин:** Салих Маннапов—яхшы филологик тәрбия алган егет, бүгенге әдәбиятның актуаль мәсьәләләрен тирәнтен аңлап яза. Яшь тәнкыйтьче поэзияне яхшы тоя, прозаны да нечкә анализлый. С. Маннапов—талантлы тәнкыйтьче. Аңа күбрәк язарга, төрле жанрда эшләргә киңәш итәсе килә. Иҗатының эчке колачын киңәйтә төшәргә кирәк: әлегә әсәр эчендәрәк фикер йөртү сизелә. Тормышка якынрак проблемаларга килсен иде ул.

**Фарваз Миңнуллин:** Салихның "Хәтер" исемле мәкаләсен укымаган булсам, мин дә Ибраһим Нуруллинның тормышка якынаю хакындагы теләкләренә кушылган булыр идем. Ләкин бу мәкаләсе белән яшь тәнкыйтьче яңа офыкларга чыга, аның колачы киңәеп китә. Салих оператив, яңа әсәр хакында аның беренче булып сүз әйтергә алынган чакларын беләбез. Ул аерым язучы турында язганда да әдәбиятның гомуми фонына куеп яза. Эчкерсезлеге, ихласлыгы белән аерылып тора: укучы белән серләшә сыман ул.

**Ринат Мөхәммәдиев:** Тәнкыйть әдәбиятның йөзен, үсеш дәрәҗәсен билгели. Без тәнкыйтьчеләргә бай, ләкин безнең киләчәк, дәвам турында кайгыртуыбыз да табигый. Тәнкыйтькә өметле яшьләр килүе куандыра мине. С.Маннапов та шундыйлардан. Перспективалы тәнкыйтьче.

**Хәсән Хәйри:** С. Маннапов тәнкыйтьче генә түгел, ул юлда, эзләнә, үзен художник итеп тоя, логик фикерләүдән бигрәк образлы фикерләүгә ныграк өмет баглый төсле. Телендәге бизәклелек тә шуннан киләдер. Художниклык сыйфатын югалтмасын иде Салих. Тасвири тәнкыйть —яхшы сәләт, ләкин тәнкыйтьтә үзеңне тыебрак язарга кирәк. Аңа үзен прозада сынап карарга киңәш итәсе килә.

**Хатип Госман:** Р. Миңнуллин иҗаты хакындагы әйбәт мәкаләнең ахырындагы “спираль”, “сират күпере” кебек метафоралар фикерне аңлауны кыенлаштыра. Чибәрләп язарга омтылу, чыннан да, үзен сиздерә. Бу, бәлки, “амфибиялек” (художниклык белән тәнкыйтьчелек кушылуы) күренешедер.

**Флүн Мусин** (*секция җитәкчесе*): Биредә бик эшлекле фикер алышу булды. Тәнкыйтьче иҗаты турында бу кадәр тәфсилле сөйләшү, әйтелгән җитди фикерләр-уңай бәяләр һәм теләкләр —шуңа кайтып кала ки, без бүген аның китабын—нәшриятка, ә үзен Язучылар союзына тәкъдим итә алабыз...

*[Секция утырышында, алда телгә алынган язучылардан тыш, Н. Юзиев, М. Хәбибуллин, Н. Дәүли, З. Мәҗитов, Г. Рәхим, Х. Халиков, А. Яхин, Ф. Сафин, Р. Низамиев, Ф. Галимуллин, Р. Кукушкин, Ф.Зөлкарнәев һ.б. — барлыгы 26 кеше катнашкан.]*

## «Төкле аягың белән!»

БЕРЕНЧЕ КИТАПКА ҺӘМ
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНА ТӘКЪДИМ ХАТЫ

Салих Маннапов (Мөдәррис Вәлиев) нәшриятка тәкъдим иткән җыентыгын “Хәтер” исемле эссе белән ача. Мәгънәле адым! Яшь тәнкыйтьченең әле яңа гына язылган әсәре китапка беренче булып кереп китә, аның тулы хокуклы, вәкаләтле илчесе буларак алга килеп баса. Димәк, егет уйлана! Бүгенге көнебезнең иң авыр һәм иң катлаулы “ХӘТЕР” мәсьәләсенә шулай тере образлар аша игътибар итүе, татар әдәбияты хәзинәсеннән иң көчле әсәрләрне төпле итеп сайлап ала белүе аның җитлеккәнлеген, җитдилеген, сугышчан характерга ия икәнлеген берсүзсез раслый.

Китапта мөхтәрәм әдипләребез Г.Бәширов, С. Хәким, Ә. Еники, М. Мәһдиев, ни өчендер коралларыбызны барлаганда еш кына хаксызга онытып җибәргәли торган якты шәхес Х. Камал, И. Юзеев, В. Нуруллин, Г. Рәхим, Р. Гатауллиннар бер сафта тезелешеп торалар. Җыентыкка кергән, югарыда исемнәре саналган әдипләребезнең иҗатлары бер-берсенекенә охшамаган, алар, һәммәсе дә диярлек, —үзенчәлекле талант ияләре. Салих Маннапов шул үзенчәлекнең төсмерләрен берәмтекләп таба, барлый алган. Үзенчәлекне таба алу мәкаләләрнең үзгә формасын билгеләгән, аһәңен аерырга булышкан. Мәкаләләрнең чын күңелдән, чын уйлардан туганлыгы күзгә бәрелеп тора. Авторның йөгерек һәм ягымлы теле бар; кирәк икән, ул усаллана, каты таләпләр дә куя белә.

Хуш... Арабызга беренче адымнарыннан ук ышаныч тудырган яшь тәнкыйтьче килә. Без аны көтә идек. Гомерләре буена татар әдәбиятының дошманнары булган, үз кәефләре өчен генә кемнәрнедер мактап, кемнәрнедер күтәреп йөрткән [кайбер] саламторханнарны алыштырырга ныклы адымлы, туры сүзле иптәш килә.

Төкле аягың белән, Салих дус!.. Мин сиңа, үз иҗатымның да сафлыгын саклауда торачак чын дуска, бик рәхәтләнеп рекомендация бирәм. Безнең союз чын кешеләргә дә мохтаҗ! Бик мохтаҗ!

*Аяз Гыйләҗев. 17 май, 1982 ел. Казан.*

## «Сабыр төбе сары алтын»

ТӘКЪДИМ ХАТЫ

Салих Маннаповны (Мөдәррис Вәлиев) мин күптән—аның студент елларыннан ук күреп беләм. Ләкин байтак кына вакыт мин аны шулай "күреп" кенә белеп йөрдем. Бәлки, моңа Мөдәрриснең артык сабыр, тыныч холкы сәбәп булгандыр. Башка бер төркем студентлар авызларыннан чатыр-чотыр ут чәчеп, редакция һәм Язучылар союзы коридорларында "гениальный" бәхәсләр корып, бәбәгеңә чәчрәп кергән бер чорда, Мөдәррис тәүфыйк кануннары кушкан микъдарда гына авыз читләре белән елмаеп, тын гына йөри бирде...

Минем алда (һәм башка күбәүләр алдында да дип беләм) Мөдәррис әдәби тәнкыйтьче, бүгенге татар әдәбиятындагы яңа күренешләргә бәһа бирүче, бүгенге әдәбиятның үзенчәлекләрен билгели алучы, аның яхшы киләчәге өчен кайгыртучы шәхес, әдәби шәхес булып ачылды.

Шунысы куанычлы, Мөдәррис—коры сүзле, "коеп куйган академ" тәнкыйтьче түгел, ә киң катлау укучыларга укылышлы, ялгансыз фикер йөртүче, караны кара дип, акны ак дип дөресен әйтеп бирә белүче тәнкыйтьче. Шул ук вакытта ул ак белән караны аерганда, кызып китеп, элгәрләр суккан күперләрне сүтеп ташламый, буш сүзләр белән әрләү-сүгүләргә ирек бирми — икенче төрле әйткәндә, ул бәхәстә дә культуралы тәнкыйтьче булып кала.

Сүземне "Сабыр төбе сары алтын" дигән мәкальдән башлаган идем. Чыннан да, студент чакта әвәрә килеп чәпчеп йөргән күбәүләрнең инде исем-фамилияләре дә онытылып бетте. Ә менә сабырлыкның соң чигенә җиткән, оялчан Мөдәррисебезнең без бүген тирәннән, күңел һәм акыл түреннән чыккан фикерләренә олыбыз-кечебез тәҗрибәле колагыбызны салабыз һәм алдыбызда инде өлгергән язучы күрәбез...

*Гәрәй Рәхим. 12 октябрь, 1982 ел. Мәскәү.*

## «Мәскәү дә каршы килмәс»

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ КАРШЫНДАГЫ
КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ УТЫРЫШЫ
БЕРКЕТМӘСЕННӘН (1983 ЕЛ, 30 МАРТ)

**Рафаэль Мостафин:** Салих Маннапов соңгы елларда татар әдәби тәнкыйте өлкәсенә килгән яшьләрдән берсе һәм арада иң талантлысы, өметлесе дип әйтер идем... Аның мәкаләләре авторның әдәбиятны тирән тоеп, аңа нечкә зәвык белән якын килүе, һәр иҗат кешесенең индивидуаль үзенчәлекләрен оста тотып ала һәм анализлый белүе хакында сөйлиләр. Язучыларның иҗатларына бәйләп, ул гомумән әдәбиятның эстетик һәм тәрбияви максатлары, аның киләчәктәге бурычлары хакында зур сүз алып бара.

**Сибгат Хәким** (Кабул итү комиссиясе рәисе): Әдәби тәнкыйтьнең бездә зур традицияләре бар. Г. Ибраһимов, Гомәр Гали, Г. Нигъмәтиләрне генә искә төшерик. Алар—чын мәгънәсендә әдәбиятның язмышы турында кайгыртып, аның өчен янып-көеп, принципиаль фикерләре белән әдәбиятның барышында даими йогынты ясап, аның юнәлешен билгеләп килгән тәнкыйтьчеләр. Алардан соң бездәге тәнкыйтьнең дәрәҗәсе шактый түбәнәйде, ваклан-ды, саф әдәби тәнкыйтьчеләр бөтенләй юкка чыкты диярлек. Тик сугыштан соң, алтмышынчы елларда гына, бер төркем яшь тәнкыйтьчеләр мәйданга килеп, тәнкыйтьнең дәрәҗәсе тагы да үсә башлады. Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев, Тәлгат Галиуллин, Ибраһим Нуруллиннар безнең әдәби тәнкыйтьне яңа югарылыкка күтәрделәр. Инде хәзер мәйданга тагы да яңарак буын тәнкыйтьчеләр килә. Мансур Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиев, Равил Кукушкиннар буыны. Шул ук буынга Салих Маннапов та карый. Араларында иң яше ул. Ләкин әзерлеге, әдәби зәвыгы белән бер дә алардан ким түгел. Мәкаләләре

кызыклы, проблемалы, язучыларның иҗатына тирән үтеп керә белә, бәяләре дәлилле, ышандыргыч. Ул күбрәк шагыйрьләр, поэзия турында яза. Күрәсең, үзенең дә шагыйрь булуыннан инде бу. Аның мәкаләләренең шигъри стиле дә, бәлки, шуның белән аңлатыладыр. Һәрхәлдә, минем үземә мондый стиль ошый, ул әдәби әсәр кебек тәэсир итә, мавыктыра, уйландыра. Мин Салих Маннаповны союзга керергә бик лаеклы дип табам. Тәнкыйтьчеләрне вакытлы матбугатта басылып чыккан мәкаләләре нигезендә союзга алу практикасы моңарчы да бар иде... Моңа Мәскәү дә каршы килми.

*[Әлеге утырышта шулай ук Н.Юзиев, А. Расих, Т.Миңнуллин катнашкан һәм чыгыш ясаган.]*

## «Усал тәнкыйтьчеләребез юк»

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫ БЕРКЕТМӘСЕННӘН (1983 ЕЛ, 10 ИЮНЬ)

**Сибгат Хәким:** Безнең әдәбият тарихында төрле тәнкыйтьчеләр бар иде. Төрле яссылыктагы, төрле дәрәҗәдәге. Бүгенге яшьләргә мин шул тарих, традицияләрдән чыгып карыйм. Мөдәррис Вәлиевне без Кабул итү комиссиясендә бертавыштан хупладык. Белемле, әзерлекле кеше килә безнең тәнкыйтькә. Язганнары анализлы, объектив. Мин аның бераз усаллыгы да сизелеп торуын телим. Кызыклы тәнкыйтьче. Өметем зур аңа. Әдәбиятка күп эшләр дип ышанам.

**Аяз Гыйләҗев:** Тәнкыйтьчеләргә мин бер критерийдан чыгып бәя бирәм: бармы аның принципиаль позициясе, шуны эзлекле дәвам итәрлек көче бармы аның? Мөдәррис беренче адымнарыннан ук әдәбият дөньясындагы акны-караны аера башлады. Ышаныч белән әйтә алабыз: иҗат йөзе булган төпле-җитди тәнкыйтьче үсеп килә.

**Фарваз Миңнуллин:** Мөдәррис үзенең зур мәсьәләләр күтәреп чыгарга сәләтле булуын раслады. Беркемгә дә охшамаган, үз тавышы булган тәнкыйтьче... Ихтирам саклап, турысын әйтеп бетермәгән чаклары булгалый, —моны искә алсын иде.



*Яңа китап чыгу авторга да, наширгә дә сөенеч (Т. Миңнуллин, Ш. Галиев, М. Вәлиев. 2003ел).*

**Шәүкәт Галиев:** Мөдәррис Вәлиевнең тәнкыйтьтә үз ачышлары бар. Китабы нәшриятта берсүзсез хуплап каршыланды. Мөдәррис "Татарстан яшьләре" газетасы аша республика күләмендә яшь тәнкыйтьчеләр студиясе оештырды һәм аны уңышлы алып бара. Моны аның бик мөһим җәмәгать эше дип санарга мөмкин.

**Илдар Юзеев:** Мөдәрриснең үзенчәлекле сыйфаты— тәнкыйть хезмәтләрен әдәби әсәр дәрәҗәсендә, тиешле форма һәм стиль табып, мавыктыргыч итеп язуы. Аңа республика яшь язучылар конференциясендә, әдәби ел йомгакларында докладлар ясау тапшырылган иде,—әйбәт башкарып чыкты, ышанычны аклады.

**Азат Әхмәдуллин:** Мөдәррис Вәлиевнең әдәби тәнкыйтьтә үз йөзе, үз стиле бар. Тәнкыйтьче алдына усал булу бурычы гына куелмый бит. Әдәбиятның сәнгатьчә асылын ачу, аны пропагандалау, аңлату бурычы да тора безнең алда.

**Тәлгат Галиуллин:** Тәнкыйтьтә бүген ике юл ачык аерыла: язучылар тәнкыйте һәм академик-гыйльми тәнкыйть. Мөдәррис Вәлиев шушы ике

юнәлешнең уртасыннан, аларны берләштереп бара: әдәби яктан тәэсирле, фәнни яктан анализлы итеп яза.

**Равил Фәйзуллин:** Мөдәрриснең үткән ел "Казан утлары"нда зур-зур берничә мәкаләсе басылды. Җитди хезмәтләр. Шуларның үзәк матбугатта да лаеклы яңгырарлык фикерләре бар иде. Ләкин алар үзебездә генә калды. Бөтенсоюз әдәби процессында активрак катнашу, гомумән, безнең әдәби тәнкыйть алдындагы бурыч булып кала әле.

**Гариф Ахунов** (Язучылар союзы идарәсе рәисе): Халтурага каршы усал тәнкыйтьчеләребез юк безнең хәзер.

**Ринат Мөхәммәдиев:** Мөдәррис Вәлиевнең халтурага каршы кискен чыгышларын барыбыз да хәтерлибез. Ләкин алар ничек кабул ителә бит...

**Гариф Ахунов:** Сезнең беравыздан хуплавыгызны да истә тотып, аны китабы чыгып өлгергәнче үк союзга алу мәсьәләсен кайгыртачакбыз. Мөдәрриснең әлегә кадәр эшләгән эшләре моңа нигез бирә.

## «Бер юллардан атлавыбыз билгесе»

НИЛ ГАФУР УЛЫ ЮЗИЕВ КИТАБЫНДАГЫ КУЛТАМГА

Мөдәррис туган!

Безнең тормыш сукмаклары, Аккош күле бакчасындагы сукмаклар кебек, гел янәшәдә бара, якынаеп, тоташып та куя. Бу китапның дөнья күрүен дә мин әнә шундый бер юллардан атлавыбызның билгесе итеп кабул итәм. Һәрдаим хәерхаһ теләктә торуың өчен чын күңелемнән рәхмәтләр юллыйм Сиңа!

Киләчәктә дә шулай бер сукмаклардан бергәләп йөрергә насыйп булсын! Тормышыңда ак бәхетләр, ныклы сәламәтлек, иҗат уңышлары теләп, хөрмәт белән:

*Нил абыең. 5 июль,1991ел.*

## «Бу, ихтимал, соңгы теләгемдер...»

Мөхтәрәм Мөдәррис әфәнде!

Сезгә зур бер үтенечем бар: Сез [Татарстан китап нәшриятында] чыгачак беренче томның "баш редактор"ы булсагыз иде. Бу бик мөһим, бик кирәк. Бигрәк тә китапның үзе өчен...

Сезне республикада белмәгән кеше юктыр. Китап эчендә Сезнең исемегез булуы ул китапның дәрәҗәсен бермә-бер күтәрәчәк... Хәзер "баш редактор" дигән вазифа бармыдыр, юкмыдыр —мин ачык кына белмим, әмма Сез беренче томның "баш редактор"ы булырга тиешсез. Бу, ихтимал, соңгы теләгемдер, ул үтәлергә тиеш.

*Ихтирам белән,*

*Әмирхан Еники. 10 январь, 2000 ел.*

# ҮЗӘКТӘ—ЗУР МӘСЬӘЛӘ

«Мәгариф» нәшриятында «Башкортстан татарлары: тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре» (2002) дигән гыйльми публицистик хезмәт дөнья күрде. Аның авторы—тел галиме, филология фәннәре докторы, Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Радик Сибәгатов. Р. Сибәгатов татар теленең яшәеше, кулланылышы, аның функциональ мөмкинлекләренең гамәлгә ашырылышы мәсьәләләре белән күптән шөгыльләнә, Татар конгрессларында әһәмиятле мәсьәләләрне кузгатып төптән уйланылган чыгышлар ясый, аның «Казан утлары» журналында басылган тирән эчтәлекле мәкаләләре дә укучыларга яхшы таныш. Әлбәттә, әлеге авторның иҗатында Башкортстандагы татарлар, аларның формалашуы һәм хәзерге хәле көнүзәк проблемага әйләнә бара. Аның укучыларга менә шундый күпкырлы, зур күләмле (192 б.) хезмәт тәкъдим итүе дә безнең фикеребезне раслый.




Башкортстандагы татарларның үзенчәлекле тарихы күптәннән инде галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп итеп килгән. XIX-XX гасырларда ук язуларда «башкорт» дип аталып йөртелә торган татарларның татарча сөйләшүләре, алар сөйләшенең Казан татарлары шивәсенә бик якын торуы, йөз-кыяфәтләре, тормыш итү рәвешләре белән дә татарлардан аерылмаулары турында телчеләр, этнографлар, тарихчылар һ. б. галимнәр язып чыкканнар (А. Бессонов, Г. Әхмәров, Н. Катанов, Ә. Юлдашев, Ж. Киекбаев, Л. Мәхмүтова, Ф. Юсупов, Т. Хәйретдинова һ. б.).

Бу юлларның авторына да Башкортстанның егермедән артык районында 200 ләп авылның сөйләшен өйрәнергә туры килде. Ул материаллар «Татар халык сөйләшләренең диалектологик атласы»нда чагылыш тапты. Табигый, кайбер авылларны башкорт дип йөртсәләр дә, аларның татарлардан бер дә аерылмаулары бездә дә зур кызыксыну уятты һәм бу хәлнең серләрен төшенү өчен 1966-1986 елларда Уфа, Оренбург, Пермь, Мәскәүдәге борынгы үзәк архивларда казындык, тарихи әдәбият белән таныштык, күпсанлы хезмәтләр (өч китап) язып чыгардык. Шунысы шатландыра, Р. Сибәгатовның тикшеренүләре безнең нәтиҗәләребезнең хаклы булуын күрсәтте. Аның җентекле, объектив хезмәтләре фәндә зур уңыш булып тора.

Р. Сибәгатовның әлеге шактый зур күләмле хезмәтендә күп кенә әһәмиятле проблемалар күтәрелгән: Көнбатыш Башкортстандагы татарларның формалашуы, аларның XVIII-XX гасырларда төрле төркемнәргә бүленгән булуы, аларның теленә күзәтүләр һ. б.

«Типтәр» атамасы нигездә «ясак кенәгәсе» мәгънәсендәге «дәфтәр» сүзеннән чыккан дигән караш чынбарлыкка туры килә булса кирәк. Фәндә күп кенә галимнәр тарафыннан әйтелгән бу фикерне Р. Сибәгатов өстәмә дәлилләр белән баетып янә бер тапкыр раслый.

**Радик СИБӘГАТОВ**. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. Казан: «Мәгариф», 2002.

Типтәрләрне төрле яклап сурәтли торган документаль чыганаклар, аларның характеры турында бай белешмә бирелә. Чыннан да, типтәрләр—социаль катлам, алар арасында төрле милләт вәкилләре булу (мәсәлән, Р. Сибгатов китабыннан күренгәнчә, 1744 елда алар арасында 36354 татар, 16126 мари, 3818 удмурт, 1396 чуваш, 126 башкорт, 8 мордва) да шуны ачык күрсәтә. XX гасыр башында типтәрләр арасында 373072 татар, 1808 мари, 3557 удмурт исәпләнгән. Күргәнебезчә, татарлар һәрвакыт типтәрләрнең зур күпчелеген тәшкил иткәннәр, күбесенчә Казан ягыннан күчкән булганнар. «Типтәр» дип йөртелгән татарлар да, марилар да, удмуртлар да үз милли сыйфатларын саклап калганнар.

Башкортстандагы катлаулы тарихи-икътисади ситуацияне, шул тарихи фонда татар халкы вәкилләре кичергән катлаулы язмышларны автор дөрес билгеләп алган. Һәм ул хаклы рәвештә: башкортлашу тулы булмаган, фин-угырлар кебек үк, «башкорт сословиесендәге татарлар да үзләренең телен, этник үзенчәлекләрен югалтмаганнар» (2 б.) дип яза.

Р. Сибгатов хезмәтенең тагын бер бик унай ягын аерым билгеләп үтми мөмкин түгел. Бу—дәлиллелек. Хезмәттә автор бай тарихи әдәбиятка таянып кына калмый, бәлки күп төрле язма чыганакларга мөрәҗәгать итә, статистик мәгълүматлар китерә. Мәсәлән, 1897 елгы халык санын алу материалларын җентекләп өйрәнү шул вакытта 350-400 мең татарны башкортка язылган дип карарга мөмкинлек бирә. «Положение о башкирах» дигән чыганактагы «жители...—башкиры-вотчинники, а по происхождению—казанские татары, пришедшие в самом начале XIX века» кебек сүзләрнең «башкорт» дип аталып йөртелә торган татарларга карата кулланылуы табигый булган, шуна күрә язма чыганаклар өчен ул бигрәк тә хас булган гыйбарә. Безнең үзебезгә дә архивларда эшләгәндә мондый типтагы мәгълүматларны күп укырга, хезмәтләребездә күп күрсәтергә туры килде. Шулай итеп, тирән эзләнү, объективлыкка омтылу, чынбарлыкны дөрес күрсәтеп, фактларны гадел бәяли белү, ягъни Р. Сибгатовның барлык хезмәтләренә хас булган күркәм сыйфатлар—аның әлеге китабының да төп хасиятен тәшкил итәләр. Шуна күрә бу китапта әлеге мәсьәләләр белән тегеяки бу юнәлештә эшләп килгән башка галимнәр белән (Р. Г. Кузеев, Д. М. Исхаков һ. б.) фикер уртаклыгы туа да.

Китапта шундый ук бай һәм кызыклы күзәтүләр Башкортстандагы йомышлы татарлар—мишәрләр—буенча да китерелә, керәшеннәрнең (хәзерге Бакалы төбәге) бу якларга килеп чыгу сәбәпләре дә күрсәтелә.

Шунысы әһәмиятле, Р. Сибгатов: Башкортстандагы татарлар килеп чыгышлары, оешу үзенчәлекләре ягыннан төрлечәрәк тарих кичерсәләр дә, татар милләтенең гомуми үсеш юлыннан читләшмәгәннәр, дип ассызыклап үтә. Бу исә дөреслеккә туры килә, тел, этнография материаллары белән дә раслана.

Китапның бер бүлеге Башкортстан татарларының теленә багышланган. Барыбыз да яхшы беләбез: тел—милләт күрсәткече, туган теле, милли теле булганда гына халык мөстәкыйль этник берәмлек буларак саклана ала. Юкка гына мәшһүр галимнәр, бөек әдипләр туган тел турында үзләренең иң матур, иң үлемсез шигырьләрен язып чыкмаганнар. Танылган галим, академик Әбрар Кәримуллинның «Тел—милләт сакчысы» дигән гыйбрәтле сүзе, безнең фикеребезчә, искиткеч тирән мәгънәгә ия. Татар халкының озын-озак формалашуы барышында аның теле дә аерылгысыз яшәп килгән. Язма әдәбиятыбыз—моның бик тә әһәмиятле бер шаһиты. Р. Сибгатов та тел үзенең даимилегең, нигездә, саклый, дигән караштан чыгып эш итә.

Хезмәтнең аеруча әһәмиятле һәм кыйммәтле якларыннан берсе шунда: анда мәсьәләләрнең куелышы, ул сорауларны тикшерү төзек логик эзлеклелектә бара. Шуна күрә дә автор XVI-XX гасырларда башкорт халкы нинди катлаулы үзенчәлекле иҗтимагый һәм икътисади шартлар кичергән булуын, ягъни катлаулы тарихи фонны сурәтләгәч кенә тел мәсьәләләренә күчә. Чыннан да, хәзерге чорда Башкортстанда куркытып «башкортлаштыру» (барыбыз да аңлыйбыз инде: кәгазьгә башкорт дип язып куеп кына халык башкортка әйләнми, ул 400-500 еллар буе башкортка әйләнмәгән, үз рухын, үз телен, үзенең яшәү рәвешен саклап килгән) утына эләккән татарлар шактый четерекле хәлдә яшиләр. Татарлармы алар, әллә инде башкортлармы? Автор мәсьәләне кабыргасы белән куя. Алай гына да түгел, татармы-башкортмы мәсьәләсен өр-яңадан, тагын бер кабат күтәреп чыга. XIX гасырда ук Башкортстандагы татарларның теле турында объектив, дөрес фикерләр әйтелгән. Шуларның берсе А. Г. Бессонов

нәтиҗәләре. Татар, башкорт телләрен белә торган, бишенче дистәне ваклый башлагач, казакъ телен дә өйрәнгән укытучы, шушы региондагы халык училищеларында озак еллар инспекторлык иткән А. Г. Бессонов хәзерге Көнбатыш Башкортстан төбәгендә таралган татар, керәшен, мишәр, башкорт, типтәр дигән төркемнәрнең сөйләшләре Казан шивәсенә бик якын булуын язып калдырган, тел фактлары белән исбатлаган. XX гасырның беренче яртысында Н. Катанов, Г. Әхмәров, Е. Малов, Ж. Вәлиди, Л. Җәләй һәм башкалар да шундый ук фикерне язып чыкканнар. Татар диалектологлары Ж. Алмаз, Ә. Әфләтунов, Л. Мәхмутова, Ф. Юсупов, Ф. Баязитова, Т. Хәйретдинова, Д. Рамазанова үзләренә хас алымнар белән, ягъни экспедицияләрдә булып, татарларны да, башкортларны да үз күзләре белән күреп, сөйләшләрен магнитофон тасмасына язып алып кайтып, Көнбатыш Башкортстан татарларының, төрле исемнәр белән аталсалар да, үзебезнең чын татарларыбыз икәнен язып, фәнни нигезләп анлатып чыктылар.

Кайбер башкорт тарихчылары (мәсәлән М. Колшәрипов), телчеләре (мәсәлән Н. Максютова—үзенең сөйләвенә караганда, аның бабалары Мәләкәстән килгән булган), аптырагач Көнбатыш Башкортстанда башкортлар татарлашканнар дип күрсәтергә тырышалар. Бу мәсьәлә дә өр-яңа түгел. Тик минә ни өчендер Дәүләкән, Благовар районнарында һәм Әчеле күл, Дим буйларындагы чын башкортлар, танылган башкорт тарихчысы Р. Кузеев күрсәтүенчә, XIII гасырлардан бирле татарлар белән аралашып, бергә яшәсәләр дә, татарлашмаганнар. Алар ни өчен сакланып калдылар икән соң? Димәк, ситуация башка булган, халык үзенең асылын бик сирәк үзгәртә, башкортлар—башкорт, татарлар татар булып бергә яши биргәннәр. Яңа жирләрдә жир өлеше алу өчен генә башкорт булып язылган татарлар да үз телләрен, үз рухларын саклаган һәм чын башкорт булганнар да үз телләрен, үз тормыш-көнкүреш рәвешләрен саклаган.

Р. Сибәгатов үзенең хезмәтендә мәсьәләнең фәнни нигезләрен ачып бара. Ул татар телен—татар теле, башкорт телен башкорт теле итә торган авазлар системасын, грамматик категорияләрне янәшә куеп, чагыштырып тикшереп чыга: башкортча—малды, беззе, һауанан, һыузын, ә татарча—малны, безне, һавадан, суның һ. б. Татар һәм башкорт телләренең фонетик яктан үзара аерылып торуларын исбат итә. Автор үзенең элгәрләре Ж. Киекбаев, Ә. Юлдашев кебек фән дөньясында атаклы булган бөек галимнәрнең дә шундый ук фикердә торуларын искә төшерә. Соңгы чорларда Көнбатыш Башкортстандагы татарларның сөйләшен башкорт теленең бер диалекты итеп күрсәтергә маташуның нигезсезлеген галим бик яхшы ачыклап күрсәтә, күп төрле фактлар белән нигезли.

Дөрес, минә шушы урында татар телчеләренең, диалектологларының бай фактик материалга, татар теленең диалектологик атласына таянып ясаган объектив тикшеренүләр нигезендә ясаган нәтиҗәләре дә киңрәк күрсәтелсә, әлеге хезмәт тагын да көчлерәк, отышлырак булыр иде. Ләкин бу хөрмәтле галимнең гаять катлаулы шартларда эшчәнлек алып баруын истә тотабыз.

Шунысын билгеләп үтик, халык саны буенча булган мәгълүматларны, бай тарихи һәм лингвистик әдәбиятны һ. б. бик күп материалларны анализлап, шул жирлектә даими күзәтүләр алып барып, Р. Сибәгатов түбәндәге фикергә килгән: тел материаллары да, экстралингвистик факторлар да төньяк-көнбатыш Башкортстан халкының сөйләм телен башкорт диалекты дип раслау өчен ышанычлы жирлек була алмый (49 б.).

Алга таба Р. Сибәгатов «хәзерге Көнбатыш Башкортстан халкы кайчандыр башкорт телендә сөйләшкәнме?» дигән сорауны ачыклау максатын да куя. Моның өчен ул «Башкортстан АССР тарихы буенча материаллар» *(«Материалы по истории Башкирской АССР».—Москва, 1936; 1949; 1956)* дигән басмаларга кертелгән документларда чагылган хәзерге жирле сөйләш үзенчәлекләрен барлап чыга. Анализ гаҗәеп җентекле, күпкырлы. Аңа каршы чыгарга теләүчеләрнең күңелендә туарга мөмкин булган барлык сораулар да истә тотылган: башкорт теленә хас **с**-лаштыру, **ж** урынына **й**, **с** урынына **һ** куллану кебек үзенчәлекләр шәхес исемнәрендә ничек чагылган? Документларны төзүче писецлар, дьяклар һ. б. нинди милләттән? Исемнәр дөрес язылганмы? Алу-сату һ.б. турындагы шундый документларны язганда нинди шәхесләр шаһит булган һ. б. Автор «Материаллар...» дигән китапларда 10500 шәхес исеме теркәлүен ачыклаган.

Автор шулардан татарча—бер төрле, ә башкорт телендә икенче төрле әйтелергә мөмкин исемнәрне **ч-с**, **с-һ**,

**ж-й, ж-ж** тәнгәллекләре буенча анализлаган. Билгеле, алар арасында татарча әйтелештәгеләре бермә-бер күбрәк. Мәсәлән, Чура варианты—52 мәртәбә, Сура варианты—2 мәртәбә, Көчек—18, Көсек—3 һ. б. ш. Янәй кабиләсенә караган исемнәрнең (89) 78-е—татарча, 11-е—башкортча, Елан кабиләсе буенча: 30-ы—татарча, 2-се—башкортча, Елдәк, Буләр, Уран, Кыргыз кабиләләреннән теркәлгән исемнәрнен барысы да татарча һ. б. ш.

«Шулай итеп,—дип яза автор,—статистик анализ фонетик анализ материалларын тагын да көчәйтә. Күпчелек исемнәр транскрипциядә татар теле үзенчәлеген саклаган... Төньяк-Көнбатыш Башкортстан халкынын сөйләм теле үзенең мөһим фонетик үзенчәлекләре (төп янгырашы) белән XVII-XVIII гасырларда ук хәзерге хәленә (татар теленә) якын булган яки бөтенләй туры килгән. Бу сөйләштә чатнап торган татарча яки гомумтөрки ч авазы өстенлек иткән. С урынына һ кулланунын эзе дә юк. Башкорт телендә булмаган ж авазы үзен сиздереп тора» (55 б.). Алга таба автор, мондый характердагы үзенчәлекләр көньяк-көнбатышка да жәелгән, дип яза. Мәсәлән, ул Мен ыруларыннан алынган 82 исемнең—75-е, Юрматы ыруларында 28 исемнен—24-е, Табын ыруларында 30 исемнен—28-е татарча язылган булуы турында саннар китерә, ә көньяк-кыпчак ырулары тоташы белән гомумтөрки янгырашлы исемнәр (36 б.) калдырган икән.

Шул ук вакытта китапта «әлеге мәгълүматлар дөреслеккә туры киләме, ул исемнәр дөрес язылганнармы?» дигән сорау янадан куела. Подьячийлар, писецлар барысы да руслар булган бит, ә татарлар һәм керәшеннәр берничә генә була. Ләкин алар татарлар белән эшләү өчен махсус әзерлекле хезмәткәрләр булган, XVIII гасырда күп кенә шәһәрләрдә татар теле укытылу да шушы фикерне раслый. Писецлар авыл һәм кеше исемнәрен мөмкин кадәр төгәл чагылдырырга тиеш булганнар. Безнең үзебезгә дә аларнын вазифаларын жиренә житкереп башкаруларына инанырга туры килгән иде. Мәсәлән, Мәскәүнең борынгы актлар архивында эзләнеп утырганда «Бюриказган» дигән авыл исеме очрады. Ю хәрефе белән язылган булгач, мин шунда ук бу авылда көнбатыш диалекты вәкилләре яши дип фараз иттем. Ике-өч ел сонрак безгә ул авылда булырга туры килде һәм теге фаразым расланды: Бюриказган авылында көнбатыш диалект вәкилләре яши булып чыкты. Димәк, писецлар авыл исемнәре әйтелешендәге кечкенә генә аерымлыкларны да чагылдырырга тырышканнар, чөнки, урта диалекттагы ү белән чагыштырганда, көнбатыш диалект вәкилләре әйтә торган ү авазы нечкәрәк, шуңа күрә писецлар «бүре» сүзен «бюри» дип язганнар да. Шәхес, ыру, авыл һ.б.ш. исемнәр, Радик Сибгатов исбатлаганча, ул анализлаган документларда мөмкин кадәр төгәл, дөрес язылганнар һәм авторның «Көнбатыш Башкортстанның моннан берничә гасыр элек үк, нигездә, татарча сөйләшүе турындагы нәтижә өчен житди дәлилләр бар» (55 б.) дигән сүзләре объектив, алар дөреслеккә туры килә.

Хезмәтнең әйтеп бетергесез әһәмияте, кыйммәте тагын шунда: бирелә анализ күп аспектларда алып барыла, автор язма документларның эчтәлеген, аларда чагылган һәртөрле мәгълүматларның барысын да исәпкә ала. Тылмачларны «татар теленә тылмач итүчеләр», дип атап күрсәтү, су чыганакларын һәм башка атамалар ике исемдә булса—русча шундый исемдә, ә татарча мондый исемдә дип күрсәтү очракларын һ. б.—барысын да махсус тикшереп бара. Мәсәлән күл турында: татарча Юлбирде, ә русча Лодеешное; яисә татарча Ялан, ә русча Кабан һ. б. Бу бай материалга ясалган күзәтү, берьяктан, әлеге объектларның борынгыдан килгән татар исемнәрен саклавын күрсәтә. Тарихтан билгеле булганча, Урал алдының руслар тарафыннан чын мәгънәсендә колонизацияләнүе өчен мөмкинлекләр Оренбург шәһәре төзелгәч, ягъни XVIII гасырнын икенче чирегендә генә туа. Ә икенче яктан, «татарское письмо», «татарского языку толмач» кебек тәгъбирләр бик актив, гадәти кулланылышта булган. Шулай итеп, «Материалы...» дигән жыентыклардагы мәгълүматны Р. Сибгатов яна күзлектән, алардагы тел үзенчәлекләренен ничек чагылышы күзлегеннән, төпле һәм тирән анализ ясый. Мондый анализ фәндә беренче мәртәбә эшләнде. Ул анын белән күп еллар буе шөгыльләнде, үз эзләнүләрен жыентыкларда, журналларда да бастырып чыгарды. Шушындый зур тикшеренүләрдән соң Р. Сибгатов тагын бер мәртәбә «башкорт» сүзе ул вакытта этнонимны гына белдермәгән, дигән нәтижәгә килде. Башкорт яки типтәр булу Көнбатыш Башкортстан крестьяннарынын социаль хәле белән

билгеләнгән икәнен ачыклады. «Төньяк-Көнбатыш Башкортстан сөйләшләре йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә татарча яңгырашлы булган. Бу хәлне Казан татарлары йогынтысы дип кенә карап булмый», дип күрсәтә. Авторның «монда, күрәсең, борынгы бабаларының уртаклыгы үзен ныграк сиздерә» (65 б.) дигән нәтиҗәсе татар диалектологлары, татар һәм башкорт тарихчыларының нәтиҗәләре белән тәңгәл килә. Әгәр фәндә кайчандыр әйтелгән фикер аның дәвамчылары тарафыннан яңа материаллар нигезендә тагын да үстерелә икән, яңа алымнар яки яңа фән тармакларында да кабатлана йә расланa икән, димәк ул фикер чынбарлыкка туры килә. Аны чын мәгънәсендә галим булган тикшерүче әйткән һәм ул фикер, тарих кайсы якка гына борылса да, сакланып калачак. Ә вакытлы сәясәт өчен язылган кайбер хезмәтләр иләктәге су кебек төшеп югала барачаклар.

Р. Сибәгатов—тирән фикерле олы галим. Ул Башкортстан татарларының гомумтатар мәдәниятенә керткән өлешен дә читтә калдыра алмый. Әйе, безнең бик күп әдипләребез, дипломатларыбыз, дәүләт эшлеклеләребез Башкортстаннан чыккан. Автор үз китабының 68-69 битләрендә китергән зур исемлекне дәвам итәргә мөмкин, чөнки без өйрәнгән 200 ләп авылның гына да һәрберсеннән берәр, йә икешәр әдибебез чыккан икәнен күреп йөрдек. Әмма хәзер бу мәсьәлә шулай ук күпьяклы һәм ул авторны, шул исәптән безне дә, бик борчый. Көчләп «башкортлаштыру» шартларында кайбер иҗат чишмәләрен ком баса, ахрысы. Катлаулы сәяси шартлар, икътисади бәйләнешләрнең йомшаруы мәдәни бәйләнешләрне да киметә. Бер Башкортстаннан гына түгел, башка күрше төбәкләрдән дә яшь көчләр, яңа шәхесләр мәркәзебез Казанга азрак килә. Дөрес, монда бер өметле факт бар: Башкортстанның үзендә татар әдипләре оешмасы төзүгә омтылыш күзәтелә, бу юлда көрәш бара. «Туган анам теле татар теле булса да, тормыш итәсе бар бит әле, шуна күрә дә кәсебем, тормышым теле—башкорт теле дип әйтергә мәҗбүр булалардыр», дип ачынып яза Р. Сибәгатов. Автор таркаулыкны җиңеп, бердәмлекне ныгытуда демократия ярдәм итә дип әйтергә тели. Әйе, Радик әфәнде язганча, үзенчәлекле тарихы, үз этник йөзе булган югары мәдәниятле халыкның үз мәдәниятен үзе иҗат итәсе килә.

Ләкин актив иҗат эшчәнлеге өчен күп төрле шартлар булу зарур. Р. Сибәгатов китабының өченче бүлегендә юкка гына Башкортстанда татар теленең хокукый статусы турында сүз алып барылмый. Автор бу юнәлештә дә инде күп еллар һәм нәтиҗәле эшләп килә, Бөтендөнья Татар конгрессы корылтайларында чыгышлар ясый, мәкаләләр язып бастыра, китаплар чыгара. Ул Башкортстан һәм, гомумән, башка регион шартларында татар теленең дәүләт статусы алу мәсьәләләрен теоретик яктан өйрәнүгә зур игътибар бирә, бу көрәшнең төп принципларын, назари әсасларын билгеләү өстендә эшли. Әлеге хезмәтендә дә автор бу мәсьәләләргә зур урын бирә: үзгәртеп кору елларындагы яңалыклар, Телләр турындагы законнар чыгу, телләрнең хокукый статусының милли суверенитет, дәүләтчелек атрибутына әйләнүе һ. б. Республикаларның зур күпчелегендә, шул исәптән Татарстанда да, төп халыкларның теле дәүләт теле хокукына ия була алды. Башкортстанда исә хәл катлаулы иде, чөнки Республикага исем бирүче халыкның зур өлеше күрше Чиләбе, Оренбург өлкәләрендә бүленеп калган, ә Башкортстанда исә безнең татарларыбыз аерылып калган. Халыкларны бүлгәләп, төрле административ үзәкләргә таратып аерып калдыру сәясәте бик еракларга карап эшләнгән булып чыкты. Татарлар, руслар, башкортлар—шушы өч милләт телләренең дәүләт статусын Башкортстан җитәкчелеге таный алмады.

Тәҗрибәле сәясмән һәм галим Р. Сибәгатов монда өч төрле сәбәп булды дип аңлата: тел ситуациясенең артык катлаулы булуы, төрле милли хәрәкәтләр арасында аңлашу юклык, хакимият дәрәҗәсендә сәяси ихтыяр һәм тәвәккәллек җитмәү. Телләр статусы өчен барган киеренке көрәш автор тарафыннан логик эзлеклелек белән, бәйнә-бәйнә һәм ачык итеп аңлатыла. Хезмәттә «тел ситуациясе» дигән төшенчәнең күп төрле факторларны үз эченә алуы языла. Татар теленең функциональ яктан югары үсештә булуы аерым ассызыклана. Шул ук вакытта татар балаларына татарча укытуның чикләнгәнлеге, мәгариф системасында татар теле һәм әдәбияты белгечләренең аз булуы һ. б. шундый фактлар татар теленең функциональ мөмкинлекләренең тагын да тараюына китерүче саннар, таблицалар белән яктыртыла. Әйе, башкортлаштырабыз дип, татар балаларына чит «ана» тел—башкорт теле—укыту активлаша бара.

Нәтиҗәдә, татар балалары ана телләрен дә тиешенчә өйрәнә алмыйлар, башкорт телен дә үзләштермиләр, чөнки соңгысы һич реаль түгел. Шулай итеп, бары тик саннарда хисап бирү өчен генә нинди зур чыгымнар тотыла! Автор бик хаклы рәвештә: «Фактик социаль статуска ия булмаган тел, закон белән кертелсә дә, дәүләт тормышының бөтен ягын да канәгатьләндерә алмый. Бу инде дөнья практикасы буенча билгеле нәрсә» (90б.) дип яза. Африка һ. б. дәүләтләреннән мисаллар китерә.

Р. Сибәгатов: «Безнең тел дәүләт теле була аламы?», дигән сорау куя. Моны булдыру өчен милли-демографик, социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси, тарихи-мәдәни, лингвистик таләпләрне санап чыга, Башкортстандагы шартларда бу таләпләрнең җитешеп бетмәвен билгеләп үтә.

Автор шулай да Башкортстанда өч телгә дәүләт теле статусы бирүне иң оптималь вариант дип саный. Ул урыс теле бөтен республика дәүләт идарәсе теле, шуның белән бергә, көнчыгыш районнарда—башкорт, ә көнбатыш районнарда татар телләре актив булачак дип күрсәтә, ә «теге яки бу төбәккә аның өчен ят булган телне көчләп тагарга тырышу нәтиҗә бирмәячәк» (97 б.) дип яза ул. Шушы хәл төрле милли конфликтлар килеп чыкмасын өчен дә иң кулай вариант булырга тиеш. Ә республика халкының өчтән бер өлеше сөйләшкән тел дәүләт әһәмиятендәге тел итеп танылмау—даими киеренкелек чыганагы булып калачак. Р. Сибәгатовның «Башкортстан халыклары телләре турындагы» закон татар һәм башкорт халыкларын берләштерми, бәлки бер-берсенә каршы куя торган юридик акт булып тора, дигән нәтиҗәсе белән күпләр килешер дип уйларга тулы нигез бар. Чөнки бу киеренкелек, чыннан да, аерым шартларда бик перспективалы булып чыгарга мөмкин.

«Башкортстан татарлары...» дигән бик бай эчтәлекле бу китапка тагын гаять әһәмиятле, искиткеч актуаль булган кушымталар да өстәлгән. Аларда татар-башкорт проблемасын чагылдырган рәсми документлар һәм материаллар бирелгән. Бу проблема Татарстан һәм Башкортстан республикалары төзелгән чакта ук М. Калинин, В.Ульянов (Ленин) имзалары куелган декрет белән рәсмиләштерелгән икән. Ул чордагы буталышлар, татарларны ике зур төркемгә аеруның законлаштырылуы турында академик И. Таһировның язмасы, Д. Исхаков хезмәтеннән өзек, төрле архивлардан язма чыганаклар теркәлгән. Аларны оригиналда укып танышу бик әһәмиятле.

«Соңгы чорда башкорт милләтенә күчерелгән татар авыллары исемлеге» (ул Д. Исхаков тарафыннан төзелгән) аеруча зур кызыксыну уята. Анда 1959, 1970 елларда халык саны алу вакытында әле татар булып исәпләнгән 373 авылның, 1979 елдагы сан алу документларында инде башкорт итеп язылуын күрәбез (121-139 битләр). «Башкортлашу» процессы менә шулай бара. 1989 елгы халык саны алу материаллары буенча исә, Башкортстанда югарыдагы 373 авыл халкыннан тыш та, 1.120.702 татар яши икән.

Җыеп әйткәндә, Р. Сибәгатовның китабында Башкортстан татарларының тарихы, теле, мәдәнияте анализлана һәм аларның бүгенге аяныч хәленең сере тирәндә ятканлыгы, ул хәлнең берничә гасырлар буе тукылып килүе күрсәтелә. Тирән әзерлекле галим һәм сәяси яктан өлгергән шәхес буларак, Р. Сибәгатов Башкортстан татарларын бердәм татар халкы язмышы позициясеннән чыгып яктырта.

Р. Сибәгатовның китабы татар халкының язмышы, аның катлаулы һәм әле һаман да өйрәнелеп җитмәгән тарихы, бай мәдәнияте белән кызыксынучыларның, шул өлкәләрдә эшләүчеләрнең өстәленә салына торган фәнни китап һәм әһәмиятле белешмә дә булып тора.

**Дәррия РАМАЗАНОВА,**

*филология фәннәре докторы.*

## *Безнең календарь*

### Мөхәммәт Садриның тууына 90 ел

*1913 елның 20 маенда Казанда туган Мөхәммәт Садриның балачагы ятимлектә уза— 1921 елгы ачлык аны берьюлы әтисез дә, әнисез дә калдыра. Ятим бала үз тормышын үзе кайгыртырга тиеш була һәм ул эшли башлый. Сабын кайнату заводында эшчеләрнең авыр тормышын күрү аның кулына каләм алдыра, заводның «Вахитовчы» исемендәге күп тиражлы газетасында Мөхәммәтнең шигырьләре, эшчеләр тормышын яктырткан язмалары даими дөнья күрә. Соңга таба исә алар республиканың «Кызыл яшьләр» газетасында, «Атака» журналларында урын алалар.*

*1932 елда Х. Туфан, Г. Гали фатихасы белән унтугыз яшьлек М. Садриның «Җыр башлана» исемле беренче шигырь китабы басыла.*

*Шушы ук елны М. Садрины Мәскәү театр институтының драматургия бүлегенә укырга җибәрәләр. Мәскәүдә яшәгән татар язучылары М. Җәлил, М. Максуд, Ш. Маннур белән якыннан аралашу аның иҗатына зур йогынты ясый. Институтны тәмамлап кайткач М. Садри 1935 елда Татарстан Язучылар союзында әдәби консультант булып эшли, аннары ике ел Татарстан дәүләт нәшриятында яшьләр-балалар әдәбият бүлегенә җитәкчелек итә.*

*1936-1941 елларда исә М. Садриның иҗаты тагын да активлаша, «Совет Ватаны өчен», «Коммунарлар турында җыр», «Волга турында җыр» исемле шигырь китаплары басыла.*

*1941 елда М. Садри илебез азатлыгын яулар өчен сугышка китә, яраланып, госпитальдә дәваланып чыкканнан соң 1943 елда татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасында хәрби корреспондент-оештыручы булып хезмәт итә.*

*Сугыштан исән-сау әйләнеп кайткач ул ике елга якын Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, 1948-53 елларда исә «Совет Татарстаны» газетасының махсус хәбәрчесе, соңрак шушы ук газетаның әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире вазифасын башкара.*

*1956 елда профессиональ-язучы булып киткәч, аның иҗаты тагын да активлаша. «Бәхет турында җыр» (1947), «Александр Матросов» (1951), «Көзге күкрәү» (1956), «Кышкы бакча» (1961) һ. б. китаплары дөнья күрә, аның шигырьләренә көйләр язылып дистәләгән җырлар иҗат ителә. Шулай ук М. Садри тәрҗемә өлкәсендә дә яратып эшли.*

*1939 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы булып, «Бәхет турында җыр»лар язган М. Садри бәхетле гомер кичереп 1999 елның 27 мартында арабыздан китеп барды.*

## Mөxəmmət Sadri

ŞİĞERLƏR

### Min Berlinnı aldım

Yuaş qına malaү idem,
Çeben də ütermədem,
Usal keşe bulırmın dip,
Uyğa da kitermədem.

Yarata idem şaw-şulı
Yazğı saban tuүların,
Məş kilgən qırmısqalarnı,
Yəşel İdel buүların.

Oslannıŋ tawına menep,
İdelgə qarıү idem,
Paroxodlar, kəүmələrne,
Sallarnı sanıү idem.

İrtən ük İdel əstennən
Taralıp betkəç toman,
Kürenə ide Qazanım
Miŋa zur zavod sıman...

Soqlanıp küzətə idem
Yal itkən minutlarda
Aq kübələklər oçuın
Zəngərsu bolıtlarğa...

Balalar yortınnan çıqqan
Ber yuaş bala idem,
Ülgən pesine kürsəm də
Ğəcəpkə qala idem.

Üzgərep kittem kinət min:
Buldım ut, buldım bolıt,
Yəşennər kebek yəşnədem,
Kükrədem küklər bulıp.

Yaqladım Məskəw cirləren
Yanar utlarğa kerep,
Can tetrəde faşist digən
Şaqşı yırtqıçnı kürep.

Doşmanğa utlar yawdırıp,
Suğışta usallandım,
Əsir həm qol bulmas øçen
Berlin qalasın aldım.

«Qazan» isemen yazıp quyıp
Reyxstag diwarına,
Aşqındıq tank østendə
Praga yullarına.

Cinep qayttılar İdelneŋ
İr-yeget ağayları;
Sezgə bulsın yaqtı dønya,
İlebez malayları.

Qurqu belməs soldat buldım
Doşmannıŋ ønnərendə...
Tağın tınıç təzüçe min
Tuğan yaq cirlərendə!

## Sayra, sanduğaçım, sayra!

Sayra, sanduğaçım, sayra,
Taldan tallarğa oçıp,
Küŋeleŋ teləgən cirgə oçıp,
Matur çəçəklər qoçıp.

Sanduğaçım sayrıy, çut-çut, dip,
Bezneŋ ildən matur il yuq, dip.

Sayra, sanduğaçım, sayra,
İnde kitməsseŋ køz də;
Taptıŋ tuğan ileŋne sin,
İrkenləp sayra bezdə.

Sanduğaçım sayrıy, çut-çut, dip,
Bezneŋ ildən matur il yuq, dip.

Bəxetlelər baqçasınnan
Cır gørli bøten cirgə;
Qəderle watanıbıznı
Maqtıybız bergə-bergə!

Sandugaçım sayrıy, çut-çut, dip,
Bezneŋ ildən matur il yuq, dip.

## Sabantuyı cırı

Sabantuyı—xezmət tuyı,
Şatlıq həm bəxet tuyı,
Uynap, cırlap, biep, kəlep
Bəyrəm itik kən buyı.

Şaw-gør kilə kiŋ bolınnar,
Qırlar həm su buyları,
Qotlı bulsın, kolxozdaşlar,
Yəmle sabantuyları.

Bəyrəm itik şatlanışıp,
Tuğannar, bergə-bergə,
Bezneŋ bergə buluıbız
Kitsen bøten ğømergə.

Şaw-gør kilə kiŋ bolınnar,
Qırlar həm su buyları,
Qotlı bulsın, kolxozdaşlar,
Yəmle sabantuyları.

## Нәҗип Думавиның тууына 120 ел

Нәҗип Думави—егерменче гасырда (аның беренче чирегендә) татар дөньясында шактый ук зур яңгыраш алган әдипләребездән. 1905 елның бәрәкәтле тәэсирендә ачылган матбугат-әдәбият мәйданына килеп, үзенең шигъри әсәрләре, хикәяләре, повестьлары, публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән актив катнаша, халык арасында популярлык казана ул. Сәйфи Кудашның «Хәтердә калган минутлар» китабының 1959 елгы (Казан) басмасында шундый бер фотосурәт бар: анда Сәгыйт Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Сәгыйть Сүнчәләйләр утырып, ә Зариф Бәшири—басып тора. Гыйбрәтле бу сурәт 1916 елда, Уфада, «Тормыш» газетасы редакциясендә алдырылган: Думавиның, яраланып, беренче бөтендөнья сугышыннан котылып кайткан чагы... З. Бәшири каяндыр Шәркый Төркестаннан килеп чыккан... Калганнары—Уфада яшәүче әдипләр... Җитди карашлар, милләт язмышын, аның киләчәген күз аллаудан гажиз—арган, акыллы йөзләр... Гасыр башы әдипләренең фаҗигале, уйда да күпне кичергән, каршылыклы язмышлары монда да чагылмыйча калмаган, әлбәттә...

Нәҗип Думавида да бу шулай.

Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев-Думави 1883 елның 19 маенда Чистай өязе (хәзерге Аксубай районы) Яна Дума авылында туа. Башта авыл мәктәбендә укый, аннары Казанга килеп, андагы мәдрәсәләрдә белем ала, рус классларына йөреп, русча да укырга-язарга өйрәнә. Иң мөһиме, үзлегеннән күп һәм гомер буе укый, өйрәнә һәм бу аның әдәби, фәлсәфи эзләнүләрендә дә чагыла... Нәҗип Думави озак еллар мөгаллимлек итә—башта, 1902-1905 елларда, казакъ далаларында, Чистайда, Уралда, 1908-1911 елларда исә атаклы Буби мәдрәсәсендә укыта. Буби мәдрәсәсе туздырылгач, ул да кулга алына. Төрмәдән чыккач тагын укыта—Рязань өлкәсенең Вәрәки авылында хәлфә була... 1906 елда рус-япон сугышында, 1915 елда империалистик сугышта катнаша (сугыш темасы аның күп шигырьләренә дә үтеп керә). Октябрь инкыйлабын ул Чистайда укытучы булып каршылый, 1921 елга кадәр шунда мәгариф өлкәсендә эшли. 1921—1925 елда туган авылында мулла булып тора. 1925 елда ул—Дагстан педагогия техникумында укытучы була, ә 1927 елдан Үзбәкстанга китеп, Сәмәрканд өлкәсендә яши, төрле урыннарда культура-агарту йортларында эшли, мөгаллимлек итә. 1933 елда (5 май) Булунгур шәһәрендә вафат була.

Нәҗип Думави иҗаты—шактый бай һәм каршылыклы. Беренче рус революциясе тәэсирендә мәйданга чыккан шагыйрь әүвәл Акмулла тәэсирендә мәгърифәтчелек (бу турыда бер мәкаләсендә Г. Тукай да әйтеп үтә) юнәлешендә, аннан социаль каршылыкларны ачкан реалистик рухтагы шигырьләрен яза, революцион-демократик поэзия тарафдары булып таныла *(«Себер», «Тавыш» һ. б. шигырьләре)*; реакция елларында исә романтик алымнар белән мәхәббәт шигырьләре, гомумфилософик уйланулар, мистика мотивлары белән модернистик характердагы шигырь-поэмалары языла. Соңрак, импрессионизмга якын торган сурәтләр өстенлек итә...

Балалар өчен шигырьләре исә гади һәм халыкчан. Шул ук вакытта Н. Думави проза әсәрләре дә яза: аның «Болгар кызы Тойгы туташ» һ. б. күп популяр хикәя-повестьлары бар. Шулай ук әдипнең татар әдәбиятында шәрекъчылыкны яклап язган полемик чыгышлары, татар әдәби хәрәкәтен үз чорына бәйле яктырткан язмалары аны алдынгы карашлы әдип итеп таныта.

Безнең көннәрдә Н. Думави иҗаты турында М. Мәһдиев, Р. Гайнанов, Р. Ганиева, З. Рәмиевләрнең җитди хезмәтләре дөнья күрде. Әдипнең 100 еллыгына Татарстан китап нәшрияты аның «Тормыш сәхифәләре» *(төзүчесе, баш сүз язучы—Р. Ганиева)* исемле калын китабын дөньяга чыгарды.

## Гариф Галиевнең тууына 100 ел

Гариф Галиев бөтен гомере буена диярлек авыл тормышын якыннан күзәтеп, авыл тормышындагы һәр процессны үз күзе белән күреп һәм шуннан иҗатына илһам алып яшәгән әдипләребезнең берсе. Аны әдәбиятыбызда авыл җырчысы, авыл язучысы дип тә атыйлар.

Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10 маенда элекке Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волосте (хәзер Татарстанның Азнакай районы) Урманай авылында вак сәүдәгәр гаиләсендә туган. 1910 елның җәендә, әтисе кинәт кенә үлеп киткәч, җиде яшьлек Гарифны Бәйрәкә авылы мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул анда 1918 елга кадәр укый.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң шәкертләр, мәдрәсә каршында һәвәскәр драма түгәрәге оештырып, тирә-як авылларда спектакльләр куеп йөриләр. Яшүсмер Гариф иң актив "артистларның" берсе була. Ул 1918 елның көзендә Бөгелмә шәһәрендә ачылган өч еллык укытучылар семинариясенә кереп укый башлагач, әдәбият-сәнгать түгәрәгенә йөри, рухи омтылышларына азык таба.

Ләкин 1921 елгы ачлык афәте Г. Галиевкә семинарияне тәмамларга мөмкинлек бирми, ул, соңгы курста укуын ташлап, туган авылына кайтырга мәҗбүр була. Анда авыл Советы секретаре булып эшли, бер үк вакытта, волость җир комиссиясе члены буларак, крестьяннар һәм авыллар арасындагы һәртөрле җир низагларын, җир дәгъваларын хәл итү эшләренә дә катнаша.

Шул чорда Г. Галиев Казанда чыга торган "Крестьян гәзите"нә язышa башлый, үзенең авыл тормышына караган кыска-кыска очеркларын, хәбәрләрен бастыра.

Кызыл Армия хезмәте вакытында да хәбәрләр язудан туктамый, соңрак хикәяләр дә яза башлый. Мәскәүдә чыга торган "Эшче" газетасының 1925 елгы ноябрь санында аның "Вәли ничек кызылармеец булды" исемле беренче хикәясе дөнья күрә. Башка хикәяләре дә шул газетада басылып чыгалар.

Армия хезмәтеннән кайткач Гариф Галиев бер кыш туган авылында, 1927-1928 елларда Азнакай урта мәктәбендә укыта. Ул елларда Мәскәүдә нәшрият кооперациясендә хезмәт итүче язучы Мәхмүт Максуд, яшь авторның "Эшче"дә басылган барлык хикәяләрен туплап, 1927 елда "Кызыл Армия хикәяләре" исемле җыентыгын бастырып чыгара.

1928 елның көзендә Г. Галиевне Бөгелмәдә чыга торган "Сабанчы" газетасы редакциясенә җаваплы секретарь итеп эшкә чакыралар. 1930 елның декабреннән Казанга күчеп килә, Авыл хуҗалыгы идарәсенең матбугат органы булган "Колхоз газетасы" (элекке "Крестьян гәзите"), "Советлар канаты" газеталары, "Колхоз бригадиры" журналы редакцияләрендә җаваплы секретарь булып эшли.

Утызынчы еллар дәвамында Г. Галиевнең әдәби иҗат эше аеруча активлаша. 1931–1941 еллар эчендә язучының тугыз китабы дөнья күрә. Алар арасында "Фамилиясез кеше", "Бибкәй аланы" кебек заманында популярлык казанган повестьлар һәм очерк җыентыклары бар. 1939 елда Гариф Галиевне Язучылар берлегенә кабул итәләр (рекомендациянең берсен М. Җәлил бирә).

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г. Галиев 1941 елның августыннан 1946 елның апреленә кадәр армия хезмәтендә була: "Кызыл сугышчы" һәм "Кызыл Армия" фронт газеталары редакцияләрендә җаваплы секретарь булып хезмәт итә. Хәрби заданиеләрне үрнәк рәвештә үтәгәне өчен ул Кызыл Йолдыз ордены, "Варшаваны азат итү өчен", "Берлинны алу өчен" медальләре белән бүләкләнә.

Сугыштан соңгы елларда Г. Галиев "Кызыл Татарстан" газетасы редакциясендә очеркист, элекке "Колхоз бригадиры" журналы яңадан чыга башлагач, 1949 елның августыннан 1958 елның маена кадәр, журналның җаваплы редакторы булып эшли.

Г. Галиев балалар әдәбиятында һәм драматургия жанрында да нәтиҗәле эшли. Аның дистәдән артык бер пәрдәле пьесасы бар. Аларның күбесе үзешчән сәнгать коллективлары тарафыннан күп мәртәбәләр сәхнәдә уйналган.

Гариф Галиев 1985 елның 22 мартында Казанда вафат булды.

# Берлекнең яңа әгъзалары

## Рифкать Хисмәт



Рифкать Әхмәдулла улы Хисмәтов 1939 елны Татарстанның Чүпрәле районы, Татар Саплыгы авылында колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе сугышта һәлак була, әнисе дүрт баланы укытып зур хезмәт юлына бастыра. Өч туганы укытучы һөнәрен сайлагангамы, Рифкать тә шул юл белән китмәкче була. Әмма кечкенә вакытта имгәнеп, күзләренең күрү сәләте бик нык какшау сәбәпле, аңа бу хыялыннан баш тартырга туры килә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң клуб мөдире вазифасын башкара. 1960 елда комсомол юлламасы белән Ульян цемент заводы төзелешенә күчеп килә. Анда үндүрт ел эшләгәннән соң, инвалид буларак, сукырлар җәмгыятенең «Автоконтакт» оешмасына күчә һәм бүгенге көндә дә шунда эшли.

Рифкать Хисмәт шигырьләр язу белән яшьтән үк шөгыльләнә, беренче шигырьләре 1954 елда ук район газеталарында дөнья күрә. Соңрак аның язмалары «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Татар иле» газеталарында, «Чаян» һәм «Аргамак» журналларында даими чыгып килә. Шулай да, авторның иҗат активлыгында Ульян шәһәрендә татар телендә чыга торган «Өмет» газетасының роле аеруча зур. «Редакция хезмәткәрләренең ярдәменнән башка, ихтимал, китабым да чыкмаган булыр иде», дип яза ул үзе дә.

Рифкать Хисмәт—чичән, декламатор шагыйрь. Ул үз язганнарын яттан белә, халык арасында—клубларда, мәктәпләрдә, төрле дини, милли, мәдәни бәйрәмнәрдә еш чыгыш ясый. Аның шигырьләре Татарстан, Ульян һәм «Азатлык» радиоларыннан еш яңгырый. «Сембер язлары» альманахында зур-зур шигырь цикллары даими басылып килә. Р. Хисмәт шигырьләре тематик һәм максатый яктан шактый төрле: олыларга адресланган җитди шигырьләр, юмор-сатира әсәрләре, балалар өчен дидактик такмаклар, багышламалар, җырлар... 2000 елда шагыйрьнең Ульян шәһәрендә «Үз сукмагым» исемле шигырьләр китабы дөнья күрде.

Татарстан Язучылар берлеге Рифкать Хисмәт иҗатына һәрвакыт игътибарлы булды. Үткән ел аның иҗаты «Шигърият остаханә»се утырышында тикшерелде, быелның 26 мартында Кабул итү коллегиясендә каралды һәм соңрак идарә утырышында Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## Таңчулпан (Чулпан Әхмәтова)



Таңчулпан (Әхмәтова Чулпан Шәрип кызы) Татарстанның Актаныш районы Бишкүмәч авылында 1966 елда дөньяга килгән. Сабыйга ата-ана тигезлегендә нибары җиде ай яшәп калырга насыйп була, ул ата назыннан мәхрүм кала. Тоеп үскәне—әни назы, әби-бабай җылысы.

Таңчулпан 1974 елда Актаныш районы Тәкмәк авылында беренче сыйныфка укырга керә. Аңа шулай ук әлеге районның Олыймән, Югары Яхшый, Киров авыллары мәктәпләрендә укырга туры килә. 1984-89 елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый.

Хезмәт юлын Татарстанның Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгы каршында оешкан «Вакыт» газетасында башлый. 1992 елдан «Шәһри Казан» газетасында икътисад бүлегендә хәбәрче, хатлар бүлеге мөдире, аннан соң фән һәм мәдәният бүлеге мөдире була.

1997 елның 12 ноябреннән Таңчулпан Татарстан Республикасы Дәүләт Советының матбугат үзәгендә әйдәүче референт булып эшли.

«Иҗат белән мәктәп елларыннан бирле шөгыльләнәм. Казан университетында укыганда олуг әдип Мөхәммәт Мәһдиев җитәкләгән «Әллүки» әдәби берләшмәсенә йөрүем чын иҗатка җитди рәвештә килергә этәргеч булды», дип яза шагыйрә үзенең автобиографиясендә.

Таңчулпанның шигъри бәйләмнәре «Идел», «Казан утлары», «Сөембикә» журналларында, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Мәгърифәт» газеталарында еш басыла килделәр. 2000 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрәнең «Кыргый чәчәк» дип исемләнгән шигырьләр тупланмасы китап буларак дөнья күрде.

2003 елның 31 мартында, идарә утырышында Таңчулпан Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде. Шагыйрә Казанда яши.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*«Шура» журналының җитәкчелек даирәсе. Уртада Риза Фәхретдин һәм Дәрдмәнд. XX йөз башы фотосы.*



*Фронтовик язучылар. Беренче рәттә (сулдан уңга)—Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Афзал Шамов, Госман Бакир, Гомәр Бәширов, Гариф Галиев; икенче рәттә—Атилла Расих, Мөхәммәт Садри, Геннадий Паушкин, Сафа Сабиров, Юрий Белостоцкий, Тихон Журавлев, Шәйхи Маннур; өченче рәттә—Мәхмүт Хөсәен, Сәет Шәкуров, Мәгъсүм Насыйбуллин, Габдулла Шәрәфетдинов, Нәби Дәүли, Мәҗит Рафиков, Габдулла Шамуков, Кави Латыйп, Әхмәт Исхак. Май, 1980 ел.*



*Татар шагыйрьләре Европада. Мөхәммәт Садри (сулда) һәм Гали Хуҗи. Вена. 1945 ел.*

*Данлыклы Матбугат йорты. 1933-35 елларда архитектор С. Пэн проекты белән конструктивизм стилендә салынган бина. XX гасырда чыккан татар китапларының, газета-журналларының күбесе шушы бинада әзерләнде һәм аның полиграфия комбинатында басылды.*





*Суверенитет өчен көрәш елларының бер күренеше. Үткән гасырның 90 еллары.*



Ictimagi-mədəni
tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни
тормышыбыздан

### МАТБУГАТНЫ НИ КӨТӘ?

Казанда "Гаммәви мәгълүмат чаралары: базар шартларында нәтиҗәле эшләү" дигән республика семинары булып узды.

Аның эшендә Россиянең Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгының хокук идарәсе башлыгы Павел Степанов, "Россия гаммәви мәгълүмат чараларын яклау" программасы буенча эшләүче "Ачык җәмгыять" (Сорос фонды) институтының даими эксперты Андрей Цитовский, "Известия" газетасының генераль директор урынбасары Павел Негоица һәм башкалар катнашты.

Семинарны ачып җибәргән элемтә министры Ринат Җәлалов үзенең чыгышында Татарстан басмалары үз-үзләрен аклый торган, мөстәкыйльрәк булсыннар иде дигән теләк белдерде. Мәскәү бу яктан шактый алга киткән һәм алардан үрнәк алырга кирәк, диде ул.

Россиянең Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгының хокук идарәсе башлыгы Павел Степанов тиздән гамәлгә керәчәк "Гаммәви мәгълүмат чаралары турында"гы закон хакында сөйләде. "Гамәлдәге закон беренче чиратта сүз иреге, журналистлар хокукларын яклау максатыннан кабул ителгән иде. Алар хәзер дә мөһим, әмма тормыш алга бара, яңа шартлар туа. Шуңлыктан яңа закон кирәк",—диде ул.

### УНИВЕРСИТЕТ ГОРУР ЯҢГЫРЫЙ

Башкалабыз Кремлендә Казан дәүләт университетына нигез салынуның 200 еллыгына багышланган чараларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты утырышы кысаларында Татарстанда мәгариф һәм фәнне үстерү юллары турында зур сөйләшү булды. Аны ТР Президенты, оештыру комитеты рәисе М. Шәймиев үздырды.

200 ел—университет өчен хәтта Аурупа үлчәмнәре буенча да зур дата. «Казан университеты шәһәрнең университетлы шәһәр буларак формалашуына йогынты ясады һәм ясый килә», диде КГУ ректоры М. Салахов.

Казан хакимияте башлыгы К. Исхаков Казан университетын үстерүнең республика максатчыл программасын тормышка ашыруның барышы турында сөйләде.

Сөйләшүдә катнашкан академиклар М. Хәсәнов, А. Коновалов, С. Дегтярев, спорт һәм яшьләр эшләре министры М. Бариев КДУ юбилеена лаеклы әзерләнүгә кагылышлы тәкъдимнәр керттеләр.

### ДУСЛЫК ВИЗИТЫ БЕЛӘН

Апрель башында Чуашстан Республикасында Татар әдәбияты көннәре үтте. Татарстанның мәдәният министры Илдус Тарханов житәкчелегендәге делегация составында Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, язучылар Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Вахит Имамов, Мөхәммәт Мирза, Резедә Вәлиева, Владимир Корчагин, жырчылар Рөстәм Маликов, Раушания Җиһангирова бар иде.

Беренче көнне үк хөкүмәт йортында ике министрлык арасында киләсе 5 еллыкка төзелгән килешүгә кул куелды. Бу тантанада Чуашстанның вице-премьеры Вячеслав Краснов, мәдәният министры Ольга Денисова, Язучылар берлеге рәисе Валерий Тургай, халык шагыйре Порфирий Афанасьев катнашты.

Очрашулар мәдәният һәм сәнгать институтында, В. И. Ульянов исемендәге Чуаш дәүләт университетында булды.

Икенче көнне очрашулар Канаш районының Сеспель авылында, Комсомол районының Урмай авылында, Батыр районының Кызыл Чишмә авылында булды. Язучылар Сеспель авылында шагыйрь М. Сеспель музеенда булып, аның һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре салдылар. Аннан соң "Родина М. Сеспеля" мемориаль комплексын карадылар.

Кичәсе көнне язучылар әдәбият музеенда булып, К. Иванов, М. Сеспель һәм И. Яковлев һәйкәлләренә чәчәк бәйләмнәре салдылар. Татар әдәбияты көннәре Чуаш милли китапханәсендә узган пресс-конференция белән тәмамланды.

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙ—БӨЕК ӘДИП

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында мәшһүр әдип, драматург, җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче

Гаяз Исхакыйның тууына 125 ел тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булып узды.

Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин язучы иҗаты аша халыкның чын тарихы кайтарылуы һәм Г. Исхакыйның 15 томлык әсәрләрен бастыру, аны урта һәм югары белем бирү йортларында өйрәнү башланачагы турында сөйләде. Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин Г. Исхакыйның тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге турында чыгыш ясады.

Юбилей кичәсендә язучы әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр тәкъдим ителде. Аларны Г. Камал театры артистлары күрсәтте.

## "ТАТНЕФТЬ"НЕҢ ҮЗ ЖУРНАЛЫ

Татарстанда нәшер ителүче басмаларның саны бер журналга артты: "Нефть и Жизнь" ("Нефть һәм Тормыш") журналының беренчесе дөнья күрде. Бу журналның хуҗасы, ягъни гамәлгә куючысы—"Татнефть" ачык акционерлык җәмгыяте.

Компаниянең генераль директоры Шәфәгать Тәхаветдинов үзләренең журналын чыгару мөһимлеген "Татнефть"нең ныгытуы һәм аңа елдан-ел кызыксыну арта баруы белән аңлатты.

"Нефть и Жизнь" ("Нефть һәм Тормыш") журналы Россиянең "Нефтегазовая Вертикаль" журналы, "Солид-инфо" агентлыгы, Әлмәт, Түбән Кама, Казан, Мәскәү журналистлары катнашында нәшер ителә. 48 битле басмада нефть өлкәсендәге төрле вакыйгалар, "Татнефть", аның эшлекле партнерлары турында мәгълүматлар тупланган. Журналда шулай ук социаль, экологик проблемаларны, мәдәният һәм спорт яңалыкларын яктырту өчен дә урын бар.

## ЯҢА РЕКТОР

Казан дәүләт педагогика университетында ректор сайлау үткәрелде. Башта ректор булырга теләүчеләр җидәү иде. Әмма сайлау җыелышына алар дүртәү генә калды. Сайлауда катнашкан 200 делегатның 173е Җәмил Нигъмәтовны яклап тавыш бирде. Шулай итеп, педагогия фәннәре докторы, 63 яшьлек Җәмил Газиз улы Нигъмәтов КДПУның ректоры булды.

## ТАРИХЫБЫЗНЫ—КҮРГӘЗМӘГӘ

Министрлар Кабинетында Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева рәислегендә үткән киңәшмәдә Казан һәм Мәскәү шәһәрендә башкалабыз тарихына багышланган документлар һәм сирәк басмалар күргәзмәсе оештыру мәсьәләсе тикшерелде. Ул күргәзмә Казанга нигез салынуның 1000 еллыгына әзерлек чаралары планы кысаларында үткәрелә.

Киңәшмәдә күргәзмәнең концепциясе һәм вакыты ачыкланды. Аның төп өлешен Россия дәүләт борынгы актлар архивы фонды һәм Татарстан Республикасы Милли архивының уникаль документлары алып торачак. Күргәзмәдә шулай ук Татарстан Республикасы, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре музейлары, китапханәләре экспонатлары, кульязмалар һәм сирәк басмалар куелачак.

Күргәзмә башта Мәскәүдә, ә җәен Казанда үтәчәк.

## ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

14-17 мартта Азнакай шәһәрендә һәм районында үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренә Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин җитәкчелегендәге делегация барды. Аның составында әдәбият-сәнгать әһелләреннән Илдар Юзеев, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Гәрәй Рәхим, Резеда Вәлиева, Шәмсия Җиһангирова, Флера Тарханова, Рифә Рахман, Рафис Корбан, Галимҗан Гыйльманов, Ләбиб Лерон, Әхәт Сафиуллин, Мөхәммәт Мирза, җырчы Мингол Галиев, аның шәкерте Лилия Сәлахова бар иде. Азнакайда кунакларга шушы төбәктә туып иҗат итүчеләр Илдус Гыйләҗев, Фәйрүзә Исмәгыйлова, хәзер Әлмәттә яшәүче шагыйрь Нур Әхмәдиев, шәһәр һәм районның үзешчән артистлары, музыкантлар кушылды. Очрашу-кичәләрне башлап җибәрү уңаеннан район үзәге мәдәният йортында тантана булды. Аны район һәм шәһәр хакимияте башлыгы шагыйрь Әнәс Исхаков ачты, быел үз юбилейларын үткәргән шагыйрь Илдар Юзеевка һәм язучы Мөсәгыйть Хәбибуллинга тәбрикләү адреслары, Азнакайда булу истәлеге итеп җирле рәссамнарның картиналарын тапшырды.

Аннары кунаклар һәм аларның Азнакайдагы каләмдәшләре, 4 төркемгә бүленеп, шәһәрнең 4 мәктәбендә, оешмаларында, 12 авылда очрашу-кичә үткәрделәр. Саубуллашу кичәсе Актүбәдә узды.

## ЯШЬ КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ ҖЫЕНЫ

Март аеның соңгы көннәрендә Татарстан Язучылар берлеге, Мәгариф, Спорт һәм яшьләр эшләре министрлыклары, "Идел" яшьләр үзәге белән бергәләп яшь язучылар семинары үткәрде. Инде икенче ел рәттән уздырыла торган бу чарага быел Татарстанның 20 районыннан һәм Удмуртия, Мари Иленнән, Казан мәктәпләреннән иҗат белән шөгыльләнүче 30 дан артык яшь автор килгән иде. Семинарга килүчеләрнең күбесе үзләре яшәгән районнарда иҗатлары белән танылып, республика һәм төбәк буенча үткәрелгән иҗат бәйгеләрендә җиңү яулаган яшьләр иде. 3 нче мәктәп-интернатка яшь талантларны сәламләргә, алар белән күрешергә, әдәби иҗат турында тәфсилләп сөйләшергә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, язучылар М. Хәбибуллин, М. Маликова, Ф. Зыятдинов, Г. Галиева, Р. Низамиев, Г. Гыйльманов, Ф. Мөслимова, Ш. Мостафин, Л. Шагыйрьҗан, Р. Вәлиева, Б. Рәхимова, Р. Рахман, Ә. Гадел, Ф. Әһлия, М. Закир, Р. Сәгъди килгән иде.

Яшь каләм ияләре арасында үзләрен төрле жанрларда сынап карaучылар, шигырь, хикәя, пьеса язучылар бар. Якын киләчәктә семинарда катнашкан яшьләрнең иң уңышлы дип табылган әсәрләре китап яисә альманах булып дөнья күрәчәк.

### КИТАП—ХӘЗИНӘ УЛ

Казан дәүләт университетының көнчыгышны өйрәнү институтында Ираннан кайтартылган китапларны бүләк итү тантанасы булды.

Әлеге басмалар Россиянең Иран ислам республикасы илчелеге каршындагы мәдәни вәкиллеге аша тапшырылды. Югары уку йорты китапханәсе мең исемләге басма белән тулыланды. Алар арасында фарсы телендәге әдәбият, фәлсәфә, суфичылык тарихы хакындагы фәнни басмалар, классика, Иранның бүгенге көн шигърияте һәм прозасы, Иран, Европа мәдәнияте, ислам инкыйлабы, сәяси икътисад турындагы китаплар, балалар әдәбияты бар.

### БОРЫНГЫДАН ГЫЙЛЕМЛЕ БЕЗ

Татарстан Милли музеенда беренче татар әлифбасы басылып чыгуга 225 ел тулуга багышланган "Белем капчыгы" исемле кичә булды.

Тәүге әлифбаны шәһәребезнең 1 нче гимназиясендә татар теле укыткан Сәгыйть Хәлфин төзи, ул 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә гарәп шрифтында дөнья күрә. Музейга килүчеләр аның үрнәге белән танышты. Бирелә үк музей фондларында саклаучы татар грамматикасы дәресләре һәм башка сирәк китаплардан оештырылган күргәзмә дә эшләде. Музей хезмәткәрләре укытучы Хәлфиннәр гаиләсе эшчәнлеге, аларның халкыбызга аң-белем таратуда куйган тырышлыклары турында сөйләделәр.

### УФАДА ОЧРАШУЛАР

Башкортстан китап нәшриятында Мөләррис Әгъләмовның "Быуат капкаһы" ("Гасыр капкасы") дигән шигырьләр китабы чыгу уңаеннан автор белән шагыйрь Наис Гамбәр Уфада булып кайттылар.

Шушы уңайдан Башкортстан китап нәшриятында башкорт язучылары һәм журналистлары катнашында очрашу үткәрелде.

Казан шагыйрьләре шулай ук Уфа дәүләт университетында, "Тулпар" журналында, "Кызыл таң" газетасында, "Ихлас" мәчетендә уздырылган очрашуларда катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

Очрашуларда Башкортстанда яшәүче татар әдипләре Марат Кәримов, Халисә Мөдәррисова, Дилә Булгакова һ. б. катнашты.

### ОСТАХАНӘЛӘРДӘ

3 апрельдә Татарстан Язучылар берлегендә әдәби тәнкыйть һәм проза остаханәләренең (житәкчеләре Мансур Вәлиев һәм Мәдинә Маликова) берләштерелгән утырышы булып узды. Аның көн тәртибенә соңгы елларда басылып чыккан әсәрләрдә әдәби геройның ни дәрәҗәдә сурәтләнүен ачыклау максаты белән "Безнең заман герое" дигән дискуссия оештыру мәсьәләсе куелган иде. Утырышка килгән әдипләр, тәнкыйтьчеләр, галимнәр бу проблеманың хәзерге әдәбият өчен актуаль булуын билгеләп үттеләр. Әлеге сөйләшү 2004 ел башыннан журналыбыз битләрендә дөнья күрә башлар дип уйланыла.

### ТЕАТР АТНАЛЫГЫ

Апрель аенда Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында балалар өчен театр атналыгы үтте. Тамашачыларга Мансур Гыйләҗевнең "Алтынбәк һәм Су кызы", Рәдиф Сәгъдинең "Гүзәл Аппаксылу", Дәржия Аппакованың "Тапкыр егет" әкиятләре, Руслан Садриевның "32 нче март" шоу-әкияте, Аманулланың "Светофорда кунакта" әкият-тамашасы, Фәнәвил Галиевнең "Мияубәк һәм Чичиета" әкияте һәм "Узма яшьлек заяга" рок-драмасы тәкъдим ителде. Атналык яшь казанлыларны театрга җәлеп итү максатыннан оештырылды.

### КАМИЛ МОТЫЙГЫЙНЫ ИСКӘ АЛЫП

Г. Тукай музеенда атаклы журналист, җырчы Камил Мотыйгыйның тууына 120 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булып узды. Тукай һәм Мотыйгый якын дуслар булган, бер мәдрәсәдә укыганнар. Уральск шәһәрендә бергәләп "Фикер" газетен һәм "Әльгасрелҗәдит" журналын чыгарганнар. Аннан соң Камил Мотыйгый бик абруйлы Каһирә мәдрәсәсендә укый. Туган ягына әйләнеп кайткач, журналист була. Гасыр башында ул җырчы буларак та популяр булган. Мотыйгый башкарган җырларның пластинкасы да сакланган. Кичәдә Камил Мотыйгыйның туганнары, нәсел дәвамчылары чыгыш ясады. Аның эш өстәлен, кульязмаларын, кара савытын, ул бик яратып уйнаган мандолинаны күрергә мөмкин иде. Очрашуда Казанның берәр урамына Мотыйгый исемен бирергә кирәк, дигән тәкъдим ясалды.

### ТУКАЙЧЫ ӘДИПЛӘР

28 март көнне Г. Тукай музеенда татар әдәбиятының күренекле әдипләре Әхмәт Фәйзинең тууына 100, Ибраһим Нуруллинның тууына 80 ел тулуга багышланган "Тукай эзләреннән" дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Бу чараның нәкъ Тукай музеенда үтүе очраклы түгел. Әхмәт Фәйзи— "Тукай" романының авторы. Ибраһим Нуруллин Казан дәүләт университетында укыган елларда ук татар халкының бөек шагыйре иҗатын өйрәнә башлап, тарихи-биографик характердагы хикәяләр һәм "Тукай Петербургта" дигән пьеса иҗат итеп, соңрак шуларны да кертеп "Атаклы

кешеләр тормышы" сериясеннән "Габдулла Тукай" дип исемләнгән китап язган кеше.

Күргәзмәдә Ә. Фәйзинең төрле елларда төшкән фотосурәтләрен, кульязмаларын, аның либреттоларына нигезләнеп куелган опералар афишаларын, И. Нуруллинның куен дәфтәрен, каләм савытын, 1942 елның ноябрендә, Әстерхан шәһәрен саклау өчен барган сугыш вакытында язучыны яралаган снаряд кыйпылчыгын күрергә мөмкин. "Тукай эзләреннән" күргәзмәсен ачу тантанасында Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан галимнәр, бу ике язучының да мирасын өйрәнгән әдәбият белгечләре, олуг әдипләрнең якыннары, туганнары катнашты.

## РӘШИТ ВАҺАПОВ КИЧӘСЕ

С. Сәйдәшев музеенда "Музыкаль Казан: XX гасыр. Иҗади портретлар" циклы кысаларында "Күңелем җыры" исемле искә алу кичәсе булып узды.

Ул Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһаповның тууына 95 ел тулуга багышланды. Р. Ваһапов татар профессиональ җыр сәнгатенә зур өлеш керткән мәшһүр җырчы иде. Аның башкаруындагы "Галиябану", "Асылъяр", "Зөләйха" кебек җырларга кем генә битараф калыр икән. Кичәдә Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров, Татарстанның халык артистлары Мингол Галиев, Рамил Курамшин, Гөлзадә Сафиуллина, Татарстанның атказанган артисткасы Җәваһирә Сәлахова, "Татарстан" журналының баш мөхәррире Рифат Фәттахов һәм Рәшит Ваһаповның туганнары үзләренең артист турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар.

## "АК КАЕННАР ЯКТЫСЫ"

3 мартта Камал театры бинасында Әлмәттә яшәп иҗат итүче язучы Нур Әхмәдиевнең иҗат кичәсе булды. Язучының дүрттомлык әсәрләре чыгу уңаеннан оештырылган кичәдә язучылар, артистлар, "Татнефть АҖ вәкилләре, депутатлар катнашты. "Ак каеннар яктысы" дип исемләнгән бу әдәби-музыкаль кичә Татарстанда нефть чыга башлауга 60, Әлмәт шәһәренә 50 ел тулуга багышланган чараларның берсе буларак уздырылды.

## БИЗӘКЛӘРГӘ ҖАН ӨРҮЧЕ КИТАП

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Сынлы сәнгать советы һәм Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасы тырышлыгы белән Гүзәл Вәлиева-Сөләймановабыың "Татар халык орнаменты" дигән китабын тәкъдир итү кичәсе үткәрелде.

Анда җиентык турындагы фикерләре белән кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү департаменты генераль директоры Нури Мостафаев һәм башкалар уртаклашты.

## КАЗАН УРАМЫ—ИҢ ЯХШЫСЫ

Төньяк башкалада үткән смотр-конкурс нәтиҗәләре буенча Санкт-Петербургның Казан урамы иң яхшы урам дип табылган.

Билгеле булганча, Татарстан башкаласы һәм Нева буендагы шәһәр арасында Санкт-Петербургның 300 еллыгы һәм Казанның 1000 еллыгы уңаеннан уртак чаралар үткәрү турында килешүгә кул куелган иде. Бу килешү нигезендә Казан төзүчеләре көче белән Санкт-Петербургның үзәгендәге Казан урамында 40 йортның фасадына капиталь ремонт ясалган.

Шушы эш җирле хакимият тарафыннан тиешенчә бәяләнгән дә инде. Санкт-Петербург губернаторы Владимир Яковлев Казан мэры Камил Исхаковка Татарстан башкаласы хакимиятенең Санкт-Петербургны төзекләндерүдәге ярдәме өчен рәхмәт хаты җибәргән. Ул шулай ук төньяк башкаланың Казан юбилеена әзерлектә һәм аны үткәрүдә актив катнашачагына ышандырды.

## ГАЛИМНӘР САФЫНА

Казан дәүләт университетының филология фәннәре буенча диссертацияләр яклау советы утырышында Алсу Гобәйдуллина "Фатих Кәрими сәяхәтнамәләренең һәм эпистоляр-публицистик әсәрләренең телен тикшерү" дигән темага (фәнни җитәкчесе филология фәннәре докторы, профессор Җ. Зәйнуллин) һәм Ләйсән Кадыйрова "Әхмәт Ясәви хикмәтләренең (Казан басмалары) лексика-семантика һәм стиль үзенчәлекләре" дигән темага (фәнни җитәкчесе филология фәннәре докторы, профессор В. Хаков) филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертацияләр яклады.

## Халыкара ТЮРКСОЙ бүләген бирү турында

***Халыкара ТЮРКСОЙ оешмасы мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә 2003 ел өчен халыкара ТЮРКСОЙ бүләге комиссиясенә гаризалар кабул итү башлануын белдерә.***

Оешманың максатлары һәм бурычлары кысасында халыкара ТЮРКСОЙ бүләгенә түбәндәге хезмәтләр тәкъдим ителә ала:

—әдәбият, музыка, сәхнә сәнгате, кинематография һәм телевидение, сынлы сәнгать һәм графика, архитектура, монументаль-пластик сәнгать, каллиграфия, декоратив-гамәли сәнгать, фотография һ. б. жанрлардагы оригиналь әсәрләр;

аерым галимнәрнең һәм авторлар төркемнәренең Төрки дөньясы мәдәниятен һәм сәнгатен алга таба да саклау, баету һәм үстерүгә этәргеч булырлык фәнни хезмәтләре;

—милли, төбәк һәм халыкара дәрәҗәдә югары бәя алган мәдәни программалар һәм проектлар.

*Кандидатларны билгеләү тәртибе*

ТЮРКСОЙ әгъзалары булган илләрнең Мәдәният министрлыклары, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге халыкара оешмалар, профильле иҗат һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре, иҗат берлекләре, гаммәви мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый хәрәкәтләр 2003 ел өчен халыкара ТЮРКСОЙ бүләген бирү буенча үз тәкъдимнәрен, 2003 елның 1 августыннан да соңга калмыйча, түбәндәге адрес буенча юллый ала:

***TÜRKSOY,***
***ATAC SOKAK, №19.***
***YENISEHIR /ANKARA-TÜRKIYE***
***Тел. (90-312) 4353161; 4312006***
***Faks (90-312) 4352760***
***E-mail: turksoy@turksoy.org.tr***

Халыкара ТЮРКСОЙ бүләгенә тәкъдим ителгән әсәрләр 2001 елның 1 гыйнварыннан соң иҗат ителгән булырга тиеш. Тәкъдим итү документлары белән бергә бүләкне дәгъва итүче авторның тәрҗемәви хәле, 4 данә фотосурәте (үлчәме 4х5), әсәрнең төп нөсхәсе яисә күчермәсе (копиясе), әгәр булса, авторның башка әсәрләре исемлеге, шулай ук, фотослайдлар, микрофильмнар, аудио-видео кассеталар, нота материаллары һ. б.ларның да булуы шарт.

Әсәрнең тексты төрек һәм рус телләренә тәрҗемә ителгән булырга тиеш.

Бүләкне дәгъва итүчеләр өчен милләт һәм яшь цензы каралмаган.

*Әсәрләрне сайлап алу һәм бәяләү тәртибе*

Бүләкне дәгъва кылучыларның әсәрләрен кабул итү, сайлау һәм башлангыч бәяләмәләр куюны ТЮРКСОЙның Генераль дирекциясе һәм белгечләрдән төзелгән бәяләү комиссиясе хәл итә.

Халыкара ТЮРКСОЙ бүләген бирү турындагы карар төрки телле илләрнең мәдәният министрлары даими Советы утырышында 2003 ел ахырында кабул кылына һәм игълан ителә. Акчалата бүләк—15.000 АКШ доллары күләмендә.

Бүләк авторлар төркеменә бирелгән очракта, аның символы һәр авторга тапшырыла, акчалата бүләк үзара бүленә. Халыкара ТЮРКСОЙ бүләге турындагы низамнамә шартларына җавап бирерлек әсәр табылмаган очракта бүләк бирелми.

Бүләккә лаек дип табылмаган әсәрләр авторларына кире кайтарыла.

***Белешмәләр өчен түбәндәге телефоннар: 92-05-03, 92-75-20***

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ХАННАР ХӘЗИНӘСЕ ЯДКАРЕ

Мәдәниятебез хәзинәсенең асыл сыйфатларын гәүдәләндергән бу затлы Коръән савытын мин берничә дистә ел буе эзләдем... Аның хакында Казан император университеты каршындагы Гыйльми җәмгыять чыгарган фәнни язмаларда тарихчы-галим В. Вельяминов-Зернов язып калдырган (1869 ел). Анда шулай ук князь М. А. Оболенский тупланмасында сакланган "көмеш Коръән савытының" төсле литографиясе басылган иде. Савыт өстендәге татарча һәм гарәпчә текстларны укыган галим бу затлы савытның хуҗасы Касыйм ханлыгы патшасының имилдәше—Карамыш улы Ишанай, дип фаразлый. Имилдәш—ханнын яисә берәр аксөякнең имчәк туганы дигән сүз. Күпме эзләнсәм дә Мәскәүдәге Корал пулатында, Санкт-Петербург һәм чит ил музейларында әйтеп үткән савытның оригиналы белән очрашырга туры килмәде. Һәм менә 2001-02 елларның кышында Милли мәдәни үзәккә Санкт-Петербургтан "Ислам сәнгате" дигән зур күргәзмә килеп төште. Мондагы дөньякүләм мәшһүр раритетлар арасында кайчандыр рәсемен генә күргән гүзәл Коръән савытының самими карендәше килеп чыкты. Ул сикәлтәле тарихи юллар үтеп, Эрмитаж музеена 1930 елны Дәүләт Азия музееннан килеп кергән. Хуҗасы—Касыйм патшасы Ураз-Мөхәммәд (1592-1610 елларда идарә итә). Ике тартмачыкның да массасы—300 грамм тирәсе (70-71 золотник—4.25 гр.), формасы һәм бизәлү ысуллары, конструктив принциплары да охшаш. Алар конверт-китап формасында эшләнгәннәр; мондый китап "кап"ларының тукымадан эшләнгән вариантлары татар авылларында әле дә очрый, һәм бу форма, шулай ук, футляр сыман күн китап тышларында да кабатлана. Шунысы кызык, бу асыл савыт изге Коръәнне бил каешына беркетеп саклау өчен кулланылган. Ерак сәфәрләрдә дә асылзатлар изге сүздән аерылырга теләмәгән. Эшләнү вакыты: Ураз-Мөхәммәднеке (текстның укылу вариантлары буенча) 1593-1594 яисә 1603-1604 еллар, Ишанайныкы—1612 ел. Ишанай Күчүм оныгы Алып-Арыслан ханлык иткән 1614-1627 елларда яши. Касыйм шәһәре посадындагы каберташта аның 1618 елда вафат булуы турында хәбәр бирелә. Һәр ике савытның башкару стиле бер, аларның авторының да бер оста булуы шөбһәсез. "Нәсх" ысулы белән башкарылган, өсләренә алтынсу йөгертелгән түгәрәк һәм озынча картушалардагы текстлар тартма эченә җыйнак кына бизәк сыман кереп утыралар, "өч-яфрак", "кош каурые" тибындагы уйма орнамент уйнаган көмеш яссылык эченә сыйдырылган "Исеме-әгъзам" догасы асылташ терәкләрне хәтерләткән фирәзә кашлар исәбенә аерым бер тотрыклылык, тантана төсе ала. Боларның барысы да әсәрнең тирән уйланылганлыгы һәм зәргәрнең зур профессиональ камиллеге турында сөйли.

Бу типтагы тартмачыклар, Казан ханлыгы һәм аның ювелир-зәркән сәнгате өчен типологик әйбер. Аның традициясе, мең төрле модификацияләргә, вариантларга кереп, Казан халкы культурасында XVIII-XIX, XX гасырларга кадәр килеп җитә. Казан музейлары безгә бу әйберләрнең соңгы чорларга караган бик күп үрнәкләрен китереп житкергәннәр.

Мәдәниятебезнең дөньякүләм югары сыйфатларын саклап бүгенге көннәргә кадәр китергән Коръән савытлары тарихыбызның бербөтенлеген күрсәткән сәнгать ядкаре, гомуммиллләт рухани символы, югары культура чагылышы да ул.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече.*

**Тышлыкның беренче битендә:** Ураз-Мөхәммәд ханның Коръән савыты.
**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Индус Сирматов.

## Якуб Зәнкиев

Төмән өлкәсенең Хужайлан авылыннан Казан каласына кайгылы хәбәр килеп иреште: 7 март көнне өлкән язучыбыз, Бөек Ватан сугышы ветераны Якуб Зәнкиев 86 яшендә вафат булган...

Якуб Камали улы Зәнкиев 1917 елның 6 апрелендә Иркутск шәһәрендә дөньяга килгән. Аның әтисе Камали Төмән өлкәсенең Тубыл районындагы Хужайлан авылында бер дигән һөнәр остасы саналган, әнисе Татарстанның Нурлат районындагы Эрә авылыннан Вәлит мәзин кызы—укымышлы Зәкирәбану булган. Шуңа күрә дә Якуб кечкенәдән үк затлы-зыялы гаиләдә тәрбияләнеп үсә. Һәм үзе дә гомерен күңелләргә яктылык өләшүгә, мөгаллимлек итүгә багышлый. 40 ел дәвамында балаларга төпле ан-белем, ныклы тәрбия бирүче Якуб ага Зәнкиев «Россия Федерациясе мәктәпләренең атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була. Себердә, үзе яшәгән төбәк мәктәпләрендә балаларны татар әдәби телендә укыту буенча да сокланырлык уңышларга ирешә.


Бер үк вакытта Якуб Зәнкиев журналистика, әдәби иҗат эше белән дә ныклап шөгыльләнә. Аның көн кадагына суккан үтемле язмалары, очерк-зарисовкалары, әдәби тәнкыйть мәкаләләре район һәм өлкә матбугатында һәм Татарстанда чыгучы төрле газет-журналларда әледән-әле күренеп тора. Ул үзен фольклорчы буларак та таныта: укучыларыбызны Төмән татарлары хәяте, гореф-гадәтләре, татар әдәби телендә борынгы төркилек чалымнары аеруча нык сакланган Себер шивәсе белән якыннан таныштыра.

Якуб ага Зәнкиевнең укучыларыбыз күңелендә киң яңгыраш тапкан «Иртеш таңнары», «Ялкында өтелгән мәхәббәт» романнары (аларның һәр икесе дә иң элек «Казан утлары» журналында басылып чыкты, аннары аерым китаплар рәвешендә дөнья күрделәр), «Кайчыколак», «Луноликая Сүзге» кебек хикәяләр җыентыклары күп гасырлык татар әдәбияты хәзинәсен тагын да баетты. Татарстан китап нәшриятында нәшер ителгән «Иртеш таңнары» романы өчен Я. Зәнкиев 2002 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Яу кырында күрсәткән батырлыклары I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм күпсанлы медальләр, тыныч хезмәттәге фидакярлеге исә Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең югары бүләкләре белән бәяләп үтелгән Якуб Камали улы Зәнкиевнең— туры сүзле, көчле рухлы олпат каләмдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе.

# ЯҢА КИТАПЛАР



Соңгы елларда Татарстан хөкүмәтенең булышлыгы белән бүгенге әдәбиятны әйдәп баручы күренекле язучыларыбызның күптомлык сайланма әсәрләре дөнья күрә башлады. Үткән елда драматург Туфан Миңнуллинның 10 томлыгы, Шәүкәт Галиев, Нурихан Фәттах, Әхсән Баяннарның бишәр томлыклары басылды. Беренчеләрдән булып шагыйрь Илдар Юзеевның томлыклары чыкты. 300, 500 битләрдән торган бу китапларга әдип иҗатының төп әсәрләре кергән. I-III томлыкларда, нигездә, шигырьләр, поэмалар, истәлекләр тупланса, IV-V томнарда шагыйрьнең сәхнә әсәрләре урын алган. Беренче томлыкның кереш өлешендә шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев турында шагыйрьләр Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Зөлфәт һәм әдәбият галиме Азат Әхмәдуллиннарның фикерләре туплап бирелгән. Татарстан китап нәшриятында нәшер ителә торган бу күптомлыклар махсус редколлегия җаваплылыгында дөньяга чыгарыла.

Томлыкларның тиражы—3000 данә.

Мөхәррире—**Рафис Корбан**, бизәлеш мөхәррире—**Рушан Шәмсетдинов**.

Индекс 73210



Индус Сирматов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)